2. Газеттің ішкі құрылымына тән лексикалық ерекшеліктер. Газет айдарларының лексикалық, лингвостилистикалық құрылысы. Газет айдарлары, басқаша айтқанда, «рубрикалар» – газеттің ішкі құрылымынан хабардар ететін, оны танытатын басты компоненттерінің бірі. «Семей таңында» айдарлардың біршамасы құрылымы жағынан тұтас, бір ғана мәселеден хабар береді. Айта кететін болсақ, «Облыс жаңалықтары», «Баспасөз маслихаты», «Қоғамдық қабылдау», «Заң және заман», «Бастауыш ұйым жиыны» [1] т. б. айдарларды қарастырсақ, бұл жердегі мақалалар тек арнайы бір тақырыптардан мағлұмат береді. Бұл не саяси жиын, не жаңа қабылданған заңға қатысты отырыс, арнайы талқылама, т. с. с мәселелерді қамтиды. Бұлардың кейбірі жасырын тұрған ілік септігінің тұлғасын қабылдап тұрғандығын көре аламыз, яғни кімнің? деген дүниенің астарын ашып отыр. Байқағанымыздай, бұған ұқсас айдарлар кез келген сөздердің қосарлануынан жасала бермейді, компоненттер көбіне қоғамдағы маңызды мәселелер мен ұғымдар атаулары болып келеді де, күрделі сөз тіркесуі нәтижесінде екі сөздің де негізгі мағынасын жинақтап бере алады.

3. Газеттің тақырыптық ерекшеліктері. Газет мақалаларын оқуға кірісерден бұрын, ең бірінші назар аударатын дүниеңіз – оның тақырыбы. «Семей таңы» – әрбір отбасының, шаңырақтың, жұрттың көзі, ойы мен көзқарасы.Сондықтан да басылымның тақырыптық ауқымы кең, сан қырлы десе де болады. Енді тақырыптық ерекшеліктеріне көз жүгіртсек: *а) Кең көлемді қамтуы; ә) Аймақ тынысы; б) Әлеуметтік мәселенің қамтылуы; в) Тыйым, дәстүр және кеңес беруге бет бұру.*

Кез келген басылым міндетті түрде сан алуан кеңестерден, пікірлерден, тәжірибелерімен бөлісуден тұратын мақалаларға толы болып келетіні сөзсіз. «Семей таңы» да бұл жайттан құр қалмаған, өз кезегінде халыққа қажет болар, пайдасы тиер деген ақпаратты қамтитын қаламгерлердің еңбегінен тұрады. Кейбірі халық медицинасы, ем-дом жолдары, одан әрі тұрмыс құрудың жолдары, алданып қалмаудың жолдары сынды шексіз тақырыптарда сөз қозғалады.

4. Жанр ерекшеліктері.Жаңалық – адамдар бұрын естімеген тың нәрсе. Жанр – сол жаңалықтың көрініс табу формасы. Жанр – тұрақты, бірнеше жылдар бойы сол күйінде қала береді, түбірімен өзгеріске ұшырамайды. «Семей таңы» газетінде мақалалар хроника, интервью және репортаж жанры түрінде кездеседі.

5. Тілдік және стильдік ерекшеліктері. Жазылатын мақаланың тілі мен стиліне журналист көп көңіл бөлуі тиіс. Тілдің түсініктілігі, әсерлілігі, көркемділігі үйлескен жағдайда ғана оқырманның қызығушылығы оянып, мақаланың қадірі артпақ. Журналисттің басты мақсаты – қазақтың бай да, көркем тілін ұтымды пайдалану. Бастысы – қаламгердің ақпаратты неғұрлым қарапайым жеткізуінде, себебі, өңшең теңеулер мен көркемдегіш құралдарды пайдалана отырып не болмаса лексикалық нормаға сай келмейтін сөз оралымдарын келтірер болса, мақаланың құндылығы жойылады. Оқырманның бәрі лингвист деуге келмейді, қарапайым халық, демек, мақаланың тілі де соған сай жазылуы тиіс.

Баспасөз құралдарының қызметі әр түрлі ой-пікірлер мен көзқарастарды шапшаң таратып, ақпаратты жедел түрде тасымалдау. «Семей таңы» газеті аймақтағы және облыстағы жағымды жаңалықтар, қоғамға қажетті деректер, халықтың табыстары мен тартыстары, мәдениет пен әдебиет жетістіктерін сөз етіп, ғылымның түрлі салаларынан да терең мағұлмат беруде теңдесі жоқ жазбалар жариялауда. Мақалалары сан қилы тақырыптарға арналып, халықтың назарын ең елеулі, көкейкесті дейтін мәселелерге аудару арқылы тек қажетті дүниемен сусындауын қамтамасыз етуде.

**Әдебиет**

1. Семей таңы. – №7 (18766). – 26 қаңтар. – 2018 жыл.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «АНА» ЛЕКСЕМАСЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Әсхәдуллина Г., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хөснетдинов Д.Х.*

Татар телендә “ана” һәм “әни” дигән бер үк төшенчәне аңлата торган ике термин бар. Аның беренчесе күбесенчә әдәби телдә норма буларак кулланылса, икенчесе беренчесенең алгы рәт варианты буларак формалашкан һәм узуаль мөрәҗәгать формасы булып хезмәт итә [3: 190].

*Ана* сүзенең этимологиясе гомумтөрки телләрдә “ана” сүзе белән бәйләнгән. *Әни* сүзе шуның нечкәртелгән варианты гына. Хәзерге татар

телендә *әни* сүзе анага мөрәҗәгать иткәндә, эндәшкәндә яки балалар аның турында сөйләгәндә әйтелә.

Р. Әхмәтьяновның “Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге”ндә *ана* сүзенә түбәндәге аңлатма бирелә:

Ана – «мать» – гомумтөрки ана “ана, ана хайван” сүзеннән. Дөньядагы барлык телләрдә охшаш яңгырашлы булган типологик ымлык тамырдан; кара: чуваш ама “ана”, һинд-европа ami “ана, әни”, элам. Амма “ана”, гарәп амма “ана; нигез, чыгыш” [1: 272].

*Ана теле* һәм шуның белән беррәттән *туган тел* сүзтезмәләре татар лингвомәдәниятенең мөһим элементын тәшкил итәләр, бу паремияләрдә дә чагылыш таба:

*Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел;*

*Иң татлысы туган тел – анам сөйләп торган тел.*

Мәгълүм ки, рус лингвомәдәниятенә бу хас түгел, ә менә Европа телләре өчен мондый хәл табигый.

Тагын шунысын билгеләп үтәргә кирәк: *ана* термины кергән фразеологизмнар түземсез кешеләргә төрттерү *(Анасының карынында ничек тугыз ай да ун көн чыдап торган)*, сабыр булырга кирәклеген искәртү *(Ана карыныннан да чыккансың)* максатыннан да кулланыла. *Ана* лексемасы түбәндәге фразеологизмнарда күзәтелә:

*Аналары белән кояшта киндер киптергән* – туганлык мөнәсәбәтендә тормаган кешеләр, ә *ана куеныннан чыкмаган* дип тормыш тәҗрибәсе күрмәгән, хезмәт белмәгән, йомшак, иркә кеше турында әйтәләр. Шыр ялангач, шәрә кеше турында *анадан тума* диләр. *Ана карынында яткан кебек* дип бар нәрсәсе дә әзер кешегә, *Ана күргән* фразеологизмы ана тәрбиясе алып үскән кешегә карата әйтелә. *Авызында анасы* – гел сүгенүче кеше. *Анаң танымаслык итү* – кешене үзгәртү; *Монысы мәсьәләнең баласы гына, менә монда анасы* – бу әле эшнең башы гына, зуррагы алда көтелә; *Кортның анасы әләкте* – абруйлы, акыллы, йогынтылы кешеләр белән танышу.

Татар халык мәкальләрендә ана һәм баланың күпкырлы мөнәсәбәтләре гәүдәләндерелә. Бик борынгы заманнардан ук ана мәхәббәте турында мәкальләр килеп житкән, һәм алар бик күп. Анага булган мәхәббәт күп кенә мәкальләрдә Туган илгә булган мәхәббәткә килеп тоташа:

*Ата-ана йорты – алтын бишек.*

*Туган илең – туган анаң.*

Анага карата кайгыртучанлык тәрбияләмичә, рухи бай, әхлаклы кеше тәрбияләү мөмкин түгел. Ата-анага булган мөнәсәбәтләргә карап, кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләр корыла. Татар халык мәкальләрендә ананың балага булган мәхәббәте ай нуры һәм кояш яктылыгы белән чагыштырыла:

*Яктылык – кояш янында, яхшылык – ана янында.*

*Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек.*

Алга таба татар халык паремиологиясендә ана образының чагылышын күзәтик. *Үги ана* турындагы мәкаль һәм әйтемнәр дә бар:

*Ана юкта үги ана да яхшы.*

*Анаң үги булса, атаң үзеңнеке булмас.*

Һәм, киресенчә, анасыз балага анасы булган бала каршы куела:

*Аналы баланың үзе тук, анасыз баланың күзе тук.*

*Аналы ятим – ярты ятим.*

Татар халкы аңындагы ана лексемасының чагылышын без халык авыз иҗаты үрнәкләрендә генә түгел, матур әдәбият әсәрләрендә, төрле характердагы язмаларда да күрәбез. Мәсәлән, Р. Фәхретдин үзенең "Тәрбияле ана" китабында болай дип яза: <...*Халыкның яхшы вә усал улмакларында күп вакытта аналарның да катышы уладыр... Тәрбияле аналар үз балаларына гына улмай, бәлки мөселманнарның барчасына хөрмәтле ана улмакдалардыр ... Аналарның хезмәтләре – иң авыр вә иң мәшәкатьле хезмәттер, аны язып бетерерлек, тел илә сөйләп бәян кыйлырлык түгелдер...*>.

Татар лингвомәдәниятендә *ана сөте* төшенчәсе мөһим символ булып тора, һәм ул фольклорда да, хәзерге татар әдәбиятында да еш очрый:

*Туган тел ул тәндә, җанда калсын,*

*Ана сөте булып гомергә,*

*Бер авылмы, ике авылмы ул,*

*Сайрашсыннар ана телендә* [4: 255].

Гомумән, татар язучылары һәм шагыйрьләре тарафыннан әниләр турында бик күп әсәрләр, шигырьләр язылган. Мисал итеп Әмирхан Еникине генә алыйк. Аның әниләр турында язган әсәрләре бик күп: «Матурлык», «Әйтелмәгән васыять», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» һ. б. Кешенең рухи байлыгын сурәтләгән әсәрләр исемлегенә Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясен дә кертеп була. Бу әсәрендә язучы баланың анага булган тирән мәхәббәтен сурәтли. Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасында да үзәктә Ана образы тора. Әсәрдә аның исеме дә бирелми, чөнки бу – барлык аналарны берләштергән образ. Ш. Хөсәеновның *Ана кешенең колагы ишетмәсә, йөрәге ишетә* дигән сүзләре канатлы гыйбарә буларак яңгырый, һәм *ана* лексемасының татар дөнья сурәтендәге үзенчәлеген дә чагылдыра.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар . кит. нәшр., 1963. – Т. 2. – Б. 245.

3. Рамазанова Д.Б. Термины родства и свойства в татарском языке. В 2-х кн. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1991. – 190 с.

4. Юзиев И. Г. Төнбоек: шигырьләр, җырлар, поэмалар – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 255 б.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ БӘЙЛӘНЕШЕ: ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ «ШҮРӘЛЕ» ПОЭМАСЫНА ЯСАЛГАН ИЛЛЮСТРАЦИЯЛӘР

*Әхмәдиева Й., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Сайфулина Ф.С.*

Иллюстрация – ул әдәбиятта сүз ярдәмендә чагылыш тапкан образлы эчтәлекне сынлы сәнгать чаралары белән ачу, дип билгели күренекле сәнгатьче А.А. Сидоров. Әлеге мәкаләбезнең **максаты** – Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасы образларының рәсем сәнгатендә чагылышы. Эшебезнең төп **өйрәнү объектлары** – Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасы һәм әсәр нигезендә ясалган рәсем үрнәкләре.

Танылган театр тәнкыйтьчесе Габдрахман Кәрам фикеренчә, “Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр. Аның шигырьләре буыннан буынга калып, миллионнарча балаларыбыз тарафыннан ятланачак вә аның шанлы исеме мәңгегә онытылмаячак” [1: 13]. Тукай иҗатын өйрәнүнең дистә елдан артык тарихы булуы, бүгенге көндә дә Г. Кәрами фикеренең дәлиле булып тора. Тормышны алдан күрә белгән шагыйрь киләчәк – балалар кулында икәнлеген аңлый. Сабыйлар милләтпәрвәр, күпкырлы белемле, тәрбияле шәхес булып үссен өчен, туган телгә, гаиләгә, өлкәннәргә, табигатькә ихтирам, тәрбияләү кечкенә чактан ук зарур дип саный. Шулай ук, Тукайны балалар өчен язарга мәҗбүр иткән нәрсә, шөбһәсез, балалык чорында алган шәхси тәҗрибәсе.

Мәктәп чорында исә бала өчен шигъриятнең әһәмиятле икәне билгеле. Баланың күңеле саф, ышанучан, хыялый була һәм шул дәвердә Тукай балалар өчен киң хыял дөньясы ача. Әдип үзе исән вакытта ук дөнья күргән 34 китабыннан, 16 сын сабыйларга багышлый. Г. Тукай халык иҗатына, мифологиягә, фольклорга, экиятләргә таяна. Аның «Су анасы», «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык» поэмаларына никадәр экияти тылсым салынган. Шуны да әйтергә кирәк, Тукай сабый күңелен аңлап, аңа гына хас булган нәфислек, эчке җылылык һәм табигый рәвештә язылган әсәрләре талантлы рәссамнар өчен саекмас илһам чишмәсе булып тора.

Тукай иҗаты темасына беренче иллюстрацияләр әдип исән вакыттагы матбугатта 1906 елдан башлап дөнья күрә. Алар – билгесез рәссам эше (имзасы «НК») дип бирелгән. Шул ук елларда “Кәҗә белән сарык” экияте, балалар өчен шигырьләр җыентыгы иллюстрацияләнә. Рәссамнарның исемнәре билгесез, ә иллюстрацияләр профессиональ яктан югары дәрәҗәдә дип әйтеп булмый. Ләкин бу иллюстрацияләр 1920 нче елларда И. Плещинский, Ш. Мөхәммәдҗанов, Г. Арсланов, Б. Урманче

кебек рәссамнарның профессиональ сәнгатен формалаштыруга этәргеч һәм зур йогынты ясый [3].

Әдәби әсәргә нигезләнеп ясалган рәсем, әсәрне тирәнрәк аңлау өчен хезмәт итә, безне кызыксындырганы исә Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасына ясалган рәсемнәр. Алар аеруча балаларга, мәктәп балаларына текстны җиңелерәк аңлау, эчтәлегенә төшенү өчен кирәк.

Тукайны, аның әсәрләрен югары кимәлдә рәсемләгән сурәтчеләр күп түгел. Шулай да Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасына күп кенә иллюстрацияләр ясаганнар. Кайберләренә тукталып китик.

Узган гасырның 20 нче елларында ук танылган скульптор, рәссам Бакый Урманче беренче иллюстрацияләрен иҗат итә. Б. Урманче сурәтләгән Шүрәле бик үзенчәлекле ясалган. Әлеге мифологик образны рәссам алтынсу-кызгылт сары, яшел төсләрне актив кулланып ясаган. Урманда яшәп, кеше күзенә артык чалынмаска тиешле әлеге мифологик җан иясен рәссам шулай күрә. Шул рәвешле ак фонда күбәләкләр, яфраклар, табигать сурәте эчендә беркатлы, ышатучан Шүрәле образы үзенчәлекле, отышлы, кызыклы итеп тасвирланган.

Икенче рәссам Ф. Әминов оста иҗат иткән “Шүрәле урманы”на мистик төсмер бирелгән. Шүрәле образын исә шушы табигатьнең бер өлеше буларак гәүдәләнеш алган. Әлеге рәсемгә карагач, Тукай шигыре юллары күз алдына килеп баса:

Билгеле, бу кап-кара урманда һәртөрле ерткыч та бар;
Юк түгел аю, бүре; төлке – җиһан корткыч та бар...
Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр;
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр [2: 62].

Әлеге образны тудыруга зур өлеш керткән рәссам Байназар Әлминов 1930 елларда әдипнең әсәрләрен иллюстрацияләүгә керешә. Башта «Шүрәле» поэмасын рәссам каләм белән ясалган aклы-каралы рәсемдә гәүдәләндерә. Соңрак исә ачык төсләр белән кыю рәвештә Тукайның «Шүрәле» һәм башка экиятләренә иллюстрацияләр ясый. Реалистик композицияләрдә төсләрнең роле бик зур. Шуны истә тотып Б. Әлминов төсләрне дөрес сайлауда, Тукай геройларының экияти дөньясы чагылыш тапкан. Бу бигрәк тә балалар өчен таныш һәм якын.

Шүрәле фәрьяд итәдер, аудан ычкынмак була
Һәм дә, ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була.
Кычкырв: “Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?” [2: 78].

Безнеңчә, фронтовик рәссам Байназар Әлминовның рәсемнәре Тукай тудырган әлеге мифологик образны бик уңышлы биргән. Бүгенге көндә балаларның Шүрәле” һәм “Су анасы” китаплары аның рәсемнәре белән нәшер ителгән.

Г. Тукайның “Шүрәле” поэмасына гына ясалган иллюстрацияләр белән генә танышып чыгып та, шагыйрьнең образлар дөньясы байлыгы – рәссамнар өчен дә бай илһам чыганагы булуын әйтергә мөмкин.

**Әдәбият**


1. Тукай Г.М. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр / төз. һәм кереш сүз авт. Ф. Бәшир; икенче басма. – Казан: атар. кит. нәшр., 2010. – 479 б.
2. Шакирова Т.Р., Хәйдарова Г.Ф. Тукай иленә сәяхәт = Путешествие в мир Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 127 б.
3. http://gabdullatukay.ru/in-art/in-graphics/tukaj-shigriyatenen-tylsymy/


## ФЭНТЕЗИ ӘСӘРЛӘРЕН ТӨРКИ ТЕЛЛӘРГӘ ҺӘВӘСКӘРИ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ МӘСЬӘЛӘСЕ


*Әхмәтгәрәева Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Фәтхуллова К.С.*


Фәнни прогресс нәтиҗәсендә барлыкка килеп, күпсанлы һәлакәтләргә канәгатьсезлек формасы буларак XX нче гасырда формалашкан фэнтези жанры шактый күп белгечләр тарафыннан өйрәнелә, аның жанр табигате күптөрле бәхәсләр уята (F.N. Magill, K. Neilson, P. Hunt, M. Lenz, В.М. Беренкова, С.А. Гоголева, В.С. Толкачева һ.б.). Ләкин хәзерге фәндә ул инде мөстәкыйль жанр буларак таныла һәм үзенчәлекле яклары аерылып чыгарыла. Фэнтези – ул фәнни фантастика һәм әдәби әкият жанрларына якын торган, фольклор һәм мифология материалларын эшкәртеп, төп концептлары яхшылык һәм явызлык булган, маҗаралы вакыйгаларны магия тулы иррациональ һәм ирреаль дөньяда сурәтләгән матур әдәбият жанры.

Британ әдәби традициясен һәм фэнтези жанрын күркәм үстереп җибәргән Джоан Роулинг та үзенең Һарри Поттер турындагы китапларында хәзерге чынбарлык белән беррәттән яшәгән тылсым дөньясын булдыра, төп мотивы яхшылык һәм явызлык көрәше булган әсәрләрендә геройның маҗараларын тергезә, моның өчен, архаик миф һәм кельт мифологиясенә нигезләнеп, махсус поэтик максатларда яңа әдәби миф тудыра.

Поттериананың дөньяда миллионлаган фанатлары бар, алар рәсми тәрҗемәләр буенча фикер алышалар, еш кына үзләре дә китапларны тәрҗемә итәләр, аларны социаль челтәрләрдә урнаштыралар. Һарри Поттер турындагы китапларның татар һәм казах телләренә тәрҗемә ителүе дә шул мәсләкле була.

Соңгы елларда фәнни әдәбиятта «фанфикшн» төшенчәсе активлашты: элек жаргон төсендә кулланылган әлеге термин бүгенге көндә аерым бер тикшеренү өлкәсенә әверелде һәм «акча табу максатын эзәрлекләмәгән, җанатарлар тарафыннан танылган мәдәният феноменнары элементларын кулланып төзелгән һәвәскәри әдәби иҗат» мәгънәсен йөртә [3]. Без аналогия буенча фэнтези әсәрләрен татар һәм казах телләренә һәвәскәри тәрҗемә итү феноменын тикшерергә булдык. Алар да

коммерция максатын күз уңында тотмый. Нигә әлеге һәвәскәри тәрҗемәчеләр чит ил бестселлерларына алына? Гареб әдәбиятының фэнтези чынбарлыгын төрки нигезгә күчерү зыянлы түгелме?

Джоан Роулинг китапларын («Harry Potter and the Philosopher's Stone», «Harry Potter and the Chamber of Secrets», «Harry Potter and the Cursed Child»), ягъни гепталогиянең беренче ике китабын һәм 2016 нчы елны Джек Торн һәм Джон Тиффани белән авторлыкта дөнья күргән пьесаны «Гыйлем» берләшмәсе каршындагы potter.tatar берлеге тәрҗемә итә («Һарри Поттер һәм Фәлсәфәче ташы», «Һарри Поттер һәм Серләр бүлмәсе», «Һарри Поттер һәм Ләгънәтле бала»). Әйтергә кирәк, «Һарри Поттер» әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүнең беренче омтылышы 2000 нче еллар уртасында ук була: «Сабантуй» газетасында Ләлә Гыймадиева тәрҗемәсендәге беренче китапның берничә өзеге бастырыла. «Гыйлем» фән һәм мәгърифәт үзәге җитәкчесе Айдар Шәйхин исә «Һарри Поттер»ны Актанышта укыганда ук тәрҗемә итеп карый: гимназия газетасында бишенче китапның беренче бүлеге һәм беренче китапның берничә бүлеге дөнья күрә.

Татар телендәге соңгы тәрҗемәләр турыдан-туры инглиз теленнән башкарыла. Герой исемнәре «Росмэн» нәшрияты китапларына якын тора, алар транлитерация һәм транскрипция ысуллары белән күчерелә, ләкин кисешмәгән урыннар да очрый (мәсәлән, Северус Снейп, Невилл Лонгботтом, Профессор Спраут). Әлеге факт рус телендәге «Росмэн» һәм Мария Спивак тәрҗемәләре көрәшен күрсәтә. Татар тәрҗемәчеләре Спивакның аудиторияне балаларда гына күрүенә һәм герой исемнәрен артык гадиләштерүгә каршы чыга.

Әлеге саваплы эшкә алынуның сәбәпләрен Айдар Шәйхин түбәндәгечә аңлата: «Миңа Һарриның татарча фикерләве, татарча уйлавы кирәк иде. Шушы популяр китапны тәрҗемә итеп, телгә кызыксыну уятырга тырыштык. Элек тә популяр китаплар тәрҗемә ителгән, нишләп әле бу эшне җанландырмаска? Үзем Робинзон Крузо маҗараларын татарча укып үстем. Мәсьәләнең икенче ягы да бар: татар әдәбиятында фантастика жанры торгынлык кичерә. Ә яшүсмерләргә тылсымлы әсәрләр кирәк» [1].

Асылда исә фэнтези жанры татар әдәбиятына чит түгел. Аның әкияти һәм фантастик элементларга бай булуы укучы аңында татар халык авыз иҗатындагы һәм әдәби традицияләрдәге ассоциацияләрне уята (К. Насыйри «Әбүгалиниса», Р. Батулла «Алып батыр маҗаралары» һ.б.).

Джоан Роулингның Һарри Поттер турындагы беренче китабы казах теленә 2016 нчы елны Актүбәнең Назарбаев ис. Интеллектуаль мәктәбе укучысы Асылай Сейтенова тарафыннан тәрҗемә ителә («Гарри Поттер және Философиялық тас»). Ул тулы бер проект рәвешендә чынга ашырыла һәм лингводидактик максатларны күз уңында тота: әлеге тәрҗемәләр казах

телен өйрәнүне җиңеләйтергә тиеш була. Әлеге проект инглиз теле укытучысы ярдәмендә башкарыла һәм мәктәпнең башка укучысы – Олжас Есенбаев сурәтләре белән баетыла [2]. Казах теленә тәрҗемә шулай ук турыдан-туры инглиз теленнән башкарыла. Вакыт-вакыт «Росмэн» тәрҗемәләре дә файдаланыла. Герой исемнәре рус тәрҗемәләрендәге кебек кала (мәсәлән, Гарри Поттер). Автор шулай ук акча табу максатын күз уңында тотмавын һәм эшне үстерер өчен, кызганычка каршы, авторлык хокукларының юклыгына басым ясый.

Шулай итеп, фэнтези әдәбиятын тәрҗемә итү – җитди тикшеренүләрне таләп иткән катлаулы һәм үзенчәлекле күренеш. Ул төрки телләрне, аерым алганда татар һәм казах телләрен дөнья мәйданына интеграцияләргә сәләтле. «Гыйлем» берләшмәсе каршындагы potter.tatar берлегенең һәм Асылай Сейтенованың «Һарри Поттер» китапларын арадаш рус теленнән башка турыдан-туры инглиз теленнән татар һәм казах телләренә һәвәскәри тәрҗемәләре дә шуны дәлилли.

**Әдәбият**

1. Айдар Шәйхин: «Һарри Поттер татар фантастларын уятып җибәрер дигән өмет» // https://realnoevremya.ru/articles/73512-intervyu-s-koordinatorom-perevoda-garri-pottera-na-tatarskiy.

2. Ученица НИШ из Актобе перевела «Гарри Поттера» на казахский язык // today.kz/news/kazahstan/2016-04-26/715759-uchenitsa-nish-iz-aktobe-perevela-garri-pottera-na-kazahskij-yazyik.

3. Шавлюк В.Б. «Фанфикшн»: от жаргонизма к термину // Вестник Нижегородского университета им. Н.И. Лобачевского. – 2017. – № 1. – С. 245–249.

## МИЛЛИ ХАРАКТЕР − БАТЫРЛЫК ЧЫГАНАГЫ

*Әхмәтова Л., Яр Чаллы педагогия көллияте, I курс студенты*

*Фән. җит. − филол. фән. канд. Минһаҗева Р.Ә.*

Батырлык, каһарманлык темасы әдәбиятыбызда традицион темалардан санала. Татарларның мифик бабасы пәһлеван, Алып батыр образы Орхон-Енисей язмалары чорыннан ук килә [1: 96].

Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» документаль повесте сугышның бөтен авырлыгын тоткын буларак узган төп геройның эчке кичерешләрен, үзендә кешелеклелек сыйфатларын, рухи ныклыкны, җиңүгә өметен югалтмаган әсир образын сурәтләве белән үзенчәлекле. Әлеге әсәр нигезендә без «батырлык» төшенчәсен ике яссылыкта, фашист төрмәсендә әсирлектә һәм совет төрмәсен үткән кеше мисалдында өйрәнүне максат итеп куйдык. Инсанны батырлыкка этәрүче төп көчләрне аңларга, аның мәхбүслек шартларында да кешелек сыйфатларын югалтмавын, рухи матурлыгын саклап кала алуының алшартларын, сәбәпләрен тикшердек.

Сугыш чорында сынауның иң авырын, рухи яктан да, физик яктан да иң тетрәндергече кичергән кеше – тоткын. Үз җиреннән, үз иленнән, үз халкыннан аерылган әсир.

Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» автобиографик повесте 1956-64 нче елларда язылган. Төп герой Нәби үзенең меңләгән иптәшләре белән Белоруссия кырында дошман чолганышында калып, әсирлеккә эләгә. Герман җирендәге концлагерьдан 1945 нче елның апрелендә качып, туган җиренә шул елның азагында кайта.

Автор әсир егетнең Туган иленә мәхәббәтен калку чагылдыра. Туган илне ярату хисе аңа авыр вакытларда көч бирә, кешелеклелек сыйфатларын сакларга ярдәм итә.

Урта гасыр әдәбиятында әсирләр Алланы тану, аңа ышану, аны ярату, тәкәбберләнмәү, аңа сыгыну аша иреккә ирешәләр. Ә инде XX нче гасыр әдәбияты әсирлекне кичерү, үзеңә рухи ныклык алу өчен Туган илеңә, аның бөеклегенә ышану кирәклеген ассызыклый. Әмма бу ышаныч белән генә тоткынлыктан котылу мөмкин түгел. Азатлыкны син башкалар ярдәменнән башка күрә алмыйсың: яки сине ватандашларын килеп азат итә (сугышта җиңүгә ирешә), яки син иптәшләрең белән күп авырлыклар күреп, качып котыласың. Гомумән, Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятында без нигездә илаһи затка – Аллаһы Тәгаләгә ышануны, аңа сыенуны күрмибез диярлек. Әлбәттә, бу илдәге коммунистик җәмгыять тарафыннан алып барылган атеистик тәрбия белән бәйле. Әсир Нәби һәм аның белән бергә тоткынлыкта булган әсирләрнең кичерешләрен сурәтләү өчен әсәрне шартлы рәвештә 2 гә бүлеп карадык: Туган илдәге лагерьларда тоткын кичерешләре һәм дошман җирендәге лагерьларда тоткын кичерешләре. Авторның фашист тоткынлыгын сурәтләүгә игътибар итик:

***Ирекне сагыну*** (Әсир солдат «читлеккә ябылган кош сыман, башта бу хәлгә килешә алмыйча арлы-бирле сугыла...Әсир солдат кая гына бармасын, башына мөгезле каскалар кигән сакчылар күрә һәм, көче бетеп, тынып кала....шунда гына ул үзенең авыр хәлен аңлый һәм ирекне өзелеп сагына башлый») [1: 12].

***Билгесезлек*** («Ә бүген мин үзем дә мескен солдат кебек, вагоннарга утырып, Германиягә китеп барам. Дөресе, китеп бармыйм, мине алып китәләр. ... Безне алда индидер көннәр көтә? Моны күз алдына китерүе мөмкин түгел. Дошман безне үз иленә коллыкка алып бара») [1: 89].

***Өмет, яшерен шатлык*** («Без, үзебезнең язмышка карап, фронт хәлләрен сизенә башладык. Немец безне үз тылына таба күчерә икән, димәк, бу юкка түгел. Немец армиясенең үкчәсенә басып куып киләләр дигән сүз») [1: 91].

***Дошман кәефенә карап, фронт вакыйгаларын күзаллау*** («...без шатланган немецны яратмый торган идек. Чөнки немец шатланганда, фронтта дошман җиңүгә ирешкән һәм шуңа рәхәтләнеп көлә кебек тоела

иде безгә. Киресенчә, әгәр дә немец ачулы булса, аның кәефе кырылган булса, без эчтән шатлык кичерә идек») [1: 103].

***Немец баенда коллыкта булуга хурлану, үртәлү һәм көчсезлек*** («Тукта, мин нишлим соң? Мин җир казыйм. Кемгә казыйм? Немец хатынына. Ә ул кем? Минем дошманым! Димәк, мин дошманыма булышам. Ә аның ире минем илемдә минем халкымны үтереп йөри, минем авылларымны яндыра, шәһәрләрне җимерә. Ә мин биредә аның йортын баетам... Аңлагыз, әсирлекнең иң авыр хурлыгы менә шул, дусларым!») [1: 134–135].

***Туган илгә чиксез ышаныч, ярату*** («...Мин совет кешесе! Мин үз язмышымны бары туган илемә генә тапшыра алам. Әгәр мине ил җинаятьче дип саный икән, атсын, ассын. Тик үз кулы белән...») [1: 159].

Әсирлеккә эләгүчеләрнең күбесенә «хыянәтче» исеме тагылып, туган илләренә кайткач, тагы да катлаулырак сынаулар көтә. Әмма, монда әсирләргә аяк астында туган туфрак булу бер яктан ышаныч бирсә дә, үз илләрендә әсир булу тойгысы хурландыра; совет иленең шомлы киләчәге борчый. Дошман җирендәге лагерьларда тоткынлык 3 елга сузыла. Монда төп геройның рухи ныклыгы һәм һәр вакыйгадан үзе өчен нәтиҗәләр ясый башлавы, рухи үсеше күренә. Бигрәк тә Германия халкы, Германия солдатлары өчен дә әлеге сугышның теләмәгән зур фаҗига икәнен аңлау төп герой өчен зур ачыш була.

«Яшәү белән үлем арасында» әсәренең ахырында автор бүгенге укучыга мөрәҗәгать итә. Туган ил, әни, тынычлык кадерен белергә, үткәннәрне онытмаска чакыра.

Тоткынлык шартларында батырлыкны иң элек кешенең рухи матурлыгы характерлый. Халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген, чыдамлыгын, сабырлыгын югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җырларга да кергән.

«Яшәү белән үлем арасында» әсәренең төп герое Нәби дә әхлакый һәм рухи ныклык үрнәге. Әнә шул сыгылмас рухи батырлыгы, милләтебезнең үзенчәлекле менталитетын ачык билгеләүче сыйфатлардан санала.

**Әдәбият**

1. Дәүли Нәби. Яшәү белән үлем арасында. Повесть. Җимерелгән бастион. Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 446 б.

2. Татар әдәбияты тарихы: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

3. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 т. – Казан: Мәгариф, 2009. − Т. 2. – 343 б.

## ТАТАР ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫНДА ПАРЛЫ СҮЗЛӘР

*Баһавиева Ч., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәлахова Р.Р.*

Фольклор теле – гомумхалык теле, сәнгатьчә эшкәртелгән җанлы сөйләм теле. Татар халык авыз иҗаты белән кызыксыну, аерым кешеләр

тарафыннан аны өйрәнергә тырышу инде күптән яшәп килә. Фольклор жанрларыннан безне кызыксындырганы – сынамышлар. “Сынамыш – халык иҗатының борынгы жанрларыннан берсе, ул табигать күренешләренә, хайван һәм кошларның гамәлләренә карап, һава торышын фаразлаудан гыйбарәт” [4: 83]. Билгеле, сынамыш юктан гына барлыкка килә алмый, ул – халыкның озак еллар дәвамында җыелып килгән күзәтү тәҗрибәсенә нигезләнә. Һәр сынамышны физика, химия, биология кануннарына нигезләнеп, аңлату мөмкин, ягъни сынамыш – ул гади охшатуга нигезләнгән әйтем генә түгел, ә фәнни яктан да исбатлый алырлык күзәтү буларак бәяләнергә хаклы. Бүгенге көндә газета-журнал битләрендә сынамышларны еш очратырга мөмкин, димәк, алар картлардан калган ышану, юрау дип кенә бәяләнмиләр, аларны укучы, аларга ышанучылар бар.

Сынамышлартел белеме белгечләре һәм галимнәрнең игътибарын җәлеп итә торган жанр. Фольклорның әлеге жанрындахалыкның тарихы, менталитеты, дөньяга карата булган күзаллаулары чагылыш таба һәмалар сынамыш теленә хас булган үзенчәлекле бай сурәтләү чаралары белән кыска һәм оста итеп биреләләр.

Һәр сынамышның нигезе – ул капма-каршы кую. Шуңа нисбәтле сынамышлар теле дә башка халык авыз иҗаты әсәрләреннән аермалы буларак, үзенә генә хас стильгә ия. Сынамышларның шушы барлык тел үзенчәлекләрен дә өйрәнү бер яктан аларның эчтәлегенә төшенү өчен хезмәт итсә, икенчедән – татар халкының фольклор телен өйрәнү мөмкинлекләрен ача. Фольлористика телен өйрәнү – ул халыкның тел тарихын өйрәнүгә бәрабәр, чөнки халык авыз иҗаты әсәрләре бик борынгы заманнарда иҗат ителгән һәм аларда шул чорга хас булган аерым бер урынлыкта яшәүче төркемнең тел үзенчәлекләре сакланып калган. Шундый үзенчәлеккә ия булган тел берәмлекләренең берсе – парлы сүзләр. Аларның татар халык сынамашларында күпләп һәм урынлы кулланылуы күзәтелә. Халык иҗатында парлы сүзләр күп төрле мәгънә төсмерләрен бирә алуда бай мөмкинлекләр тудыра. Ул төсмерләр, нигездә, түбәндәгеләрдән гыйбарәт: гомумиләштерү, хәрәкәтнең өзлексез булуы, кабатлануы, интенсивлык, конкретлык, җыелмалылык, образлылык. Парлы сүзләрдәге мәгънәви төрлелек, аларның киң кулланылышы телебезне, һичшиксез, баета, күп мәгънәле итә һәм, шуның белән бергә, яңа стилистик мөмкинлекләр ача.

Сынамышларда, гадәттә, парлы сүзләр мәгънәне я көчәйтеп (экспрессия), я киңәйтеп, я гомумиләштереп киләләр:*җир-ана, ай-йолдыз, чәчәк-үлән, сөңге-кыя, ут-яшен, кар-боз, күренер-күренмәс* [4: 83]. Түбәндәге мисалларда парлы сүзләр үзләренең беренчел, ягъни туры мәгънәләрендә кулланылганнар: *Февральдә каен ботагында карлар* ***алка-***

***алка*** *булып асылынып торса, ул елда иген уңар* [3: 30]; *Һавада аҗаган уйнаса,* ***иген-ашлык*** *уңар* [3: 30]; ***Чаңгы-чана*** *юлы соңга калса, ашлык уңар* [3: 30]. Шулай ук сынамышларда парлы сүзләрнең икенчел, ягъни күчерелмә мәгънәдә булганнары да халык тарафыннан оста файдаланылган. Мәсәлән, *Әгәр* ***ябалак-ябалак*** *кар яуса, борчак белән чикләвек уңар* [1: 278]; *Сабан сөргәндә* ***ярмалы-ярмалы*** *балчык чыкса, ул җирдә ашлык уңар* [1: 278].

Сынмышларда парлы сүзләрнең төрле стилистик максатларда кулланылышы күзәтелә. Аларның компонентларын ирекле рәвештә алмаштырып куя алу, парлы сүзләрдә туган тоташ мәгънәгә һичнинди үзгәреш бирми. Мәсәлән, *ут-ялкын – ялкын-ут; җил-давыл – давыл-җил* [2: 113]. Сынамышлар мисалында карап үтик: *Март башы көн кояшлы булса,* ***яшелчә-җимеш*** *уңа* [2: 31]; *Имән чикләвеге күп булган елны кыш җылы килә һәм алдагы җәй –* ***туклык-иминлек*** [2: 31]; *Кыш* ***бәсле-томанлы*** *булса, җәй иген уңа* [2: 31].

Телебездә парлы сүзләрнең лексик-тематик төркемнәре шактый күп. Алар халык иҗаты үрнәкләре булган сынамышларда да органик рәвештә объектив чагылыш таба. Шуларның берничәсенә тукталабыз.

1. Табигать күренешләрен белдергән парлы сүзләр: *Әгәр кышын* ***комлы-карлы*** *буран булса, иген уңар* [2: 31]; *Октябрьнең җидесендә* ***җил-давыл*** *котырса, яз иртә килер* [2: 32]; *Гыйнварь* ***кар-бозга*** *бай булса, җәй эссе булыр* [2: 32]; *Беренче гыйнварда* ***давыл-буран*** *булса, иген уңар* [2: 32]; *Майның яңгырлы булуы* ***иген-печәнгә*** *файда, җимешкә – зыян* [2: 32]. Бу сынамышларда табигать күренешләре парлы сүзләр кулланылу хисабына хәрәкәтчәнрәк, күренешнең микъдари зурлыгы ачыграк күзаллана.

2. Төрле процессны (эш-хәрәкәтне, халәтне) белдергән парлы сүзләр: *Карлыгачлар* ***чыр-чу*** *килеп, түбән очса, яңгыр явар* [2: 33]; *Ай очы белән туса, көннәр* ***явым-төшемле*** *булыр* [2: 33]. Бу тематик төркемдәге парлы сүзләр эш-хәрәкәтнең тоташ киңлеген иңли, колачлый алган.

3. Дини йолалар, һәр төрле ышануга бәйле парлы сүзләр: *Ел башы буласы төнне кичен һәр ашлыкның саламын кар астына куеп, бер атнадан алып кара: кайсы ашлыкның саламы бүрткән,* ***озын-очлы*** *булса – шуны күбрәк чәчәргә кирәк* [2: 30]. *Барс елы –* ***байлык-куаныч****, Тычкан елы –* ***байлык****, Куй елы – кытлык, Куян елы – йотлык* [2: 30]. Мисаллардан күренгәнчә, парлы сүзләрдәге компонентлар мәгънәви яктан үзара тәэсир итешеп, экспрессияне арттыра.

Шулай итеп,сынамышларда кулланылган парлы сүзләрнең структур-семантик төзелеше аерым үзенчәлеккә ия булып тора. Парлы сүзләрдәге мәгънәви төрлелек, аларның киң кулланылышы телебезне, һичшиксез, баета, күп мәгънәле итә һәм, шуның белән бергә, яңа стилистик мөмкинлекләр ача.

**Әдәбият**

1. Гыйльманов Г. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 388 б.

2. Миңнуллин К., Урманче Ф. Татар халык иҗаты: Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004. – 479 б.

3. Мәхмүтов Х.Ш. Халык афоризмнары. Беренче китап. – Казан: Мәгариф, 2002. – 143 б.

4. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Т. 3. – 199 б.

## KURBANGALİ HALİDİ'NİN HAYATI VE TOPLUMDAKİ YERİ

*Begimtayev Ch., Kırgızistan-Türkiye Manas ünv., doktora öğrencisi*
*Danışmanı – Doç. Dr. Abdiyev T.*

Kurbangali Halidi ecdatları arasında Türkmen Baba adlı büyük bir zatın olduğu bilinmektedir. Türkmen Baba Hive prenslerinden olmuştur. Bunun dışında bu adamın hakkında fazla malumat bulunmamaktadır. Kurbangali Halidi, kendi eseri Tevarih-i Hamse-i Şarki kitabında kendi soyunun Nogaylardan geldiğini ileri sürmektedir. Halidi'nin yazdığına göre, babası Halit tüccar olup, aslen Kazan'ın Urnaşbaşı koyündendir. Baba Halit genç yaşlarından itibaren Kazak steplerinde ticarete başlamış, daha sonra da Kurbangali'nin doğduğu, o zamanlar bir okug olan Ayagöz şehrine yerleşmiştir [1: 97]. Bazen Türkistan ve Taşkend şehirlerine de gidip geliyormuş.

İlk eğitimine Ayagöz medresesinde başlayan Kurbangali, daha sonra eğitimine Semipalatinsk (Semey) medreselerinde devam etmiştir. Doğunun büyük bilim adamı Şahabuddin Marcani'nin Usul-i Cedid ekolünü tamamlayan Kurbangali, zamanının ilerici din aydını olmuş ve görüşü Usul-i Cedid esasında oluşmuştur. Buralarda hem dini hem de modern ilimler tahsil eden Kurbangali Arap, Fars dillerini öğrenmiştir. Ana dili Tatar Türkçesinin yanısıra, hemen bütün Türk lehçelerine vakıf olan Kurbangali, Kazak ve Uygur lehçelerini mükemmel derecede, Rus dilini ise sadece konuşma dili seviyesinde biliyordu. Ailesiyle birlikte Türk dünyasının çeşitli yörelerinde ikamet etmeleri, Kazak, Uygur ve daha başka Türk halkları ile iç içe yaşamaları, onların dilini, kültürünü, tarihini, folklorunu yakından tanımasında büyük rol oynadı.

Kurbangali, medreseden mezun olduktan sonra Kamarittin Hazretin yardımcı müridi olarak ders vermiştir. Hocasının dikkatini çekmesi, onun bilime karşı büyük ilgisindendir. Yalnız, Kurbangali'nin müritlik görevi fazla uzamamıştır. O zamanlarda Usul-i Cedid okulundan korkmuş, eski yöntemi korumuş Semey'deki 15 cami ve medresenin imamları Kamarittin Hazretin tuttuğu yolunu İslama ve Rus hükümetine karşı bir siyaset olarak kabul etmişlerdir. Bunun hakkında şikayet yazıp onu okuldan çıkartmışlardır [2: 18].

Hocası Semey okulundan dışlandığı anda Kurbangali de Ayagöz'e gelir. Okulda ders vermesine izin olmadığından dolayı o, ticarete başlamıştır. Bu işi yaparak Kazak ülkesini bol bol gezmiş ve şecereler toplamıştır.

Dini ve ticareti uyumla tutabilen Hacı Halit, Kurbangali yirmi sekiz yaşını doldurduktan sonra ticaret nedeniyle Bakta sınırına taşınmıştır. Bu olay, 1872 yılına denk gelmiştir. Bundan önce iki yıl, yani 1870'te Lepsi kalesinde imamlık yaptığını Tevarih-i Hamse-i Şarkide anlatmıştır. Bakta ve Çuguçak şehirlerinin arasındaki mesafe 12 kilometreydi. Bu bölgede Rus konsolosluğu da açılmıştır. Bu nedenle, baba oğul bilimadamlar 1873-1874 yılları arasında hem medresesi ve camisi mevcut olan, hem de Rusya etkisi altında kalan Çuguçak şehrine taşınmışlardır. 1874'te Ayagöz'lük Hacı Hüsnüddin'in daveti ile Çuguçak şehrinin camisine imam seçilmiştir [2: 20]. 1874'de başladığı imamlık vazifesini hayatının sonuna kadar devam ettirmiştir. 1881 yılından itibaren şehrin ve civarındaki kırsal Müslüman kesimlerin kadısı olarak da hizmet vermiştir.

Bu hizmetlerinin yanısıra Kurbangali hem tarihçi hem de bir etnograftır. Tarih ve etnografya sahasında araştırmaları için material toplamak üzere Türkistan coğrafyasında özel seyahatler düzenlemiştir. Eserlerinde yazılı materyallerin bulunmadığı hallerde sözlü tarihi materyallere ve şecerelere büyük önem vermiştir. Kazakistan, Orta Asya ve Doğu Türkistan tarih, kültür ve etnografyasına Çuguçak'tan başlayarak Doğu Türkistan'ın derinliklerine, Turfan şehrine kadar yaptığı ilmi seyahat esnasında temin ettigi not ve materyalleri kullanmıştır. Kurbangali'nin bir tarihçi ve etnograf olarak ilim aleminde tanınması ise hiç şüphesiz yaklaşık 800 sayfayı bulan hacimli eseri Tevarih-i Hamse-i Şarki adlı eseridir. Bu eseri Altın Beşik Evladı tabir ettiği Fergana hanlarının tarihini, Altışehir (Doğu Türkistan) hanları, Kazak hanları, Kalmaklar, Moğol-Tatar tarihi, Japon ve Çin tarihlerini içine alan geniş bir coğrafyanın tarih ve kültür hazinesidir. Bilhassa Kazakistan ve Doğu Turkistan Türklerinin tarih, coğrafya, kültür ve folkloru için tükenmez bir bilgi kaynağıdır. Şehirlerin tarihi, mahalli terimler, kavim-boy adları, yer adları, bölge kavimlerinin inancı, gelenek ve görenekleri bizzat içlerinden biri tarafından detaylı bir şekilde analiz edilmiştir [1: 98].

Kari Kurbangali Halidi tarafından 1889 yılında yazılmaya başlanan bu eser, Çağatay Türkçesiyle kaleme alınmış olup 1910 yılında tamamlanmıştır. Eser, 1910 yılında Kazan'daki Örnek matbaasında basılmıştır. Yazar, 10 bölümden oluşan bu eserinde Arap, Fars, Türk, Moğol ve Çin dilinde yazılmış olan kaynakları kullanarak Kazak, Tatar, Moğol, Türk ve Çin halklarının tarihini yazmıştır. Yazar bu eserini yazarken Rus araştırmacıları W. Radloff, A. Wambery ve H. Katanov'un kitaplarından da faydalanmıştır. Bunun yanında, Kurbangali Halidi'nin en büyük özelliklerinden biri, bir konu hakkında yazı yazarken, elindeki bütün kaynaklardan faydalanarak konuyu izah etmeye çalışmasıdır. Kurbangali Halidi, Tevarih-i Hamse-i Şarki adlı eserini yazarken bilinmeyen bir çok yazma eserin yanında Tibyan-ı Nafik, Cihan-nüma, Kaide-yi Özbekiyye, Gıyas'ul-Luğat, Şecere-i Türki, Tarih-i Taberi, Hayrullah Efendi

Tarihi, İbn-i Haldunun Usul-i Tevarih ve Bilal Naziminin Gazavat-ı Çin adlı yazma eserlerinden de faydalanmıştır.

Elyazmasını 1910'da Kazan şehrinin Örnek matbaasında kitap halinde yayınlamıştır. Böylece, önemli, olay açısından zengin, tarihsel-bilişsel çelişki içinde olan zamanda yaşamış Kurbangali Halidi, 14 Mart 1913'te Çuguçak'ta vefat etmiştir [3: 35–36].

**Kaynakça**

1. Ünal F. Tatar Alim Kurbanali Haci Halidoğlu'nun Orta ve Guney doğu Avrupa Seyahati // Güney-Doğu Avrupa Araştırmaları Dergisi. 0 (14). – 2008.

2. Halidi K. Kazak koljazbaları.Tauarih-i Hamsa-i Şarki. c. 10. T.Jurtbay, B.Mustafayev, Ş.Begimtayev.(çev.). – Almatı: El-şejire, 2018.

3. Gencal B. XIX. Yüzyıl Doğu Türkistan Tarihi Hakkında Yazılmış Olan Birinci Elden Kaynaklar // Manas Sosyal Araştırmalar Dergisi. 2 (8) – 2013.

## РОЛЬ МЕЖДОМЕТИЙ В ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКОМ ФОНДЕ ТАТАРСКОГО И АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКОВ

*Болгарова А., КФУ, студент I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Исламова Э.А.*

Междометие представляет собой малоизученный класс слов в лингвистике. Проанализировав функционирование междометия в английском и татарском языках мы пришли к выводу, что данная часть речи имеет много схожих черт в сопоставляемых языках, а также выявили особенности употребления междометий в данных разносистемных языках.

В татарском языке достаточно много междометий, которые в устойчивом виде укрепились в составе фразеологизмов. Среди них междометия *ай-һай, өф, ә, эһ, уф, ах* являются самыми часто употребляющимися в составе фразеологизмов. Например: ы***х*** *та итми* [2: 263]; и***х****, егетләр, кибә (бит) җилекләр* [1: 303]; а***й*** *җык тигере* [1: 42].

Императивные междометия татарского языка реже употребляются в составе фразеологических единиц. Например: ***мә*** *аягың, бир таягым* или *"****мә*** *сиңа" да "бир миңа* [2: 28]; *мә бишне* [2: 28]; н***а*** *дисәң бармый,* ***ту*** *дисәң туктамый* [2: 34].

Также среди междометий есть такие, которые используются в ряде фразеологизмов. Смысл междометия может варьироваться, а может оставаться неизменным в зависимости от того, в составе кагого фразеологизма оно использовалось. Например: ***ай-һай, вай-һай*** *күп булу* (восхищение); ***ай-һай*** *да юк* (горестный ропот)*;* ***ай-һай*** *ла* или ***ай-һай*** *ләбаса* (сожаление); ***ай-һай*** *салу* (сожаление, недоумение); ***ай-һай*** *телең, тел очында безең* (восхищение)*;* ***ай-һай****, Шәйхел, төлке микән, койрыгы озын* (подозрение) [1: 41–42]; ***өф*** *итеп кенә;* ***өф*** *иткән дә җир юк;* ***өф-өф*** *итеп;* ***өф-өф*** *кеше* – выражение бережного отношения к кому-либо или чему-либо [2 : 328]; ***уф*** *башым, юкмы калган ашың;* ***уф*** *дип суласам, дәрьялар болгана;* ***уф****, йөрәгем такта чәй;* ***уф****, чәкүшкәдәй башым*

*мичкәдәй булды;* ***уф,*** *эчәгем-бавырым өзелә* - выражение недовольствия, усталости [2: 202–203]; ***ах*** *Алла транспорты* (ропот); ***ах*** *итеп тору* (восхищение); ***ах*** *хәлгә төшү* (ропот, жалоба) [4: 105–106]; ***ай-ваена*** *карамый (карамастан),* ***ай-ваена*** *куймау* – выражение ропота, несогласия*;* ***ай-вай*** *килү,* ***ай-вай*** *салу* – выражение радости, счастья [1: 38].

По сравнению с татарским языком, во фразеологическом фонде английского языка междометия встречаются редко. Проанализировав большой фразеологический словарь А.В. Кунина, мы обнаружили несколько примеров, в составе которых имеются междометия. Например: ***hurra(h)'s (hurray's)*** *nest* [3]; ***oh*** *my ears and whiskers* [3]; *can't say* ***bo (boh*** или ***boo)*** *to a goose* [3]; ***hum*** *and haw* [3].

Как видно из этих примеров, междометия в английском языке употребляются в составе фразеологизмов в устойчивой форме. По сравнению с татарским языком, в английском языке не так много фразеологизмов, в составе которых имеются междометия. Однако лингвисты выделяют в английском языке междометные фразеологизмы. Междометные фразеологизмы – это фразеологизмы, которые служат для выражения различных чувств, эмоций, волевых побуждений. Так же как и другие междометия, они обладают целостным переносным смыслом, образностью и экспрессивностью. Однако отличие междометных фразеологических единиц – быть средством выражения ментального или эмоционального отношения говорящего к предмету. То есть для них, так же, как и для междометий, характерно нивелирование функции номинации. Они называются междометными из-за своей функции, а не из-за присутствия в их составе междометия. Напротив, сами междометные фразеологизмы обычно не содержат в себе междометия.

В большом англо-русском фразеологическом словаре А.В. Кунин отдельно выделяет междометные фразеологизмы [3]. Рассмотрим несколько примеров: 1) *Good Lord! – видит бог!, боже (мой)!* – восклицание, выражающее удивление, досаду и т. п.; 2) *by the Lord Harry*! *– чёрт возьми!* В данном фразеологизме *the Lord* Harry– это шутливое прозвище дьявола; 3) *by golly! – ей-богу! бог мой!, честное слово!; о, чёрт!, чёрт возьми!; не может быть! – восклицание, выражающее удивление, досаду и т.п.;* 4) *Good for you! (good for (on) you (him, etc.)!)* – браво! молодцом! – восклицание, выражающее восхищение, поощрение и т. п.; 5) *Good luck! – в добрый час!* – восклицание, выражающее добрые пожелания. Обычно оно используется при прощании.

В английском языке некоторые источники рассматривают слова *Good morning, Good afternoon, Good evening, Good night* так же, как междометные фразеологизмы.

Среди междометных фразеологизмов английского языка можно найти эквиваленты татарским фразеологическим единицам. Например, фразеологизм *damn it (all)! – к чёрту! чёрт подери! тьфу, пропасть!* ***(восклицание, выражающее удивление, досаду и т. п.) имеет аналог в татарском языке: шайтан алгыры!***

Итак, проведенный нами сопоставительный анализ роли междометия во фразеологическом фонде татарского и английского языков выявил, что роль междометий среди фразеологизмов татарского языка более существенна, чем английского. В татарских фразеологических единицах междометия встречаются гораздо чаще и имеют устойчивый характер. Их употребление можно классифицировать в зависимости от видов междометий, частоты употребления и по смыслу. В английском языке более часто употребляются междометные фразеологические единицы, которые также выражают чувства и эмоции говорящего.

**Литература**

1. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Т. 1. – 495 б.

2. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 т.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Т. 2. – 365 б.

3. Кунин А.В. Англо-русский фразеологический словарь. – М.: Рус. яз., 1984. – 944 с.

## ТЮРКИЗМЫ В РАННЕЙ ЛИРИКЕ С. ЕСЕНИНА

*Валеева Э., КФУ, магистрант II курса*

*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Гилазетдинова Г.Х.*

Всестороннее изучение заимствованной лексики русского языка является актуальной задачей современной лингвистической науки. Настоящая работа посвящена рассмотрению тюркизмов в ранней лирике С. Есенина. В ходе анализа было выявлено, что в ранних стихотворениях С. Есенина встречаются тюркские заимствования, которые можно отнести к разным лексико-семантическим группам. В данной статье рассматриваются тюркизмы группы *«Этнографические реалии»*.

В группу *«Этнографические реалии»* были включены такие тюркские заимствования, как *ковер, фата, сарафан, армяк, шаль, сафьян, бирюза, жемчуг, алмаз, бусы, серьги*. В данной группе выделяется ряд подгрупп. Рассмотрим некоторые их них.

1. Предметы домашнего обихода. Сюда мы включили следующие подгруппы слов:

– названия материй, покрытия. Например, *ковер*.

А по двору метелица  
*Ковром* шелковым стелется (1910) [2].

Н.Хусаинов считает, что слово *ковер* является древнерусским заимствованием из тюркского «ковур» – мех, шуба [4]. Слово полностью асси-

милировано в языке, означает «изделие из шерстяной и другой пряжи, часто с ворсом, употребляемое для покрытия пола, украшения стен» [3].

– названия одежды или ее деталей: *фата, сарафан, шаль* и др.:

А пойду плясать под гусли,

Так сорву твою *фату* (1911) [2].

Слово «фата», происходящее от персидско-таджикского «футе», «фута», означает «пояс из хлопчатобумажной или шелковой ткани; платок; чалму» [1]. Согласно «Большому толковому словарю русского языка, фата – это «закрывающее голову и верхнюю часть тела лёгкое женское покрывало из кисеи, шелка, тюля, кружев (обычно служащее свадебным головным убором невесты)» [3].

Рассмотрим пример использования тюркизма *сарафан*:

Хороша была Танюша, краше не было в селе,

красной рюшкою по белу *сарафан* на подоле (1911) [2].

Слово «сарафан», происходящее от персидского «сарапа» и таджикского «сарупо», означает «одежду, халат, а также комплект верхней одежды, подаренный кому-нибудь, например, приближенному от эмира, жениху от родителей невесты» [3].

Рассмотрим еще один пример с тюркизмом-названием одежды:

Но остался в складках смятой *шали*

Запах меда из невинных рук (1916) [2].

Выделенная лексема *шаль*, по материалам «Словаря тюркизмов русского языка» Е.Н.Шиповой, является заимствованием от тюркского слова «шәл» [5].

Слово «армяк» также является заимствованным из тюркского языка, в частности происходит от тюрк. ärmäk «одежда из верблюжьей шерсти, армяк» [5].

Скинь-покинь свой *армяк* полинялый,

Проходи с нею к зарослям в терем (1915) [2].

Следующим примером является слово «сафьян». Согласно словарю Е.Н. Шиповой, «сафьян» заимствован из киргизского «сактыян», что означает мягкую кожу с крупными порами, выделываемая из козьей шкуры [5].

– названия драгоценных камней, украшений: *бирюза, жемчуг, алмаз, бусы, серьги*. Например:

Васильками сердце светится, горит в нем *бирюза,*

Я играю на тальяночке про синие глаза (1912) [2].

Выделенное слово является заимствованием из тюркского «фирүзә» [5]. Слово является названием драгоценного камня синего цвета. В данном случае слово употреблено в переносном значении, чтобы подчеркнуть очаровательную синеву глаз любимой девушки.

Следующий пример:

Мне на встречу, как *серёжки*

Прозвенит девичий смех (1914) [2].

В словаре тюркских заимствований Е.Шиповой имеется несколько версий о происхождении слова *серьги*. Фасмер приводит мнение Грота, Миклошича, Соболевского, которые предполагали, что серьга является преобразованием из др.-рус. усерязъ (11 в.), однако замечает, что «правильнее считать русское слово заимствованием из др.-чув. sürür 'кольцо', чув. sore, sera 'кольцо', тат. jozok, тур., чаг. juzuk – то же» [3: 611].

Рассмотрим другой пример:

Между сосен, между елок,
Меж берез кудрявых *бус*,
Под венком, в кольце иголок
Мне мерещится Исус (1914) [2].

Слово *бусы* считается заимствованием из арабского, которое пришло в русский язык через тюркский язык [5].

Итак, тюркизмы лексико-семантической группы «Этнографические реалии» достаточно часто встречаются в ранней лирике С. Есенина. Большинство заимствований данной группы имеют персидское происхождение, как правило, это слова, прочно вошедшие в лексическую систему русского языка. Необходимо отметить, что в стихотворениях поэта наиболее употребительными тюркизмами являются названия драгоценных камней и украшений.

**Литература**

1. Абдуллоев Д. Арабские, персидско-таджикские и тюркские заимствования в русском языке. – СПб: Изд-во политех. ун-та, 2016. – 60 с.
2. Есенин С. Собрание сочинение в трех томах.– М.: Правда, 1970. – Т. 1. – 383 с.
3. Кузнецов С. Большой толковый словарь русского языка. – СПб.: Норинт, 2000. – 1536 с.
4. Хусаинов Н.Н. Словарь тюркских основ русского языка. – Уфа: Полиграфдизайн, 2012. – 636 с.
5. Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов русского языка. – Алма-Ата: Изд-во «Наука» Казахской ССР, 1976. – 444 с.

## КОЛ ГАЛИНЕҢ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНДА КӨНЧЫГЫШ РОМАНТИЗМЫ

*Вәлиева А., Буа р-ны Түбән Наратбаш мәктәбе, IX сыйныф*
*Җит. – Шәрәфетдинова Л.Г.*

Романтизм – XVIII йөз ахыры һәм XIX йөзнең беренче яртысындагы Европа әдәбиятларында формалашкан иҗат методы һзм әдәби юнәлеш.

Совет Көнчыгышы, шул исәптән татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларында Европа тибындагы яңа Романтизм бары тик XX йөз башында гына барлыкка килә. Татар әдәбиятының барлык чорлары өчен дә романтизм юлдаш. Кол Галидән башлап XVIII гасыр азагына кадәр татар әдәбиятында өстенлек итүче иҗат методы Көнчыгыш тибындагы романтизм булды.

Көнчыгыш романтизмына әкияти, мифологик, дини мотивлар хас. Аның геройлары гадәттән тыш матур, акыллы, гадел һ. б. итеп тасвирлана. К. Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасын шундый юнәлештә карарга була.

"Кыйссаи Йосыф" инде сигез гасырдан бирле халык күңелендә, аңында, теле һәм язуында, әдәби һәм мәдәни мирасында яшәп килә; ул һаман да шул халыкның рухи-эстетик дөньясына эзлекле рәвештә тәэсир ясый торган, ягъни аңар ямь һәм төс бирә торган иң асыл җәүһәрләрнең берсе булып кала килә. Халкыбыз тормышына, аның рухи дөньясына бу кыйссаның ни кадәр тирән үтеп керүен әсәрнең сюжет һәм мотивлары халык җырлары, әкият, бәет һәм легендалар белән беррәттән йөрүеннән, ниһаять, күп очракта киң җәмәгатьчелекнең китапны язучының кем икәнен дә, әсәрнең үзе кайда, кайчан. ничек, ни өчен иҗат ителүен дә уйлап тормастан һаман аңар мөрәҗагать итүеннән һаман шуннан ләззәт алуыннан күрергә мөмкин.

Безнең эрага кадәр өч мең еллар элек яһүдләр Йосыф вә Зөләйха турындагы мифка үзләренчә исем биреп, "Библия"гә керткәннәр. Шуннан ул христианнарның "Ветхий завет" исемле китапларына, аннан VII гасырда "Йосыф сүрәсе" астында Коръәнгә дә теркәлгән.

"Йосыф вә Зөләйха" сюжетының ерак гасырларга сузылган тарихы бар. Кол Галигә кадәр һәм аның чорында "Йосыф вә Зөләйха" темасына язылган байтак әсәрләр булган. Гарәп, фарсы телләрен яхшы белгән һәм Көнчыгыш әдәбияты традицияләрен нык үзләштергән К. Гали, һичшиксез, бу фактлар белән таныш булган. Шагыйрьнең "Йосыф вә Зөләйха" поэмасының сюжеты турында "Китап эчрә бишәк аның мәшһүрлеге" дип язуы нәкъ әнә шушы фактларны күз алдына китереп бастыра.

Шагыйрьнең дөньяга карашлары, социаль-иҗтимагый һәм идея-эстетик идеаллары шактый катлаулы һәм каршылыклы. Ул, һичшиксез, кешеләрнең газаплы яки бәхетле тормышы, кайгысы һәм шатлыгы, уй һәм фикер йөртүләре, хәрәкәте яисә эшчәнлеге, аның киләчәге – гомумән бөтен яшәеше һәм рухи үзгәреше югарыдан, тәңре, алла тарафыннан билгеләнеп куелган язмыш буенча бара дигән идеалистик караште тора. Кол Гали үзенең иҗат эшчәнлегенә дә шушы күзлектән чыгып караган.

Әдәби геройларның киләчәген, язмышын шулуй алдан билгеләнеп куелган схема буенча аңлатырга тырышу, бер Кол Галигә һәм гомумән башка борынгы татар язучылырына гына хас әйбер түгел. Ул күп кенә халыкларның борынгы һәм урта гасыр әдәбияты өчен уртак бер алым булып тора. Мәсәлән.борынгы грек, рим һәм Көнбатыш, Көнчыгыш, шул җөмләдән рус әдәбиятында да билгеле бер язучылар, шагыйрьләр геройларның хәрәкәтләрен, рухи дөньяларын алла, язмыш яки "рок" кушуы буенча була дип аңлатканнар.

Композициясе, сюжет төзелеше белән генә түгел, аерым эпизодлары, вакыйгалары белән дә поэма борынгы болгар-татар яки башка халыкларның әкиятләрдәге элементларны хәтерләтә. Мәсәлән, “кое” образы.Бу сүз поэмада берничә урында күренә. ”Кое” яки җир астына төшү фактлары әкиятләрдә күп очрый.

“Төш күрү” дә “Кыйссаи Йосыф” поэмасының шундый ук бер художество алымы. Әсәрдә төш күрмәгән кеше юк диярлек (Якуб, Динә, Йосыф, Зөләйха, Малик бине Догар һ.б.).Аларның тормыш юллары яки аерым эпизодлар төш белән билгеләнә. Шагыйрьнең бу алымы аның дөньяга карашы һәм ул яшәгән чорларда халык арасында төшкә ышану, аны юрау гадәтләренең шактый таралган булуы белән бик нык бәйләнгән.

Йосыф 72 тел белә, аның көче “кырык ирнең” куәтеннән артык, Зөләйха Йосыфка “өч йөз алтмыш төрле кием әзерләтә. ”Ата белән угыл 70 ел аерым торалар.

Поэмада мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Алардагы саннар, туры мәгънәдән бигрәк, күплекне, гадәттән тыш арттыруны белдерәләр. Шунысына игътибар итәргә кирәк: саннарның, нигездә, теләсә нинди түгел, ә символик мәгънәгә ия булганнары күбрәк алына. Мәсәлән, Мисыр патшасының төшендә җиде саны еш кабатлана: җиде симез сыер, җиде арык сыер, җиде тук башак, җиде ач башак. Мәгълүм булганча, табигатьтәге аерым күренешләр белән бәйләнгән бу сан (атнанаң җиде көне, җиде планета, җиде төс һ.б.) мифологиядә, фольклорда һәм язма әдәбиятта образлы, символик вазифа үти. Өч саны белән дә шундый ук хәл: Зөләйха Йосыфны өч мәртәбә төшендә күрә, агалары үз туганнарының “өч төрле гаебе барлыгын күрсәтәләр.”

Поэмада каһарманнарның яшьләрен бирүдә дә шартлылык, әкияти традицияләргә иярү күзгә ташлана. Мәсәлән, Кәнгән коесындагы заһидка 1200 яшь. Укучыга 11 яшьтә дип тәкъдим ителгән Йосыф 50 елдан артык коеда, 12 ел зинданда утыра, “30 яшендә” хөкемдар булып, бик озак вакыт Мисыр белән идарә итә, 60 еллап гомерен “Әмин” каласында уздыра. Шактый олы яшьтәге Якуб улыннан 70 ел буе аерылып тора, аннан соң да әле “40” ел яши. Якубның да ,Йосыфның да, Ибне-Йәминнең дә “12 угылы бар” дип күсәтү – мифологиядән, фольклордан килә торган күренеш.

Шулай ук,поэмада Йосыф белән Зөләйханың мәхәббәте аерым бер эпизод булып тора. Мәхәббәт темасы төрки әдәбиятка гына түгел, көнчыгыш әдәбиятына да хас. Ул матур һәм илаһилаштырып бирелә.

“Кыйссаи Йосыф” поэмасының йогынтысын Мөхәммәдъярдан башлап Габдулла Тукайга,Мәҗит Гафурига кадәр күп кенә татар һәм башкорт әдипләре тойганнар. ”Кыйссаи Йосыф”поэмасының сюжетына нигезләнеп үзләренең мәхәббәт турындагы әсәрләрен язганнар. “Кыйссаи Йосыф” поэмасы бүгенге көндә дә яратып укыла. Аның турында галимнәр

шактый күп яздылар. Шундыйлардан: Җәвад Алмаз, Фазыл Фасиев, Н. Хисамов, Р. Ганиева һ. б.

**Әдәбият**

1. Кол Гали Кыйссаи Йосыф. – Казан: Татар. кит. нәш., 1983. – 540 б.

2. Татар әдәбияты тарихы. 6 т. – Казан: Татар. кит. нәш., 1984. – Т. 1. – 568 б.

3. Хисамов Н. Татар теле һәм әдәбияты. 5 нче китап. – Казан: Татар. кит. нәш., 1976 – 294 б.

4. Җәвад А. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – № 12 – 127 б.

## ЗООНИМ КОМПОНЕНТЛЫ ЧАГЫШТЫРУЛАРНЫҢ ЯСАЛУ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРЕ

*Вәлиева З, КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Габдрахманова Ф.Х.*

Чагыштыру – телдә иң еш очрый торган тел-сурәтләү чараларының берсе. Аерым билгеләре буенча әйберләрне һәм күренешләрне бер-берсе белән тиңләштерү, тәңгәл кую һәм аларның охшаш якларын күрсәтү чагыштыру алымының нигезендә ята. Чагыштырулар тел-сурәтләү чарасы рәвешендә матур әдәбият стилендә киң кулланыла. Персонажларның характерлы үзенчәлекләрен индивидуальләштерү, табигать күренешләрен сурәтләү, төрле вакыйгаларны җанлы итеп тасвирлауда аларның роле зур. Чагыштырулар шулай ук публицистик сөйләмдә, фәнни әдәбиятта, эпистоляр стильдә, халык телендә дә күп очрый.

"Матур әдәбиятта тормышны, чынбарлыкны чагылдыру махсус кануннарга нигезләнә. Тел элекке традицияләр нигезендә өзлексез үсеп һәм яңарып тора. Яңа формалар, телдәге сурәтләү чаралары белән тыгыз бәйләнешкә кереп, сөйләмне тагы да баета һәм камилләштерә. Сурәтләү-тасвирлау алымнары әсәрнең идея эчтәлеге, төзелеш һәм анда катнашучыларның характерын ачу белән тыгыз бәйләнгән була" [4: 6].

Чагыштыру – логика фәненә караган төшенчәләрнең берсе. Ул фикерләү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бер-берсе белән бәйләнгән нинди дә булса ике (яки берничә) төшенчәне чагыштырып, без аларның уртак һәм аермалы якларын билгели алабыз.

Чагыштыруда ике предмет яки берәр нинди күренеш, вакыйга бирелә. Шуларның берсе чагыштырылучы (субъект), икенчесе чагыштыручы (объект) була. Чагыштырылучы белән чагыштыручы телдә үзара нинди дә булса грамматик чара ярдәмендә бәйләнә. Татар телендә алар түбәндәгеләр: дай/дәй, -рак/-рәк, -ча/-чә аффикслары; кебек, шикелле һ.б. бәйлекләр; бәйлек ролендә килгән сүзләр; бул-, ит- кебек ярдәмче фигыльләр; гүя, әйтерсең лә һ.б. теркәгечләр; мөнәсәбәтле сүзләр һ.б.

Без караган әсәрләрдә чагыштыруларны тикшереп, чагыштырма планда анализлау нәтиҗәсендә без түбәндәге фикерләргә килдек:

тикшерелгән чагыштыруларның күбесендә бәйләүче чара функциясен охшату-чагыштыру бәйлекләре (*кебек, төсле, шикелле*) үти:

*Күзлеген борын очына гына элгән Карп Васильевич картларча ашыкмыйча, әкрен генә атлый, ә Газинурның күкрәгендә, әйтерсең, казан кайный, ул* ***колын шикелле юргаларга*** *гына тора.*

*Кара каргаларның йомыркалары өчен Газинурның менмәгән агачы юк иде. Бу юлы да ул* ***мәче кебек үрмәләп менеп китте.***

*Бәхетле хатыннар бу чакта ирләренең җылы куенында* ***ак куян кебек йомылып йоклыйлар*** *әле, ә ирсез хатыннар.*

*Миңнурыйның, серле абага чәчәге төсле, ачылып киткән минутлары бик сирәк һәм кыска була, әмма шундый минутларда гына аның күңелендәге чын тойгыны сизәргә мөмкин, чөнки икенче секундта* ***ул инде, йомарланган керпесыман****, чәнечкегә әверелә.*

*Кипяток... – диде* ***Газзән, үзе яз көне беренче тапкыр өненнән чыга башлаган карт аю төсле*** *ашыкмый гына полкадан төшә башлады.*

Икенче урында -дай/-дәй, -тай/-тәй кушымчалары тора.

*<...> Тагын аҗарданниләрдер бик сорашасым килә, ләкин шул арада аш өеннән кемдер аны кычкырып дәште, һәм* ***кече кодача, кәҗә бәтиедәй*** *уйнаклап, йөгерә-йөгерә китеп тә барды.*

*Картның да бит нәсел очы гүя шушы баһадир таудан һәм назлы елгачыктан башланып киткән, ул шушы җирләрнең туфрагында аунап үскән,* ***Тимерҗаны*** *да шушы таулар куенында* ***бөркет баласыдай үсте.***

“Бул” ярдәмче фигыле белән бер генә мисал табылды:

*Ләкин Локман картның күңеленә «Алырлар, барыбер алырлар...» дигән* ***уй сөлек булып оялады****, бары Тимерҗанны алганчы сугыш бетеп куймасмы дигән өмет кенә аны бераз тынычландырып тора иде.*

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, без тикшергән әсәрләрдә *кебек, шикелле, төсле* бәйлекләре, *-дай/-дәй, -тай/-тәй* кушымчалары, *бул* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган зооним компонентлы чагыштырулар еш кулланылган.

**Әдәбият**

1. Әпсәләмов Г.С. Ак чәчәкләр: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 510 б.
2. Әпсәләмов Г.С. Газинур: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 400 б.
3. Еники Ә. Әсәрләр: 5 т.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Т. 1. – 447 б.
4. Хаков В.Х. Стилистика һәм сүз сәнгате. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 274 б.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫНДА ҺӘМ АНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ СИНОНИМНАР

*Вилданова Ә., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмухаметова Э.Н.*

Тәрҗемә итү ихтыяҗы кешеләр башка халыклар белән аралаша башлагач, сәүдә элемтәләре урнаштырырга кирәк булгач туа. Башта кешеләр көнкүреш сүзләрен генә тәрҗемә итсәләр, тора бара инде әдәби,

мәдәни мирас белән дә алмашу теләге барлыкка килә. Тәрҗемә белеме зур тизлек белән алга барса да, бүгенге көндә тәрҗемә әсәрләрендә төгәлсезлекләр шактый. Бигрәк тә телнең сүз байлыгын күрсәткән синонимнарны бер телдән икенче телгә күчергәндә аларның шактый булуы күренә. Беренчедән, телдә сүзләр арта бара, синонимик оялар төрле алынма, телнең үз закончалыклары белән барлыкка килгән сүзләр исәбенә тулыланып тора, ә бу тәрҗемә вакытында кирәкле берәмлекне сайлауны кыенлаштыра. Икенчедән, тәрҗемә әсәрләрендә синонимнарның бирелешен тикшерүчеләр бүгенге көнгә кадәр юк. Теманың актуальлеге дә шуннан гыйбарәт.

Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы – иң күп укыла торган әсәрләрнең берсе. Әсәрдә синонимнарның роле гаять зур, алар шактый күп кулланылган. Рус теленә тәрҗемәдә дә алар, нигездә, сакланганнар. Моны исбатлау өчен, без әсәрнең беренче бүлекчәсен анализладык һәм анда булган синонимик берәмлекләрне исәпләдек. Кечкенә генә әлеге өзектә барлыгы 9 синонимик оя, 21 синоним берәмлек очрый. Ә әсәрнең тәрҗемәсенә исә 11 синонимик оя һәм 22 синоним сүз кулланылганлыгын күрергә мөмкин. Күренә ки, тәрҗемә әсәрендә синонимик оялар һәм синоним берәмлекләр күбрәк. Бу бер тел берәмлекләрен икенче телдә бер сүз белән генә аңлатып булмау, чынбарлыктагы күренешләрне төрле яклап ачыклауга бәйле. Ләкин төп нөсхәдә бирелгән барлык синонимнарның да тәрҗемәдә бирелмәү очраклары да күзәтелә. Димәк, синонимнарның тулысынча, алыштырып тәрҗемә ителгән, яки, гомумән, тәрҗемә ителмәгән төрләре бар. Синонимнарны тәрҗемә итүдә билгеле бер кагыйдәләр юк. Алар бары тик урынлы кулланылырга һәм төп нөсхәдә әйтелгән фикерне, эчтәлеккә зыян китермичә, тәрҗемәдә дә җиткерергә тиеш. Алар аша укучы геройның тышкы кыяфәтен, характер-холкын, күңел хәләтен; вакыйгалар барган чорның, урыннарның үзенчәлеген күзаллый.

“Ак чәчәкләр” романында синонимнар уңышлы тәрҗемә ителгән урыннар күп. Мисал өчен, “*Ләкин Диләфрүзнең аяк тавышы тынуга,* ***ялт*** *записканы алып,* ***тиз-тиз*** *укырга кереште, аннары түшәмгә текәлде*” [2: 44] – *“Асия* ***моментально*** *схватила записку,* ***быстро*** *пробежала и опять сердито уставилась в потолок”* [1: 42]. Күргәнебезчә, *ялт* һәм *тиз-тиз* синонимнары *моментально* һәм *быстро* дип дөрес, тулы тәрҗемә ителгән. Ул төп нөсхәдә бирелгән фикерне тәрҗемәдә тулысы белән ачык һәм аңлаешлы итеп күрсәтә. Түбәндәге мисалларны да тулы тәрҗемә үрнәкләренә кертеп карарга була: *“Барысы да әкрен генә* ***тына, сүнә*** *бара... кеше дә шулай”* [2: 59] – *“Горизонт* ***меркнет****, всё* ***замирает****...”* [1: 56]. *“Әгәр аның үз-үзен ничек тыйганлыгын, үз-үзенә карата никадәр* ***аяусыз, шәфкатьсез*** *булганлыгын, барлык кичергән газапларын сөйләсәң, кеше ышанмас иде”* [2: 72] – *“Если бы рассказать, как она себя*

*сдерживает, осуждает, как она* ***сурова*** *и* ***беспощадна*** *к себе, как мучается, - никто не поверил бы"* [1: 69]. *"****Хурлык, оят****, җинаять!"* [2: 261] – *"****Позор, стыд****, преступление!"* [1: 254]. Әлеге мисалларның тулы тәрҗемә икәнен, иң беренче чиратта, сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп дәлилләп була. Нөсхәдәге синонимнарны тәрҗемәче ничек тәрҗемә итсә, сүзлекләрдә дә шулай тәрҗемә ителгән. Икенчедән, тәрҗемәдәге синонимнар нөсхәдәге синонимнарның мәгънәсен, җөмләдәге вазыйфасын укучыга аңлаешлы итеп, мәгълүматка зыян китермичә ачып бирә.

Синонимнарны алыштыру юлы белән дә тәрҗемә итү күзәтелә. Мисал өчен, *"Әнкәй гел* ***янасың, пешәсең*** *дип әрли"* [2: 40] җөмләсе – *"Мама причитает, что все время* ***в огне горю****"* [1: 39] дип бирелә. Әлеге мисалдан күренгәнчә, *янасың, пешәсең* синонимнары *гореть в огне* фразеологизмы белән алыштырып тәрҗемә ителгән. Безнеңчә, моның сәбәбе – татар телендәге *пешәсең* сүзенә рус телендә уңышлы тәрҗемә булмау, чөнки сүзлекләрдә ул *вариться, свариться; печься, испечься; обжигаться, обвариться* дип тәрҗемә ителгән. Күргәнебезчә, бу контекстта аларны куллану дөрес булмас иде. Шулай ук түбәндәге мисалда да синоним алыштырып тәрҗемә ителгән: *"И* ***юләр****, и* ***сантый****! – диде ул кызганып та, битәрләп тә"* [2: 141] – *"Вот* ***глупец****, вот* ***простак****!"* [1: 135]. *Юләр* сүзе сүзлекләрдә *дурак, дурачок, глупый, ненормальный, умалишённый, душевнобольной* дип тәрҗемә ителә, тәрҗемәче *глупый* вариантын ала, ләкин аны иркәләйтү-кечерәйтү формасында *глупец* дип бирә. Шулай ук *сантый* сүзе дә сүзлекләрдә *дурачок, дуралей* дип тәрҗемә ителгән, ә тәрҗемәче аны *простак* сүзе белән алыштыруны кулай күргән. Контексттан чыгып карасак, әлеге алыштырулар, дөрестән дә, бик уңышлы, чөнки автор монда геройның беркатлы булуын күрсәтергә тели, тәрҗемәче авторның әлеге фикерен *простак* сүзе белән тулырак күрсәтә.

Тәрҗемәдә шулай ук төп нөсхәдә булган синонимнарны төшереп калдыру очраклары да күзәтелде. Мисал өчен, *"Галина Петровнаны ул башкача итеп, бигрәк тә* ***боегып, моңланып*** *кичке шәфәкъка карап утырган авыру итеп уйлый алмый иде"* [2: 37] – *"В час его отлёта она* ***грустно*** *смотрела на заходящее солнце"* [1: 37]. Күргәнебезчә, *боегып, моңланып* синонимнарының берсе төшеп калган һәм *грустно* дип кенә тәрҗемә ителгән. Ә түбәндәге җөмләдәге синонимнар да, гомумән, җөмлә үзе дә тәрҗемә ителмәгән, төшереп калдырылган: *"Мин үз-үземне кызганмыйм, үз-үземә бик* ***аяусыз, шәфкатьсез*** *буласым килә"* [2: 61].

Гомумән алганда, Г. Әпсәләмовның иҗатында синонимнарның роле зур, ләкин аларның тәрҗемәдә бирелүе төрле һәм үзенчәлекле. Фәнни эш барышында синонимнар 3 төркемгә бүленде. Романда һәрбер төркемгә дә туры килүче мисаллар бар, димәк, тәрҗемә идеаль түгел. Тәрҗемә иткәндә

җибәрелгән хаталарны булдырмау һәм тәрҗемә өлкәсендә синонимнарны аерым алып өйрәнүгә киләчәктә зур урын бирелер дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**

1. Абсалямов А.С. Белые цветы: Роман. / Пер. с татарского К. Горбунова. Художник И. Субаев. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1987. – 560 с.

2. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 575 б.

## УРТА МӘКТӘПТӘ ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

*Вилданова И., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалиева Л.Ф.*

Табышмак татар халык авыз иҗатының кыска жанрына карый. Ул ике кисәктән тора: берсе – табышмагы әйтелү, икенчесе – чишелеше, ягъни җавабы. Табышмагын берәү әйтсә, җавабын икенче берәү әйтә. Һәр табышмак шулай чишелә.

Татар мәктәпләре өчен бирелгән дәреслекләрдә табышмаклар 5 нче сыйныфта өйрәнелә. Әдәби сүзлекчәдә түбәндәге билгеләмә бар: “Табышмак – төп сыйфатлары, кыяфәте читләтеп әйтү аша белдерелгән әйбер яки күренешне табу максатын куйган жанр” [1: 172]. Безнеңчә, биредә “жанр” сүзе урынына “халык авыз иҗаты әсәре” яки “кыска жанр төре әсәре” дип куелса, уңышлырак булыр иде.

Сан ягыннан табышмаклар бик аз бирелгән: барысы 11 табышмак. Аларның җаваплары төрле өлкәләргә карый, күбесенчә предметларны белдерә. Тема ахырында кызыклы, мавыктыргыч биремнәр бирелгән:

– “Табышмак ул – ...” дигән җөмләне үз сүзләрегез белән төгәлләп куегыз, җавапларыгызны чагыштырыгыз.

– Үзегез теләгән табышмакка рәсем ясагыз. Ни өчен шулай ясадыгыз. Аңлатыгыз.

Әлеге биремнәр укучыларның фикер йөртү, үзара фикер алышу сәләтен үстерәләр. Әмма биремнәр арасында сорау тудырганнары да бар. Мәсәлән: “Табышмак ничек һәм кайчан барлыкка килгән? Аларның төп сыйфаты нәрсәдә?” Әлеге сорауга җавап бирү өчен теоретик мәгълүмат бирелгән булырга тиеш, әмма дәреслектә ул юк. Укучылар әлеге сорауга җавапны өйдә әзерләп килергә тиешме, яисә җавапны фикер йөртеп, табарга тиешләрме? Безнеңчә, укучылар мәкаль-әйтемнәрне үткәч, табышмакларга керер алдыннан әлеге сорауга җавап әзерләп килергә тиеш. Укытучы балаларга әлеге мәгълүматны табу чыганагын әйтсә, яисә дәреснең кереш өлешендә әлеге мәгълүматны хәбәр итсә, әйбәт булыр иде.

Тагын шундый сорау бирелгән: “Табышмакны ни өчен күбесенчә балалар ярата?” Бу сорауны ишеткәч, балалар югалып калырга мөмкин. Без әлеге сорауны түбәндәгечә үзгәртер идек: “Балалар, сез табышмак яратасызмы? Ни өчен?” Әлеге очракта балалар бернинди авырлыксыз сорауга җавап бирә алачаклар.

Дәреслектә табышмакны өйрәнү өчен материал бик аз бирелгән. Шунлыктан укытучы әдәбият дәресләренә әзерләнгәндә өстәмә биремнәр, сораулар, викториналар әзерләп килергә тиеш дип саныйбыз.

Рус мәктәпләрендә укучы рус балалары табышмакларны 6 нчы сыйныфта үтәләр. Ә. Мотыйгуллина дәреслегендә табышмакларга аңлатма татар һәм рус телләрендә бирелгән: "Табышмаклар – кинаяләп яки сүз уйнатып әйтелгән һәм төп мәгънәсен уйлап белергә кирәк булган фольклор әсәренең бер төре. Гадәттә, ике өлештән тора: берсе – сорау, икенчесе – аның җавабы" [2: 108]. Әлеге дәреслектә 5 табышмак бирелгән, биремнәр – өчәү. Гомумән алганда, табышмак темасын үтү өчен дәреслектә материал бик аз. Дәреслектәге биремнәр теорияне кабатлауга, бирелгән табышмакларны дәфтәргә язуга һәм балаларның нинди табышмаклар белүен сорауга кайтып кала.

Күргәнебезчә, табышмакларны өйрәнү өчен дәреслек белән генә эшләү аз. Биредә уеннар, грамматик биремнәр оештыру кирәк. Без табышмаклар темасын үткәндә түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итәр идек: 1. Кем күбрәк табышмак әйтә? Әлеге биремне билгеле бер тематикага багышлап та үткәрергә мөмкин. Мәсәлән: хайваннар, кошлар, күк җисемнәре турында табышмаклар әйтү. Әлбәттә, иң күп табышмак әйткән укучыга яхшы бәя бирелергә тиеш. 2. Бирелгән рәсемнәргә карата табышмак әйтү яки уйлап чыгару. Әлеге бирем укучыларның фикерләү сәләтен арттыра. 3. Тапкыр җаваплы табышмаклар әйтү. Алар укучылырның уйлау дәрәҗәсен арттыра, сөйләмен камилләштерә. Төрле чыганаклардан тапкыр җаваплы табышмаклар табып килергә әйтү дә татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен балаларга өйрәтүдә мөһим чыганак булып тора. Мәсәлән: *Нинди сәгать тәүлеккә ике генә мәртәбә вакытны дөрес күрсәтә*? *Елның нинди айлары 28 көнне үз эченә ала*? 4. "Шаяру" уены. *Бер күл – күл, ике күл нәрсә*? (Күлләр). *Казан уртасында нәрсә бар*? ("З" хәрефе)

Табышмакны иң яратып әйтүчеләр балалар, яшүсмерләр, шуңа күрә мәктәпләрдә халык иҗаты башлангыч сыйныфларда ук өйрәтелә башлый. 5-6 нчы сыйныфларда әдәбият дәресендә бу темага аерым сәгатьләр дә каралган. Шулай ук укытучылар табышмакларны әдәбият дәресендә генә түгел, бүтән дәресләрдә дә, тәрбия бирү сәгатьләрендә, класстан тыш чараларда да куллана алалар.

Халык авыз иҗаты үрнәкләрен балаларга яттан өйрәтү, төрле хезмәтләрдән эзләнү эше алып бару, аларны кулланып диалоглар төзеп сөйләтү – укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә. Шулай итеп, балаларның сөйләме камилләшә, байый, сүзлек запасы арта. Укытучы дәресләрдә төрле күнегүләрдән файдаланып, балаларның сөйләм телен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Күргәнебезчә, табышмакларны татар мәктәпләрендә укучы балалар 5, ә рус мәктәбендәге укучылар 6 нчы сыйныфта үтәләр. Әлеге ике дәреслектә дә теманы үтү өчен материал бик аз бирелгән. Дәресләрдә табышмаклар чишү укучыларның уйлау, логик фикерәү сәләтен, фантазиясен үстерүдә ярдәм итәләр. Шулай ук табышмаклар балаларның күзаллавын киңәйтүдә дә зур роль уйныйлар. Рус балалары өчен табышмаклар әйтешү һәм аларны чишү һәрбер әйбернең сыйфатын, яңа сүзләрне истә калдырырга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Ганиева Ф.Ә. Әдәбият. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова; [рәссамы Светлана Ибраһимова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 175 б.

2. Мотыйгуллина Ә.Р. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 6 нче с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кис. / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Э.Х. Гыйзәтуллина; [рәссамы Диләрә Нәүрүзова]. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2014. – 119 б.

## РОЛЬ ПРОЕКТА «ВОЗВРАЩЕНИЕ К ИСТОКАМ» В ФОРМИРОВАНИИ ЭТНОКУЛЬТУРНОЙ КОМПЕТЕНТНОСТИ СТУДЕНТОВ

*Вотякова А., Удмуртский республиканский социально-педагогический колледж, студент IV курса*

*Рук. – Танаева С.Е.*

XXI век – это время кардинальных изменений в России и модернизации всех сфер ее социальной жизни. В том числе и образования.

Педагогические учебные заведения должны опережать происходящие социальные изменения, готовить своих студентов – завтрашних учителей к работе в обновляющихся условиях. Формирование готовности будущих учителей к осуществлению воспитательной деятельности в образовательных организациях на сегодняшний день остается приоритетным направлением учебно-воспитательного процесса педагогического учебного заведения, в том числе и нашего.

Наш колледж решает одновременно две важнейшие задачи: воспитание патриотизма, гражданственности, духовности, нравственности у будущих учителей и их профессиональной подготовки к осуществлению воспитательной деятельности в образовательных организациях. В формировании профессионально-значимых качеств личности студентов УРСПК важная роль принадлежит и средствам музейной педагогики.

В нашу жизнь входят новые технологические процессы, среди которых и проектирование, предлагающее обучение и развитие студентов на активной основе через целесообразную деятельность. В этом учебном году нами вновь был разработан проект «Возвращение к истокам». Целью данного проекта является развитие гражданственности, этнокультурных компетенций студентов через овладение профессионально – практическими

умениями и навыками музейной педагогики. Для реализации проекта были разработаны задачи: создать краеведческий отряд как механизм реализации социально значимой молодёжной инициативы, организовать исследовательскую деятельность в выбранном населённом пункте Удмуртии, представляющем этнокультурный интерес.

И в прекрасный сентябрьский день нам, активистам музея, совместно с главным редактором газеты «Янарыш» Рамзиёй Габбасовой и преподавателями колледжа удалось съездить в экспедицию в татарскую деревню Тавзямал Киясовского района. Татарская деревня порадовала солнечным светом и живописными видами. Нас встретили радушные местные жители, устроив нам чаепитие. Жители с удовольствием делились информацией о своей родной деревне. Годом образования деревни принято считать 1834 год, так как именно в этот год появилось самое раннее упоминание о деревне Тавзямал, тогда еще Елабужского уезда Вятской губернии. В настоящее время в деревне проживает 191 человек. Из них 13 учащихся, 4 студента и 56 трудоспособных гражданина, все остальные – это люди пенсионного возраста. В деревне имеется один магазин, фельдшерский пункт, фермерское хозяйство, дом культуры, а также мечеть. Мечеть строили всей деревней сами жители. Абдуллин Мансур Хайруллович внёс большой вклад в создание мечети: резные наличники, чарующие своим причудливым узором, а также минарет, устремленный ввысь – это всё изготовлено его «золотыми руками». Мечеть строили в течение двух лет. Теперь она радушно принимает население деревни в своих стенах и радует взгляд прохожих чудесным видом. Также жители деревни показали нам родник, который в настоящее время отреставрирован Мазиковым Булатом. На данный момент тавзямальцы активно думают над названием своего родника. Пока на народном голосовании лидирует «Тауҗамал чишмәсе», что в переводе с татарского обозначает «Тавзямальский родник».

В этот день нам удалось увидеть творчество местных жителей. В местном клубе был организован концерт для жителей и гостей. Вокальный ансамбль Тавзямала «Чулпан» погрузил нас в чарующие татарские напевы. Данный ансамбль радует людей своим творчеством уже 23 года. Ансамбль принимает участие в местных и районных мероприятиях, выступает на международных фестивалях и выездных концертах.

Нас поразила богатая материальная культура жителей деревни. Об этом свидетельствуют отзывы студентов – участников экспедиции: «Поездка произвела огромное впечатление. Я получила необычайное удовольствие и наиболее полное представление о татарах Удмуртии. Когда рассказывают о чем-либо красиво и со знанием дела, информация хорошо запоминается, а когда ещё и показывают – усваивается великолепно», «Я узнала много нового про Тавзямал, его жителей, их быт и культуру. Я не знала,

насколько богата история нашей земли. После этой встречи я стала по-другому относиться к тому месту, где живу». Так и подошла к концу наша экспедиция, которая дала возможность приобщиться к татарской культуре, узнать много нового и интересного, насладиться прекрасными видами, а также пообщаться с такими открытыми и искренними людьми. Эта поездка подвела к мысли о том, что нужно знать историю малой родины, чтить традиции, исследовать культуру родного края. На этом проект «Возвращение к истокам» не завершен, впереди – новые экспедиции.

**Литература**

1. Народы России: Атлас культур и религий / отв.ред. В.А. Тишков, А.В. Журавский, О.Е. Казьмина. – М.: ИПЦ "Дизайн. Информация. Картография", 2008. – 256 с.

2. Степаненко Е.А. Праздники, обычаи и традиции татарского народа [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://www.syl.ru/article/359277/prazdniki-obyichai-i-traditsii-tatarskogo-naroda, свободный. – Загл. с экрана (дата обращения: 27.09.2018).

## КӨРКЕМ МАЗМҰНДАҒЫ ӘЛЕУМЕТТІК ӨМІР КӨРІНІСІ

*Габбасова А., М. Қозыбаев атындағы Солтүстік Қазақстан мемлекеттік университеті, ІІ курс магистранты*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., проф. Ж.Т. Қадыров, ғылым магистрі Тагудретова Б.Б.*

Балалар әдебиеті – бүгінгі ұлттық әдебиетімізде көркемдік-шығармашылық және тағылымдық-тәрбиелік мақсаттарды басты назарда ұстап, балалардың жас ерекшелігіне қарай дамып келе жатқан сала. Бұл салада балалардың жастық, білімділік ерекшеліктері еске алынады. Олардың психологиялық өсу процестері ескеріледі.

Қазақ балалар әдебиеті жылдан жылға сан жағынан да, идеялық сапасы жағынан да өсіп келеді. Мұның қоғамдық ірі мәні бар. Өйткені балалар әдебиеті – жас ұрпақтарға ұлттық тәрбие берудің қуатты құралы. Ол жастарды ұлттық патриоттық рухта тәрбиелейді, озық ойларымен қаруландырады. Қандай қиыншылықтарды болса да, оларды жеңуге ұмтылдырып, жігер-қайратын арттырады.

XXI ғасырдың балалары өзінің ойлау қабілеті, таным-түсінігі, мүмкіндіктері мен мұқтаждықтары жағынан өткен ғасырдың елуінші жылдарымен салыстырғанда, әлдеқайда алда, биікте тұр. Себебі сонау жылдары велосипед, қағаздың өзі таңсық нәрсе болса, балалар ұшқыш, мұғалім болам деп армандаса, қазіргі заман балаларының арман-мақсаттары мүлде басқа. Төменгі сыныпта оқитын балалардың өзі компьютерден бас алмайды, ұялы телефонды үлкендерден қалыспай ұстайды, кітапханаға баратын бала аз, техниканың дүрілдеп дамып тұрған заманында баланың таным-түсінігі де, арман-мұраты да өзгерді.

Қазіргі қазақ балалар әдебиетінің қалтарыстарына көз жіберсек, социалистік реализм шарттарының күні бүгінге дейін қаз-қалпында

сақталып келгеніне көзіміз жетіп, жаңаша жазуға шақыратын модернизм сияқты ағымдардың тамыр байлар топырағын таппағанына қынжылған болар едік. Қай кітапты ашсақ да, бір жағымдымен, бір жағымсызбен деген кейіпкерлер алдыңнан, көлденеңіңнен шыға келетіні қоспасыз шындық қой. Олар оқырман сезімін оята алмайды, көбі шала-жансар. Қуанғандары да, жылағандары да жасанды. Біз жәбір көріп, көз жасын төккен қаздан гөрі ағайынды Гримдердің «Сүйкімсіз балапанын» қаттырақ аяймыз. Ендеше кейіпкерлеріміздің көпшілігі өлшеулі жерге жығылмай жетіп, жаттаған сөздерін жаңылмай айта алатын роботтарға ұқсайды.

Қастек Баянбай «Кішкентай әдебиеттің үлкен мұңы» атты мақаласында: «Оқырманның бауырына кіріп, тонның ішкі бауындай жақындаса алмайды, күлмейтін, жыламайтын жасанды мүсіндер бәріне де салқын. Сонысына қарай оқырмандар да оларға самарқау. Кітаптың соңғы бетін жапқан бойда есімін де, түр-түсін де, қылығын да ұмытады», – дейді.

«Жазушы өз кейіпкерлерінің іс-әрекетін, өмірге көзқарасын, яғни, характерлерін айқындау арқылы халықтың белгілі бір кезеңдегі тіршілігін, болмысын, қоғамдық идеяны көрсетеді. Бір сөзбен айтқанда, қоғамдық идея көркем образ арқылы көрініп отырады. Әрбір көркем образдың өзі өмір сүріп отырған қоғамына, әлеуметтік ортасына байланысты, яғни, типті жағдайға орай көрінуі реалистік шығарманың басты шарттарының бірінен саналады. Олай болса типті образды жазушы жоқтан бар етіп, ойдан, қиялдан тудырмайды, оның өзі қоғамдық өмірдің даму процесін тудырады. Сондықтан да позицияда тұрса ғана өмір көрінісін шынайы түрде дәуірі тудырған нағыз типті характерді жасай алады. Өйтпеген күнде, заманы, әлеуметтік ортасы тудырған типті образдарды жалған идеяға қойса, образ да бар шындығынан айырылып жалған шығады» [1: 38].

Дегенмен, бұл кезеңде де алдыңғы қатардағы жетекші образ ретінде бояуы қанық реалистік образдар түрлерін алдымен айта кеткен жөн. Бұл бағытта жоғарыда аталған қаламгерлердің қай-қайсысы да уақыт тынысын сездіре алатын, көркемдік талап деңгейінде өрілген балалар бейнелерін жасауға атсалысып келді. Жасыратыны жоқ, олардың басым көпшілігі сол жылдардағы ауыл балаларынан алынған жиынтық бейнелер болғаны байқалады. «Көркем әдебиеттегі образ дегеннің өзі ақиқат өмірдегі адам және бір адам емес, жиынтық бейне ғой. Ал өмірдегі әрбір адам өзінше оригинал, өзінше құпия. Әр адамды ашу, тану қажет» [2: 41]. Қазақ жазушылары қаламынан шыққан мұндай жиынтық бейнелердің барлығы бірдей көркемдік биік деңгейде сомдалды деп бағалау да қиын.

Қазіргі қазақ балалар прозасындағы жеткіншектер бейнесін жасауда көркемдікпен өзіндік өрнек салып, бедерлі жиынтық образдар жасап жүрген жазушылардың бірі – Тынымбай Нұрмағамбетов. Бұл қаламгер жөнінде пікір айтушылардың бірі: «Адамның жан-дүниесіне, характер

ерекшелігіне үңіліп, сезім мен суретті қатар іздеп жүрген қаламгерлердің бірі – Тынымбай Нұрмағамбетов. Тынымбай өмірді жақсы біледі, ол сол өмірдің өзіндік өрнегін шебер тілмен өрнектеп беруге бейім» деп түйіндеген болатын [3: 46].

Тәуелсіздік кезеңімен бірге келген қоғамдық-экономикалық өзгерістер қазақ прозасына да жаңа леп алып келді. Ұлттық идеяға негізделген біршама дүниелер келді. Аталмыш кезеңдегі жер мен ел тағдыры, «қазақтың алтын бесігі – ауыл» тақырыбы мен ұлттық таным, ұлттық рухты бейнелеп жазған туындылардың өзіндік ерекшеліктері болды. Ол ерекшелік алдымен өмір шындығының көркем шындыққа айналу формасында болды. Осы кезеңге дейін кеңестік жүйе қыспағынан еркін ажырап шыққан қазақ әдебиеті алғашында абдырап қалғаны рас-тын. Ұлттық салт-дәстүрімізді, ислами құндылықтарымызды дәріптеп, қазақылығымызды жоғары көтеріп бейнелеген туындылармен бірге саяси-әлеуметтік өміріміздегі болып жатқан өзгерістер: ауылдың қаңырап бос қалуы, алып-сатқан саудагерлермен, бизнесмендер мен қарапайым адамдар бейнесінің шындығы шынайы әлеуметтік пайыммен бедерленді.

Бүгінгі заманның балалары өткен кезеңдердегі балалар тағдырын, яғни, ата-әкелеріміздің өмір жолдарын, балалық кездерін, олардың өмір сүрген дәуірін біле бермейді, кей жағдайда білуге де ниет етпейді. Ол – тарих. «Тарихты білмей, өткенді, қазіргі жағдайды білу, келешекті болжау қиын», – деп Әл Фараби айтқандай, әдебиетіміздің тарихын білуіміз – басты міндет. Ол кезеңдерді біз тарихтан, әсіресе көркем шығармаларды оқу арқылы біліп танимыз.

Қорытындылай келе, көркем мазмұндағы әлеуметтік өмір көрінісінің балалар прозасында берілуін бағалауда Б. Ыбырайымның мына бір пікіріне назар салғымыз келеді: «Жинақтап айтқанда, жетпісінші-сексенінші жылдардағы балалар жазушылары енді балалық шақты, көңілді мектеп өмірін, ауыл тірлігі мен тұрмысын, жан-жануарларды суреттеумен шектелмей, болмысты кейіпкерлердің өзіндік адамгершілік мұраттарына орай туындайтын талап-ұмтылыстарымен тығыз бірлікте байыптауға, көркемдік ойдың саралануы мен өз кезіндегі белгі-бедерін барлауға бастайтын көптеген эстетикалық-этикалық категорияларды образдар арқылы батыл бейнелеуге ден қойды... Шеберлік деңгейі өсіп, көркемдік шындық болмысты байыптау мен бейнелеудің өзіндік жүйесіне, өмірдің аналитикалық, образды шежіресіне айналды.

**Әдебиет**

1. Дүйсенов М. Әдебиеттегі мазмұн мен форманың бірлігі / М. Дүйсенов. – Алматы: М. Әуезов атындағы әдебиет және өнер институты, 1962. – 209 б.

2. Сахариев Б. Күрескер тұлғасы: мақалалар, зерттеулер. – Алматы: Жазушы, 1979. – 375 б.

3.Дәрімбетов Б. Жастар туралы / Құрастырушы С. Әшімбаев. – Алматы: Жалын, 1981. – 208 б.

# ХӘЙ ВАХИТ ДРАМАЛАРЫНДА ФОЛЬКЛОР

*Габдрәшитова А., Габизов И.,Саба р-ны Шәмәрдән лицее, XI сыйныф*
*Җит. – Сабирова Р.Ә.*

Фольклорның әдәбиятка һәм сәнгатькә күпьяклы тәэсире – танылган хакыйкать. Халык иҗатындагы сюжет һәм мотивларны куллану исә борынгыдан алып бүгенгәчә дәвам итә. Кайсы гына чор әдәбиятына яки кайсы гына язучы,шагыйрь яисә драматург иҗатына күз салсак та, халык авыз иҗаты белән бәйләнешне күрә алабыз. Хәй Вахит иҗатының фольклор белән бәйләнеше ни дәрәҗәдә икән? Менә шушы сорау кызыксындырды безне. Шул сәбәпле без фәнни-тикшеренү эшебезне Хәй Вахит әсәрләрендә халык авыз иҗатының ни дәрәҗәдә кулланылуын өйрәнүгә багышладык һәм “Хәй Вахит драмаларында фольклор” дип атадык. Эшебезнең максаты – әсәрләрне өйрәнеп, фольклор белән бәйләнешен ачыклау. Тикшерү объекты итеп, “Яшьлек юллары”, “Пьесалар”, “Күк капусы ачылса” җыентыкларын алдык.

Хәй Вахит, чын халыкчан драматург буларак, иҗатында фольклорга еш мөрәҗәгать иткән. Аларда автор татар фольклорының мәкаль, җыр, әкият, хикәят, сынамыш, һәм башка жанрларына караган әсәрләрен үзгәрешсез хәлендә тулаем да, өлешчә дә, кирәк булганда үзгәртеп тә файдаланган. Х. Вахит үз иҗатында характер тудыруда еш кулланылган поэтик алым – мәкаль-әйтемнәрне аеруча еш кулланган. Алар аша әсәрләренең телен халык сөйләменә якынайткан, образлылыгын көчәйтүгә китергән. Хәй Вахит мәкальләрне үз әсәренә күбесенчә әзер хәлдә кертеп җибәрә. Мәсәлән, “Тел сөяксез, ул ни сөйләмәс”, “Телең нәрсә сөйләгәнне колагы ишетми”, “Дүрт аяклы ат та сөртенә”. Ә кайбер очракта ул аны үзенә кирәкле рәвештә үзгәртеп кертә. Мәсәлән, “Беренче мәхәббәт” драмасында “Кызым сиңа әйтәм, киленем, син тыңла” мәкален “Кызым сиңа әйтәм, Тәлгать, син тыңла”, “Бер акыл яхшы, ике акыл яхшырак” урынына “Бер акыл яхшы, бер ярым акыл яхшырак” дип, Рәхиләнең гади генә нәрсәләрне дә аңлый алмавына ишарә итә. Драматург әсәрләрендә башка милләт халкының да мәкальләреннән оста файдаланган. Рус халкының “В каждой шутке есть доля правды”, “Не было бы счастья да несчастье помогло”, “Чем черт не шутит, когда бог спит” мәкальләрен “Сәер кеше” драмасында бик оста кулланган. Шулай ук “Рәхим итегез” пьесасында немец халкының “Укысаң, катман булырсың; укымасаң – черки” мәкален Зәйтүнәнең сөйләменә кертеп, аның белем дәрәҗәсен күрсәтүгә ирешә. Ә инде “Җырым табар сине” драмасында кытай халык мәкален дә урынлы куллана : “Ун адым атларга кирәк булганда, тугыз

адым атлагач, ярты юлны үттем дип исәпләргә була”. Драматургның 13 сәхнә әсәреннән 72 мәкаль һәм әйтем язып алдык.

Җырлар – халык иҗатының бик бай һәм үзенчәлекле ягы. Җырда – кешенең уй-теләкләре, хис-кичерешләре; тел әйтә алмаганны җыр әйтеп бирә. Шуңа да Х. Вахит сәнгатьнең бу төренә еш мөрәҗәгать иткәндер. Пьесаларында татар халык җырларын да, үзе язган җырларны да шактый күп куллана. Мин тикшергән әсәрләрдә халык җырларының барлык төрләре дә очрый. Йола җырларына мисалга, никах туенда башкарылган җырларны әйтә алабыз. “Талак, талак”, “Ике килен-килендәш”, “Соңгы хат”, “Күк капусы ачылса” музыкаль комедияләрендә туй йоласы белән, шушы матур бәйрәмдә башкарыла торган җыр-такмаклар белән танышабыз: *Ай икегез, икегез, Икегезнең битегез... Икегез дә пар килгәнсез, Тигез гомер итегез...* (“Сәер кеше”).

Лирик җырларга килгәндә, Х. Вахит татар халык җырларын ничек бар шулай гына алмый, ә бәлки, аларны берникадәр үзгәртә: я кушымтаны, я текстны ситуациягә туры килгән сүзләр белән алмаштыра. Мәсәлән, “Талак, талак” пьесасында түбәндәге татар халык җырының соңгы кушымтасын үзгәртә: *Җир җиләге ачы була Үз вакытында пешмәсә. Кеше хәлен кеше белми Үз башына төшмәсә. Сайрый тургай, Җырлый бытбылдык. Кем идек тә, Кем булып калдык.* Кода булып килгән Шәйдулланың хис-кичерешен җиткерү максатыннан, “*Кем идек тә ,кем булып калдык*” урынына “ *Кода булып килдек, хур булдык”* дип бирә.

Драма әсәрләренең һәркайсында аеруча киң кулланылучы җырлар лирик җырлар төркеменә карый. Бу җырлар, чыннан да, кешенең рухи халәтен чагылдыру өчен бик уңышлы. Аларда геройның хәсрәте дә, шатлыгы да чагылыш таба: *Җир җиләге җирдә булмый ,Түтәлдә булмас инде. Минем күңелем синдә булмый,Бүтәндә булмас инде* (“Беренче мәхәббәт”). Тарихи җырлар көндәлек тормышта еш яңгырамыйлар. Әсәр текстында без аларны очратмадык.Мисаллардан күренгәнчә, язучы халык җырларын тирән мәгънәне җыйнак бирү хасиятеннән оста файдалана. Шулай ук Х. Вахит драма әсәрләрендә табышмаклар да (“Утта янмый, суда батмый” (“Сәер кеше”), әкият мотивларын да (“бүре барыбызны да берәм-берәм тотып ашады” (“Сәер кеше”), үртәвечләрне дә (Газиз: көнче, Рәмзия: көнче, Газиз: бака-ка, Рәмзия: бака-ка” (“Күк капусы ачылса”), сынамышларны да (“Күк капусы ачылса”) очратырга була. “Җырым табар сине” пьесасында юрау белән дә очрашабыз: Сәрия сөйгәне Шәүкәт турында: “Яратамы соң ул мине? Әгәр дә яратса, ул янындагы кызны биергә чакырмаячак, минем янга да килмәячәк. Ул тәрәзә янына китәчәк. Әгәр дә яратса” дип юрый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, драма әсәрләрендә халык авыз иҗаты үрнәкләре, аеруча җырлар, такмаклар, мәкаль-әйтемнәр шактый еш

кулланылган. Аларның вазифасы күптөрле. Алар геройларның хис-кичерешләрен тулырак чагылдыру, сөйләмне матурлау, эмоциональлекне арттыру өчен хезмәт итәләр.

**Әдәбият**

1. Әхмәдуллин А. Хәй Вахит (1918-1978: [драматург тур.] // Татар әдәбияты тарихы.– 2001. – Т. 6. – Б. 388–405.
2. Ключарев А.С. Татар халык җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 488 б.
3. Хәй Вахит. Күк капусы ачылса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 350 б.
4. Хәй Вахит. Яшьлек юллары. Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978, – 421 б.
5. Хәй Вахит. Пьесалар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1984. – 192 б.

## Г. САБИТОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ОБРАЗ ТУДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Габдуллин Р., КФУ, I магистранты*
*Фән. җит. – канд. филол. наук., доц. Гайнуллина Г.Р.*

1960–1980 еллар прозасында психологизм традицияләрен үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән Габделхай Сабитовның әдәби текстының үзенчәлекләрен образ тудыру ягыннан җәһәтеннән өйрәнү бик вакытлы һәм урынлы дип табылды.

Г. Сабитов иҗатында игътибар еш кына балачактан үсмерлеккә күчү чорына юнәлтелә. Әдипнең «Ярсулы яз» (1971) исемле хикәясендә яшүсмер образлары алга чыгарылган. Вакыйгада Гамил, Гөлүсә, Галләм абый образлары катнаша. Персонаж характеры башкалар белән мөнәсәбәттә, эш-гамәлләрдә, тойгы-хисләр тасвирланышында, сөйләмдә бирелә.

Г. Сабитов бөтен әсәрләрендә дә кеше образын табигатьнең бер өлеше итеп тасвирлый.Хикәядә вакыйга яз көне бара. Яз көне бөтен җиһан уяна, яңа тормыш башлана,яңа тәэсирләр кирәк була башлый. Гамил белән дә шул ук хәл. Тик быелгы яз «әллә ничек бик ярсулы да, бераз ямансурак та» [1: 335]. Бу ямансулык малайга да күчә: «Әллә нәрсә булды малай күңеленә. Кайгы дисә, кайгырыр сәбәбе дә юк, сагыш дисә, сагыныр кешесе дә юк. Ә шулай да күңел нәрсәдер юксына, нәрсәдер көтә» [1: 335]. Әсәрдә яз ике яссылыкта тасвирлана: табигый яз һәм күңелдәге яз. Хикәядә алар тыгыз үрелеп баралар. Тагын шунысы да мөһим: алар икесе дә ярсулы. Автор аны көчле позициягә дә чыгара. Шушы ярсулык геройларны үзләре өчен гадәти булмаган гамәлләр кылырга этәрәчәк тә. Димәк, Гамил белән Гөлүсәнең күңел халәте табигать белән янәшә бирелә.

Хикәядә Гамил – төп герой. Ул – гади укучы, башкалар кебек үк мәктәпкә йөри, дәрестә утыра һәм контроль эшләр эшли. Гамил математика белән дус һәм класста иң яхшы укучыларның берсе. Бервакыт малай үзе өчен гадәти булмаган эш башкара: күрше кызы Гөлүсәгә караламасын бирми. Әсәрнең конфликты Гамилнең Гөлүсәгә ярдәм итүдән баш тартуы, «күрше хакын» үтәмәве булып оеша. Шулай итеп, әсәрдә Гөлүсә образы килеп керә. Ул ярдәмче образ вазифасын үти һәм төп

персонажны билгеле бер вакыйгаларда үсеш-үзгәрешкә этәрүче була. Образ ясау алымнарының берсе – геройны башкалар белән каршы кую – портретны, эш-гамәлләрне сурәтләгәндә, сөйләшү-аралашу рәвешен күрсәткәндә ачык күренә. Күңел талпынуы малайны аның өчен гадәти булмаган адымнар ясарга этәрә. Контроль эш язылган караламага «җиргә төшкән чыпчыкны эләктерергә тырнак чарлап торганда, чыпчык очып киткәч, мәче баласы ничек караса», Гөлүсә дә нәкъ шулай күзләрен тутырып карап тора. Малай аны юкка гына мәче белән чагыштырмый. Вакыйгаларның мондый борылышына әзер булмаган Гамил шулай да югалып калмый. Ул кызга җавап рәвешендә тагын берәр «этлек» эшләргә тиеш дип саный. Язның «ярсулы ташкыны» яшүсмерләрнең күңелләренә үтеп кереп, гадәти булмаган адымнар ясарга этәрә. Гамилнең инде үч алу планы да әзер: кар астына су төшкәнен белгәч, ул кое казый һәм аның су белән тулганын көтеп тора, кое авызына көрәк каплап, юеш кар җәеп куя. Әзерлек эшләре тәмамланып, мәктәптән өйгә кайтып барышлый бер-ике сүз алышканнан соң, Гөлүсә Гамилгә бүтәнчә булып күренә. Малай күңелендә бер мизгелдә әллә нинди үзгәрешләр булып ала. Шушы урында хикәяләүче Гөлүсәнең портретын бирә. Әйтергә кирәк, Г. Сабитовның язу стиленең тагын бер үзенчәлеге – тышкы кыяфәтне сурәтләгән вакытта геройга шәхси мөнәсәбәтен белдерүе, ягъни тойгы-портрет төрен яратып куллануы: «Бөеренә таянды да, кечкенә генә ап-ак итек-читекләре белән юеш кар чәчрәтеп, бөтерчектәй бөтерелеп куйды, кыбырсык. Килешеп тә тора икән үзенә. Неп-нечкә билле, тиз тиңентен генә язгы пәлтәсе дә, башына бәйләгән аллы-гөлле, буй-буй шарфы да өздереп килешә. Ә бигрәк тә әлеге шул уенчыктай җиңел ак читекләре! Әйтерсең ак бәкәлле колын» [1: 91]. Инде күзләренә тутырып карагач, үч алу хисен соклану алыштырып куя: «Ә күзләре... Озын керфекләр арасына яшеренгәннәр дә менә-менә көлеп җибәрергә торалар. Керфекләре дисәң... Туа-тумыштан терәлеп торган күрше булып, бер урам чирәмендә аунап, шушы көннең шушы сәгатенә кадәр ничек искәрмәде икән Гамил бу керфекләрне... Шундый озын, шундый куелар, әйтерсең аерым бөртекләр түгел, ә тоташкан кара элпәләр – кара күбәләк канатлары...» [1: 91]. Хәзер инде Гамил киресенчә, кызны үзе үк казыган коедан коткарырга тели: «Әллә кинәт кенә әлеге ак итек-читекләрне кызганып куйды Гамил, әллә кызыйның нәзек кенә аякларын аяды, әллә инде һавадагы тургайлар бер-бер киңәш бирде үзенә!» [1: 91]. Шулай итеп, малай көтмәгәндә бар ниятләрен үзгәртеп куя. Бу урында укучы Гамилнең күңел кылларын селкетеп җибәргән табигать образының малайга тәэсирен тоеп ала. Ярсулы яз тәэсире, тургайлар тавышы, түбәдән тамып торган тамчылар, рәхәт кояш нурлары һәм Гөлүсәнең кара керфекләре – болар барысы да Гамилнең күңеле инде күптән көтеп яшәгән үзгәрешләргә этәргеч була.

Г. Сабитов хикәяләре – татар прозасының энҗе сәйләне ул. Әдипнең барлык хикәяләре 1960–1980 еллар әдәби барышы контекстында һичшиксез тирәнтен өйрәнелергә тиешле.

**Әдәбият**

1. Сабитов Г. Ай сукмагы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 335 б.

## И. ЮЗЕЕВНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫНДА ПОЭМА ЖАНРЫ

*Габидуллина Э., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Юсупова Н.М.*

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты үсешенә тирән өлеш керткән һәм үзенең шигъри аһәңе, романтик рухы беләнаерылып торган шагыйрьләрнең берсе – И. Юзеев. Аның исеме республикада чыга торган газета-журнал битләрендә илленче елларның башында ук күренә башлый. Унсигез яшендә язган “Тормыш җиңә” поэмасы заманында укучылар тарафыннан җылы кабул ителсә дә, татар шигърияте мәйданында улүзенең “Таныш моңнар”ы (1955) белән танылa. Әлеге поэма “Совет әдәбияты” журналында чыгу белән үк яшьләрнең яратып укыла торган әсәренә әверелә.Әсәр әдәби тәнкыйть һәм җәмәгатьчелек тарафыннан да югары бәяләнә [4: 300].

Алтмышынчы елларда И. Юзеев шигъриятендә берничә жанр формасы тармакланып китә: берсе – зур күләмле эпик поэмалар, икенчесе – халык традициясенә якын торган лирик җыр текстлары, өченчесе – балалар өчен язылган шигырьләр. И. Юзеев поэзиядә форма төрлелегенә омтылса да, аның иң яраткан һәм иң продуктив эшли торган жанры булып поэма кала [4: 309]. Ул – 20 дән артык поэма авторы.

Поэма – лиро-эпик жанрлар арасында күләмлесе; аңарда прозаның хикәяләү алымнары, сюжет-композиция төзелеше, лирик чигенешләр, кисәкләр белән бергә үрелеп, аралышып килә.Борынгы заманнарда тезмә белән язылган барлык әсәрләрне дә поэма дип йөрткәннәр. Хәзер бу термин белән вакыйгалар һәм хисләр агышын шигъри формада хикәяләгән урта күләмле лиро-эпик әсәрләрне атыйлар. Иң элек, поэмаларга гына хас булган сыйфатларның берсе – вакыйгалык, дип саныйлар белгечләр. Бу якка “Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр” сүзлегендә дә басым ясала: “Поэма – лиро-эпик жанр атамасы, сюжет сызыклары лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп бара, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә торган әсәр” [1: 143].

И. Юзеевның башлангыч чор иҗатында туган җирне ярату, яшьлек, мәхәббәт мотивлары әйдәп бара. Бу тенденция поэма жанрында да алда тора. Мәсәлән, аны татар поэзиясендә яшьлек шагыйре итеп таныткан “Таныш моңнар” (1954–1955) поэмасы яшь кыз Резидәнең хезмәткә мөнәсәбәтеүзгәрүне сурәтли. Мәхәббәтеннән һәм хезмәтеннән баш тартып, шәһәргә институтка киткән Резидә үзе дә хезмәт кешесенә, тир түгүдән тәм

табучыга әверелә. Поэмада, хезмәт кешегә бәхет һәм үзен файдалы итеп тою китерә, мәхәббәт – иң кадерле хис, тормыш авырлыклары алдында югалып калмаска кирәк, чын мәхәббәт тормыш каршылыкларына бирешми, кебек фикерләр укучыга җиткерелә [3: 60].

Мәхмүт Калинкин һәм Фатыйма Гафурова истәлегенә багышланган "Фәрит-Фәридә"(1958–1959) драматик поэмасында исә фаҗигале, үкенечле мәхәббәт тарихы үзәккә алына: күршедә үскән, бер-берсен яраткан Фәрит белән Фәридә фашистларга каршы партизан хәрәкәтендә катнашалар, кулга алыналар һәм үтереләләр. Әсәрдә туган ил өчен гомерен биргән яшьләрнең үлемсезлеге, батырлыкка дан җырлау мотивлары көчле бирелә [3: 60]. Әсәрне үлем-үлемсезлек каршылыгы аша яшәү мәгънәсе турындагы эчтәлек тулаем ачып җибәрә. Автор әсәрдә янәшәлек алымын отышлы файдалана һәм шуның белән укучының игътибарын җәлеп итә. Шагыйрь, романтик әдәбиятка хас булганча, вакыт күренеше ярдәмендә вакыйгаларны янәшә кую мөмкинлегеннән файдалана. Мәсәлән, мәктәп балаларының буранда тау шуу вакыйгасы, 18 яшьлек егет белән кызның туган көннәрен үткәрү сугыш башлану белән алышына [2: 65].

Шуның белән янәшәдә әсәрләрдә, гомумән, кеше рухының бөеклеге, кешенең яшәү көче, ныклыкның тамырлары,нигезе хакында уйланулар да аерым бер әһәмияткә ия. Шагыйрьнең бу чор иҗатында шәхеснең үз-үзен һәм яшәешне танып-белү фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле фәлсәфи мотивларның көчәеп китүен күрергә мөмкин. Мәсәлән, композициясе һәм ритмик аһәңе белән башка әсәрләреннән аерылып торган "Өчәү чыктык ерак юлга..." (1965) поэмасында кәккүккә бәйле ышынулар тергезелә. Кешенең тормышта үз урынын эзләве хакындагы поэмасында И. Юзеев, Фазылҗан язмышы аркылы, кешенең яшәеше һәм үз-үзен танып-белүе, кеше гомеренең кыйммәте, язмыш, яшәү, яшәеш мәгънәсе хакында фәлсәфи фикерләрен җиткерә. Композицион яктан реалистик, романтик, фәлсәфи катлам-башлангычларның кушылмасы, синтезы төсендә уйланылган әсәрне кәккүкнең кеше гомерен санавы хакында бәян (мифологик ышану) бербөтенгә туплый [3: 63]. Әсәрнең идеясе буларак, кеше кулында үз язмышы гына түгел, бөтен галәм, кешелек язмышы, кеше шуны тоеп, миссиясен үтәп яшәргә тиеш дигән фикере аша җиткерелә.

Күргәнебезчә, шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында мәйданга килгән өч поэмасы да романтик рухы, яшьлек дәрте, омтылышы, фикерләве белән аерылып тора. Әсәрләрендә лирик герой яки хикәяләүче җир һәм галәм берлегенә омтыла, ил язмышы өчен борчыла [3: 80]. Бу поэмаларда кешенең яшәешне һәм үз-үзен танып-белүе, кеше гомеренең кыйммәте, кеше язмышы, яшәү мәгънәсе хакында фикерләр әйдәп бара.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төз.-авт. Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 272 б.

2. Даутов А. И. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм. – Казан: ИНТЕЛПРЕСС, 2002. – 152 б.

3. ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы: 2 кисәктә. 2 нче кис. / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. – 252 б.

4. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: 60–90 еллар әдәбияты. – Казан, Раннур, 2001. – 544 б.

## ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ «БУРАНДА» ХИКӘЯСЕНДӘ ӘДӘБИ УРЫН ҺӘМ ВАКЫТ БИРЕЛЕШЕ

*Газиева А., Казан, 34 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Гимадеева Н.Р.*

Татар халкының күренекле язучысы Шәриф Камал безнең өчен күпсанлы хикәяләрен, повестьларын мирас итеп калдырган әдип. Без аның әсәрләре белән урта сыйныфлардан ук танышып киләбез.

Язучы кешеләр табигатендәге кыргыйлык, вәхшилек, ваемсызлык, каты күңеллелек кебек тискәре сыйфатларны калкытып күрсәтә. Биредә автор үз геройларында тискәре сыйфатларны туплап бирә. Әйтергә кирәк, аның бу геройлары “уяна”, ләкин инде соң була. Шундый әсәрләр рәтенә Ш.Камалның “Буранда” исемле хикәясен кертәбез.

Әлеге әсәр үткен сюжеты, психологизмы, бай сурәтләү чаралары белән генә түгел, ә үзенчәлекле хронотоп бирелеше ягыннан да игътибарны җәлеп итә.

Хронотоп урын һәм вакыт берлеген тәшкил итә. Терминнар һәм төшенчәләрнең әдәби энциклопедиясендә хронотопка түбәндәге билгеләмә бирелә: “Хронотоп (грек. chronos – вакыт, topos – урын) – әдәбиятта чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау; әдәби әсәрдә сурәтләнгән дөньяның әһәмиятле элементы” [1: 214]. Димәк, хронотопта урын һәм вакыт бердәмлектә, кушылуда чагылыш таба.

Ш.Камалның “Буранда” хикәясенең урын-вакыт ягыннан оештырылышы үзенчәлекле. Әсәрдә хронотоп геройның уй-кичерешләрен, теләк-омтылышларын ачыкларга ярдәм итә.

Әсәрдәге вакытны өч үзәк тирәсенә җыярга мөмкин:

1. Календарь вакыт. 2. Вакыйгалар вакыты. 3. Перцептив вакыт [4]. Повестьта календарь вакыт – кыш ел фасылына туры килә. Әсәр башында ук кышкы күренешләр бирелгән: “Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган,дулый, лапас һәм морҗаларда әллә нинди моңлы җырлар җырлана иде...” [6: 16]. Кыш Мостафа тормышындагы билгеле бер халәтне ассызыклый, ягъни ул символик мәгънәгә ия.

Вакыйгалар вакыты ХХ йөз башы белән билгеләнә. Ул кешеләрнең яшәү рәвешендә, көнкүреш детальләрендә табыла. Хикәядә китерелгән

түбәндәге юллар, вакыйганың Герман сугышыннан соң булуына ишарәли: “Аның картузы кызыл тирәле булып, шинель погоннарына сары буяу белән Германия императорының вензеле төшерелгән иде: Вильгельм Икенче – Калуга полкының шефы, имеш” [6: 8].

Ләкин иң мөһиме – перцептив вакыт. Ул Мостафа күңелендәге хис һәм акыл көрәшен күзәтеп, аның фикер агышы артыннан “ияреп бару” кебек тәэсир калдыра, киңәйтелгән, сузылган булуы белән дә үзенчәлекле. Димәк, ул психологик характерда чагылыш таба. Әлеге вакыт Мостафаның әнисе белән очрашуын көтүдән – өмет өзүгә вакыйгасын үз эченә ала. Психологик вакыт исә геройның уйлары, эчке монологлары, хис-кичереш, хәл-халәт үзгәреше белән бирелгән.

Календарь вакытта туры килә торган кышкы буран күренеше Мостафа күңелендәге эч пошу, борчылу, күңелсезлек, моңлану белән үрелеп барыла. Шулай итеп, календарь вакыт һәм психологик вакыт бер-берсен кабатлап килә. Бу кабатлау табигать һәм кеше халәтен янәшә куярга ярдәм итә.

Мостафа солдаттан үзгәреп кайта, бу үзгәрешне дусты да сизеп ала. Мостафаны нидер борчый, ул каядыр ашыга. Әсәрдәге ярдәмче вакыйга – яшь бала елавы, әнисенең төн буе күзен дә йоммый аны тынычландырырга теләве. Бу төнне Мостафаның күңелендәге хисләре асты-өскә килә. Төн хронотобы аңа тынычлык алып килми, киресенчә, кайчандыр гамьсез, кешедән көләргә яратучы, салкын җанлы кешенең йөрәгендә борчу барлыкка китерә. Бу төн аның әнисенә булган хисләрен тагын да көчәйтә. Мостафа мине дә әнием шулай юаткандыр, яраткандыр дип уйлый башлый.

Икенче хронотопик образ – буран. Буранның бер көчәеп, бер тынып торуы Мостафаның күңел халәтен, анасы турында булган уйларын көчәйтә.

Бу әсәрдә төп конфликтның үсеше – Мостафаның күңел кичерешләренең хәрәкәте – психологик характерда билгеләнә: әнисе белән аралашмавы, анасына күрсәткән тәрбиясезлеге, аннан үскәч тә гафу сорамавы, илтифатсыз һәм салкын мөгалләмәсе.

Әсәрдә юл хронотобы аерым әһәмияткә ия. Бу юл бер тәүлек юл түгел, ә бәлки егерме еллык юлны тәшкил итә, ягъни ул геройның әнисенә таба юлы буларак аңлашыла. Төп геройның юлы туган нигез – ят җир – туган нигез түгәрәген хасил итә. Туган нигезгә Кайту/Кайтмау капма-каршылыгы, оппозициясе ике яклы. Бер яктан герой әнисез үсүе турында уйлана, икенче яктан үзенең әхлаксызлыгы турында борчыла. Бу ялгызлык хронотобын билгели. 20 ел инде Мостафа әнисенә “әни” дип әйткәне булмый. Хәтта җил дә аның колагына: “Әйт! Анам дип әйт... Егерме ел инде... ишетәсеңме!” – дип пышылдый кебек. Аның тизрәк кайтып җитәсе, әнисен күреп, гафу үтенәсе килә. Вакыйгалар геройның уенда үткәннән бүгенгегә һәм киләчәккә даими рәвештә күчеп, Үткән / Бүгенге / Киләчәк оппозициясен хасил итә.

Перцептив хронотопны геройның шәхси кичерешләре тәшкил итә, дидек. Геройның яшьлеге, бүгенгесе күздән кичерелә, алар ярдәмче сюжет сызыгы булып тора. Сюжет сызыгын берләштерүче үзәк булып, хәсрәт мотивы тора. Фатыйманың күз яше, анасының саташуы, ниһаять, Мостафаның акырып-акырып елавы хәсрәт мотивын тулылыландыра. Хәсрәт хисенең сәбәбе-әнисен рәнҗетүе. Ә әнисе бала җанлы, мәрхәмәтле. Гомере буе Мостафаны сагына, ярата.

Перцептив хронотоп буларак төшне күрсәтә алабыз. Юлда Мостафа төш күрә, ул балачакның матур мизгелләре белән бәйле: "әллә нинди канатлы һәм бик матур балалар беләй уйный. Алар аны тарткалыйлар... этәләр... уяна – анасы аны үбеп-үбеп елый...". Ягъни ул төшендә өнендә күрергә өметләнгән күренешләрне күрә. Перцептив хронотоп булып саналган геройның үткәненә кайтып, хатирәләрен яңартуга автор ретроспекция алымын куллану аша ирешә. Аның ярдәмендә Мостафа, балачагы, үсмерчагы вакытларына барып кайта: әнисенең 6 яшьлек улы Мостафа белән хушлашып китүе, аның кайнар яшьләре, әнисен рәнҗетеп, начар сүзләр әйтүе, битенә көл сипкәне...

Ә хәзер исә Мостафа олыгайган, барысын да аңлый, анасыннан үзенең илтифатсызлылыгы һәм салкын карашы өчен гафу үтенергә тели. Бу тупса хронотобы белән билгеләнеп, очрашу, көрешү мәгънәсенә туры килеп билгеләгнә. Герой әлеге тупсаны атлап чыгарга әзер. Мостафа 20 ел буе әнисе белән күрешә алмауга киртә булып торган хисләрен җиңеп, әнисе янына кайта. Тупсаны атлап керә, шул вакытта әнисе дә үлеп китә. Бәхиллек алырга бер мизгел җитми кала. Бу мизгелләр Мостафаны гомерлек газапка сала.

Шулай итеп, әсәрдә әдәби урын һәм вакыт геройның психологик халәтен, уй-кичерешләрен, теләк-омтылышларын ачыкларга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе. Очерки по исторической поэтике // Вопросы литературы и эстетики. – М.: Худож. лит., 1975. – С. 23.

3. Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В.Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

4. Татар әдәбияты тарихы: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

**Чыганак**

5. Камал Ш. Бәхет эзләгәндә: Хикәяләр, повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 16–23.

## ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫН «БЕР КӨН – БЕР ГОМЕР» РОМАНЫНДА ҺӘМ АНЫҢ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ РЕАЛИЯЛӘР БИРЕЛЕШЕ

*Газизова И., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Мөгътәсимова Г.Р.*

Дөнья халыкларының үзара бәйләнешләре нәтиҗәсендә мәдәният, тел һәм башка өлкәләрнең бер-берсенә йогынты ясавы күзәтелә, ә тәрҗемә

исә төрле милләт вәкилләренең аралашуына, рухи байлыклар белән алмашуына хезмәт итә. Әдәби әсәрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткән вакытта аның стилен, мәгънәсен, тел һәм сурәтләү чараларын, авторның укучыга җиткерергә теләгән төп фикерен, һәм шулай ук һәр милләтнең үзенә генә хас булган милли колоритын саклап кучерү мөһим. Кайсы да булса халыкка яки халыкларга гына хас специфик элементларны белдерә торган сүзләр реалияләр дип атала. Аларны тәрҗемә итү милли һәм тарихи үзенчәлекләрне бирү процессында зур игътибар таләп итә.

Тәрҗемә белгечләре реалияләрне төркемләүнең төрле юлларын тәкъдим итәләр. И.С. Алексеева классификациясендә реалияләр өч төргә бүленә: 1. Географик реалияләр: а) физик география терминнары: *саванна, джунгли*; б) эндемика терминнары: *баобаб, коала*. 2. Этнографик реалияләр: а) кием-салым: *мантон, кимоно*; б) корылмалар һәм көнкүреш җиһазлары: *сауна, ызба*; в) милли эшчәнлек төрләре: *икебана, скоморох*; г) йолалар, ырымнар, уеннар: *вендетта, тамада*; д) мифология һәм культлар: *тролль, санта*; е) үлчәү һәм акча берәмлекләре: *евро, лира*. 3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр: *кантон, большевиклар* .

Әдәби тәрҗемәнең күп кенә мәсьәләләре әсәрнең милли колоритын саклау һәм тәңгәлләштерүгә бәйле. Тәрҗемәче теге яки бу илнең тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, гомумән, милли үзенчәлекләрен чагылдырган кайбер реалияләрне тәрҗемә иткәндә аеруча игътибарлы булырга тиеш.

Күренекле тел галиме Рүзәл Юсупов реалияләрне тәрҗемә итүнең өч юлын күрсәтә: 1. Тулы яки өлешчә транслитерация (реалия исемен турыдан-туры алу яки аның тамырын тәрҗемә теле аффикслары белән бергә куллану). 2. Реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау. 3. Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдалану.

Р.А. Юсупов фикеренчә, бер телдән икенче телгә тасвирлау юлы (аңлатмалы юл) белән тәрҗемә ителә алмаслык сүз юк. Ләкин, оригинал телендәге лексик кыскалыкны саклау һәм бирелгән әйбернең специфик характерын күрсәтү өчен, транслитерация алымы кулайрак.

Чыңгыз Айтматов романында һәм аның татарчага тәрҗемәсендә реалияләр бирелешен Р.А. Юсупов классификациясе нигезендә тикшергәч, түбәндәге төркемнәрне билгеләдек:

1. Тулы яки өлешчә транслитерация кулланып тәрҗемә итү: *“**Едигей** не расслышал, но понял – он так и думал”* [1: 8] – *“**Идегәй** аның сүзләрен ишетмәде, әмма аңлады – үзе дә шулайдыр дип уйлаган иде”* [2: 8]; *“Сильный электрический свет в железнодорожной будке вдруг резко обнаружил глубокие и никогда не исчезавшие уже морщины на синюшно потемневших щеках **Укубалы**”* [1: 9] – *“Ап-ак итеп акшарланган кечкенә будкадагы көчле электр яктысында **Үкүбаланың** каралып күгәргән битендә*

*югалмаслык булып уелган сырлар аерым-ачык күренә”* [2: 9]; *“Обычно это делают в день захоронения, незадолго до выноса, перед общей молитвой в доме умершего – перед* ***дженазой****”* [1: 53] – *“Гадәттә, андый эш мәет җирлисе көнне, мәрхүмнең өендә җыелган кешеләр алдында* ***җеназа*** *догасы укып, аны соңгы юлга күтәреп чыгар алдыннан башкарыла”* [2: 54]; *“После того как не решился Казангап возвращаться в* ***Бешагач****, застряли они на станции* ***Кумбель****, деваться было некуда”* [1: 67] – *“Казанга* ***Бишагачка*** *кайту уеннан чүгеп, шул ук вакытта элекке урынына да кире китмәгәннән соң, бер кузгалып чыгып кит тә, тагын шунда ничек кире кайтмак кирәк? –* ***Күмбелдә*** *нишләргә дә белми аптырап калалар”* [2: 69].

2. Тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау: *“... и никакую собаку ни за какие деньги не затянуть было тогда сюда, на* ***сарозеки****.”* [1: 10] – *“Кеше түгел, этне дә өстерәп алып килеп булмый торган бу* ***Сары Үзәккә*** *Казангап килеп эшли башлаганда Оспан әле дөньяга тумагандыр да”* [2: 10].

3. Чит тел реалиясенә якын сүздән файдалану: *“Требовалось большое терпение в поисках добычи по иссохшим* ***буеракам*** *и облысевшим логам.”* [1: 5] – *“Коры* ***ерганаклар****, шәрәләнеп калган чокыр-чакырлар буйлап чабулый-чабулый тамак туйдыру өчен зур түземлелек кирәк.”* [2: 5]; *“...и к рассвету степь покрывалась белесым, как* ***солончак****, налетом недолговечного инея”* [1: 6] – *“Ә төнлә белән туфрак бик тиз суына һәм таң атканда бөтен җирне,* ***тозлык*** *өсте кебек, кырау каплап киткән кебек була”* [2: 6]; *“А между делом показал Эдильбаю, как* ***саван*** *надо кроить”* [1: 53] – *“Эш арасында ул тагын Әдилбайга* ***кәфенне*** *ничек кисәргә өйрәтте”* [2: 55].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: телнең милли колоритын чагылдыручы реалияләр әдәби әсәрләрдә еш кулланылалар. Чыңгыз Айтматовның иҗаты да искәрмә түгел. Р. Шириязданов исә бу реалияләрне мөмкин кадәр тулырак, сыйфатлырак бирергә тырышкан, һәм моңа ирешкән дә. “Бер көн – бер гомер” романындагы күпчелек реалияләр тәрҗемәдә транслитерация ярдәмендә бирелгәннәр. Икенче урында – чит тел реалиясенә якын сүздән файдалану ысулы. Ә реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау Р. Шириязданов эшчәнлегендә актив кулланылмый.

**Әдәбият**


1. Айтматов Ч.Т. Буранный полустанок (И дольше века длится день...): Роман. – М.: Советский писатель, 1984. – 304 с.

2. Айтматов Ч.Т. Бер көн – бер гомер: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 287 б.

3. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений. – СПб.: СПбГУ; М.: Академия, 2004. – 181 с.

4. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан, 2003. – Б. 223.

5. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008 – Б. 74.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ФИН-УГОР АЛЫНМАЛАРЫ

*Гайнутдинова А., Удмуртия Республикасының социаль-педагогика көллияте, IV курс студенты*
*Җит. – Хәкимова В.Х.*

Фин-угор һәм татар телендәге алынмалар икеяклы типка керәләр. Әгәр Идел буе фин-угор телләренә татар сүзләре күпләп кергән булса, шулай ук татар телендә дә фин-угор сүзләрен табарга була. Ләкин алар татар телендә әллә ни күп түгел. Фин-угор алынмалары татар телендә ике төрле була:

а) әдәби телдәге фин-угор алынмалары;

б) диалектлардагы алынмалар.

Татар әдәби теленә фин-угор сүзләренең бер өлеше диалектлар, җанлы телләрдән кергән, икенче төркеме рус яки башка тел аша алынган.

Ф.С. Фасеев «Угро-фин телләреннән кергән сүзләр, терминологик яктан бигрәк, этногенез, тарихи лексикология һәм этимология өчен мөһим. Һичшиксез, татар телендә фин-угор субстратына караган лексик күренешләр бар: бүкән-чурбан, шүрәле-леший, лесной дух, кытәмә-вид рыбы (голец, пеструшка), сәндерә-полати, лепка-темя (родильное место темени ребенка) һ.б.

Диалектларда, топонимикада алар тагын да күбрәк һәм махсус тикшерүне таләп итәләр», – дип яза.

Икенчедән, фин-угор телләрендәге п белән башланган сүзләр татар телендә п белән ук кергән: *пилмән, пильмен, пимә, пурга, пошн* һ.б.

Н.Б. Борһанова үсемлек атамаларыннан миләш (рябина), курыс (липа), шәмкә, шәмкәлек (молодой сосняк), кебек сүзләрне фин-угор телләреннән кергән дип саный.

Фин-угор телләреннән кергән үсемлек атамаларына тагын берничә сүзне өстәргә мөмкин. Татар телендәге шепкән (рыжик) сүзенең беренче компоненты шеп удмурт һәм коми телләрендә башакны белдерә. Шеп сүзе төрки телләрдә башак мәгънәсендә кулланылмый. Ылыс сүзе дә шулай ук фин-угор телләреннән кергән. Чагыштыр: *удмурт, коми: лыс; мари: луш, лусь (хвоя)*. Галимнәр тукучылык станының детальләренә атамалар кеше яки хайван әгъзаларына охшатып бирелгән дип язалар. Тукучылык һөнәренең шактый борынгылыгын күздә тотканда татар теленә бу атамаларның фин-угор телләреннән керү ихтималы зур. Мәсәлән, татар телендәге шүре сүзенең этимологиясен төрки нигездә ачыкларга материал юк, ә фин-угор телләрендәге сир белән бәйләү нигезлерәк булыр кебек. Ул телләрдә шүре сүзенең мондый атамасы булуы ачыклана.

Удмурт теленнән кергән атамалар урта диалект сөйләшләренә хас. Мәсәлән: *баргаз каз (одинокий, невыводивший птенцов), пичкәчә (золовка), кылкыну (клохтать), кутыр (окольный, вокруг), шелеп (щечки)* һ.б.

Минзәлә сөйләшендәге бызгы (женщина в доме, вмешивающаяся во все и везде) удмурт телендәге сүзләр.

Урта диалектта әдәби телдәге авыру сүзенең чир, чирләү синонимы бар. Чирләшкә дип еш авыручан кешегә әйтәләр. Бу сүз фин-угор телләрендә дә бар: удмурт: чер; мари: чер, цер; рус телендәге чирей (фурункул) сүзе дә шул ук чир белән бәйле булырга кирәк. Шәркә (грязный, неряха) сүзе фин-угор телләрендәге шар (грязь) сүзенә кайтып кала. Шулай ук шакшы (грязный) сүзе дә татар теленә фин-угор телләреннән кергән булырга кирәк.

Татар һәм күрше фин-угор халыкларының тормыш-көнкүрештә аралашуы аларның лексикасында тирән эз калдырган. Коми, удмурт телләрдәге төрки алынмаларның күбесе болгар чорына карый. Ул алынмаларда шул дәвердәге безнең бабаларыбызның лексикасы өлешчә булса да ачыклана. Коми һәм удмуртлар нигез телдән аерылганнан соң (Х йөз), удмурт теленә татар сүзләре җирле сөйләшләрдән күпләп керү дәвам итә. Нигездә бу процесс хәзер дә тукталмаган. Мари һәм мордва телләре белән дә шундый ук күренеш. Бу телләрдәге төрки алынмаларның иң зур өлешен татар сүзләре тәшкил итә. Мари, мордва, коми һәм удмурт телләренең формашуында болгар-татар компоненты күләмле катлам хасыйл иткән. Болгар-татар йогынтысы әлеге телләрнең барлык ярусларына да таралган.

**Әдәбият**

1. Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. – М.: Наука, 1978. – С. 119–120.
2. Гаффарова Ф.Ф. Татарча-русча-удмуртча сөйләүлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 215 б.
3. Основы финно-угорского языкознания.– М., 1974. – Т. 1. – 409 с.
4. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре. – Казан, 1969. – 250 б.
5. Халиков А.Х. Татар халкының килеп чыгышы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 250 б.

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ҖИРЛЕ ОНОМАСТИК МАТЕРИАЛ КУЛЛАНУ

*Гайфуллина И., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Һадиева Г.К.*

Тел һәм аның үсеш-үзгәреш закончалыклары җәмгыять тарихы, әлеге телне барлыкка китерүче, саклаучы, аны йөртүче халыкның үткәне белән тыгыз бәйләнештә тора. Шунлыктан телне өйрәнүне җәмгыять тарихыннан, аның материаль һәм рухи мәдәниятенең тарихыннан аерып карау мөмкин түгел.

Телнең структур элементларыннан лексика, аерым алганда сүзлек составының бер катламын тәшкил иткән ялгызлык исемнәре мәдәният белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Бу күренеш, үз чиратында, кеше

исемнәренең һәм географик атамаларның экстралингвистик функциясе белән аңлатыла. В.Д. Бондалетов фикеренчә, «ономастик материал теләсә кайсы югары үсеш алган телнең сүзлек составын тәшкил итә, һәм ул тел, география, тарих һәм башка җәмгыяви, табигать фәннәре кебек өйрәнелергә лаек» [2: 3].

Гомуми белем бирү оешмаларының традицион белем бирү нигезе – телне, тел нормаларын үзләштерү өчен структур-семантик яктан тасвирлау – коммунтикатив һәм культурологик аспектлар исәбенә тулыландырыла. Соңгы вакытта дәүләт белем бирү стандартлары структурасындагы милли-региональ компонентның уку-укыту практикасына кертелү процессы күзәтелә. Шуңа нисбәтле татар теле дәресләрендә җирле ономастик материал куллану, аларның үзләштерелүен тәэмин итү бүгенге көндә аеруча актуаль.

Туган тел дәресләрендә укытыла торган ономастика лингвистик курсы дигән вакытта «телне укыту процессында тематик һәм лингвистик якка басым ясауга мөнәсәбәтле системалы һәм эзлекле рәвештә җирле тел материалын куллануны кертү»не күз алдында тоту кирәк [1: 17].

Гомуми белем бирү оешмаларында ономастик материалны уку-укыту процессында куллану, укучылар тарафыннан үзләштерелү дәрәҗәсе укучыларда милли үзаң формалаштыру мәсьәләсенә барып тоташа.

Т.В. Майорова үзенең «Туган якны лингвистик өйрәнү эшендә ономастика» дигән мәкаләсендә ономастик материалны җыюның мөһимлеген ассызыклый, әлеге эш төрен мәктәптә оештыру зарурлыгы һәм югары уку йортларында дәвам ителергә тиешлеге хакында бәян итә, ономастик материал җыю эшенең специфик программасын тәкъдим итә. Галим фикеренчә, «ономастик язып алу (теркәү) ялгызлык исемнәренең бәйләнеше, бер-берсенә йогынтысы, үзара тәэсир итешү процессын ачыкларга ярдәм итәчәк» [3: 43].

Ялгызлык исемнәрнең барлыкка килүе тарихи мотивлашкан булуы белән үзенчәлекле. Топонимнарда, мисал өчен, табигать, ландшафт үзенчәлекләре, социаль-сәяси тормышның аерым бер яклары һәм социаль-икътисади мөнәсәбәтләр дә чагылыш таба. Географлар фикеренчә, күп кенә ялгызлык исемнәр тарихи әһәмияткә ия булуга нисбәтле кием төрләре, ризык әзерләү ысуллары кебек традицион этнографияне өйрәнү предметлары белән бер рәттә тора. Татар телен белгән һәм әлеге телдә иркле аралаша алган кеше өчен *Казан, Алабуга, Буа, Чаллы* төрки чыгышлы җирле шәһәр атамаларының семантик нигезен тәшкил иткән мәгълүматны сиземләү зур авырлык тудырмый.

Ономастик лексика туган тел укытучысы тарафыннан торак пунктлар, илләр турындагы мәгълүматны уку-укыту процессына кертү һәм аны ныгыту алымы буларак кулланылырга мөмкин һәм тиеш. Ялгызлык исемнәрен этимологиясе ягыннан интерпретацияләү, зат яки географик

объект хакындагы мәгълүмат белән бергә аларның лексик-семантик үсеш закончалыкларын билгеләү – икенчел фон белемнәре, локаль ассоциацияләр формалаштыруның табигый юлы. Әлеге атамаларны кабул итүнең эчке мотивациясе аларны аралашу процессында кулланган очракта (экскурсиядә, театр-музейларда, текст, картина, газета, видеоязма белән эшләү барышында аларны аңлату зарурлыгы барлыкка килгәндә) арта. Т.В. Майорова шәһәр мәктәпләре өчен ономастик материалны өйрәнүдә дәрестән тыш чаралар буларак архивларга бару, туган як турындагы документлар белән танышу, фәнни-популяр әдәбият уку, экскурсияләргә, музей һәм библиотекаларга баруны тәкъдим итә.

Туган тел дәресләре кысаларында ономастик материалны уку-укыту мәсьәләсе, беренче чиратта, региональ үзенчәлекне һәм атаманың билгеле булу-булмавын исәпкә алып чишелергә һәм, укучыларның кызыксынуларына бәйле булып, аларда ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләүгә юнәлдерелергә тиеш. Гомумән алганда, топонимик материалның объемы уку-укыту этабына һәм максатларга бәйле.

Кызганычка каршы, туган тел дәресләрендә ономастиканы өйрәнүгә аз вакыт бүленеп бирелә. Бу исә, үз чиратында, укытучы иҗатында, уку-укыту методларын һәм формаларын ирекле сайлау мөмкинлегендә, уку-укыту процессының дифференциацияләнүендә тискәре чагыла.

Методистлар исә туган телне укытуда ономастикага туган як үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнү эше буларак якын килүне һәм әлеге материалны дәрестән тыш чараларда да актив куллануны тәкъдим итәләр, чөнки «якташларның һәм алар турындагы «тере» сүз кече ватанга кызыксыну уята, аның үткәне һәм бүгенгесе турында сөйли; ахырда, болар бар да уку-укыту процессының гуманлашуына китерә» [1: 17–18].

Җирле ономастик материалны туган тел дәресләрендә лексика, орфография, орфоэпия, тел тарихы, сүзьясалышны өйрәнү барышында куллану (сөйләм культурасы буенча күнегүләр, полисонимнар кергән әдәби әсәр яки публицистик материаллар белән эшләү) дәресләрне интеграцияләүгә, дәрес-экскурсия, дәрес-сәяхәт, иҗади конкурслар һәм дәресне, рольләргә бүленеп, уен форматында үткәрү мөмкинлеген бирә.

Туган тел дәресләрендә җирле ономастик материалны үзләштерүдә география укытучысының да әлеге эштә катнашуын тәэмин итү уңай нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Бу очракта, Е.М. Поспелов фикеренчә, географ-филолог-тарихчы ансамблендә һәр катнашучының уртак максатка буйсынуы һәм актив катнашуы таләп ителә, чөнки туган тел дәресләрендә географик атамаларга мөрәҗәгать итү туган тел укытучысының эшчәнлек мәйданын киңәйтә, яңа ысул-алымнарны продуктив куллануга юл ача [4: 119].

Ономастик лексиканы этимологик һәм сүз ясалышы, тел тарихы аспектыннан чыгып тикшерү укучыларның игътибарын җәлеп итә,

фамилияләрнең килеп чыгышын ачыклау процессы исә әлеге өлкәгә кызыксыну артуны тәэмин итә. Әлеге эш төре белән шөгыльләнү барышында, нигездә, чагыштырма-тарихи, чагыштырма ысуллар куллану уңай нәтиҗәләргә китерә.

Йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин: туган тел дәресләрендә җирле ономастик материалны даими һәм эзлекле куллану укучыларда туган якка мәхәббәт тәрбияли, ономастик материалга кызыксыну хисе артуга сәбәпче була. Шул рәвешле, туган тел укытучылары һәр предметның тәрбияви мөмкинлекләрен киңәйтүне, укучылардан белемнәрне мөстәкыйль үзләштерүне таләп иткән мәктәп реформасына үз өлешләрен кертә.

**Әдәбият**


1. Благова Н.Г., Коренева Л.А., Родченко О.Д. О концепцииобучения русскому языку с учетом регионального компонента (Для средней общеобразовательной школы) // РЯШ – 1993. – №4 – С. 16–19.
2. Бондалетов В.Д. Русская ономастика. – М., 1983. – С. 43–47.
3. Майорова Т.М. Ономастика в лингвокраеведческой работе // РЯШ – 2000. – №4. – С. 46–47.
4. Поспелов Е.М. Топонимика в школе // Пособие для учителей. – М., 1981. – С. 46–47.


## МӘКТӘП КУРСЫНДА Г. ТУКАЙ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ


*Гайфуллина Л., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш*


Төп гомуми белем бирү оешмаларында татар әдәбияты дәресләрендә шәхестә милли бергәлек һәм гражданлык хисләре тәрбияләү максатыннан, классик язучылар иҗаты, аларның гүзәл әсәрләре белән таныштыруны, әдәби әсәрне анализлау һәм шәрехләү методларын үзләштерүне күздә тота, язучылар һәм шагыйрьләр иҗатындагы яңалыкны аңлау да аның вазифасы булып тора.

Татар телендә белем бирү оешмаларында Габдулла Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә дәресләр шактый күп бирелә. Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүнең максаты – шагыйрь мирасын һәм тормыш юлын өйрәнү, аның халык тормышындагы тоткан урынын билгеләү, әсәрләре аша тормышны аңларга өйрәнү, сүз сәнгатен рухи юлдаш итү. Г. Исхакый үзенең “Тукай мәктәптә” мәкаләсендә Тукай иҗатының мәктәптәге роле мәсьәләсенә бәйле рәвештә “әдәбиятның мәктәптәге урыны, укытуның бурычлары, максатлары турында сүз алып бара” [1: 36]. Ә алар – балаларны тормышка әзерләү, дөреслекне төшенергә өйрәтү, балаларның рухына азык бирү, аларда югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү, авторның үз сүзләре белән әйтсәк, “кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйлатырга өйрәтү” [2: 125].

Мәктәптә Габдулла Тукай дәресләре төрле яссылыкта көтелгән нәтиҗәләр бирсен өчен, яңа инновацион технологияләр, яңа алымнар

кулланып үткәрү зарури. Укучыларда, әдәбиятка мәхәббәт уяту өчен, безгә гадәти дәресләр белән гадәти булмаган дәресләрне дә бергә үреп алып бару нәтиҗәле юл булып тора. Болай эшләгәндә, бертөрлелектән котылып кына калмыйча, барлык укучыларның да дәресләрдә актив катнашуларына ирешергә була. ФДББС буенча төп максатыбыз – укучыларда үзлекләреннән белем алуга омтылыш уяту. Хәзерге вакытта туган тел һәм туган әдәбият укытуның төп максаты түбәндәгедән гыйбарәт: "...укучының үзүсешкә әзерлеге һәм төрле яклап камил, иҗади үзүсешкә сәләтле, милли гореф-гадәтләр, Россия Һәм Бөтендөнья культурасы кыйммәтләре нигезендә тормышта үз урынын тапкан шәхес булып формалашу, җаваплы, продуктив, интеллектуаль, оештыруга сәләтле сыйфатларга ия укучы тәрбияләү" [3].

Педагогик технология укытуны, белемнәрне үзләштерүне, идея-фикерне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Педагогик технология белем бирүнең иң уңышлы юлларын өйрәнүче фән буларак та, педагогик процесста кулланыла торган ысуллар, чаралар системасы буларак та, белем бирү процессы буларак та билгеләнә. "Шәхси, инструменталь һәм педагогик-методологик чараларны хәрәкәтләндерү" [5: 78].

Ничек итеп Г. Тукай иҗатын өйрәнү процессын «заманлаштырырга», нинди яңа технологияләр куллану эффектив булыр дигән сораулар туа. Дәрес эчтәлегендә укытучының инновацион педагогик технологияләрне кулланып эшләве дә чагылыш табарга тиеш. Информацион технологияләрне гамәлгә кую күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә, этәргеч бирә. Интернет челтәреннән Габдулла Тукайның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган сайтларны табарга мөмкин, шуларның иң уңышлысы "Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал. Монда "Иҗат", "Тукай даирәсе", "Тукай фәне", "Тукай сәнгатьтә", "Тукай музейлары", "Тукай премиясе", "Без – Тукайлы халык!" дип аталган бүлекләрдә шагыйрьнең тормыш юлына һәм иҗатына карата төрле елларда әдипнең дуслары, чордашлары язган истәлекләр, галимнәребезнең фәнни язмалары тупланып бирелә.

Г. Тукайның биграфиясе белән танышу дәресләрендә, бу бигрәк тә 5 нче сыйныфта Г. Тукайның "Исемдә калганнар" автобиографик повестен, 6 нчы сыйныфта Ә. Фәйзинең "Тукай" романын, 7 нче сыйныфта Г. Тукайның биографиясен өйрәнүне дәвам итү барышында Ә.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясен (ИҮТ) куллану отышлы. Уку эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, белем-күнекмәләр формалаштыру – әлеге технологиянең төп шарты булып тора. Төркемдә укучы башкалар сөйләгәнне тыңларга, үз фикерен дәлилләргә, кызыклы фикер әйткән иптәшенә хөрмәт белән карарга өйрәнә.

Проектлар методы укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачарга, үстерергә һәм шәхес өчен бик әһәмиятле булган игътибарлылык, максатчанлык, җаваплылык, аралаша белү кебек сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә. “Проектлау процессы билгеле бер тәртипкә буйсына, ул укучылар тарафыннан төзелә” [4: 9]. Аеруча 10 нчы сыйныфта Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын тирәнтенрәк өйрәнү өчен проектлар методы ярдәмгә килә ала. Мәсәлән, Г. Тукай биографиясе", "Г. Тукай – мәгърифәтче" һ. б. проектлар тормышка ашырыла ала. Проект эшен башкарганда, укучылар өстәмә чыганаклар эзләргә, табылган мәгълүматларны кулланырга өйрәнәләр, аралашу күнекмәләрен үстерәләр, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерәләр, төркемнәрдә эшләргә өйрәнәләр, аларда җаваплылык хисе, үз-үзенә ышаныч формалаша.

Татар әдәбияты дәресләрендә яңа төр технологияләр кулланып укытып, югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Г. Тукай иҗатын мәктәп укучылары кызыксынып өйрәнгән саен, бөек Тукаебызга ихтирамнары арта, шагыйрь мирасы белән тулысынча танышып, аның әсәрләреннән ул үзенә рухи азык алалар. Киләчәктә мәктәп программалары, дәреслекләр төзелгәндә, Тукай иҗатының төп үзенчәлекләрен билгеләгән, шагыйрь шәхесенә һәм мирасына мәхәббәт уяткан гүзәл әсәрләре күбрәк урын алсыннар иде.

**Әдәбият**

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Гаяз Исхакыйның “Тукай мәктәптә” мәкаләсендә методик-педагогик карашлары // Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 35–38.

2. Исхакый Г.Г. Тукай мәктәптә // Мәктәп. – 1914. – № 6. – 125 б.

3. Сәмигуллин Г.Х. Укчыларның проект эше белән идарә итү // Мәгариф, 2004. – № 12. – Б. 2–13.

4. Селевко Г.К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие. – М.: Народное образование, 1998. – 256 с.

5. https://pedportal.net/ [мөрәҗәгать итү вакыты: 04.01.19]

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ ИҖАТЫН ҺӘМ «ЯЗГЫ АҖАГАН» РОМАНЫН ӨЙРӘНҮ: ТАРИХИ ЯССЫЛЫК ҺӘМ БҮГЕНГЕ АЛЫМНАР

*Галиева А., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Минһаҗева Л.И.*

«Язгы аҗаган» хатирәләр рәвешендә язылган. Әмма искә төшерүләр табигый рәвештә бүгенге хәлләр белән үрелеп бара. 1922 елдан башланган вакыйгалар тезмәсе 1957 елда өзелеп кала, ягъни утыз биш ел эчендә кешеләр, кичергән фаҗигале хәлләр гәүдәләнә анда.

М. Хәсәнов иҗаты тематика ягыннан шактый бай. Татарстан китап нәшриятында 1975 елда басылып чыккан “Саумы, кояш” романы безне бөтенләй икенче тормыш – революциягә кадәрге татар хезмәт ияләренең

аянычлы хәле, аларның сыйнфый аңыусү һәм изелүгә каршы көрәштә актив катнашып китүләре белән таныштыра.

Автор бу әсәрен шактый озак – унҗиде ел яза. Роман зур иҗади эзләнүләрнең нәтиҗәсе булып дөньяга килә. Һәм, әйтергә кирәк, татар совет әдәбиятын тарихи-революцион вакыйгалар, халык язмышы фонында сурәтләнгән колоритлы образлар белән баетуга әйбәт өлеш булып тора ул. Романдагы вакыйгалар егерменче йөзнең беренче елларыннан алып 1919 елда Казанны ак чехлардан азат итүгә кадәр булган чорны эченә ала. Әсәрнең төп героинясы Гөлбану гади авыл кызыннан революциянең актив солдатына әверелә. Аны да башта, гасырлар буена формалашкан кануннар белән, туктатырга телиләр."Соң син бит хатын-кыз! Укымаган, томана бер татар хатыны. Политика, сәяси эшләр белән шөгыльләнү синен эшмени соң?" – дип аны бу юлдан йөз чөертергә омтылалар. Әмма кимсетелүне үз язмышында татыган Гөлбануның карары нык "Томана татар хатыны да кеше ләбаса!.. Аныңда тураясы, башын калкытасы, кояшны күрәсе килә" диган нәтиҗә ясый ул. Әмма ирек кояшын күрү эчен бик куп сынаулар, авырлыклар аша үтәргә кирәк була шуләле аңа. Авыл байлары эзәрлекләвеннән качып, Казанга килергә, үзләре кебек үк ачлы-туклы яшәүче бер эшче гаиләсенең почмагына сыенырга, Мәрхәмбикә-байбикәгәунбиш ел бил бөгәргә, бик күп ызгыш-талаш күрергә туры килә. Гөлбану революцион көрәшнең корбаннар таләп итүен дә аңлый. Шушы изге көрәш юлында чын революция солдаты булып әверелә [2: 151].

Бу күләмле әсәр – бу лирик, драматик һәм фаҗигале олы симфония аеруча халыкчанлыгы белән күңелләрне яулый. Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романында композицион оештырылыштагы бер үзенчәлек күзгә ташлана. Әсәр үзендә ике романы берләштергән кебек тоела.

Әсәрне өйрәнгәндә яңа алымнардан киң файдаланырга була. Мәсәлән, түбәндәге биремнәр:

Конэрс (CORNERS) – структурасы белән эшләү.

– Син кайсы образ турында сөйләргә теләр идең?

1. Образ исемнәрен язып стенага ябыштырырга.

2. Укучылар теләгән образлары янына барып басалар.

– Бу образ сине кайсы сыйфатлары белән җәлеп итте?

1. Үз төркемнәрендә партнерлар табып, үзләренең фикерләре белән уртаклашалар. Партнерларын алыштырып, алар тагы бер кат сөйләп алырга тиеш.

(Укытучы берничә укучыдан сорый, алар үзләренең фикерләре белән уртаклашалар).

Таймд раунд робин (Timed Round Robin) структурасы белән эшләү.

– Укучылар, сез әсәрне ничек тәмамлар идегез?

Бу сорауга җавап бирү өчен, группадагы һәр укучының 30 секунд вакыты булачак.

(Беренче номерлы укучы җавап бирә башлый (№1), вакыт китте. – 30 секунд вакыт үтте, хәзер сораугa җавап бирүне группалардагы №2 укучы дәвам итә (30 секунд). Укытучы кайсы укучы җавап бирәсен әйтеп бара, фикер алышу билгеле бер эзлеклелектә дәвам итә (№1 – №2 – №3 – №4).

Әсәрдә вакыйгалар үзара сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә булып, урынны, вакытны, тышкы дөнья-тирәлекне һәм геройларның эчке кичерешләре-халәтен күрсәтәләр, күз алдына китереп бастыралар. Бу вакытта сурәтләү ярдәмгә килә. Автор геройларның портретын, пейзаж, урынны, катнашучыларның халәтен, кәефе үзгәрүне һ.б. сурәтләп бирә, әйбер, табигать, хис-кичереш, кеше образлары тудыра. Әсәрдә образлар гадәти тормыштагыча: эш-гамәлләрдә, күренешләрдә, уй-фикерләрдә, хыял-омтылышларда сурәтләнә, төрле сыйфатлар, каршылыклар җыелмасы итеп күрсәтелә.

Минем фикеремчә, әдәбият дәресләрендә тәнкыйди фикер йөртергә өйрәтү дә зур әһәмиткә ия. Бу җәһәттән “кейс”, “инсерт төзү”, “синквейн” алымнарын куллану яхшы нәтиҗә бирә. Кызганычка каршы, әлеге алымнар буенча мөгаллимнәр өчен бик аз мәгълүмат бирелгән, булган кадәресе дә рус телен өйрәнү методикасына нигезләнгән.

Йомгаклап әйткәндә, түбәндәгеләрне искә алып үтәргә кирәк, мәктәптә әдәбият дәресләрендә “Язгы аҗаган” романын өйрәнүдә заманча дәреслекләр буенча укыту гына җитми, биредә инновацион педагогик технологияләр тәкъдим иткән чаралардан да максатчан файдалану әһәмиятле.

**Әдәбият**

1. Галимуллин Ф. Юл кешесе // Казан утлары. – 1982. – №3. – Б. 147–154.

## РЕЧЕВЫЕ ОБРАЩЕНИЯ В ЯЗЫКОВОМ ЭТИКЕТЕ ТАТАРСКОЙ ЭТНОКУЛЬТУРЫ

*Галимова Г., КФУ, аспирант III курса*

*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Юсупова А.Ш.*

В социокультурных условиях языкового контакта проблемы изучения речевых стереотипов включают в себя много вопросов, связанных с межкультурной коммуникацией и языковой компетентностью народа. На наш взгляд, значимость изучения речевых стереотипов объясняется тенденциями активного взаимодействия различных этнокультур и усиления роли процессов этнической идентификации. В настоящее время вопрос о специфике речевых стереотипов общения в разных лингвокультурах является весьма актуальным. В этом плане особый интерес представляет исследование речевых стереотипов обращения татар в этнокультурном аспекте.

Цель нашего исследования – лингвистический анализ стереотипов языкового этикета, выявление этнокультурной специфики употребления этикетных стереотипов татар. Предметом исследования являются речевые стереотипы в языковом этикете татарской этнокультуры.

Материалами исследования являются следующие речевые стереотипы языкового выражения: речевые формулы этикета, устойчивые выражения, клише, примеры из художественных текстов, пословицы и поговорки, фразеологические единицы в татарском и турецком языках. В исследовании использовались следующие методы: описательный, метод сплошной выборки, метод обработки, интерпретации, а также лингвокультурологический, лексико-семантический и контекстный анализ.

Речевая культура является важным элементом духовной культуры, важной частью поведения и общения. Обращение является одним из контактных средств в коммуникативной культуре. Система обращений связана со следующими условиями: степень знакомства, сфера и обстановка общения, статус и личностные отношения собеседников. В татарской речевой культуре традиционно обращались на «ты». Форма обращения на «вы» распространилась под влиянием русской речи и употребляется при обращении к незнакомым людям как выражение уважительного отношения.

В официально-деловой речевой культуре под влиянием русского языка принято обращаться в форме фамилия+имя=отчество. Такая модель обращений обычно употребляются в официальных документах, в языке прессы и юристпруденции. Обращение по имени-отчеству употребляется к мало знакомому человеку со статусом или знакомому человеку, коллеге в официальной обстановке: *Әмир Хәсәнович, Әмир Хәсән улы, Әминә Кәримовна, Әминә Кәрим кызы.*Официальными формами обращения являются *җәмәгать (народ), туганнар (родственники), милләттәшләр (человек одной с кем-либо национальности, соплеменник), якташлар (земляки), хезмәттәшләр (коллеги).*В деловом этикете широкое распространие получили обращения *ханым (обращение к замужней женщине), туташ (обращение к незамужней), әфәнде (господин)*: *Әнисә ханым, Әминә туташ, Каюм әфәнде.*

В нейтральном или фамильярном стиле к людям старше по возрасту обращаются *апа (тетя), абый (дядя), бабай (дедушка), әби (бабушка),* а к людям младше по возрасту используются *энем (младший брат), сеңелем (младшая сестра).*В дружеских отношениях может употребляться слова *дус // дустым // дускай, ахирәт (друг, приятель), малай, кызый (обращение к подружке).*

В татарском языке в обращении к родственникам есть своя специфика. Своеобразием для татарского этикета является обращение к родственникам с использованием терминов родства как *апа (тетя), абый (брат), энем (младший брат), сеңелем (младшая сестра), әби // дәү әни*

*(бабушка), бабай // дәүәти (дедушка).* Пожилые люди при обращении к детям а также к молодым людям используют *балам (дитя), улым (сынок), кызым (дочка),* при ласковом обращении – *наным, балакай, бәбкәм.* К близким родственникам использовались такие обращения как *матур апа, алма апа, тәти абый, нәнә абый, дәү апа, дәү абый, ерак әби.* В татарских семьях муж и жена вместо имени часто обращаются *әтисе, әнисе, атасы, анасы, картым, карчыгым, хатын, син, сиңайтәм.* Эта особенность связана тем, что в истории нельзя было вслух произносить имя мужа – оно табуировалось.

Среди обращений встречается значительное число реалий, которые передают национальный колорит. Например, в фамильярном стиле активно применяются ласковые обращения *кадерлем (дорогой), җаным // җаныем // җанкисәгем, (душа моя), бәгърем/ /бәгырькәем (душенька), сөеклем (любимый), алтыным (золото мое), күгәрченем (голубушка), былбылым (соловей мой), акыллым (умница моя).* Следует отметить, что оценочное значение обращений в татарском языке передаются при помощи аффиксов принадлежности *-ым/-ем/-м, -кай/-кәй.*

Таким образом, в этикете татарской этнокультур отражаются многовековые традиции, обычаи, привычки, верования народа, богатый опыт языковой культуры. В татарском языковом этикете в условиях глобализации, благодаря межкультурным, социально-экономическим контактам нашли отражение как восточные, так и западные черты речевого поведения.

На наш взгляд, системное изучение и описание речевых стереотипов татарского народа было бы перспективно в сфере интересов лингвистики, лингвокультурологии, этики и культурологии.

**Литература**


1. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. – М.: ВЛАДОС; Казань: Магариф, 2004. – 239 с.

2. Исина, Г.И. Стереотипы и национальная языковая картина мира: автореф. дисс. ... док. филол. наук. – Алматы, 2008. – 55 с.

3. Nabiullina G.A. Yusupova A.Sh. On the Linguistic Situation of the Tatar Diaspora in the USA. Mediterranean Journal of Social Sciences. Vol. 6. No. 5. Is. 3, 2015. pp. 298–302.

4. Yusupova A.Sh., Galiullina G.R., Denmukhametova E.N. Representation of national mentality in Turkic-Tatar vocabulary. Life Scince Journal. Vol. 11, Is. 7. No. 66. 2014. pp. 506–508.

5. Zamaletdinov R.R., Zamaletdinova G.F., Nurmukhametova R.S. The Lexicon and its Reflection in the Inner World of the Individual (on the basis of the Tatar Language). Journal of Language and Literature. 2014. No 5 (4). pp. 333–335.


## ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА ИҖАТЫНДА ОБРАЗЛАР БИРЕЛЕШЕ


*Галимова Д., Казан, 23 нче мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Шәехова А.Х.*


XX–XXI гасыр чикләрендә татар поэзиясе эчтәлек һәм форма, фәлсәфи яктан тирәнәя, төрлеләнә. Чынбарлыкны, рухи дөньяны үзләренчә

күрү сәләтенә ия, бай фикерле, гүзәллекне тоя, сәяси хәрәкәтләрне аңлый торган сәләтле сүз осталары, яшь язучылар, ташкын кебек, килеп кереп тора. Алар арасында “Такташның яшьлек чоры иҗатын хәтерләткән” [2: 432] бик тә үзенчәлекле яшь шагыйрә – Лилия Гыйбадуллина. Яшь шагыйрәнең иҗат җимешләре Татарстанның “Казан утлары”, “Идел”, “Мәйдан”, “Мәдәни җомга”, “Шәһри Казан”; Башкортстанның “Тулпар”, “Шоңкар”, “Йәшлек” [4: 5] кебек газета-журналларында басылып килә.

Лилия Гыйбадуллинаның иҗаты тәнкыйттән читтә йөри. Бу як фәнни эшебезнең актуальлеген тәшкил итә. Фәнни эшебезнең максаты: Лилия Гыйбадуллина иҗатын образлылык биреше ягыннан тикшерү. Максатка ирешер өчен түбәндәге бурычлар куелды: Л. Гыйбадуллина иҗаты белән танышу, аның турында тәнкыйди материал туплау, образлылык биреше ягыннан тикшерү.

Шигырьләрнең үзләренә килсәк, сафлык, ихласлык, матурлык, мәхәббәт белән сугарылган табигать образлары күзгә ташлана. “Җил” [3: 34] шигырен алыйк. Бу шигырьдә – җил образы. Шушы образны тасвирлаганда, автор җанландыру алымын еш куллана. Мәсәлән, җил “сөйли”, “табигатьнең җырын көйли”, “сөйләштерә”, “серләштерә”, “уйнап йөри”, “уйлап йөри”, “урлап китә”, “куа”, “ишеткән”. Минемчә, автор җил образы аша гомернең фанилеген, вакытның агышын тасвирлаган. Шигырьнең кайбер юлларына игътибар итик. “Биек агач яфракларын сөйләштерә, / Изрәп яткан үләннәрне серләштерә” – бу юлларда гомернең яз-җәй мизгелләре, “Берәүләрнең бүрекләрен урлап китә, / Салкын кышта карлар өеп кызык итә” юлларында – гомернең кыш мизгеле, “Күзләр моңсу, ә ул шаян яфрак куа, / Тынын өрсә, җырлый кырда кура” юлларында тормышның күзләре ачык сизелә. Шигырьнең соңгы юлында автор гомуми нәтиҗә чыгара: “Еллар җилләр җитезлеге белән узып тора.” Адәм үз тормышында нәрсә генә күрсә дә, дөнья барыбер “җилләр җитезлеге белән” алга бара. Кыскача әйткәндә, җил – гомернең, вакытның тиз үтүе. Әсәрдә шагыйрә кулланган метафораларга *табигать җыры*, *җилләр җитезлеге,* эпитетларга *чал чәчле җил, шаян яфрак*, *моңсу күзләр*не кертеп була.

“Яңгыр” [3: 42] шигыренә Лилия Гыйбадуллина яңгыр образын алган. Яңгыр ул – яшәү чыганагы. Ул “табигать яшәртә”. Яңгыр булса, урманнар яшәрә, елгалар ташый, җир-ана терелә. Яңгыр образын тасвирлаганда, автор аны яшенле, ярсулы дип яза, аңа “зәңгәр күк хуҗасы” (монда шагыйрә метафора тропын кулланган) дип эндәшә. Шулай ук яңгырны “асылташ” белән тиңли. Минемчә, шагыйрә бу әсәрендә яңгыр образы белән кеше күңелен параллель рәвештә тасвирлый. Болытлар, яңгырлар булмаганда, зәңгәр күк кояш белән балкый. Шулай ук кеше күңеле дә: адәм кайгы-хәсрәтләр күрмәсә, аның җаны тыныч, кәефе бөтен була. Яшенле яңгыр, ярсулы яңгыр сүзтезмәләре күңелнең моң-зар, кайгы

белән тулуын аңлата. Яңгырның “күңеле тулганда”, ул “чиләкләп коя”. Кеше күңеле тулгач, ул елый. “Елачы бер, әйдә”, “Еласаң, бушанып калырсың” дип лирик герой үзенең күңеленә эндәшә. Чыннан да, елап алсаң, күңелдә ниндидер бер җиңеллек сизәсең. Яңгыр явып үткәч, күктә кояш балкый, салават күпере чыга. Шулай ук кеше үзенең күңелендәге кайгы-борчуларын чыгаргач, аның кәефе күтәрелә, эчендәге авыр хисләр җиңеләя, начар уйлар югала.

Лилия Гыйбадуллина иҗатындагы татлы җимешләрнең берсе – “Имән” [4: 23] шигыре. Бу әдәби әсәрдә имән образы сурәтләнә. Имән “кара көйгән”, “карт”, аның ботаклары “көчсез”, ләкин ул “сабыр”, аның тамыры “нык”. Минем уйлавымча, имән образы бу шигырьдә карт кешене күз алдына китерә. “Ут-дәһшәтне күреп кара көйгән” имән – кайгы-хәсрәт, тормышның әче-төчесен күп күргән кеше. Имән “ялгыз башын таш кыяга игән”, аның “көчсез ботаклары җиргә тигән”. Шулай ук кешенең дә хәле юк, ул көчсез, авырлыклар күреп хәлсезләнгән ул. Ләкин имәндә дә, кеше күңелендә дә өмет сүнмәгән. Имәннең тамыры нык, ә кеше күңеленең пакълеге, сафлыгы, чисталыгы бар, аның ышанычлары, өметләре зур. Шулай булгач, “сабыр имән күтәрелер, яфрак ярыр”, кешенең дә өметләре чынга ашар, киләчәге яхшы булыр, “изге айдан иман табар”.

“Йолдызлар” [4: 13] шигырендә дөньяның, яшәешнең матурлыгын күрә белмәгән, күңеле начар уйлар белән тулган кешеләр сурәтләнә. Автор аларны “таш бәгырь”, “күңелдә ачылмас келәләр” дип яза. Чыннан да, искиткеч тылсымлы йолдызларны “кирәкмәс чүп” дигән кеше кеше түгел. Шагыйрә әсәрнең соңгы юлларында өмет белдерә: “һәр таш җанның да үз күге, үз күзе, йолдызы бар...”. Кеше бу дөньяда яши икән, димәк аның хыяллары, уй-ниятләре бар. Кешегә Ходай тарафыннан күз бирелгән. Шушы күзләр аша кеше матурлыкны күрә, таный, аңлый белергә тиеш. Адәмнең өмете булырга тиеш. Чөнки шушы өметләр, йолдызлар булып, безгә яшәр өчен көч бирәләр, алга атлар өчен максатлар куеп, юлыбызны яктыртып торалар.

Шагыйрәнең “Юкка” [3: 18] дигән дүртьюллык шигырендә образ буларак лирик геройның өметләре күренә. Бу өметләр аклык, сафлык, чисталык, пакълек белән тулы. Шагыйрә аларны ак гөрләвек белән чагыштыра, ак хыяллар, хыяллар океаны, ак дулкыннар кебек образлы сурәтләр белән бизи. Өметләр ак хыяллар океанын ак дулкыннар белән тышларга агып китәләр. Тик өметләрне автор чынга ашмаслык дигән фикер белән тәмамлый.

Лилия Гыйбадуллина күңелендә, шигырьләреннән күргәнебезчә, югары дәрәҗәдә романтик, эчкерсез һәм ихлас шигырьләр яралган. Лилия – җир кызы, ләкин аның уйлары, хыяллары биектә. Лилия ханым – табигать кызы. Аның кайсы гына шигырен алма, анда – күк, болытлар,

йолдызлар, кояш, ай, җил... Бүгенге катлаулы, усал, шәфкать белмәгән аяусыз дөньябызда гөнаһсыз, рухи, әхлакый тормышның чишмә башын – сафлыкны, ихласлыкны, матурлык һәм мәхәббәтне саклап яшәргә чакыра Лилия Гыйбадуллина.

**Литература**


1. Гыйбадуллина Л. Мин бәхетне күрәм!..: Шигырьләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – 47 б.
2. Гыйбадуллина Л. Тынлык кайтавазы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 39 б.
3. Галиуллин Т. Татар шигърияте: 1980–2000 еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – 229 б.
4. Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – 455 б.


## ЛУИЗА ЯНСУАР ШИГЪРИЯТЕНЕҢ ТЕЛЕ ҺӘМ СТИЛЕ


*Галиуллина Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*


Тел – әдәбиятның беренче элементы. Әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен, тел-стиль чараларын өйрәнү – кешенең эстетик зәвыгы формалашуга, матурлыкны тоярга, туган телнең эчке серләрен, потенциаль мөмкинлекләрен тирәнрәк үзләштерергә, дөньяга карашын киңәйтүгә, әсәрне аңлауга, язучының осталыгын билгеләүгә зур ярдәм итә. Әдәби әсәрләрнең телен өйрәнгәндә, нигездә, түбәндәгеләргә игътибар ителә: сүз-образ (сүз-сурәт), сүз сәнгате, гомумкулланышта булган төрле лексик берәмлекләрнең күпмәгънәлелеге, стилистик характеры, эмоциональ-экспрессив сүзләр, гади сөйләм лексикасы, язучының фразеология, мәкаль-әйтем, сурәтләү чаралары, поэтик бизәкләр, синтаксик фигуралар белән эш итүдәге новаторлыгы, образлы телнең эстетик сыйфаты, язучы һәм халык теле һ. б. [1: 24].

Язучы, яки шагыйрьнең профессиональ осталыгы, ул иҗат иткән әсәрнең ни дәрәҗәдә сәнгатьле һәм идея-эстетик яктан кыйммәтле булуында. Бу иң беренче чиратта аның теленә бәйле. Тел әдәбият дөньясында гаҗәеп корал дидек. Ә инде шагыйрьнең талант иясе булу-булмавы аның телебездәге поэтик хәзинәләрдән оста файдалана белүенә бәйле [3: 56]. Сүзләрнең туры мәгънәлегенә нигезләнеп, сурәт ясау үзенчәлеге автологик алымы дип атала. Әлеге алымга антоним, синоним, омоним, сүзне кабатлау һ. б. керә. Шуларның кайберләрен карап үтик:

*Мин <u>тамырым</u> белән <u>Җирне</u> кочам,*
*<u>Җаным</u> белән иңлим <u>Күкләрне</u>.*

“Син Күкләрне колачладың...” шигыренең әлеге строфасында Луиза Янсуар антонимнар куллана.

*<u>Бер көнлекме</u>, әллә <u>мәңгелекме</u>*
*Син торгызган храмның диварлары? –*
*Әле җиһан бу көнгәчә юрый*
*<u>Мәсихме</u> ул, диеп, <u>диванамы</u> (Мәсих).*

Луиза Янсуарның күп кенә шигырьләре керәшен, христиан дине мотивлары белән иҗат ителгән.

*Карыйм да сиңа... <u>елмаям</u>,*

*Карыйм да... <u>көләм</u>:*

“Очыш” шигырендә автор *елмаям-көләм* синонимнарын кулланган.

*Күңелем назга сусаган –*

*Күбәләктәй <u>очына</u>.*

*Хисләрем сүтелеп киткән,*

*Чыгалмыйм һич <u>очына</u>.*

“Сусадым” шигырендә *очына*(фигыль) – *очына* (исем) омонимнары оста кулланылган [4: 159].

Әдәби әсәрнең тукымасындагы сүзләргә билгеле бер әйберне, күренешне атап, аңлатып бирү вазифасына тагын икенче эш – әсәр эчтәлегендә тасвирлана торган вакыйганы укучыга образлар аша җиткерү максаты да өстәлә.

Шул ук вакытта язучы үзенең әсәрләрендә сүзләрнең күчерелмә мәгънәләрен куллана ала. Әлеге алым металогик алым дип атала. Әлеге алымга метафора, эпитет, оксюморон, гипербола һ.б. керә.Берничә мисал карап үтик.

*<u>Иделең</u>*

*<u>Илереп дәшмәде</u>:*

*– Җиңелдең...*

*Дастаннар сүтелә җилләрдә–*

*Кем тели, шул аны җилгәрә.*

“Сөембикә” шигырендә автор метафора кулланганын күрәбез.

*Беләм, безне тормый көтеп һичбер җәза,*

*Беләм, иман – зиндан түгел, түгел газап.*

*<u>Ул хачына менгән көннән</u> җирдәгеләр*

*Бар гөнаһтан мәңгелеккә инде азат.*

“Инану” шигырендә авторның метонимия куллана. “Ул хачына менгән көннән”дигән юлда без сүз Гайсә турында икәнен аңлыйбыз.

Автор үзенең образлар аша әйтергә теләгән фикерен укучыга җиткерү өчен, сүзләрне төгәл һәм урынлы булырлык итеп сайлый. Югыйсә, укучы авторның ни әйтергә теләгәнен аңламаячак.

Сүзнең сурәт ясау мөмкинлеген өйрәнгәндә, иң элек төп игътибарны аның мәгънә эчтәлегендәге билгеле бер образлылыкның булу-булмавына юнәлдерергә кирәк. Шушы нигездә сүзнең тасвирлау мөмкинлеген төгәлрәк итеп билгели алабыз [2: 82].

Луиза Янсуарның иҗаты, теле бик кызыклы һәм үзенчәлекле. Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин:

– Луиза Янсуар иҗатында автологик һәм металогик алымнарны бик оста һәм күп куллана. Иң еш автологик алымнардан антоним, синоним һәм

кабатлау алымнары, ә иң еш кулланылган металогик алымнардан – метафора, эпитет, метонимия, чагыштыру;

– аның иҗатында күп кенә керәшен мотивлары чагыла, чөнки ул чыгышы белән татар халкының керәшен этник төркеменә карый, шуңа күрә әлеге үзенчәлек булуы табигый;

– язучының иҗатында христиан диненә караган сүзләр, мотивлар аерым урын алып тора. Татар халкының керәшен этник төркеменә караганлыктан, аның күп кенә шигырьләре әлеге мотивлар белән сугарылган.

Яңа чор язучысы буларак Луиза Янсуар татар шигъриятенә яңа сулыш алып керә. Чын шагыйрь булыр өчен, Луиза Янсуарда табигый талант та, амбиция дә, гыйсьянчылык рухы да бар. Ул актив иҗат итүчеләрнең берсе булып, шигъриятендәге теле һәм стиль үзенчәлекләре белән аерым игътибарга лаек. Киләчәктә дә Луиза Янсуар үзенең укучыларын яңадан-яңа иҗат җимешләре белән сөендерер дип өметләнәм.

**Әдәбият**

1. Ефимов А.И. Стилистика художественной речи. – М., 1967,– 142 б.

2. Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы.–Казан: Мәгариф, 2002.– 199 б.

3. Хаков В.Х. Татар әдәби теле.– Казан: Татар. кит. нәшр. –1999. – 425 б.

4. Янсуар Л. Болан кызы: шигырьләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – 159 б

## ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ С СЕМАНТИКОЙ ЦВЕТООБОЗНАЧЕНИЯ В РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ

*Галлямова А., Высокогорский р-н, Ямашурминская средняя школа, IX класс*

*Рук. – Сибгатуллина Р.К., Сираева Р.Х.*

Фразеологические единицы являются универсальными единицами, характерными почти для всех языков, несмотря на это в каждом языке они несут в себе уникальные качества, свойственные только данной национальной (языковой) культуре.

Фразеологизм, согласно толковому словарю Ожегова – это устойчивое выражение с самостоятельным значением, близким к идиоматическому. Фразеологизмы – это несвободные сочетания слов, обладающие целостным лексическим значением, используемые для называния отдельных предметов, признаков, эмоций и чувств, свойств и черт характера, явлений, ситуаций и действий. Фразеологизмы используются как готовые речевые единицы. В фразеологических единицах сосредоточена наротная мудрость, результаты всего культурного опыта народа. Фразеологизмы в большинстве берут начало в народной речи. Внутреннее содержание фразеологических единиц отражает разнообразные стороны жизни. Совокупность различных по характеру значения и структуре фразеологических единиц образует фразеологический состав языка.

Интересными являются фразеологизмы, в состав которых входит название цвета. Ведь наша повседневная жизнь полна различных цветов. Разные цвета по-разному воздействуют на человеческую душу - вдохновляют или угнетают, рождают ощущение тепла или прохлады. Значения цветов во многих языках, особенно европейских, имеют сходства, и это облегчает их понимание. Но существуют и различия в употреблении цветов в фразеологизмах.

В русских и татарских фразеологизмах также получила отражение народная символика цвета. Красный цвет во фразеологизмах обоих языков имеет как сходства, так и различия в значениях. В русских фразеологизмах он встречается в таких значениях как красивый: «*красный молодец*», «*красная девица*», то есть молодые, красивые люди; хороший погожий, например «*красный денек*», остроумие «*красное словцо*». Совпадает красный цвет в татарских и русских фразеологизмах в значении смущения, стыда. Например, «*покраснеть как рак*», «*краснеть до корней*», *чәч төпләренә кадәр кызару* (вогнать кого-либо в краску, смутить кого-либо). В сравниваемых языках красный цвет встречается в значении пожара: *кызыл сыер – пожар; кызыл әтәч җибәрү – поджечь.* В русском фразеологизме «*пустить красного петуха*» обозначает: устроить пожар в чужом доме, совершить поджог.

Фразеологизм татарского языка *кызыл авыз* связан с умением разговаривать красиво. *Кызыл авыз – любящий насмехаться над людьми.*

Так же красный цвет встречается в значении революции. *Кызыл туй – свадьба под революционным лозунгом.*

В значении чего-то невозможного, не сбудущегося никогда – *кызыл кар яугач.* В значении главной мысли, идеи текста. *кызыл җеп булып сузылу* – красной нитью проходить.

В значении не совподения внешней красоты с внутренним миром человека ***кызыл тиз уңа.***

Также встречаются другие фразеологические единицы с семантикой красного цвета как в татарском, так и в русском языке, такие как *кызыл юл – красная строка.*

Таким образом, в татарском языке можно выделить и положительные, и отрицательные значения красного цвета во фразеологизмах.

Рассмотрим употребление фразеологических единиц с семантикой зеленого цвета в татарском и русском языках.

В татарском толковом словаре зеленый цвет обозначает: 1) основной цвет в спектре между синим и желтым; цвет травы, растения, цвет листьев; 2) обросший растением, покрытый зеленью; 3) состоящий из травы, листьев; 4) незрелый (в отношении фруктов); 5) очень молодой, неопытный, без подготовки.

В русском толковом словаре С.И. Ожегова зеленый цвет обозначает: 1) цвет травы, листвы; 2) о цвете лица: бледный, землинистого оттенка; 3) о плодах: недозрелый; 4) неопытный по молодости.

Зеленый цвет во фразеологизмах часто ассоциируется с природой: «*зеленый друг*». Зеленый цвет имеет так же значение «неопытный», «юный», это видно на примере русского выражения «*зелёный юнец*», «*молодо-зелено*» – о незрелой молодежи. В фразеологизмах татарского языка *яшел авыз, яшел кыяр* и *яшел борын* употребляются в значении «неопытный, наивный, молодой»

В татарском языке фразеологические единицы с компонентом *яшел* могут выражать семантику «неприятный». Например, *яшел тавыш* (неприятный уху, резкий голос).

В сравниваемых нами языках есть фразеологические единицы с семантикой зеленого цвета, которые передают значение «благоприятного стечения обстоятельств». Например, *яшел урам* (открытые дороги). В русском фразеологизме «*зелёная улица*» (свободный путь).

В обоих сопоставляемых нами языках фразеологизмы с компонентом *зеленый* могут выражать негативную коннотацию: в татарском и русском языке зеленый цвет – это цвет спиртных напитков “*зеленый змий*” – “*яшел елан*”.

Таким образом, значения в употреблении цветов красный и зеленый многих татарских и русских фразеологизмов имеют сходства.

**Литература**

1. Ахунзянов Г.Х. Татар теленең идиомалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – 118 б.

2. Ахатов Г.Х. Фразеологический словарь татарского языка: на тат. языке. – Казань: Казан. кн. изд-во, 1982. – 176 с.

3. Закиров Р.Р. Фразеологические единицы с компонентом цветообозначения в английском, русском и татарском языках: автореф. дис… канд. филолог. наук. – Казань, 2003 – 25 с.

## ТАТАР ТЕЛЛЕ ТЕЛЕВИДЕНИЕ: БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ

*Гарипова Р., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Юсупов А.Ф.*

Кешелек тарихы бик күп үзенчәлекле ачышлар һәм уйлап табуларга бай. Телевидение шулар арасында алдынгы урыннарның берсен алып тора. Ул – тавыш һәм сурәтнең зур ераклыкка бирелеше. Әлеге ачыш өстендә төрле илләрдән берничә дистә еллар буе күп кенә галимнәр эшли: Б.Л. Розинг, В.К. Зворыкин, Г. Оглоблинский, П. Нипков, Г. Герц һ.б. 1895 нче елда кешелек дөньясы / кешелек җәмгыяте радио һәм кино кебек эшләнмәләр белән байый. Бу сурәтне ерак араларга кадәр бирү кирәклеге ихтыяҗын алга чыгара. 1911 нче елда Россия инженеры Борис Розинг сурәтне үзе уйлап тапкан электр-нурланыш көпшәсе ярдәмендә тапшыруга патент ала, шуның ярдәмендә электрон телевидение барлыкка килә.

1925 нче елда аның укучысы Владимир Зворыгин электрон телевизор тәкъдим итә. 1929 нчы елда инженер Григорий Оглоблинский белән берлектә Зворыкин иконоскоп, ягъни беренче тапшыру трупкасы / көпшәсе уйлап чыгаралар. Ә инде 1936 нчы елда В. Зворыкин лабораториясендә лампалы беренче лампалы электрон телевизор эшләнә. 1928 нче елда беренче телевизион станция үз эшчәнлеген башлый. Улисс Санабрия беренчеләрдән булып үзенең радиостанциясендә сурәт һәм тавышны бергә бирә башлый. Ә инде даими рәвештә телетапшырулар алып бару 1934 нче елда Германиядә эшли башлый.

1950 нче елда АКШта төсле телевидение барлыкка килә. Әкренләп телевизион жанрлар системасы формалаша, тапшыру архивлары, профессиональ тележурналистлар һәм алып баручылар барлыкка килә. XX гасырның икенче яртысында илнең һәр ике гаиләсендә телевизор барлыкка килә, ягъни телевидение массачыл характер ала.

Россиядә телевидение үсеше тарихы соңарып башлана. Моңа төп сәбәп булып Икенче Бөтендөнья сугышының башлануы тора. 1931 нче елда урта дулкында транслятор җибәрелгәч, даими вещание башлана. 1933 нче елда “Б–2” радиоприемнигына телесигналлар кабул итә торган приставкалар чыгара башлыйлар. 1951 нче елда СССРның Дәүләт Радиосының Үзәк телевидениесе оеша. 1965 нче елда СССРда телевизион сигналны илнең бөтен территориясенә трансляцияли торган беренче спутник җибәрелә.

1951 нче елның 22 нче мартында СССР Министрлар Советы Карары нигезендә Телевидениенең Үзәк студиясе оеша, киләчәктә ул СССРның Үзәк телевидениесенә әйләнә. Телевидениенең үзәк студиясенең структурасы түбәндәгечә була: әдәби-драматик тапшырулар редакциясе, музыкаль тапшырулар редакциясе, балалар тапшырулары редакциясе һәм иҗтимагый-сәяси редакция.

Татарстанда Дәүләт телевизион үзәге 1959 нчы елның ноябрь аенда Казанның Шамиль Усманов урамында ачыла. Татарстанда телевидениенең барлыкка килүе һәм үсүе мәгълүмат тарату өлкәсендә генә түгел, ә республиканың барлык тормышында чын мәгънәсендә революцион вакыйга була [3: 163]. Татарстан телевидениясенең тарихын берничә этапка бүлеп карыйлар: 1) Татарстан телевидениесенең Студия буларак эшчәнлеге – 1955–1959 нчы еллар; 2) Дәүләт телевизион үзәгенең эшли башлау чоры – 1959–70 нче еллар; 3) Татарстан дәүләт телевидениесе структурасының техник җиһазлар белән тәэмин ителү һәм үсеш чоры – 1970–1985 нче еллар; 4) 1990–2000 нче еллар – милли күтәрелеш чоры, яңа форматтагы тапшырулар; 5) 2002 нче елның 26 нчы августында “Татарстан – Яңа гасыр” каналына нигез салыну [1: 25; 2: 49–52].

Татар телевидениесенең иҗат күтәрелеше 60 нчы елларда сизелә башлый. Әлеге чорда телетамашачы беренче телевизион спектакльләр ка-

рый. XX гасырның 80-90 нчы елларында илдә барган вәзгыять телеведение тормышына да яңа сулыш өрә: үзгәртеп кору сәясәте гражданнарга вөждан иреге, сүз һәм матбугат иреге бирә.

2000 нче еллар башында эфирга "Татарстан – Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе чыга башлый. Татарстан Республикасында 2012 нче елның 15 нче июненнән "ТНВ-Планета" каналына нигез салына. 30 нчы августтан канал планлы рәвештә эшли башлады. Ул Бөтендөньяга таралган татар халкын берләштереп, ерак илләрдәге татарлар тормышы, аларга Татарстандагы вәзгыять, яңалыкларны җиткерә [2: 52].

2011 нче елның маенда "Мәйдан" исемле татар музыкаль телеканалы эшли башлый. Иң элек Татарстан республикасының 10 шәһәрендә күрсәтә. Ә инде 18 нче сентябрьдән башлап канал үзенең телевизион тапшырулары, музыкаль клипларын күрсәтә башлый. Мәйдан – ул татар телевидениесе тарихында беренче музыкаль күңел ачу телеканалы. 2012 нче елның апрель аенда тагын бер татар музыкаль каналы эшли башлый – ТМТВ. Ул "Барс-медиа" инновацион эшлекле үзәкнең каналы булып тора. Тәүлек буе татарча концертлар, җырлар, клиплар күрсәтә.

2018 нче елның 12 ноябрендә "Шаян ТВ" каналы эшли башлады. Тәүлекнең 24 сәгатендә эшли торган балалар каналында 20 дән артык танып-белүне, белем бирүне һәм фикерләүне үстерергә ярдәм итүче үзенчәлекле программалар, телевизион уен-шоулар һәм викториналар, шулай ук татар теленә тәрҗемә ителгән иң яхшы мультипликацион фильмнар, фәнни-популяр, документаль, әдәби жанрлардагы дөньякүләм танылган тапшырулар урын алган. Тапшырулар шартлы рәвештә өч төркем тамашачыга юнәлдерелгән: 0–7, 7–11, 11–15 яшь.

Гомумән алганда, телевидение бүген кешелек җәмгыятендә мөһим информацион һәм күңел ачу чарасы булып тора.

**Әдәбият**

1. Даутова Р.В. Телевидение Татарстана: от прошлого к настоящему. – Казань: Новое знание, 2010. – 280 с.

2. Фатыйхова М.Х. «ТНВ-Планета» – халыкара иярчен мәйданында татар каналы // Белем һәм тәрбия чарасы буларак татар журналистикасы: «Мәгариф» журналының 100 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2014. – Б. 49–52.

3. Фәттахов И.Ф. Татарстан радиосы һәм телевидениесе: үсеш динамикасы / Телевидение и радио: динамики и контексты: научный сборник. – Казань: Центр инновационных технологий, 2016. – С. 121–127.

## ТАРИХНЫ ШӘХЕСЛӘР ЯСЫЙ

*Гарифуллина А., Яр Чаллы педагогия көллияте, III курс студенты*

*Фән. җит. − филол. фән. канд., доц. Минһаҗева Р.Ә.*

Татар милләте тарихында билгеле эз калдырган, гасырлар дәвамында халык теленнән төшмәгән батыр каһарманнары бар. Шуларның иң күренеклесе – XVIII йөздә яшәгән легендар шәхес Батырша.

Тарихны, халкыбызның мәдәниятен тирәнрәк белү теләге безне Батырша образының әдәбиятта яктырылышын өйрәнүгә рухландырды.

Без Батырша турында язылган өч әсәргә тукталдык. Беренчесе – Җәмит Рәхимовның «Батырша»тарихи романына, икенчесе – Ркаил Зәйдулланың «Батырша» хикәясенә, өченчесе – Фәүзия Бәйрәмованың «Батырша явы» повестена.

Җәмит Рәхимовның күләмле «Батырша» романы 1992 нче елда ук, үзгәртеп корулар үтеп, куәтле милли азатлык җилләре искән, милли үзаң уянган чорда иҗат ителгән. Нәкъ бу роман аңа ул чорда каләм уйнаткан мәшһүр татар прозаиклары рәтендә иң лаеклы урыннарның берсен яулап алу мөмкинлеген бирә.

Тарихыбызга күз салсак, XVI гасыр урталарыннан, Иван Грозный Казанны яулап алгач, татар халкы өчен бик авыр, рәхимсез, катлаулы еллар башлана: диннән биздерү, чукындыру еллары... Милли изү сәясәтенә түзә алмыйча, Идел-Урал буенда яшәүче халыклар 1755 нче елның язында баш күтәрәләр. Әлеге түнтәрелеш башында − Батырша (Габдулла Баһадиршаһ Гали углы Галиев) исемле каһарман була. Кызганыч, бу күтәрелеш бастырыла, Батырша кулга алына һәм биш елга якын төрмәләрдә иза чигә. Ул 1762 елда Петербургның Шлиссельбург зинданында сакчылар белән бәрелештә һәлак була.

Җ. Рәхимов әсәрендә әнә шул фаҗигале вакыйгаларны шактый тулы яктырта. Автор Батыршаның аянычлы язмышы аша тулы бер татар милләтенең фаҗигасен бирә алган. Шул чорның милли колоритын, сәяси-иҗтимагый барышын сурәтләгәндә, әдипнең күпсанлы тарихи материаллар, фактлар белән эш итүен, вакыйгаларның иң мөһимнәрен генә сайлап алып бирүен күреп була [3].

Аның Батыршасының каһарманлыгы, иң беренче чиратта, татар дәүләтчелеген кайтарырга теләүдә түгел, ә милли экспанцияне туктатып, төрле диндәге милләтләр арасында гаделлек, тигезлек урнаштырырга омтылуда. Аны мәчетләребезнең җимерүләре, мөселман зиратларының туздырылып, кабер ташларының чиркәү нигезен итеп файдалануы, ата-бабаларыбыздан килгән ислам диненең кимсетелүе бик тетрәндерә, сызланырга мәҗбүр итә. Ул иң әүвәл иманы, кавеме күтәрелешкә чыккан шәхес.

Күрәбез, Җ.Рәхимовның «Батырша» романы 1552 елда үз дәүләтен югалтуга дучар ителгән татар милләтенең олы фаҗигасен, азатлык өчен көрәш сәхифәләрен бөтен кискенлеге белән күрсәткән булуы белән татар әдәбияты тарихында мөһим урын алып тора.

Батырша образын үзәккә куйган икенче әсәр − Ркаил Зәйдулланың «Татар тажы» (2004) исемле китабына кергән һәм милләтебезнең X-XVIII гасырда яшәгән һәм татар тарихында тирән эз калдырган шәхесләренә багышланган хикәяләр сериясеннән − «Батырша» хикәясе.

Китапның кулга алуга ук, рәссамнәр Рушан һәм Рэм Шәмсетдиновларның үз эшләренең чын осталары, тарихны яхшы белеп эш итүчеләр булуы күренә. Китаптагы рәсемнән без Батырша образын тагы да тулырак күз алдына китерүгә ирешәбез.

Автор китабын тыйнак кына «нәни» хикәяләр дип атаса да, катлаулы тарихыбызны үтемле итеп, патриотлык, милли үзаң тәрбияли торган якларына басым ясап, татар таҗын төрле заманнарда йөрткән шәхесләрне тулы яктыртып, тарихи чорга үз бәясен бирүгә ирешә.

Р. Зәйдулла иң әүвәл Батыршаның сынмас рухлы шәхес булуына игътибар иткән. Төрмәдән Батыршаның патшага: «Без әле бетмәдек. Безнең көчебез әле бар», – дип хат язу күренешен дә автор шул җәһәттән керткән булырга тиеш [1: 99]. Алты ел төрмәдә утыргач, «монда исән килеш черегәнче, алышта үлүең яхшы», – дип, сакчыларга каршы һөҗүм оештыра, богаулы куллары белән дошман белән алышканда, ярсудан йөрәге ярылып үлүен бәян кыла. «Батырша! Син безнең йөрәгебезгә янә батырлык чаткысы сал!», − дигән өндәү-мөрәҗәгать белән йомгаклый Р. Зәйдулла хикәясен [1: 99].

Өченче авторыбыз − Ф. Бәйрәмованың «Батырша явы» әсәре 2012 нче елда милли татар хәрәкәтенең «Батырша елы» дип игълан итү уңаеннан басыла. Тарих фәннәре кандидаты, язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова моңа кадәр бу каһарман турында «Батырша җитәкчелегендә милли азатлык көрәше» (2005) фәнни-тарихи хезмәтен, «Баһадиршаһ» (2006) исемле романын иҗат итә.

«Батырша явы» әсәре исә алдагы ике әсәрдән күләме ягыннан кыскалыгы, гомумиләштерүләре белән аерылып тора. Ул Батырша күтәрелешенең сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен ачык бәян итә, аның тарихтагы әһәмиятенә, милләтебезне чукындырудан саклап калудагы роленә тәфсилләп туктала. Авторның Батырша хәзрәт гамәлләренә күбрәк ислам дине һәм ата-бабаларыбыздан килгән дәүләтчелек ягыннан игътибар иткәнлеге күренә.

Йомгаклап шуны әйтик: тарихны шәхесләр ясыйлар. Аерым шәхесләрнең тарих мәйданындагы ролен инкяр итеп булмый. Әмма алар үзләре генә тарих тудыра алмыйлар. Шәхесләр халык эчендә формалашалар, җитлегәләр. Җәмгыять, халык һәм шәхес проблемасы бу өч авторның әсәрендә дә уртак итеп һәм калку итеп күрсәткән мәсьәләләрнең берсе.

**Әдәбият**


1. Бәйрәмова Ф. Баһадиршаһ: әдәби-документаль роман. − Казан: Аяз, 2006. – 304 б.

2. Зәйдуллин Р. Татар таҗы: X–XVIII гасырларда яшәгән олуг кешеләр турында нәни хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 2004.−103 б.

3. Рәхимов Җ. Батырша. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 461 б.

# ХӘСӘН ТУФАННЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫНДА ПОЭМА ЖАНРЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

*Гарифуллина Э., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Юсупова Н.М.*

"Шигырьләрдә – шагыйрь язмышы" дигән гыйбарә күбебезгә таныш. Хәсән Фәхри улы Туфан әнә шундыйлардан. Ул – чын мәгънәсендә шигърият дөньясына гашыйк кешеләрнең берсе. Аның өчен шигырь язу куаныч һәм юаныч чыганагы гына булып калмыйча, хәтта тормыш эликсирына да әйләнә һәм Х. Туфанны ХХ йөз әдәбият мәйданында үз мәктәбен булдырган, классик иҗаты белән узган гасыр шигъриятендә тирән эз калдырган, милли сүз сәнгатен сүз-сурәт һәм фикер, сәнгатьчәлек ягыннан баеткан сүз осталарының берсе дәрәҗәсенә күтәрә.

Х. Туфан әдәби мәйданга сүз сәнгатенең яңа үсеш юлларын эзләп, шартлы алым-сурәтләргә урын биргән, имажинизм, футуризм кебек модернистик агымнар, алымнар белән мавыккан, һәр яктан яңалыкка омтылган 20 нче елларында аяк баса һәм үзенең иҗат юлында берничә баскыч, этапны үтә. Аның исеме матбугатта беренче тапкыр 1924 елда күренә: шул елны «Октябрь баласы» журналы һәм «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә берничә шигыре басылып чыга [3: 213]. Шуннан соң нибары өч ел үткәч, ягъни 1927 елда, Туфан инде танылган шагыйрь булып китә [1: 13]. Хәсән Туфанның башлангыч чор иҗатына караган аеруча уңышлы эшләнгән әсәрләре итеп "Ике чор арасында", "Башлана башлады" һәм тематикасы буенча аларга якын торган "Бибиевләр", "Татарстанда" поэмалары санала. Укучыларны да, тәнкыйтьчеләрне дә үзенә бик тиз җәлеп иткән беренче зур поэтик әсәре "Урал эскизлары" була. Шуннан соң ул бу әсәрендә эскизлар рәвешендә генә билгеләнгән темаларны да, образларны да тирәнәйтеп үстерә бара.

Поэма (*грек. poieta, тат. иҗат итәм*) дип "вакыйгалар, хисләр агышын шигъри формада хикәяли торган урта күләмле лиро-эпик әсәр" [2: 214] атала. Шунысы мөһим: автор үзе бу әсәрләрен поэма дип атамаган һәм, гомумән, аларның жанрын билгеләмәгән. Ихтимал, ул үзен теге яки бу жанр кануннарына бәйләп куярга теләмәгәндер; әгәр алай итсәм, күңелемдә тулып ашкан уй-хисләрне сыйдырып бетерә алмам дип уйлагандыр [1: 15].

Әдәбият фәнендә "Урал эскизлары" шигырьләр циклы дип йөртелә. Әйе, анда "Козырь туз", "Соңгы сарай янында" дигән өлешләре кебек, аерым әсәр булып яши ала торган бүлекләр дә бар. Бер үк вакытта әсәрне үзенчәлекле поэма дип тә билгеләп була. Анда ачык күренеп торган сюжет та, традицион формадагы композиция, ярылып яткан кульминация һәм чишелеш тә юк. Бары автор хыялына буйсынып, алар салмак кына җәелә-үсә баралар, укучыны ихтыярсыз рәвештә ияртеп-әйдәп китәләр. Ләкин

өермәле елларның чын күренешләрен иңләү, фикерләренең фәлсәфи саллылыгы, автор хисләренең киеренкелеге ягыннан бу әсәр – чын поэма.

“Ике чор арасында” (1927), “Башлана башлады” (1927), “Бибиевләр” (1927) кебек поэмаларында ул тормыш фактларын, чынбарлык күренешләрен заман турындагы иҗтимагый-фәлсәфи уйланулар белән тыгыз бәйләп, инкыйлаб чорындагы социаль атмосфераны, искелек белән яңалык көрәшен, идеяләр бәрелешен, шул процесста тормышның, кеше шәхесенең ничек үзгәрә, яңара баруын җанлы картиналар һәм колоритлы эшче характерлары аша ачып бирә. Вакыйгалар чолганышында, үз чорының таләпләренә җавап төсендә, яңа җәмгыять төзүче, шул юлда киләчәккә оптимистларча караучы геройларны үзәккә куя. Чорның әһәмиятле, олы темаларын, әхлакый-фәлсәфи проблемаларын күтәреп, социалистик реализм кысаларында иҗат ителгән бу поэмалар циклы сәнгати яктан йомшаграк эшләнгән, эпик башлангычка зур урын бирүе белән характерлана. Мәсәлән, “Ике чор арасында” поэмасы Хәсән Туфанның автобиографик материалларына корылган. Үсмер малай образында шагыйрь үзенең яшьлек көннәрен күз алдыннан кичерә. Поэмада геройларның әсәр язылган чордагы хәле сурәтләнә. Авторның “Башлана башлады” исемле икенче поэмасында инкыйлаб вакыйгаларына мөнәсәбәте сурәтләнә.

Сәнгати яктан Туфан катлаулы, имажинистик сурәт тудыру белән мавыга: укучыга әлегә аз таныш, абстракт сурәтне эмоциональ төшенчә белән янәшә кую аша яңа ассоциацияләр тудырырга омтыла [3: 215]. Шул юлда төн – кара сыер, завод торбасыннан чыккан ялкын – сыер муеныннан аккан кара кан кебек метафоралар белән чуарланган образлылык барлыкка килә; «бодай күк бүрткән язгы уй / Шытылды / Казанның башында», «Безнең хисләр каный / Кимчелекне җиңмәү үченнән», «Әнкәй – авыл, әткәй – завод – кода, / Гареп – килен, / Кияү – Азия» кебек сурәтләр ярдәмендә яңа тормышны үзенчәлекле чагылдыру омтылышы күзәтелә.

Якты киләчәккә ышаныч мотивы белән сугарылган «Татарстанда» поэмасында үткән / бүгенге оппозициясе элек / хәзер кебек формалашып, аерым бүлекләр формасында әсәр структурасында ук урын ала. Саз, губерна, кышлак кебек детальләр үткәннең билгесе кебек кабул ителә, үткән бәхетсезлек чыганагы, бүгенге кешене бәхетле итә кебек фикер алга чыга, трактор, марш кебек бүгенгене тергезгән образ, сүз-сурәтләр шушы мәгънәне төрле яклап көчәйтүгә хезмәт итә. Риторик эндәш төсендә аерып куелган хушлашу гыйбарәсе, саубуллашу белән бергә, бөтенләйгә аерылу мәгънәсенә дә ишарә ясый.

Х. Туфанның башлангыч чор иҗатына йомгак ясап, шуны әйтергә була: шагыйрьнең бу елларда иҗат иткән әсәрләре саф эпик алымы, характерларның җанлы сурәтләнүе, образлы-эмоциональ чараларның

тыгызлыгы, стиленең сөйләм интонациясенә корылуы, сюжет вакыйгаларының табигый һәм иркен үсеше поэма жанрының үзенчәлекле булып үсеп китүенә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Галиуллин Т. Алга барышлый // Хәсән Туфан. Шагыйрьнең иҗат юлы турында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 11–35.

2. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.

3. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: 2 кисәктә. 1 нче кис. / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан ун-ты нәшр, 2011. – Б. 213.

## ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕ КАБАТЛАГАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ЭШ ТӨРЛӘРЕ

*Гатина А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сәгъдиева Р.К.*

Татар теле дәресләрендә эндәш сүзләр башлангыч сыйныфларда ук өйрәтелә башлый. 5–6 нчы сыйныфта эндәш сүзләрне кабатлауга карата берничә күнегү бирелә. Мәсәлән: *Күнегү 7.* Эндәш сүз булган җөмләне табып, дәфтәрегезгә язып куегыз [7: 7]. *Күнегү 57.* Балаларга эндәшкәндә кулланыла торган исемнәр язып килегез [9: 31].

7 нче сыйныфта эндәш сүзләргә билгеләмә, кулланылыш үзенчәлекләре турында мәгълүматлар бирелә. Түбәндәге күнегүләр укучыларда эндәш сүзләр турында белемнәрне формалаштырырга ярдәм итә: ияне эндәш сүзгә әйләндереп, җөмләләрне үзгәртеп языгыз [4: 118]; эндәш сүзләрне табып, аларның нинди максат белән (мөрәҗәгать итү, бәяләү) кулланаuын аңлатыгыз [4: 118]; җөмләләрне күчереп языгыз. Эндәш сүзләрне табып, астына сызыгыз [4: 119].

8 нче сыйныф дәреслегендә эндәш сүзләрне синтаксик яктан тикшерү үрнәге, шартлы билгесе һәм берничә күнегү бирелә [3: 6–7, 147].

Рус мәктәпләрендә укучы балалар өчен төзелгән дәреслекләрдә дә эндәш сүзләрне кабатлага күнегүләр бирелә. Мәсәлән, эндәш сүзне табып әйтегез [8: 11]; эндәш сүз кергән җөмләдә нинди фигыль кулланылган [8: 15]; бирелгән сүзләр бер очракта – ия, икенче очракта эндәш сүз булырлык итеп, җәенке җөмләләр төзеп языгыз [8: 16].

8 нче сыйныфта укучылар эндәш сүзләрне җөмлә кисәге буларак өйрәнәләр. Биредә эндәш сүзгә билгеләмә, тыныш билгеләре һ.б. кагыйдәләр бирелә [5: 126–131].

Эндәш сүзләр турында өйрәнү һәм ныгыту дәресләрендә тыныш билгеләрен куярга өйрәтүгә игътибар итәргә кирәк: укучылар җөмлә башында килгәндә – эндәш сүздән соң, җөмлә уртасында килгәндә – ике яктан да, җөмлә ахырында килгәндә, аннан алда өтер куелуын белеп, үз мисаллары белән ныгытып барсыннар.

Мәсәлән, түбәндәге җөмләләрне мисалга китерергә була:

а) җөмлә башында: **Әбекәй,** синең җырың бигрәк кызык, әйеме? [6: 360].

ә) җөмлә уртасында: Сафиуллам белән күрештерден, **Сафиулла,** дим, никләр бер авыз сүз дәшмисең, сиңа әйтәм? [6: 365].

б) җөмлә ахырында: Нәмәгә аптырап калдың, **гөлкәем**? [6: 361].

Күнегүләр эшләткәндә, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр үткәрүгә күбрәк урын бирергә кирәк. Шулай ук дәрестә компьютер технологияләреннән презентацияләрне дә файдаланырга була. Бер грамматик категорияне икенчеләре белән буташтырмасыннар өчен, үткәннәр белән үреп, чагыштырып карарга өйрәтү мөһим.

Түбәндәге кайбер күнегүләрне эшләтеп, укучыларга алган белемнәрен сөйләмнәрендә һәм язма эшләрендә файдалана белү күнекмәләре бирелә:

– Эндәш сүзләрне табып, астына сызу. Лексик-семантик яктан нинди сүзләр белән бирелүен аңлату.

– Җөмләләрдә эндәш сүзләрне табу. Алар янында кирәкле тыныш билгеләрен куеп язу.

– Диктантлар яздыру яки аңлатмалы язу үткәрү.

– Тестлар оештыру.

– Укытучы тәкъдим иткән схемалар ярдәмендә җөмләләр төзеп язу.

– Медиа файллар ярдәмендә төрле биремнәр башкару һ.б.

Мәсәлән укучыларга презентация ярдәмендә түбәндәге күнегүне бирергә була. Г.Тукай шигырьләрендә төшеп калган эндәш сүзләрне һәм тыныш билгеләрен куярга, тыныш билгеләренең куелышын аңлатырга:

1. Әйт әле ...
Сөйләшик бергәләп.
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек? (“Бала белән Күбәләк”)

2. Әйдәле ... өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр! (“Кызыклы шәкерт”)

3. И ... һич юк икәндер мәрхәмәт хисең синең,
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең? (“Шүрәле”)

Файдалану өчен эндәш сүзләрне рәсемнәр аша бирергә дә мөмкин.

Шулай ук дәрестә модель төзү алымын да кулланырга була:

1. Эндәш сүз, ……; 2) …., эндәш сүз, ……..; 3)…., эндәш сүз; 4) Ымлык + эндәш сүз, ……. .

Бу темага программада бик аз вакыт бирелгән. Шулай да теманы укучыларның яхшы итеп үзләштерүенә ирешү таләп ителә. Соңыннан билгеле инде, укучыларның теманы үзләштерүләрен, тыныш билгесен дөрес куя белүләрен сынау максаты белән, язма эшләр (диктант, изложение, сочинение) үткәрергә, йомшак үзләштерүчеләр белән аерым эшләргә, консультацияләр бирергә дә кирәк була.

**Әдәбият**

1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

2. Максимов Н.В., Нәбиуллина Г.Ә. Татар теле. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 159 б.

3. Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2016. – 223 б.

4. Харисова Ч.М., Максимов Н.В., Сәйфетдинов Р.Р. Татар теле. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 207 б.

5. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит, нәшр., 2015. – 159 б.

# ТУГАН ТӨБӘК МИКРОТОПОНИМИЯСЕНӘ КҮЗӘТҮ

(Балтач төбәге микротопонимиясе материалында)

*Гафурова И., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Галиуллина Г.Р.*

Туган төбәк ономастикасын өйрәнү гуманитар фәннәр өчен гаять әһәмиятле өлкәләрдән санала, чөнки бу төр тикшеренүләр фәнни яктан гына түгел, яшь буынны милли рухта тәрбияләү ягыннан да отышлы. Шунлыктан белем бирү оешмаларында тел, тарих дәресләреннән тыш, класстан тыш эшләр кысасында да ономастик материалны куллану мөмкинчелеге бар. Без әлеге мәкалә кысасында Балтач районы мисалында туган төбәк микротопонимиясенә кагылышлы мәгълүматларга күзәтү ясыйбыз. Әлеге материалларны сыйныфтан тыш эшләр башкарганда, түгәрәкләрдә, проект эшләре башкарганда кулланырга мөмкин.

Ономастикада *ойконим* термины барлык төр торак пункт атамаларын белдерү өчен кулланыла һәм топонимның бер төре булып санала. Топонимиканың ойконимнарның килеп чыгышын, үсеш һәм кулланылыш закончалыкларын өйрәнә торган бүлеге ойконимика дип, ә ойконимнарның тулаем җыелмасы ойконимия дип атала [4].

Авыл ойконимик термины – гомумтатар телендә киң таралган, әдәби телебезгә дә, барлык татар сөйләшләренә дә хас булган лексик берәмлек. Борынгы төрки телдә *агыл* сүзе “хайваннарны куып кертү урыны, утар” мәгънәсен белдергән. Гомумтөрки *агыл, ауыл, аwыл* ойконимик терминының борынгы *агыл* “терлекләрне яисә аулап тотылган хайваннарны беркадәр вакыт ябып асрау өчен ясалган киртә, ихата, кура” сүзеннән ясалган булуы мәгълүм. *Агыл* сүзе үзе исә *аг-аң-ау* тамырына нигезләнеп барлыкка килгән дигән караш бар [1: 72]. Чыннан да, борынгы кыргый һәм ярымкыргый хайван көтүләрен берьюлы суеп, итен сакларга мөмкин булмаган (бигрәк тә эссе җәй көннәрендә), шуның өчен аларны киртәләп алынган бер урында туплап-җыеп тотканнар. Мондый зур хайван

көтүе мал, байлык булганлыктан, әлеге киртә тирәсенә бөтен ыру торак корып утырган һәм агыл “авыл” барлыкка килгән.

Балтач районы топонимиясендә *сала* ойконимик термины катнашып, *Яңа Сала+выч, Иске Сала+выч* дигән татар авыллары исеме ясалган. Татар теленә “авыл” мәгънәсенә ия булган *сала* ойконимик термины славян телләреннән (борынгы рус телендә село) кергән булса кирәк. Гомумтөрки *салу* “кору” тамырыннан ясалган булырга да мөмкин. Казан ханлыгы чоры язма истәлеге Сәхипгәрәй хан ярлыгында (1523) бу сүз *сала харҗы* – “авыл салым” рәвешле теркәлгән: Касыйм сөйләшендә зур авылны сала (*Дүрт сала, Бием сала* һ.б.), кечкенә авылны *диривна* диләр [1: 72].

*Иле* “авылы” ойконимик термины катнашып шактый авыл атамалары ясалган. Балтач районына кергән авыллар арасында *Кариле, Яңгул иле, Таузар иле* дигән торак пунктлар бар.

Татар телендә *урам* ойконимик термины гомумкулланылышка ия. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә *урам* сүзенә “гадәттә ике яклап тезелгән йортлар арасында җәяүлеләр, атлылар, машиналар белән йөрү өчен булган озынча ачыклык, юл” дигән аңлатма бирелгән [2: 141].

Төрки телләрдә *урам* сүзе берничә мәгънәгә ия. Казан арты сөйләшенең балтач урынчылыгында тыкрык җирле географик термины урамны белдерә. Мәсәлән, *Тегәрҗеп тыкрыгы* (Салавыч), ферма тыкрыгы, райтоп тыкрыгы (Салавыч) һ.б.

Гомумтатар *урам* ойконимик терминына нигезләнеп, Татарстанда һәм башка урыннарда татарлар яши торган һәрбер торак пунктта диярлек урам атамалары барлыкка килгән. Мәсәлән, өйләнмәгән егетләре күп булганлыктан, Салавыч авылының бер урамы Алашалар урамы дип атала. Авылның иң кырыенда урнашып, Тышкы урам, йортлары бер рәткә тезелеп торганлыктан, Тегәрҗеп урамы; Әкмәш кушаматлы кеше яшәгәнлектән, Әкмәш тыкрыгы дип йөртелә торган урамнар әле дә саклана.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *оч* сүзенең ойконимик мәгънәсенә нәрсәнең дә булса уртадан, үзәктән ераклашкан ягы, чите, башы дигән мәгънә бирелгән [4]. Урта диалектның Казан арты сөйләшләре төркемендә урам һәм авыл очын белдерә торган *оч* сүзе, тау ягы сөйләшләрендә *баш* сүзе кулланыла: *Түбән оч, Югары оч, Аргы оч, Урам баш, Шайтан очы* һ.б.

*Тыкрык* ойконимик терминына нигезләнеп, татарлар яши торган һәрбер торак пунктта диярлек, микротопонимнар ясалган. Мәсәлән, *Тегәрҗеп тыкрыгы, Хәллә тыкрыгы, Тегермән тыкрыгы, Алашалар тыкрыгы, Көсәй тыкрыгы, Мөбарәк тыкрыгы.*

Мисаллардан күренгәнчә, тыкрык атамаларының зур күпчелеге йортлары шул тыкрык янында булган гаилә башлыгының исеме яки кушаматы + тыкрык ойконимик термины моделе белән ясалган.

Татар әдәби телендә һәм җирле сөйләшләрдә йорт-җирне, хуҗалык берәмлеген белдерү өчен хезмәт итә торган ойконимик терминнар байтак. Әдәби телебездә әлеге төшенчәне белдерү өчен йорт, аның синонимы өй, хуҗалык терминнары кулланыла. Татар теле сөйләшләрендә мондый ойконимик терминнар тагын да күбрәк.

Татар теле микротопонимнары һәм топонимнары озак еллар дәвамында формалашкан. Топонимнарның бер төре булган ойконимик терминнар төзелеш-архитектура терминнары белән уртак булу күзгә ташлана. Димәк, ойконимия үзе кешеләрнең төзелеш-корылыш эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

**Әдәбият**


1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге.– Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. – Т. 1. – 543 б.
2. Гарипова Ф.Г. Татарстан микротопонимнар сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 245 б.
3. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 286 б.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге [Электрон ресурс]. – http://www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/tatar-leksikologiya-tom3-chast1.php?clear_cache=Y


## МУСА ҖӘЛИЛ ИҖАТЫНДА ЮМОР


*Гәрәева Ә., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, XI сыйныф*

*Җит. – Галимҗанова Д.И.*


Бу хезмәтебезнең максаты М. Җәлил әсәрләрендә юмор хисенең бирелешен анализлау. Төп максатка ирешү өчен безнең тарафтан түбәндәге мәсьәләләр хәл ителде. М. Җәлил иҗаты өйрәнелде. М. Җәлил иҗатын өйрәнүче әдәбият һәм тел белгечләре хезмәтләре анализланды. Алар арасында К. Бадыйков, Р. Мостафин, Г. Кашшаф һәм башкалар хезмәтләре. Татар әдәбият тәнкыйтендә Әмир Мәхмүдовның “Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал” дигән хезмәте анализланды. М. Җәлилнең ундүрттән артык шигыре тикшерелде.

З. Мәҗитов шагыйрьнең тоткынлыкта шаян шигырьләр иҗат итүен, «беренчедән, кайгы-хәсрәтне җиңүе, гадәттән тыш авыр шартларда да фашизмга каршы көрәшеп була дигән фикергә килүе, икенчедән, үзенең язганнарын бер бөтен итеп туплау ыша¬нычы һәм дәрте рухландырган», [3: 273–274] – дип күрсәтә. Шунысы үзенчәлекле, Моабит шигырьләренең күпчелегендә, юмористик әсәрләренең барысында да тыныч тормыш вакыйгалары сурәтләнә.

Моабит шигырьләре теле, идея-эстетик эчтәлеге, поэтик стильләренең камиллеге ягыннан сугыш чоры поэзиясендә күренекле урын алып тора. Алар шагыйрьнең Ватанга, үз халкына кайнар мәхәббәтен, дошманга ачы нәфрәтен, сагышлы һәм газаплы кичерешләрен, шул ук вакытта аның юморга бай көчле рухын чагылдыра.

М. Җәлилнең юмористик шигырьләрендә гади сөйләм, диалекталь, китап сүзләре, күчерелмә мәгънәле сүзләр, алынмалар, үзгәртеп кулланган сүзләр дә байтак. Мәсәлән: Гади сөйләм сүзләре – чарка (савыт) [5: 52], апара (камыр башы) [5: 54], мут (хәйләкәр) [5: 228], чөкердәшеп, гөрләшеп утыру, чабу [5: 116]. Искергән сүзләр – тәмамән (тәмам) [5:54], мәгъшука (сөйгән яр) [5: 80]. Күчерелмә мәгънәле сүзләр-бутка(ботка — буталчыклану) [5: 52], сырыша (сыена) [5: 196]. Алынма сүзләр – кубарь (бөтерчек), «клуб», «мода», «танго», «конюшнә», барышня, процент, артист, кассир [4: 467]. Сүзлекләргә теркемләнгән сирәк очрый торган сүзләр: ләктем (эләктем) [5: 80], тин (тиен), күз-каш, сырлы-мырлы, симәнкә, эләүкә, сусыз-парсыз [4: 467]. Болар юмор тонын бирүдә әһәмиятле стилистик функция башкаралар.

Сүз уйнату ярдәмендә гомумкулланылыштагы гадәти сүзләргә дә шагыйрь көтелмәгән үткен, шаян мәгънә сала:

Ник елмайдың, каш сикертеп,
Яратмагач, йөрмәгәч?
Ник ашаттың тозлы балык
Соңыннан су бирмәгәч? [5: 154].

Юмор тонын көчәйтү максатында шагыйрь мәгънәдәш сүзләрдән дә файдалана:

Иркәм белән икебез,
Пар алмадай битебез,
Чөкердәшеп, гөрләшеп,
Утырабыз серләшеп [5: 116].

Уңай мәгънәле сүзләрне берәр тискәре сүзгә каршы кую да юмор рухы бирә:

Киткән чакта кайсын озатасың
Назлап, сыйпап, мактап, иркәләп.
Ә кайберсен куып чыгарасың
Якасыннан тотып типкәләп [5: 52].

Монда назлап, сыйпап, мактап, иркәләп дигән сүзләр типкәләп сүзенә кискен каршы куела. Синоним сүзләрне градация рәвешендә куллану да юмористик максатка хезмәт итә:

Бетте бакчам, кырылды,
Һич чара юк каһәргә.
Охшап калды түтәлләр
Бомбаланган шәһәргә [5: 228].

Биредә бетте, кырылды сүзләре – әнә шундыйлар.

Мәхәббәт сүзе дә зур гына синонимик оя төзи: гыйшкым, мескен гыйшкым, минем гыйшкым, томаулы гыйшык, чир, су һ. б. Биредәге томаулы гыйшык, чир, су сүзләре, шулай ук дару – агу, ләззәт – михнәт,

елау – көлү [5: 78] кебек капма-каршы мәгънәле сүзләр дә аның әсәрләрендә юмористик функция үтиләр:

Икенче көн ни күрәм?
– Бер елыйм да, бер көләм.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ертык юбкадан [5: 76].

Кабатлаулы һәм парлы сыйфатлар ярдә¬мендә шагыйрь көнкүрештәге гади генә әйберләрне дә юмор объектына әверелдерүгә ирешә: сусыз-парсыз мунчада, баскыч-баскыч коры эләүкә, эленеп-салынып торган пәрәвез [4: 467].

М. Җәлилнең юмористик әсәрләрендә фразеологик әйтелмәләр аерым урын алып тора. Аның унөч шигырендә генә дә шундый иллеләп әйтелмә бар. Мәсәлән, сабырлыгын югалту, үч итү, җен белсен, үтерә карашлары, сәнәккә утырту [5: 116]. Аларның күпчелеге бары тик юмор стиленә генә хас. Күп кенә әйтелмәләрне ул, шигырьнең эчтәлегенә туры, китереп, үзгәртеп тә кулланган. Мәсәлән, «Күршеләр»дә ул эчкә җылы кергәч дигән әйтелмәне «эчкә җылы йөгергәч» формасында, эчтә бүре саклагач дигәнне – эчтә бүре асрагач дип үзгәртә һ. б.

Шагыйрь әсәрләрендә, юмористик тасвирлау чаралары буларак, чагыштырулар да зур роль уйный. Алар көтелмәгәнлеге һәм эш-хәлне, процессны көлкеле итеп сурәтләве белән үзенчәлекле. Мәсәлән: кубарь (бөтерчек) төсле башын биеп торгач [5: 52], мескен гыйшкым кызган куык төсле шартлады, гашыйкларча авыр сулыйм дисәм, болан төсле чабып кайттым [5: 128].

Юмор тонын бирүдә шагыйрь эпитетлардан да файдалана: өметсез кәҗә [5: 228], мамык кул [5: 196], ипле урын, калын мичкә, яшел күзле мәшһүр шадра шагыйрь [5: 54].

М. Җәлил шигырьләрендә төрле образлар да көлке чарасы булып хезмәт итә: томау, гыйшык (абстракт образлар), кәҗә, бүре, борча (аллегорик образлар), сәгать, кызыл кәбестә (предмет – образлар).

Тискәре мәгънәле чагыштыруларны да шагыйрь юмор чарасы буларак куллана: абау ямьсез сугуы, чиркәү кага диярсең, үч иткән күк чаба, утырган күк сәнәккә [5: 116].

Халыкның тапкыр, шаян рухын чагылдыручы, үткен, җор телдә язылган шигырьләре М. Җәлилнең чын мәгънәсендә юмор остасы булуы турында сөйли.

**Әдәбият**

1. Кашшаф Г. По завещанию Мусы Джалиля. Пер. с тат. Рафаиля Хакимова. – Казань: Тат. кн. изд., 1984. – 224 с.

2. Махмудов А. Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля. – Казань: Тат. кн. изд., 1980. – 143 с.

3. Мәҗитов З. Сугышчан поэзия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 182 б.

4. Җәлил Муса. Моабит дәфтәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 714 б.
5. Җәлил Муса. Моабит дәфтәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 311 б.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ «АК ЧӘЧӘКЛӘР»ЕНДӘ ТӨС КОМПОНЕНТЛЫ ЧАГЫШТЫРУЛАРНЫҢ ЯСАЛЫШ ЯГЫННАН ТӨРЛӘРЕ

*Гомәрова Д., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – фил. фән. канд., доц. Габдрахманова Ф.Х.*

Төс белдерүче сүзләр төрле фән тармакларында өйрәнелә. Психологиядә төс проблемасы тоемлау һәм кабул итү дәрәҗәсендә каралып, кешенең психологиясенә, кәефенә һәм сәламәтлегенә дә тәэсир итә дип санала. Төсләр һәрбер халыкта төрлечә кабул ителеп, телдә дә үзенчәлекле чагылыш таба. Алар телдә һәрдаим үзгәреп һәм үсеп торалар.

Әдәбиятта төс гомуми категорияләрдән берсе булып санала. Төс – эстетик тәэсирле объектлар тудыру юлы белән тормышны үзләштерү, аңлату формасы. Төс әдәби әсәрдәге сурәтнең өлешләрнең характеристикасын атый. Аннан башка әдәбиятта тормышны сурәтләү, күзаллау, танып-белү, кабат иҗат итү мөмкин түгел. Шулай да кешеләр төсләргә карата төрлечә нисбәттә торалар. Билгеле бер әдипнең эстетик зәвыгы нинди дә булса төсләрне аеруча яратуда чагыла. Бу аларның биологик үзенчәлекләренә (җенесе, яше) һәм иҗтимагый-психологик дәрәҗәсенә (милләтенә, темпераментына) бәйле.

Төсләр аерым бер милләтнең үзенчәлеген чагылдырган кебек чагыштырулар да халыкның дөньяга карашларын, билгеле бер кануннарга мөнәсәбәтләрен җиткерә ала. Галимнәр фикеренчә, сүзләр үзенчәлекле мәгънәләре белән тел коллективына хас яшәү рәвешен генә түгел, ә аның фикерләү рәвешен дә чагылдыралар. Чагыштырулар тел-сурәтләү чарасы рәвешендә матур әдәбият стилендә киң кулланыла, публицистик сөйләмдә, фәнни әдәбияттә, эпистоляр стильдә, халык телендә дә күп очрый.

Әдәби әсәрләрдә чагыштыруларның функциональ мөмкинлекләре гаять киң, алар, гадәти сурәтләү чарасы, тел бизәге генә булып калмыйлар, ә бәлки мәгънәви-эстетик вазыйфа да башкаралар. Бу исә үз чиратында бүгенге көндә чагыштыруларның кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнүнең мөһимлеген раслый.

Чагыштырулар кебек, сыман, төсле, шикелле, әйтерсең сүзләре һәм -дай/-дәй, -тай/-тәй кушымчалары ярдәмендә ясалалар.

Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәрендә кулланылган төс компонентлы чагыштыруларны карап, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

Иң еш кулланылганы – *кебек* сүзе белән ясалган чагыштырулар:

Маһирә ханымның *кара болыт кебек чәчләре* вакыт-вакыт аны акылдан шаштырыр хәлгә җиткерә иде.

Гөлшәһидә үзенең иң яраткан эре бизәкле, киң итәкле юбкасын һәм *кар кебек ак* кофтасын кигән, нечкә биленә нәфис пластмасса билбау салган, аякларында ак босоножкалар.

*Төсле* сүзе белән ясалган чагыштырулар да аз булмады:

Гөлшәһидә исә буйга аңардан озынрак, *кара карга канаты төсле* чем-кара толымнарын биек итеп артка төеп куйган.

Алардан иң истә калганнары *кара бөрлегән төсле* кап-кара күзле, бик яшь, бик беркатлы Лена, «Саратау бикәсе» дигән кушаматлы, сары чәчле, таза беләкле көләч Люся, аз сүзле кырысрак табигатьле Татьяна Аркадьевна.

*Шикелле* сүзе белән ясалган бары тик бер генә чагыштыру табылды: Бу Солтанморатова кичә аңа да *кара җил шикелле* ташланган иде.

*Әйтерсең* сүзе белән ясалган чагыштырулар да очрады: Агач кайрылары, коймалар каралган, *әйтерсең*, аларны дымсу кара хәтфәгә төргәннәр. Ул шундый кызу йөри, аның ак калфагы, *әйтерсең*, ак яшен кебек безнең ишек турысыннан сызылып үтеп китә.

Тәңкә карлар шундый эре ява, *әйтерсең*, күктән әкрен генә, тын гына ак чәчәкләр коела.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була, Г. Әпсәләмов «Ак чәчәкләр» әсәрендә *кебек, төсле, әйттерсен* һәм *шикелле* сүзләре ярдәмендә ясалган төс компонентлы чагыштыруларны кулланган. Ләкин сыман һәм -*дай* / -*дәй*, -*тай* / -*тәй* кушымчалары ярдәмендә ясалган төс компонентлы чагыштырулар табылмады. Ләкин әлеге ысул бары тик без карап үткән төс компонентлы чагыштыруларда гына кулланылмаган.

**Әдәбият**

1. Базыма Б. Цвет и психика. Харьков, 2001. – 54 с.

2. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. – М.: ВЛАДОС; Казань: Магариф, 2004. – 239 с.

3. Поварисов С.Ш. Татар телендә чагыштыру төзелеше. Уфа: БашДУ, 1996. – 100 б.

4. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр: Роман. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1989. – 510 б.

## СОПОСТАВИТЕЛЬНЫЙ АНАЛИЗ ПОСЛОВИЦ В РАЗНОСТРУКТУРНЫХ ЯЗЫКАХ

*Губайдуллина Л., Казань, гимназия №20, XI класс*

*Джоан Себастьян Гарридо Пинилья, КНИТУ им. А.Н.Туполева – КАИ,*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Зиннатуллина Г.Ф.*

Пословицы и поговорки являются неотъемлемой частью культуры любого народа. В них всегда отражается народная мудрость, на основе которых лежит размышления о жизни и ее ценностях.

Одной из актуальных проблем современной семасиологии и сопоставительной лингвистики является проблема выявления семантических эквивалентов как в близкородственных, так и неродственных языках, а также способов перевода безэквивалентных единиц с исходного языка на

другие. Поэтому при сравнительно-сопоставительном изучении языков значительное место отводится вопросам межъязыковой эквивалентности.

Эквивалентность лексических единиц базируется на одинаковой предметно-понятийной отнесенности слова, которая позволяет одной языковой единице выступать вместо другой.

В пределах одной языковой системы отношения эквивалентности совпадают с синонимическими отношениями.

Проблема эквивалентности рассматривается вместе с категорией адекватности перевода. Адекватность как свойство перевода ориентировано на получателя сообщения. Так, перевод считается адекватным, если коммуникация оказывается успешной. Таким образом, адекватность является главным образом характеристикой не степени соответствия текста переводу текста оригинала, а степени его соответствия ожиданиям участников коммуникации [2: 289]. Однако в переводоведении хорошим переводом считается эквивалентный перевод [4: 117], под которым понимается максимально полная передача «коммуникативно-функционального инварианта» оригинала.

В переводоведении проблема эквивалентности рассматривается в процессе установления семантических соответствий. По Л.С. Бархударову, существует три основных типа семантических соответствий между лексическими единицами нескольких языков: 1) полное соответствие; 2) частичное соответствие; 3) отсутствие соответствия [1: 27].

Каждый народ отличается своеобразным видением мира. Это может быть обусловлено разной верой, разным менталитетом, разными традициями и обычаями, разной культурой. Носителями такой этнокультурной информации являются пословицы. Сравнение пословиц и поговорок разных народов показывает, как много общего имеют эти народы. В пословицах и поговорках отражен богатый исторический опыт народа, представления, связанные с трудовой деятельностью, бытом и культурой людей.

Для семантического анализа татарских, русских, английских и испанских пословиц рассмотрели следующие общие темы:

1. «Ум, учение, внутренний мир человека». Смысл данных пословиц заключается в том, что человек должен учиться и получать знания всю свою жизнь. Вышеприведенные примеры пословиц из всех четырех языков, подтверждают, что каждый народ в человеке, прежде всего, ценит ум, мудрость. Имеются как, полностью аналогичные пословицы и поговорки, так и частично соответствующие друг другу.

2. «Труд, земледелие». Из пословиц видим, что татарский, русский, английский и испанский народ умеет ценить труд как единственный источник, дающий жизнь. Народы традиционно занимались земледелием и с большим уважением относились к труду человека. Работа играет наиваж-

нейшую роль в жизни человека, поэтому пословицы о труде занимают значительное место в пословичных запасах языков. В данной категории чаще встречаются частично соответствующие по смыслу пословицы.

3. «Народный опыт». В этих пословицах нашли отражение вечные общечеловеческие нравственные ценности народов. В данной категории больше отмечено частичное соответствие пословиц.

4. «Дружба». В основном люди передавали свои наблюдения об отношениях – о дружбе, учили о том, как правильно дружить, размышляли о плохой дружбе, показывали, к чему ведет пренебрежение и предательство.

5. «Любовь, счастье». Английские и испанские пословицы и поговорки очень созвучны с русскими и татарскими, в основном они о дружбе, семье, еде, труде, любви к родине, о любви и счастье, женщинах и отношениях – это является их национальной особенностью.

Применительно к исследуемому материалу полными эквивалентами в татарском, русском, английском и испанском языках можно назвать следующие пословицы: Например, тат. «Йөз ел яшә, йөз ел өйрән» – рус. «Век живи, век учись» – англ. «Live and learn» (Живи и учись) – испан. «Vive y aprende» (Живи и учись); тат. «Бәхет акчада түгел » – рус. «Не в деньгах счастье» – англ. «True happiness is not on the bargain counter» (Истинное счастье не на прилавке) – испан. «El dinero no compra la felicidad» (За деньги не купишь счастье); тат. «Сәламәт тәндә – аек акыл» – рус. «В здоровом теле – здоровый дух» – англ. «A sound mind in a sound body» (Здоровый дух в здоровом теле)– испан. «Una mente sana es un cuerpo sano» (Здоровый ум – здоровое тело); тат. «Кем эшләми, шул ашамый» – рус. «Кто не работает, тот не ест» – англ. «Who does not work does not eat» (Кто не работает, тот не ест) – испан. «Hay que trabajar para comer» (Мы должны работать, чтобы поесть); тат. «Ходай сакланганны саклармын, дигән» рус. «Береженого Бог бережет» – англ. «God helps them that help themselves» – испан. «Ayudate que yo te ayudare (Помоги себе и я помогу тебе)»; тат. «Күзләр – күңел көзгесе» – рус. «Глаза – зеркало души» – англ. «The eyes are the window of the soul» (Глаза – окно души) – испан. «Los ojos son las ventanas del alma (Глаза – окно души)».

Частичными эквивалентами в татарском, русском и испанском языках можно назвать следующие пословицы: Например, тат. «Дусның искесе, хатынның яңасы яхшы» – рус. «Старый друг лучше новых двух» – англ. «Old friends and old wine and old gold are best» (Старые друзья, старое вино и старое золото лучше всего) – испан. «Mejor viejo conocido que nuevo por conocer (Лучше старый знакомый, чем новый друг)»; тат. «Дусны табу җиңел, саклавы авыр» – рус. «Друга ищи, а найдешь, береги» – англ. «A friend is not so soon gotten as lost» (Друга потерять быстрее, чем найти) – испан. «Un amigo se gana dificilmente y se pierde facilmente» (Друга трудно найти, легко терять); тат. «Ни чәчсәң, шуны урырсың» – рус. «Что

посеешь, то и пожнешь» – англ. «A bad beginning makes a bad ending (Плохое начало ведёт к плохому концу)» – испан. «Lo que comienza mal termina mal» (То, что начинается неправильно, заканчивается плохо).

В следующих пословицах мы видим отсутствие соответствия: Например, тат. «Кызыл кар яугач» – рус. «Когда на горе рак свистнет» – англ. «When the devil is blind» (Когда черт ослепнет) – испан. «Cuando los cerdos vuelen» (Когда свиньи полетят); тат. «Чикләвек ватмасаң, төшен ашый алмассың» – рус. «Без труда не вытащишь и рыбки из пруда» – англ. «No sweet without sweat» (Не попотев, сладкого не получишь) – испан. «Sin dolor no hay recompensa» (Без боли нет награды).

Татары, русские, англичане и испанцы принадлежат разным этносам, их языки относятся к разным языковым группам и семьям. Несмотря на различия в языках и культурах у них много сходных по смыслу пословиц.

В пословицах нашли отражение общечеловеческие ценности, идеи добра и зла, древние традиции воспитания. Через пословицы осуществлялось воспитание в подрастающем поколении чувства любви к Родине, к родному языку, уважения к труду. В пословицах прославляется ум, стремление к учению, к знаниям [3: 112].

Сравнение пословиц показывает, как много общего имеют народы, что, в свою очередь, способствует их лучшему взаимопониманию и сближению. Они обогащают речь, придают ей точность и выразительность. Изучая мудрость чужого народа, мы начинаем понимать их мировоззрение, менталитет, какие ценности они охраняют, какие моральные нормы блюдут. Поэтому сравнивая пословицы и поговорки разных народов, мы не только существенно пополняем свой словарный запас, но и развиваемся, как личность.

**Литература**

1. Бархударов Л.С. Язык и перевод (Вопросы общей и частной теории перевода). – М.: Международные отношения, 1975. – 240 с.

2. Бережан С.Г. Семантическая эквивалентность лексических единиц. – Кишинев: Штиинца, 1973. – 372 с.

3. Зиннатуллина Г.Ф., Гиниятуллина Л. М. Межъязыковая эквивалентность пословиц в разноструктурных языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2017. №5 (71). Ч. 3. – с. 82–87.

4. Которова Е.Г. Проблема межъязыковой эквивалентности в лексической семантике (на основе анализа русского и немецкого языков): дис. … докт. филол. наук: 10.02.19. – Москва, 1997. – 343 с.

5. Словарь лингвистических терминов [Электронный ресурс]. URL: http://endic.ru/linguistics (дата обращения: 12.01.2019).

## СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ ИҖАТЫНДА ДИНИ МОТИВЛАР

*Гыйздәтуллина Н., Яр Чаллы педагогия көллияте, III курс студенты*

*Фән. җит. − филол. фән. канд., доц. Минһаҗева Р.Ә.*

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте үзенең үсеш юлының барлык чорларында диярлек ислам белән бәйләнешен югалтмады. Мөселманнарның

Изге китабы – Коръән һәр чор әдипләре өчен алыштыргысыз илһам чыганагы булып торды. Алай гына да түгел, Коръән сүрәләре Көнбатыш Аурупа һәм рус әдипләре тарафыннан да иркен файдаланылды.

XX йөз шагыйрьләре Г. Тукай, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, М. Гафури, Н. Думави әсәрләрен укыганда, шунысы ачык күренә, җирдәге гаделсезлек, кешеләрнең бер-берсенә карата соң чиктә миһербансызлык күрсәтүе әдипләрне Аллага үпкә, хәтта аерым очракларда шелтә сүзләре белән мөрәҗәгать итәргә этәрә. Әмма бу сүзләр күңел халәтенең аеруча төшенке минутларында әйтеләләр, чынлыкта исә катлаулы мизгелләрдә алар кулларына Коръән алып юанганнар.

Октябрь инкыйлабыннан соң хакимият дингә карашны мәҗбүри рәвештә үзгәртергә теләсә дә, шагыйрьләр иҗатында дини образлар һәм мотивлар чагылыш табуын туктатмый. Иҗаты Коръән мотивлары белән үрелгән шагыйрьләрнең берсе – Сәгыйть Сүнчәләй (1889–1941).

С. Сүнчәләй (1889–1941) – татар әдәбияты һәм мәдәниятендә тирән эз калдырган шәхес. Аның иҗаты озак еллар халыктан яшерелеп килде, бу шәхес үзе дә фаҗигале язмышка дучар ителде. Әмма Сталинның шәхес культы фаш ителгәч, 1956 елда, исеме өлешчә акланып, иҗатының бер өлеше 1961 елда «Сайланма әсәрләр» исеме белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыга.

С.Сүнчәләй иҗатында дини теманы өйрәнгәндә шуны истә тоту кирәк: аның шигырьләрен язылу вакытлары буенча өч чорга бүлеп карыйлар – 1914 елга кадәр, 1914–1919 еллар, 1919 елдан соңгы иҗат этаплары.

Ул беренче иҗат тәҗрибәләрен рус һәм Европа классикларын тәрҗемә итү белән башлый. 1911 елда аның Некрасовтан тәрҗемә ителгән «Дога» әсәре басылып чыга: И ходаем, бир халыкка якты көн!// Рәхмәтең берлә сыйла аның эшен! // Ник нигезлә халыкларның хөрлеген, // Чәч аларга тугрылыкның орлыгын // Яктылыкка эт аларны тиз генә, // Нурлатыр аларны тугры эз генә // [2: 205].

Галимнәр билгеләп үткәнчә, «бу юллардан гади бер тәрҗемә генә түгел, ә заман тавышы ишетелеп тора: яшь татар шагыйре, бөек рус шагыйренең изге теләкләрен кабатлап, яңа революцион чорны каршылый һәм халыкчан әдәби традицияләрне дәвам иттерүен белдерә». Күренгәнчә, әлеге строфаларда шагыйрь үзен гади халыклар җырчысы итеп таныта, шул ук вакытта ул Аллага чын күңеленнән инана, аңа мөрәҗәгать итә, иң зур теләкләрен (ә алар шәхси мәнфәгать белән түгел, халык интереслары белән бәйләнгән) белдерә һәм бу теләкләрнең кабул булачагына күңелендә өмет яши. Шагыйрьнең Аллага өмет итеп яшәве, кешеләр, халыклар тормышы-барышында Тәңренең роле зур дип аңлавы шуннан да аңлашыла, 1910 елда язган «Тәңремә» («С. Сүнчәләй шигырьләре»ндә (1913) 1910 елгы шигырьләр рәтендә басылган) исемле шигырендә: «Ул

бөек, ул көчле дим, юк охшашы, юк, – дим, – тиңе», – дип Аллага мәдхия җырлый. Гомеренең кайгылы, газаплы мизгелләрендә аның лирик герое Ходайга сыена, аңардан ярдәм сорый:

«Бир миңа гомрем барында бер генә шат, якты көн! // Бир минем шәфкатьле Тәңрем, тормышым бик бит читен» // [1: 123].

Дини өйрәтмәләрнең нигезен адәм баласының Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылуы, яралуы турындагы фикер тәшкил итә. С. Сүнчәләй иҗатында әлеге фикер кешене «алла бәндәсе», «тәңре бәндәсе» итеп сурәтләү рәвешен ала. Фикерне дәлилләп, С. Сүнчәләйнең Г. Тукайга багышлап язылган «Шагыйрьгә» шигыреннән өзек китерергә мөмкин:

«Әй, шагыйрь! Белсән иде, нинди синең кадрең биек: // Син Ходайның илчесе – һәм җырларың вәхи кебек // Бу туган җирдә караңгы төн хөкем сөргәндә, син // Гел юатып җырлыйсың ул тәңренең күп бәндәсен // Җыр белән яктыртасың сансыз күңелләрне, шагыйрь, // Җырлыйсың да өзгәлисең төнге коллык пәрдәсен» // [2: 218].

Моннан соңгы елларда да, Тукай образына мөрәҗәгать иткәндә, Сүнчәләй бу елларда традиционга әверелгән кояш, ай, йолдыз образлы сурәтләренә генә түгел, килеп чыгышы белән дини булган, әмма метафорик мәгънәдә татар, гомумән, көнчыгыш әдәбиятларында шактый еш кулланыла торган оҗмах образына мөрәҗәгать итә: «Йә, ничек киң ул сәгадәтле кояшның яктысы! // Нинди төс юк нурларында! Һәммәсе оҗмах төсе!» // [2: 54].

С. Сүнчәләй, остазы Г. Тукай иҗатында дини мотивларның мул булуын дәлилләп, түбәндәге фактларны китерергә була: шагыйрьнең «Мигъраҗ» шигыре өчен нигез булып Коръәннең 17 нче сүрәсе тора, «Кадер киче» шигыре 97 нче сүрә нигезендә язылган, шигырьләрендә шулай ук фәрештә, оҗмах, тәмугъ, пәйгамбәрләр, дини бәйрәм атамалары кебек ислам атрибутикасы, Ходайга мөрәҗәгатьләр дә еш урын алган.

Шул рәвешле, С. Сүнчәләй иҗатының буеннан-буена сузылган дини мотивлар шагыйрьнең күңел халәте борылышларына, илдәге дәһшәтле вакыйгаларга бәйле рәвештә үзгәреш кичерәләр.

Күзәтүләребез шуны күрсәтә: 1910–1914 елларда – иҗатының чәчәк ату дәверендә С. Сүнчәләй әсәрләрендәге дини мотивлар Аллага берсүзсез буйсыну, ислам тәгълиматларын иң изге кануннар буларак кабул итү рәвешен ала. Мөселман С. Сүнчәләйнең лирик героенда дөньядагы рәхимсезлеккә, хаксызлыкка карата эчке ризасызлык туа. Әмма аның лирик каһарманы ислам кануннары буенча яшәү тәртибеннән ваз кичми, хакыйкатьне исламнан, Коръәннән эзли.

Иҗатының соңгы этабында ул, Изге китапка, Аллаһыга тел тидермәгән рәвештә, кайбер надан муллаларны һәм алар пропагандалаган динне кискен рәвештә тәнкыйтьләүгә дә бара. Дөрес, иҗатындагы мондый үзгәрешне шул заман шаукымы, чор таләбе белән дә аңлатып булыр иде.

**Әдәбият**

1. Мусабекова Р. Сагит Сунчелей: судьба и творчество. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2001. – 292 с.

2. Сүнчәләй С. Әсәрләр һәм хатлар / төз. З.Рәмиев. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2005. – 365 б.

## ЛЕКСИКАДА ТӨРКИ ҺӘМ ФИН-УГОР ТӘЭСИР ИТЕШҮЛӘРЕ

*Гыйззәтуллина А., Удмуртия Республикасының социаль-педагогика көллияте, IV курс студенты*

*Җит. – Хәкимова В.Х.*

Күренекле татар галиме М.З. Зәкиев фин-угор телләре белән бәйләнешләрне өйрәнүнең әһәмиятле, актуаль булуына аеруча игътибар итә.

Тарихчылар Идел буе һәм Урал алдында, Кама буйларында фин-угор кабиләләренең бирегә төрки телдә сөйләшүчеләр килгәнче үк яшәгән булулары хакында язалар. Төрки телдә сөйләшүче халыклар килгәннән соң да фин-угорлар әлеге территорияләрдә яшәүләрен дәвам итәләр. Әмма төрки һәм фин-угор тәэсир итешүләре мәсьәләре кызыклы төс ала. Килгән төрки телле кабиләләрнең тәэсире фин-угор телләренә көчлерәк булып чыга. А.Х. Халиков мәсьәләнең культура һәм антропологик ягына карата болай дип яза: ”Тел, культура һәм беркадәр дәрәҗәдә антропологик кыяфәт буенча Идел буе татарлары барыннан да элек башкортларга, казакъларга, үзбәкләргә һәм башкаларга якын торалар”. Шулай булгач,татар халкының этногенезында төрки халыкларга бәйле этник катлам хәлиткеч роль уйнаган диясе килә. Ләкин шул ук вакытта галимнәр татар халкы культурасындагы кайбер элементларның һәм антропологик яктан кайбер билгеләрнең фин-угор халыклары-удмуртлар, марилар, мордваларның һәм башкаларның культура һәм антропологик үзенчәкләре белән охшаш булуын күрсәтәләр. Шуңа күрә фин-угор кабиләләренең дә татар халкының этногенезында күпмедер дәрәҗәдә катнашканлыгын исәпкә алмый мөмкин түгел. Дөрес, фин-угор кабиләләренең катнашы монда халиткеч роль уйнамаган.

Үзебезнең хезмәтебездә без дә бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертергә булдык. Күренекле тарихчы галимнәребез Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин дә үзләренең хезмәтләрендә фин-угор халыкларының төрки-татарлар өчен ят түгеллеген, безнең арабызда уртаклыклар күп булуы турында язып калдыруларын беләбез. Һәм фин-угор халыклары белән бергә уздырылган семинарларда, фәнни-практик конференцияләрдә бәхәсләшергә туры килгән очраклар да бар. Ә бәхәсне фәнни яктан дәлилләп кенә җиңәргә мөмкин. Шуңа күрә, күрше фин-угор телләренә татар теленең йогынтысын һәм киресенчә, татар теленә күрше фин-угор телләренең йогынтысын, ул телләрнең үзара тәэсир итешү юнәлешен ачыкларга тырышып карыйк.

Удмурт, мари,мордва телләрендәге төрки алынмаларның чыганак телен һәм керү юлын билгеләүдә берьяклылык белән очрашырга туры килә.Мәсьәлә шунда, кайбер галимнәр төрки сүзләрнең иң зур күпчелеген Идел буе фин-угор телләренә чуваш теле аша кергән дигән карашны алга сөрәләр.Мәсәлән, М.Р. Федотов мари телендәге төрки сүзләрне турыдан-туры чуваш теленнән кергән дигән караштa тора. Моның шулай икәнлеген берничә мисал өстендә дә күрергә була.

М.Р. Федотов, мәсәлән, мари телендәге азу, йонгылыш, йорга, йонештараш, кычкыраш, кылган, лайык, мыйык, тумана, тус, явык кебек сүзләрне чуваш теленнән дип күрсәтә. Хәзер аларны татар теле белен янәшә куеп чагыштырыйк.

| Чуваш | Мари | Татар |
|---|---|---|
| асав | азу | азу |
| йарха | йорга | йурга |
| кашкар | кычкыраш | кычкырышу |
| калкан | кылган | кылган |
| майах | мыйык | мыйык |
| нахта | нукта | нокта |
| тамана | тумана | томана |
| текел | тугал | төгәл |
| тес | тус | төс |
| симес | емыж | йимеш,җимеш |
| япах | явык | ябы |

Чагыштырудан мари теленә әлеге сүзләрнең татар теленнән кергәнлеге ачык күренә. Бу уңайдан бер сорау туа: мариларга бу сүзләр чуваш теленнән кергән булса, алар әлеге сүзләрне ни өчен яңадан татарчалаштырдылар икән? Әлбәттә, чынлыкта марилар ул сүзләрне татарчалаштырмаган, аларны татар теленнән турыдан-туры алганнар. Моны әлеге сүзләрнең фономорфологик тышчасы ук әйтеп тора. Ә менә чуваш теленә дә ул сүзләр татар теленнән кергән булып чыга. Моны да аларның чуваш телендәге фонетик тышчасы күрсәтеп тора.

М.Р. Федотов гарәп һәм фарсы сүзләрен дә мари теленә чуваш теле аша кергән дип раслау ягында тора. Чагыштырыгыз:

| Чуваш | Мари | Татар |
|---|---|---|
| тенче | туня | дөнья |
| ас-хакал | ушакыл | уш-акыл |
| еметле | умыт | өмет |
| калап | калып | калып |
| лайах | лайык | лайык |
| маскал | мыскал | мыскал |
| несел | насыл | нәсел |

| | | |
|---|---|---|
| риса | реза | риза |
| рехxет | ракат | рәхәт һ.б |

Гарәп һәм фарсы сүзләренең чуваш һәм мари телләрендә үзләштерелүендәге үзенчәлекләр үк аларның нигездә һәр ике телгә дә татар теле аша керүен күрсәтә. Бу турда күренекле галим Риф Ахметьянов үзенең "Сравнительное исследование татарского и чувашского языков" хезмәтендә язып чыга.

**Әдәбият**


1. Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. – М.: Наука, 1978. – С. 119–120.
2. Гаффарова Ф.Ф. Татарча-русча-удмуртча сөйләүлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 215 б.
3. Основы финно-угорского языкознания.– М.,1974. – Т. 1. – 409 с.
4. Халиков А.Х. Татар халкының килеп чыгышы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 250 б.


## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ГАРӘП-ФАРСЫ ҺӘМ РУС-ЕВРОПА АЛЫНМАЛАРЫ ЯЗЫЛЫШЫНДА ВАРИАНТЛЫЛЫК

(татар теленең язма корпусы мисалында)


*Гыйлметдинова А., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*


Татар теленең бүгенге тормышта, җәмгыятьтә яшәеше турында фикер йөрткәндә, орфографиягә кагылышлы мәсьәләләрне билгеләп үтмичә булмый. Хәзерге вакытта газета-журнал битләрендә, яңарак нәшер ителгән китапларда һәм хәтта фәнни әдәбиятта да сүзләрнең язылышында вариантлылык яшәп килә. Татар телендә төрле елларда басылып чыккан орфографик сүзлекләр шактый булуга карамастан, бу мәсьәлә әлегәчә хәл ителмәгән.

Тикшерену эшебезнең максаты – татар телендәге гарәп-фарсы һәм рус-европа алынмалары язылышындагы төрлелеккә күзәтү ясау вариантлылыкның барлыкка килү сәбәпләренә тукталу. Материал "Татар теленең язма корпусы"на нигезләнеп тупланды һәм шулар нигезендә статистик анализ ясалды.

Гарәп-фарсы алынмаларындагы сузыкларны язуда вариантлылык аеруча еш күзгә ташлана.

**а-я-ә:** *фидакарь // фидакяр // фидакәр, инкарь // инкяр // инкәр, ядкарь // ядкяр // ядкәр* вариантлары хәзерге татар әдәби телендә еш кулланыла.

Бу сүзләрдә کار кушымчасын *-карь* дип язу график принципка таяну нәтиҗәсе: чыганак телдә к артыннан "әлиф" барлыгын исәпкә алып язу, ләкин бу вариант орфоэпиягә тискәре йогынты ясый: *к* хәрефе артыннан килгән а хәрефен күреп, к ны кече тел [к] тартыгы итеп укып, әдәби әйтелешне бозалар. Татар теленең язма корпусында *фидакарь* 3510, *инкарь* 1688, ә *ядкарь* варианты,гомумән, теркәлмәгән.

کار кушымчасын *-кяр* белән язып белдерү к хәрефен дөрес укыту

өчен барлыкка килгән. 2017 елда басылган орфографик сүзлек нәкъ тә менә *-кяр* варианты белән язылышны норма итеп алган: *фидакяр* [5: 305]; *инкяр* [5:107]; *ядкяр* [5: 351]. Татар теленең язма корпусында *фидакяр* 121, *инкяр* 641, *ядкяр* 101 тапкыр теркәлгән. Мондый язылыш ,нигездә, дини стильдә, тарих сәхифәләрен шәрехләгән язмаларда күзәтелде.

Әлеге вариантларны *кәр* белән язу татарчалаштырылган, халыкчанлашкан язылыш варианты булып кабул ителә, чөнки *кәр* дип укыганда, тел арты к тартыгы белән нечкә сузык янәшә килә, бу үзенчәлек татар теленең фонетик төзелешенә хас. Язма корпуста *ядкәр* варианты 488, *фидакәр* 10, ә *инкәр* варианты нибары 2 тапкыр гына очрады.

**и-ы(ый):** *тәүфикъ // тәүфыйк, зәвекъ // зәвык, шәрекъ // шәрык* вариантларының барлыкка килүе гарәп - фарсы алынмаларындагы увуляр [к], [г] тартыкларының язылышына бәйле.

*Тәүфикъ // тәүфыйк* вариантларын тикшерик. Орфографик сүзлекләрдә [3: 210; 4: 320; 5: 268] әлеге сүз тәүфыйк рәвешендә теркәлгән. *Тәүфикъ* – орфографик кагыйдәне саклап язу, *тәүфыйк* варианты – кагыйдәдән чыгарма буларак карала ала, ләкин бу вариант киңрәк таралыш алган, әмма шуңа да карамастан *тәүфикъ* варианты икенче вариантка караганда язма корпуста күбрәк очрады, 515 мәртәбә, *тәүфыйк* варианты исә 500 тапкыр.

Рус-европа телләреннән алынган сүзләрне әле “русча”, әле “европача”, әле “татарча” яза торгач, орфографик вариантлар ишәя.

Беренче чиратта татар теленең гади сөйләме үзенчәлекләре телебездә зур урын алып торган рус алынмаларына йогынты ясый. Мәсәлән*, молодец // маладис, кровать // карават, самовар // самавыр, велосипед // сәпит, кастрюль // кәстрүл, газета // газет // гәҗит // гәзит, кәрҗин // кәрзин // корзина* һ. б.

*Велосипед // сәпит* вариантларын карап үтик. *Велосипед* варианты татар теленең язма корпусында 3951 тапкыр теркәлгән. *Сәпит* варианты исә – 143 мәртәбә. Әлеге вариантны язучылар стилистик максаттан кулланалар.

*Самовар//самавыр* вариантларында килгәндә исә, орфографик сүзлекләрдә әлеге сүзнең язылышында төрлелек күзәтелә: *самовар* [3: 173], *самавыр* [4: 283; 5: 237]. Язма корпуста *самовар* варианты 1359 мәртәбә очрады, *самавыр* варианты исә 3246 тапкыр.

Европа телләреннән татар теленә кергән сүзләр дә аз түгел телебездә. Кайбер европа алынмаларындагы [г] тартыгын рус орфоэпиясе үрнәгендә түгел, европача тел арты [х] һәм тамак төбе [һ] арасындагы тартык аваз белән алыштыру таралыш алды. Әлеге әйтелеш үзенчәлеге хәзерге татар орфографиясенә йогынты ясады. Нәтиҗәдә *Гарри // Һарри, Гейне // Һейне, Голливуд // Һолливуд* кебек вариантлар барлыкка килде.

Мәсәлән, *Һарри // Гарри* вариантларын карап үтсәк, *Һарри* варианты татар теленең язма корпусында 1325 тапкыр теркәлгән, ә *Гарии* варианты нибары 894 мәртәбә генә.

*Туннель // тоннель* вариантларын карап үтик. Язма корпуста *тоннель* варианты 2271 тапкыр, *туннель* варианты исә 159 мәртәбә теркәлгән. Шуны да әйтергә кирәк, әлеге берәмлекләр орфографик сүзлеләргә дә вариант булып, төрлечә теркәлгәннәр: *туннель // тоннель* [3: 205], *туннель // тоннель* [4: 343], *туннель* [5: 287].

Шулай итеп, татар теленең орфографик кагыйдәләре камил булмау һәм булганны сакланмау сәбәпле, алынмалар язылышында вариантлар яши. Бу төрлелек, билгеле, телнең сафлыгын җимерә. Шуңа күрә алынмаларны язу буенча бердәй орфографик принцип булдырып, вариантлардан мөмкин кадәр котылырга кирәк.

**Әдәбият**


1. Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәш., 2006. – 256 б.
2. Татар грамматикасы: 3 т. / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. – Тул. 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. 1.– 512 б.
3. Татар теленең орфография сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 279 б.
4. Татар теленең орфография сүзлеге. – Казан: Раннур, 2002. – 432 б.
5. Татар теленең орфография сүзлеге: Морфологик-орфографик белешмәлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 423 б.


## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ СЫЙФАТ ФИГЫЛЬ ФОРМАЛАРЫН КУЛЛАНУ


*Гыйлмуллина Д., Казан, 4 нче гимназия-интернат, IX сыйныф*

*Җит. – Садыкова Р.Г., Шакирова И.А.*


Татар телендә дә, төрек телендә дә телдә еш кулланыла торган “Сыйфат фигыль” темасы буенча җентекләп күзәтү ясарга булдык. Түбәндәге бурыч һәм максатларны алдык: төрек һәм татар телләре арасындагы охшаш һәм аермалы якларны аера белү; сыйфат фигыльнең сөйләмдә кулланылыш дәрәҗәсен билгеләү; сыйфат фигыльнең үзенчәлекләрен ачыклау.

Сыйфат фигыль – үзендә фигыль һәм сыйфат сүз төркемнәренең үзенчәлекләрен берләштергән фигыль формасы. Ул берничә заман формасына ия була [1: 255].

*Сыйфат фигыльнең заман формалары.*

*1. Хәзерге заман сыйфат фигыль (Durum bildiren sıfat-fiil)*

Хәзерге заман сыйфат фигыльнең ике формасы актив кулланылышта: гади һәм тезмә форма. Гади формасы фигыльнең тамыр яки ясалма нигезенә учы/-үче кушымчасы кушылып ясала [1: 300]. Мәсәлән: Ишек кагучының кем икәнлеген сорагач, ишек ачыла [2: 567].

Тезмә формасы: -а,-ә, -ый,-и кушымчалы фигыль һәм «торган» ярдәмлек сүзе белән ясала. Мәсәлән: <...>алгы позицияне зурайтып күрү – алданудан нык саклый торган нәрсә [2: 96]. Искәрмәләр дә бар.

Ә төрек телендә бу төр хәзерге заман сыйфат фигыльнең кушымчасы *-an/-en*. Еш кына ул үткәндә барлыкка килгән һәм нәтиҗәсе хәзер дә дәвам иткән билгене белдерә һәм бу очракларда ул татар телендәге *-ган* кушымчасы белән тәрҗемә ителеп үткән заман сыйфат фигыльгә әйләнә [4: 143]. Мисал: Yapılan teklif, yavrucağın aklını başından almıştı [5: 19]. “Ясалган тәкъдим баланы акылдан яздырды”.

2. *Үткән заман сыйфат фигыль (Geçtiş zaman sıfat-fiil)*

Татар телендә үткән заман сыйфат фигыль фигыльнең тамыр яки ясалма нигезенә -ган/-гән, -кан/-кән кушымчалары ялганып ясала. Юклыгы башка фигыльләрдәгечә -ма/-мә кушымчасы белән белдерелә [3: 300]. Мәсәлән: Аз йөкләгән күп ташыр (Мәкаль).

Төрек телендә дә үткән заман сыйфат фигыль үткәнгә караган билгене белдерә. Ләкин аның -dık/-duk, -mış/-muş кушымчалы төрләре бар [4: 146]. Мисал: Oturduğu ev kendisinindi [5: 223].“Яшәгән өе үзенеке иде”. Kadın dehşete düşmüş bir sesle haykırdı [5: 89]. “Хатын куркыныч(кайгыга төшкән) тавыш белән кычкырды”.

3. *Киләчәк заман сыйфат фигыль (Gelecek zaman sıfat-fiil)*

Татар телендә киләчәк заман сыйфат фигыльнең өч төре бар. Беренчесе ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк кушымчалары белән ясала [3: 301]. Мисал: Күңелләрдән диңгез буена китәчәк кошлар кебек [2: 49].

Икенчесе -р/-ыр/-ер, -ар/-әр кушымчалары белән ясала [3: 301]. Мисал: Сөртенмәс тояк булмас, ялгышмас тел булмас (Мәкаль).

Өченчесе -асы/-әсе, -ыйсы/-исә кушымчалары белән ясала [3: 301]. Мисал: Гафият хатын-кызлар китәсе якка юнәлде [2: 293].

Ә төрек телендә киләчәк заман сыйфат фигыльнең күрсәткече -acak/-ecek генә [4: 150]. Мәсәлән: Sıra evde verilecek zıyafete gelmişti [5: 15].“Чират өйдә биреләчәк банкетка килде”.

4. *Хәзерге-киләчәк заман сыйфат фигыль (Geniş zaman sıfat-fiil)*

Төрек телендә, татар теленнән аермалы буларак, хәзерге-киләчәк заман бар. Бу төр сыйфат фигыльнең күрсәткече: -r; юклыкта: -maz. Бу сыйфат фигыльләр тезмә исемнәр ясауда катнашалар [4: 151]: güler yüz “көләч йөз”,atar damar “артерия”, bilgisayar “компьютер”, kaynar su “кайнар су”.

Нәтиҗә ясап шуны әйтә алам: сыйфат фигыльләр татар телендә дә, төрек телендә дә еш кулланылалар, алар әдәби әсәрләрдә генә түгел, халык авыз иҗатында да очрыйлар. Морфологик, синтаксик, грамматик яктан ике телдә дә сыйфат фигыльләр охшаш, ләкин аермаларын да табып була.

**Әдәбият**

1. Зәкиев М.З. Татар грамматикасы.– Казан: Фикер, 2002. – Т. 2. – 520 б.
2. Онытылмас еллар. – Казан: Мәгариф, 1993. – 285 б.

3. Сафиуллина Ф. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 489 б.
4. Rəximova A. Tərek Grammatikası (Türk Dil bilgisi). – Казан: Юкона, 2002. – 344 б.
5. Suavi Cüneyd. Hayatın İçinden. – Ankara: Zafer Yayınları, 2006. – 280 b.

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
(тартык авазлар мисалында)

*Гыймадиева Г., КФУ, V курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Саттарова М.Р.*

Тел белемендә фонетика предметы артык киң аңлатыла. Фонетика – тел белеменең бер бүлеге, ул авазларны, аларның кушылмаларын, аваз үзгәрешләрен өйрәнә. Авазлар әйтелеше буенча ике төркемгә бүленә: сузык һәм тартык авазларга. Әлеге эшебездә татар һәм төрек теленең тартык– ünsüz ses авазларын карап китәчәкбез.

Татар телендә барлыгы 28 тартык аваз бар: [б], [п], [м], [w], [ф], [д], [т], [н], [з], [с], [ж], [җ], [ч], [ш], [л], [р], [й], [к], [къ], [г], [гъ], [х], [ң], [һ], ['] (һәмзә), рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланыла торганнар [в], [ц], [щ]. Төрек телендә 21 тартык аваз (ünsüz ses) бар. Алар [b], [c], [d], [g], [j], [z], [v], [m], [n], [l], [r], [y], [p], [k], [ç], [f], [h], [s], [ş], [t] һәм бер тартык аваз [ğ] (yumuşak g). Ике телдә булган үзенчәлекләрне карап китергә була.

Яңгырау [б], [д] һәм саңгырау [п], [т] тартыклар төрек телендәге яңгырау [b], [d] һәм саңгырау [p], [t] авазлары бер-берсеннән берникадәр яклары белән генә аерыла. Ирен-ирен [б]-[b] һәм тел алды [д]-[d] тартыклары йомык, шартлаулы, шаулы, яңгырау авыз авазлары. Төрек телендә бу авазлар йомыграк әйтелә, ягъни тавыш ярылгылары киеренкелекне әз кичерә: bir – бер, dost – дус.

Ирен-ирен [п]-[p] һәм [т]-[t] тартыклары йомык, шартлаулы, шаулы, саңгырау авыз авазлары. Төрек телендәге бу тартыклар ясалу ягы белән аерыла: җиңелчә сулыш алу белән әйтеләләр: posta – почта. Татар телендә п авазы нигездә сүз азагында кулланыла, ә төрек телендә төрле урында булырга мөмкин.

[к]-[k] һәм [г]-[g] тартыклары тел арты, йомык, шаулы, саңгырау, авыз авазлары. Ике телдә дә бу авазлар калын һәм нечкә була. Калын [к]-[k] һәм [г]-[g] авазлары төрек телендә әйтелеше буенча җиңелчә сулыш белән әйтеләләр. Татар һәм төрек телендә алар арткы рәт сузыклары белән кулланыла. Ә нечкә [к]-[k] һәм [г]-[g] авазлары татар телендә нечкә сузыклар янында киләләр: килен, икәү, ә төрек телендә сузык авазлар янында килгәндә җиңелчә сулыш белән әйтеләләр: *kir-пычрак, kül-көл, gül-күл.*

Яңгырау [в]- [v] һәм саңгырау [ф]-[f] ирен-теш, өрелмәле, шаулы, авыз авазлары. [в]- [v] авазлары татар теленә алынма сүзләрдә генә кулланыла һәм җанлы сөйләмдә [w] авазы белән алыштырыла, ә төрек телендә ике сузык арасында һәм икенче сузык иренләшкән булса ирен-ирен, [w] авазы итеп әйтелә: tavuk. Төрек телендә [v] авазы

саңгыраулашмый: av (ау), sav (ку). [ф]-[f] авазлары төрек телендәге сүзләрдә, сүз башында очрамыйлар, авыз ияртемнәреннән кала: fırlamak (сикереп чыгарга), fakir (ярлы). Ә татар телендә төрле урында килергә мөмкин: Фәридә, ефәк, саф.

Яңгырау [з]-[z], [ш]-[ş] һәм саңгырау [с]-[s], [ж]-[j] авазлары тел алды, өрелмәле, авыз авазлары. Икесендә дә бу авазлар калын һәм нечкә төрләре бар: зирәк, шакмак, шәүлә, zaman, zil, dış diş; саулык, sokak, söz-сүз; гөҗлә, bagaj, jüri. [ш]-[ş] авазлары сүз башында сирәк кулланыла һәм әйтелеш ягыннан төгәл әйтеләләр. [ж]-[j] авазлары татар телендә аваз иярнемнәре нигезендә ясалган сүзләрдә очрыйлар: выжылдый, ә төрек телендә бу аваз көнбатыш-европадан кергән сүзләрдә кулланыла: jandarma, jilet.

Саңгырау [ч]-[c] һәм яңгырау [ж]-[ç] авазлары шаулы, татар телендә өрелмәле, ә төрек телендә аффрикат тартык булып тора. Икеседә нечкә һәм калын сузыклар янында киләләр: чәчәк-çiçek, aç; can, ceva. Төрек телендәге [ç] авазы әйткәндә “д” һәм “ж” авазларын бергә кушып әйтергә кирәк: sıcak.

Ирен-ирен [м]-[m] һәм тел алды [н]-[n] ике телдә дә йомык, сонор, борын авазлары. Аерма сизелми, әмма [н]-[n] тартыгы ике телдә дә сүз башында сирәк кулланыла, нечкә һәм калын төрләре бар: нокта, nisan.

Тел алды тартыгы [л]-[l] ике телдә дә ярымйомык, ян-як сонат, авыз авазы. Татар һәм төрек телендә дә үз сүзләрендә сүз башында сирәк кулланыла, күбрәк алынма сүзләрдә очрый: бала, кызыл, ләкин, altın, el, lâle. лапылдый, лыгырдый.

Тел алды [р], [r] тартыгы кылтыраулы сонант. Ике телдә дә әйтелеш, көчсезрәк әйтелә һәм сүз ахырында саңгыраулаша: bir-бер, getir-китер. Шулай ук, охшаш яклары булып, сузык белән сонор арасында килсә һәм бу аваз төшеп кала: берлән-белән. Төрек телендә сузык алдыннан килсә шулай ук төшеп кала: arslan-a’slan, bir şey- bişe, bir kitap-bikitap.

Тел уртасы тартыклары [й], [y] авазлары ике телдә дә өрелмәле, шаулы, яңгырау, авыз авазлары. Алар татар һәм төрек телендә дә төрле урында килә алалар: ay, yel, [йул], ай. Ике телдә дә бу авазлар сузыклар белән кушыла һәм сүз башында тотрыклы әйтелә. Төрек телендә сүзләр тиз әйтелгән вакытта [y] авазы ике [i] сузыгы арасында редукция кичерә: iyi- ии.

[һ]-[h] авазлары өрелмәле, шаулы, саңгырау, авыз авазы. Бу аваз әйткәндә һава өрелеп кенә чыга. Татар сүзләрендә бик сирәк очрый: әһә. Күбрәк гарәп-фарсы сүзләрендә кулланыла: һәйкәл, шәһәр. Төрек һәм татар телендә бу авазлар уртада килсә, әйткән вакытта төшеп калырга яки җиңелчә сулыш белән әйтелергә мөмкин: шәһәр, daha.

Кече тел тартыгы [х] өрелмәле, шаулы, саңгырау. авыз авазы. Бу аваз гарәп-фарсы, рус алынмаларда очрый. Төрек телендә бу аваз булмаса да, [h] авазы белән якын, чөнки [h] авазы алынма сүзләрдә сүз башында каты итеп әйтелә, охшаш ягы дип карарга була: хатын, хуҗа, hafta-атна, hasta-авыру.

[ң] тартыгы сонор, яңгырау, борын авазы. Төрек телендә бу аваз юк, әмма кайбер сүзләрне әйткәндә, әйтелеш ягыннан охшашлыгы сизелә: renk.

['] (һәмзә) – йомык, шартлаулы, шаулы, саңгырау тартык. Бу аваз татар сүзләрендә аз очрый һәм сүз башында килми: [мә'мәйәтәм], [тә'сир].

[ğ] (yumuşak g) тартыгы аерым тавышка ия түгел. Алгы рәт сузыклары белән янәшә килгәндә [у] авазы кебек әйтелә: değnek-таяк, öğren-өйрән.

Бу авазлардан тыш, татар телендә рус теленнән кергән [ц] [в] [щ] тартыклары рус алынмаларында гына кулланылалар: циркуль, вагон, щи.

Түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга була: ике телдә дә яңгырау, саңгырау тартыклар бар. Ясалышлары буенча, ясалу ысулы да тулысынча туры килә. Билгеле тартыкларның сүз, иҗек башында яки ахырында килүләре белән аерылалар.

**Әдәбият**

1. Щека Ю.В. Практическая грамматика турецкого языка. – М.: Запад, 2007. – 27 с.
2. Сафиуллина Ф.С. Закиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2006. – 197 б.

## ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВАНЫҢ «ҺИҖРӘТ» РОМАНЫНДА ҺИҖРӘТ СҮЗЕНЕҢ ЛЕКСИК СОСТАВЫ

*Гыйрфанова Л., КФУ, I курс магистранты*
*Җит. – филол. фән. канд., доц. Хәбутдинова М.М.*

Фәүзия Бәйрәмованың "Һиҗрәт" романы узган ел дөнья күрде. Әлеге әсәр өч китаптан тора – "Һиҗрәт кәрваны", "Һиҗрәт авылы", "Татарның мәңгелек һиҗрәте". Тарихи роман узган гасыр башында дин хакына туган җирләрен калдырып, Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр булган татарлар язмышын сурәтли. Омск өлкәсенең Тара төбәгендә яшәгән милләттәшләребезнең Төркиягә күченүләре, юлда очраган авырлыклары, Төркиядәге яшәүләре эзлекле рәвештә бирелгән.

Фәнни эшебезнең максаты: "Һиҗрәт" романына нигезләнеп һиҗрәт сүзенең лексик мәгънәсен тикшерү. Максатыбызга ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды: татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән "һиҗрәт" сүзенең мәгънәсен ачыклау; Фәүзия Бәйрәмованың "Һиҗрәт" романы белән танышу; Һиҗрәт сүзенең кулланышының лексик мәгънәсен ачыклау.

Фәүзия Бәйрәмованың "Һиҗрәт" романында һиҗрәт сүзе еш кабатлана. Вакыйгаларның милләтебезгә тискәре йогынтысын, әлеге иҗтимагый процессның халык язмышында уйнаган ролен күрсәтү өчен, ул әсәрнең исеменә чыгарылып, көчле позициядә тора.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать итсәк, һиҗрәт – мөселманнарда ел исәбе башы (Мөхәммәтнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп киткән көне: 622 нче елның 16 нчы июле) [2: 822]. Ягъни, яшәгән урыныңны ташлап башка җиргә күчү. Шуны әйтергә кирәк, күченү бер ил территориясендә барган.

Һиҗрәт итү (кылу) – күчеп китү, чит илгә китү; эмиграция [2: 822]. Фәүзия Бәйрәмованың әсәрендә һиҗрәт сүзе “чит илгә күчеп китү, туган җиреңне калдыру, туган җирне ташлап китү” мәгънәсендә кулланыла. Әсәр башында ук әлеге мәгънә ассызыклана: *Кая барса да, күңелендә, телендә бер сүз – “һиҗрәт”, илдән китү, дин-ислам хакына туган яклар белән мәңгегә бәхилләшү.*

*“Һиҗрәт”, “һиҗрәт”, дисәләр дә, дин-ислам хакына бөтен нәселең, хәттә ки авылың белән кубарылып, туып-үскән җирләреңне мәңгегә калдырып, бер белмәгән якларга чыгып китәргә күпләр әзер түгел иде.*

*Һиҗрәт бит ул, иманны, динне саклап калу өчен, Аллаһ ризалыгы өчен дингә ирек булган урынга күчеп китү...*

Әсәрдә “һиҗрәт сәфәре” сүзтезмәсен куллана. Сәфәр – ерак юл, сәяхәт [2: 711]. Автор сәфәрләренең озын, ерак араны үтәргә кирәк булуына төшендерә. Икенче яктан карасак, чит илләрдә, ерак җирләрдә булып дөнья гизеп, җәмгыять гадәти яшәешкә кайткач, кире туган җирләренә кайту мөмкинлеген дә инкяр итми: *Әмма иң куркынычы, Юанбаш Мөхәммәди кулга алынгач, һиҗрәт сәфәре дә өзелергә мөмкин иде…*

*– Шулай итеп, һиҗрәт сәфәрен өзәргә булдыңмы, энем? – диде ул, Исмайның каршысына ук килеп.*

Фәүзия Бәйрәмова әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр һиҗрәт кылуның милләт язмышында зур әһәмияткә ия булуына басым ясый. Рәсәйдә иҗтимагый сәбәпләр аркасында барлыкка килгән күченүнең Ислам дине файдасына, иман хакына икәнен аңлаган милләтчеләр язмышы аша тасвирлый. Геройларның икелүләреннән, бер фикергә килә алмаган вакыйгаларда әлеге әһәмият чагыла: *Әмма һиҗрәт – икеле-микеле уйный торган нәрсә түгел, бу – бик җитди эш, бары тик Аллаһ ризалыгы өчен, дин-ислам хакына башкарыла торган гамәл.*

“Һиҗрәт” сүзе дин-ислам хакына дигән сүзләр белән янәшә тора. Әлеге сүзләр һиҗрәт сүзенә төгәллек кертәләр, аның нинди максатны күз алдында тотып башкарылганын ачыклый. *Һиҗрәт турында сүз, дин-ислам хакына Госманлы иленә – Төркиягә күчеп китү мәсьәләсе Идел-Уралда гына түгел, Себердә дә күтәрелеп-күтәрелеп ала, илдәге хәлләргә карап, халыкның да кәефе үзгәреп тора.*

*Исән калу өчен бары бер генә юл бар, ул – бу Аллаһ каргаган илдән китү, дин-ислам хакына һиҗрәт кылу иде...* Әсәрдә дин-ислам хакына һиҗрәт кылуларының сәбәбе дә әйтелә: *Халыкның ашыга-ашыга туган җирләрен ташлап китәргә җыенуының төп сәбәбе булып чукындыру куркынычы тора иде.*

Һиҗрәт кылучыларның савабы, эшләгән изге эшләре үзләренең тормышларына, гаиләләренә генә кайтып калмый, милләт язмышы,

киләчәк буынга барып тоташа. Әлеге фикерне автор әсәрдәге Зәйнәп абыстай персонажы аша җиткерә:

*– Мин китәм инде... Аллаһ янына китәм... Үз өемә кайтам... Мине юлда ташлап калдырмагыз... Мөселманча күмегез... Соңгы әманәтем шул... Үлемтек-кәфенлекләрем үзем белән... Мин аларны юлга алып чыккан идем... Һиҗрәтем өзелә инде... Шул үкенеч...*

*– Һиҗрәтең өзелмәс, туганым, борчылма... Юлга һиҗрәт нияте белән чыккач, савабы да һиҗрәт өчен булыр, инша Аллаһ!*

Фәүзия Бәйрәмованың "Һиҗрәт" романы милләтнең язмышы белән бәйләнгән. Һиҗрәт мәгънәсенә автор халкыбызның дин-милләт өчен туган җирләрен ташлап китүләрен, динне саклап калырга теләүләрен, милләт өчен савап эшләүләрен тасвирлый. Туган җирләренә кире әйләнеп кайту мөмкинлекләрен дә инкяр итми.

**Әдәбият**


1. Интернет-ресурс: Казан утлары журналы. – URL: http://kazanutlary.ru/news/roman/hijret-1-11-ozek (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.01.2019).
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.


## ИДИОМЫ И ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ В АНГЛИЙСКОМ, РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ


*Давтян К., Спасский р-н, Болгарская СОШ №1, XI класс*

*Рук. – Курзаева М.Е., Хабибуллина Р.Г.*


Речь является основным способом взаимодействия людей. Сделать речь ярче, передать смысл темы беседы, передать настроение, отношение к тем или иным обстоятельствам помогают уместные в конкретной ситуации цитаты, пословицы, поговорки и фразеологизмы. Использование образных выражений при изучении языка дает возможность пополнить словарный запас, овладеть навыками оперирования идиоматическими конструкциями. Чтобы правильно изъясняться и трактовать слова собеседника нужно знать фразеологизмы.

Фразеологизмом называют особый речевой оборот, неизменное словосочетание, которое не воспринимается в буквальном смысле и не всегда имеет дословный перевод. Виду того, что некоторые фразеологизмы невозможно перевести дословно, часто возникают трудности перевода и понимания.

Идиома – это своеобразное выражение, устойчивый оборот речи, значение которого не определяется значением входящих в его состав слов; неразложимое словосочетание. Как правило, идиома не переводится дословно с одного языка на другой, обычно при переводе ищется смысловой эквивалент.

На национальную особенность обратили внимание исследователи фразеологии. Поэтому фразеологизмы и определили термином "идиома",

что в переводе с греческого означает “своеобразная”. В английском языке они называются “idioms”, а в татарском языке «фразеологик берәмлекләр».

В русском языке имеется большое количество русских устойчивых выражений, которым нет аналогов в английском языке: «*повесить нос, без царя в голове, душа в пятки ушла, губа не дура, на лбу написано, рыльце в пуху*» и т. д. Поскольку при дословном переводе теряется смысл и стилистическая окраска таких фразеологизмов, и часто возникают трудности понимания и перевода. Многие из них пришли из басен, произведений русских писателей, остальные были созданы в народе. В национальном татарском языке очень много прекрасных и интересных устойчивых сочетаний. *Держать язык за зубами – телен бәйдә тоту, телеңне тыю-hold one's tongue* не говорить (ничего) лишнего, помалкивать*; кошки скребут – йөрәкне тырнап тора – be sick at heart* употребляют, когда хочется показать, что что-то очень сильно волнует, потрясло, пронзило, "проникло в душу"; *вертеться на кончике языка – тел очында тору – the word is one the tip of my tongue* очень хочется сказать, спросить.

Сравнение идиом разных народов показывает, как много общего имеют эти народы, что, в свою очередь, способствует их лучшему взаимопониманию и сближению. В английском, русском и татарском языках встречаются одинаковые идиомы. Многие устойчивые обороты легко переводятся на русский язык, другие нуждаются в объяснении. Также в английском языке встречаются идиомы, которые при переводе на русский и татарский языки звучат по-другому, но их смысл остается тем же. Но точно кто у кого позаимствовал эти выражения не понятно.

Вот похожие идиомы: "*parents hand everything on a silver platter*", что дословно переводится, как "*родители все подают на серебряном блюде"*. Наше выражение *«на блюдечке с голубой каемкой»* практически соответствует английскому. А на татарском языке есть выражение только немного подходящее по смыслу *“әзергә хәзер* ”. Сложно, но все-таки можно догадаться, какой смысл выражения "*is in the soup"* (досл. "в супе"). Близким по значению будет русское "*сесть в лужу"* или татарское “*кәкре каенга терәлү*”, то есть попасть в беду или неловкое положение. «*Busy as a bee*» дословно переводится, как *«занята как пчела».* В русском языке есть похожее выражение «*занята, как белка в колесе*». А на татарском языке это выражение звучит совсем по-другому: “*мәшәкать белән мәшгуль булу”*. В этом случае сохраняется только схожие значения.

Английская идиоматика, очень разнообразная, достаточно сложна для изучающих английский язык. Из известных науке языков нет таких, в которых бы совсем не было идиом. Но английский язык обошел всех. В процессе исследования возникла проблема с переводом идиом на татарский язык. В виду того что татарская культура очень своеобразна,

нахождение идиом с одинаковыми значениями в татарском, русском и английском языках оказалось довольно сложным. Несмотря на большой идиоматический запас татарского языка, не всегда можно найти эквивалентную идиому на русском и английском языках. А идиом, схожих и по строению, и по структуре, и по значению совсем мало. При сравнении фразеологизмов в английском, татарском и русском языках были обнаружены сходные по структуре фразеологизмы. При анализе их было обнаружено сходство в строении, образности и стилистической окраске*:* *играть с огнем – to play with fire – ут белән уйнау*; *нет дыма без огня – there is no smoke without fire – утсыз төтен чыкмый; жить как кошка с собакой – a cat and dog life – эт белән мәче сыман.* Часть этих идиом являются уже интернациональными, и на исконность их претендуют разные языки, т. е. в каждом языке они считаются своими. Следующие выражения весьма сходны в русском, татарском и английском языках: *Как натянутая струна – straight as a tight string – кыл тарткан кебек; искать иголку в стоге сена – look for a needle in a bottom of hay – эскерттән энә эзләү; оборотная сторона медали – the other side of the coin – медальнең икенче ягы.*

Из данной работы следует, что изучение идиом является необходимым звеном в процессе изучения языка, так как: усиливает понимание языка; помогает сделать речь более образной, эмоциональной; помогает понять национальную культуру страны изучаемого языка.

**Литература**

1. Гарифуллин С.Ф. Татарча-русча-инглизчә сүзлек. – Казан: Хәтер, 2010. – 296 б.
2. Гольцова Н.Г. Русский язык. 10-11 классы. – Казань, 2011 – 448с. .
3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002 – 406 б.

## УРТА МӘКТӘПНЕҢ 5 НЧЕ СЫЙНЫФЫНДА МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Дәүләтшина Э., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Йосыпова Н.М.*

Әдәбиятка 1960 нчы елларда килгән шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов чорның үсеш-үзгәрешләренә, яңа тенденцияләренә ияреп, яңа үрләр яулап, матур әсәрләрен иҗат итә. Авторның күпчелек шигырьләре җәмгыятькә бәя бирү, милләт язмышы темаларына багышлана. Башка авторлар белән беррәттән, Мөдәррис Әгъләмов та гади кешенең рухи дөньясын, җәмгыятьтәге, гаиләдәге мөнәсәбәтләрен, үткәне һәм киләчәге турында уйлануларын, туган халкына, якыннарына булган хисләрен, телебезне саклап калу мәсьәләләрен яктырткан әсәрләр иҗат итә, иҗади әсәрләрдә татар милләтенең бөек шәхесләре образларын тудыра, табигать, экология темалары сурәтләнә.

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен Федераль дәүләт белем бирү

стандартларына нигезләнеп, Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина авторлыгында 2017 нче елда чыккан 5 нче сыйныф өчен татар әдәбияты дәреслегендә Мөдәррис Әгъләмов иҗатын өйрәнү дә урын алган [1: 115]. Укучылар бу әдип иҗаты белән "Татар язучылары һәм шагыйрьләре туган ил, туган як турында" дигән бүлектә таныша. Укучыларга шагыйрьнең тормыш юлы турында кыска гына күләмдә материал бирелә, уку һәм анализлау өчен "Матурлык минем белән" шигыре тәкъдим ителә. Шигырь тексты белән танышканнан соң, укучылардан дәреслектә куелган сорауларга җавап табу сорала. Әлеге сораулар арасында матурлык төшенчәсенә бәйлеләре дә, шигырь структурасына һәм эчтәлегенә бәйлеләре дә бар. Бу сораулар балаларга әсәрне аңларга, шигырьнең мәгънәви структурасы буенча нәтиҗәләр ясарга һәм эчтәлекне истә калдырырга ярдәм итә. "Матурлык минем белән" шигыре балаларга кабул итү өчен җиңел һәм матур эчтәлекле. Укучылар шигырьне укыгач, үзләрендә рухи һәм тышкы матурлык булдыруга омтылырга, күңел матурлыгы һәм тышкы матурлыкны аерып карый белергә тиеш.

Укучыларга М. Әгъләмов турында С. Хәкимнең истәлекләреннән өзек тә китерелә. Соңыннан, укучыларның үзләренә туган як, табигать турында шигырь язып карарга тәкъдим ителә. Бу эш төрен проект методы форматында яки шигырь конкурсы кебек оештырырга да мөмкин.

Эш төре буларак, укучыларга шигырь эчтәлегенә бәйле синквейн төзү тәкъдим итәргә дә була. Синквейн – кыска, рифмалашмаган 5 юллык шигырь [3: 43]. Әлеге эшне башкару өчен укучыларга тема буларак матурлык, гүзәллек сүзләрен бирергә мөмкин. Теманы язганнан соң, укучылар теманы ачу өчен сыйфат сүз төркеменә караган ике сүз язарга, ягъни бирелгән сүзнең билгесен ачыкларга тиеш. Әйтик, матурлык эчке һәм тышкы һ. б. Алдагы юлда укучылар бирелгән сүзгә бәйле өч фигыль китерәләр. Мисал өчен, матурлык темасына бәйле саклау, соклану, югалтмау һ. б. кебек фигыльләрне язарга мөмкин. Дүртенче юлда укучыдан дүрт сүздән торган бер җөмлә язу сорала. Мәсәлән, мин матурлыкны сакларга тырышам һ. б. Соңгы юлда нәтиҗә буларак бер сүз языла. Әйтик, саклау, үзгәрү һ. б. Моннан тыш, укучыларга кластер методын да тәкъдим итәргә була. Шул ук матурлык, эчке һәм тышкы матурлык сүзләре белән балалар кластер төзи. Синквейн, кластер кебек эш төрләре укучыларда кызыксыну уята, үз фикерләрен традицион булмаган формада белдерергә мөмкинлек ача.

Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнүче укучылар өчен Ә.Р. Мотыйгуллина авторлыгында төзелгән 5 нче сыйныф дәреслегенең 2 нче кисәгендә дә Мөдәррис Әгъләмов иҗаты өйрәнелә [2: 84]. Укучылар шагыйрь иҗаты белән "Кеше – табигать баласы" дигән бүлектә таныша. Әлеге сыйныфта да укучыларга шагыйрьнең тормыш юлы турында кыска гына мәгълүмат бирелә һәм

“Матурлык минем белән” шигыре тәкъдим ителә. Татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылардан аермалы буларак, бу сыйныф укучыларына шигырьгә бәйле башка төрлерәк сораулар китерелә. Берничә сорау авторның тормыш юлына бәйле, ягъни укучыларга шагыйрьнең биографиясен истә калдыру максатыннан куелган. Алга таба сораулар һәр строфага бәйле төзелгән, бу сораулар шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итә. Бу сыйныф укучыларына тәрҗемә итү буенча да биремнәр куела.

Алга таба укучыларга уку һәм анализлау өчен шагыйрьнең “Җир-ана, кояш һәм башкалар” балладасыннан өзек бирелә. Татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучыларга әлеге баллада тәкъдим ителми. Укучылар баллададан өзек белән һәм сүзлектә бирелгән аңлашылмаган сүзләрнең тәрҗемәсе белән таныша. Баллада соңында эчтәлеккә бәйле сораулар жанр үзенчәлекләрен искә төшерүгә, ягъни теоретик материалны ныгытуга, геройлар системасын анализлауга юнәлтелә. Дәреслек авторлары укучыларга кеше һәм табигать арасындагы бәйләнеш буенча да сораулар әзерләгән. Укучылар табигать, Җир-ана кешеләргә һәрвакыт шәфкатьлеме дигән сорауга үз фикерләрен әйтергә, дәлилләргә тиеш.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, М. Әгъләмов иҗаты мәктәп программасында лаеклы урын ала, аның шигырьләре зур тәрбияви көчкә ия, җитди дөньяви проблемаларны чишү ихтыяҗын күз алдына китереп бастыра.

М. Әгъләмов иҗатын өйрәнү дәресләрендә эш төрләреннән дә иркен файдаланырга мөмкин. Алар арасында проект методы, кластер, синквейн төзү методлары уңышлы булыр иде. Укучыларга проект темалары тәкъдим иткәндә табигать белән кешеләр арасындагы бәйләнеш, экологик проблемаларга бәйле темаларны бирергә мөмкин.

**Әдәбият**

1. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: Мәгариф–Вакыт нәшр., 2017. – 143 б.

2. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. 2 кисәктә. 2 нче кис. / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Л.К. Хисмәтова; [рәссамы Диләрә Нәүрүзова]. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2017. – 111 б.

3. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек / төз.: А.Х. Мөхәммәтҗанова, Р.Б. Камаева, – Казан: ТРМҮИ, 2015 – 68 б.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЧАРАЛАР

*Долгова Л., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Бүгенге көндә сыйныфтан тыш эшләр, дәресләр кебек үк, укучыларның татар теле буенча белемнәрен киңәйтү, туган телгә мәхәббәт,

туган тел аша халыкны, аның тарихын, культурасын, хезмәтен олылау хисләре тәрбияләү юнәлешен күз алдында тотып оештырыла. Татар теленнән сыйныфтан тыш эшләрнең төп максаты – укучыларда туган телне тирәнрәк өйрәнүгә, аның байлыкларыннан мөмкин кадәр тулырак файдаланырга омтылыш тудыру.

Телебезгә мәхәббәт тәрбияләү процессында, халкыбызның гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре, тормыш-көнкүреше, дини ышанулар белән таныштыру сыйныфтан тыш эшләрдә зур әһәмияткә ия. Милли шәхес төшенчәсе үзенчәлекле төп кыйммәтләр системасы белән бәйләнгән, әлеге кыйммәтләр социаль һәм мәдәният организмы булган шәхеснең эш-гамәлләре программасын тәшкил итә [3: 11]. Милли шәхес тәрбияләнгән даирәдә, тарихи һәм мәдәни үзенчәлекләр мөһим, чөнки һәр халык үзенең яшәешен туган телендә чагылдыра, мәдәниятендә калыплашкан күзаллаулар аша дөньяны бәяли.

Керәшен татарларында табигать күренешләренә, ел фасылларына бәйле бәйрәмнәр, йолалар күп. Аларны бөтен авыл халкы белән үткәрә торган булганнар. Күп бәйрәмнәрнең үзенә генә хас җырлары, биюләры, такмаклары бар. Аларда күбрәк борынгыдан килгән халык йолалары өстенлек алган. Кызганычка каршы, вакытлар узу белән күп йолалар онытылып бара. Бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, сынамышлар, юраулар көн-күрешебездә югалмасын өчен, яшь буыны милли кыйммәтләр белән дәрестән тыш чараларда таныштыру бүгенге тормышыбызда урынлы.

Май чабу бик борынгы заманнардан – мәҗүсилек чорыннан ук сакланып килгән бәйрәм. Икенче төрле аны “Кышны озату” дип тә атыйлар. Май чабу атнасы ел саен Олы көнгә бәйле рәвештә төрлечә килә. Ул Пасха алдыннан була торган 7 атналык уразага бер атна калгач башлана [4: 21].

Борынгы гадәт буенча Май чабу бәйрәме төрле йолалар белән үрелеп барган. Җигүле атларны сөлгеләр белән бизәп, гармун уйнап, авыл урамнары буенча җырлап йөрүләр, мавыктыргыч уеннар, урамда пешерелгән кайнар коймак ашау, җимешле чәйләр эчү, чана шуулар, кызлар утырмасы оештырганнар. Май чабуның махсус җырлары бар. Бәйрәмнең соңгы ноктасы – кар өстендә саламнан эшләнгән, керәшен киеменә киендерелгән курчакны яндыру һәм җырлар җырлап, өйләргә таралу.

Шуны әйтергә кирәк, бу һич тә дини бәйрәм түгел. Ә игенчеләрнең, кыр эшләрендә катнашучы халыкның язгы эшкә күчә башлау чорын билгеләп үтү, алда зур хезмәт икәнлеген раслап торучы бәйрәм. Май чабу үткәннән соң кызу эшкә әзерлек башлана. Әлеге бәйрәмдә татар халкына хас төп сыйфат – эш сөючәнлек ачыклана. Шулай ук үз эшенә битараф булмаулыгы, табигать биргән һәр көннән уңыш алып калырга тырышканлыгы күренә. Сынамышларга игътибар итсәк тә, алар да хезмәт

һәм уңыш белән бәйле: “Май чабуда кар яуса, карабодай уңа”, “Май чабу алдыннан килгән якшәмбедә көн бозылса, җәй көне гөмбә күп була”.

Май чабу бәйрәме атнасының һәр көне билгеле бер тәртиптә бара. Дүшәмбе – бәйрәм каршылау көне, сишәмбе – уеннар көне, чәршәмбе – “тәмле тамаклар көне”, ягъни кияүләр каенанада кунакта булалар. Кече атна (пәнҗешәмбе) – бәйрәмнең иң кызган көне, татар атнасы (җомга) көнне каенаналар кияүләренә кунакка баралар, атна кич (шимбә) – каен сеңелләр утырмага килә торган көн. Ә атна көнне (якшәмбе) бәйрәм белән саубуллашалар. Халык әлеге системаны юкка гына уйлап тапмаган. Май чабу бәйрәменнән соң, кунакка йөрешүләр бик сирәк, яисә бөтенләй дә булмаган. Чөнки кызу эш башланган, халык уразага кергән. Туганнар бер-берсендә кунакта булырга өлгерсен, килен кешеләр әти-әниләре белән күрешеп, ә әти-әниләр кызларының ничек яшәвен карап китү максатыннан төзелгән система. Әлеге бәйрәм керәшен татарларының тагын бер сыйфатын – кунакчыллыгын характерлый.

Май чабу бәйрәменең соңгы көне – Пручти көн дип билгелә. Пручти көнне (Прощёное воскресенье) бөтен кеше бер-береннән кичерү сораган. Кичерүне ниндидер начарлык, явызлык эшләгән кеше генә түгел, ә һәр кеше сорый. Бер-береңә итагатьлек, хөрмәт йөзеннән эшләнә. Башкаларга карата битараф булмау, алга таба да бергә дус-тату яшәүне күз алдында тота. Керәшен татарларының киң күңеллекләрен күрсәтә, сине рәнҗеткән кешене дә гафу итә алу сыйфатын ассызыклый.

Барыбызга да билгеле булганча, Май чабу атнасының символы – коймак. Дүшәмбе һәр өйдә, гаиләнең үзенә генә билгеле рецептлары буенча, коймак пешерелә. Табадан төшкән беренче коймак, ата-аналар рухи өчен дип, ачык тәрәзәгә куела. Ата-бабаларыбызны зурлау, аларны хөрмәт итә белү сыйфаты да салынган Май чабу бәйрәменә. Шуны әйтергә кирәк, керәшен татарларында, ерак сәфәргә чыгар алдыннан яки үлгәннәрне искә алу көннәрендә дә коймак пешерелә. Буыннарыбызны онытмау, аларны хөрмәт итүнең бер чарасы.

Татар халкының бәйрәмнәренә, йолаларына бәйле дәрестән тыш эшләр укучыларда зур кызыксыну уятып кына калмый, гомумкешелек һәм милли үзенчәлекле бәямәләр нигезләрен һәм һәр халыкның кыйммәти-норматив дөнья күренеше үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Милли менталитетны, шәхеснең һәм милли мәдәниятнең үзәген ача. Соңгы елларда халкыбызның үткәндәге традицияләрен, бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен торгызуда зур җанлылык сизелә. Бу хәл киләчәккә безнең өметебезне арттыра һәм ышанычыбызны ныгыта.

**Әдәбият**

1. Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан: Матбугат йорты, 1997. – 248 б.

2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
3. Филиппов А. С. Карендәшләр. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – 80 б.

## ОРАЗГҮЛ НҰРМАҒАМБЕТОВАНЫҢ МҰРАСЫНДАҒЫ ҚАЗАҚ-МАЖАР ӘДЕБИ БАЙЛАНЫСТАРЫ

*Ермағанова М., Жолдасбекова З., Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университеті Ғылыми кітапхана қызметкерлері*

Қазақ халқының рухани мәдениетінің асыл мұраларының бірі – сирек кездесетін қолжазбалар мен алуан түрлі сирек басылымдардың түпнұсқасы. Қазіргі таңда қолжазбалар мен сирек басылымдар – халықтың жады мен тарихы есебінде еліміздегі ең ірі кітапханалары, мұрағаттары, ғылыми зерттеу орталықтарының қорында сақталған.

Мемлекет басышысы Н. Назарбаев: «Бүгінгі күнді түсініп-түйсіну үшін де, болашақтың дидарын көзге елестету үшін де кешегі кезеңге көз жіберуіміз керек», – деп өткенге баға беру арқылы ғана болашақтың жолы саралානатынын баса айтады [2: 185].

Осы бағытта Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университетінің ғылыми кітапханасы осындай көне заманнан қалған рухани байлықты сақтап келе жатқан қолжазба орталықтарының бірі.

Шеңбер құпия сыр бүккен белгісіздіктің, шетсіз-шексіз кеңістіктің, мәңгілік өлшеусіз уақыттың көшпелілер санасында қалыптасқан таңба – белгісі десек, ұрпақ жалғасытығын, ру тектің өміршеңдігін я болмаса тоқтауын, тоқырауын, жоғалуын, жойылуын бедерлейтін символдық мағына қазақ түсінігінде шеңбер формалы шаңырақ ие. Үш-үштен айқастырылып қосылған түзу сызықтың (күлдіреуіш) бір шеңбер бойына (шаңырақ шеңбері) тоғыстырылуы – жеті атаның бір шаңырақ астынан өрбіп-өнген ұрпағының бірлігін, яғни рулы елдің тектік бірлігін көрсетеді».

Сондай – ақ Батыс қазақстандық құдағи жүзіктер екі бастаудың, екі шаңырақтың ілік жекжат болуын бейнелейді. Бұл жүзікті келінге деген жылы қабағы, қамқорлығы үшін қыз шешесі құдағиына салады.

Ғұламалар айтып кеткендей, осы киіз үйден қазақ халқының аспан әлеміне, есептеу жүйесіне, экономикалық біліктілігі, мәдениет пен өнердегі талғамы – жалпы өмір тәжірибесіндегі іске бейімділігі аңғарылады. Ал 12–13 ғасырлардағы мемлекеттердің Алтын Орда, Ақ Орда, Көк Орда деп аталуының өзі осы киіз үйге байланысты екенін Шоқан Уәлиханов айтқан.

**Әдебиеттер**


1. Қазақ әдеби тілінің сөздігі / Құрастырған: А. Жаңабекова, Т. Жанұзақов, Б. Әбілқасымов және т.б. – Алматы: Қазақ энциклопедиясы, 2011. Т. 15. – 824 б.
2. Нұрмағамбетов Ә. Сөз сырына саяхат. – Алматы: Жалын, 1990. – 128 б.
3. Исаева Г. Шаңырақ // Ана тілі. – 19 қараша. – 2015.
4. Қайдар Ә. Қазақтар ана тілі әлемінде: Этнолингвистикалық сөздік. – Алматы: Сардар, 2013. – Т. 1. – 824 б.
5. Кононов А.Н. О семантике слов кара и ак в тюркской географической терминологии // Известия Отделения общественных наук Академии наук Таджикской ССР. 1954, вып. 5. – С. 45–60.


## ҚАЗАҚ ЕРТЕГІЛЕРІНІҢ ЗЕРТТЕЛУ ТАРИХЫ


*Жұрнаш А., М. Қозыбаев атындағы Солтүстік Қазақстан мемлекеттік университеті, «Филология» мамандығының ІІ курс магистранты.*
*Ғылыми жетекшілер – ф.ғ.к., профессор Ж.Т. Қадыров, ғылым магистрі Садықов Н.Ш.*


Қиял-ғажайып ертегілердің классикалық типі қаһарманды басқа дүниеге аттандыру, ғажайып құралдарды табу, қиын тапсырмаларды орындау, құда түсу, жауыз күштерден құтылу сияқты композициялық бөлшектерді қамтиды. Ол көбінесе қаһарманның үйленуімен және таққа отыруымен аяқталады. Ертегілердің классикалық түрі шығыс пен батыс халықтарына кең таралған. Қазақтың қиял-ғажайып ертегілері ерекше дара

тұрған дүниелер емес, оның көптеген сюжеттері дүниежүзіне белгілі ертегілердің варианттары болып келеді.

Ертегілердің енді бір түрі батырлық ертегі. «Батырлық ертегі» деген термин фольклортану ғылымында төрт түрлі мағынада қолданылады. В.М.Жирмунский бұл жанрға Оңтүстік Сібірдегі түркі-монғол халықтарының көне эпосын жатқызады. Қаһармандық эпостың шығу тарихын зерттеген Е.М.Мелетинский «Батырлық ертегі» деп угорлар мен тунгус-маньчжур және кейбір Сібір халықтарының әңгіме түрінде келетін эпостан басқа шығармаларын атайды. Орыс былиналарының білгір зерттеушісі А.М.Астахова «Батырлық ертегі» түріне халық эпосының батырлары туралы кейінгі замандарда пайда болған ертегі түріндегі шығармаларды жатқызады. Сонымен қатар бұл жанрға ерлік, қаһармандық мазмұндағы қиял-ғажайып ертегілер жатқызылып жүр. Қазақтың батырлық ертегісі осы төрт мағынаны түгел қамтиды. Мұнда аталған төрт түрдің бәрі бар, әсіресе, эпосқа дейінгі және жырдың ертегіге айналған түрлері кең тараған.

Қазақ ертегілерінің құрамында батырлық ерегілер бар екенін М.Әуезов те айтқан. Ол кісі дәл осы терминді қолданбаса да бұл жанрдың екі тобын дұрыс көрсекен. «Сол ертегілердің ішінде, – деп жазады Мұхтар Әуезов – ең ескірегін алсақ, бұрынғы ескі нанымды білдіретін жалмауыздар араласқан ертегілер мн кәсіп ертегілер болады. Кәсіптік ертегілерге өте көп кіретін аңшылық өте ескі ертегілер «Еділ-Жайық», «Құламерген» сияқтылар болса, бұнда иен тау, елсіз өзендерде жалғыз мекен еткен батыр аңшылары әңгімеге кіреді». Ғалымның бұл айтып отырған ертегілері ең көне екені рас. Ол – хикаядан, бір жағы, қиял-ғажайып ертегіге, екінші жағы, батырлық ертегіге айналады. Басқаша айтқанда, «Еділ-Жайық», «Құламерген» сияқты шығармалар – архаикалық батырлық ертегінің негізін қалаған хикаялар. Мұхтар Әуезов көне батыр-аңшылар туралы әңгімелермен бірге кейінгі замандарда туған «Батыр әңгімелер» бар кенін айта келіп, былай деп жазады: «Қазақ ертегілерінде жоғарыда айтылған ескі түрлерінен басқа, берірек заманда шыққан жаңарақ әңгімелер де бар. Мәселен өлең өлшеуіне түскен батырлар әңгімелерінің барлығы ертегі болып кеткен, батыр әңгімесін көп ел құмартып тыңдайтын болғандықтан ел қиялы бергі замандардың батырларын да ертегінің қаһарманы қылып әкеткен». Сөйтіп, ғалым бұл жерде батырлық ертегінің екінші бір тобын, яғни жырдан туған ертегілерді айтып отыр. Ғалымның бұл пікірі кейінгі зерттеулерде де толық дәлелеледенді. Батырлық ертегіні қарастырған Е.Костюхин де, С.Қасқабасов та қазақ халық прозасының бұл жанры екі топтан тұратынын, оның бірі – көне дәуір тумасы да, екіншісі-кейінгі ғасырлардың туындысы екенін көрсетті.

Батырлық ертегілердің тақырыптық диапазоны соншалықты кең емес. Мұнда екі сала бар. Бірі – болашақ батырдың некелік сынақтан өтуі: қыздың

немесе әкесінің қиын-қиын тапсырмаларын орындау, балуандық пен мергендік сыннан сүрінбей өту, жаяу жарыста жеңіп шығу т.т. Екіншісі – әр түрлі ғажайып мақұлықтармен және жау елдің қолымен соғысу.

Архаикалық батырлық ертегінің сюжеті кейіпкердің бүкіл өмір-баянын қамтиды: 1) пролог, яғни кейіпкердің туу тарихы; 2) кейіпкердің үйлену тарихы; 3) кейіпкердің үйленгеннен кейінгі тарихы.

Екінші топтағы ертегілердің сюжеті мұндай кең емес. Бұл ертегілердің негізгі тақырыбы – рулар мен тайпалар, қалмақтар мен қазақтар арасындағы ұрыс, жанжал, бір ру батырының екіншіден кек алуы. Кейде ертегі сюжеті кейіпкердің ұрпағы туралы эпилогты да қамтиды.

Қазақтың батырлық ертегілерін ұлттық филология ғылымында арнайы зерттеп, диссертация жазған – Ысқақова З. Кейіпкерлері, олардың атқаратын функциясы талданады, сондай-ақ батырлық ертектің композициялық құрылымы мен көркемдік табиғаты зерттелген.

Зерттеуші батырлық ертекті ішкі мазмұндық сипатына қарай мынадай төрт топқа: 1. Архаикалық ертек. 2. Классикалық батырлық ертек. 3. Ертеден жырланып келе жатқан батырлық эпостардың проза түріндегі нұсқалары. 4. Дастанға айналған ертектер деп бөлген.

Сонымен қатар мақалада ертектердің кейіпкерлерін талдап, әсіресе батырдың серігі – аттың бейнесі және батырдың қас жауының бірі – жалғыз көзді дәу образы арнайы қарастырылған [1: 51].

«Аталмыш ертегілерді зерттеушілер әртүрлі тарапта тексеріп (көне эпос, батырлық ертегі), түрлі ой-пікірлер жинақтауының нәтижесінде халық прозасының жалпы даму жолы жан-жақты ескеріліп, ертегілердің іштей саралануындағы батырлық ертегілердің қалыптасуының ғылыми негізі тұжырымдалған, яғни стадиялық тұрғыдан батырлық ертегінің өзінің екі түрлі сипатын ажырату қалыптасты. Біріншісі – көне (архаикалық) батырлық ертегілер. Екіншісі – кейінгі дәуірде XVIII–XIX ғасырда туған» [2: 7].

Қазақтың ертегілік прозасында өзінің сюжеттік құрамы мен мазмұны, композициялық құрылымы мен стилі жағынан оқшауланып тұратын бірталай ертегі бар. Алайда, ұлттық фольклортану ғылымымызда олар жеке зерттелмей «тұрмыс-салт ертегілердің» тобында қарастырылып жүр. Ал бұл ертегілер өзінің сипатты белгілері бойынша таза «тұрмыс-салт ертегі» емес. Новеллалық ертегілердің қаһармандарына келер болсақ, олар батыр да мерген емес. Новеллалық ертегінің басқа ертегіден басты айырмасы – оқиғалардың қазақтың кең даласында емес, шаһарда, хан ордасында өтуінде.

Новеллалық ертегілер адамның басынан кешкен шытырман, қызғылықты да әдеттен тыс уақиғалармен байланысты болса, ал сатиралық ертегілер қанаушылар мен арамтамақ құзғындарды әшкерелеп, әдеттегі ауыл өмірін бейнелейді. Бұнда уақиға орны – кәдімгі ауыл, кейіпкерлері – ауылдағы малшы мен бай, молда. Сатиралық ертегілер – әлеуметтік

мазмұны жағынан шырыға түскен кемелденген сананың жемісі. Сатиралық ертегіде ақымақтар мен қу тазша, Алдар көсе, Қожанасыр бейнелері болуы – ертегілік прозаның жаңа көркем сапаға көшкенінің белгісі, өйткені бұл кейіпкерлер қоғамның дамуына сәйкес өзгерген халық дүниетанымына байланысты пайда болған. Сатиралық ертегілердің қаһармандары өздерінің әлеуметтік жағдайын өмірдегі әділетсіздікті түсіне де, сезіне де білетін және оған қарсы да күресе алатын жандар болып келеді. Сөйтіп, ертегі әрбір қаһарманға нақтылы әлеуметтік сипаттама береді.

**Әдебиет**

1. Алпысбаева Қ. Қазақтың батырлық ертегілерінің сюжеттік ерекшеліктері. // Керуен. – 2013. – № 1 (30). – Б. 50–68.

2. Бабалар сөзі. Жүз томдық. Батырлық ертегілер – Астана: Фолиант, 2011. – Т 75. – 424 б.

## ФӘНИС ЯРУЛЛИН ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ АНТОНИМНАР

*Закирова А., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, X сыйныф*
*Җит. – Мулласалихова Г.Г.*

Татар әдәбиятында Фәнис Яруллинның үз урыны бар. Аның, кайсы гына жанрда булмасын, әсәрләрен беркемнеке белән дә бутап булмый. Ул сүзнең яңгырашына һәм тәэсир итү көченә дә зур әһәмият биргән. Аның әсәрләре җиңел укыла, теләсә кайсы образ җанлы булып күз алдына килеп баса. Иң тәэсирле һәм үтемле сүзләрне сайлап, аларны үткен юморга төреп бирә белгән язучы. Кеше характеры турында укыйсың икән, син аны үтәли күргән кебек буласың, ул ашаган ризыкның тәмен, ул йөргән болыннарның исен тоясың. Моның сере шунда: язучы кулланып язган сүзләрнең эмоциональ көче бик зур.

Безнең эзләнү эшенең темасы – «Фәнис Яруллин шигырьләрендәге антонимнар». Максатыбыз – Ф. Яруллин шигырьләрендәге антонимнарны табу һәм төркемләү; аларның шигырь эчтәлегенә йогынтысын ачыклау. Бурычлар: Ф. Яруллин шигырьләрен уку, антонимнарны җыю; алар белән башкаларны да таныштыру.

Тормыш капма-каршылыктан тора. Яхшы янында начар, ак янында кара бар. Бөтен сүзләрнең дә антонимнары булмый. Тел һәм әдәбият фәнендә дә антоним, антитеза, оксюмороннар дигән лексик чаралар, стилистик фигуралар бар. Әсәрләрдә антонимнарның булуы нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген аңларга ярдәм итәләр. Антонимнар даими һәм контекстуаль антонимнарга бүленә.

Антонимнар матур әдәбиятка борынгы заманнардан ук килеп кергәннәр. Халык авыз иҗатында, бигрәк тә мәкаль-әйтемнәрдә, табышмакларда антонимнар күп очрый. Антоним сүзләр кулланып сурәт ясау әдәбият белемендә антитеза дип атала. Нигезе халык авыз иҗатына барып тоташа торган бу алым хәзерге поэзиядә актив кулланыла. Н. Исәнбәт төзегән татар халык мәкальләре тупланмасында (3 томда)

меңнәрчә мәкальләр антонимнар ярдәмендә ясалганнар. Кайберләре тулысынча антонимнардан тора. Шигырьләрен укып чыкканнан соң, Ф. Яруллинны "антонимнар энциклопедиясе" дип атап булыр иде. 286 антоним таптым, әмма бу чик түгел.

Аның сурәтләү осталыгы зур, тел-сүз байлыгыннан уңышлы файдалана. Ф. Яруллин ил язмышына сәясәткә битараф түгел. Ул кулланган антонимнар арасында канатлы сүзләр булырлык гыйбарәләр дә бар. Мәсәлән: *Аклык кирәк безгә аклык кирәк, / Бик күбәйде җирдә каралык. Йөз кайгыга түзәсең дә, бер кайгыдан авасың.*

Шигырьләреннән җыйган кайбер антонимнарга күз салыйк: *Күкләр белән җирне тоташтырып, шәфәкъларга кушылып янасың* [2: 131]; *Керми киттем каен урманына, / Каен урманнары ак иде. Керер идем, күңелемә минем / Кара уйлар тулган чак иде. / Ап-ак каеннарның йөзләренә сарылмады кара уйларым* [2: 132]. *Ярып әйтә дошман да, дус та* [2: 136].

**Күренешләрнең, предметларның, кешеләрнең сыйфатларын тасвирлау**: *Дусларга да, дошманга да / Ачык иде кочаклар* [2: 144]. *Гигант булмасам да, кәрлә түгел, бәхетемә җитә буйларым* [3: 145]. *Намусыңа күз ташла бер, Чистамы ул, керлеме?* [3: 226]. *Барыбер килерен белсәң дә, / Көтәсең сөенеп-көенеп* [2: 234]. *Сабыр кеше дә саналмыйм, мин бер түземсез бәндә* [3: 153].

**Вакыт төшенчәсен тасвирлыйлар**: *Гел эчүләргә бәйләнгән үткәнем, киләчәгем. Эчтем язлар яктылыгын, / Сарысын эчтем көзнең. / Кышларның аклыгын эчтем, / Җәйләрнең җылылыгын* [2: 139]. *Язны – көзгә, көзне – язга / Кушучыда шул ук кошлар* [2: 142]. *Нәрсә эзлим мин бу җирдән / Бәргәләнеп көн вә төн?* [3: 146]. *Башак җыйдым язын-көзен кырларында* [2: 156]. *Кышларында гөл эзләдем, / Җәйләреннән ак карлар* [2: 160]. *Кушылалар төннәр белән көннәр* [3: 152].

**Процессларны каршы куялар**: *Нидер чәчкән булабыз да / Нидер урган булабыз. / Анысын сүтеп, монысын корып, дөнья көткән булабыз. Була көннәр – өзелә соңгы өмет. / Беттем, дигәч, шуны бирәү ялгый килеп* [2: 135]. *Эзләдем, таптым, югалттым... / Бар байлыгымны югалтсам, / Яңасын таба тордым* [2: 140]. *Алданамын белмичә дә, Алданамын белеп тә. / Алдануларны кичерәм / Елап та һәм көлеп тә* [2: 148]. *Күктә очкан коштан эзләр калмый, / Башта туган уйдан эз кала* [2: 150]. *"Кеше китә-җыры кала", – диләр, бер җыр калсын әле бездән дә* [2: 151].

**Күренешләрнең озынлыгын күләмен, урнашуын белдерәләр**: *Сикердем упкыннар аша, / Үрелдем кыяларга* [3: 140]. *Күкләр зәңгәрлеген эчеп, / Кабат җирләргә төштем* [2: 139]. *Күкне – җиргә, җирне – күккә / Нурлар белән бәйли-бәйли, оча алар* [3: 142].

**Гомумирәк төшенчәләрне белдерәләр**: *Эчтем шатлык, эчтем сагыш / Тустаганнар тутырып* [2: 139]. *Булды инде, бар да булды – Агы да, карасы да* [2: 140]. *Уйлыйм, уйлыйм, үткәннәрне уйлыйм / Киләчәкне*

*уйлыйм еш кына* [3: 150]. *Буталалар төшләр белән өннәр* [2: 152]. *Кайгылар тетрәтсен, / Шатлыклар дөрләтсен, / Мәхәббәт җырлатсын, Хыянәт елатсын* [2: 155]. *Әллә нинди төшләр кирә, Өннәремдә һичбер вакыт / Эшли алмас эшләр кирә* [3: 159]. *Кибә яшьләр, иелә башлар, / Шатлык китә, зар кала* [3: 167]. *Бәхет белән бәхетсезлек һәрвакытта янәшә* [2: 227]. *Савап белән гөнаһ кушылып беткән / Дөнья, ахры, шулай төзелгән* [2: 230]. *Каралыктан сырхаулаган җанны / Дәваласын иде шул аклык* [3: 234]. *Кергә күмелеп озак яттык инде, / Ак чәчәкләр булып бер калкыйк* [2: 247]. *Акыллылар акыл җыя, Юләрләр акыл сата. / Исерекләр ил җитәкли / Аеклар көтү көтә* [2: 245].

**Контекстуаль антонимнар**: *Миңа алтмыш тулган диләр, / Кем чыгарган бу сүзне? / Тутыра алмый әле йөрәк / Һаман да унсигезне* [2: 133]. *Була көннәр – / бәреп керә бәхет. / Була шундый көннәр – / авып төшә тәхет* [2: 171]. *Упкыннарда биеклекләр күрәм, / Кара төннән табам яктылык* [2: 145]. *Бер булса да очкын булдым учагында, / Бер булса да дулкын булдым елгасында* [2: 156]. *Менәсе килә кайвакыт / Биек-биек үрләргә, / Тормышның түбәнлекләре / Күренмәслек җирләргә* [2: 161].

Ф. Яруллин сүзнең бөек көчен, тасвирлау мөмкинлекләрен тоеп, үзенә генә хас иҗат стилен тудырган.

**Әдәбият**


1. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999. – 350 б.
2. Яруллин Ф. Танышлар арасында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 350 б.
3. Яруллин Ф. Күңел яктысы. Шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 245 б.


## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ҺӘМ ФАВАРИС ГАЛИЕВ ИҖАТЫНДА ОХШАШ ЯКЛАР


*Закирова М., Балтач р-ны Смәел урта мәктәбе, XI сыйныф*
*Җит. – Гыйзәтуллина М.Р., Нәбиева Г.*


Шагыйрь булсаң, дөрләп кенә,
Янып-көеп кенә була.
Шагыйрь гади була алмый,
Шагыйрь бөек кенә була!

Күңеленә нинди генә уйлар килсә дә, аларның һәммәсен шагыйрь Роберт Миңнуллин шигырьләре – җырларыннан, татар халкының милли һәм рухи асылын билгеләгән, шагыйрьнең иҗатын, тирән һәм киң дәрья кебек, тулаем иңләгән милли моңнан табарга була.

Бу хезмәттә сүз тыйнак, тыныч, ләкин зур йөрәкле, киң күңелле, чын мәгънәсендә талантлы кеше, олы шәхес Роберт Миңнуллин һәм авылдашыбыз Фаварис Галиев турында барачак.

Шагыйрьләрне шартлы рәвештә ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Берәүләр, укучы күңелендә туган як хисе уяту өчен, бөтен

дөньяны әйләнеп чыгалар. Икенчеләр гомерләре буе үз яклары, үз авыллары, үз әниләре турында язалар һәм шундый ук мәхәббәт, абруй казаналар. Ике шагыйрьне дә мин соңгылар рәтенә кертер идем.

“Фаварис Галиев – бәхетле кеше. Аның бөтен язмышы – яшәеше, уй – хыяллары, гамәлләре туган җирдә. Гомере буе туган авылы кырларында икмәк үстергән. “Россия Федерациясенең атказанган агрономы” дигән абруйлы исеме аның җир табибы буларак яулаган үрләрен, кемлеген үзе үк әйтеп тора. Шагыйрь буларак, Фаварисның табигатьне аңлый, аның һәр фасылындагы халәтен рәссамнарча бизәкле сурәтли белүенә сокланмый мөмкин түгел...” Әлеге сүзләр Фаварис Галиевның 2011 нче елда басылып чыккан “Көзге яшьнәү” шигырьләр җыентыгының кереш сүз өлешеннән алынды. Фаварис аганы җир кешесе, табигать баласы дип атап бер дә ялгышмаган районнашыбыз, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре һәм сәнгать эшлеклесе, шагыйрь Г.Мөхәммәтшин.

«Миңа калса, Роберт Миңнуллинның төп максаты әдәбият, сәнгать, каләмдәшләр, балалар дөньясы, милли тел, дин, туган тел, туган төбәк, туган ил һәм туган халык турында шагыйрь акылында, шагыйрь күңелендә булган уй-хисләр, фикерләр, икеләнүләр, борчылулар, сөенүләр, кирәк урында чүт кенә күкрәк кагып алулар аша замандашлар белән ачыктан-ачык, бернинди рыясыз рәвештә күзгә – күз карап сөйләшү», – ди шагыйрь иҗаты турында Гәрәй Рәхим. Чыннан да, Татарстан Дәүләт Советы трибунасыннан һәм башка трибуналардан сөйләгән докладлар һәм чыгышлар, журналист яки каләмдәшең белән күзгә-күз карап сөйләшкән интервьюлар һәм әңгәмәләр, конкрет әдәби жанрга, китапка, каләмдәшкә багышланган мәкаләләр – барысы да моны исбат итә. Иҗади эшемнең йомгак сүзләре итеп мин Равил Рахманиның сүзләрен китерер идем: «Роберт Миңнуллин, милләтебезнең улы буларак, тормышыбызның дүрт мөстәкыйль өлкәсендә һәм жанрында үзенең нәрсәгә сәләтле булуын раслап күрсәтте. Иң әһәмиятлесе, безгә татарның кайсы юлдан барырга кирәклеген яшәп күрсәтте».

Кешеләргә без яхшылык эшлик!
Эшләмәсәк – гарьлек.
Тик яхшылык эшләү җиңел түгел,
Ул – зур фидакарьлек!
Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,
Бу заманда бигрәк,
Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,
Ә эшләргә кирәк!

“Көзге яшьнәү” Ф. Галиевның 70 яшьлек юбилее уңаеннан басылып чыккан тәүге шигырьләр китабы. Без аны кулга алуга ук бер тында укып чыктык. Тематикасы ягыннан авыл табигате, җир турында

язылган шигырьләре аеруча кызыксыну уятты. Без әлеге эшебезне менә шушы темага багышларга уйладык һәм авылдашыбыз иҗатындагы үзенчәлекләрне, охшаш якларны, сурәтләү алымнарын башка шагыйрьләр иҗатыннан эзләп табып өйрәнүне үзебезгә максат итеп куйдык. Әлбәттә, Ф. Галиев һәм Р. Миңнуллин шигырьләрен чагыштырып карау, өйрәнү бик мавыктыргыч эш булып чыкты.

Җаныгызда нинди хистер, Миңа гына кадерледер
Уйларыгызда нидер? Туган җирнең бу тәме?...
Сезгә, бәлки, монда бар да Туган җирем шушы гына…
Гадәтидер, гадидер. Юк, дусларым, бүтәне («Шушы инде…»)

“Җир сулышы” шигырендә дә Фаварис ага туган ягына мәдхия укый.

Кышкы чорда салкын кырда
Җил белән кар куышы.
Урманга бәс булып куна
Җирнең салкын сулышы...

Роберт Миңнуллин мине, иң элек, шәхес буларак сокландыра. Шагыйрьнең зурлыгы талантында гына түгел, күңеленең игелекле һәм укучыларына итагатьле булуында да. Иҗаты белән дә кешелеклелеге белән дә җанга якын ул. Шуңа күрә дә аның шигырьләрен укыгач, җырларын тыңлагач, күңел пакьләнеп,яктырып кала. Чыннан да, Татарстанның бер генә төбәгендә дә (һәм Башкортстанда да) аның иҗатын якын күрмәгән, җырларын яратып җырламаган, үзен ихлас күңелдән хөрмәт итмәгән кеше юктыр. Ул – балалар күңеленә тирән үтеп керердәй итеп язылган шигырьләр, кечкенә әкиятләр, табышмаклар, сүз уйнатулар авторы. Биредә, кабатлап булса да, өстәргә кирәк: Роберт Миңнуллин – өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә бер үк дәрәҗәдә талантлы итеп язучы шагыйрь. Ә инде аның әсәрләре тематикасының чагылышы гади авылдашыбыз иҗатында да күренүе безнең өчен олы горурлык билгесе.

## Г. ГЫЙЛЬМАНОВНЫҢ «ЙОРТ ИЯСЕ» ХИКӘЯСЕНДӘ МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

*Зарипова Г., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Минһаҗева Л.И.*

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2003), Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби бүләге лауреаты (2002), Татарстан Республикасының Мактау грамотасы иясе (1994) Галимҗан Гыйльманов озак еллар дәвамында татар халкының борынгы мифларын, риваять-легендаларын, им-томнарын, юрамышларын барлау һәм җыю, ияләр-рухлар дөньясын, тәңречелек тәгълиматын өйрәнү юлында гыйльми эзләнүләрен дәвам иттерә. 1996 һәм 1998 елларда

басылып чыккан «Татар мифлары» – биш том итеп уйланылган шул җыелманың тәүге ике китабын тәшкил итә.

Модернизмга хас жанр, поэтика, композиция, стиль сыйфатлары әдипнең «Албастылар» (1999), «Оча торган кешеләр» (2000) исемле күләмле әсәрләренә дә хас. Фантастик-хыялый һәм маҗаралы әдәбияттан аермалы буларак, бу романнарда вакыйгалар чынбарлык белән хыял кисешкән чиктә бара, шул сәбәпле образлар бирелешендәге серлелек, композицион интрига, психологик киеренкелек көчәя төшә [1: 444–446].

Г. Гыйльманов иҗатына Д. Заһидуллина, Ф. Урманчиев, Л. Минһаҗева, А. Шәмсутова һ.б. кызыклы гына күзәтүләр эшләделәр. Шулар арасыннан Алсу Шәмсутова Г. Гыйльмановның үзенә генә хас сурәтләү алымы турында: «Әдәби әсәрдә яңа дөнья, дөньяның үзенчәлекле моделен тудыру алымы бар. Әдәбият белемендә мондый күренешне «миф тудыру» дип атыйлар», – дигән фикер әйтә [5: 142].

Ләйлә Минһаҗева Г. Гыйльмановны әкияти һәм реальлекнең тыгыз бәйләнеше әсәрләрнең спецификасын тудыручылар рәтенә кертә. Ягъни, «Татар балалар язучылары легенда һәм риваятьләр, әкияти сюжетлар һәм хәзерге яшәеш арасында параллельлек үткәрергә омтылалар. Бу хәл мәгънәгә тирәнрәк үтеп керергә, халык, тарих белән горурланырга мөмкинлекләр ача. Мондый әсәрләрдә төп геройлар бөтен бер персонажлар системасын специфик итә», – ди, һәм шул язучылар исәбендә Г. Гыйльмановны да атый [3: 692].

Г. Гыйльманов – әдәбиятта үзен танытып өлгергән өлкән язучы. 1972 елларда матбугатта күренә башлап, ике дистә елдан артык вакыт татар әдәбиятын үзенең әсәрләре белән тулыландырып бара.

Г. Гыйльманов үз каләмен әдәбиятның төрле жанрларында сынап карый. Ул шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, җыр текстлары авторы да. Аның проза жанрындагы әсәрләре тупланган беренче китабы «Тозлы яңгыр» исемле. Анда авторның парча, нәсер, әдәби этюд, повесть жанрында язылган әсәрләре урнаштырылган. «Тозлы яңгыр» повестенда модернизм билгеләрен күзәтергә мөмкин. Мондый билгеләр язучының алдагы иҗатында да күренә. «Албастылар», «Оча торган кешеләр» исемле күләмле әсәрләре моңа дәлил булып торалар, фантастик хыялый һәм маҗаралы әдәбияттән аермалы буларак, бу романнарда реаль вакыйгалар чынбарлык белән хыял кисешкән чиктә бара. Шуңа күрә мондый әсәрләрдә көчәя барган серлелек, интрига, киеренкелек урын ала. Соңрак язылган «Ак ат сагышы», «Җанбалык», «Фәрештә», «Шартлау» кебек проза әсәрләре дә шул юнәлешкә нигезләнеп язылган. Г. Гыйльманов иҗатындагы бу үзенчәлекнең чагылуы тиккә генә түгелдер, чөнки ул «Татар мифлары» дип аталган хезмәт авторы да.

«Йорт иясе» әсәренең исеменнән үк аның мифологик образ белән бәйле булуы аңлашыла. Йорт иясе яшәү урыны итеп идән астын сайлый, көндезләрен шунда гомер сөреп, төнге сәгатьләрдә генә үз биләмәләренә чыгып йөри; иң мөһиме: өйне саклый, бик тырышып карый торган рух ул [4: 203].

Шәһәрдә туып-үсеп, әтисе белән беренче тапкыр авылга кайткан Илүсәнең авыл турындагы беренчел фикерләре чагыла. Аннан соң исә, Рух исемле егет белән танышып, кызда авылга карата җылы хисләр тууын күрәбез. Җылы хисләр исә, егетне ошатудан башлана. Ләкин, Мәстүрә әбинең ашыгып ясаган нәтиҗәләре, ягъни моннан бик күп еллар элек чыгып китеп читтә тормыш корган Нәҗип малае Рухны – йорт иясе дип уйлап, өйгә дога кылу күренешләре күзәтелә. Әлеге җирлектә Мәстүрә әби авызыннан әйтелгән сүзләрдән йорт иясенең нинди җан иясе булуын, аның ни өчен кешеләр күзенә мәҗбүр булуын һәм йорт иясен тынычландыру өчен нинди йола үтәргә кирәклеген күрәбез.

Илүсәнең әтисе – Рамилнең дә «җанын эзләп кайту» турындагы сүзләре Мәстүрә әби әйткән сүзләр белән туры килә. Аннан, авылдан чыгып киткән Нәҗип хакында борчылып, рухы йорт иясе рәвешенә кереп, буш торган йортыннан борчылып чыккан, дигән фикер әйттерелә.

Хикәядәге Рух исеменә дә игътибар итәргә кирәк. Рух – җан дигәнне аңлата. Уку барышында әлеге исем укучыны бераз алдый. Егетне, дөрестән дә, йорт иясе булган дигән фикергә китерә. Ләкин хикәя ахырындагы борылыш фикерне икенче якка үзгәртеп куя. Шулай булса да, әлеге көтелмәгән нәтиҗә йорт ияләре хакында, туган нигез, авылга әйләнеп кайту; балаларга, оныкларга нигезне мирас итү турындагы уйларга җирлек калдыра.

Шулай итеп, Г. Гыйльмановның йорт иясе образын Мәстүрә карчыктан сөйләтүе бик отышлы. Ул аны куркыныч итеп сурәтләп түгел, ә җиңелчә «телгә кертеп» укучыга җиткерә һәм үткән-бүгенге-киләчәк турында уйланырга мәҗбүр итә. Г. Гыйльмановның мифик образны керткән «Йорт иясе» хикәясендә экият белән чынбарлык, миф белән реальлек тыгыз бәйләнештә тора.

**Әдәбият**

1. Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек: 2 т. / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Т. 1. – 751 б.

2. Гыйльманов Г. Тәкъдиргә юл: хикәяләр, новеллалар (2001–2012) // Г. Гыйльманов. – Казан: Рухият, 2014. – 447 б..

3. Мингазова Л.И. Детская поэзия Г. Гильманова в контексте этических исканий современности // Матер. Междунар. науч.-практ. конф. «Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия». – Казань: ИФИ, 2013. – 692 с.

4. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 388 б.

5. Шәмсутова А. Галимҗан Гыйльманов иҗаты // Мәйдан. – 2007 – №4. – Б. 142.

# Ф.ЯХИН ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ КОШ ОБРАЗЫНЫҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

*Зарипова Д., Кукмара р-ны Зур Кукмара урта мәктәбе, XI сыйныф*
*Җит. – Гатауллина А.Ф.*

Матур әдәбият әсәрләрендә кошлар образы бик еш очрый. Аларның беришләре табигать матурлыгын күрсәтү өчен кулланылсалар, икенчеләре әсәр геройларының эчке яки тышкы сыйфатларын ачып бирү ролен үтиләр. Әсәр героеның үзенә туры килә торган кош образы белән чагыштырылып бирелүе әсәрнең тел-сурәтләү чарасы буларак бизәлешен барлыкка китерә, вакыйгалар күренешен сынландыра. Кешеләрнең генә түгел, димәк, кошларның да укучыга әйтер сүзе була.

Танылган язучы, шагыйрь, әдәбият белгече Фәрит Яхин иҗатында да кош образлары мөһим урын алып тора. Мәсәлән, "Һомай кошы" хикәясендә малай әтисе белән болынга печән чабарга барганда, бер кошка игътибар итә, аның бу кошны әлегә кадәр бер дә очратканы булмый. Бу таныш булмаган кош турында тизрәк белергә теләп, малай әтисенә сораулар яудыра башлый. Малайның әтисе әлеге кошны очратуларына чиксез куана, чөнки Һомай кошы – сәгадәт билгесе, ул бәхет китерә. Малай Һомай кошын күрүе, аның күләгәсе астында калуы аркасында киләчәктә үз бәхетенә ирешәчәгенә ышанычы арта [2: 21]. Әлеге хикәядә Һомай кошы образы бәхет, өмет, якты киләчәк символы булып тора. Мифологик ышанулар буенча һомай кошы (феникс) күләгәсе төшкән кеше бәхетле була [1: 142].

Фәрит Яхинның кош образы аеруча тулы ачылган тагын бер хикәясе – "Аккош моңы". Буага аккош төшкән. Ул ялгызы гына йөзә. Аккошны автор искиткеч гүзәл итеп сурәтли: "агачлар арасыннан аккошның озын муены, кабарып торган канатлары аермачык шәйләнеп, затлы рәсемнәрдәгечә күзне иркәли" [2: 36]. Ләкин аккошның тышкы матурлыгы аның күңел халәтенә каршы куела, аның күзләре сагышлы һәм кызыл, башы күкрәгенә яткан: "Аккош үзенә үлем тели кебек иде. Бу вакытта ул миңа кош түгел, бәлки әкиятләрдә сөйләнелә торган сихер золымында изаланучы хан кызы кебек тоелды. Ниндидер кара җанлы сихерче бер чибәр кызны шушындый газапларга дучар иткәндер" [2: 36]. Хикәядә аккош турында ышанулар да урын алган: "Аккош зары хәвефле ул. Киленнәрнең буен шиңдерә, балаларның күңелен сындыра. Ялгыз аккош күргән кешеләр бәхетсез булалар икән". Әсәрдә Галиябану һәм аккошның язмышы параллель сурәтләнә. Аккошның да, Галиябануның да язмышлары фаҗига белән өзелә: аккошны ике килбәтсез милиционер атып үтерәләр, ә Галиябану исә Казанга җибәрелү кайгысын күтәрә алмый, үз-үзенә кул сала. Аккош – төрки-татар мифологиясе персонажы, халыкның тотемистик нәсел башы. "Аккош моңы" хикәясендә әлеге образ сагыш һәм ялгызлык, өметсезлек һәм бәхетсезлек символы буларак кулланыла.

“Ак канатлы бөркет баласы” хикәясендә малайлар көчле давылдан соң зарар күргән бөркет оясына юлыгалар: “Бөркетләр яңгырдан тәмам чыланган, каурыйлары асылынып-асылынып төшкән. Аларны ата-аналары җаннарын атып саклыйлар. Ә читтәрәге, инде егылып төшәр кебек тоелган дүртенче лачын баласы, канатларының берсен һаман да асылындырган хәлендә җыеп алалмыйча талпына, кычкыра. Атасыдыр инде, бөркетләрнең олырагы һәм тагын да шөкәтсезрәге, куркынычы, аның саен иелгәләп аны чукый, төшереп җибәрергә теләп оясыннан арырак этә тора. Лачын баласы бирешми, һаман да ныграк ябыша. Һай, кыяфәте кызганыч, җаннар өзелеп китә.” Малайлар көзен, күчмә кошлар җылы якларга китеп беткәч, күктә очкан бөркетне күреп алалар. Әйе, бу теге, оясыннан егылып төшәргә тиеш булган, канатын яшен сугып еккан агач сыдырган бөркет баласы! Ак канатлы бөркет баласы! Ул кайвакыт пәйда була, гүя авылның саулыгын-иминлеген белешеп йөри, аннан тагын югала. Малайлар хәзер, каз саклауның ни икәнлеген онытып, рәхәтләнеп туп тибәләр. Күктә лачын йөзсә, козгын, карчыга, тилгән ишеләр ерак кача икән. Хикәядә тормыш сынауларына бирешмәскә, бөркеттәй кодрәтле, горур, көчле рухлы булып калырга кирәк дигән идея үткәрелә.

Күке чыннан да кеше гомерен саный микән? “Күке фалы” хикәясендә әлеге сорауга җавап табарга мөмкин: “Сорыйммы әллә? Юк! Сорамыйм! Ходай күпме биргән, шул инде безгә. Анысын да күкедән санатып торырга димени? Аннары, каян белсен ди ул? Күке – фәрештә түгел. Аллаһының Тәкъдирләр китабын укый алмый, хәер, укый да белми!” Күкедән гомернең күпме калуын санату бер дә уен эш түгел икән, ләбаса. Хикәяләүче геройның әнисе күкедән калган гомерен санатырга була. Күке өч кенә тапкыр күкелди. Һәм күке фалы чынга да аша – ана өч елдан, кисәк авырып китеп, гүр иясе була.

Язучының кошлар образына хас булган сыйфатларны ачканда метафора, эпитет, чагыштыру кебек тел-сурәтләү чараларын иркен куллануы, ышануларга, мифологик хикәятләргә мөрәҗәгать итүе башка авторлардан аерылып тора. Фәрит Яхинның хикәяләрендә психологизм көчле, алар укучының дикъкатен яулый алуы белән дә сокландыра.

**Әдәбият**

1. Гыйльманов Г. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар, йолалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 388 б.
2. Яхин Ф. Ак әбиләр догасы: хикәяләр һәм повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 388 б.

## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ РЕКЛАМА СЛОГАННАРЫНЫҢ КАЙБЕР ЛИНГВИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Зарипова Җ., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалетдинова Г.Ф.*

Заманча реклама сүз иҗатының иң актив үсеш алган өлкәләренең берсе. Бүгенге көндә татар һәм башкорт реклама индустриясе тирән

үзгәрешләр чорын кичерә. Төрле объектив һәм субъектив кыенлыкларга карамастан, дәүләт телендә рекламаны гамәлгә кертү процессы дәвам итә.

Рекламаның асылы – идея, информация җиткерүдә оригиналь форма табу. “Уңышлы реклама тексты – ул товарның атамасы, текст һәм визуаль элементларның үзара нисбәте, бер бөтен булып килүе. Беренче чиратта, реклама текстының эчтәлеге – уникаль сату-алу тәкъдим” [1: 32].

Безнең максат – татар һәм башкорт реклама текстларыннан реклама слогннарын барлау һәм аларның лингвистик үзенчәлекләрен ачыклау.

“Слоган” *(sluagh-gharim)* сүзе тамырлары белән үле кельт теле галл теленә барып тоташа һәм “сугышка чакыру” дигәнне аңлата. “Слоган – реклама текстының башка компонентларыннан аерым яши алучы, реклама тәкъдимен кыскартылган варианты булган, мөстәкыйль хәбәр” дип яза реклама теоретигы А.С. Ильин.

И. Низамов реклама текстларының алдагы структурасын тәкъдим итә:*“башисем – төп өлеш – очлам” (заголовок – основная часть – слоган)* композицион схемасы [2: 12].

Гадәттә, чит ил һәм рус реклама теоретиклары башисем белән слоганны (И. Низамов буенча *очлам*) тәңгәлләштерә, бер компонентның синонимик атамалары буларак карый.

Татар һәм башкорт реклама текстларын синтаксик яктан тикшерсәк, слоганнарның нигезендә күпчелек кыска, өндәү җөмләләр ята: *“Яхшы кәеф бездән башлана!”* (“Татар радиосы” радиостанциясе). *“Был һеҙҙең “Байрам”* (“Байрам” кибетләре челтәре).

Әлеге слоганнар кыска һәм илһамландыручы, позитив халәт тудыручы. Өндәү җөмлә – һәрвакыт сигнал, көчле экспрессив алым. Ике телдә дә риторик сорауларны уңышлы куллану очракларын күзәтеп була: “*Кунак көтәсезме? “Бәхетле”гә керегез!”* (“Бәхетле” кибетләр челтәре). *“Мин “Уралсиб”ты һайланым. Ә һеҙ?”* (“Уралсиб” коммерция банкы).

Әлеге мисаллада кулланучы алдында риторик сораулар куела һәм ул “юк” дип җавап кайтара алмый. Рекламада риторик сорау – ул копирайтерларның хәйләсе, манипулятив капкыны [3: 133].

Төрки халыкларда туганлык атамалары аерым бер лексик катламны тәшкил итә. Һәр милләттә *әби, бабай, әти, әни, абый, апа, энем, сеңлем* кебек туганлык атамалары киң кулланыла һәм алар татар-башкорт кешесе зиһененә позитив тәэсир итә. Милли копирайтерлар реклама слоганнарына да әлеге төр лексиканы кертә: *“Куана абый-апай, шатлана әби-бабай! Ташламаллар тулы май – «Толонит» белән елмай*” (“Толонит стоматология клиникасы). *Балаларға ата-әсәйҙәр кәрәк, ә ата-әсәйҙәргә “Терпекәй”* (“Терпекәй” балар кибете).

Лексик үзенчәлекләр арасында игътибарны аеруча җәлеп иткәннәре – этнонимнар белән топонимнар куллану: *“Ысын башҡорттар “Урал-*

*батыр” менән сәйәхәт итә!* (“Урал-батыр” Башкортостанның милли туроператоры). *“Болгар радиосы — һәр татарның йөрәгендә”* (“Болгар радиосы” радиостанцияләр челтәре).

“Татар”, “болгар”, “башкорттар” кебек этнонимнарны куллану рекламаның манипулятив потенциалын көчәйтә, чөнки слоган конкрет милләт кешесенә мөрәҗәгать итә. Беренче мисалда, этноним потенциаль кулланучылар аудиториясен чикли һәм моны маркетинг уңышсызлык дип атарга мөмкин.

Топонимнарга килгәндә, татар һәм башкорт телләрендә алдагы мисалларны китерергә мөмкин: *“Биләр суы. Бабаларыбыз эчкән су”* (“Биләр суы” эчәргә яраклы су сатучы компания). *“Башкортостанны тәмләп кара!”* (“Аҙык-түлек” милли ресторан).

Милли-мәдәни компонент булган топонимнарда патриотик коннотация бар һәм алар җирле халыкка көчле тәэсир итә. Кулланучыга үзенең туган ягы җитештерүчесенең продукциясен сайлау принципиаль позиция булырга мөмкин.

Татар, башкорт реклама слоганнарында кулланылган лингвистик алымнар без караган мисаллар белән генә чикләнми. Моннан тыш, текстның манипулятив функциясен көчәйтү өчен полисемия, сынландыру, персонификация кебек алымнарга да уңышлы мисаллар китерергә мөмин.

Татар һәм башкорт реклама текстларында конкуренциягә сәләтле слоганнар юк дәрәҗәсендә. Татарча һәм башкортча язылган слоганнарны гомуми реклама текстыннан аеру авыр, алар мөстәкыйль, тулы канлы реклама хәбәре буларак яшәми. Әлеге проблеманың төп ике сәбәбе: татар һәм башкорт реклама индустриясенең формалашу этабында булуы һәм милли копирайтинг өлкәсендә специалистлар әзерләүче үзәкләр юк.

**Әдәбият**

1. Ильин А.С. Реклама в коммуникационном процессе: курс лекций – М.: КНОРУС, 2013. – 142 с.

2. Низамов И.М. Татар рекламы һәм матбугат: Татар массакүләм мәгълүмат чараларында реклама текстын оештыру, язу һәм бизәүнең кайбер мәсьәләләре. – Казан, 1997. – 110 б.

3. Федоткин Л.Н. Социология рекламы – М.: Добросвет, 1995. – 388 с.

## ШӘКӘРІМ ЖӘНЕ МӘШҺҮР-ЖҮСІП КӨПЕЙҰЛЫ ЛИРИКАСЫНЫҢ ЕУРОПАЛЫҚ ЖАНР ҮЛГІЛЕРІ БОЙЫНША ЖІКТЕЛУІ

*Зейнолова Г., М. Қозыбаев атындағы Солтүстік Қазақстан мемлекеттік университеті, І курс магистранты*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., проф. Қадыров Ж.Т.*

Еуропалық үлгідегі өлеңдердің бірі – мұң өлеңдер, яғни элегия. Еуропа, ал нақтырақ грек әдебиетіндегі лириканың бір түрі – элегия. Элегия (грек. elegeia – жоқтау әні) – ойлы, мұңға толы, қаралы характерде жазылған музыкалық пьеса. Ежелгі Грекия мен Римде әр түрлі тақырыптағы элегиялар туып, алғашқыдаолар лирикалық, сатиралық және

жауынгерлік сипатта болды. Кейінірек мұң аралас лирик. ән-толғау түріндегі музыкалық туындылар ғана элегиялар деп аталды. Қайта өркендеу дәуірінде элегия еуропалық елдердің музыкасы мен әдебиетінде де тарала бастады. Жалпы, элегия өзінің мазмұны, идеялық тұрғысынан шығыс әдебиетіндегі лириканың бір түрі мінажатқа ұқсас келеді. Қазақ әдебиетіндегі мінәжат жанры туралы алғашқы толымды анықтама төл әдебиеттануымыздың негізін салушы А. Байтұрсынұлы қаламына тиесілі: «Діни дәуір мұңды-зарлы өлеңдеріне «мінәжат» деп ат қойған. Әуелде «мінәжат» деп ғұламалардың Құдайғаайтқан зары, арызы, наласы айтылған. Бара-бара зарлық, мұңлық мағынасынаайналып, зарлық өлең сияқты сөздер де «мінәжат деп аталатын болған [1: 52]», – дей келе, нағыз мінажатқа төмендегідей мысал келтіреді:

Он сегіз мың ғаламның,
Падишасы едің, құдайым!
Құдая саған жырлаймын,
Кешіргейсің, күнайым!
Өзіңнің нашар пендеңмін,
Әр жапаңа көнгенмін,
Ғашірбектей тағама
Медет берер күн бүгін [1: 150–151].

Автор бұл өлең шумағына «Ғашірбек соғысып жүргенде, байлауда тұрған Жүсіпбек құдайға, тауларға мінажат қып айтқан сөзі» деген түсіндірме береді. Түркі тектес халықтар поэзиясында Қ.А. Яссауи мінажаттарыносы жанрдың көшбасшысы деп бағалауымызға болады. Сопы-ақын өз хикметтеріндеАлла Тағалаға, оның пайғамбарларына деген сүйіспеншілік төгіп тұрады:

Жаппар ием, жеңілдеткіл таразыны,
Шапағатшы дос Мұхаммед бізге тілер.
Құлдарынарахым еткіл, иә, Алла,
Саясатты ұлы күнде не қылғаймыз? [2: 200].
Немесе:
Ол «Аласт биррабикум» деді құда,
«Қалу бала» деп аруақтар үн қатты.
Жылап келдік есігіңе, Жаратқан Алла,
Рақым етсең, жүз мың есе қуаныш болар [2: 254].
Иә, илаhи, ынсап бергіл жаным құрбан,
Жаннан безіп отқа түсті пәруаналар.
Көңіліме тоқтау салып, мал-мүлкімді шашайын,
Мал-мүлкін сарп етер диуаналар [2: 248].

Яссауи Алла Тағаладан ешқандай бақ пен байлық сұрамайды немесе басқа да пендеуи тілек тілемейді. Таза сопылық дүниетанымнан

туған шынайы жалбарыну. Ол үшін ең қымбат нәрсе – екінші дүние бақыты, одан қалса Хақ дидарын көру.

Ислам дінінің енуімен бірге төл әдебиетіміздегі сыйыну мәнді жырлар ислами реңкке ие болып, «Аллаға мінәжат» ұғымының аясына топтасты. Әлем әдебиетінің ежелгі нұсқаларында жиі кездесетін гимндер де мадақ пен мінәжаттың біріккен түрі әріалғашқы бастау-көрінісі болып табылады. Сондықтан кез келген ұлт әдебиетіндегі мінәжаттың даму жолы сол әдебиеттің алғашқы үлгілерінен бастау алып, бүкіл өн бойына созылып жатқан құбылыс десек, қателеспейміз. Ал жазба әдебиеттің біртұтас, тұлғаланған жанры ретіндегі мінәжаттың шығу төркіні исламдық араб поэзиясынан бастау алады. Басқа да бірқатар шығыстық жанрлар секілді исламдық мазмұндағы мінәжат түркі жазба әдебиетіне парсы поэзиясы арқылы сатылай енген. Әдебиеттанушы И. Жеменей парсы әдебиетінде «мінәжат» сөзінің бес түрлі мағынасы барекендігін көрсетеді: 1) біреумен сырласу, сыбырласу; 2) Алламен сырласу; 3) біреудің ішкіойын ұғыну; 4) сырласу; 5) Алладан тілеу.

Айта кету керек, қазіргі татар әдебиетінде халықтық мұң-шер өлеңдерінің үлкен бөлігі жалбарыну мәнді болмаса да, Аллаатынаайтылмаса да мінәжат жанрының туындылары ретінде қарастырылады [3: 93]. Мұндай өлеңдер қатарына дүниенің өткіншілігі мен алдамшылығын, айырылысудың ащы зарын өзек еткен мұңдасу сипатты туындылар және салауаттар мен хикаяттарды қамтитын діни мазмұнды жырлар жатады. Татар әдебиеттанушылары осындай жүйелеу әдісін негіз етеотырып, бірқатар зерттеулерді дүниеге келтірді. Классикалық араб поэзиясын зерттеген көрнектішығыстанушы Б.Я. Шидфар жанрлар жүйесінде белгілі бір иерархия байқалатынын айқындап, оларды «жоғарғы жанр», «орта жанр», «төменгі жанр» аталатын топтарға бөлген болатын [4: 122]. Осы бағыттағы ізденістерді дамыта отырып, әдебиеттанушы А. Шарипов 13–14 ғасырлардағы түркі-татар поэзиясы негізінде жоғары, орта және төменгі рангалы жанрларға анықтама беріп, саралап көрсетеді. Зерттеуші мінәжатты жоғары рангалы жанрға жатқызады: «Жанры высокогоранга − это поэтическая публицистика, т.е. произведения, направленные на самые высокие идеалы и на высокие цели. К этим жанрам относятся: таухид, касыда (особенно касыда-нагт, посвященная пророку Мухаммеду), мунаджат (где поэт обращается к Богу, просит у Всевышнего помилования), мадхия и марсия [5: 54]».

Шәкәрімнің «Өлген көңіл, ындынсыз өмір» атты өлеңі – осы жанрдағы туындының бірі. Ақын табиғаттың, елдің бір қуанышты өмірінің көрінісін беру арқылы оған қарама-қарсы өзінің халін суреттейді, яғни конрастты қолданады.

Көшейін деп қыбырлап,

Ел қыстаудан қозғалды.
Жаралы жүрек жыбырлап,
Жазылмай жалғыз сол қалды.

Көріп отырғанымыздай, ақын контрастты мейлінше шебер пайдаланған. Қыс бітіп, ел қыстаудан жайлауға көшіп барады, оның көңілділігі соншалық – жанған оттай көшіп барады. Әзілдескен қыз-бозбалалар, қар еріп, жан-жануар, табиғат оянуда, бәрі де көңілді, ал оған қарама-қарсы ақын көңілі қайғылы. Жүрек жай жүрек емес, «сұм», «жаралы» жүрек, ол жанданып, тіпті «өліп қалған», «оятса да тұрмайды. Көңіл де солай жанданған:«қабағын да аша алмайды». Осыншалық шуаққа, мейірімге толы елдің өмірі, табиғат – бәрі ол жүректі « oята алмайды», ол» қайта өшеді». Ол – ақынның қайғысының зор, ауыр екендігінің бір көрінісі. Міне, Шәкәрім бейнелеуіш құралдарды керемет әрі орынды қолданып, батыс әдебиеті үлгісіндегі жанрдың түрі – элегияның керемет үлгісін жасаған. Ақынның өзге элегия өлеңдері: «Өзіме», «Қош» т. б.

Мәшһүр-Жүсіп туындыларындағы мұң әйтеуір зәр төгу үшін емес, отарланған аз халықтың тағдырына алаң болудан лирикалық қаһарманда туған күрделі сезімді мұң мен қиналу, үміт пен торығуды қабат арқалауға бағындырылған:

Алды-арты дүиенің – қараңғы түн,
Үміт бар болар деген бір жарық күн.
Құр босқа текке айғайлап, зорықпайын,
Жаяудан шаң шықпайды, жалғыздан-үн.

Ақын елдің сол тұстағы өмірін қараңғы түнге балайды, жарқын болашақты «жарық күн» дейді. «Мыңмен жалғыз алыстым, кінә қойма» деген Абайға ұқсап, «жаяудан үн шықпайды, босқа зорықпайын» деп, өзінің жалғыз екендігін көрсетеді. Ақын өзінің мұңлы халіне салып, «тастан аққан бұлақтың да, маңыраған лақтың да зарлы үні бар» деп, паралеллизм арқылы сипаттайды. Ал ақылды, есті, сөзді ұғар адам дегенді ақын «құлақты» метанимиясымен көрсетеді. «Құлаққа – алтын сырға» мәтелін өзгеше етіп, «болсын сырға құлақтыға» деп қолданады. Яғни, біз жоғарыда Шәкәрімнің элегиясында табиғат, қоршаған орта мен лирикалық қаһарман көңілі арасындағы қарама-қарсылықты, контрасттық суретті байқасақ, Мәшһүр-Жүсіпте керісінше, табиғат, айнала бәрі де лирикалық қаһарманмен қосылып мұңлы, зарлы күйге ауысқан. Бұл екі ақынның өзіндік стильдерін, бейне, сезімді сипаттаудағы ерекшеліктерін аңғартады.

**Әдебиет**

1. Байтұрсынов А. Әдебиет танытқыш. Зерттеу мен өлеңдер. – Алматы: Атамұра, 2003. – 208 б.

2. Екімыңжылдық дала жыры. / Бас редактор Ә. Нысанбаев. – Алматы: Қазақ энциклопедиясы, 2000 – 752 б.

3. Жеменей И. Шәкәрім және парсы әдебиеті // Шәкәрім әлемі. – 2005. – № 3. – Б. 91–95.

4. Шидфар Б. Я. Образная система арабской классической литературы (VI–XII вв.). – М.: Изд. дом Марджани, 2011. – 320 с.
5. Шарипов А.М. Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе. – Казань: Изд-во Казанск. ун-та, 2001. – 587 с.

## ОТРИЦАТЕЛЬНЫЙ ОБРАЗ ЖЕНЩИНЫ В ФОЛЬКЛОРЕ СИБИРСКИХ ТАТАР: ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ

*Зиннатуллина Г., Тобольский пединститут им. Д.И. Менделеева (филиал) ТюмГУ, студент III курса*
*Науч. рук. – док. филол. наук, доц. Файзуллина Г.Ч.*

Фольклор сибирских татар, как и фольклор любого другого народа, является основой народной культуры. На сегодняшний день известно множество жанров «народного искусства», каждый из которых берет свое начало в глубокой древности. Помимо этого фольклор способен наиболее ярко продемонстрировать мировоззрение и менталитет народа. Его изучение поможет проследить историю возникновения и развития образа человека, его поведение в обществе и семье.

Актуальность нашего исследования продиктована современной ситуацией в народной культуре. Многие народные культуры, в том числе и говоры, находятся под угрозой исчезновения. Наиболее яркий пример – культура сибирских татар, находящаяся под охраной ЮНЕСКО.

Целью данного исследования является изучение отрицательного женского образа в языковом сознании сибирских татар посредством анализа фольклорных произведений.

Обратимся к «Словарю диалектов сибирских татар» Д.Г. Тумашевой для выявления лексем, связанных с женским образом. Таковыми являются нейтральные лексемы *кыс* «девушка», а также характерная только для сибирских татар лексема *пицә* «жена» (ср.: *бичә* в пермском говоре среднего диалекта татарского языка). Нередко используют синоним *өйгеше* (дом + человек, досл. ‘домашний человек’), который наиболее ярко подчеркивает статус сибирско-татарской женщины в обществе. Примечательно, что лексема *пицә* в некоторых районах Тюменской области имеет отрицательную окраску, отражая при этом снисходительное отношение к девушке.

В семейно-бытовых отношениях сибирских татар наибольшей критике подвергалась молодая невестка. Тому свидетельствуют сохранившиеся до сих пор такие паремии как *Килен кеше – ким кеше, йалцы пелән тиң кеше* (Невестка – недостаточный человек, наравне с батрачкой), существует вариация *Килен кеше – ким кеше, көцек пелән тиң кеше* (Невестка – недостаточный человек, наравне с щенком). Подобное отношение, возможно, объяснялось юностью жены, отсутствием жизненного опыта, каких-либо знаний. В сибирско-татарской культуре высоко ценится женская мудрость: *Ир иткән тә қатын – юк иткән тә*

*қатын* (И сделавшая мужа (человека из него) – женщина, и уничтожившая [мужа] – женщина).

В культуре сибирских татар отношение к женщине можно увидеть и в сюжетах сказок (йомак). Как и в паремиях, заключающих в себе элементы социальной и нравственной критики, подобную функцию реализует бытовая сказка. Йомақ «не только развлекает читателей, но и открыто учит тому, как следует себя в вести в какой-либо ситуации» [5: 44]. Так в сказке *Субу падыша* (Наивный падишах) резко возбраняется, осуждается неверность и прелюбодеяние жены. Жена своим поведением, обманом и глупостью не только унизила мужа-падишаха, но и погубила себя.

Образ неверной жены, бессердечной матери раскрывается в сказке *Қас* (Гусь), которая ради прелюбодеяния готова была погубить своих малолетних сыновей. Подобное поведение привело женщину к смерти через повешение.

В паремиях и бытовых сказках раскрывается социально-нравственная критика поведения девушки. Но наиболее ярко отрицательное отношение к женскому образу в целом можно увидеть в мифологии и волшебных сказках сибирских татар. В данном случае следует обратить внимание на номинации женских образов.

Необходимо отметить, что преимущественную часть образов злых сверхъестественных сил составляют именно женские. К таковым относятся, *албасты, әләмәце, мәцгәй, пицен, урман қортқайақ, йалмауыс, пери.* Подробнее рассмотрим некоторые из них.

Распространенный среди тюркских народов образ *албасты* у сибирских татар является женским духом болезни, который олицетворяется в образе старой женщины с распущенными волосами и длинными, доходящими до колен грудями, твердыми и острыми ногтями на пальцах рук. Это не только дух болезни, а прежде всего злой дух рожениц. Он нападает на беременных и особенно большой вред наносит роженице, давит, душит ее, стараясь умертвить ребенка в утробе матери [2: 1993]. Миф об этом духе до сих пор распространен в деревнях Вагайского и Тобольского районов Тюменской области. Помимо этого, *албасты* называют женщин, внешне неприятных, зачастую с длинными неухоженными волосами.

Образ *әләмәцес* мало изучен в фольклоре. Но исходя из сюжетов мифов *әләмәце* представляет собой старуху, которая крадет и убивает детей. *Әләмәце* появляется во время снежных буранов и вьюг. И сегодня во время сильных снежных бурь детей не выпускают из дома, пугая злой старухой.

Следующий образ злого духа именуется *мәцгәй, который* описывается как кровососущий злой дух женского пола в виде пылающего огненного шара, выходящий на охоту в вечернее или ночное время. Добычей такого духа становятся остатки крови в местах забоя скотины, а

иногда и запоздниввшиеся на улице люди. Злой дух возвращается домой к телу через трубу. На следующий день у женщины, в теле которой заключен демон, болит голова, живот, и ее тошнит кровью. Во вторичной номинации *мәцгәй* называют прожорливого человека [4: 36].

Образы *урман қортқайақ* и *йалмауыс* схожи по своему описанию. Обычно – это одинокая старуха, которая живет вдали от деревни. Қортқайақ, как правило, питается людьми, высасывает кровь, приносит прочие несчастья. В сказке «Урман қортқайақ» старуха обманом поселяется в доме семи осиротевших девочек и каждый день съедает по одной. Только две девочки смогли спастись от прожорливой старухи. А в сказке *Тимергендек* есть упоминание, что *қортқайақ* является матерью злого духа *йелбегена.*

Таким образом, в сибирско-татарской культуре отношение к женщинам ярко представлено в устном народном творчестве. Можно увидеть предвзятое отношение к молодой невестке, подвергавшейся необоснованной критике, что выражено в пословицах и поговорках. Данная тенденция прослеживается в бытовых сказках, обличающих неверных и глупых жен, тем самым указывая на нравственные и интеллектуальные изъяны женского образа.

Мифы и волшебные сказки сибирских татар отражают большую часть злых духов именно с женским образом. Помимо этого, лексемы, используемые для наименования нечистой силы применяются и для вторичной номинации, указывая на такие качества, как небрежность внешнего вида (распущенные растрепанные волосы, неухоженность, лишний вес, нечистоплотность), асоциальную манеру поведения (грубость, тупость, алчность, прожорливость).

**Литература**

1. Бакиева Г.Т. Пословицы и поговорки сибирских татар – Тобольск: Полиграфист, 2016. – 76 с.

2. Валеев Ф.Т. Сибирские татары: культура и быт. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1993. – 208 с.

3. Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1992. – 225 с.

4. Файзуллина Г.Ч. Образ человека в диалектной языковой картине мира: (на материале татарских народных говоров Тюменской области): автореф. дисс. … докт. филол. наук. – Казань, 2017. – 44 с.

5. Юсупов Ф.Ю. Сибирские татары из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар II: Йомаклар – сказки. – Казань: Магариф–Вакыт. 2016. – 887 с.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНӘ КАРАТА

*Ибләминова З., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Соңгы елларда татар телен укыту мәсьәләсе кискен калкып чыкты. Әлеге мәсьәләгә карата төрле матбугат чараларында да бик күп мәкаләләр

Ғылыми-қолданбалы бағытта нақты педагогикалық идеялар мен тұжырымдарға негізделген жаңа педагогикалық технологиялар жобаланады; мұғалімдерге педагогикалық технологияларды оқытудың бірнеше түрлерін бөліп көрсетуге мүмкіндік береді. Қазіргі әдістемеде технологиялардың бірнеше түрлері бар. Солардың ішінде орта оқу орындарының оқу үрдісінде қолдануға ұсынылатын бірқатар технологиялар бар.

Сондай педагогикалық технологиялардың бірі «Оқу мен жазу арқылы сын тұрғысынан ойлауды дамыту». Сын тұрғысынан ойлау

технологиясының негізгі мәні – шыңдалған ойлау, кез келген даму деңгейіне байланысты мәселелерге сын көзбен қарау; күрделі мәселелерді шешуге, аса маңызды, жауапты шешім қабылдауға құштарлық; үйрету мен үйрену бірлігінің, үйренудің қызығушылығынан тұратын, үйренушінің сеніміне негізделген құрылым.

Бұл бағдарламаның мақсаты барлық жастағы оқушыларының кез келген мазмұн, түсінікке сыни тұрғыдан қарап, екі ұйғарым бір пікірдің біреуін таңдауға сапалы шешім қабылдауды осы сабақтарда үйренеді. Сын тұрғысынан ойлау – сынау емес, шыңдалған, бірін-бірі толықтырған ойлау десек қателеспейміз. Сын тұрғысынан ойлау дегеніміз – ой қозғай отырып, оқушының өз ойымен өзгелердің ойына сыни қарап, естігенін, білгенін талдап, салыстырып, реттеп, сұрыптап, жүйелеп, білмегенін өзі зерттеп, дәлелдеп, тұжырым жасауға бағыттау, өз бетімен және бірлесіп шығармашылық жұмыс жасау [3]. Оқушылардың осындай қабілеттерін дамытуға әр түрлі әдіс – тәсілдерді қолдануға болады.

Білім берудің сапасын жақсарту мақсатында «Сын тұрғысынан ойлау» технологиясын өз сабақтарымда қолданып жүрмін. Сын тұрғысынан ойлау технологиясының мені қызықтырғаны баланың өзі ізденіп дәлелдеуі. Ол бұрын тек тыңдаушы болса, енді ізденуші, ойланушы, өз ойын дәлелдеуші, ал мұғалім осы әрекетте бағыттаушы, ұйымдастырушы. «Оқу мен жазу арқылы сын тұрғысынан ойлауды дамыту» технологиясымен жұмыс жасау кезінде бұл сабақтар баланың танымдық белсенділігін арттыруға, өз бетінше білім алуға, шығармашылығын қалыптастыруға ықпал етеді, оқушылар - оқудың қызықты, ұжымды бірлесіп жұмыс жасауға үйрететіндігін, білімнің тереңдігі әрі тиянақтылығы артатындығын байқалады.

Бұл стратегияларды қолданудағы менің міндетім – баланың өзіне деген шығармашылық қабілетін дамыту, өзін тұлға ретінде сезінетіндей мүмкіндік ашу. Өзін тұлға ретінде сезінген бала әрқашан өмірде өз жолын таба алады.

Дәстүрлі сабақ пен сын тұрғысынан ойлау технологиясы арқылы өткізілген сабақты салыстыра отырып, мынадай қорытынды жасауға болады:

Дәстүрлі сабақта:

– күнделікті қолданылатын әдіс-тәсілдерден оқушылар жалығады, қызығушылығы төмендейді;

– оқушылар бірден кірісіп кете алмайды, шулап кетеді;

– оқушылардың белсенділігі орташа деңгейде болады;

– оқушының жеке жауапкершілігі төмен;

– кейде берілген тапсырмаларды жасауға үлгере алмайды.

Сын тұрғысынан ойлауды дамыту сабақтарында:

– сын тұрғысынан ойлау – жеке тұлғаның танымдық процестеріне, еріктік процестеріне, сезімдеріне, эмоцияларына әсер етеді.

– бір-бірінің пікірін тыңдау, сыйлауға ынтымақты қарым – қатынастың негізі қаланды;

– мұғаліммен еркін сөйлесіп, пікір алмастыруға үйренеді;

– өзін-өзі, бірін-бірі бағалауға;

– өз ойын ашық, еркін айтуға, пікір алмасуға, достарының ойын тыңдай;

– отырып, проблеманы шешу жолдарын іздей отырып, қиындықты шешуге көмектесуге дағдыланады;

– өзін жеке дара тұлға ретінде тануға жол ашуға;

– белсенді шығармашылықты ойлауға негіз қаланды.

Нәтижесінде оқушылардың белсенділігі артып, жан – жақты дамиды, пәнге деген қызығушылықтары арта түседі.

**Әдебиет**

1. Уәли Н. Қазақ сөз мәдениетінің теориялық негіздері: филология ғылым. докт. ... диссер. – Алматы, 2007. – 328 б.

2. Қабдықайырұлы Қ. Оқытудың педагогикалық жаңа технологиясы: Оқу құралы. – Алматы: РБК, 1999. – 254 б.

3. Ташенова А. Сын тұрғысынан ойлауды оқу мен жазу арқылы дамыту // Білім-Образование. – 2006. – №2. – Б. 15–18.

## ИСТОРИЯ ШКОЛЫ – ЭТО ИСТОРИЯ СТРАНЫ

*Кольчанова Ю., Больше-Фроловская СОШ Буинского р-на, X класс*

*Рук. – Исмагилова Г.Т.*

Больше-Фроловская школа Буинского муниципального района впервые открыла свои двери в далёком 1932 году (на то время семилетняя школа), не закрывала их и во время Великой Отечественной войны. Школа по праву гордится своей историей.

Постройка школы была осуществлена на деньги Веры Николаевны Фигнер (дочь мирового судьи из Тетюшского уезда Казанской губернии, известная русская политическая деятельница), с которой поддерживал связь Лаврентьев И.Е. (в то время библиотекарь Тетюшского уезда), и Михаил Иванович Анисимов («энергичный крестьянин… Он очень увлечен мыслью о сушилке» (из письма Фигнер Лебедевой)), секретарь сельскохозяйственного кредитного общества. После октябрьской революции, уже в преклонных летах, Вера Николаевна несколько раз ездила в села Тетюшского уезда, помогала школам, детдомам и просто людям, нуждающимся в участии. В селе Большое Фролово она останавливалась в семье учителя Ивана Егоровича Лаврентьева. Он и его жена Пелагея Андреевна были энтузиастами нового строя. Иван Егорович, кроме непосредственных своих учительских обязанностей, заведовал библиотекой. Несмотря на большую семью – семеро детей, – Поленька вела еще курсы ликбеза, работала в сельсовете.

Письма и другие архивные документы дают представления о том, как заботилась В. Фигнер о своих земляках. Отрывки из писем Пелагеи Андреевны Лаврентьевой Вере Николаевне Фигнеро строительстве новой школы:

«… Сегодня коллективы начали ломать поповский дом и сегодня же перевезут его на площадь, а с завтрашнего начинают строить. Молодой избач (Сергей, старший сын Лаврентьевых) дело наладит живо, будет у нас своя читальня… (15 апреля 1929 года)».

«Ура! Милая Вера Николаевна! Ведь у нас во Фролове теперь есть по милости молодого избача изба-читальня, клуб, библиотека. Сегодня в нем закончат класть голландки. Хотя залезли рублей на 70 в долг, но как-нибудь от спектаклей, где субботниками, актив заработает. В день урожая будет торжественное открытие избы-читальни. Вы, дорогая, верно, уже будете у нас на торжественном открытии школы... дождемся этого дня, что наша новая школа вберет в себя и старых, и малых, и виновницу ее сооружения. Ведь так будет? Теперь ежедневно по очереди работают по 30-40 мужчин и женщин - копают под фундамент канавы в полтора метра глубины, грунт очень твердый, сколько переломали одних лопат, хорошо, что кузнецы оправляют их бесплатно (постановление сельсовета). Завтра канавы рыть кончают. Пришли уже каменщики класть фундамент. Население работает бесплатно, горячее участие принимают колхозы (1 октября 1929 года)».

«... В воскресенье или 5-6-го будет открытие школы, вот уж тогда поикаете и Вы, милая Вера Николаевна! Ну уж, достанется Вам! Ведь это Вы заставили построить у нас такую школу, вложили в нее свои средства. Предисполкома Соловьев говорил, что большой портрет Ваш готов для школы».

И так, школа открыла свои двери ученикам. В связи с модернизацией промышленности и сельского хозяйства вышел декрет об обязательном семилетнем образовании. В 1932 году в школу были направлены все холостые парни и девчата в возрасте до 20-ти лет. Старожилы хорошо помнят, как за парты вместе с ними, малолетками, сели чубатые молодцы, которые пришли к школе с гармошками и самокрутками в зубах.

Не остались без образования и остальные неграмотные колхозники. По воспоминаниям дочери первого директора школы Александра Егоровича Лаврентьева (брата библиотекаря И.Е. Лаврентьева) Авроры, хорошисты-старшеклассники ездили по деревням для проведения ликбеза с неграмотными.

### Жизнь школьников

Школа стала не только образовательным учреждением, но и культурным, досуговым центром. Здесь соединяются и основное, и дополнительное образование. Насыщенной была жизнь школьников и в свободное от уроков время. Досуг часто приходилось подчинять требованиям эпохи, и он приобретал не только развлекательный, но и общественно значимый характер.

В большом почете в школе был спорт. Особенно популярны малые школьные спартакиады, победители которых участвовали в городских и областных соревнованиях. В выходные дни, в любую погоду, пионеры брали рюкзаки и отправлялись в поход, зажигали костры, пели пионерские песни.

Многие ребята принимали участие в самодеятельности. Учащиеся инсценировали и обыгрывали события, происходящие в стране и эпизоды из школьной жизни. Вообще учащиеся того времени отличались большой самостоятельностью. Это была эпоха первых пятилеток, характерной чертой которых был высокий энтузиазм людей.

**Директора школы**

С 1932 по 1961 гг. директором Больше-Фроловской школы был Александр Егорович Лаврентьев. С 1961 года по 1963 год школой руководил Журавлев Николай Порфирьевич. С 1963 года по 1967 год – Мясников Петр Яковлевич. С 1967 года по 1973 год – Никашин Герман Андреевич. С 1973 года по 1975 год – Ионов Михаил Иванович. С 1975 года по 1982 год – Хусаинов Фатих Мустафинович. С 1982 года по 1991 год – Акмалдинов Фариз Фарукович. С 1991 года по 2012 год – Руслова Надежда Павловна. С 2012 года по 2015 год – Ханбиков Ильгиз Фаридович. С 2015года по 2017 год – Садыков Ленар Муслыхович. С 2017года по 2018 год – Мухаметзянов Марат Ильшатович. С 2018 года – по сей день Кавеев Рамиль Наилевич.

Да, менялись директора. Каждый из них старался привнести в школу что-то новое, передовое.

## МИН ҮЗЕМНЕҢ НӘСЕЛЕМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ

*Куакалова Г., беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе, IX сыйныф*

*Җит. – Мтеева З.Ш.*

Гөнаһсызга җиргә кан-яшь түгелмәсен,

Буыннарны бәйләп торган нәсел җебем өзелмәсен!

Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт белән караганның гына киләчәге бар. Шәҗәрәңне, нәсел агачыңны белү, эзләү – барыбызның да изге бурычы.Борынгы заманнардан ук татар халкында ата-баба нәселен, җиде буынны белү изге бурыч булып саналган. Мөселман булган кеше үзенең әти һәм әнисе ягыннан булган җиде буын бабалары рухына дога укырга тиеш була. Шуңа күрә дә ил агалары – аксакаллар үзләренең нәсел агачын төзегәннәр һәм үз ыруларының кабатланмас тарихын язып барганнар, шәҗәрәсен төзегәннәр, киләчәк буынга ядкарь – истәлек калдырганнар. Кеше җирдә үзенең кыска гына гомере эчендә барысына да өлгерергә, барын да таныргa, белергә, изгелекләр эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне җиңеп чыгарга һәм, иң мөһиме, үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш, аралашып яшәүне ныгыту өчен дә кирәк. Нәсел-ыру тарихын өйрәнү, ягъни үз шәҗәрәсен төзү – һәр гаиләнең изге бурычы.

Без нинди нәсел кешесе? Кем безнең бабаларыбыз? Алар нинди кеше булган? Кешеләргә нинди файда китергәннәр? – дигән сораулар туды миндә.

Минем эзләнү-тикшерү эшем – "Горурланам мин үземнең нәселем белән". Максатыма ирешер өчен күп эзләнергә, сорашырга, нәселебезне тикшерергә туры килде. Эзләнгән, сорашкан саен яңа һәм кызыклы мәгълүматларга юлыктым. Ул мәгълүматлар әле тикшерүне көтәләр.

Сүземне буыннар чылбырын тоташтыручы Ялалетдин бабам турында сөйләүдән башлыйм. Ул 1819 елда крестьян гаиләсендә туган. Кызганычка каршы, жиденче буын бабам турында мәгълүматлар бик аз. Бары шунысы билгеле була, бу нәсел элек-электән укымышлы, муллалар, мөгаллим һәм авылдагы халыкның яклаучылары булып танылганнар.

Алтынчы буын бабам-Шәрәфетдин. Бабам 1837 елда урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.Заманына күрә ул укымышлы булган, берничә тел белгән. Үзендә төрле китаплар саклаган, кешеләрне дәвалау белән шөгыльләнгән. Халык аны бик яраткан, аның янына киңәш сорап килгән. Шәрәфетдин бабамның да бер улы барлыгы гына билгеле.

Бишенче буын бабам – Садретдин (Садрый) бабай. Ул 1858 елда туа.Указлы мулла була.Раскулачивание тотынгач, бабай куркып үзенең указын качыра. Авылда аны ратканга, берәү дә аның указы барлыгын белгертми. Заманнар тынычлангач, бабай указын күпме генэ эзләсә дә таба алмый. Бары 1951 елда әтиемнең әтисе минем дәү әтием иске сарайны сүтеп яңаны ясаганда указ табыла, ләкин аның язмышы бүгенге көндә билгеле түгел.

Садрый бабай куаклар үстерү һәм аларны сату белән шөгыльләнә. Ул авылдан-авылга куак ал дип йөргәнгә,аны куакал килә дип каршы алганнар. Шуңа аның кушаматы куакал булып кала.Безнең авыл Чуашия җирлегенә урнашу сәбәпле, чуаш халкы белән гомер-гомергә тыгыз элемтәдә яшәгәннәр."Эс мен ятлы?" – дигән сорауга бабам "Эб куакал" дигән. Шулай итеп аларның фамилияләре Куакалов дип метрикәгә язылган.

Дуртенче буын кешесе ул Шәйхелислам бабам.

Олы уллары Абзалетдин авылның чибәре Камария әбине өйләнгән дә бәхет эзләргә алтын приискасына киткән. Бабай кайтып-китеп йөргән арада әбием берсеннән-берсе матур, акыллы биш бала таба.

Галиябануы Казан дәүләт педагогик институтын бетереп Аликово районында укытучы булып эшли. Бу бәхетле гаиләдә бер кыз, ике ул үсә.

Илханиясе дә апалары кебек укытучы һөнәрен сайлый һәм бүгенге көндә Казан шәһәренең №4 гимназиясендә директор хезмәтен башкара. Аларның бердәнбер уллары Рамиле үсеп җитә.

Төпчекләре Илханнары авылда төп йортта кала. Бу бәхетле гаиләдә игезәк балалар туа-кызлары Зөлфия һәм уллары Зөфәр. Зөлфия бу нәселнең төп һөнәре булган укытучы һөнәрен сайлый.

Өченче буын бабам минем иң ратканым, шуның тәрбиясендә үскәнмен һәм сагынып яшәгән бабай Зиатдин бабам.

Бабам белән әбием балаларыннан уңалар. Минем әтием Зиатдин бабам белән әбиемнең өченче балалары..Мин үзебезнең гаиләне бик бәхетле дип уйлыйм.Чөнки янәшәмдә минем өчен якын булган әти,әнием бар. Әнием Зелфия мәктәптә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Без гаиләдә өч кыз үстек.

Шәйхелислам бабайның икенче баласы – Минебиян әби. Сабирулла бабай белән дүрт бала үстерәләр. Сабирулла бабай һәм Минебиян әби мәктәптә укытучы булганга күрәдерме, балалары да әти-әниләренең юлын сайлыйлар.

Нәсел агачы – шәҗәрәне барлаганда, зур горурлык хисләре кичердем.. Гомерләрен мөгаллимлек эшенә багышлаган, бездә дә бу эшкә мәхәббәт уяткан әби-бабаларыбызның, абый-апаларыбызның тормыш юллары миндә соклану һәм кызыксыну уятты. Дистә еллар буена эстафета булып күчә барган әлеге һөнәргә безнең гаиләнең мәхәббәте әле дә сүнми, сүрелми. Һәм мин үзебезнең нәкъ менә шушы олугъ, хөрмәтле, затлы нәселдән булуыбыз белән чын күңелдән горурланам.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: тиккә генә әби-баба нәселнең нигезе, ата-ана гаилә тоткасы,бала-чага нәсел дәвамчысы дип әйтмәгәннәр. Әйе, һичшиксез, бала иң элек әти-әни үрнәгендә тәрбияләнә. Бала нинди генә нәселдән булуга карамастан,үз гаиләсенең тарихын белергә тиеш.Кешеләргә карата мәрхәмәтле булсак, әти-әниләребезне хөрмәт итеп тәрбия кылсак, милләтебез өчен файдалы эшләр башкарсак, бабаларыбызның изге туфрагын кадерләп сакласак, тормышыбыз матур һәм мәгънәле булыр дип ышанам.

## Ф. ӘМИРХАННЫҢ «ХӘЯТ» ПОВЕСТЕН ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Латипова Ч., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Ф. Әмирханның әдәби мирасында “Хәят” повесте (1911) – укучылар тарафыннан иң яратылып укылган әсәрләрнең берсе. Язучының “Хәят” әсәре психологик кичерешләргә бик бай. Чынбарлыкның романтик сурәтләүләр белән оста итеп үрелеп баруы, ягъни реаль тормыш белән хыялый дөньяның янәшә яшәве һәм бәрелешүе – болар бар да сюжетны мавыктыргыч итеп төзергә ярдәм иткән.

Уку-укыту процессына яңа стандартлар үтеп кергәч, укыту программаларына да үзгәрешләр кертелде. 2016 нчы елга кадәр Ф. Әмирханның “Хәят” повесте 10 нчы сыйныфта өйрәнелә иде. ФДББС гамәлгә кергәннән соң, Д.Ф. Заһидуллина һәм Н.М. Йосыпова тарафыннан төзелгән “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”да [1: 18] әлеге әсәр 9 нчы сыйныф укучылар өчен тәкъдим ителгән әсәрләр минимумы исемлегендә тора. Шулай ук Ә.М. Закирҗанов һәм Г.М. Фәхретдинова

тарафыннан тәкъдим ителгән авторык (эш) программасына күз салсак [2: 87], әлеге әсәр 9 нчы сыйныф укучыларына тәкъдим ителә.

Мәктәп системасындагы яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары программаларны да яңарту проблемасын көн тәртибенә куйды [3: 53]. 2016 нчы елда нәшер ителгән дәреслеккә күз салсак, Ф.Әмирханның "Хәят" повесте 9 нчы сыйныф әдәбият дәреслегенә кертелгәне ачыкланды. Татар мәктәпләрендә 9 нчы сыйныф дәреслеге Ә.М. Зәкирҗанов һәм Г.М. Фәхретдинов тарафыннан төзелгән. Бүгенге көндә татар мәктәпләре әлеге дәреслек белән укыйлар һәм ул шулай ук дәүләт дәреслекләре исеменә кертелгән.

Шунысын әйтеп китәргә кирәк, дәреслектә Ф. Әмирханның биографиясе бөтенләй бирелми. Бу аңлашыла да, чөнки татар мәктәбендә белем алучылар аның иҗаты белән 5 нче һәм 8 нче сыйныфта инде танышып китәләр. 9 нчы сыйныф та исә язучының тормыш сукмаклары тәкъдим ителгән сораулар буенча искә төшерелә.

Дәреслектә Ф. Әмирханның тәнкыйди эшчәнлеге турында берникадәр мәгълүмат бирелеп китә. Аңа Т.Ш. Гыйлаҗевның мәкаләсен уку, тикшерү һәм анализлау ярдәмендә ирешелә. Ә ул язма "Ф. Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә төп тенденцияләр" дип атала. Әлеге мәкаләдән соң шулай ук сораулар һәм биремнәр бар.

Әсәрне укырга керешкәнче, "Хәят" повестен укырга әзерләнәбез" дигән өлеш өстендә эш оештырыла. Укучыларга шулай ук сораулар тәкъдим ителә. Алар аша Ф. Әмирханның узган сыйныфта укылган әсәрләрен искә төшерү, анда күтәрелгән проблемаларны ачыклау күздә тотыла. Әлеге сораулар әсәрне укырга әзерли һәм аларны проблемалы сораулар дип тә карарга була.

Повесть өзекләрен укып чыкканнан соң, "Хәят" повестена анализ ясала. Әсәрнең жанры, темасы, проблемалары, конфликтлар, идея, сюжет элементлары билгеләнә. Шуннан соң Хәят образына характеристика бирелә.

Әлеге эш төрләреннән соң, сораулар һәм биремнәр бүлекчәсе урнаштырылган. Алар шулай ук берничә төркемгә бүленеп бирелә. Беренче төркем тулы анализ, нәтиҗәләр ясауны максат итсә, икенче төркем сораулар исә мөстәкыйль уйланып, эзләнеп җавап бирүне күздә тота. Өченче төркемдә исә индивидуаль эш өчен биремнәр тәкъдим ителә.

Дәреслектә шулай ук Г. Ибраһимовның "Хәят" повестена рецензиясе урнаштырылган. Аны бәяләү юнәлешендәге сораулар язманы аңлау, авторның фикер сөрешенә төшенү нияте белән тәкъдим ителгәннәр. Алынган мәгълүматны гамәлдә нығыту максаты белән рецензияны ничек язу турында белешмә бирелә. Рецензия белән аннтотация, фикер әйтү арасында аерымлыклар билгеләнә. Дәрестә Г. Ибраһимов рецензиясе үрнәгендә һәм тәкъдим ителгән сораулар ярдәмендә "Хәят" повестена рецензия яздыру көтелгән нәтиҗәләргә китерә.

Күренә ки, яңа буын стандартларына нигезләнеп төзелгән дәреслектә укучыларга төрледән-төрле гамәли эшләр һәм биремнәр тәкъдим ителә. Алар укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерүгә корылган. “Хәят” повестена ике сәгать бирелгәндә дә, икенче дәресне нәкъ менә шушы сораулар һәм биремнәр белән эшләүне оештырырга була. Укучылар өйдә әсәрне укып килеп, дәрестә төркемнәрдә эш, дәрес-диспут, дәрес-әңгәмә, дәрес-дискуссия формасында алып барырга мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

1. Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан авторлык (эш) программасы. / Ә.М. Закирҗанов, Г.М. Фәхретдинова. – Казан, 2014. – 56 б.

2. Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1–11 нче сыйныфлар / [басма өчен Г.Р. Галиуллина, Д.Ф. Заһидуллина җаваплы ]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 85 б.

3. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 311 б.

4. Шакирова Т.Р. Фатих Әмирхан: тәрҗемәи хәле. Истәлекләр. Әсәрләр. Анализ үрнәкләре. Дәрес эшкәртмәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010 – 366 б.

## Г. ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕНЫҢ ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ

*Лотфуллина Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Сәйфулина Ф.С.*

Әдәби музейлар – олы әдәби мирас калдырган, әдәби барышка сизелерлек йогынты ясаган, үзеннән соң яңадан-яңа буын шагыйрьләр тәрбияләрлек традицияләр формалаштырган талантлар тормышына, иҗатына багышлап төзелә. Аларның бурычы – шагыйрь яки язучы шәхесе белән бәйле истәлекләрне, биографик документларны, алар яшәгән заманның рухи байлыкларын саклау.

Башкалабызда шундый истәлекле хәтирәләр саклаган урыннар байтак. Шуларның иң кыйммәтлеләре – шагыйрь Г. Тукай исеме белән бәйле.

Белгәнебезчә, Казанда Тукай исеме белән бәйле урыннар күп. Шуларның берсе – шәһәрнең Тукай урамы һәм аның әйләнә-тирәсе. Бу урыннар шагыйрьнең журналист һәм публицист буларак күпкырлы эшчәнлеге белән бәйләнгән. Моннан ерак түгел ул атаклы «Печән базарында» сатирик әсәрләренә прототиплар тапкан. Бирелә «Шәрык клубы»нда татар яшьләре кичәләр уздырган. 1910 елда Тукай да монда үзенең «Халык әдәбияте» лекциясен укыган һәм рухланып: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул...» [2: 26], – дип белдергән. Тукай урамыннан тар тыкрыклар буйлап шагыйрьнең яраткан урыны – Кабан күле ярына чыгарга була. 1913 елның 15 апрелендә шушы ук урамнан Тукайны соңгы юлга озату- кайгылы митингы узган.

Казаныбызның Тукай урамындагы тарихи йорт – безнең эзләнүләребезнең үзәгендә торачак. XIX гасыр азагы – XX гасыр башы архитектура истәлеге булган әлеге бинада халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның Әдәби музее урнашкан. Иске Татар Бистәсенең күрке булган әлеге бинаны халыкта “Шамил йорты” дип тә йөртәләр, чөнки 1882–1906 елларда монда Дагъстан халкының Милли азатлык көрәше лидеры имам Шамилнең уртанчы улы Мөхәммәт Шаффа Шамил яшәгән. Бу йортны аның каенатасы – атаклы татар бае, беренече дәрәҗәдәге сәүдәгәр Ибраһим Аппаков узенең 18 яшьлек кызы Бибимәрьямбануга бирнә буларак бүләк итүе билгеле.

Тукайның үзе әлеге йортта булуы турында мәгълүмат сакланмаган. Язучы, публицист Рафаэль Мостафин фикеренчә, байларны бик өнәп бетермәгән Тукай бу йортка аяк басмаган. Шагыйрь, чынлап та, үз чорындагы дворян шагыйрь-язучылар кебек яшәмәгән, гомерен күпчелек кунакханә номерларында уздырган. Шул сәбәпле, шагыйрьнең шәхси әйберләре дә бик аз сакланган.

Музей экспозициясе, анда тәкъдим ителгән әйберләр Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты турында җентекле мәгълүмат бирә: шагыйрьнең бала чагы; әдип булып формалашкан Җаек һәм Казан чоры еллары; шагыйрьнең Түбән Новгород, Сембер өязе, Әстерхан, Өфе, Петербург калаларына булган сәяхәтләре; Тукайның шәхес һәм язучы буларак дөньяга танылуы турында сөйли. Музейда, шулай ук, Г. Тукай яшәгән чор, аның даирәсеннән булган аерым шәхесләр турында да мәгълүмат алырга мөмкин.

Шунысы да кызыклы, әлеге музейда XIX–XX гасырлар чигендәге Казан тормышын күзалларга мөмкинлек бирүче экспонатлар байтак. Аларның күбесен Милли музей фондлары һәм истәлек әйберләре тәшкил итә. Болар барысы да шагыйрьнең формалашу, үсеш даирәсен күз алдына китерергә, иҗат мирасын бөтен тирәнлеге белән аңларга ярдәм итә. Музейда шагыйрьнең фотоархивын, Тукай язышкан гәҗит һәм журналларның төп нөсхәләрен, төрле телләрдә чыккан әсәрләрен күрергә була.

Аерым игътибарга лаек әйберләрдән Тукайның шәхси әйберләре: фаянс котыйчык (шкатулка) – апасына беренче кул хакыннан алган бүләге; кара бәрхет түбәтәй; каләм савыты (Питербургтан 1912 елда алып кайткан булган); шагыйрьнең юл кәрҗине; күлмәк запонкалары (көмештән) – дусларының бүләге; шагыйрьнең вафатыннан соң алынган йөз маскасы.

Музей Тукай белән бәйле татар рухын ачу өчен хезмәт итәрлек дәрәҗәдә итеп 1996 елда үзгәртелеп эшләнде. Соңгы еллардагы реставрация – әлеге музейның халыкка хезмәт итү мөмкинлекләрен тагын да киңәйтте, техник чаралар ярдәмендә шагыйрь иҗатын караучыга, тыңлаучыга үтемле итеп җиткерү мөмкинлеген тудырды.

Музей экспонатларының һәм гомумән эшләнешенең үзенчәлеге шунда: ул полифоник яңгырашлы, катлаулы һәм катлы-катлы эчтәлеккә ия итеп төзелгән. Монда Тукайның биографиясен күзалларга теләп кигән кешеләр аның тормышын шул заман белән бәйләнештә таба, рухын тоярга ниятләүчеләргә әдипнең җанын сиземләрлек халәт һәм экспозиция материаллары да җитәрлек, иҗат манерасын һәм үзенчәлекләрен эзләүчеләргә дә киң мөмкинлекләр ачылган, замандашлары һәм Тукай, шигърият һәм Тукай, фән һәм Тукай, журналистика һәм Тукай, сәнгать һәм Тукай, шагыйрьнең идеаллары кебек шактый күп һәм катлаулы темалар ачыла. Әлеге бай материалны кызыксыну тудырырлык итеп тыңлаучыларга җиткерү, экспозиция материалларын күрсәтә һәм аңлата белү – экскурсия алып баручылар кулында.

Г. Тукай әдәби музее эше – татар милли-мәдәният дөньясының бер учагы, шагыйрь исемен мәңгеләштерү юнәлешендәге эшләрнең олы, нәтиҗәле бер юнәлеше.

**Әдәбият**


1. Нәгыймуллина Р. Кыйммәтле ядкярләр // Шәһри Казан. – 1913. – 15 гыйнвар.
2. Тукай Г. Әсәрләр. 4 томда. Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1955. – 376 б.


## МӘКТӘПТӘ ДИФФЕРЕНЦИАЛЬ ЯКЫН КИЛЕП УКЫТУ АЛЫМЫН КУЛЛАНУ


*Мананова М., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – пед. фән. док., проф. Харисов Ф.Ф.*


Дифференциаль якын килеп укыту ул – укучыларны төрле группаларга гына бүлү түгел, ә аларның белем дәрәҗәсе, сәләте бунча туплау да. Дәресләрдә дифференциаль биремнәрне куллану уңай нәтиҗәләр бирә. Балаларда белемгә мәхәббәт уятуда, аларның бер-берсеннән читенсенүен кисәтүдә, бер эштән икенче эшкә күчү тизлеген арттыруда, балаларны ялыктырмауда, белем һәм күнекмәләрне системалаштыруда укытуны дифференциальләштерүнең роле зур. Мондый эш укучыларның акыл дәрәҗәсен үстереп кенә калмый, ә аларны психологик яктан да камилләштерә һәм тәрбияли.

Дифференциаль якын килеп укыту алымының отышлы яклары:

– укуның мотвация дәрәҗәсе барлыкка килә;

– көчле укучыларга да, белем дәрәҗәсе түбәнрәк булган укучыларга да ярдәм итү мөмкинлеге туа;

– предметны начаррак үзләштерүче укучылар белән эшләү мөмкинлеге күпкә арта;

– көчле укучыларның күбрәк белү теләге үсә.

Дифференциаль якын килеп укыту алымын дәреснең төрле этапларында кулланырга мөмкин. Мәсәлән, өйгә эш бирү этабын карыйк. Бу алым начаррак укучы балага да гомуми белем һәм күнекмәләрне үзләштерү мөмкинлеген бирә. Дифференциальләштерелгән биремле өй

эше яхшы укучыларга югарырак баскычка күтәрелергә ярдәм итә. Өй эшләре төркемләп бирелә. Көчле укучылар өчен эзләнү характерындагы биремнәрне тәкъдим итәргә мөмкин.

Дифференциаль якын килеп укыту алымын дәреснең яңа теманы аңлату этабында да кулланырга була. Яңа тема барлык укучыларга да бер төрле аңлатыла. Күрсәтмә материал күбрәк кулланылган саен, укучы яңа теманы яхшырак үзләштерә. Дәрескә нәтиҗә ясаганда көчле укучыга үзлегеннән кагыйдә формалаштыру биремен йөкләргә мөмкин. Һәм начаррак үзләштерүче берничә укучыдан моны кабатлатырга мөмкин. Укучыларга яңа теоретик материал әзер рәвештә бирелми, шуның нәтиҗәсендә теоретик биремнәр укытуны проблемалы итә.

Дифференциаль якын килеп укыту алымын дәреснең ныгыту этабында да отышлы кулланып була. Укытучы әлеге этап өчен биремнәрне алдан яхшылап уйларга тиеш. Моның өчен ярдәмгә схемалар, тест биремнәре, сингапур укыту методлары һ.б. килә.

Дәрестә дифференциальләшкән мөстәкыйль эшләр дә уздырырга була. Бу очракта информацион компьютер технологияләре дә эшкә җигелә. Компьютерда “йомшак” укучыларга тест биремнәрен үтәргә, ә “көчле” укучыларга үзләренә тест биремнәрен төзергә тәкъдим итәргә мөмкин.

Педагогик әдәбиятта “эчке” һәм “тышкы” дифференциация төшенчәләрен аерып күрсәтәләр. “Эчке” дифференциация ул – укыту процессын дәрес барышында бер сыйныфта укучы балаларның белем дәрәҗәләрен, сәләт, омтылышларын, шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру дигән сүз. Бу очракта дифференциация индивидуализация белән охшаш була. Ә “тышкы” дифференциация булганда төрле әзерлектәге укучылар шәхси күрсәткечләре: сәләтләре, кызыксынулары һ.б. буенча берничә төркемгә берләшәләр.

Рус балаларын татар теленә өйрәткәндә дифференциаль якын килеп укыту алымын куллануны укучыларга төрле дәрәҗәдә якын килү дип аңларга кирәк. Әлеге алым һәр укучыга үз белем дәрәҗәсенә туры килердәй биремнәр белән эшләргә мөмкинлек бирә. Әдәби уку предметы буенча берничә мисал карап үтик.

1 нче бирем (“көчле” укучылар өчен). Әлеге төркемдәге һәр укучыга картинкалар таратыла. Укучы картина буенча кечкенә хикәя төзеп сөйләргә тиеш (5–7 җөмлә).

2 нче бирем (уртача белем дәрәҗәле укучылар өчен). Шулай ук картинкалар таратыла һәм алар артында сораулар тәкъдим ителгән була. Укучы шул сорауларга телдән җавап бирә белергә тиеш.

3 нче төркем (“йомшак” укучылар өчен). Укучыларга фигыльләр язылган карточкалар таратыла, алар бу сүзләрне тәрҗемә итәргә тиеш.

Чит телләрне өйрәнү лексикага өйрәтүдән башлана. Татар теленә өйрәткәндә дә шул ук хәл. Лексикага өйрәтүне дә өч төрле юнәлештә эшләргә мөмкин. Өйдә өйрәнергә бирелгән сүзләрне өч төркемдә өч төрле итеп тикшерергә мөмкин. Беренче төркем укучылар сүзләрне русчасын да, татарча тәрҗемәсен дә үзләре яза (хәтер диктанты кебек). Икенче һәм өченче төркемдә укучылар өчен сүзләр рус яки татар телендә бирелә, алар тәрҗемәсен генә язарга тиеш.

Текст белән эшләгәндә дә төрле дәрәҗәдәге биремнәрне башкартырга була.

1 нче төркем өчен бирем: текст буенча сорауларга җавап бирергә яки үзлекләреннән сораулар төзергә.

2 нче төркем өчен бирем: тексттан төп эчтәлекне чагылдырган җөмләне табып укырга.

3 нче төркем өчен бирем: текстны укырга.

Шулай итеп, дифференциациаль якын килеп укыту алымының чит телләргә өйрәткәндә дә уңышлы файдаланылуын күрдек. Бу алым укучыларның да, укытучының да эшен күпкә җиңеләйтә, предметка кызыксынуны арттыра, уңышлы нәтиҗәләр бирә. Әлеге алымның отышлы ягы – укучыларда сөйләм эшчәнлегенең һәм сөйләм иҗатының төрле төрләрендә мөстәкыйль уку күнекмәләрен үстерү. Дифференциаль якын килеп укыту алымы ярдәмендә чит телгә өйрәткәндә, төп бурыч укучыларның шәхси әзерлеген истә тотып, аларның танып-белүгә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бәйле.

**Әдәбият**

1. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә алымнар. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2009. – 106 б.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

*Мәрданова З., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кириллова З.Н.*

Татар телен укыту методикасы елдан-ел камилләшә, төрле методикаларга баю күренеше күзәтелә. Алар, үз чиратында, баланың тел өйрәнүгә карата булган теләген көчәйтеп, уңай нәтиҗәләргә этәрә. Егерме беренче гасыр баласын китаптагы күнегүләр, сөйләп аңлату белән генә канәгатьләндереп булмый, әлбәттә. Замана укытучыны да, укучыны да даими эзләнергә, кызыксынырга чакыра. Татар теле дәресләрендә уеннар, мультимедиалы проектор, группаларда эшләү, проектлар әзерләү кебек алымнар кулланып, тел өйрәнүне тагын да кызыклырак һәм нәтиҗәлерәк итәргә мөмкин. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, шулай ук темаларның эчтәлегеннән чыгып, төрле педагогик технологияләрне куллану укучыларның кызыксынуларын арттыру белән беррәттән, белем алуның сыйфатын да камилләштерергә ярдәм итә. Чөнки укучылар

укытучы кушканга гына түгел, ә үзләре кызыксынып, әлеге процесста актив катнашалар.

Соңгы елларда татар теле дәресләрендә уен технологиясеннән файдалануның нәтиҗәлелеге турында күп фикерләр йөри.

Уен – гаҗәеп киң төшенчә. Шиллер уенны «һәр сәнгатьнең нигезе» дип санаган. Уен бөтен кешелек мәдәниятенең нигезендә ята, чөнки уен – иҗат эшенең беренче адымы. Ул – мәҗбүрилектән котылу юлы: кеше уйнаган вакытта ирекле уйный, тоя, иҗат итә башлый, бары тик яшәешнең табигый эчке законнарына гына буйсына.Укучылар коллективында уен һәм белем бирү бер-берсенә шул кадәр тыгыз үрелгән, кайбер очракларда аларның чикләрен билгеләү дә кыен, чөнки уенның кайчан шаярудан туктап, чын хезмәткә әйләнүен белеп булмый. Укучыларга хас хәрәкәтчәнлек, яңалыкка омтылыш күп [2].

Уеннарны белем бирү процессында куллануның берничә төрен аерып күрсәтәләр:

– әле өйрәнелмәгән татар лексикасын үзләштерергә ярдәм итүче уеннар;

– өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итүче уеннар;

– грамматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирүче уеннар;

– грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итүче уеннар.

С. Айдарова – рус телле балаларга татар телен укытканда, уен технологияләрен файдаланырга тәкъдим иткән методикалар авторы. Ул бүгенге көндә әлеге методикаларның Казанның 60нчы һәм 33нче мәктәпләрендә уңышлы файдаланылуын искәртә.

“Уеннар – телгә өйрәтү чарасы. Уен эчендәге кагыйдәләр укучы баланы белемнәр үзләштерүгә үз теләге белән кушылырга этәрә. Уенда катнашу өчен, әлбәттә, алдарак алган белемнәр дә кирәк. Уеннарның үзенчәлеге дә шунда: алар дәрестә игътибарлы булырга омтылыш тудыра”, – дип аңлата С. Айдарова.

“Уеннар төрле булырга мөмкин – шәхси, парлы, коллектив уеннар. Иҗади, тәрбияви, коммуникатив, дидактик уеннар. Методик яктан дөрес үткәрелгән уен балада телгә мәхәббәт тәрбияли, сөйләм күнекмәләрен үстерә, аны табигый нормаларга якынайта”, – дип билгеләп үтә галимә [4].

Чыннан да, укучыларның алган белем һәм күнекмәләрен камилләштерүдә, аларның үз фикерләрен язма яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белүдә, укучыларны тел белән кызыксынуларын арттыруда уенның роле әйтеп бетергесез зур. Уен технологиясен дәреснең бер этабында куллану белән беррәттән, дәресне тулысынча уен формасында да үткәрергә була. Иң зур таләп – укучыларны кызыксындырырлык проблемалы сораулар куя белү. Методик яктан дөрес төзелгән уен –

укучының телгә карта булган кызыксынуын үстерү белән бергә, мәгълүмат тупларга, белемнәр алырга да ярдәм итә.

Г.К. Селевко уеннарны дүрт юнәлешкә аерып карый. Болар: дидактик, тәрбияви, үстерелешле һәм социальләштерүче уеннар. Болар барысы да Федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килә. Уеннарны яңа материалны аңлатуда да, белемнәрне ныгыту барышында да, телдән сөйләм эшчәнлегенең өйрәтү вакытында да файдаланырга мөмкин. Укытучы теләсәкайсы уенга тукталып, укучыларга белем бирү белән янәшә әхлак тәрбиясе дә сеңдерә ала.

Дәрестә реаль тормыш картиналарына якынайтылган ситуацияләр урын алырга тиеш. Мәсәлән, “Китапханәдә”, “Мәктәптә”, “Кунакта”, “Базарда”, “Безнең гаилә”, “Мин Татарстанда яшим”, “Кибеттә” һ. б. “Журналист”, “Могҗизалар кыры”, “Сүзләр баттлы”, “Күренекле шәхесләр”, “Күршеләр” һ. б. шундый рольле уеннар татар теле дәресен тагын да кызыклы итә, балаларга телне өйрәнүгә дәрт өсти [3].

Шулай ук соңгы вакытларда дәрестә актив һәм укучылар тарафыннан яратып кабул ителә торган проект технологиясенең әһәмиятен ассызыклап үтик. Әлеге технология билгеле бер тематикага караган темаларны үзләштергәннән соң, белемнәрне гомумиләштерү дәресе буларак кулланыла. Проект технологиясе укучыларда түбәндәге күнекмәләрне үстерергә ярдәм итә:

– группаларда эшли белү;

– үз фикереңне әйтергә курыкмау;

– иҗади фикерләү, иҗади якын килеп эшләү;

– уңышлы карарлар кабул итә белү.

Проект технологиясе барышында, укучыларның шәхси эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бала аңында билгеле бер тема буенча белемнәр формалаша.

**Әдәбият**


1. Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогикалымнар. – К(И)ФУ АФ нәшрияты, 2012. – 137 б.
2. https://infourok.ru/tatar-tele-dreslrend-pedagogik-tehnologiyalr-1311054.html
3. https://infourok.ru/tatar-telen-yrtd-uen-elementlari-1366729.html
4. https://infourok.ru/tatar-telen-yrtd-uen-elementlari-1366729.html


## ЭТИКЕТ ТАТАРСКОГО ЗАСТОЛЬЯ В СЕЛЕ ТОКАЕВО


*Мингалеева А., Чувашия, Комсомольский р-н, Токаевская СОШ, X класс*

*Рук. – Гималтдинова Д.М.*


Современный мир стремительно меняется. Глобализация привела к тому, что стирается граница между народами. Люди по всему миру стали одинаково питаться продуктами быстрого приготовления, одеваться в джинсы, жить в одинаковых жилищах и проводить время у экранов компьютера или телевизора. Люди столетиями жили размеренной традицион-

ной жизнью, а за последние 10–20 лет жизнь кардинально изменилась. На этом фоне становится очевидным важность сохранения народных традиций и знаний народов. Поэтому данная работа является исключительно актуальной, потому что она направлена на изучение и сохранение народных знаний в области застольного этикета татар.

**Цель работы** – изучение традиций застольного этикета татар села Токаево Комсомольского района Чувашской республики.

**Задачи:**

1. Изучить литературу по теме татарского этикета застолий.
2. Опросить старожилов села о традициях приема гостей.
3. Выяснить, по каким праздникам обычно приглашали гостей.
4. Узнать, как сервировались столы, как рассаживались гости.
5. Выяснить, какие подарки дарили в гостях.
6. Описать типичное меню и последовательность подачи блюд.
7. Найти предметы старины, связанные с приемом гостей.

В ходе исследовательской работы были использованы следующие методы: 1. Изучение краеведческой литературы и обзор татарских Интернет сайтов. 2. Опрос старожилов. 3. Анкетирование. 4. Статистическая обработка данных. 5. Реконструкция.

Надо отметить, что данная исследовательская работа привлекла большой интерес жителей. Ученикам было очень интересно помогать авторам работы. Бабушки и дедушки были очень рады, что внуки интересуются стариной, историей, они с удовольствием доставали из сундуков старенькие, но любимые татарские платья, тюбетейки, в которых ходили в гости, показывали домотканые скатерти, салфетки, коврики, деревянные самодельные ложки, маслобойки, формы для выпекания хлеба и др.

Родители тоже всячески помогали: по просьбе детей пекли различные блюда, фотографировали.

Все получили огромное удовольствие от участия в данном проекте! Осознали гордость за то, что принадлежат к своему народу. Почувствовали ответственность за сохранение и передачу традиционных народных знаний дальше – своим потомкам.

**Возродим утраченное**

Детская Экспедиция «Возродим утраченное» дала многое. Мы лучше узнали традиционную кухню и быт наших бабушек, нашли огромное количество предметов старины. Познакомились с традиционным татарским этикетом, традицией приглашения гостей. Записали воспоминания многих пожилых людей.

Традиционная татарская кухня, впитавшая в себя кулинарные традиции булгар, русских, чувашей, влияние Востока и Европы, богата самыми разнообразными блюдами повседневного и праздничного стола. И по

сей день сохранились не только замечательные рецепты национальной кулинарии, но и существовавшее в веках радушное гостеприимство народа. Особенность татарской кухни это то, что все кушанья можно разделить на следующие виды: жидкие горячие блюда, вторые блюда, печеные изделия с несладкой начинкой (также подававшиеся на второе), печеные изделия со сладкой начинкой, подававшиеся к чаю, лакомства, напитки. Появилась гордость за свой татарский народ, за то, что у народа такая богатая история со своими традициями, национальной кухней.

Было проведено анкетирование школьников, которое показало, что большинство учеников знает свои национальные блюда, многие даже умеют готовить. Дети гордятся татарской национальной кухней.

Экспедиция привлекла к себе огромный интерес школьников, многие ученики подходили к участникам с желанием присоединиться. Выяснилось, что у многих детей в семьях, живущих с представителями старших поколений, есть много ценных старинных экспонатов. Очень рады были пожилые участвовать консультантами в Экспедиции.

Таким образом, краеведческая Экспедиция пробудила необычайный интерес школьников, у детей проснулось национальное самосознание, гордость за свою культуру.

В рамках данной работы не удалось полностью охватить все вопросы, зато было решено работу продолжить в виде проекта – альбома «Традиционный татарский этикет»: сделать качественные фотографии предметов старины, записать воспоминания пожилых, чтобы оставить в памяти поколений свои народные национальные традиции.

Известный татарский просветитель и энциклопедист Каюм Насыри в своей книге о воспитании описал ряд правил, обязательных во время еды: «За стол садись сразу же, как только подадут еду, не заставляй себя ждать. Ешь правой рукой, если за столом собрались почтенные люди, не тяни к еде руку раньше них – это невоспитанность. В умеренной еде большая польза – будешь здоров телом, ясен умом, силен памятью». Хочется, чтобы молодое поколение не забывало наставления пожилых.

**Литература**

1. Паркер Э.Н. Татары. История возникновения великого народа. – М.: Наука, 2010. – 323 с.
2. Шихаб Китапчы Наследие татар. – Казань: Алгоритм, 2013. – 369 с.

## ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘТҮДӘ ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

*Минзина Н., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – пед. фән. канд., доц. Фәтхуллова К.С.*

Төп аралашу чарасы буларак тел кешеләрне берләштерә, шәхесара һәм социаль мөнәсәбәтләрне билгеле бер тәртипкә китерә, мәгълүмат туплау һәм саклауны тәэмин итә, кеше аңын формалаштыра. Тел берәмлекләрен

куллану аша сөйләм барлыкка килә, һәм ул төп аралашу ысулы булып тора. Шунлыктан бүгенге көндә һәрбер телне мәдәниятара һәм шәхесара аралашу чарасы буларак укыту иң мөһим мәсьәләләрдән санала.

Татарстан Республикасында урта гомуми белем бирү системасының төп бурычы – иҗади фикерләүче, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле шәхес тәрбияләү. Заманча педагогик технологияләр белем бирү барышын яңача гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Бүгенге көндә туган тел укытучылары тарафыннан киң кулланыла торган технологияләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: проектлар технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, уен технологиясе, үстерелешле укыту технологиясе, интегратив укыту технологиясе, модульләп укыту технологиясе, этнопедагогик технологияләр, дистанцион технологияләр, тәнкыйди фикерләү технологиясе, концентрик белем бирү технологиясе, кейс технологиясе һ. б. [3: 49].

Төрки телләр – алтай макрогаиләсенең тугандаш телләр гаиләсе булып санала. Әлеге телләрдә 170 милионнан артык кеше сөйләшә. Әлеге телләр кардәшлек җепләре белән тыгыз бәйләнгән. Фонетик һәм грамматик яктан шактый охшаш татар һәм төрекмән телләрен яңа педагогик технологияләр ярдәмендә өйрәтүгә күзәтү ясап үтик. Иҗади үсеш технологиясенә киңрәк тукталып, аңа хас булган үзенчәлекләргә игътибар итик. Бу технология өч өлештән тора: беренчесе – төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомимиләштерү; икенчесе – укучыларның эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру; өченчесе – модельләштерү. Модельләр һәм калыплар белән эш итәргә даими өйрәткәндә, сөйләм кыскара, автоматлаша һәм фикергә әверелә. Модель төзү – иҗади эш, чөнки аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекле билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачып бирәләр. Шул нигездә, әлеге алым телләр өйрәнүгә кызыксыну уяту, аралашу-аңлашуга ирешү чарасы да булып тора.

Татар телен дә, төрекмән телен дә өйрәткәндә, укучыларның сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, төрле модельләрдән файдаланырга мөмкин. Мәсәлән, төрле килешләрдәге исемнәрне гамәли кулланырга өйрәтү өчен, түбәндәге җөмлә калыпларыннан файдаланып була: *Алсуда китап бар. (У Алсу есть книга). Kitap Amanda bar. (У Амана есть книга). Китапны Алсудан сора (Попроси книгу у Алсу). Kitaby sen Amandan sora. (Попроси книгу у Амана)* һ.б.

Телләрне өйрәтүдә заманча технологияләрнең берсе – проектлар яклату. Бу очракта укучылар тәкъдим ителгән теманы мөстәкыйль рәвештә тирәнтен өйрәнәләр һәм бу эшкә иҗади якын килләр. Проектны укучы үзе генә дә башкарып чыга ала, яки 2–3 кешелек төркемгә берләшеп эшләү дә яхшы нәтиҗәгә китерә. Ахырдан тема буенча презентация әзерләнә, һәм ул дәрестә яклана. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрки дөнья белән бәйле төрле кызыклы проект темаларын тәкъдим итеп була: “Татар

милли ашлары”; “Татар милли киемнәре”; “Татар халкының гореф-гадәтләре”; “Татар халкының күренекле шәхесләре”; “Татарстан һәм Төрекманстан мөнәсәбәтләре”; “Татар һәм төрекмән халыкларының авыз иҗаты” һ. б. Мәсәлән, соңгы тема буенча укучылар төрекмән һәм татар телләренең мәкаль-әйтемнәрен чагыштырып өйрәнә алалар: *Яндырма – үзең янарсың, казыма – үзең төшәрсең* (төрекмән мәкале). *Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең* (татар мәкале). *Дөньяда иң татлы һәм иң ачы ул – тел* (төрекмән мәкале). *Сөйдергән дә тел, көйдергән дә тел* (татар мәкале) һ. б.

Сыйфатлы белем бирү өчен, әлеге технологияләрне системалы файдалану мөһим, чөнки алар ярдәмендә укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыруга, иҗади мөмкинлекләрен ачып бирүгә, үзлектән белем алу күнекмәләрен үстерүгә ирешеп була. Моның белән беррәттән, яңа технологияләр дәресләрдә уңай психологик халәт булдырырга, уку проблемасын хәл итәргә, укучыларның эзләнү, мәгълүматны эшкәртү һәм гомумиләштерү эшчәнлеген оештырырга, аларның коммуникатив компетенциясен үстерергә ярдәм итә. Гомумән алганда, төрки телләрне өйрәнү нәтиҗәсендә, укучылар көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия була алалар. Хәзерге дөньяда телләргә өйрәтү системасын яңа технологияләрдән башка күз алдына китерү мөмкин дә түгел. Алар тел өйрәнүчегә берьюлы графика, текст, видео, анимация, тавышлы эффектлардан файдаланырга мөмкинлек бирә [2: 315].

Йомгак ясап әйткәндә, төрки телләрне укыту өлкәсендә дә инновацион технологияләрне куллануга тиешле игътибар бирү кирәк дип саныйбыз. Моның өчен һәр укытучы методик осталыгын һәм иҗади активлыгын арттыру, гамәли эшчәнлеген камилләштерү, белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итүгә омтылырга бурычлы. Телләрне аралашу чарасы буларак укыту өчен, иң нәтиҗәле технологияләрне куллану, дәресләрдә алардан киң файдалану аеруча зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

1. Педагогические технологии / Под общей ред. В.С. Кукушина. – М.: ИКЦ «Март», 2004. – 336 с.

2. Полат Е.С. Новые педагогические и информационные технологии в системе образования: уч. пособие для вузов. – М.: Академия, 2002. – 272 с.

## МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ ТӘРҖЕМӘДӘ БИРҮ

(Г. Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре материалында)

*Мисбахова С., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Тел хәзинәсенең мөһим бер асылташы булып фразеологик берәмлекләр исәпләнә. Бу әйтелмәләр ярдәмендә кыска, ләкин шактый

үтемле итеп үз фикерләреңне җиткерергә була. Фразеология сөйләмне баетуда, аны үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, әдәби әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда зур роль уйный.

Академик В.В. Виноградов күрсәтүенчә, компонентларының берләшү дәрәҗәсенә карап, фразеологизмнарны өч төркемгә бүлергә мөмкин: фразеологик ныгытмалар, фразеологик бердәмлекләр, фразеологик тезмәләр. Ул лингвистикада иң киң таралган фразеологизм составындагы компонентларның идеоматиклыкка нигезләнгән классификациясен тәкъдим итә.

Г. Яхинаның «Зулейха открывает глаза» әсәрендә һәм аның Ф. Тарханова тарафыннан татар теленә тәрҗемәсендәге фразеологик берәмлекләр В.В. Виноградов тәкъдим иткән классификация буенча каралды.

1.Фразеологик ныгымалар: *Но нет сил* ***оторвать глаза*** *от потолка.* [5: 8]. – *"Тик* ***күзләрне*** *түшәмнән* ***аерып булмый*** *– хәле юк* [4: 78]. *Не оторвать глаза.* – Пристально, внимательно, непрерывно смотреть на кого или на что-либо.

*– Прикладывай руку, Зулейха,* ***не тяни время****,– вздыхает по-дружески, душевно, не отрывая влюбленного взгляда от толстых гладких бревен, щедро проложенных добротной лохматой паклей.* [5: 82]. – *Зөләйха, кулыңны куй,* ***вакытны сузма****, – диде Мансур дусларча җылы тавыш белән* [4: 82]. *Тянуть время* – Медлить в начатом деле или в осуществлении чего-либо.

*–Где тебя* ***шайтан носит****, мокрая курица?!* [5: 85]. – *Син* ***кая югалдың, шайтан алгыры****, җебегән тавык?!* [4: 86]. *Черт носит* – Выражение резкого недовольства тем, что кто-либо пропадает, ходит где-то, долго не появляется.

2. Фразеологик бердәмлек: *А не то зарубил бы,* ***грех на душу взял****.* [5: 61]. *– Аллага шөкер, югыйсә чабып үтереп,* ***җанына гөнаһ алган*** *булыр иде* [4: 861]. *Взять грех на душу* – Совершать неблаговидный или тяжкий поступок.

*Если сон – почему свет так* ***режет глаза*** [5: 79]? – *Төш булса, ник ут яктысы* ***күзләрне кисә****?* [4: 79]. *Резать глаза* – Утомлять зрение, производить неприятное зрительное впечатление чрезмерной яркостью, пестротой.

*– Мой Муртаза* ***шкуру-то с тебя спустит!*** *– хрипит с крыльца Упыриха, и ветер развевает тощие веревки ее легких белых кос* [5: 86]. – *Минем Мортазам* ***тиреңне тунар!*** *– дип гырылдап кычкырды Убырлы* [4: 86]. *Спустить шкуру* – Жестоко обходиться, не щадить.

3. Фразеологик тезмәләр: *– Никогда, ни разу* ***пальцем не тронула!*** [5: 38]. – *Беркайчан да, хәтта* ***бармагымны да тидергәнем юк!*** [4: 36]. *Пальцем не трогать.* – Не причинить ни малейшего вреда.

***Язык отсох*** *вас агитировать* [5: 1]. – *Сезне агитлый-агитлый* ***тел кипте*** *инде* [4: 81]. *Язык отсохнет (отсох).* – Кто-либо лишится (лишился) дара речи.

*В глазах рябит.* – Быстро сменяясь, мелькает, пестрит при восприятии зрением: *Всего-то и было у него этих баб за жизнь – стыдно признаться* ***– по пальцам одной руки перечесть*** [5: 94]. – *Гомере буе якыннан аралашып йөргән хатыннары (әйтергә дә оят)* ***бер кул бармакларыннан артмады*** [4: 92]. *По пальцам можно пересчитать* – так мало, что нетрудно сосчитать: *Игнатов* ***задирает голову*** *– осматривается* [5: 99]. – *Игнатов,* ***башын күтәреп****, күз йөртеп чыкты* [4: 99].

Г. Яхинаның «Зулейха открывает глаза» әсәрендә фразеология киң чагылыш тапкан. Әдип әсәрдә матур эчтәлекле, образлы сурәтләү чараларын бик мул кулланган. Образлы сурәтләү чараларын кулланып, язучы геройлар сөйләмен һәм аларның хис-кичерешләрен бирүдә үз максатына ирешкән. Тәрҗемәче исә, үз чиратында, фразеологик әйтелмәләрне күбесенчә тәрҗемә-сурәтләү алымы белән тәрҗемә иткән. Әлеге ысулны, ягъни, фразеологизмны тәрҗемәдә фразеологизм белән бирмәү очрагын тәрҗемәчеләр соңгы очракта гына кулланалар, ләкин шулай да, фразеологик әйтелмәне лексик мәгънәсенә якын торган сүзләр белән белдерү автор өчен дә, укучылар өчен уңайлы форма булып тора.

**Әдәбият**

1. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. – М.: Наука, 2014. – 426 с.

2. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. – Казань: Ихлас, 2012. – Б. 91.

3. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2001. – Б. 312.

4. Яхина Г.Ш. Зөләйха күзләрен ача: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 511 б.

5. Яхина Г.Ш. Зулейха открывает глаза: роман – М.: Издетельство АСТ, 2018. – 508 с.

## ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ МАКТАУ-ХУПЛАУ СҮЗЛӘРЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫНДА ОХШАШ ҺӘМ АЕРМАЛЫ ЯКЛАР

*Михайлишина А., Яшел Үзән р-ны Әйшә урта мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – Хәмәтҗанова Г.И.*

Татар һәм инглиз телләрендә урын алган мактау һәм хуплау сүзләренең, лексик-семантик үзенчәлекләренә бәйле рәвешле, коммуникатив-прагматик кулланылышын тикшердек. Әлеге ике телдә кулланыла торган мактау сүзләренең охшаш һәм аермалы якларын чагыштырма планда анализлап, гомуми нәтиҗәләргә күз салыйк. Башта һәр ике телдә дә мактау һәм хуплауны белдерә торган уртак чараларга – универсалийларга тукталыйк. Алар түбәндәгеләр:

− кешенең тышкы кыяфәтенә кагылышлы комплиментлар – мактау сүзләре: *Синең йөзең, тавышың көләр өчен яратылган; Бик чибәр син; Сез хәзер шәһәребезнең беренче гүзәле бит; Кыяфәтегез, тфү, тфү, күз тимәсен. Бик яшь күренәсез әле; It would be so silly to pretend that you*

*weren't divinely handsome; You're more lovely than ever; You're wonderful and you're as beautiful as a Greek god; Gosh, you look swell; You're still the best-looking man in England; They're such awfully nice kids* һ. б.

– *Бер кыш эчендә сез, Хәят, танымаслык үсеп киткәнсез,* ***тагы да матурлангансыз*** (Ф.Әмирхан "Хәят"). – *It would be so silly to pretend that* ***you weren't divinely handsome*** (W.S. Maugham "Theatre").

– кешенең эчке характерына бәйле, күркәм сыйфатларына мөнәсәбәтле мактау сүзләре: *Син бик яхшы кеше, синең күңелең яхшы; Син бик бала җанлы кешегә охшагансың; Син бит үзең дә бер генә идең; Сүзгә-өнгә дә бик ягымлы иде; Изге күңелле булды ул, олы җанлы; Бик булган кеше Сез; You've been far, far too kind to us already; You have been very generous to me; I know that you're good. You have a charming character; He really is frightfully devoted* һ.б.

– ***Син бик яхшы кеше, синең күңелең яхшы****. Дөньяда иң сөйгәнем, иң якыным булып син каласың* (Ш.Камал "Ике яхшы"). – ***You've been far, far too kind*** *to us already* (W.S. Maugham "Theatre").

– хуҗабикәләргә карата кулланыла торган хуплау һәм мактау сүзләре: *Яшәгән урының оҗмахларга тиң икән; Сез бик уңган хуҗабикә; Өегез һәрвакыт ялт иткән; Сез бик тәмле пешерәсез; Ашка-суга бик остасыз; Өегез шундый нурлы; Ашларыгыз – телеңне йотарлык; Өегез искиткеч чиста, пөхтә That very charming little house of the Soames Forsytes, quite individual, really elegant!; I can recommend her as an excellent wife* һ.б

– *Сөбханалла!* ***Яшәгән урының оҗмахларга тиң икән****, малай* (Г.Галиева "Өзелгән өмет"). – ***That very charming little house of the Soames Forsytes, quite individual, my dear – really elegant*** (J. Galsworthy "The man of property").

Тикшеренүләр нәтиҗәсендә татар яисә инглиз теленә хас булган үзенчәлекле мактау һәм хуплау формаларының актив булуы ачыкланды. Алда билгеләп үтелгәнчә, бу күренеш әлеге телләрдә сөйләшүче халыкларның гореф-гадәтләре, традицияләре, фикерләү, чынбарлыкны кабул итү рәвеше һәм, гомумән, менталитет белән бәйле. Инглиз телендәге мактау һәм хуплауны белдерә торган уникалийлар түбәндәгеләр:

– кешенең һөнәри осталыгына кагылышлы мактау һәм хуплау сүзләре: *You've got a wonderful voice, the voice that can wring an audience's heart. I tell you, you've got the makings of a great actress; You have been here a great many years and I think you've fulfilled your duties quite satisfactorily; He knew his work from A to Z; He's a great artist, a very great artist. He has a genius* һ. б.

Татар теле өчен хас булган гыйбарәләр түбәндәгеләр:

– кием-салым, чәч, киенүгә кагылышлы мактау сүзләре: *Бу күлмәк Сезгә бик килешә; Бу төс Сезне ачып җибәрә; Сез һәрвакыт зәвык белән киенәсез; Сез киемне сайлый беләсез; Чәчегезне бик оста ясыйсыз; Бүген аеруча матур бизәнгәнсез; Сез шулкадәр затлы киенәсез; Костюмыгыз искитмәле* һ. б.

– кешенең батырлыгын һәм кыюлыгын хуплау, мактау сүзләре: *Ну, егетсең, егет!; Менә егет ичмасам! Өч кешегә каршы эшли бит ул; Батыр йөрәкле кеше Сез; Сездәй кыюлар булмас; Курку белмәс җан Сез; Сез шундый чыдам* һ. б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, сөйләмдә мактау һәм хуплауны күптөрле гыйбарәләр белдереп килә. Әлеге формаларның һәм барлык телләр өчен дә уртак булганнары (кешенең тышкы кыяфәтенә кагылышлы мактау һәм хуплау сүзләре; кешенең эчке, кешелеклелек сыйфатларына мөнәсәбәтле мактау һәм хуплау сүзләре; хуҗабикәгә карата кулланыла торган мактау һәм хуплау сүзләре һ.б.), һәм аерым бер телдә генә чагылыш тапканнары (кием-салым, чәч, киенүгә кагылышлы; кешенең һөнәри осталыгына кагылышлы; хайван, кош-кортларның уңай сыйфатларына кагылышлы мактау һәм хуплау сүзләре; һ. б.) аралашуның аерылгысыз бер элементы булып тора.

**Әдәбият**

1. Абдуллин А.А. Этические выражения в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2006. – 25 с.

2. Белан Д.В. Комплимент в американской и французской коммуникативных культурах: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – М., 2007. – 21с.

3. Виноградов С.И. Нормативный и коммуникативно-прагматический аспект культуры речи // Культура русской речи и эффективность общения. – М., 1996. – 493 с.

**Чыганаклар**

4. Вәлиев М. Идел яры. Повестьлар, новеллалар, хатирәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 461 б.

5. Гази И. Малайлыкта кунакта. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 152 б.

6. Christie A. Death on the Nile. – М.: Менеджер, 2006. – 282 с.

7. Fitzgerald F.S. The great Gatsby. – СПб: КАРО, 2008. – 256 с.

## РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР ЙӨРТҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

(8 нче сыйныфта «сүзтезмә» темасын өйрәтү мисалында)

*Мөбарәкшина Л., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хөснетдинов Д.Х.*

Хәзерге көндә Рәсәй белем бирү системасына актив рәвештә инновация дигән төшенчә кертелә башлады. Инновация ул һәрвакыт яңа әйбер уйлап табу гына түгел, ул башка культурада уйлап табылган технологияләр, укыту методлары да булырга мөмкин. Шундыйлардан булып проект технологиясе, кейс-технологиясе, эшлекле-уен һәм башкалар. Укыту субьекты – белем алучы.

Актив белем алуның берничә сыйфатын билгелиләр:

– мәҗбүри активлык, укучының үз теләгенә игътибар бирмичә мәҗбүри рәвештә актив булуы;

– бик озак вакыт укучыларның уку барышында катнашуы;

– мөстәкыйль рәвештә иҗади карар кылу, укуга карата мотивацияне арттыру;

– системалы рәвештә укытучы һәм белем алучыларның хезмәттәшлеге;

– белем алу агышын чынбарлыкка якын китереп эш итү [1: 52].

Мәкаләдә без инновацион технологияләрнең бер төре булган тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе белән танышырбыз һәм аны 8 нче сыйныфта “сүзтезмә” темасын өйрәнгәндә куллану юлларын карап үтәрбез.

Тәнкыйди фикерләү (ингл. critical thinking) – ул системалы фикер йөреше, аның ярдәмендә нәтиҗә, интерпретация чыгару, алган белемнәрне ситуациягә карап куллану. Тәнкыйди фикерләүне гади фикерләүгә караганда югарырак дип карарга була [4].

Менә бу технологияне 8 нче сыйныфында татар теле дәресендә “сүзтезмә” темасын үткәндә ничек кулланып була соң?

Беренчедән, сүзтезмә сүзенең дәреслектәге билгеләмәсе белән танышып китик. Дәреслектә сүзтезмәгә түбәндәге билгеләмә бирелгән: “Ияртүле бәйләнеш нәтиҗәсендә җөмлә һәм сүзтезмә барлыкка килә. Җөмләдә хәбәр ия турында хәбәр итә, ә сүзтезмәдә ияртүче сүз ияртүче сүзне ачыклап килә. Кимендә ике мөстәкыйль мәгънәле сүзнең үзара ияртүле бәйләнешкә керүе нәтиҗәсендә сүзтезмә оеша” [2: 41]. Дәреслектә төрле эш төрләре тәкъдим ителә, мәсәлән, сүзтезмәләрне русчага тәрҗемә итү, бирелгән сүзләрдән сүзтезмәләр төзү һ. б. Биремнәр, бертөрле генә булмаса да, белем алучылар өчен яңа түгел.

Без тәнкыйди фикер йөртү технологиясенең берничә алымын тәкъдим итәбез:

1) 8 нче сыйныфлар өчен татар теле дәресендә синтаксис бүлегенең “сүзтезмәләр” темасын үткәндә “фикерләр кәрзине” дигән алымын куллану.

Иң беренче чиратта һәр белем алучы сүзтезмә турында үзенең фикерен яза, аннан соң, парларда эш башлана. Белем алучылар бер-берсенең җавапларын тикшерәләр һәм чагыштыралар. Икенчедән, һәр укучы “кәрзингә” кечкенә генә кәгазьгә үз фикерен язып сала, соңыннан инде җаваплар укыла һәм әңгәмә корыла.

2) “Ачкыч сүзләр нигезендә хикәя-фараз төзү” алымы.

Ачкыч сүләр тәкъдим ителә, шул сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзелә, темага караган хикәя-фарыз кылына. Барлык белем алучылар өчен дә, үз фикерләренең авторныкы белән туры-килү килмәвен тикшерү зур кызыксыну тудыра.

3) “Кластер” төзү алымы.

Алым яңа белемнәрне системалаштыру өчен кулланыла. Ул болай алып барыла уртага тема языла һәм уклар ярдәмендә кирәкле төшенчәләр языла. Кластерны дәреснең төрле этабында кулланып була.Сүзтезмә темасын үткәч, кластер алымын кулланып була: сүзтезмә төрләрен икегә бүленә – ирекле сүзтезмәләр һәм фразеологик сүзтезмәләр, ирекле

сүзтезмәләр үз чиратында – гади һәм катлаулы сүзтезмәләргә бүленә. Бу схемага нигезләнеп укучылар рефлексия этабында алган белемнәрен искә төшерәләр, яхшырак истә калдыралар.

Шулай итеп, тәнкыйди фикер йөртү, инновацион технологияләрнең, укучыларда темага карата кызыксындыру тудырырга сәләтле бер төре. Тәнкыйди фикер йөртүне татар теле дәресләрендә “сүзтезмә” темсын үткәндә кулланырга мөмкин. Без тәкъдим иткән алымнар укучыларның яшь үзчәлеген истә тотып төзелде.

**Әдәбият**

1. Красикова Е.Н. Кейс-метод в структуре и содержании методической компетенции лингвиста-преподавателя: дис. … канд. пед. наук. – Ставрополь, 2009. – 177 с.

2. Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 8 нче с-ф. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2016. – 223 б.

3. Фәтхуллова К.С. Заманча дәрес – сыйфатлы белем нигезе. // Мәгариф, 2016. – №8. – Б. 48–51.

4. https://ru.wikipedia.org/wiki/Критическое_мышление

## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНДӘ «ЙӨРӘК» КОНЦЕПТЫ БЕЛӘН ЯСАЛГАН ЭМОТИВ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

*Мөхәммәтвәлиева Ф., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Эмотив фразеологик берәмлекләр дөньяны танып белү һәм кабул итү вакытында кешенең объектив чынбарлыкка булган мөнәсәбәтен, бәяләвен белдерә. Халыкның мәдәнияте һәм менталитеты турындагы мәгълүматларның кыйммәтле чыганагы булган әлеге берәмлекләр составында концептлар гәүдәләнеш таба. Татар һәм башкорт телләрендә кешенең рухи халәтен, хис-кичерешләрен белдергән күпчелек эмотив фразеологик берәмлекләрнең ясалышында “йөрәк” концепты кулланыла. Тәгъдим ителгән мәкаләдә алар чагыштырма планда тикшерелә.

Татар һәм башкорт телләрендә лингвокультурологик тикшеренүләр, концептлар белән бәйле эзләнүләргә багышланган Р.Р. Җамалетдинов, Г.Р. Галиуллина, Р.Р. Данилова, Ф.Х. Тарасова, Р.Р. Закирова, Л.Р. Гарипова, Ф.Р. Сибгаева, Ф.Х. Габдрахманова, Д.Х. Хөснетдинов, Л.Х. Шаәяхмәтова, З.М. Раемһуҗина, Р.Х. Хәйруллина, М.В. Зәйнуллин һ.б. ның хезмәтләре бар.

Фразеологик берәмлекләрне тел белгечләре дистә еллар дәвамында өйрәнеп, теркәп килгәннәр. Ш.А. Рамазанов, Г.Х. Әхәтов, Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Н. Исәнбәт, Г.Х. Ахунҗанов, Р.Г. Йосыпов, Ф.С. Сафиуллина хезмәтләрендә татар теле фразеологиясе төрле яклап тикшерелгән.

Башкорт теле фразеологиясен өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән галимнәр булып С.Н. Моратов, Х.Г. Йосыпов, Ж.Г. Киекбаев, З.Г. Ураксин,

Ф.А. Нәдершина, М.Х. Әхтәмов, Г.Г. Каһарманов, З.М. Раемһуҗина, Р.Х. Хәйруллина исәпләнә.

Татар һәм башкорт телләренең фразеологизмнарын чагыштырма тикшерү буенча С.Н. Моратов беренче адым ясый. “Устойчивые словосочетания в тюркских языках” (1961) хезмәтендә автор фразеологик берәмлекләрнең структур типларын, формалашуның закончалыкларын ачыклый, аларның төрки телләрнең сүзлек составында һәм грамматик сафында тоткан урынын билгели.

Лексикада татар һәм башкорт телләренең уртак яклары күп: икесе дә борынгы төрки телгә карый һәм үзара тарихи, мәдәни бәйләнештә яши. Эмотив фразеологик берәмлекләрнең төп өлешен гомумтөрки сүзләр тәшкил итә. Соматизмнар – кеше гәүдәсе әгъзаларын атаучы сүзләр лексик фондның иң борынгы катламы булып саналалар һәм тотрыклы берәмлекләр рәтенә керәләр. Йөрәк сүзенең килеп чыгышы гомумтөрки *йүрәк,* монгол телендәге *җүрүк* сүзеннән дип аңлатыла. Күп этимологлар *йөрү* гомумтөрки *йүр* – “йөрү, хәрәкәтләнү” сүзеннән ясалган дип карыйлар [3: 276].

Татар һәм башкорт телләрендә “йөрәк” сүзенең билгеләмәләре охшаш. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә берничә мәгънә бирелә: 1) кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы, капчыксыман үзәк орган; 2) кешенең эчке дөньясы, хис-тойгылары, күңеле; 3) көч-куәт, гайрәт, кыюлык; 4) нәрсәнең дә булса үзәге, төп өлеше [4: 214].

Н. Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге” һәм З.Г. Ураксинның “Башҡорт теленең фразеологик һүҙлеге” материалында татар һәм башкорт телендә “йөрәк” концепты белән ясалган эмотив фразеологик берәмлекләргә күзәтү ясыйк.

Якын күргән, кадерле, сөйгән кешегә карата әйтелгән ФБ: (тат.) *йөрәк парәсе, йөрәк парчасы, йөрәк маем;* (башк.) *йөрәк параһы, йөрәк бәгъре, йөрәк майы, йөрәк ите.*

Көчле, курку белмәс, гайрәтле кеше түбәндәге фразеологик берәмлекләр белән тасвирлана: (тат.) *арыслан йөрәк, куш йөрәкле, йөрәгендә бар;* (башк.) *арыҫлан йөрәк, ҡуш йөрәк.*

Татар һәм башкорт телләрендә хиссез, игътибарсыз, гамьсез кешегә мөнәсәбәтле мондый фразеологизмнар очрый: (тат.) *йөрәге боз, салкын йөрәк, йон йөрәк, йөрәген мүк баскан;* (башк.) *йөрәгенә йөн үҫкән.*

Рухи тынычлану алу, борчылудан, шомлы хисләрдән арынып, күңелдә ышаныч туу хисен белдерүче ФБ: (тат.) *йөрәк басылу, йөрәккә җылы керү, йөрәк урынына утыру, йөрәк мае эрү, йөрәктән авыр таш төшкәндәй булу;* (башк.) *йөрәк баҫылыу, йөрәккә ял булыу, йөрәк урынына ултырыу, йөрәккә (эскә) йылы инеү.*

Кемне дә булса йомшарту, үзеңә карату, игътибар иттерү: (тат.) *йөрәген эретү, йөрәгенә ачкыч табу (ярату);* (башк.) *йөрәкте эретеү, йөрәген яулап алыу, йөрәгенә ия булу, йөрәгенә инеү.*

Дулкынлану, шомлану, курку кебек хис-кичерешләрне белдерү өчен мондый эмотив ФБ очрый: (тат.) *йөрәк алыну, йөрәк атылып чыгарга җитү, йөрәкне учта тоту, йөрәк ташу, йөрәк үкчәгә китү, йөрәк чыга язу;* (башк.) *йөрәк алыныу, йөрәк ҡубыу, йөрәк шыу (жыу) итеү, йөрәк үксәгә китеү, йөрәк ҡубыу, йөрәк ҡабарыу.*

Рухи газап кичерү, бик нык борчылу, тынычлыкны югалту яки көнләшү хисен белдерүче ФБ: (тат.) *йөрәк яну (әрнү, өгәләнү, телгәләнү), йөрәк парчалану, йөрәк кубу, йөрәкне кимерү, йөрәкне тунау, йөрәк итен ашау (талау), йөрәккә тию, йөрәккә тоз салу;* (башк.) *йөрәк яныу, йөрәк ҡыҫылыу, йөрәк ҡайнау, йөрәк әсеү, йөрәкте киҫеү, йөрәккә ут һалыу, йөрәген һоро бесәй тырнау, йөрәккә ҡан һауыу, йөрәкте өйкәү.*

Фразеологик берәмлекләр дөнья телләренең һәркайсында булганга күрә, аларга уртак үзенчәлекләр һәм типологик күренешләр хас. Кардәш төрки телләрдә бу аеруча ачык чагыла. "Йөрәк" сүзенә тирән этномәдәни мәгънә салынып, әлеге концепт татар һәм башкорт халкының рухын, менталитетының иҗтимагый-психологик үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Дөньяны күзаллауда милли-мәдәни үзенчәлекләр, кыйммәтләр системасы татар һәм башкорт халкы өчен уртак дигән нәтиҗә ясала.

**Әдәбият**

1. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

2. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Т. 1. – 495 б.

3. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика: 2-е изд., доп. / отв. ред. Э. Р. Тенишев. – М.: Наука, 2001. – 821 с.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

5. Ураҡсин З.Ғ. Башҡорт теленең фразеологик һүҙлеге. – Яңыртылған, 2-се баҫма. – Өфө: Китап, 2006. – 344 б.

## ЫРЫМНАР БУШ СҮЗ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

*Мөхетдинова А., Буа, 2 нче лицей, X сыйныф*
*Җит. – Сәлахетдинова Г.С.*

Безнең тормышта ырымнар тулып ята. Алай гына да түгел, һәр ымхәрәкәтне, төчкерү-йөткерүне ниндидер ырымга бәйлибез, нәрсәгә дә булса юрыйбыз. Иртән караватның кайсы ягыннан, кайсы аяктан торып басудан башлап, көн дәвамында ниләр кылуыбыз, нәрсәләр күрүебез, ничек ятып йоклавыбыз – барысы да диярлек ниндидер ырымнарга барып тоташа.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «Ырым – борынгыдан калган, күбесенчә ялган ышануларга, хорафатларга нигезләнгән гадәт, йола 2. Кайбер күренеш һәм вакыйгаларда киләчәкне алдан хәбәр итә торган,

уңышка яки уңышсызлыкка сәбәпче була ала торган тылсым көче бар дип юрау турында 3. Хорафатлар буенча: кешеләргә, табигатькә йогынты ясый торган магик алымнар, чаралар; сихер 4. Ырымчы тарафыннан өшкереп әзерләнгән төнәтмә һ. б. ш. дәвалау чарасы» диелгән.

Тәрҗемә сүзлекләрендә «Ырым – сущ. 1. поверье, верования; халык ырымнары народные поверья (верования); 2. примета, предрассудок; 3. заклинание, наговор, заговор, колдовство, нашёптывание || колдовской; ~ белән дәвалау лечить наговорами; ~ сүзләре колдовские слова; 4. снадобье, зелье» – дип күрсәтелгән.

Ырымнар – борынгы жанр. Алар ыруглык дәверендә үк барлыкка килгәннәр. Аларны магик көчкә ия булган әйтем-формулалар дип әйтә алабыз. Кечкенәдән безгә "пычактан ашама", "бер чыгып киткәч, өйгә кире кермә", "бусага аркылы әйбер бирергә ярамый" ише кисәтүләр ишетергә туры килде. Әмма ни өчен ярамаганын беркем аңлатмый иде. Әлеге ырымнарның барысы да борын-борын заманнардан ук килә. Кешелек дөньясының күпгасырлык тарихы дәвамында халык теге яки бу күренешләрне күзәтеп, шул рәвешле киләчәкне юрарга өйрәнгән. Әлеге ырымнар тормышта ни буласын алдан чамалап, әзерләнеп куярга ярдәм иткән.

Практик ихтыяҗ таләбеннән чыгып, ырымнар ак һәм кара ырымнарга бүленәләр. Ак ырымнарга кешене бәла-казадан, төрле авырулардан саклау ырымнары керә. Кара ырымнар бозу, зыян ясау кебек тискәре максат белән башкарылганнар.

Балаларда үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә халык ырымнардан киң файдаланган. Мәсәлән, өстәл сөрткәндә чүп калдырсаң, киявең шадра булыр; чит кеше мендәрендә йокласаң, чәчең коелыр. Өстәлгә кием куярга ярамый – чир иярер. Киемне кигән килеш тексәң, бәхетеңне тегәсең. Ашагач, өстәл өстен кәгазь белән сөртсәң, талашуга. Ашагач, урындыкны алып куймасаң, ирең ялкау булыр. Ашаганда аякны селтәп утырырга ярамый, шайтан алып китәр. Киемне сул ягы белән төрергә ярамый, бәхетсезлек, диләр. Тоз чәчсәң, тавыш-гаугага. Кеше өлешен ашарга ярамый, бәхетсезлек. Өстәлгә, тәрәзә төбенә, тупсага утырырга ярамый, чир иярер. Баш киеме белән уйнарга ярамый, башың авыртыр. Китек савыттан ашарга ярамый, бәхетең китек булыр. Май күп ашасаң, күзең күрмәс булыр. Кояш баегач өй җыештырсаң, кер юсаң, йорттан бәрәкәт китәр, игелек күрмәссең. Савыт-сабаны юмыйча ятсаң, пәри туй үткәрер. Кайчы белән уйнасаң, талашырсың.

Бу ырымнарның һәммәсе дә балаларны начар гадәтләрдән арындыру, төрле бәхетсезлекләрдән саклау, тәрбия бирү максатыннан уйлап чыгарылган.

Шундый ук ырымнар башка халыкларда, шул исәптән рус халкында да бар. Мәсәлән, 1) Рассыпать соль – к ссоре. Эш шунда: элек тоз бик кыйммәт саналган. Шулай ук тоздан явыз көчләр курка дип уйлаганнар. Шул заманнардан ук кунакларны ипи-тоз белән каршы алу гадәте кергән. 2) Нельзя есть с ножа. Бабаларыбыз өчен пычак – эш коралы, реаль куркынычтан һәм явыз көчләрдән саклану чарасы саналган. Пычак – уенчык түгел, аның белән сак файдаланырга кирәк. Пычактан ашау кешеләрне явызландыра торган көчләрне уята дип уйлаганнар. 3) Дома свистишь – деньги проглядишь. Борынгы халыклар ышануы буенча, сызгыру – өйгә явыз көчләрне чакыру яки йорт иясен үпкәләтү мөмкин дип саналган. Йорт иясе үпкәләп чыгып китсә, үзе белән муллыкны һәм хуҗаларның тынычлыгын да алып китә дип ышанганнар.

Мәчегә бәйле юраулар да төрлечә аңлатыла, кайсыбер милләтләрдә кара мәчегә юлыгу уңышсызлык билгесе дип кабул ителсә, мисырлылар мәчене, нинди генә төстә булуына карамастан, яхшылык кына китерүче хайван дип саныйлар. Элек-электән халыкта яңа йортка иң беренче итеп песи керткәннәр. Хәзер бу йоланың мәгънәсе онытылып бара. Шулай да кайбер кешеләр бу ырымны үтиләр, чөнки мәче өйдәге уңай һәм тискәре энергетик зоналарны билгеләргә һәм аларны нейтральләштерергә мөмкин.

Алда әйтелгәнчә, ырымнар бүгенге көндә иҗат ителмиләр. Хәзер алар кулланылмый башладылар дип әйтергә дә була. Шулай да кайбер ырымнар мәктәп яшендәге балалар арасында популяр булып саналалар. Мәсәлән, Җомга 13е. Бу ырым күбрәк христиан динендәге халык арасында популяр, чөнки мөселманнарда җомга, гомумән, изге көн булып санала. Тик шулай да бу көн безне шикләндерә, куркыта. Нәкъ шуңа да бу көнне күңелсез хәлләр булгалап тора. Татар халкы "Курыкканга куш күренә" дигән бит.

Ырымнарны өйрәнеп, мин шундый нәтиҗәгә килдем: әби-бабаларыбыздан сакланып калган, хәзерге көнгә кадәр җиткән рухи байлыкны югалтырга, онытырга тиеш түгелбез. Бу ырымнарны кызыксынып өйрәнеп, тормышта кулланырга мөмкин. Алар – ата-бабалар сүзе, халык акылы, өлкәннәр кисәтүе.

**Әдәбият**


1. Бакиров М.Х. Ырымнар // Мирас. – 2003. – № 1 – Б. 22–32.
2. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. – Казан, 1941. – 188 б.
3. Мәхмүдов Х. Борынгылар әйткән сүзләр. – Казан: Фикер, 2002. –256 б.


## МИГРАЦИОН СҮЗЛӘР


*Муллахметова Л., Удмуртия Республикасының социаль-педагогика көллияте, IV курс студенты*

*Җит. – Хәкимова В.Х.*


Алынма сүзләр үзләренең керү юллары һәм тарихи сәбәпләре ягыннан өч типка аерылалар: берьяклы, икеяклы һәм миграцион сүзләр.

Кайбер сүзләр чыганак телдә кулланыштан төшеп кала, онытыла, ә алган телдә, киресенчә, активлаша һәм чыганак телгә алынма булып яңадан кайта, ягъни чыганак тел үз сүзен башка телдән ала.

Чыганак телләргә бәйле рәвештә татар лексикасындагы алынмалар көнчыгыш алынмалары, рус сүзләре, фин-угор, төрки, Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләр, интернационализмнарга бүлеп карала.

Алынма сүзләр алган телнең фонетик һәм грамматик закончалыкларына буйсыналар, еш кына семантик яктан да үзгәрәләр. Әмма алган телдә алынмаларда биргән телнең борынгы фонетик, грамматик күренешләре дә саклана.

Язма тел аша кергән сүзләр еш кына график үзләштереләләр, аларда чыганак телдәге әйтелеш саклынмый.

Барлык милләтләр дә берсе белән берсе аралаша, берсеннән берсе тормыш тәҗрибәсе ала. Халыкларның үзара контактлашуы телнең лексикасында чагыла. Борын борыннан халыкларның тарихи контактлары нәтиҗәсендә бер телдән икенче телгә һәм әнә шулай өченче, дүртенче телләргә яңа сүзләр алынган. Мондый сүзләр халыктан халыкка күчеп йөри. Миграцион сүзләр алынма катламга керә, ләкин алар ике тел арасындагы алынмалардан таралыш географиясенең киңлеге белән нык аерылалар. Алынмалар гадәттә территориаль якын ике телгә яки ике төркемгә караса (мәсәлән, рус-татар, татар удмурт кебек), миграцион сүзләр исә төрле система телләргә күчеп йөриләр, алар территориаль яктан чикләнмәгән була. Миграцион сүзләр арасында бик борынгы катлам тәшкил итә торган борынгы Кытай, санскрит, борынгы Иран һ.б. Шундый телләрдән таралган сүзләр хәзерге телләрдә фонетик, семантик һәм морфологик яктан шул кадәр көчле үзләштерелгәннәр ки, еш кына аларның генетикасын ачыклау читенләшә. Өстәвенә миграцион сүзләр аларны башка телләргә тапшыручы арадаш телләрдә үк инде фонетик һәм морфологик яктан арадаш телнең закончалыкларына нык кына ярашкан, буйсынган булалар. Нәтиҗәдә икенче яисә өченче тапкыр үзләштерү барлыкка килә.

Миграцион сүзләрне алынма сүзләрнең бер катламы итеп карау дөресрәк булыр, минемчә. Алар генетик кардәшлекне түгел, ә тарихи контактларны күрсәтә торган мөһим фактлар.

Татар лексикасында да миграцион сүзләр билгеле бер урын алып тора. Рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләргә тукталыйк.

**Инглиз теленнән кергән сүзләр:** комбайн, кекс, рельс, футбол, фильм, доллар, клоун, чемпион, рекорд һ.б.

**Немец теленнән кергән сүзләр:** галстук, бухгалтер, слесарь, ракета, лозунг, полиция, штаб, цех, фокус һ.б.

**Француз теленнән кергән сүзләр:** сезон, балет, багаж, декрет, соус, ресторан, партия, тираж, тариф, ферма, лотерея һ.б.

**Грек һәм латин теләреннән кергән сүзләр:** биология, драма, хор, мотор, сатира, колония, стипендия, композитор, аттестат, логика, конкурс, программа, кредит һ.б.

**Итальян теленнән кергән сүзләр:** аккорд, карикатура, тенор, трио, макарон, вермишель, салфетка һ.б.

Помидор, томат, кофе, какао, апельсин, лимон, банан, ананас һ.б. шундый үсемлек атамалары да миграцион сүзләргә керә. Хайван атамаларыннан барс сүзе дә миграцион катламга керә.

Төрле система телләргә бик борынгы заманнарда ук күчкән сүзләрдән буран, тайфун, чәй, цунами, атлас, альманах һ.б. сүзләрне күрсәтергә мөмкин.

Кайбер миграцион сүзләрнең территориясе таррак та була. Шундыйларга мисал итеп чуман сүзен китерергә мөмкин. Чагыштыр: коми, удмурт: чуман (берестяная коробка, корзина); мари: чоман (большой лубяной короб); чуваш: чуман; татар: чуман (большая корзина, плетенка); мансый: чумпел (ковш); рус: чумич, чумеч (татар әдәби теле); чум (кастрюля). Ике чум сөт җыйдым (минзәлә сөйләше); татар: чуму (нырять). В.И. Лыткин, Е.С. Гуляев коми һәм удмурт телләрендәге чуман сүзен гомумпермь дип, ә мари теленә чоман борынгы чуваш теленнән кергән дип саныйлар.

Чум тамырының һәм аннан ясалган сүзләрнең борынгы төрки язмаларда булуын, аларның таралашын искә алганда, чуман сүзен төрки телләрдән таралган дияргә була.

**Әдәбият**


1. Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле. Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10-11нче сыйныфлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008. – 351 б.

2. Иванов. В.В. Миграционные термины в языках Евразии. – Конференция ностратические языки и ностратическое языкознание АН СССР: тезисы докладов. – М., 1977. – 67 б.

3. Основы финно-угорского языкознания. – Т.1. – М., 1974. – 409 б.


## ӘСӘРДӘ ЭТНОМӘДӘНИ ЛЕКСИКАНЫҢ РОЛЕ

(Аяз Гыйләҗевнең «Тәрәзәләр» хикәясе мисалында)


*Мунадиева М., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Юсупов А.Ф.*


Этномәдәни лексика галимнәрнең күптән инде күз уңында, һәм татар теленең көнкүреш лексикасының бу төркеме шактый тирән өйрәнелгән. Мәсәлән, Ф.С. Баязитова, А.С. Борһанова, Р.Р. Җамалетдинов, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.Ю. Юсупов, Ә.Ш. Юсупова һ.б. хезмәтләрендә киемсалым атамалары, Р.С. Нурмөхәммәтова, Г.Р. Мөгътәсимова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. хезмәтләрендә ризык атамалары, Р.Г. Мөхәммәдова, Й. Мөхәммәтшин хезмәтләрендә “Торак” лексик-тематик төркеме төрле аспектларда тикшерелә.

Тел сүзлек байлыгының этномәдәният лексикасы дип аерылып карала торган катламы халыкның тарихи үсеше дәвамында тупланган төп мәдәни төшенчәләрне үз эченә ала [1: 27]. Бу мәкаләдә А. Гыйләҗевның “Тәрәзәләр” хикәясендәге матди мәдәнияткә караган кайбер берәмлекләргә күзәтү ясалыр.

А. Гыйләҗевның “Тәрәзәләр” хикәясендәге кием-салым атамаларына да игътибар итәргә булдык. Әдипнең әсәрендә күлмәк, халат, итәк, чалбар, алъяпкыч һ.б. кием-салым атамалары очрады.

Күлмәк – 1) хатын-кызлар өчен кофта белән итәге бергә тоташтырылып, яисә билендә җөйсез генә бербөтен итеп тегелгән кием [2: 330]. Әсәрдән мисал: *Ире кайткан көннәрдә Маһирә зәңгәр күлмәген киеп җиңеләеп, яшәреп йөрде...* [3]. 2) Гәүдәнең өске өлешенә киелә торган җиңел кием (ирләр өчен): *Улы үсә төшкәч, күз алдында булсын, дип, аның күлмәк изүенә таккан иде ул аларны* [3].

Сәдәп – киемнең ике чабуын, изүнең ике ягын, җиң беләзеген һ.б. эләктереп тору өчен хезмәт итә торган яссы төймәдән гыйбарәт эләктергеч [2: 496]. Әлеге хикәядә “сәдәп” сүзенең “сәдәф” варианты кулланыла. п~ф чиратлашуы күзәтелә. Шулай ук бу әсәрдә сәдәф гади бер кием элементы гына түгел, ә бәлки символ, хатынның әлеге сәдәфне иренең истәлеге итеп саклавы, аны көтүе, яратуы символы. Мәсәлән: *Бу бәләкәй сәдәфнең Маһирә өчен зур тарихы бар. Өйләнешкән елны ук ире Әхтәри, сигезенче мартка дип, Маһирәгә зәңгәр күлмәк бүләк иткән иде. Шул күлмәкнең җиң очында иде инде ул сәдәф; Тик җиң очындагы сәдәфләрне саклый иде Маһирә* [3].

Әлеге әсәрдә гадәти кием атамалары кулланылган. Бу табигый, чөнки тикшерелгән әсәрдә вакыйгалар сугыштан соңгы авыр чорга карый. Бу вакытта халыкның киемгә ярлы булганы күренә. Шулай итеп без әдәби әсәрләр аша кешеләрнең киенү культурасы үсешен күзаллый алабыз.

Ризык атамалары – матди мәдәният лексикасының бер өлешен тәшкил итә һәм алар халыкның яшәү шартлары, тормышының байлыгы, муллыгы һ.б. белән бәйле [1: 32]. Татарларда ипи, икмәк иң кадерле ризык, бу сүзләр синоним булып торалар. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә дә әлеге ике сүзгә бер үк төрле аңлатма бирелә:

Икмәк, ипи – 1. Ачы камырдан мичтә пешерелгән азык. 2. Ашлык. Үсеп утырган иген. 3. күч. Гомумән ашамлык, азык. 4. күч. Яшәү, көн күрү чарасы; эш хакы халыкка эш бар, икмәк бар. 5. диал. Кәрәздәге чаршын [2: 282]. Без тикшергән әсәрдә ипи-икмәк сүзләре беренче мәгънәдә кулланылдылар: *Өстәлгә ике тәлинкә, юка гына итеп туралган ипи телемнәре һәм ике кашык куелган; Авызына капкан икмәген дә йотып бетермичә, ул, абына-сөртенә, ишеккә атылды* [3].

Шулай итеп, әсәрдә без *ипи, икмәк, өйрә, коймак, сөт* кебек ризык атамаларын очраттык. Әлеге хикәядә ризык атамаларының аз төре кулланылуы вакыйгаларның халык, ил өчен авыр вакытларда баруын

аңлата. Чыннан да, әсәрдә вакыйгалар сугыштан соңгы чорда бара. Ул вакытта халыкның иң төп ризыклары булып, әлбәттә, сөт белән ипи булган, һәм аларны ачлыктан саклап калган. Димәк, әсәрдә ризык атамаларын куллану осталыгы авторга вакыйгалар барган чорны төгәл сурәтләргә ярдәм итә.

Матди мәдәният кыйммәтләре арасында йорт-торак белән бәйләнгән төркем мөһим урын алып тора. А. Гыйләҗевның "Тәрәзәләр" хикәясендә дә без торак-йорт атамалары белән очраштык. Мәсәлән: йорт, өй, тәрәзә, бүлмә, капка, кыек һ.б. Татар телендә йорт һәм өй лексемалары синоним буларак йөрсә дә, аларның аермалы яклары да бар. Йорт бер нигез, гаилә әгъзалары яши торган торакны тулаем, ягъни янындагы барлык каралты-куралары, корылмалары белән тулаем атый. Өй исә таррак мәгънәдә, ешрак йортның эчке өлешен аңлата: *Безне өй туена чакырдылар...; Йортлардагы йөзләрчә тәрәзәләрне күргәч, ул бөтенләй югалып калды* [3].

Тәрәзәләр – өй эчен тышкы дөнья белән бәйләү, яктылык кертү чарасы. "Тәрәзәләр" хикәясендә, исеме үк әйтеп тора, тәрәзә элементы зур роль уйный. Автор фикеренчә, *Кешене тышкы дөнья белән бәйли бит ул тәрәзә... Шуның өчен зур булсыннар алар. Тәрәзә алларында бакчалар, гөлләр булсын...* [3] Әлеге әсәрдә тәрәзә торак-йорт матди лексикасы элементы гына түгел, ә бәлки символ да булып тора. Ул тышкы һәм эчке дөньяны бәйләп тору символы. Тәрәзә төпләрендә гөлләр үсү, тәрәзәдә ут яну – тормыш, яшәеш символы: *Тәрәзәдә ут бар икән, димәк, анда тормыш, тереклек бар!..* [3] Хикәянең төп герое өчен дә тәрәзәләр яшәү мәгънәсенә әйләнә, ул үзенең тормышын "тәрәзәләр" белән бәйли, пыялачы һөнәрен сайлый: *үген тәрәзәләр аңа ниндидер әкиятләр дөньясын ачучы бәхет капкалары булып тоелалар* [3].

Димәк, әсәрдә кулланылган матди-мәдәният лексикасы гади сүз генә түгел, ул ниндидер яшерен мәгънә дә йөртә ала. Шулай ук матди-мәдәни лексика авторга чор картинасын тулырак сурәтләргә ярдәм иткәнен дә күрдек. Автор алар аша үзенең фикерен җиткерә, әсәрен тәэсирле итә.

**Әдәбият**


1. Нурмөхәммәтова Р.С. Татар теленең этномәдәният лексикасы // Татарика-Tatarica. – 2016. – № 6. – Б. 27–42.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
3. http://kitap.net.ru/gilyazov2.php


## ФОЛЬКЛОРНЫЕ СРЕДСТВА ЯЗЫКА В ПОВЕСТИ М. КАРИМА «ДОЛГОЕ-ДОЛГОЕ ДЕТСТВО» И ИХ ИСПОЛЬЗОВАНИЕ НА УРОКАХ РОДНОГО БАШКИРСКОГО ЯЗЫКА


*Мухаметова Г., БГПУ им. М. Акмуллы, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. пед. наук, доц. Тагирова С.А.*


В народном быту башкир пословицы и поговорки служили руководящими принципами деятельности. В процессе своего существования этот фоль-

клорный жанр подвергался некоторой «шлифовке», однако неизменной осталась наставительно-назидательная направленность пословично-поговорочных изречений. Кроме того, неотъемлемым элементом содержания пословиц и поговорок является «цитатность», ссылка на авторитет общепринятого мнения. Значит, пословицы выступают формулами чужой мудрости и опыта, средством аргументации. Очевидно, что пословицы и поговорки ситуативны. Употребляясь в конкретной ситуации, пословицы ставят всю ситуацию в связь с какой-либо общеизвестной закономерностью [2: 6].

Пословица – мудрое изречение, имеющее глубокий смысл, она даёт рассказчику возможность яснее выражаться в своих мыслях. По своей жанровой природе к пословице близка поговорка. Она часто употребляется в переносном значении и в поговорках чаще всего нет смысла, и ограничиваются они различными иносказательными выражениями – это их главное отличие от пословиц.

Ряд лингвистов (Ткаченко П.В., Шанский Н.М., Ефимов А.Н.) вплоть до настоящего времени рассматривают этот жанр народного творчества в одном ряду с фразеологией языка, исходя из того, что пословицы являются воспроизводимыми единицами языка, вносятся в речь в готовом виде и употребляются в иносказательном смысле. Однако между пословицами и фразеологическими единицами имеются существенные различия. Пословица выражает суждение *(Волков бояться – в лес не ходить)* и в речевом контексте остается всегда законченным целым. А фразеологическая единица выражает понятие: *набрать в рот воды* (упорно молчать) и выполняет роль члена предложения. Поговорки, являясь промежуточным звеном в цепи языковых единиц, по семантике и структуре стоят ближе к фразеологии, чем пословицы. [3: 9–10].

В языке повести М. Карима «Долгое-долгое детство» особый интерес представляют пословицы и поговорки: **«Яҡшылыҡтың сиге юҡ – яманлыҡтың төбө юҡ»** (букв.: «У доброты нет предела, у злодеяния нет дна»); **«Мөхәббәт сәсеп, һағыш урҙым»** (букв.: «Посеял любовь, собрал тоску») и др.; **«Ғәҙәт – ҡылыҡтың эйәһе»** (букв.: «Привычка — хозяин характера»; «**Егеттәр теле әйткән һүҙ – ҡырҡылып ауған имән»** (букв.: «Слово, сказанное егетом – срубленный и сваленный дуб») и др. Каждая пословица или поговорка имеет в структуре произведения идейно-смысловую нагрузку. Во-первых, М. Карим сам активно употреблял в обиходе данные жанры; во-вторых, использовал их в контексте речи персонажей, описания событий и т. д. с тем, чтобы, избегая многословия, просторных описаний, придать смысловую ёмкость художественному содержанию.

Так, благодаря пословицам и поговоркам речь Старшей Матери изобилует особой образностью и иносказательностью. Например, примеры из повести: Бәлки, ошонан башлап минең салбарымдың да кеҫәһе тылсымлыға әйләнер. **«Йомарт ҡулға мал керер»,** – ти Оло инәйем [1: 9]. – **Ирем**

**киҫәге – итем киҫәге.** Бар сихыры шунда. – Ошоларҙы әйткәс, Оло инәйем көрһөнөп ҡуйғандай итте. Бәлки, көрһөнмәгәндер ҙә. [1: 12]. – **Арыҡ аттың күгәне киң, тиме.** Шашма! Бер бәрәс бирһәң, хаттин ашҡан [1: 15]. «**Ағас күрке япраҡ, әҙәм күрке сепрәк»,** – тине бер саҡ Оло инәйем [1: 26].

Народная фразеология, восходящая своими корнями в культурные стереотипы и языковое сознание башкир широко используется в языке повести. Многогранность фразеологии в повести указывает, прежде всего, на богатое историческое наследие, воплощает в себе непостижимую авторскую индивидуальность М. Карима и народного сознания, ведь не случайно большинство фразеологизмов получило жизнь именно в народе.

Кроме отдельных слов, в языке повести в качестве особых лингвистических единиц употребляются и более сложные образования, называемые обычно фразеологическими оборотами или фразеологизмами. Например: *Бәхетһеҙлектең бер төнгә һуңлап ҡалыуы, унан* ***өмөттөң өҙөлмәүе*** *бәхеттең бер төнгә китмәй тороуы кеше өсөн ҙур бүләк түгелме ни?* ***Хәйләһеҙ хәйләгә*** *сик ҡуйыу. Бөтә ауылды баҫып торған* ***ҡайғы быуаһы*** *бөтән ерҙән йырылғандар. Үгеҙҙең көслөлөгөн* ***бот буйы*** *малайҙа белә. Тик* ***өҙөлгән өмөт*** *менән ҡалын хәтер генә төҙәлмәй, онотолмай.* ***Балауыҙ һығыу. Ҡыл да ҡыймылдатмай.*** *Йүгергәндән* ***йүн булмай*** [1: 26–29].

В повести «Долгое-долгое детство», автор использует некоторые фразеологизмы для создания экспрессивного фона произведения. Например, фразеологизм *йән тетрәткес* используется автором для создания эмоционального ракурса повествования. Например: *Ҡапыл* ***йән тетрәткес,*** *ғазаплы, әрнеүле бер тауыш минең ҡолағыма, юҡ, ҡолағым аша йөрәгемә бәреп инде* [1: 8]. *Раузаның* ***йән тетрәткес*** *йырынан һуң бәрәү ҙә ҡул сапманы, бөтәһе лә ҡатып ҡалды* [1: 142].

Тематические группы, на которые можно разделить фразеологические единицы и слова в повести, так или иначе характеризуют героев повести, их отношения к действительности, чувства, речь. Поэтому многие слова и фразеологические единицы вступают в синонимические отношения. Повесть насыщена героями, которые по-разному характеризуется автором, в портретной характеристике и в психологических зарисовках встречаются следующие фразеологимы: *Беҙ Түбән ос Ҡара Йомағолдарға китеп барабыҙ. Уның бисәһе бәпескә сирләгән. Беҙгә, беҙгә тип ни инде, Оло инәйемә, йөҙө* ***көл кеүек ағарған*** *Ҡара Йомағол үҙе килеп хәбәр итте* [1: 14]. *Арҡан. Бау ишкәндә ваҡыт тиҙ үтә ул. Осо ла, сиге лә юҡ уның – иш тә иш кенә. – Ҡара Йомағол йомоҡ кешеләрҙән һанала, уның ауыҙынан* ***һүҙҙе көрәк менән ҡайырып алырға*** *кәрәк, тиҙәр. Бөгөн* ***теле-телгә йоҡмай.*** *Бер аҙ шымып тора ла дауам итә* [1: 15]. *Беҙҙең эштә был хәл – игеҙәктәрҙе әйтәм – бары икенсе тапҡыр ғына булды.* ***Бүреһе олоно*** *Ҡара Йомағолдоң!*

*Бер бәрәс кенә, әлбиттә, аҙырағын аҙыраҡ та. Кендек әбейенән уҙып, мин нимә әйтә алам?* [1: 15].

Таким образом, в описании лишь одного персонажа повести, Кара Юмагула, М. Карим использует несколько фразеологизмов для портретной характеристики, изображения эмоционального состояния персонажа.

Образы фольклора и язык народного творчества выступает в творчестве писателя посредником между конкретным национальным явлением и обобщающим представлением.

Применение пословиц, поговорок и фразеологизмов на уроках родного башкирского языка является средством обогащения словарного запаса обучающихся, способствует расширению их кругозора, а так же лучшему их усвоению. Опираясь на изучение повести М. Карима «Долгое-долгое детство», для обучающихся старших классов можно предложить следующие задания:

1. Пословица, поговорка или же фразеологизм из данной повести может быть использована в качестве эпиграфа. Например: «Яҡшылыҡтың сиге юҡ – яманлыҡтың төбө юҡ».

2. Прочитайте пословицы, объясните их смысл и подберите эквиваленты: «Ҡолаҡтан ингән һүҙ йөрәккә еткәс, боҙ булыр»; «Мөхәббәт сәсеп, һағыш урҙым»; «Егеттәр теле әйткән һүҙ – ҡырҡылып ауған имән».

3. Прочитайте фразеологизмы, объясните их смыл и попробуйте нарисовать или изобразить: «йән тетрәткес»; «һүҙҙе көрәк менән ҡайырып алырға»; «бүреһе олоно»; «өҙөлгән өмөт».

Таким образом, изучение пословиц, поговорок и фразеологизмов позволяет глубже узнать культурное наследие своего народа. Сопоставительный анализ пословиц башкирского и русского языков предоставляет обучающимся сравнивать обычаи, традиции.

Язык народного творчества в повести «Долгое-долгое детство» содержит в себе материал для исследования на уроках родного башкирского языка в школе. Анализ фольклорных средств в произведении М. Карима позволяет составить целостное представление о языке фольклора, обогащает речь обучащихся, развивает их языковую и культурологическую компетенции.

**Литература**

1. Кәрим М.С. Оҙон-оҙаҡ бала саҡ. Повесть. – Өфө: Китап, 1982. – 287 б.
2. Нәҙершина Ф.А. Халыҡ һүҙе. – Өфө: Китап, 2006. – 287 б.
3. Ураксин З.А. Фразеологический словарь башкирского языка. – Уфа: Китап, 1996. – 241 с.

## АҚЫНДАР ШЫҒАРМАШЫЛЫҒЫНДАҒЫ МИФТІК САРЫН

*Мүрсәлім Г., Қазақ инновациялық гуманитарлық-заң университеті, PhD докторант*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. док., проф. Каскабасов С.А.*

Қазіргі қазақ поэзиясының өз алдына дамып, жаңалану үрдісінде өзгеше тың ізденістерге бет бұрып келе жатқаны белгілі.

Туған жерге арналған өлеңдердің басым көпшілгінде ақындар қазақтың кең даласын, тау, тас, өзен-суымен қоса жанды бейнеде алынып, онымен сырласады, мұң шағады.

Туған жерді ауылды жырлауда ақындар мифтік таным-түсініктерге жүгіне отырып «ауыл» деген ұғымның өзін ғажайып та киелі сипатпен бейнелейді. Ғалым Т.Жұртбай: «Көшпелі халықтың нысаналық атауына сүйенсек, Жер деген сөздің мағынасының өзі ұлы ұғымдық астардан шыққан. Жер. Біздің жердің жемісін жеп, ырыздығымызды айырамыз. Есесіне ол біздің тәнімізді қойнауына жасырады, денемізді азық етеді. Көне түркі пайымдауынша: «Түбінде бәрімізді осы топырақ жер, қорек қылар. Тек жанымыз ғанаКөк Тәңірге ұшып кетпек», деген қисынмен Жер атанған» – деп жазса [1: 82], тағы бір әдебиеттанушы ғалым А. Шәріп «Ұлттық идеяны халықтың қонысқа көзқарасына қатыссыз елестету мүмкін еместігін» ескере отырып, «Жер – кез-келген этностың, тәуелсіз, таупықты тұрмыс-тіршілігінің кепілі ғана емес оның тамырын тереңнен тартқан таным-түсінігіндегі ең қадірлі, қастерлі ұғымдардың ұйытқысы... Қазақтардың дәстүрлі дүниетанымындағы атамекенді ардақтау, аялау сезімі көне түркілік кезеңде көшпенділердің мифтік-поэтикалық ойлау жүйесіне орайлас, Жер-Анаға табыну тұрғысында қалыптасқан «қоныс-құт-құдірет» формуласына тәуелді», – деген тұжырым жасайды [2: 51]. Осы тұжырымға назар аудара отырып, ұлттық поэзиямызда Алтай мен Атырау, Арқа мен Алатау, Еділ мен Ертістің қасиетті ұғымға айналған мифопоэтикалық нысандар екенін айта кеткен жөн.

Ақындар поэзиясында көнеден келе жатқан дүниеге келгенде кіндік қаны тамған жер, өлгенде де бір уыс топырағы бұйыратын мекен деген ұғымдар сан түрлі тұрғыдан жаңғыртылады.

Сондай-ақ Жанат Әскербекқызының «Жалғыз тал» өлеңінде туған жердің жүдеу халін өз көңіл-күйімен астастыра суреттейтін психологиялық параллелизм қолданылған. Өлеңде жапан далада жалғыз өсіп тұрған ағашты кие тұту түсінігінің сарыны бар. Ағаш культінің негізі-әлем кеңістігі жайлы мифтік ұғымдардан тарайды. Өйткені, әлем ағашы – мифтік кеңістіктердің дәнекері. Ағашқа тіл бітіру, оған адами қасиеттер таңып, көбеюдің, адам өсімінің символы ретінде суреттеу ежелден келе жатқан дәстүр.

Жалғызтал, Жапанда бітіп, жабықтың ба екен,
Жалғыздық көріп, жабықтың ба екен,
Жапырақтарың жамырай жылап,
Жалғыз жолаушыны налыттың ба екен.. Жалғызтал [3: 87].

Белгілі обьектімен қарым-қатынасқа түсу шарты арнау жанрының негізгі белгісі ғана емес, жанрлық форманы тудырушы компоненті болып табылады.

Ол бұл жанрдың құрылымын ұйымдастырушы, поэтикалық киімін кидіруші десе де болады. Даланы поэтикалық тұрғыдан жырлайтын

ақындарда оның кеңдігі, жомарттығы, кешегі тарихы мен бүгінгі халі кейде объект, кейде фон ретінде алынады. Дала – ата-бабалардан қалған мирас. Оның әрбір құбылысы киеге, қасиетке ие деген ұғымдар, лирикалық кейіпкер танымында басты мән иеленеді.

Мәселен, Ырысбек Дәбейұлының таумен сөйлесу сарынында жазылған «Қаратау» өзенінде тау – ескі тарихтың, биіктік пен паңдықтың символы ретінде алынған. Шығармадағы фольклорлық сипатты екі тұрғыдан көрсетуге болады. Оның ең бастысы – туған жерге қатысты. Жалпы, жер ұғымы – ежелден бергі түсінік (мифтік, тәңірлік) бойынша, өзгермеудің, мәңгіліктің, тұрақтылықтың символы. Ең көне мифтік мағынасы: адам баласының туылғанда кіндік аны тамған жер ретінде киелілікке ие. Себебі, анимистік ұғымда «қан – адам жанының заттанған бір бөлшегі». Сондықтан адам кіндік қаны тамған жерге байлаулы болады. Екіншіден, туған жер ата-бабалардың өмір сүрген мекені, әрі жандарының жай тапқан орны. Бұл аталар аруағын қадірлейтін ұғым үшін ең елеулі дәстүр. Сондай-ақ адамның топырақтан жаратылуы туралы мұсылмандық сенім де бұл ұғымды күрделендіре түскен. Туған жерден топырақ бұйыру, алыста жерленсе де, туған топырағына әкеліп жерлеу әрекеттірі осыны меңзейді. Сондай-ақ туған жер көне мифтік түсінікте кеңістікті айқындаудың, жіктеудің сипатын да білдіреді.

А. Темірбайдың «Ашу», «Сезім» өлеңдерінде «Дала – көне тарих куәсі», көп жасаған қария бейнесінде алынады. Дала өткен мен бүгінгі ұрпақтың аралық көпірі символында алынған. Өзінің туған жерге деген сүйіспеншілігін танытуда ақын «Мен өлігін көрсетпейтін жақсы итпін» деген нақылмен тұжырымдап, заман, қоғамның келеңсіздігін «Жындыхана – заман», – дейді. Осындай парықсыздық мол орын алған қоғамдағы арқа сүйері – кең дала, туған ел. Бірақ жамандықтың өтеріне сенеді. Ақынның «Ертістің» бойы өлеңіндегі мифтік-символикалық көріністердің де адамға тән уақыт пен кеңістіктегі шындықтың жарқылы мол бояу мен терең әсерлеп бедерлейтін айшығы қалың басталып, баяу тартатын не тоқырап қалатын әлжуаз қиял емес, желкенін көтеріп, айдан асып кететін асқақ, астарлы, қыран қанатты ой екпіні шырқау зеңгірінен түспей қояды [4: 182]. Яғни, «туған жер» әлемнің реттелген, игерілген, тәртіпке келтірілген, кеңістігі (ата-бабалар қонысы, атамекен, атажұрт). Оның сыртында «жат», «бөтен» кеңістік жауға тән кеңістік иелердің мекені (сиқырлық, зұлым күштердің мекені). қорғанатын панасы, саясы дейтін ұғымдарды жинақтайды. Туған жердің тауы мен тасы, өзен суы бәрі осындай киелі қасиетке ие.

**Әдебиет**


1. Жыр-десте. – Алматы, 2004. – Б. 36.
2. Темірбай А. Автопортрет. – Алматы, 2007. – 126 б.
3. Әскербекқызы Ж. Қаз қанатындағы ғұмыр. – Алматы, 2008. – Б. 18.
4. Бекмұратұлы С. Қасиет // Жұрағат. – 2003. – №2 – Б. 7.

# ГАЗЕТ ТАҚЫРЫПТАРЫН ЗЕРТТЕУДІҢ АСПЕКТІЛЕРІ

*Наби А., Западно Казахстанский иннавационно-технологический университет, магистрант*

Газет беттеріндегі тақырыптарға лингвистердің көп көңіл бөлгені белгілі. Тақырып сөйлем тұрғысынан зерттелді: бір құрамды сөйлем мәселесімен байланысты қарастырылды (Попов), мәтін элементі ретінде зерттелді (Гальперин), мәтінмен өзара байланыстылығы да зерттеу нысаны болды (Лазарева).

И.А. Сыровтың пікірінше, газет беттеріндегі тақырыптар мәтін тақырыбы бола отырып, өзіндік синтаксистік тұлғасы бар, мәтін мазмұнын тікелей немесе жанама түрде көрсетуші және бір лебізді екінші лебізден ажыратып, орын жағынан мәтіннің алдында келетін коммуникативтік бірлік болып табылады [1: 59]. Қазіргі кезде жалпы тіл білімінде газет мәтінінің тақырыптары құрылымдық, семантикалық, функционалдық және прагматикалық тұрғыдан зерттеліп келеді.

Н.А. Кожинаның тұжырымдауынша, тақырып сөйлем емес. Тақырыптағы кез келген тілдік бірлік номинативтік немесе предикаттық қызмет атқаратындықтан, тақырып құрылымына қарай сөйлеммен омонимдес болып келеді. Сол себепті етістіктес тақырыптарда омономдес етістікті сөйлемдермен салыстырғанда коммуникативтілік басым болып келеді де, ал есімді тақырыптарды омонимдес сөздермен, сөз тіркестерімен салыстырғанда предикативтілік мән басым болып келеді [2: 13–14].

Қазақ тіл білімінде газет тақырыптарын сөйлем тұрғысынан зерттегенде, ғалымдардың оларды тақырыпты сөйлемдер қатарында қарастыратынын көреміз. Мысалы, А. Әбілқаев тақырыпты сөйлемнің төрт түрін берген:

1) мекен тақырыпты сөйлем, жалпы және жалқы есімді мекен тақырыптарына жер, су, орман, тау тақырыптары және қала, ауыл, мекеме, ұйым, үй, бөлме т.б. жатады;

2) мезгіл тақырыпты сөйлемге мезгіл мағынасын білдіретін күн, ай, жыл тақырыптары және мезгілдің белгілі бір мөлшерін білдіретін шақ, кез, түс, түн, қараңғы, кеш, күз, жаз, көктем, қыс, т.б. тақырыптар жатады;

3) зат тақырыпты сөйлемге табиғат құбылысының көрініс тақырыптары, үй жиһазы, оқиғаға байланысты басқа да заттар тақырыптары жатады, кітап-журнал сыртына жазылған тақырыптар, газет аттары, бас тақырыптар мен тақырыпша тақырыптары жатады;

4) сан тақырыпты сөйлем [3: 45–48].

Бұл жерде автор тарапынан тақырыптардың тек зат есімнен жасалған түрлері ғана ескеріліп, сөйлем тұлғалы тақырыптар назардан тыс қалған сияқты.

Қазақ ғалымдарының сөйлем туралы көзқарастарын жинақтай келе, Т.Н. Ермекова сөйлемнің сөз бен сөз тіркесінен басты айырмашылығы оның коммуникативтілік қызметінде екенін айтады. «Сөз номинативтік

қызмет атқарады, яғни заттың, құбылыстың не солардың белгілерінің, қасиеттерінің тақырыптары ретінде қолданылады. Ал белгілі бір хабарды жеткізу, әлдене жайында сұрау т. б. біршама тиянақталған ойды білдіру қасиеті тек сөйлемге ғана тән.

Тақырыптарды прагматикалық қырынан қарастыру үлкен қызығушылық тудырып отыр. Прагматика таңба теориясының бір бөлігі ретінде ертеден болғанымен, тілдік құбылыстарды прагматикалық тұрғыдан қарастыру XX ғасырдың 60-жылдарында пайда болды. XIX ғасырдың екінші жартысында тіл білімі саласында көптеген ғалымдардың назары тіл жүйесі құрылымы мәселесін қарастырудан оның қызмет ету ерекшеліктерін анықтауға ауды.

Сонымен, әрбір автор өзіне тақырыпат таңдағанда атауыштық, ақпараттық қызметтермен қатар оның прагматикалық әлеуетін қарастыруға барынша күш салады. Осы мақсатпен адресант қолданысын лингвопрагматикалық тәсілдерін былайша санамалап көрсетуге болады:

• таңбалық сипатта жеткізілетін прагматикалық әсер – тыныс белгілері мен әріптаңбаның көлемі, түсі, қанықтығы, көлбеу немесе тік орналасуы сияқты визуалды түрде қабылданатын таңбалық белгілер;

• оқырманның когнитивтік санасына тікелей әсер ететін этнолингвистикалық, лингвоелтанымдық мазмұндағы лингвокультуремаларды таңдау тәсілі. Бұл аталғандарға адресаттың аялық білімі, тілдік және этнопсихолингвистикалық компетенттілігі сияқты факторлар негіз болады;

• таза ақпараттық емес, прагматикалық-коммуникативтік міндет артылатын тақырыпаттар ретінде логоэпистемалардың**,** тілдегі әр түрлі фразеологиялық бірліктердің, мақал-мәтелдердің құбылысы түрлендіре қолданылуы;

• ұлттық емес, ұжымдық сипатта кеңінен танымал болған кино, музыкалық, опералық шығармалардың кейіпкерлерінің есімдерімен (Никулин, Чаплин, Ревизор т.б.) байланысты қолданыстар».

Тақырыптардың прагматикасы мен бағыттылығы тілдің лексика-семантикалық кеңістігі арқылы жүзеге асырылады. Өткен оқиғаға субъективті авторлық бағалау өзара денотаттық және сигнификаттық мағына байланысқан әр түрлі деңгейдегі әсер ету құралдарының әр қилылығын қамтамасыз етеді. Ол тақырыптардағы әсер ету құралдарының өзара әсерін анықтайды. Прагматикалық орталық адресант факторына, прагматикалық жағдаятқа, бағалай және предикат нысандарына байланысты қалыптасады.

**Әдебиет**

1. Әбілқаев А. Қазіргі қазақ тіліндегі жай сөйлем түрлері. – Алматы: Қаз. мем. оқу-педаг. бас., 1983. – 59 б.

2. Кожина Н.А. Заглавие художественного произведения: структура, функции, типология: (на материале русской прозы XIX-XX вв.): автореф. дис. ... канд. филол наук. – М., 1986. – 24 с.

3. Сыров И.А. Функционально-семантическая классификация заглавий и их роль в организации текста // Филологические науки. – 2002. – №3. – С. 59–68.

# СРАВНИТЕЛЬНЫЙ АНАЛИЗ РУССКИХ И ТУРЕЦКИХ ПОСЛОВИЦ О ЛЮБВИ

*Назимкина А., КФУ, студент I курса*
*Науч. рук. – Башаран В.И.*

Согласно «Толковому словарю русского языка» С.И. Ожегова, «Пословица – краткое народное изречение с назидательным содержанием, народный афоризм» [1: 568]. По сути, это самая элементарная форма поэтической речи, в которой используются различные стилистические приемы, как стихотворный размер, рифма и др. Очень часто пословица обладает необычной, запоминающейся формой, в которой скрыта острая мысль, но при этом в краткой, меткой и образной форме отражена история и запечатлены события. При этом они активно используются и в повседневной речи, являясь некими «уроками морали и наставлений» [2: 18]. «Поспешишь – людей насмешишь»; «что посеешь, то и пожнешь»; «век живи – век учись» и др. Главная особенность пословицы, по мнению многих исследователей – ее законченность и назидательное содержание.

Тема пословиц активно изучается как российскими, так и зарубежными исследователями. В России это: А.А. Потебня, В.В. Виноградов, М.М. Бахтин и др. Среди зарубежных исследователей можно выделить: С. Айдына, О. Аксоя.

Язык, являясь неотъемлимой частью культуры народа, включает в себя национальные особенности. Поэтому и в пословицах находят отражение национальный колорит, стереотипы, культурная специфика. При этом в пословицах и поговорках разных народов есть много интернациональных тем и мотивов. Это вполне понятно, так как народы разных стран и культур имеют, как правило, схожие моральные идеалы. Поэтому, сравнивая пословицы, мы получаем прекрасную возможность существенно расширить собственные знания этих языков, познакомиться с некоторыми обычаями и фактами истории, научиться понимать народную мудрость, приобщиться к общечеловеческим моральным ценностям.

В турецком языке слово «пословица» переводится как «atasözü», что дословно означает «слова отцов», что позволяет говорить о турецких пословицах, как о «словах назидания» и «советах» [5: 89].

Пословицы отражают все стороны жизни людей, отношения, личные качества, поведение и др. Для исследования были выбраны пословицы о любви, так как эта тема имеет общечеловеческое значение. И в русских, и в турецких пословицах данная тема занимает важное место. Говоря о значении слова любовь, здесь можно говорить:

1. О любви к родине: Любовь к родине сильнее смерти; Родина любимая – мать родимая (рус.); [2: 45]. // Ana gibi yar vatan gibi diyar olmaz (Не будет такой любимой, как мать; не будет другой такой страны, как

родина); Bülbülü altın kafese koymuşlar “Ah vatanım” demiş (Поместили словья в золотую клетку, сказал: «Ах, родина, моя!») (тур.); [4: 32].

2. О братской любви: Братская любовь крепче каменной стены; Доброе братство лучше богатства (рус.); [2, с. 33]. // **Kardeşim olsun da kanlım olsun (Пусть и кровник, но мой брат); Allah kardeşi kardeş yaratmış, kesesini ayrı yaratmış (Аллах создал брата, но карман его отдельно) (тур.)** [4: 21].

3. Материнской любви: *И добрая мачеха, а всё не мать; Сердце матери греет лучше солнца (рус.);* [3: 41]. // Ağlarsa anam ağlar, başkası yalan ağlar (если кто и будет плакать, то моя мама, другие будут плакать лживо) **(тур.)** [4: 13].

4. Любви одного человека к другому: Без солнышка нельзя пробыть, без милого нельзя прожить; Где сердце лежит, туда оно и бежит [3: 26].// Aşıka sevdadan vazgeçirmeye say, deryayı kurutmaya say gibidir (заставить отказаться от любви влюбленного, что высушить реку); Aşık alemi kör, dört yanını duvar sanır (Мир влюбленного слеп, все четыре стороны кажутся ему стенами.); Aşk bir deryadır, dalmayan bilmez (Любовь-это река, кто не нырнет, тот не познает (тур.) и др. [4: 6].

Одним из самых главных различий является то, что в турецком языке, говоря о романтичной стороне любви мужчины и женщины, используется лексема «aşk», а для обозначения более глубоких чувств, а также любви к Родине, работе и т.д. используется лексема «sevgi».

Сравнительный анализ русских и турецких пословиц показал, что есть универсальные и уникальные явления для обоих языков: вера в силу любви, ее необходимость в жизни человека, страдание, неподконтрольность, противоречивость и др. При этом любовь часто связана с разлукой, предполагает желание быть рядом с человеком, которого любят.

На современном этапе развития человеческого общества активизируется межкультурное общение. Успешность межкультурной коммуникации безусловно зависит от изучения и сопоставления иностранного языка с родным. В этой связи сопоставительное изучение пословиц разных народов представляется чрезвычайно важным, поскольку именно сопоставление значений является одним из источников получения сведений о культуре, обычаях, традициях, отражающих национальные ценности того или иного народа.

Рассмотренные примеры пословиц, существующих в английском и русском языках, мы нашли как сходные черты, присущие обеим культурам, так и фундаментальные отличия. Фольклор помогает не только понять через язык душу народа, но и увидеть происходившие с ним исторические события, повлиявшие на становление нации и государства, понять быт и условия труда, увидеть отношения к жизни и соплеменникам.

**Литература**

1. Ожегов С.И. Толковый словарь русского языка. – М: АСТ, 2014. – 736 с.

2. Русские пословицы и поговорки / сост. К.Г. Берсенева. – М.: Центрполиграф, 2010 – 250 с.

3. Сысоев В.Д. Пословицы и поговорки. – М.: АСТ Астрель, 2007. – 191 с.

4. Aksoy, Ö.A. Atasözleri Sözlüğü. İstanbul: İnkilap Kitabevi, 1988. – 197 s.

5. Aydın S. Kültürel bir miras olarak atasözlerinin kullanımı üzerine Türkçe Öğretmenlerinin görüşleri // Folklor/Edebiyat. –cilt: 19: sayı 75, 2013/13.

## ПЕРЕКЛЮЧЕНИЕ КОДА, СМЕШЕНИЕ КОДА: ИСТОРИЯ ВОПРОСА

*Нигматуллина М., КФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Ашрапова А.Х.*

Значительный интерес, возникший в начале прошлого столетия, к проблемам двуязычия нельзя считать лишь заслугой развития лингвистики, а важно отметить и заметное влияние роста других наук. Например, психологии, этнографии, социологии, где язык является важнейшим условием связи человека и общества. В свою очередь, в Западной Европе первыми, кто заинтересовался двуязычем были не лингвисты, а именно психологи, которых привлекла проблема влияния билингвизма на развитие ребенка [2: 76].

А также в последнее время значительно вырос престиж проблемы ПК и изменилось отношение к данному процессу. Если раньше переход с одного языка на другой рассматривался, как проявление недостаточной лингвистической компетенции говорящего, ведущего к потере чистоты языка, то сегодня большинство лингвистов признают, что ПК – это сложный, определенным образом организованный и управляемый процесс, требующий мастерства выполнения, т.е. особой компетенции. В последние десятилетия, в связи с тем, что ПК и СК стало неотъемлемой частью коммуникативной системы в современном двуязычном обществе, то и явление билингвизма начало изучаться с новых точек зрения. В современном мире вопросы о ПК и СК являются достаточно разработанными и широко изученными. Но если заглянуть в саму историю изучения вопросов ПК и СК, то можно узнать, что с 1970-ых годов явление ПК рассматривается с 3 основных позиций:

1. Социолингвистический подход. Здесь рассматривается вопрос о том, что является причиной перехода человека с одного кода на другой во время разговора. Например, довольно обширная теоретическая база была разработана учеными П. Мёйскен и Л. Милрой, К. Вулар, С. Альварес-Каккамо. Их исследования направлены на выявление места ПК в конкретных исторических и социальных условиях. Приблизительно в то же время Б. Рэмптон выделил «смешение кодов» (crossing) как определенный тип ПК, который преодолевает границы социальных классов, языковых сообществ и даже этносов.

2. Психосоциолингвистический подход. Данный подход раскрывается в теории К. Майерс-Скоттон и в ее модели маркированности. Рассматривая теорию исследовательницы, можно выяснить, что в любом многоязычном

сообществе каждый язык ассоциируется с определенными социальными ролями, которые обозначены, как наборами прав и обязанностей. Главной идеей данной теории является «переговорный принцип», где в процессе разговора выбор кода происходит так, что им определяются наборы прав и обязанностей собеседников в данной коммуникативной ситуации.

3. Лингвистический подход. Здесь рассматривается проблема различия между действительным ПК и включением в речь отдельных единиц из другого языка – лексическими заимствованиями.

В зарубежной лингвистике рассмотрение проблематики ПК и СК нашло свое отображение в работах: Г. Шухардта (1882, 1884, 1909, 1918), Дж. Баркера (1947), Г. Ворта (1954), Дж. Фишмана (1967, 1968), У. Вайнрайха (1970), Ж. Блома (1972), Дж. Гамперца (1975), Э. Хаугена (1972), А. Мартине (1963) и М. Клайна (1991). Не так давно двуязычной речи (в особенности, изучению ПК и реже - СК) посвящены работы таких зарубежных исследователей, как например, P. Auer, 1999; H. Wolff, 1999; K. Namba, 2000; J. Hammink, 2000; P. Gardner-Chloros, M. Edwards, 2004; R. Redouane, 2005; C. Riehl, 2005; Ch. Nilep, 2006 и других. Одними из самых значимых исследований признают теории К. Майерс-Скоттон (1997, 2002, 2008) и П. Мэйскена (2000, 2004).

В отечественном языкознании началом разработки данной проблемы считается исследование И. А. Бодуэна де Куртенэ (1901). А также ценный вклад внесли труды Е. М. Верещагина, 1967; М. М. Михайлова, 1969; Л. В. Щербы, 1974; Ю. Д. Дешериева, 1966, 1972; В. Ю. Михальченко, 1975; В. А. Ицкович, 1972; Г. Н. Макаровой, 1984 и многих других ученых. А из более современных можно назвать работы О. С. Парфеновой, 1995; С. Г. Васильевой, 1999, 2000; Л. П. Крысина, 2000; С. Т. Санной, 2000; Е. В. Головко, 2001; А. Ю. Русакова, 2004; О. Н. Сычевой, 2005; Е. А. Проценко, 2006; Э. В. Хилхановой, 2008; Г. А. Дырхеевой, 2009; М. Г. Исаевой, 2009 и других [1: 17].

Если рассмотреть ПК и СК на примере русско-английской речи, то этот вопрос будет очень актуальным в наши дни. Но проблема контактирования русского языка с другими языками начала привлекать внимание ученых еще с XIX в., а со второй половины XX в. большинство отечественных ученых начали изучать вопрос англо-русских языковых контактов, где значительное число исследований посвящалось вопросам заимствований из английского языка в русский. Например: Л. Л. Бабалова (1962), В. Ю. Мартинек (1972), С. А. Беляева (1973), В. М. Аристова (1978), И. Е. Аверьянова (1984), В. В. Карапетян (1988), И. Н. Обухова (1991), Е. В. Ларионова (1993), И. Е. Абрамова (1999), В. В. Касьянов (2001), Е. Н. Галичкина (2001); А. М. Антонова (2002), Н. А. Бондарева (2003) и другие [2: 76].

Несомненно, на сегодняшнюю коммуникативную ситуацию в России и в мировом сообществе влияет социально-экономическое и культурное развитие общества. Мы не можем отрицать широту распространения английского языка и такую его значительную социальную функцию в современном обществе, как служение средством общения для различных народов мира. Изучение явления ПК и СК в ситуации билингвизма является главным в теории языковых контактов, развитие которых активизировалось в современном мире, где процессы миграции населения и национальной мобильности приобрели массовый характер.

**Литература**

1. Казакевич, О. А. Смешение и переключение кодов в речи северных селькупов [Текст] / О. А. Казакевич // Речевое общение в условиях языковой неоднородности: – М.: Эдиториал УРСС, 2000. – С. 14–21

2. Сычева О. Н. Кодовое смешение и переключение на английский язык в среде русского социума: Дис. канд. филол. наук. – В., 2005. – 76 с.

## РАВИЛ БОХАРАЕВ – МИЛЛӘТЕБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

*Нургалиева Җ., Казан, 181 нче мәктәп, IX сыйныф*

*Җит. – Валиуллина А.Ф.*

Һәр кешенең тормышы – үзенә бер тарих. Берәүләрнең ул, үз көенә генә аккан елга кебек, тыныч кына, сиздермичә уза. Ә икенчеләрнеке ярсу тау елгасына охшаган: юлында очраган вак-төяк нәрсәгә игътибар итмичә, каядыр ашкына, гел алга омтыла.

Татар әдәбиятында милли проблемалар белән сугарылган әсәрләр күп. Милләт мәнфәгатләрен кайгырткан,аның үткәнен,бүгенгесен бөтен барлыгы белән чагылдырган әдипләрнең иҗаты да онытылмый. Үз иҗаты белән халыкка хезмәт иткән Равил Бохараевка тукталасым килә. Бу шәхеснең татар милләте өчен куйган хезмәтләрен санап бетерерлек түгел. Шагыйрь, журналист буларак танылган Равил Бохараевның Татарстанда, Рәсәйдә генә түгел, ә дөньяның бар кыйтгасында да зур бәя алуы, куйган хезмәтләре өчен бүләкләре турында без нәрсәләр беләбез соң? Туган тел дәресендә укытучыбыз чит җирләрдә яшәп татар халкына тугры хезмәт иткән шәхесләр турында сөйләде. Рудольф Нуриев, Роальд Сәгъдиев, София Гобәйдуллина һәм башка милләттәшләребез турында күбебез белә. Ә менә Равил Бохараев турында сөйли башлагач, аның тормышы, хезмәтләре, иҗаты миңа аеруча тәэсир итте. Татар әдәбятын, мәдәниятын дөньяга танытучы, Тукай иҗатын тирән белгән. Әлбәттә, мин аның эшенә бәя бирә алмыйм, минем белемем, тормыш тәҗрибәм дә алай бай түгел әлегә... Равил Бохараев шәхесе тирән хөрмәт хисе тудырганга, аның турында язарга булдым. Безне, 21 нче гасыр балаларын нәрсә белән шаккаттыру да авыр, ә менә Казанда математиклар гаиләсендә туып, университетта математик-

кибернетик белгечлеге алып, татар, рус, инглиз, венгр телләрендә шигырьләр язган кеше турында китап кулыма кергәч мин шаккаттым.

Кем соң ул Равил Бохараев? Мине аның төрле яклы шәхес булуы игътибарымны җәлеп итте.

Равил Бохараев 1951 нче елның 18 нче октябрендә Казанда туа. Әтисе – Рәис Бохараев (1929–2009) КДУ профессоры, әнисе Найрә Габдрахманова (1929–2008) КДУ доценты, фәннәр кандидаты. Равил Бохараев 1974 нче елда КДУ ның мехматын кызыл дипломга тәмамлый. 1969 нчы елда беренче шигырьләре дөнья күрә.

1977 нче елда Мәскәүдә МГУ аспирантурасын теоретик кибернетика буенча тәмамлый. Ләкин әдәбиятка тартылуы, яшь кенә егетнең фәлсәфи характердагы хезмәтләр яза башлавы аны иҗат дәрьясына алып китә. 1971 нче елда 20 яшьлек студент “ Тень Тамерлана” дигән поэма иҗат итә. “Гаҗәп, тоталь атеизм вакытында язылган бу поэмасында ул христиан һәм мөселман дини китапларының тирән белгече итеп күрсәткән. Еллар узгач бу поэма үзенең әһәмиятен югалтмый, ә киресенчә яңа мәгънә төсмере алды” – дип язды Лидия Григорьева.

Равил Бохараев 1977 нче елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. 1980 нче елларда СССРның иң яхшы шагыйрьләреннән санала. Ул бик күп сәяхәт итә, СССР да яшәүче халыкларның тормышын, тарихын, мәдәниятен өйрәнә. Алтайда озак сәфәрдә була. Бертуктаусыз эзләнгән, күңеленә тынгылык тапмаган математик, шагыйрь, фәлсәфәче, тарихчы, дин тарихларын тирәннән өйрәнгән, дөнья әдәбиятын тирән белгән бу зур шәхесне мин – менә шуңа күрә 21 нче гасыр мәгърифәтчесе дип атар идем. Чынгыз Айтматов: «Произведения Равиля Бухараева настолько значительны по смыслу и формам, что можно сказать с полным основанием и энтузиазмом: Равиль Бухараев – интеллектуальная гордость нации!» – дигән Аксакал, фәлсәфәче, әдәбият белгеченең мондый сүзләре, миңа калса, иң югары бәя. Равил Бохараев 1990 нчы елдан Лондонда яши. 1992–2007 нче елларда Би-би-си да Рәсәйнең штат хезмәткәре буларак эшли. Би-би-си журналистлары аны дөнья мәдәниятләрен, диннәрен якынайтучы, аңлаучы, күпер салучы КЕШЕ дип атаганнар. Шигырьләр, пьесалар, тарихи хезмәтләр авторы, татарчадан русчага, инглиз, венгр телләренә тәрҗемә иткән – барлыгы 40 тан артык китап авторы ул. Шунысы гаҗәп, аның турында мәгълүмат туплый башлагач, интернет челтәреннән татар телендә Равил Бохараев хезмәтләренә кагылышлы материалларга тап булмадым дисәм дә ярый. Шаккаткыч, ничек инде Лондонда, Сиднейда, Нью-Йоркта, Франциядә, Бельгиядә университет программаларына кертелгән кешенең хезмәтләрен бездә ныклап өйрәнүче юк? Әллә мин генә белмимме? Милли китапханәнен картотекасында андый мәгълүматка очрамадым. Равил Бохараевның венгр телендә язылган “Венок Сонетов” җыентыгы венгр та-

рихында әдәбиятта беренче шундый әсәр дип атадылар. Венгрия журналистлары Равил Бохараев турында Татар халкының бөек шагыйре, дөнья гражданины дип атадылар. Бу сүзләргә Равил Раисович "Узем рус телендә язучы татар шагыйре, Казан шәһәренең гражданины" дип атады.

Равил Бохараев 1998 нче елда АКШ та һәм Англиядә Татар поэзиясының тарихи антологиясын инглиз телендә тәрҗемә итеп бастыра. 2008 нче елда Корьәнне русчага яңача тәрҗемә итеп чыгара. Инглиз һәм рус телле аудиторияга Ислам диненең дөрес тәрҗемәсен, асылын аңларга ярдәм иткән кеше ул. Мин аның ул өлкәдәге эшләре белән ныклап таныш түгелмен. Күпсанлы экспертлар, фән белгечләренең биргән бәяләреннән, эшләреннән генә укып фикер йөртә алам.

Равил Бохараев Г.Тукай иҗатын яхшы белгән , аның шигырьләрен тәрҗемә иткән. Кемгә ничектер, миңа калса, алар халык язмышын, авыр тарихын тирән белгән кеше тарафыннан тәрҗемә ителгән сыман. Бу минем фикерем, әйтеп узганымча, минем белемем, тормыш тәҗрибәм дә зур түгел. Ә менә Анна Ахматова, Венера Думаева-Валиева һәм Равил Бохараев тәрҗемә иткән "Китмибез" шигырен берничә тапкыр укыгач, Равил Бохараевның тәрҗемәсе миңа күбрәк якын икәнен аңладым. Бу конференциядә чыгыш ясавымның максаты бар. Чит илдә яшәп ,татар халкын дөньяда таныту өчен, тарихын, мәдәниятен башка кыйтгаларда белсеннәр өчен хәзерге көндә аннан да күбрәк эшләгән кешене табу мөмкин түгелдер. Безгә, 21 нче гасыр яшьләренә, Равил Бохараев кебек мәгърифәтчене өйрәнү бик урынлы, кирәкле эш дип саныйм. Аның хезмәтенә бүгенге көндә эле тиешенчә бәя дә бирелмәгән.

**Әдәбият**


1. Милостыня родного языка // Дружба народов. – 2009. – №3.
2. Призрак совести, или Фантомные боли настоящего // Дружба народов. 2010 .
3. Татарское эго // Дружба народов. – 2009. – №7.


## СҮЗЛЕКЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҖӘМГЫЯТЬ ТОРМЫШЫНДАГЫ РОЛЕ


*Нурмөхәммәтов Ф., КФУ, I курс магистранты*

*Фәнни җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*


Сүзлекләр төзү практикасы һәм теориясе белән тел белеменең лексикография дигән бүлеге шөгыльләнә. Бу төр кулланмаларның һәр халыкта зур тарихы бар. Төрле халыкларда гамәли лексикография формаларының үсешендә охшаш өч чор билгелиләр: 1) *сүзлекләргә кадәрге чор*да төп максат таныш булмаган сүзләрне аңлату булган; 2) *борынгы сүзлекләр чоры*нда бу хезмәтләр әдәби телне өйрәнү вазифасын үтәгән, чөнки ул вакытта күп халыкларда сөйләм теле әдәби телдән бик нык аерылып торган; 3) *нык үсеш алган лексикография чоры* милли әдәби телләрнең үсеше белән бәйле. Бу чорда сүзлекләр телнең сүзлек составын тасвирлау һәм нормага салу, җәмгыятьнең тел-сөйләм әдәбен үстерүгә хезмәт итәләр.

Хәзерге чор сүзлек белеме сүзлекләрнең гаять мөһим иҗтимагый функциясен ассызыклыйлар, чөнки бүгенге көндә әлеге хезмәтләр җәмгыятьнең билгеле бер чордагы белемнәр җыелмасын теркәү белән шөгыльләнәләр. Лексикографиядә сүзлекләрнең типологиясе эшкәртелгән: иң элек аларны *энциклопедик* һәм *лингвистик* дигән ике төргә аералар.

Энциклопедияләрнең төп үзенчәлеге шунда, аларда сүзләр түгел, ә теге яки бу сүз белән белдерелгән реалияләр (предметлар һәм шәхесләр, күренешләр һәм төшенчәләр) аңлатыла. Универсаль энциклопедияләр һәм энциклопедик сүзлекләр белән беррәттән, аерым тармакларга караган энциклопедияләр дә була. Мисал өчен, фәлсәфә, тарих, техника, математика, физика, авыл хуҗалыгы, медицина, тау эшләре, дипломатия, педагогика, әдәбият һ. б. Төрле белем дәрәҗәсенә ия булган теләсә кайсы укучы энциклопедияләрдә үзен кызыксындырган сорауларга җавап таба ала. Энциклопедияләр мөһим үзбелем чарасы санала.

Лингвистик сүзлекләр эчендә *бертелле* (аңлатмалы һ.б.ш.), *икетелле* (тәрҗемәле) сүзлекләр, *уку-укыту сүзлекләре* (телне өйрәнү өчен төзеләләр), *фәнни-техник лексикография* (терминологик сүзлекләр) аерып карала.

Һәрбер сүзлек сүзлек мәкаләләреннән төзелә. *Сүзлек мәкаләсе* – сүзлекнең төп төзелеш берәмлеге, сүзлектәге баш берәмлекне аңлата һәм аның төп характеристикаларын ача торган текст. Сүзлек мәкаләсенең төзелеше сүзлекнең бурычлары белән билгеләнә. Әмма һәр сүзлек мәкаләсе дә *төп сүз*дән башлана (башкача әйткәндә, *баш сүз, лемма, кара сүз* (калын кара хәрефләр белән басылганга) һ.б). Төп сүзләр *лөгатьлек*, яки *сүзлекнең сул ягы*н барлыкка китерәләр.

*Сүзлекнең уң ягы*нда төп берәмлек аңлатыла. Уң як зона һәрбер сүзлеккә аерым эшкәртелә. Мисал өчн, аңлатмалы сүзлекнең уң ягы түбәндәге өлешләрдән гыйбарәт була: сүзнең грамматик характеристикасы, аңлатма, мәгънә тибы (туры, күчерелмә); иллюстрацияләр (цитата, өзекләр); сүзьясалыш оясы; «ромба арты» («заромбовая») дип атала торган өлештә фразеологизмнар һ.б. китерелә. Барлык сүзлек мәкаләләре *сүзлекнең корпусы*н барлыкка китерә. Корпустан тыш, һәрбер сүзлектә кереш сүз, «Сүзлектән ничек файдаланырга» дигән бүлек, шартлы кыскартылмалар исемлеге һ.б. була.

*Сүзлек мәкаләсе* – сүзнең портреты; аны дөрес аңлау өчен, сүзлек мәкаләсен укый, андагы бөтен мәгълүматны ала белергә кирәк.

Тел белән бергә аның нормалары да үсә, камилләшә. Димәк, әдәби тел нормаларын бер тапкыр һәм гомерлеккә өйрәнеп булмый. Әдәби нормаларны үзләштерү өчен, даими рәвештә үз сөйләм культураңны үстерергә, авыр очракларда төрле сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә, алардан тиешле белешмәләр тупларга кирәк.

Хәзерге фәнни прогресс чорында, мәгълүмат кызу тизлек белән туплана торган дәвердә төрле фәнни өлкәләргә караган басмалар агымы көчәя. Бу хәл фәнни, гамәли һәм танып белү характерындагы ышанычлы мәгълүматларны тиз һәм уңайлы эзләү өчен төзелгән төрле белешмә әдәбиятка ихтыяҗны арттыра. Сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән башка хәзерге тормышны күз алдына да китерү кыен, чөнки аларда кешелекнең гаять зур күләмдәге белемнәре тыгызлап (пресслап), алфавит тәртибендә урнаштырыла. Сүзлекләр һәм белешмәлекләр – кешегә тормышта даими рәвештә белемнәрен арттыру һәм тел культурасын күтәрү өчен хезмәт итә торган әсбаплар. Аларны лаеклы рәвештә цивилизация юлдашлары дип атыйлар. Сүзлекләр – чынлап торып милли телнең бетмәс-төкәнмәс хәзинәсе. Алар халыкның тормышы, уй-фикерләре, борчу-хәсрәтләре һәм шатлык-сөенечләре турында тарихи елъязма; сүзлеккә теркәлгән һәр сүз тел хуҗасы булган халыкның тормышы, эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнгән. Сүзлекләр милли мәдәниятнең бер элементы, чөнки сүздә халык тормышының күп кенә яклары чагылыш таба.

Шул рәвешчә, сүзлекләрнең җәмгыятьтәге роле бәяләп бетергесез. Аларның гомуми вазифасы – дөнья һәм милли тел турында белемнәрне теркәү, системага салу, туплау, саклау һәм аларны буыннан буынга тапшыру. Аерым кеше тормышында да сүзлекләрнең әһәмияте бик зур. Сүзлекләрне уку, аларга даими рәвештә мөрәҗәгать итү сүзләр запасын һәм фразеологик байлыкны арттыра; тел нормалары белән таныштыра; сүзләрне, аларның грамматик формаларын уңышсыз һәм урынсыз кулланудан саклый; дөрес әйтелешне формалаштыра. Сүзлекләр телне киңрәк танып белергә, сүзләрне тирәнрәк аңларга, логик фикерләүне үстерергә ярдәм итә.

Бүген җәмгыятьнең рухи тормышында, халыкның мәдәни мирасын аңлауда сүзлекләрнең әһәмиятенә күбрәк игътибар ителә. В.А. Козырев һәм В.Д. Черняк сүзләре белән әйткәндә: «сөйләм әдәбенең гомуми дәрәҗәсе куркыныч төстә түбәнәю үз сөйләмеңә аңлы мөнәсәбәт күнекмәләре формалаштыруда иң мөһим һәм алыштыргысыз кулланма буларак сүзлекләрнең ролен аеруча кискен рәвештә аңларга мәҗбүр итә»[1: 8].

**Әдәбият**

1. Козырев В.А., Черняк В.Д. Русская лексикография: пособие для вузов. – М.: Дрофа, 2004. – 288 с.

2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

## О СУЩНОСТИ ЭТНОКУЛЬТУРНОГО ОБРАЗОВАНИЯ

*Нурмухаметова А., КФУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Тарасова Ф.Х.*

Россия – многонациональная страна, и с древних времен на ее территории проживает более ста коренных народов со своими традициями,

языком и культурой. Духовные ценности страны, которые воплощены в национальных культурах различных народов России, безграничны. Полиэтничность является главным историческим достоянием и преимуществом нашей страны [2].

Наше общество едино благодаря культуре сотрудничества и мирного сосуществования народов, которое сохраняется в течение многих веков. Но все же иногда проблемы межэтнического характера проявляются в повседневной жизни общества: напряженность, возникающая между представителями разных этнических групп, случаи унижения достоинства народов.

Характеризуя современную социокультурную ситуацию в России, исследователи отмечают, что в силу определенных исторических событий последнего столетия, намечается процесс отчуждения человека от своего культурно-исторического наследия, нарушения преемственности поколений. Как результат проявляются элементы унификации культурных образцов, значительно затрудняется этническая самоидентификация подрастающего поколения, с трудом формируется нравственная позиция личности.

В таких условиях закономерно усиление интереса научной и педагогической общественности к вопросам этнокультурного образования. Этническая культура любого народа аккумулирует и отражает совокупность морально-нравственных и культурных ценностей каждого этноса. Передавая из поколения в поколение формы деятельности и поведения, этнокультура, несомненно, содержит в себе огромный нравственный потенциал и выступает гарантом сохранения стабильности и прогрессивного развития общества. Очевидно, что обращение к нравственному опыту многих поколений, к традиционным ценностям, использование богатого ресурса этнокультурных традиций является важным условием успешной реализации задач нравственного воспитания подрастающего поколения.

Поэтому перед системой образования ставится цель – подготовить профессионально компетентную и творчески развитую личность, гражданина определенного этносоциума, культуры, а также гражданина мира. Обучающиеся должны иметь представление об этнических общностях и их культуре, то есть владеть этнокультурной компетентностью. Этнокультурное образование направлено на формирование цельной этнокультурной компетенции, которая сочетает моноэтническую глубину и полиэтническую широту постижения этнокультур [1: 193].

Тема этнокультурного образования освещена в работах многих ученых. Основываясь на общей типологии формирования содержания образования, А.Б. Афанасьева выделяет *этнокультурологический, лингвистический, полиэтнический, историко-культурологический, региональный, этнопсихолого-педагогический компоненты в структуре этнокультурного образования* [1: 194].

*Этнокультурологический* компонент определяется внутренней структурой этнокультуры, обуславливается этнофилологическими, художественно-творческими, поведенческими, мировоззренческими элементами этнокультуры, которые входят в процесс образования.

*Лингвистический* компонент является важной частью этнокультурологического компонента, имеет особое значение для межнационального общения. В современном поликультурном обществе выделяют следующие уровни: этнический, суперэтнический (в России – русский язык), надэтнический (язык международного общения).

Под *полиэтническим компонентом* понимается пространственно-горизонтальная координата модели этнокультурного образования. Этнологические и этногеографические знания о различных этнических группах, традициях и категориях, формируется и полиэтнический компонент.

Историко-культурологический компонент определяется в результате понимания исторического развития этнокультуры, ее целостности, способов вступления в цивилизационный процесс, в систему национальной и мировой культуры.

*Региональный компонент* обращает внимание на этнокультурный материал в конкретном регионе, рассматривая этнологические связи и историко-временные пласты в развитии этнокультуры.

*Этнопсихолого-педагогический* компонент учитывает этническую идентичность, менталитет обучающихся, особенности процесса освоения и осмысления ценностей культуры этноса.

В связи с этим, можно констатировать, что этнокультурное образование нужно для того, чтобы сформировать этнокультурно-компетентную личность. Способствуя сохранению культурного кода нации, творческого переосмысления исторического опыта, этнокультурное образование призвано гарантировать соответствующий мировым стандартам уровень знаний и навыков, осуществлять трансляцию культуры народов республики, регионов, стран.

**Литература**

1. Афанасьева, А.Б. Этнокультурное образование: сущность, структура содержания, проблемы совершенствования // Знание. Понимание. Умение. – 2009. – №3. – С. 189–195.

2. Российский научно-практический журнал [Электронный ресурс] / под ред. Аманжоловой Д.А. – Режим доступа: http://futureruss.ru/worldculture/ethnic-groups/civil_society.html

## А. ПУШКИНЫҢ «КАПИТАН КЫЗЫ» ӘСӘРЕНЕҢ КЫТАЙ ҺӘМ УЙГУР ТЕЛЛӘРЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

*Нуэрсяти Н., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Денмөхәммәтова Э.Н.*

Рус язучылары арасында әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән авторларның берсе – А.С. Пушкин. Аның “Капитан кызы” (Капитанская дочка)

повесте генә дә 16 телгә тәрҗемә ителгән. Алар арасында инглиз, алман, француз, испан, казах, кыргыз, үзбәк, грузин, абхаз һ.б. телләрне күрсәтергә мөмкин. Бу әсәрнең татарча, уйгурча һәм кытайча вариантлары да бар.

А.С. Пушкинның "Капитанская дочька" әсәрен татар теленә – А. Шамов, кытай теленә Лоу Вен Фей, ә уйгурчага Кадыр Хасанов тәрҗемә итәләр. А. Шамов – татар әдәбиятында, иң беренче чиратта, оригиналь проза әсәрләре – хикәяләр һәм повестьлар иҗат итүче буларак танылган язучы.

А. Шамов – әдәби тәрҗемә остасы. Аның тәрҗемәсендә татар укучылары дөнья, рус классикасының, совет чоры рус язучыларының бик күп әсәрләре белән танышалар. Алар арасында Ф. Гладковның "Цемент" (1928), "Энергия" (1934) романнары, немец язучысы Э. Ремаркның "На западном фронте без перемен" ("Көнбатыш фронтта үзгәреш юк", 1930) романы, А. Пушкинның "Капитанская дочка" ("Капитан кызы", 1936), Н. Островскийның "Как закалялась сталь" ("Корыч ничек чыныкты", 1936) һ. б. әсәрләр бар.

Кытай халкын рус язучыларының әсәрләре белән Лоу Вен Фей таныштыра. Ул – филология фәннәре докторы, кытай язучысы, тәрҗемәчеләр җәмгыяте әгъзасы булып тора. Рус телен камил белүе Лоу Вен Фейга рус классик язучыларының катлаулы әсәрләрен кытай теленә тәрҗемә итүгә ярдәм итә. Дөнья әдәбияты киңлекләрендә ул иң элек дөньяның классик әсәрләр тәрҗемәчесе буларак таныш. Шулай ук ул кытай теленә рус язучыларының әсәрләрен дә тәрҗемә иткән. 2014 елда Россиядә чит ил кешеләре өчен үткәрелгән "Чтение России" конкурсында лауреат исеменә лаек була. Лоу Вен Фейның әдәби мирасы бай. Ул үзен язучы буларак та, тәрҗемәче буларак та, фәнни хезмәткәр, галим буларак та танытты. Аның 100дән артык хезмәте бар. Рус җәмәгатьчелегенә кытай теленә А. Пушкин, Л. Толстой. С. Карамзин әсәрләрен тәрҗемә итүе белән таныла.

Кадын Хасанов исә уйгур әдәбияты классигы, Казахстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, драматург һәм тәрҗемәче. Ул А. Пушкин, М. Лермонтов, Т. Шевченко, М. Горький, Джамбула, Низами һәм Нәваи әсәрләрен дөнья телләренә тәрҗемә итүе белән таныла. Ул ике дистә ел Кулҗа һәм Өримчидә яши һәм Кытайда яшәүче уйгурлар өчен күп кенә рус әсәрләрен тәрҗемә итә. Әлеге хезмәте, 1949нчы елда Казахстанга кайткач, уйгур графикасында Алматыда бастырыла һәм кытайда яшәүче уйгурларга таратыла.

Тәрҗемә – бер телдә әйтелгән, язылган фикерне, сүзне, әсәрләрне икенче тел чаралары белән коммуникатив яктан тәңгәл килгән текст рәвешендә бирү. Тәрҗемәнең төп принциплары барлык телләр, тәрҗемә ителә торган барлык материал өчен уртак. Иң мөһиме – төп нөсхәнең эчтәлеге һәм формасы берлеген мөмкин кадәр тулырак саклау бурыч итеп куела.

тәрҗемәләрдә алар шактый гади яңгырыйлар һәм укучыга аңлаешлы итеп биреләләр. “Капитан кызы” әсәрендә шактый күп искергән сүзләр дә кулланылуын ассызыкларга кирәк. Алар сурәтләнә торган күренешне яхшырак тасвирлау, Пушкин чорын белдерү һәм шул чор телен күрсәтүче дәлил буларак киләләр һәм һәр тәрҗемәдә дә кулланылар. Бу исә А.С. Пушкин әсәрен дөрес аңларгпа ярдәм итә.

## УЙГУР ТЕЛЕНДӘ ЯУЛЫК АТАМАЛАРЫ

*Нуэрсяти Х., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

X гасыр башында ислам динен кабул иткәннән соң, дин буенча уйгур хатын-кызлары да, ир-атлары да баш киеме кияргә тиеш булганнар. Төрле яшькә, яшәгән мохитенә, һава торышына һәм гореф-гадәтләргә карап хатын-кызларның һәм ир-атларның баш киемнәре төрле булган [6].

Абдукирем Рахманның 2008 елда басылган “Уйгур гореф-гадәтләре” китабында уйгур халкының мәдәнияте тулы итеп тасвирланган. Анда уйгурларның милли киемнәре, бизәнү әйберләре, туклану культурасы, һөнәрләре, йола-бәйрәмнәре, дини карашлары һ.б. турында бай мәгълүмат тупланган. Мәсәлән, әлеге хезмәттән уйгур милли баш киемнәре турында түбәндәге мәгълүматларны белергә мөмкин. Уйгурларның милли киемнәре арасында баш киемнәре зур урын алып тора. Уйгур ир-атлары нинди ел фасылы булуга карамастан, баш киеменнән йөриләр, ә хатын-кызлар яулык яки доппа (түбәтәй) кия. Туйга яки кешенең кайгысын уртаклашырга барганда баш киеме кию мәҗбүри. Баш киеме киеп йөрмәгән кешене башкаларны хөрмәт итмәүче, әдәпсез кешегә саныйлар [5: 19].

Уйгурларда төскә мөнәсәбәт төрле: ак төс – сафлыкны, кызыл төс – шатлыкны, сары төс – моңсулыкны, күк төсе – бәхетне, кара төс кайгыны аңлата; яшел төс ислам диненең төп төсе булып тора. Чәчәкле бизәкләрнең формаларына, төсләренә карап, кешенең ярлы/бай, кыз/хатын, урта яшьтә / карт, йөклеме / юкмы, шәһәрдәнме / авылданмы икәнен белеп була [1].

Уйгурларда яулыкның (ромал) 25 төре бар: *дака яулык, епь (җеп) яулык, чаи яулык, һәрәң яулык, тивет яулык, гөреп яулык, мәнчур яулык, герпитишен яулык, әйнәк яулык, һеллә яулык, ефәк яулык, болыт тәглип яулык, йон яулык, кәмерт яулык, шаеии яулык, ак яулык, сәрәнгә яулык, пәрән яулык, гыҗым яулык, кәчмер яулык, личек яулык, личек яулык, чүмбәл яулык, тивит яулык, чәчмә яулык.*

*Дака, епь (җеп), чаи яулыклар* 1,5 м озынлыкта, квадрат формасында була. Дака яулык – ак төстә, ә епь (җеп) һәм чаи яулыклар көрән һәм кара булалар. Гадәттә, бу яулыкларны хатын-кызлар берәр гаиләдә кеше вафат булганнан соң, кайгыларын уртаклашу өчен барганда ябалар [6: 292–293].

*Йон* һәм *шаеии яулыклар* ак һәм соры төстә булалар, гадәттә, аларны кыш көне ябалар. Бу яулыкларны кәҗә йонынннан бәйлиләр.

Хатын-кыз *ефәк яулык*ны уң якка бәйләп куйса, ул кияүдә булу мәгънәсен, ә сул якка бәйләсә, ул кияүгә чыкмаганны, баш артына бәйләсә, баласы бар дигәнне аңлата.

*Ак яулык*ны уйгурларда, кеше вафат булганнан соң, аның бертуган һәм туганнан туган кардәшләре бәйли. Бертуганнар 40 көн, ә туганнан туган кардәшләр 7 көн ак яулыктан йөри. Тиешле вакыт үткәч, аны кара яулыкка алыштыра.

*Сәрәнгә яулык*. Сәрәнгә – шырпы кабы дигәнне аңлата, ягъни шырпы кабына сыя торган кечкенә генә яулык булган. XX гасырның азагында ир-кеше хатын-кызның кулын сораганда шул капны бирә торган булган. Хатын-кыз ризалашса, яулыкны муенына сала торган булган, ризалашмаса, капны кире кайтарган.

*Пәрән яулык.* Пәрән – бик-бик юка дигәнне аңлата. Элек хатын-кызның бизәк, мәрҗән урынына муенына бәйли торган яулыгы булган. Хәзерге вакытта стюардессалар муенына бәйли торган яулык булып санала.

*Гыжҗым яулык.* Җыелган, кечкенә дигән форманы анлаткан. Беләзек урынына киелә торган булган. Ун кулына киелгән булса, егете бар, кияүдә дигәнне аңлаткан. Сул кулына киелгән булса, егете юк, кияүдә түгел дигәнне аңлаткан.

*Кәчмер яулык*. Кодагыйлар туй көнне бер-берсенә бирелә торган бүләк булган. Бер-берсенең җилкәләренә салып куйганнар, “мин сине якын иттем, кодагый булдык, апа-сеңел булдык” дигәнне аңлата.

*Личек яулык*. Олы яшьтәге әбиләр бәйли торган, намазлык яулыгы.

*Чүмбәл яулык*. Кызыл төстәге, бизәкле яулык. Туй көнне кичтән киленнең йөзен күрер өчен, кайнана, бүләк итеп, кызның җилкәсенә сала, киленне шул яулык белән беренче тапкыр күрә. “Мин сине кызым кебек якын иттем, әни-кыз кебек гел шулай калыйк,” – дигәнне аңлата. Чүмбәл яулык бүтән кешегә тапшырылырга тиеш түгел, сандыкта сакланырга тиеш.

*Тивит яулык*. Тивит – озын гомер дигәнне аңлата. Туй көнне ике яктан әниләргә, дәү-әниләргә бүләк итеп бирә торган яулык булып санала. “Озын гомер итегез, хөрмәттә, бәхеттә яшәгез”, - дигәнне аңлата.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, кием-салым атамаларының бер өлешен тәшкил иткән баш киемнәре халыкның гасырлар дәвамында формалашкан киенү рәвешенә тугры калган, бары материалы, эшләнгән урыны белән бәйле төгәллекләр кертелү генә телдәге лексик берәмлекләрнең санын арттырган диярга була.

**Әдәбият**

1. Аблыз А. Чинҗан кадимки дәвердеки кием кижәк мәдәнияте хакыда. – Чинҗан: Чинҗан гүзәл сәнгать фотосурәт нәшр., 2009. – 274 б.

2. Зунун Г. Чинҗанның милли кием һәм гөл бизәкләре. – Урумчи: Урумчи Чинҗан халык нәшр., 2009. – 274 б.

3. Мөхәммәт А. Чинҗан таң дәверендә кием-кичәкләр. – Кытай: Кытай иҗтимагый фәннәр нәшр., 2009. – 266 б.
4. Рахман А. Уйгурларның гореф-гадәтләре. – Урумчи: Урумчи Чинҗан яшьләр нәшр, 2008. – 266 б.
5. Торсунтухти А. Уйгурларның гореф-гадәтләре. – Урумчи: Урумчи халык нәшр., 2013. – 208 б.
6. Хошур Я. Уйгурлар. – Урумчи: Урумчи милләтләр нәшр, 1997. – 309 б.

## КӨРКЕМ ПРОЗАДАҒЫ ШЫҢҒЫС ХАН БЕЙНЕСІ
## (Ә. Кекілбаев пен Ш. Айтматов туындылары негізінде)

*Нұрғали Р., Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университеті, II курс студенті*
*Ғыл. жет. – PhD-доктор Кішкенбаева Ж.Қ.*

Көркем әдебиеттегі Шыңғыс хан бейнесі бірсыпыра зерттеулерге арқау болғаны белгілі. Жалпы әлем әдебиетінде де бұл тарихи тұлғаның болмыс-бітімін сомдаған қаламгерлер өз көркемдік әлемінің Шыңғыс ханын бейнеледі.

Ә. Кекілбаевтың «Ханша-дария хикаясы» мен әлемге танымал қырғыз қаламгері Шыңғыс Айтматовтың «Шыңғыс ханның ақ бұлты» повесі – даңқты қолбасшының көркем бейнесін жасауда бір-біріне үндес келген шығармалар деуге болады. Ә. Кекілбаев повесінің өзегіне алынған – тарихи тұлғаға қатысы бар таңғұт аңызының желісі. Бұл туындының бастауында оқырман күздің салқын таңында ұйқысынан оянған ұлы билеушінің жанындағы мазасыздықты біледі. Кәрілікке бет бұрған қаһарлы әміршінің жан дүниесіндегі толқудың сыры тереңде. Ол әуелі тарамыс саусақтарындағы асыл тасты жүзіктерді түгендейді. Бұл жүзіктер – оның өткен сәттерінің тархы, жеңімпаздығының дәлелі ғана емес, жеңіліп тұрып бас имеген асқақ рухтың куәсіндей. Осылайша авторлық баяндау арқылы он саусақтағы жүзіктің тарихы, олардың иелерінің тағдыры мен болмысы оқырманға мәлім болады. Осы жүзіктер тек өрлік пен ерлікті ғана емес, дүниеқоңыздықты да еске салғандай. Әміршінің жеңе алмағаны – ерлік қана емес, дүниеқоңыздық та екен: «Термездің базарында бір саудагердің бұны көргенде жалма-жан саусағындағы жүзігін шешіп алып, жұтып жібергені бар. Бұл қасындағы сарбазға тап сол бойда мұнша дүниеқоңыз саудагердің ішін жарғызып, жүзікті таптыртып алды. Мына біреу күлгін жаһұт сол» [1: 8]. Осылай жүзік түгендеп, олардың тарихын ойында жаңғыртқан ұлы билеушінің есіне көрген түсі оралады. Міне, хикаят желісінің бастау алар тұсы да осы. Жүзіктер тарихы – оқиғаның дәлелдемесі немесе кіріспесі.

Ш. Айтматов повесінде де ең әуелі бас қаһарманның даңқы баяндалады. «Азияның ұлы даласын көктей өтіп, Батыс әлемін жаулап алуға аттанған Шыңғысханның» [2: 264] ұлылығы мен үстемдігін таныта түсетін бір нәрсе бар, ол – көк төсінде жүзген ақша бұлт. «Жол бойы

Шыңғысханның басын күннен көлегейлеп бір шоқ бұлт еріп келе жатқан еді. Қаған қайда барса, әлгі бұлт та соңынан ере жүреді...ол Көк тәңірісінің Жер бетіндегі билеушіге деген шарапатының белгісі болатын» [1: 265]. Автордың кейіпкер туралы әңгімесі оның даңқын, ерекше жаратылысын осылайша таныстырудан басталады.

Ә. Кекілбаев хикаясында алдыңғы қатарда бас кейіпкердің жан дүниесі көрініс береді. Повестің бірінші тарауы түгелімен кейіпкердің өткен күндерді қолындағы жүзік иелерінің тағдырын еске алуға рналған. Жорықты тек жеңіспен аяқтайтын жиһангердің қатыгездігі мен қанқұмарлығы осы жүзіктер тарихымен байланыста танытылады. Бас имегендерді аяусыз жазалап, ажал құштырған билеушінің жүріп өткен жолында тірі қалатындар – басын баққандар. Оның фәлсапасы бойынша (ақиқат осылай): «Басын баққандар тек басын бағатындардан туады. Сөйтіп, бұдан былай дүниеде тек басын бағатындар өмір сүреді». Кейіпкер болмысы осылай танылудан басталса, ары қарай оның көрген тосын түсі жаңа бір оқиғаға мегзегендей болады [4: 130]. Шығарманың негізгі оқиғасына бұрылар арна да осы көрген түстен басталады дедік. Өткен шақтың оқиғасы арқылы бүгіннің өзекті мәселесін тұспалдау – көркем әдебиеттегі өміршең тәсілдің бірі. Тарихта есімдері қалған Ұлы әміршілердің қарама-қайшылыққа толы күрделі болмысы олардың тұтас тұлғасын, сондай-ақ сол заманның тарихи шындығын танытады. Әр пенденің табиғатына тән жақсылық пен жамандық, олардың ішкі жан дүниесіндегі бітіспес тартысы поэтикалық дискурста түрлі қалыппен көрініс береді. Тарихтан белгілі ұлы тұлғалардың, оның ішінде әлемді жаулап алушы әміршілердің мықтылығы мен әлсіздігін суреткер Ә. Кекілбаев барынша терең, жан-жақты танытады. Нәпсі алдындағы әлсіздік – жұмыр басты пенденің бәріне ортақ осалдық. Мұндай дәрменсіздік, әлсіздік, әсіресе, әлемді жаулап алушы ұлы әміршілерге тән екенін автор көркем баяндау арқылы жеткізеді. Күллі жаһанды билеуге ұмтылған пенделік пиғыл көргенін өзінен өзгеге тиесілі емес деп түсінеді. Байлық та, билік те, сұлулық та оның құзырында болып, дегеніне көнуі керек екен. Бұл тойымсыздық пен өлермендік ақыр соңында өз басына ажал боп келерін білді ме екен олар? Әділет пен өзімшілдіктің арасындағы тартыс Ә. Кекілбаевтың «Ханша-дария хикаясының» алғашқы тарауында Термездің базарындағы саудагердің қолындағы жүзікті жұтып жіберетін дүниеқоңыздығына таң қалған Шыңғыс хан сол саудагердің қарнын жарғызып, жүзікті алдырған өзінің дүниеқоңыздығы басым екенін білмейді. Адам бойындағы дүниеқоңыздық, ашкөздік секілді нәпсілік дерттермен күресіп жүрмін деп түсінетін Шыңғыс ханның өзі қандай жан сонда? Ел намысы мен әйел намысын бәрінен жоғары қойған таңғұт әміршісінің жары Гүрбелжінді бауырына баспақ болған ниеті өзіне ажал

болып келген билеушінің күллі болмысы психологиялық иірімдермен беріледі. «Дүниеде билеуші атаулы бет-ажары келіскенмен, денесінде тыртығы бар сұлу әйелмен бірдей ғой. Әлгіндей әйел сыртынан алдына келген еркектің құлқынын құртып, құмартқызып отырғанмен, ішінен әлем-жәлем боп, қорынумен болады. Сұлулығыма табынған еркек денемдегі мінімді біліп қоймаса екен деп қуыстанады. Өйткені, әлгі міні білініп қойған күні сұлу аты да құриды. Билеушілер де сыртымен ықтырып отырғанымен, ішінен сескенеді, бағыныштысын бойына дарытқысы келмейді. Ал сарай маңының сабылмаларының да нәпсіқор еркектердей қашан барлық гәпті біліп болғанша өліп-өшетін ескі әдеті бар» [1: 12–13]. Сырттай айбарлы, айбынды, жеңілмейтін асқақ жеңімпаздың іштей қорқақ, үрейшіл, үркек болуы оның қандай жан екенін оқырманына айғақтаған үстіне айғақтай түседі. Оның осы үрейі санасына маза бермей, ауыр түстер көреді. Сол көрген түстері үрей үстіне үрей қосып, көңіліне секем ұялатады. Бұл құпия жанның кім екенін әмірші тани кетеді: «Бейсауат адам, міне, бұның өзін тінтіп, тергеп-тексеріп тұр. Үстінде аю терісінен жасалған кеудешесі бар. Тани кетті. Мынау, апыр-ау өзі ғой. Баяғыда соғына шырақ алып түскен дұшпандарынан жасырынып, тау ішінде Қасар мергенге еріп қашып-пысып жүргенде тап осындай еді ғой». Болмысының әйтеуір бір бұрышына жасырынған адами сауал әміршінің өзіне өзі болып көрінумен тұспалданады. Әмірші өзінен өзі сескенетіндей. Өзі-өзі үрейлендіретіндей. Әмірші өзінің пенделік нәпсісінен аса алмайды. Осыншама үрей мен секем тәубеге келуге емес, керісінше, тағы да жорыққа шығып, бір елді тізе бүктіруге шақырғандай. Ұйқы мен ояудың арасындағы әмірші халі тым құбылмалы. Ұйықтап жатып ағыл-тегіл жылайды да. Жарты әлемді бағындырған билеушінің жылауы жай емес. «Өлшеулі ғұмырдың алдамшы жылдары» баяншы айтуында «аяр ажалдың мойнына салып қойып, шошытып алмайын деп, қатты жұлқымай бір шетінен шым-шымдап өзіне тартып жататын әзәзіл жібек тұзағы» [1: 17] сияқты сезіледі. Баяншы осылайша кейіпкер болмысын ішкі сезім құбылысы, ойы, күйзелісі мен ширығуы арқылы ашады. Ат үстінен гөрі мамық төсекке бейімделе бастаған Ұлы билеушінің пенделік ындыны әлі де болса тыйылмағандай. Түсіне жалаңаш әйелдің кіргенін ойымен сан саққа жүгірткен әмірші арман-мақсатынан жаңылғандай күй кешеді. Повесть оқиғасының дамуында аңға шыққан әмірші мен Қасар мерген арасындағы диалогтың маңызы ерекше. «Автордың назарынан Гүрбелжін сұлудың көңіл-күйі де тыс қалмаған. Ерекше жаратылған ару тек сырт сұлулығымен ғана емес, ішкі рух қуатымен, қайсарлығымен, намысымен аңыз кейіпкеріне айналса, мына повесте жарына адал, ел намысын биік қойған асқақ жан ретінде Шыңғыс ханның өр тұлғасын аласартқандай болады. Шыңғыс хан – Шидүрге / Гүрбелжін тартысында жеңіске жеткен

кім, жеңіліс тапқан кім? Елін талқан етіп, ерін өлтірген қатыгез жаннан ару әйел кек қайтарды. Яғни, түбегейлі жеңіске жеткен Шидүрге. Ол өліп кетсе де сағы сынбаған, дұшпанын табанына сала алған. Ару әйелдің алдында дәрменсіздігін билеуші өзі де мойындаған. Оның асқақтығына бас иіп, желең көйлегін жеке отауда ұстауды, ол отау ұлы әміршінің Кіші Ордасы болып саналатынын өсиет етеді.

**Әдебиет**

1. Кекілбаев Ә. Ханша-Дария хикаясы. Балладалар мен роман. – Алматы: Атамұра, 2003. – 320 б.

2. Женетт Ж. Фигуры. – М.: Сабашниковых, 1998. – Т. 2. – С. 944.

3. Айтматов Ш. Ғасырдан да ұзақ күн. Роман, повесть. – Алматы: Атамұра, 2005. – 312 б.

4. Кішкенбаева Ж. Баяндау дискурсындағы нарратор-автордың өзіндік сипаттары (Б.Майлиннің «Шұғаның белгісі» хикаяты бойынша) // Л.Н. Гумилев атындағы Еуразия ұлттық университетінің Хабаршысы. Гуманитарлық ғылымдар сериясы. – 2015. – № 5 (108). – Б. 129–135.

## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ ИҖАТЫНДА ФОЛЬКЛОР ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Пазюкова И., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалиева Л.Ф.*

Татар халык авыз иҗаты белән кызыксыну, аерым кешеләр тарафыннан аны өйрәнергә тырышу, иҗатчыларның әледән-әле халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итүе инде күптән яшәп килә. Әмма гаҗәеп дәрәҗәдә бай, күп кырлы татар фольклорын фән буларак өйрәнә башлау, аның үсеп китүе узган гасырның беренче яртысына туры килә.Татар халык иҗатын туплау, анализлау, өйрәнү эшенә беренчеләрдән булып тотынучылар арасында Нәкый Исәнбәт тә була.

Халыкның рухын – фикерен, моңын, уйларын, хыял омтылышларын заман укучысына һәм киләчәк буыннарга барып житәрдәй итеп сурәтләү сәләтенә ия булган талантлы художниклар турында сүз чыкканда, шуларның берсе итеп Нәкый Исәнбәт исемен телгә аласы килә [3: 19].

Нәкый Исәнбәт – беренче чиратта һәм иң элек күп гасырлык бай тарихы булган татар әдәбиятының үз туфрагында житешкән, үз традицияләрендә үскән талант иясе. Ул – татар әдәбиятын үзенчәлекле әсәрләрбелән баеткан талантлы язучы. Нәкый Исәнбәт – татар драматургиясенең Г.Камал кебек олы шәхесләр башлап җибәргән традицияләрен дәвам итүче дә, халык авыз иҗатының бай хәзинәләрен туплап эшкәрткән зур галим дә. Әмма Нәкый Исәнбәт хаклы рәвештә татар әдәбияты мәйданында барыннан да бигрәк зур драматург буларак бәяләнә. Чыннан да, әдипнеңуннарча елга сузылган иҗатында төп урынны драматургия алып тора. Комедия өлкәсендә булсын, трагедия яки драма өлкәсендә булсын, ул бердәй уңышка ирешә, драматургиябезнең биекләрен билгеләрдәй классик камиллектәге әсәрләр иҗат итә [1: 39]. Галимнәр һәм тәнкыйтьчеләр язган тикшеренүләрнең иң зур күпчелеге дә аның драматургиясенә багышланган.

Н. Ханзафаровның, А. Әхмәдуллинның, И. Нуруллин һәм Һәнүз Мәхмүтов кебек галимнәрнең монографик хезмәтләрендә һәм мәкаләләрендә бу иҗатның этаплары, андагы аерым җанрларның эчтәлеге, идея һәм сәнгатьчә йөзе шактый тулы яктыртылган [5: 354].

Әдипнең драматурглык иҗаты гаять авыр һәм катлаулы елларга туры килә. Әдәбият мәйданының сирәк кыяларыннан берсе булганга, заманның җил-давыллары аның йөзенә сызгырып, бәрелеп узалар [4: 28].

“Җирән чичән белән Карачәч сылу” әсәрендә иҗат кешесенең туры рухани иреге яклана һәм ул ирекнең хан деспотиясе белән килешкесез каршылыкта булуы тасвир ителә, хакимият һәм иҗат, деспотея һәм рухани бәйсезлек мәсьәләсе куела. Хан Җирән чичәнгә үз сакалын теләгәнчә сыпырырга да хакы юклыгын аңлатканда, автор шушы гротеск – арттыру аша Сталин деспотиясенә ишарә ясый түгелме?

Нәкый Исәнбәт фольклор байлыгыннан оста файдалана,әсәрләрендә сурәтләнгән вакыйгалар әкият элементлары белән үрелепбара. Әсәрләренең теле бик образлы, төрле бизәкләргә, сурәтләүчараларына гаять бай.Күтәренке стиль тудыру өчен гади сөйләмгә шигъри элементлар,аеруча рифмалаштыру китереп кертә, мәкаль-әйтемнәрне иркен куллана. Бер генә мисал алыйк: “Тукта, акылың озын булса да, телеңнән озын түгелдер” [3: 344].

Фразеологик әйтемнәр – халкыбызның күңел энҗеләре. Н. Исәнбәт әсәрләрендә алар чиксез күп кулланылган: “Җибәрәмме соң кулыма төшкән чакта?.. Синең өчен хан тагын минем башымны алсынмы?” [3: 346], “Нигә телсез калсын, әйтте ич” [3: 264].

Нәкый Исәнбәтнең язу стиле турында сүз барганда традицион фольклор чаралары – метафора, метонимия, чагыштыру, сынландыру – да аеруча үзенчәлекле чагылыш тапканын әйтү кирәктер. Түбәндәге мисаллар карап үтик: “Әллә кеше. Әллә чыжым баганасы (метафора)”, “Сокланышып тып-тын калган бөтен мәйдан (метонимия)” [3: 269]. “Пылау өстендәге йөземем! Эрбет чикләвегем!” (сынландыру) [3: 276].

Драматург үзенең үзәк каһарманнары булган Җирән чичәнне һәм Карачәч сылуны халыкта барлык гүзәл сыйфатлар гәүдәленеше итеп бирә.Әхлакый саф, тугры, байлыкка. малга битараф, тапкыр, куркусыз шушы ике чичән дәүләт идарәсенең масаюлы тәкәбберлеген, әхлаксызлыгын, мәкерен һәм кансызлыгын җинеп чыгалар. Автор таланты белән бу шундый табигый һәм ышандыргыч итеп бирелә ки, әсәр тулаем халыкта үз-үзенә, үз көченә ышаныч уята, аның яшәячәгенә иманны ныгыта.

Әлеге драма әсәрендә XIV йөзнең урталарында Идел буенда барган вакыйгалар сурәтләнә. Җирән Чичән шулай ук – халык тарафыннан тудырылган образ. Әдипнең бу әсәрләрендә дә, башкаларында да хезмәт кешесенең кайгы-хәсрәтләре, көндәлек проблемалары күрсәтелә.

Н. Исәнбәт аларны мәрхәмәтсез, кайчак надан, куркак хаким сыйныфларга каршы куя. Уңай геройлар, үзләренең зирәклекләре ярдәмендә, тормыш киртәләрен җиңеп чыгалар. Н. Исәнбәт халык авыз иҗатында киң таралыш тапкан фикерләргә таяна, үз әсәрләрендә шуларның иң куәтлеләрен ассызыклый. Әдип, тарихны халык тудыра дип санаганга, шулай эшли.

Халыкчан мотивларны сюжетка салу, сурәтләү чараларын, әкият-такмазаларны, татар халык җырларын урынлы куллану аның иҗатын искиткеч мавыктыргыч һәм халыкчан иткән.

Кыскасы, Нәкый Исәнбәт иҗаты XX йөз башы татар мәдәнияте белән безнең чор арасындагы җанлы күпер булып тора.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр исемлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Гозәеров Г. Нәкый "Ревизоры" // Башкорстан. – 1930. – 15 январь.
3. Комедия һәм драмалар. – Казан: Татгосиздат, 1955. – 135 б.
4. Кырлай егете. Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 328 б.
5. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 544 б.


## ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ С КОМПОНЕНТОМ «ВЕТЕР» В РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ: ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ КОММЕНТАРИЙ


*Покушева М., ТюмГУ, студент III курса*

*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Ермакова Е.Н.*


2. Хадиева Г. К. Татар теле фонетикасы. Лекцияләрнең конспекты. 2014. – 17б. [Электронный ресурс]. URL: https://docviewer.yandex.ru/view/661606178/

## ТУГАН ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘ ММЧ РОЛЕ

*Сабитова З., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Кузьмина Х.Х.*

Массакүләм мәгълүмат чаралары (ММЧ) − бүгенге дөньяда җәмгыятьнең бөтенлеген тәэмин итүче факторларның берсе. Аның балаларга ни рәвешле тәэсир итүен, нинди алымнар ярдәмендә үзаңнарын формалаштырырга ярдәм итүен ачыклау кирәк. Яшүсмерләрнең киләчәктә нинди шәхесләр булып үсүенә аларның бүген нәрсә караулары, тыңлаулары һәм укулары да турыдан-туры йогынты ясый, чөнки нәкъ менә бу яшьтә яшүсмернең дөньяга үз карашлары туплана башлый. Еш кына үзе яратып караган канал, укыган басма матбугат укучыда ышаныч тудыра, ул андагы фикерләрне һәм аларның бирелешен дөрес дип кабул итә, үзенә үрнәк итеп ала. Яшүсмерләрдә ышану һәм бар мәгълүматны сеңдереп бару

бигрәк тә еш күзәтелә. Шуңа да аларның сыйфатлы һәм дөрес тәрбия бирә торган материал укулары аеруча мөһим.

Татар теленең үсеше яшьләрнең аны ни дәрәҗәдә белүенә бәйле. Әлеге вазифа турыдан-туры алар укый торган басма матбугат җилкәсенә төшә. Тел кануннарын формалаштыруда матбугат зур роль уйный. Татар халкында «ташка баскандай» дигән гыйбарә яши. Әлеге сүз бүгенге көн өчен дә актуаль: кеше Интернетка да, электрон газета-журналларга да түгел, ә нәкъ менә кәгазьгә басылган материалга ышана, аны дөрес дип саный. Бу, чыннан да, шулай: бастырып чыгарганчы, материал күп тапкыр тикшерү аша уза, хаталар минимиаль дәрәҗәдә очрый. Матбугатта тел проблемаларын, бигрәк тә газета-журнал телендә киткән стилистик, орфографик, пунктуацион хаталарны тикшерү кирәк. Шуңа күрә вакытлы матбугатта чыккан хаталарны барлау, төзәтү һәм аларны киләчәктә булдырмау ММЧның төп максатларыннан берсе булырга тиеш.

«Ялкын» − урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларының айлык татар журналы. Биредә басылган материалларның төп үзенчәлеге – аларның нәкъ менә балага, яшүсмергә йөз тотуы. Шуңа да һәр язмада диярлек «дустым», «син» сүзләре очравы табигый. Мәсәлән, Эльвира Һадиева «Җитмеш чакрым юлны кичтек без» («Ялкын», гыйнвар, 2015) язмасында «Ә сез үз сәяхәт маршрутыгызны төзергә әзерме инде, Колумб дусларым?» дип мөрәҗәгать итә.

Журналда иң еш очрый торган хата − сүз тәртибе бозылу. «Төрле яктан мине атлар эзәрлекли: шигърияттә, рәсем, дизайн сәнгатендә...», − ди Илнур Низамиев «Алар гасырлар буе безнең белән...» язмасында («Ялкын», гыйнвар, 2015). Шул ук язмадан тагын бер мисал: «Тракторлар, машиналар кулланышка керү белән атлар китте кешедән» («Ялкын», гыйнвар, 2015).

Журнал битләрендә «самолет, «вертолет» ише сүзләр шул килеш тәкъдим ителә. Монысы телне артык катлауландырмау максаты белән, яшүсмер теленә якын телдә язу өчен эшләнә. Шул ук вакытта яшүсмерләр белән бер дулкында булу өчен, алар кебек «сөйләшә»: сленг, неологизмнар еш күзәтелә. Неологизм түбәндәге җөмләдә очрый. Эльвира Һадиева, «Җитмеш чакрым юлны кичтек без»: «Серле дөньялар чакыра калса, күңелең гел каядыр ашкынса, димәк синдә – сәяхәтомания» («Ялкын», гыйнвар, 2015). Сленг сүзләр очраган язмага мисал итеп Лиана Мәрданованың «Син – чынмы, әллә ялганмы?»сын китерәбез: «Диварыңа кем кергәнен белеп була дигән хәбәр таралгач, Вконтакте социаль челтәрендә фейк битләр шактый күбәйде». («Ялкын», гыйнвар, 2015). Резидә Әлмиева, «Мин» – дөньяның үзәге: «Фотоларның нindиләре күбрәк – үзең генә «чекиниться» иткәннәреме, төркем белән төшкәннәреме яки көзге каршына басып, үстергән буеңны күрсәткәннәреме?» («Ялкын», август, 2015).

«Ялкын»да дөнья күргән материалларда гади сөйләм сүзләренә дә юлыгырга мөмкин: «Һәй, егетләр, Rap бәрәбезме?» («Ялкын», июнь, 2015).

Кайбер сүзләр татар теленә тәрҗемә ителсә дә, җәя эчендә аларның русча тәрҗемәләләре бирелә. Монысы ике төрле аңлау мөмкинлеге калмасын өчен эшләнә. «Баш түбәсенә чәчне аз гына күпертеп (начес ясап) өяргә, көдрәләтергә һәм тузгытырга мөмкин». («Хыялга өч адым», май, 2016). Кайбер сүзләр исә шул килеш, ягъни рус телендә, куштырнаклар эчендә бирелә. Гүзәл Мортазина: «Төенчекләр белән хушлашырга вакыт», «Электрон карталарның тагын берсе – җәмәгать транспортында кулланыла торган «проездной»лар ( «Ялкын», май, 2016).

Журнал битләренә күз салсак, беренче карашка, хата юктыр кебек. Җөмләләр төзек, камил, орфографик һәм пунктуацион, стиль хаталары аз, тик шулай да очрый. Чаткы Ялкынлы «Фотобум: безнең көн сурәтләре»: «Фотоларымны гомумән социаль челтәрләргә куймаска тырышам» («Ялкын», август, 2016). «Гомумән» – кереш сүз, ике яктан өтер белән аерылырга тиеш. Хәреф хаталары. Чаткы Ялкынлы, «Ерактан гына булса да»: «Белеме буенча – икъдисадчы, ә күңеле белән – иҗатчы ул, әйтерсең, бу дөньяга моң таратыр өчен килгән...» («Ялкын», август, 2016).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: журнал әдәби, камил, яшүсмер өчен аңлаешлы һәм җиңел телдә чыгарыла, әмма, сирәк булса да, хаталар очратырга мөмкин. Журналда булган бар нәрсәне укучы дөрес дип кабул итә, шуңа да хаталарны булдырмау мөһим. Язмаларда яшүсмерләр сөйләменә хас неологизмнар, сленг сүзләр, гади сөйләм сүзләре актив кулланыла. «Ялкын» замана белән бергә атлый.

Журнал саф, чиста татар телендә чыгарылып, яшүсмерләрнең телен камилләштерүдә, әдәби сөйләм күнекмәләрен арттыруда, һәм гомумән, аларның белемле, зәвыклы шәхесләр итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

**Әдәбият**

1. Гарифуллин В.З. Журналист осталыгы: югары уку йортларының журналистика бүлеге студентлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан, 2004. – 347 б.

2. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 147 б.

3. Хаков В.Х.. Тел – тарих көзгесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 234 б.

## ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ҮСЕМЛЕК АТАМАЛАРЫ

*Сабитова Л., Бөгелмә р-ны М. Өнҗәл ис. лицей-интернат, X сыйныф*

*Җит. – Доган Д.И.*

Җыр – халык лирикасының иң киң таралган төре, сүз белән көйнең үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкарыла торган поэтик-музыкаль әсәр, яки, киң мәгънәдә алганда, шундый төр әсәрләрне белдерә торган жанр. Җырның төп функциясе халыкның һәм шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыруга кайтып кала. Шушы үзенчәлекләрдән чыгып, Г. Тукай аларны «халык күңеленең көзгесе» дип атаган.

Татар халык җырларында бигрәк тә үсемлекләр атамалары бик еш кулланылган. Мондый җырлар халык күңеленә кереп, бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаганнар. Алар табигать күренешләрен сурәтләү белән генә чикләнмиләр, шулай ук кешенең эчке дөньясын, рухи халәтен, туган якка, сөйгән ярны сагыну, саргаю, ярату кебек хисләрне дә сурәтлиләр. Элек-электән кешеләр үсемлекләр ярдәмендә хисләрен белгерткәннәр. Һәрбер үсемлек үзенә генә хас мәгънәгә ия. Мәсәлән, гөл –мәхәббәт, ландышлар – сафлык, каен – ялгызлык, ә имән – тормыш символы.

Җырларны үсемлекләр кергән җырлар һәм агач атамалары кергән җырларга бүлеп карарга була. Агач атамалары кергән татар халык җырлары бихисап. Шуларнын арасында: «Өй артында шомыртым», «Ак каен», «Бөрлегән», «Талларым» , «Бөдрә тал» , «Алмагачлары», «Тал бөгелә» һ.б. да бар.

1) ***«Ак каен»*** җырындагы каенны һәр яз саен кеше күңеле кебек яшәреп, бизәнеп торган агачка тиңләп була:

Ап-ак ***каен*** – инде бик карт каен,
Яшел яфрак яра һәр ел саен,
Кояш җылы нурын сипкәндә
Бизәлә ул язлар килгәндә (Татар халык җыры).

2) ***«Бөрлегән»*** җырында мәхәббәт хисләре яктыртыла. Сөйгән яр үзенең яраткан кешесенең күзләрен ***бөрлегән*** белән чагыштырып, сагынганын аңлата:

***Бөрлегәнем, бөрлегән,***
***Бөрлегәндәй*** **күзләреңне**
Бик сагындым, бергенәм,
Бик сагындым, бергенәм (Татар халык җыры).

***«Өй артында шомыртым»*** җырында туган илнең **бөрлегәндәй** чәчәк булып атканы сурәтләнә:

Өй артында шомыртым бар,
Яннарында ***бөрлегән*** шул,
***Бөрлегәндәй*** матур булып
Чәчәк ата ил генәм.
Яннарында бөрлегән (Татар халык җыры).

3) Татар халкында ***тал*** образы көчле рухны, авырлыкларга бирешмәүне, сынмауны белдерә. ***«Бөдрә тал»*** җырында сөйгән ярны, туган ярны сагынып җырлана:

***Талдан талга*** кунып сайрый микән,
Таң алдыннан сары ла сандугач?
Сандугачлар тавышы моңлы икән,
Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач.
Бөдрә ***тал,*** чит илләрдә йөреп

Гыйбрәт ал (Татар халык җыры).

Һәр җырда үләннәр атамаларының үзенең үзенчәлеге бар. Алар һәр җырда төрле мәънәдә килергә мөмкин. Мәсәлән, умырзая чәчәге бер җырда кеше гомерен аңлатып килсә, икенчесендә ул тәүге мәхәббәтне тасвирлый. Шулай ук кеше күнеленең аклыгы, пакълыгы турында да җырлана.

1) ***«Умырзая»*** җырында кеше гомерен язын вакытлыча гына чәчәк аткан ***умырзая*** чәчәге белән чагыштыра:

***Умырзая*** бик тиз үсеп чыга,
Бик аз гына яши тураеп.
Умырзая бик тиз
Башын аска ия,
***Умырзая*** сула моңаеп (Татар халык көе, Әхмәт Фәйзи сүз.).

***«Кызлар күңеле – ак умырзая»*** җырында ***умырзая*** чәчәге – аклык, сафлык билгесен белдерә, һәм кызларның күңелен ***умырзая*** белән чагыштыра.

3) ***«Гөлләр үсә»*** җырында автор гөлләр чәчәге аша сагыну хисләрен җиткерергә тырышкан.

Сандугач сайрап су эчә
Кызыл ***гөл*** арасыннан;
Иртән торып, хатлар көтәм
Син дустым тарафыннан (Татар халык җыры).

**Гөл** – мәхәббәт символы. Кеше мәхәббәтсез яши алмый, гөл кебек сула. ***«Аллы-гөлле гөлчәчәк»*** җырында сөйгән яр нәфис, алсу гөлчәчәк белән чагыштырыла:

***Аллы-гөлле гөлчәчәкне***
Иснә, бәгърем, исле ул;
***Үзе алсу, үзе нәфис,***
Бигрәк синең төсле ул (Татар халык җыры).

***«Гөлләр иле»*** җырында автор туган ягын ***гөлләр*** белән чагыштыра. Туган якның гүзәллеге шул ***гөлләргә*** тиң дип яза ул.

Нәтиҗә итеп, шуны әйтәсебез килә: үсемлекләрнең кеше тормышында роле бик зур. Шулай ук татар халык иҗатында да алар үз кыйммәтен югалтмаганнар. Халык лирикасында, символлар итеп, төрле табигать объектлары: аерым алганда, агачлар (алмагач, тал, тирәк, каен, шомырт, чия, карлыган, балан, миләш), төсләр киң кулланыла. Кайбер җырларның беренче ике юлында табигать күренеше бирелеп, калган юлларына ниндидер башка мәгънә салына. Ә кайбер җырларда бөтен строфада да үсемлекләр атамалары кулланылырга мөмкин. Мондый образ-сурәтләр, кагыйдә буларак, татар халкының мохитеннән, яшәгән тирәлегеннән алыналар. Киләсе буынга халык җырларын мирас итеп калдырыру – бу һәрберебезнең бурычы, чөнки бу җырлар һәрчак заманча яңгыраячаклар, үз әһәмиятен югалтмаячаклар.

**Әдәбият**

1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 359 б.

2. Надиров И. Татар халык җырлары. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1981. – 891 б.

3. Урманче Ф., Миңнуллин К. Татар халык иҗаты // Хрестоматия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 479 б.

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘГЕ МӘКАЛЬЛӘРДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫ

*Саглам З., Казан, 4нче гимназия-интернат, XI сыйныф*

*Җит. – Хатбуллина З.М.*

Atasözü kelime anlamı olarak geçmişten günümüze gelen özlü sözlerdir. Atasözü olarak tabir edilen sözler oldukça anlamlı ve sözü okuyan kişileri düşündürecek nitelikte olan sözlerdir. Atasözü tarihi oldukça eskidir. Atasözleri hayatımız boyunca bize ders verecek niteliktedir. Atasözleri Atalarımız'dan kalan ünlü ve asla unutulmayacak standartlarda olan kafiyeli ve uyumlu sözlerdir. Atasözleri belli bir toplumun ve/veya bütün insanlığın yaşam felsefesidir. İnsanlarda bulunan sevgi, kıskançlık, bencillik, dostluk, düşmanlık gibi duygular evrenseldir. Bu nedenle bu duyguları yansıtan atasözleri de evrensel olarak kabul edilmektedir.

Atasözlerinin konulara çoğu zaman kullanıldıkları bölgeye ve ülkeye göre değişiklikler gösterir. Türk toplumunda tarih boyunca askerlik ve çiftçilik önemli olduğu için at, it, kurt, koyun, silah ve yiğitlik konusunda Türkçe'de pek çok atasözü vardır. Buna karşın Alman atasözlerinde daha çok ayı, kartal gibi Almanya'nın sembolü haline gelmiş konulara yer verilir. Bu nedenlerle, atasözlerinde evrensel ve toplumsal düzen ile bu düzendeki iyi, kötü bütün özellikler görülür.

Ben bir feminist olduğum için tatar ve türk dilindeki atasözlerde kadın objelerini araştırmaya karar verdim. Feminizm, her ortamda kadının özgürlüğünü savunan ve çok eski çağlardan bugünlere kadar ulaşmış bir akımdır. Bu akımın ortaya çıkmasının nedeni ise, dünyada yaşanan kadın-erkek eşitsizliğidir. Bu araştırmam atalarımız kadınlara verdiği değeri gösterecek ve tatar, türk dillerinin kardeşliğini kanıtlayacaktır. Yaptığım bu araştırmayla Tatar ve Türk halkının kültürüyle de daha yakından tanışacağız.

Kadınlarla ilgili olan atasözlerini mantıken dört gruba ayırabiliriz.

1. kadınlar ve onların karakterlerindeki eksikleri
2. kadınların iç ve dış güzelliği
3. atalarımızdan halkımıza layık kadın olma konusunda tavsiyeler
4. erkekler için doğru eş bulma öğütleri

Eğer bu türk atasözleri gruplarını oran olarak karşılaştırırsak şöyle bir sıralamada olurlardı:

1. atalarımızdan halkımıza layık kadın olma konusuna tavsiyeler

2. kadınların iç ve dış güzelliği
3. kadınlar ve onların karakterlerindeki eksikleri
4. erkekler için doğru eş bulma öğütleri

Tatarcada ise:

1.erkekler için doğru eş bulma öğütleri
2. kadınların iç ve dış güzelliği
3. kadınlar ve onların karakterlerindeki eksikleri
4. atalarımızdan halkımıza layık kadın olma konusuna tavsiyeler

Üzücü olan ise, türkçede kadın karakteri hep erkeğe bağlanmış ve atalarımız bize öğüt verirken en önemli şeyin kocalarımıza layık olmanın ve iyi bir ev kadını olmanın bir bayan için en önemli şey olduğundan bahsediyolar, tatarcada ise kadın erkeğe bağlı olmayan ayrı bir insan olarak ele alınmış, öğüt verilirken daha çok kibarlığa, alçakgönüllülüğe, sadeliğe önem verilmiştir. Kadınların karakteriksik eksikleri hakkında olan tatar ve türk atasözlerini karşılaştırınca tatar atasözlerinin daha nazik olduğu kararına çıkabiliyoruz. Yani, türk atasözlerinde kadın kelimesinin daha kaba versiyonları kullanılabiliyor, mesela "karı", "hatun"(*Bal arıdan, kavga karıdan çıkar; Dul karı şeytan karı, aldatır alır bekarı)*, ama tatar dilinde ise kadının kötü taraflarından bahsedilirken bile "bayan", "kız" (*Хатын-кыз күп булган йортта су булмый.;Яман хатын мактаныр, төшкә тикле ятам, дип.*)olarak hitap ediliyor. Üzücü ve ortak olan da iki dilde de kadınları "tavuk" ve "şeytan" gibi hayvan ve varliklarla aynı seviyeye koyup kıyaslanmasıdır.(*Kadın erkeğin şeytanıdır;Kadının işi tavukların eşinmesine benzer; Шайтан булдыра алмаганны хатын булдырган.*)

İyi yönlerden bakarsak, türkçede kadın ne kadar erkeğe bağlansa da üzülmemeleri ve hakları kocaları tarafından çiğnenmemesi için kadın haklarını koruyan ve değerini yükselten bir sürü atasözü vardır. Mesela: *1) Erkek arslan arslan da Dişi arslan arslan değil mi? 2) Avrat (kadın) malı, kapı mandalı 3) Eti ciğer eden de avrat, ciğeri et eden de.*

Tatarların ve türklerin dini bir olduğu için dini taraftan kadın terbiyesi, namusuyla ilgili atasözleri de vardır: *1) Hırsızlık bir ekmekten, kahpelik bir öpmekten. 2) Dişi köpek kuyruğunu sallamayınca, erkek köpek ardına düşmez. 3) Әдәпле кыз сәдәпле. 4) Çok gezen tavuk ayağında pis getirir. 5) Оялчан кыз – сөйкемле кыз.*

Toplam sayı olarak türkçede kadın, karı, hanım sözleri içeren atasözü sayısı tatarcadan daha azdır.

Tatar ve türk dilleri kardeş diller olduğu için ve dinimiz aynı, kültürümüz benzediği için aynı anlamda olan atasözü sayısı da az değil.

*1) Bağın taşlısı, karının saçlısı =Тауның күрке - таш, кызның күрке - чәч. 2) Кызы барның назы бар = Kiz evi naz evi. 3) Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын = Avrat var ev yapar, avrat var ev yıkar.*

**Kaynakça**

1) http://www.nkfu.com/kadinlar-ile-ilgili-atasozleri-ve-anlamlari/

2) https://www.lafsozluk.com/2011/03/kadin-ile-ilgili-atasozleri-deyimler-ve.html?m=1

3) http://www.nenedirvikipedi.com/atasozuvedeyim/kadin-kelimesi-ile-ilgili-atasozleri-ve-deyimler-25052.html

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИР-АТ МАТУРЛЫГЫН СУРӘТЛИ ТОРГАН ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

(татар халык мәкальләре материалында)

*Садрова Л., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Сибгаева Ф.Р.*

Татар халкының мәкальләре, табышмаклары, әкият-легендалары, җырлары үзәгендә күбрәк акыллы, уңган, булган, батыр, чибәр кешеләр сурәтләнгән. Татар халык мәкальләрен анализлау барышында мәкальләрне түбәндәге тематик төркемнәргә аерып карадык:

1. Ир-атның тышкы кыяфәтен тасвирлый торган лексик берәмлекләр.

Татар халкының элек электән матурлыкка үз идеалы булган. Татар кызлары каен сыман зифа буйлы, карлыгач канатыдай кыйгач кашлы, шомырттай кара күзле булган. Ә егетләр имәндәй нык, сөлектәй зифа буйлы, бөркеттәй кыю, җитез булган. Матурлыкка багышланган татар халык мәкальләре күбесе чагыштыруда төзелгән. Мәсәлән, *Егет булсаң, җилек бул, суда йөзгән сөлек бул!; Ирләр имән тамыры, кызлар бодай камыры.* Татар ир-аты кара тәнле, кара күзле, кара чәчле, матур итеп үстерелгән сакаллы булган. *Асыл ата баласы кара булыр, Сары мыек, күк күзле – чура булыр; Ар иренле килсен, ир борынлы килсен.*

2. Ир-атның көчен, батырлыгын тасвирлый торган лексик берәмлекләр.

Гадәттә безнең халкыбыз матурлыкны батырлык белән янәшә куйган, батырлык турында күп мәкаль дә иҗат иткән. Мәсәлән, *Батырга үлем юк; Батырлыгыңны кулың белән күрсәт; Батырлыкта матурлык; Батыр үз халкын яклый; Ефәк билбау бил күрке, батыр егет ил күрке* һ.б.

3. Яшь үзенчәлеген тасвирлый торган лексик берәмлекләр ир-атның осталыгына, характерына карап, яшь-картка бүленә: *Ир утызда – арыслан; Кырыкка хәтле – малай, кырыктан соң – бабай.* Татарларда яшьлек физик көч белән сүрәтләнсә, картлыкка хөрмәт белән карыйлар: *Ишәк авырганын белмәс, ир картайганын белмәс; Күл корыса сазлык булыр, ир картайса сызлавык булыр.* Өлкән кеше, беренче чиратта, – ул зирәк кеше: *Яшь көченә таяна, карт акылына; Бабаң бүреге белән киңәш итсә, барын да булдыра.*

4. Ир-атның хезмәткә мөнәсәбәтен тасвирлый торган лексик берәмлекләр: *Идел кичми ил булмас, эш белмәгән ир булмас*; *Ир мактаныр, корал эшләр*; *Ир асылы эштә беленә* һ.б.

5. Ир-атның туганнары һәм гаиләсенә карата булган мөнәсәбәтен тасвирлый торган лексик берәмлекләр. Ир кешенең матурлыгы аның хатынына булган мөнәсәбәтендә дә чагыла. Ә татар халкы бу турыда болай ди: "*Ир баш, хатын муен*; *Кызны бәхетле иткән кеше ир*; *Ир үз сүзе белән йөрсә, үзе дә ир булыр* һ.б.

Гаилә мөнәсәбәтләре *кияү егет, ир* лексемалары аша күрсәтелә. Мәкальләрдән күренгәнчә, өйләнү уңай бәяләнә: *Ир өйләнми тәүфыйк тапмый*; *Өйләнгәч акыл керә*.

Малай – нәселне дәвам итүче, варис, булачак хуҗа. Шуңа күрә ир бала үзенең кыз туганнарыннан өстенрәк: *Ир бала унбиштә өй хуҗасы; Кыз тапканга ай туган, ул тапканга көн туган*.

Ир-атның булдыклылыгы аның гаиләсеннән, үстергән балаларының тәрбиясеннән күренә. *Балага иң куәтле кеше — ата; Атаның кырыслыгы балдан татлы;* Әлеге мәкальләрдән күренгәнчә, гаиләдә балаларны тәрбияләүдә ата өлге булып тора.

7. Егет кешене тасвирлый торган лексик берәмлекләр.

Мондый мәкальләрдә егет кешенең матурлыгы аның тышкы кыяфәтендә генә түгел, иң мөһиме аның рухи дөньсында, аның көчендә булырга тиешлеге аеруча да ачык күрсәтелә. Мәсәлән, Е*гетләрнең асылы, арысланнар нәселе; Егет байлыгы кесәдә түгел, йөрәктә була* һ.б.

Чын ир-ат үз сүзе өчен һәрвакыт җавап бирә, шуңа күрә һәр сүзен үлчәп сөйли, бәясен белә: *Ир әйткәненнән кайтмас*. Татар ир-аты өчен әйткән сүзендә тормау зур хурлык булып санала. Ә чын ир азсүзле була: *Азамат ирнең билгесе – аз сөйләр дә, күп тыңлар*.

Ир затын юмартлык, кешелеклек, эш сөючәнлек бизи: *Ага булыр егетнең итәк-җиңе мул булыр; Егет күрке – акылы белән*; *Егет булсаң, егетлегеңне эштә күрсәт; Һөнәрсез егет – йөгәнсез ат* һ.б.

Татарларга намуслылык, әдәплелек, тыйнаклык хас: *Алдан сөйләү ир-егет эше түгел; Намуслы ир хур булмас; Күлне камыш матурлый, ирне намус матурлый*; шулай ук горурлык һәм азатлык сөю: *Ир, башын бөксә дә, тезен чүкмәс; Ир икмәге – иркенлек; ир күңеле – сәхрә*.

Ир-атның тормыш юлы – ул актив рәвештә үсү, ир булу, һәрвакыт алга, биеклеккә омтылу. Киткән ялгышлар, хаталар ирләрне зирәгрәк һәм сакчыллырак булырга өйрәтә: *Дөнья күрми, ир булмый; Кайда гына барып, кайда гына йөрмәс ир башкае белән ат башы*.

Мәкальләрдә ир-ат үз максатына ирешүчән, зирәк, акыллы, үзенең намусы өчен көрәшергә әзер, батыр, тәвәккәл: *Ир кеше ирлек хакына җанын аямас; Ирлек беләктә түгел – йөрәктә*. Киресенчә

булганда: *Ирмен дигән ир унбиштә дә "башмын" диер; ир түгелмен дигән егерме биштә дә "яшьмен" диер; Йә хурлык, йә ирлек; Һәр бүрек кигән ир түгел*.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, ир-ат өчен нормадан читләшү һәм үз-үзен тоту хатын-кызларныкына охшый башласа, җәмгыять тарафыннан тискәре бәя алган: *Катышма, катымша булырсың; Хатын кыяфәтле ирдән хатын артык.*

Ир-ат холкының тискәре сыйфатлары итеп ялкаулык, сәләтсезлек, эшсезлек, гамьсезлек, куркаклык санала: *Өйдә арыслан кебек, урамга чыкса – тычкан кебек; Төшкә хәтле ачылмаган кибеттән биз, төшкә хәтле йоклаган егеттән биз*. Мондый сыйфатларга ия булган ир кешегә тискәре караганнар, чөнки ир-ат һәрвакыт гаиләне туендырып торучы һәм балаларына үрнәк булган, ә хатын-кыз гаилә учагын саклаган.

**Әдәбият**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – Т. 1. – 913 б.
2. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – Т. 2. – 959 б.
3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – Т. 3. – 1013 б.

## АЛАШ ҰРАНДЫ «САРЫАРҚА» ЖӘНЕ ХАЛЕЛ ҒАББАСҰЛЫ

*Садықова Р., Қазақ инновациялық гуманитарлық-заң университеті, PhD докторант*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. док,. проф. Дихан Қамзабекұлы*

«Сарыарқа» газетіне Алаш қаламгерлерінің барлығы бірдей шоғырланды. Олар: Әлихан Бөкейханов, Ахмет Байтұрсынов, Міржақып Дулатов, Жүсіпбек Аймауытов, Шәкәрім Құдайбердиев, Халел Ғаббасұлы, Райымжан Мәрсекұлы, Мағжан Жұмабаев, Мұхтар Әуезов, Сәбит Дөнентаев, т. б. «Қазақ» газеті большевиктер тарапынан қыспаққа алынып, шығарушылары қуғынға ұшыраған кезде Ахмет Байтұрсынов пен Міржақып Дулатов саяси көзқарастарын «Сарыарқа» арқылы жеткізіп тұрды. Газеттің басқа басылымдардан ерекшелігі - «Сыртқы хабарлар» айдары жұмыс істеді, яғни шетел жаңалықтарына зор мән берілді. Саяси қақтығыстар заманында қазақтың өз орнын айқындау үшін оның маңызы орасан болатын. Жалпы, «Сарыарқа» таза саяси басылым болды, әдеби шығармалар жоққа тән. Кездесетін өлең-жырлардың заман талабына сай күрескерлік сипаты басым. «Сарыарқа» газеті аумалы-төкпелі заманда ұлтқа қызмет ету үшін дүниеге келіп, сол мақсатына толық жеткен басылым. Қазақ халқының басын қосуға күш салып, бірлікке шақырды. Бір адамның басындағы қайғыны сөз ете отырып, бүкіл қазақтың соған жұмыла көмек беруіне себеп болған. Семей өңірінде дүниеге келгенімен, жоқтағаны – бүкіл қазақ мұңы болды.

«Сарыарқа» газетін ақтара отырып, қазақ журналистикасының бастауындағы тың ізденістерді, ерекше шешімдерді байқаймыз. Газет заман талабына сай жеделдікті, нақтылықты, байыптылықты ту еткен.

XX ғасыр басындағы Алаш арыстарының Әлихан Бөкейханұлы мен Ахмет Байтұрсынұлы бастаған үлкен бір шығармашылық шоғыры – қайта өрлеу ауқымындағы тұлғалар. Халық санасында өшпей, ұлт жандылық ерен істерімен жұртшылық зердесінде мәңгілік жазылып қалған бұл тарихи тұлғалар қоғамның рухани өмірінің көптеген салаларында жарқырап көрініп, бүкіл ұлт мәдениеті мен әдебиетіне үлкен ықпал етті. Демократиялық, ағартушылық, ұлт азаттық рухындағы қайта өрлеу дәуірінің міндеттері оларды әрі жазушы, әрі журналист, әрі публицист, әрі ғалым, әрі қоғам қайраткері болуға ұмтылдырды.

«Сол 1917–18 жылғы ұлы дүбір, ұлы майданда Семейде шыққан «Сарыарқа» газеті Алаштың тілі болды» [1: 158]. «Сарыарқа» газеті демократтық, мәдени-ағартушылық күресін жалғастырған қазақ зиялыларын өз маңына топтастырған, көркем, саяси публицистикамен халық мұңын, ұлт мүддесін өткір жазған басылым еді.

Бұл турасында профессор Дихан Қамзабекұлы: «Бұл газетті парақтап қарасаңыз, шынында да большевиктік диктатурамен «ұлы дүбір, ұлы майданда» аянбай күрескенін көресіз» – деп өз ойын сабақтайды [2: 158].

«Сарыарқа» газетінде жарияланған публицистикалық мақалалардың көтерген басты мәселелері: қазақтар өз алдына ел болды, осы орайда ұлт зиялылары мен оқыған азаматтары жоспарлап жүзеге асыра бастаған Алашорда үкіметін құрып, мемлекеттілікті қалпына келтіру, яғни жоғалған елдікті қайта қолға алып, егемендікке жету, осыған дейін де қазақ баспасөзі көтерген ағартушылық, демократтық идеяларды насихаттау болды.

Мәселен, ұлтымыздың дербес азат мемлекеті Алашорда өкіметін құру, оның баянды болашағы жолындағы елдің бірлігінің тарихи маңызы жайлы Халел Ғаббасұлы «Алаш автономиясы» мақаласында былай деп жазған: «Қазақтың уақытша үкіметі – «Алашорда» Алаш қаласына келіп, Алаш автономиясын жариялағаннан кейін, қазақ баласы бағынған үкіметіміз осы деп сеніп ант беріп, басқа үкіметті танымай, өз үкіметінің әмірін екі қылмай орындау керек. Жұрт жұмылуының белгісі осы. Бұл жұрт намысына, арына тігілетін нәрсе. Жұрт намысының, Алаш аруағының сыналатын жері – нақ осы жер! Қазақты жұрт қатарына қосамын десе, жоқ қара қазан, сары баланы біреудің босағасына апарып өтемін десе, бұл жұмыс енді жұрттың өз қолында болады. Біз сенеміз. Ақ табан шұбырынды, алқа көл сұлама неше-неше қиын қыстау жерлерден бұл күнге дейін аман өтіп, тарих жүзінде жоғалмайтын беріктігін көрсеткен, Алаш ұранды қазақ баласы жұртқа түскен мына өмір сынынан да аман-есен аяғын шалдырмай өтер деп» [3].

«Сарыарқа» бейресми, тәуелсіз басылым қатарына жатады. «Сарыарқа» газеті Семей өңіріндегі алғашқы қазақ тіліндегі басылым болды. Газет бетінде жарияланған материалдар сол кезеңдегі әдебиетіміздің даму бағытын, қоғамдық ойдың ауқымын танытып қана қоймай, сол дәуірдің қоғамдық, саяси, әлеуметтік мәселелерін кеңірек танытуға мүмкіндік берді. Екі жылдан астам уақыт шығып тұрған «Сарыарқа» газетіне редакторлық жасаған адамдар алашқа танымал, елі мен жеріне қайтсем жақсылық жасаймын деп талпынған адал жүректі азаматтар болды. Олар – Райымжан Мәрсеков, Халел Ғаббасұлы, Имам Әлімбеков, Шынжы Керейбаев.

«Сарыарқа» газетінің редакторлары барлық күш-жігерлерін салып, әлеуметтік қажеттілікті дәл баса отырып, мерзімді баспасөзді дамытуға өз үлестерін қоса білді. Осылардың бірі мен бірегейі «Сарыарқа» газетінің құрылтайшысы, редакторы һәм онда жарияланған бас мақалалардың авторы – Халел Ғаббасұлы. Ол «Сарыарқа» газетінің 10, 11, 12, 13, 14 және 21, 30, 31, 32, 34, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42, 57 сандарына қол қойған.

Сөйтіп, Халел Ғаббасұлы XX ғасыр басында «Серке» газетінен басталған қазақ баспасөзіндегі демократтық, ұлт азаттық рухтағы публицистиканы «Сарыарқа» газетінде редакторлық, шығармашылық істерімен одан әрі дамытты. Халел Ғаббасұлы басқарған кездегі «Сарыарқа» газетінде жарияланған келіссөздерде халықтың мақсат-мұраттарымен бірге, Алашорда өкіметі, оның ұлттық тәуелсіз мемлекет ретіндегі болашақ бағыт, бағдары да халыққа кеңінен насихатталды. Бұл орайда, жоғарыда айтылған Х. Ғаббасұлының бас мақалаларынан өзге, ел басқарған басылымның идеялық ұстанымы, ұлттық тұғыры да қазақ елінің азат таңының жаршысына айналды.

**Әдебиет**

1. Сейфуллин С. Тар жол, тайғақ кешу. – Алматы: Қазақ мемлекеттік көркем әдебиет баспасы, 1960. – 486 б.
2. Қамзабекұлы Д. XX ғасыр зиялылары // Жұлдыз. – 2001. – № 11.
3. Қазақстан энциклопедиясы. – Алматы: Аруана, 2001. Т. 7. – 548 б.
4. Сыдықов Е. Алаш қаласының тарихы. Зерттеу. – Семей, 2010. – 154 б.
5. ШҚО ҚЗТҚО 73-қор, 01-тізбе, 479-іс, 65 б.

## МЕЖЪЯЗЫКОВАЯ И МЕЖКУЛЬТУРНАЯ КОММУНИКАЦИЯ НА УРОКАХ ИСТОРИИ И ОБЩЕСТВОЗНАНИЯ

*Саламова И., СОШ №11 Бугульминского р-на, XI класс*
*Рук. – Салимова Р.М.*

Роль иностранных языков и практическая значимость в межъязыковой коммуникации в русле культурной глобализации не может быть преувеличена. Взаимодействие и взаимопроникновение национальных культур и языков – предпосылка их общечеловеческой значимости.

Межъязыковая коммуникация определяется дальнейшей необходимостью освоения нового образовательного пространства. В

учебном процессе школы появились новые уроки, как политология, мировая художественная культура, маркетинг, менеджмент, влияющие на традиционное содержание обучения.

Словом можно поднять дух человека, успокоить его, похвалить за малые заслуги, но словом можно расстроить, обидеть. Именно поэтому необходимо, прежде чем что-то сказать, подумать, как человек отнесётся к сказанному, поймёт ли вашу мысль, примет ли ваш совет. Словами лучше не бросаться, а беречь красоту самой богатой, прекрасной русской речи. С каждым годом всё больше наш язык пополняется иностранными словами. Их так много в нашей речи: государство, политика, президент, парламент, импичмент, дистрибьютор, республика, демократия, федерация, монархия, экономика, Конституция, философия, рубрикатор, реквизиты, гипотеза, диспозиция, санкция и т.д. [2] Такие примеры иностранных слов используются на уроках истории и обществознания. Поэтому большое значение на этих уроках придается овладению понятийным аппаратом.

Владеть понятием – это знать его содержание, объем, а также связи и отношения с другими понятиями. Это значит уметь применять его в учебном познании. Работа с терминами способствует развитию познавательной активности обучающихся, содействует развитию интереса к изучению истории и обществознания, создает приятную атмосферу учебной деятельности, раскованности, способствует разрядке напряженности, снимает усталость.

Одним из интересных применений латинского языка в современном мире является нейминг. Нейминг (от англ. "naming" – создание имени) – это процесс разработки названия фирмы, бренда. Название фирмы, типографии, ателье, парикмахерской, фабрики, производства, издательства, рекламного или модельного агентства, магазина, интернет-портала, торгового центра, акционерного общества звучит на латинском языке солидно и благозвучно [2].

Наша память носит избирательный характер: лучше запоминается то, что важно, интересно. А ведь используются не только слова, но и целые выражения. Именно латинские выражения, неизменно пользуются особой популярностью на уроках истории и обществознания.

«Alea jacta est» – жребий брошен (перейти Рубикон) – высказывание принадлежит Гаю Юлию Цезарю. По преданию, когда Цезарь 10 января 49 года до н.э. перешел со своей армией реку Рубикон под Равенной, он произнес по-гречески «anerriophtho kybos» [1].

«Omnia mea mecum porto». (Всё свое ношу с собой), – так сказал судья Биант из Приены, один из семи мудрецов Древней Греции, когда он вынужден был покинуть родной город и, к удивлению сограждан, не взял с собой ничего из нажитого имущества [1].

«Alter Ego». (Второе я) – высказывание Зенона Младшего. Понятие «Alter Ego» сегодня используется для описания довольно большого количества феноменов «второго Я». Речь может идти о раздвоении личности у людей с психическими заболеваниями, или фиктивном, другом Я, которое многие люди создают себе сегодня в Интернете. Иногда «Alter Ego» называют людей, которые очень похожи на нас, но иначе относятся к своим задаткам [1].

«Amicus Plato, sed magis veritas» (Платон мне друг, но истина дороже), «Aurea mediocritas» (Золотая середина), «Cogito, ergo sum» (Я мыслю, следовательно, я существую), « Festina lente!» – поспешай медленно! (Спеши медленно), «Potius sero quam nunquam» (Лучше поздно, чем никогда) [1].

В данных цитатах заключается глубокий смысл и красота. Ведь не случайно они появились на свет – их родили людская фантазия и разум. Одни из них игривы, а другие заставляют задуматься. Если присмотреться по внимательнее к цитатам, то можно обнаружить поразительную вещь: они подходят к любому случаю жизни, что-то можно ехидно бросить в лицо обидчику, что-то – произнести с укором или с насмешкой, многие крылатые слова воспринимаются как шутка.

Наши обучающиеся используют цитаты великих ученых и мыслителей для написания эссе, мини-сочинений и статей не только на уроках истории, но и обществознания. Работа с цитатами побуждает школьников к высказыванию своей точки зрения по той или иной проблеме, развивает способность: анализировать, делать заключения, обобщать. Поскольку та или иная ситуация, отраженная в цитате, находит выражение в жизненном и языковом опыте и проявляется в ценностной ориентации, личностном подходе, развивая чувство уверенности в себе.

**Литература**

1. Пёппельманн К. Крылатые латинские выражения и что за ними стоит. Серия «Библиотека студента». – Ростов-на-Дону: Феникс, 2009, – 256 с.

2. Словарь иностранных слов. – 18-е изд., стер. – М.: Рус. яз., 1989. – 624 с.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫНДА ТИРӘЛЕК ҺӘМ ГЕРОЙ КАРШЫЛЫГЫ

*Салахова А., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Үз фикереңне, үз идеалыңны тудыру барышында тирәлек белән каршылыкка очрамый калмыйсың. Бу мәсьәлә бүгенге көндә дә **актуаль** кала бирә. Аның кайсы як файдасына хәл ителүе, ягъни тирәлекнең сине кысрыклавы яки, киресенчә, шәхеснең җиңүе чорга, әллә инде анда барган сәясәткә бәйләп карала? Тирәлек һәм герой каршылыгын ачыклауны **максат** иткән фәнни эшебезнең **тикшерү объекты** итеп, Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романын алуыбыз очраклы гына түгел: язучы үзенең олы таланты һәм күпкырлы әдәби-фәнни иҗаты, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге

белән үз исемен алтын хәрефләр белән тарих битләренә язып калдырды. Ә максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды: XX гасыр әдәбияты белән танышу, Г. Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат җыю, әсәрләрендә тирәлек белән шәхес арасындагы каршылыкларны табу; “Яшь йөрәкләр” романын укып, анализ ясау. Фәнни эш анализ алымы, күзәтү, гомумиләштерү **методы** белән башкарылды.

1912 елның маенда Г. Ибраһимов үзенең беренче зур әсәрен – “Яшь йөрәкләр” романын тәмамлый, Һәм 1913 нче елда басылып чыгу белән, аңа төрле яклап нәзарый фикерләр ява башлый. Аларда геройлар белән тирәлек арасындагы каршылык төрлечә бәяләнә һәм Г. Ибраһимов та “Әдәбият кануннары” (1918) китабында әсәренә үз фикерен әйтеп уза: “Яшь йөрәкләр” – роман. Анда искелек белән яңалыкның көрәшү дәверендәге хәлләр төрле каһарманнар аркылы тасвир ителгәннәр. Искелек геройлары: Җәләл мулла, Гәрәй мирза һәм аларның хатыннары; яңалык геройлары: Сабир, Зыя, Госман, Сәлим, Камилә һәм башкалар”, дип язган иде. Мәгълүм ки, әлеге роман 1905-1907 еллар революциясе йогынтысында халыкта – яшьләрдә – милли аң уянуын күрсәткән эчтәлекле әсәр. Автор үзе үк бәяләгәнчә, төп каһарманнар яшьләрнең рухи дөньялары эти-әниләре белән тыгыз мөнәсәбәттә: охшаш яки капма-каршы. Әлеге каршылыкларда татар халкының киләчәге, милләтнең хәле, язмышы мәсьәләләре күтәрелә.

Дөрестән дә, тирәлек белән геройлар арасындагы каршылык “аталар” һәм “балалар” яссылыгында үсә: Зыя белән Җәләш мулла, Сабир белән Җәләш мулла, Мәрьям белән Фатыйма бикә. Мисал өчен, Зыя образын гына алыйк: ул музыка белән “җенләнгән”. Аңа татар көйләрен ишетү, кубыз яки гармун уйнау – яшәү өчен зарури булган мөһим шартларның берсе. Ләкин рухи ихтыяҗлары ул яшәгән тормыш белән каршылыкка керә, музыкага булган омтылышларын канәгатьләндерү өчен шартлар аның өендә дә, мәдрәсәдә дә, гомумән, татар дөньясында юк. “Ул, мәктәптән кайткач, ындырдагы кибәннәр арасына качып, яисә кешегә күренмичә генә, мунчага бикләнеп, кубызын тарта башлый” [3: 276]. Җәләш мулла улының музыка белән җенләнеп утырганын күрсә, “бер ходай үзе генә сакласын, ул сак кына мунчага килеп керә дә, иң әүвәл яңаклап, тибеп ега, аннан соң колагыннан өстерәп, өйгә китерә дә, анасы, туганнары алдында: – Икенче андый эшкә катышма!! Катышма!! Катышма!! – дип, эт урынына кыйнап ташлый” [3: 276].

Шулай ук Мәрьям образын алыйк: балачакта ул бары тик Зыя белән генә уйнап үсә. Ләкин сабыйлык вакыты узып, яшүсмерлек чоры башлангач, Мәрьям белән Зыя арасында пәрдә барлыкка килә. Егетнең мәдрәсәдән кайтканын белгәч, аның янына йөгереп керергә дә, муенына асылынырга тели, әмма шулчак кыз үзендә әллә нинди тойгы сизә, ягъни мондый хәл ярыймы, әллә юкмы?.. Аның ят кешеләр кебек басып торуын

күргәч, Зөләйха абыстай, кыюлык бирергә теләп: “Мәрьям туташ, синме? Ник анда торасың, монда кил, ул синең абыең ич!” [3: 310] дип әйтә, әмма аның сүзләренә каршы кискен рәвештә Фатыйма бикә: “Куй, ахирәт, ярамас: ул – зур кыз ич инде!” [3: 310] дип куя.

Зыя солдатка алынгач та, Мәрьямне Фәхригә кияүгә биреп куялар. Әсәр барышында шунысы игътибарга лаеклы: Фатыйма бикә кызына ирне “көчләү юлы” белән тагарга теләми, чөнки “кара халыктагы кебек” мәҗбүриләп кияүгә бирү, Гәрәй мирза хатынына, бер генә дә килешми, ягъни ничек тә булса үзенең ризалыгын алырга кирәк.

Ә Сабирның тормышы бөтенләй башкача чишелә. Ул белем алудан да, “гыйлем хәзинәсе булган” китапханәләрдән, мәдәнияттән, музыкадан һәм башка бик күп әйберләрдән читләшеп, аларга кул селтәп, авылга кайтып “яңа томыш” башларга тели. Бирердә аның үз йорты, кулга сука тотып эшли алырлык җире, аты булачак. Зыяга әйткән сүзләреннән күренгәнчә, ул авылга ирек артыннан кайта: “... минем үз малым, үз дөньям булыр. Минем алдар хыялым тараер. Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә.” [3: 271]. Балаларына күп өметләр баглаган Җәләш муллага әлеге сүзләр хурлык кебек тоела: “... хәзрәткә, бер адәмнең “мин патша булмыйм, мин көтүчелекне яратам... Мин тәхеттән төшеп, озын чыбыркы белән сыер көтәргә китәм!” дигәненә охшап күренә” [3: 270].

Шулай итеп, тирәлек белән шәхес арасындагы каршылык меңнәрчә еллар дәвамында яшәп килә, бары тик кайбер урыннарда нигезе, асылы гына үзгәрә. Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романында гәүдәләндерелгән искечә фикер йөртүче ата-аналар белән яңача фикерләүче балалар арасындагы бәрелеш гаилә кысаларыннан чыгып, тагын да киңрәк масштабта – милләт яшәешендә – киңрәк колач җәя. Шәхеснең җиңүе яки кысрыклануын да чор яисә сәясәткә генә бәйләп карау дөрес түгел, чөнки алар бер-берсе белән янәшә үсә, үзгәрә.

**Әдәбият**

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр.– Казан: Татар. кит. нәшр. 1957. – Т. 1. – 523 б.

## К ВОПРОСУ ОБ ИДЕНТИЧНОСТИ И ЭТНИЧЕСКИХ СТЕРЕОТИПАХ КОЧЕВНИКОВ ЕВРАЗИИ

*Сарин К., Евразийский национальный университет имени Л.Н. Гумилева, PhD докторант*

*Науч. рук. – академик НАН РК, докт. ист. наук, проф. Сыдыков Е.Б.*

Понятие идентичности включено в глоссарии ряда гуманитарных наук – психологии, этнографии-этнологии, культурной антропологии, со-

циологии и может отражать социальную, экзистенциальную, религиозную, профессиональную, языковую, сексуальную ментальную модель самого себя. Идентичность является особым свойством человеческой психики в концентрированном виде представлять свою самость по отношению к внешнему миру, сочетаясь с ним или отличаясь по ряду принципиальных или формальных признаков. Эта форма самоопределения может носить, как строго индивидуальный, так и групповой характер.

Этническая идентичность, одна из форм, которая в современном глобальном, и в ряде частей света, постиндустриальном мире, играет важную роль, а в случае с резко выраженной религиозной идентичностью или социальной, может принимать радикальные формы противопоставления своей этнической группы всему остальному миру. Поэтому изучение существовавших форм этнической идентичности и ее признаков, представляется актуальным и важным для современных гуманитарных наук, в том числе истории.В основе этнической идентичности стоит этноцентризм, который выступает инструментом для выявления в окружающих людях тех или иных этнических признаков – языка или речевых признаков, психологии тела – мимики, жестов, антропологических черт, норм поведения – этики. Данные признаки выступает важной частью ролевого репертуара поведения человека в обществе и формируются при подавляющем влиянии той или иной этнической культуры. Современной казахское общество имеет сложное устройство, по мимо внутренней системы трайбализма, регионализма, оно имеет масштабное деление по языковому признаку. Данный вопрос, не стоит, таким образом, что одна часть казахского общества не понимает другую. Вопрос заключен в потреблении информации и погружении в разноязыковые информационные поля – казахское по преимуществу и русское соответственно. Изучение признаков, которые скрепляют этнос, поддерживают его устойчивое состояние и дают возможность для развития в дальнейшем представляется важной задачей.

Важной частью казахской идентичности на современном этапе является соотнесения «себя» с кочевой цивилизацией Евразии. Это обусловлено рядом исторических факторов, главным из которых, является то, что современные казахи, являются прямыми этническими и культурными потомками средневековых и древних кочевников Центральной Азии. И в данном ключе интересно рассмотреть в диахроническом аспекте существовавшие и существующие гетеро и автостереотипы. Современное научное понимание этнического стереотипа связано с работами ряда исследователей применявших теории различного уровня анализа — от индивидуалистских теорий 3. Фрейда и А. Адлера до собственно социальных теорий К. Юнга, Э. Фромма, С. Московичи и других [1: 124]. Основываясь на этом, мы можем сформулировать несколько основных понятий, которые помогут

при дальнейших исследованиях в данном направлении. Этнические стереотипы являются видами социальных стереотипов, которые представляют коллективные, устойчивые, обобщённые и упрощённые эмоционально окрашенные, представление одной этнической группы о другой группе или о самой себе. Понятие стереотипа в современной гуманитарной науке имеет междисциплинарный характер, получив развитие в социологии и социальной психологии в 20-х гг. прошлого столетия оно стало предметом анализа с точки зрения теории коммуникации, этнологии, культуры, литературы, философии языка и истории [2: 227–235]. Этнические стереотипы формируются главным образом на уровне обыденного сознания и передаются следующему поколению в виде однозначных сущностей. В содержании которых, как правило, зафиксированы приоритетные оценочные мнения о психологических особенностях и поведении людей другой этнической группы, её моральных, умственных, физических качествах, суждения об указанных качествах, а так же может присутствовать предписание к действию в отношении людей данной общности или группы. На содержание этнических стереотипов оказывают влияние три основные группы факторов. Во-первых, специфика стерео типизируемой группы (ее психология, система ценностей, закрепленная в культуре и в обыденном сознании, общественно-историческое развитие). Во-вторых, социально-политические и экономические условия развития групп и специфика взаимоотношений между ними, сложившаяся на момент контакта. В третьих длительность и глубина исторического взаимодействия. Типологически этнические стереотипы подразделяются на гетеростереотипы и автостереотипы. Гетеростереотипы – это образы представителей других этнических групп, сложившиеся в данной группе. Они могут быть как позитивные, так и негативные, в зависимости от исторического опыта взаимодействия данных народов. Изменчивость оценок связана с меняющейся ситуацией в отношениях. Признаки, из которых слагаются внешний облик и поведение, могут иметь осведомительное значение и выполнять регулятивную функцию. Таким образом на основе этих стереотипов неизбежно создаются соответствующие типы межэтнического общения и поведения людей [2: 227–235]. Автостереотипы – это представление членов конкретной этнической группы о самих себе. В данном случае объектом этнического стереотипа являются наиболее типичные представители своей этнической группы. Автостереотипы, как правило, представляют комплекс положительных оценок. Но иногда среди этнических меньшинств встречается и отрицательные самооценки. Подобные группы с низким статусом могут соглашаться с их относительно более низким положением в обществе. На становление этнических гетеро и автостереотипов так же влияют три группы условий: 1) политическая, экономическая и религиозная си-

стемы общества, формирующие определенный набор норм, ценностей, идеалов, императивов. В идеале формирование этого набора происходит в непротиворечивом единстве, присущем ценностному отражению, ценностному атрибутированию действительности этнической элитой; 2) социально-психологическая представленность норм, ценностей, идеалов и императивов внутри непосредственного окружения индивида. Установлено, что индивид тем легче идентифицирует себя с определенной группой, чем больше его коммуникативных связей замыкается внутри нее; 3) индивидуально-психологическое бытие индивида, то есть совокупность реальных фактов его жизни [3:. 138]. Интерес вызывает факт существенной стабильности стереотипов по отношению к кочевникам на протяжении длительного периода, это в свою очередь вызвано сильным консервативным характером самого кочевого образа жизни, вырабатываемые культурные модели поведения связанные с образом жизни и типом хозяйства, были характерны как для скифов, так и для средневековых кочевников, а ряд из них существуют в современном казахском обществе.

**Литература**

1. Тощенко Ж.Т., Хухорева О.Н. Стереотип // Тезаурус социологии. Тематический словарь-справочник. – М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2009. – 487 с.
2. Стефаненко Т.Г. Этнопсихология. – М.: Академический проект, 1999. – 320 с.
3. Великая Степь в античных и византийских источниках. – Алматы: Баур, 2005. – 1304 с.

## «УЫЗ» ЛЕКСЕМАСЫНЫҢ ҚОЛДАНЫЛУ ЕРЕКШЕЛІКТЕРІ

*Сатбай Ж., КФУ, II курс магистранты*
*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., доц. Нурмухаметова Р.С.*

Қазақ тілін зерттеп, өзінің қолтаңбасын қалтырған, тіл білгірі А. Ысқақов: «тіл-тілдің сөздік құрамы әр халықтың өз тарихының, өз тұрмысының, өз мәдениетінің, оның дүниелік (материалдық) және рухани қазынасының айнасы сияқты болып есептеледі. Өйткені, өмірдің сала-саласындағы құбылыстардың бәрі де тілдің сөздігіне іздерін тастап, оған тиісті сөздерді куә етіп, дақ қалдырып отырады» – деп кез келген сөздің фундаменті бар екендігін, олардың көне түбір тұлғасын зерттеп, этимологиясын анықтауға болатынын айтқан [1: 3].

Халықтық тағам лексикасы үй, киім терминдеріне қарағанда анағұрлым тұрақты болып келеді. Қазақ халқы тағамға қатты мән берген, олар – «ас адамның арқауы», «ас тұрған жерде, ауру жоламайды», «ас қадірін білмеген аштан өледі, ат қадірін білмеген жаяу қалады» деп емдік қасиеті мол ас әзірлеген.

Қазақ халқы асты үш түрге бөледі. Олар ақ (сүт тағамдары), қызыл (ет тағамдары) және көк (жеміс тағамдары). Мал және онан алынатын өнімдер қазақтың басты байлық қоры. Соның ішінде ұлт тағамдарының негізгі көзі болып табылатын сүттің орны бір бөлек. Сүт тағамдарын халық

бір сөзбен ақ деп атайды. Осы ақтан бірнеше жүздеген, мыңдаған жылдар бойы халық аса бай тәжірибе жинақтай жүре одан жүзден астам тамақ түрлері мен дайындау әдістерін жасаған. Және олардың көптеген қызықты атаулары мен орны және алуан түрлі ерекше жасау, пісіру жолдары тағы бар. Сөйтіп бір сүттен сұйық, қою, қоймалжың, ащы, тұщы, жұмсақ, қатты, ұнтақ тағамдар жасап шығарған. Олардың көпшілігі қазіргі кезде қазақ дастарқанынан сирек көрінетін жеңсік ас қатарына жатады.

Соңғы уақытта ғалымдардың тағамтану саласына деген қызығушылығы артып келеді. Соның ішінде, ас-тағамға байланысты сөз тіркестері, аспаздық лексика бірліктерінің халық тілінде кеңінен қолданылуы етек жая бастады. Қазақ халқы үшін ет тағамдарымен қоса сүтті және сүттен алынатын тағамдарды дастархан мәзірінде көп пайдаланған. Түркі мифологиясында оны ерекше қасиет тұтқан. «Ақ» – пәктіктің, тазалықтың көрсеткіші болып саналады. Екіншіден, сүт көшпенді халықтардың негізгі қорегі [2: 8].

Көшпенділердің сүт тағамдарын дайындау және қолдануында да өзіндік ерекшелік бар. Мысалы: уыз – жаңадан туған сиырдың алғашқы сүтінен дайындалатын тағам. Ол үшін уыз сүтке сүт құйып суытып, тұз салып, қойдың бүйеніне құйып, қайнап жатқан ет сорпасына, салады. Уызды көршілері және туыстарына береді. Ең алдымен одан үй иелері дәм татады, содан кейін қонақтарға береді. Дәм татпас бұрын, қонақтар «ақ мол болсын!» деген тілек айтады [3: 199].

«Уыз» лексемасын толығырақ төмендегіше талдай кетсек:

«Уыз» – зат есім. Төлдеген малдың алғашқы сүті [4: 409]. Уыз сөзі (у + ыз) қосымшасынан құралған. У (ащы) әуелде «уу» деген өз мағынасында болған. Мал жеген ащы (көк) шөп деген ұғымда болғанға ұқсайды. (У + ыз) -ыз көне түркілік көптік мәнін білдіретін жұрнақ екендігі белгілі. Демек, «у» + «ыз» (уыз) көп (мол) алғашқы деген ұғымға қарай ойысқан. «Уыз» – жаңа төлдеген малдың желініне жиналатын қою сүт. «Уызға» байланысты қолданыста жүрген бірқатар сөз тіркестерінен мысал келтірейік:

**Аузынан уыз сүті кеппеген.** Жас. *Рақымның аузынан уызы тамған өрімдей кезі (Ж.Мұзапаров «Қаби қарт»).*

**Уыз қымыз.** Жазғытұрым кездегі алғашқы қымыз. *Қырдың таза ауасынжұтып, майдың уыз қымызын ішу мың да бір ем (С.Досанов, «Тау жолы»).*

**Уызы арылмаған.** Дәулеті шайқалмаған, бақ-дәулеті таймаған. *Бұл өзі жеті атасынан бері уызы арылмаған, бағы таймаған, басы сәждеге тимеген... бір жауыз еді (С. Торайғыров «Таңд шығ»).*

**Уыздай ұйыды.** Береке-бірлігі бұзылмады, ынтмағы жарасты. *Соғыстың салдарынан небір уыздай ұйыған семьялардың шаңырағы орта-сына түсті (Ө.Қанахин «Жер бас»)* [5: 89].

Тағы бір назар аударарлық жағдай – қазақтардың сүт тағамдарына байланысты тиымдары. Мысалы, сүтті үйден күн батқаннан кейін алып шығуға болмайтындығы, немесе, алып шыққан жағдайда ай түспесін деп бетін жабу салты. Қазақтардың ұғымында сүтті жерге тамызуға болмайды, ал төгіп алған жағдайда ол жерді адам аяғы баспаған, топырақпен жапқан.

Жоғарыда сөз болған тұрақты сөз тіркестерінен қазақтардың ежелгі салт-дәстүрінде «ақ» және «уыз» ұғымының аса киелі болғанын байқауға болады. Сондықтан болар тілімізде «ақ жалғасын, ақтың киесіне ұшырасын, ақ ұрсын» іспеттес сөз тіркестері берік орын алған.

Қорыта келе, сүт тағамдарына байланысты салт-дәстүрлер, сөз орамдары, тұрақты сөз тіркестері қазақ халқында көп кездеседі деп айтуға болады.

**Әдебиет**


1. Жанпеисов Е.Н. Этнокультурная лексика казахского языка (на материалах произведений М. Ауэзова). – Алма-Ата: Наука, 1989. – 130 с.
2. Жұмағұлова Ө.А. Аспаздық әлемдегі метафоралық қолданыстың ерекшелігі // Известия Национальной Академии наук Республики Казахстан. –2013. – №4. – С. 85–91.
3. Қазақ тілінің түсіндірме сөздігі. – Алма-Ата, 1986. – Т. 1. – Б. 10.
4. Тұрышев А.Қ. Мәшһүр-Жүсіп шығармаларындағы заттық мәдениет лексикасы. – Павлодар: Кереку, 2008. – Т. 1. – 244 б.
5. Ысқақов А. Кіріспе – Кіт.: Қазақ тілінің түсіндірме сөздігі. – Алматы, 1974. – Т. 1.– Б. 3.


## ГОМӘР БӘШИРОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФОЛЬКЛОРИЗМНАР


*Сәйфетдинова Д., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалиева Л.Ф.*


Фольклоризм термины француз фокльлористы П. Себийо тарафыннан беренче тапкыр тәкъдим ителә. Фольклоризм – әдәби әсәрләрдә фольклор элементларын куллану дигән сүз. Башка халыклардагы кебек үк, татар әдәбиятында да халык авыз иҗаты үрнәкләре идея-эстетик һәм әдәби кыйммәтләрнең бер чыганагы санала. К.Антошин фикеренчә, “фольклор һәр милли культураның бәһасез байлыгы булган һәм булачак”. Әсәрдә фольклор элементларын куллану аның телен баета, әсәрне тагын да тормышчанрак итә, геройларның характерын, психологиясен ачарга ярдәм итә.

Әлеге мәкаләдә без Г. Бәшировның “Намус” романында кулланылган халык авыз иҗаты үрнәкләрен карап китәрбез.

Бөек ватан сугышы елларында колхоз авылы һәм аның кешеләрен сүрәтләүгә багышланган “Намус” романы татар әдәбияты үсешендә зур бер адым була. Халык арасында яшәү, аның тарихы һәм хәзерге тормышы, мәдәнияте һәм рухи кичерешләре белән тирәнтен таныш булу язучыга халык тормышын киң күләмдә, төрле яклап яктыртырга мөмкинлек биргән. Әсәрдәге һәр образның язмышы реаль тормыш вакыйгалары белән, халыкның тарихы белән тыгыз бәйләнештә сүрәтләнгән. Шуңа күрә, укучы әсәрнең һәрбер юлын үзе белгән, үзе кичергән вакыйга кебек яратып укый.

Бу романның югары сәнгатҗ әсәре булып, әдәбиятта мактаулы урын тотуында фольклорның да роле, һичшиксез, зур.

Әсәрдә Нәфисә белән Гөлзәбәр, Мәүлиха һәм Зәйнәпбану, Хәйдәр, Айтуган карт, Тимери һәм башка күп кенә геройлар "*Тырышкан табар, ташка кадак кагар*" дигән мәкальгә чын күңелләреннән ышаналар.

*"Мәүлиха түтинең аңа күптән үк каны кызып утыра иде – элеп кенә алып китте: – Һе! Кара син аны, кая суза тәмгысын! –диде. – Ник, ишеткәнең юкмени! Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар!"* [1].

Карчык үз фикерләрен халык мәкальләре ярдәмендә оста гына әйтеп бирә алу сәләтенә ия. Шулай ук колхоз кызларының хәсрәтләрен борынгы кайгы-хәсрәт җырлары, шатлыкларын күңелле такмаклар белән, нәфрәтләрен сатирик мәзәкләр аша әйтеп бирә белү сәләтенә ия.

Искиткеч бай халык иҗаты белән автор Нәфисә образын да матур гына сүрәтләп бирә. Мәкаль-әйтем, такмак, җыр – һәммәсе дә бу образны ачуга ярдәм итә. Нәфисә үз урынында нәфис сүзгә дә оста, урынында шаян такмак та әйтә белә, үх урынында халык җырлары аша күңелендәгесен әйтеп сала белә. Автор Нәфисәнең көченә һәм акылына ышануын кечкенә генә бер деталь аша, халык авыз иҗаты ярдәмендә, бик оста тасвирлаган. Сөйгән ярын сугышта югалткач: "*И Газиз, Газиз... үземнең ярым итеп сине сайлаган идем. Икебез дә бәхетле булабыз, бүтәннәрне дә бәхетле итәрбез дигән идем. Ай бирде, кояш күпсенде, атылган йолдыз төсле, бер балыктың да, сүндең...*" [1] дип, халык әйтемнәрен оста куллана.

Авыл халкы Нәфисәне кияүгә димли башлагач, Нәфисә андыйларга "*Татарга тылмач кирәкми, ни эшләргә кирәген мин үзем дә беләм*", – дип, ярым фольклор, ярым үз сүзләре белән мәсьәләгә кире кайтмаслык итеп җавап бирә.

Бәширов шулай ук уңмаган колхоз председателе Сәйфи образын сүрәтләгәндә фольклордан бик оста файдалана. Ул, Нәфисәнең уңышны күтәрү өчен орлыкның иң яхшысын чәчәргә кирәклеге турында тәкъдименә, көлеп: "*Һи, һи, һи! Быелгысы елнымы? Юк, кодача, бу әкиятеңне әнә оланнарга сөйлә инде син, яме! Миңа бүгенге көнем кадерле. Менә бүгенем. Иртәгеге өчен ишәк кайгырган. Иртәгә әллә кем бар, әллә кем юк әле", "Аннары бит, кодача, җаны барның җүне бар, җитмәсә әле аның тирән генә кесәсе дә бар. Колхоз дигән белән дә бит, агайның бармагы әле һаман да үзенә таба кәкре ич!"* [1].

Романда бик оста сүрәтләнгән тагын бер персонаж – Йөзлебикә образы да бик кызыклы. Бу образны ачу өчен Бәширов мәкаль-әйтемнәргә бик еш мөрәҗәгать итә. Романда ул бик җор телле булып сүрәтләнә: "*Минем кызым кияү күргән нәрсәме*" *дигәндәй, кунакларны ятсынмасмы инде бу чорсыз... диди, сыерын ишек алдына чыгарды. Сыер дуласа – аттан яман, диләр, – дөрес*

*икән*". Йөзлебикә кеткелдәп көлеп җибәрде: *Әйтәм бит, үпкән-кочкан җилгә очкан, ди. Яшь чагында бер җилкенеп алмыйча әллә*" [1].

Бәширов әсәрләрендә кулланылган әйтемнәрнең халыкныкы булуына шик калмаслык итеп, "халык әйткән", "борынгылар әйткән" гыйбарәләрен бик оста куллана.

Мәкальләр Г. Бәшировның милли характер тудырудагы көчле коралы булып тора. Халык иҗатының бу кыйммәтле үрнәкләре әдип тарафыннан идея-эстетик максатларга яраштырылып, авторның хикәяләү осталыгын тагын да баеталар, тулыландыралар. Әсәр тукымасына алып кергән мәкальләр аша Бәширов үз халкының яшәеш, дөньяга караш үзенчәлекләрен, психологиясен уңышлы ачуга ирешә.

**Әдәбият**

1. Бәширов Г. И язмыш, язмыш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 310 б.
2. Мухаметшин Р.М. Окрыленный борьбой. – Казань, 1987. – 125 с.

## ТАТАРЧА ҺӘМ ТӨРЕКЧӘ ЗООНИМЛЫ МӘКАЛЬЛӘР ТӘҢГӘЛЛЕГЕ

*Сәйфетдинова Л., КФУ, V курс студенты*
*Фән. җит. – фил.фән.канд., доц. Г.Р. Мөгьтәсимова*

Халык афоризмнары арасында һәм әдәби – эстетик кыйммәте буенча, һәм сан ягыннан төп урынны, һичшиксез, мәкальләр һәм әйтемнәр алып тора. Җыйнап әйткәндә мәкаль нәрсә дигәнгә шундый билгеләмә биреп була: сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер, тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип әйтелә. Мәкальләрдән тормыш итү өчен күп киңәшләр, акыл алырга мөмкин. Чөнки алар – халык авыз иҗатының иң борынгы төре, шул ук вакытта иң кыска, иң җыйнак төре дә.

Хайван атамалары мәкальләр составында бик еш күзәтелә. Элек-электән хайваннарга хас кайбер сыйфатларны кешеләр белән бәйләп караганнар. Мәкальләрдә еш кына хайван образлары аша кешенең тышкы кыяфәтен, характерын, үз-үзен тотышын ачыкларга була. Бу закончалык шуның белән бәйле: кешеләр элек-электән хайваннар белән тыгыз мөнәсәбәттә торганнар. Татар һәм төрек телләренең хайван атамалары кулланылган мәкальләрен тикшергәннән соң, кайбер охшашлыкларны һәм үзгәлекләрне күрергә мөмкин булуы ачыкланды.

Зооним компонентлы 500 гә якын татар һәм төрек мәкальләрен барланды. Әлеге мәкальләр арасында мәгънәви яктан тулысынча тәңгәл килә торганнары да бар. Бу очракта мәкальләрнең составы һәм структурасы еш кына бермә-бер туры килә, телнең грамматик үзенчәлекләре дә шул охшаш була. Мәсәлән: ***Бүредән*** *курыккан урманга бармас.* - ***Kurttan*** *korkan ormana gitmez;* ***Мәче*** *булмаган җирдә күсегә ирек.* - ***Kedinin*** *bulunmadığı yerde sıçanlar başkaldırır; Бирелгән* ***атның*** *тешен*

*санамыйлар. - Beleş **atın** dişine bakılmaz; Ике **куянның** койрыгын тоту. - İki **tavşanı** birden kovalamak.*

Мондый мәкальләр контексттан тыш та бердәй, денотатив һәм коннотатив үзенчәлекләргә ия була. Алар татар телендә дә, төрек телендә дә тәңгәл очракларда кулланыла алалар. Андый мәкальләрне тәрҗемә итү дә авырлык тудырмый, чөнки андый мәкальләрдә милли колорит чагылыш тапмый. Мәсәлән, *Өргән эт тешләми. - Havlayan köpek ısırmaz; Этсез өйгә бүре төшәр. - Köpeksiz köye kurt iner.*

Бу мәкальләр чыганаклары белән бер конкрет тамырга барып тоташа. Мисал өчен, "Эт белән мәче кебек яшәү" (тур. "Kedi köpek gibi yaşamak", анг. "Like cats and dogs"). Мондый сурәтле антитеза күп кенә халыклар өчен универсаль, чөнки эт белән мәсе мөнәсәбәте барлык халыкларда да кеше тормышында стандарт рәвешендә чагыла. Бу очракларда чагыштырма телләрнең мәкаль берәмлекләренең тулы эквивалентлыгы ачыклана. Милләтара мәкальләр еш кына уртак мифик геройлар, әдәби образларны калькалаштыралар.

Тикшеренү барышында бик күп кызыклы, файдалы мәгълүматлар ачыкланды. Ике телдә дә хайван атамаларын мәкальләрдә куллану еш күзәтелә. Бу күренеш төрки халыкларның тере табигать белән тыгыз бәйләнештә торуыннан килеп чыгадыр, мөгаен. Телне бизәкле итүдә алар зур роль уйныйлар. Гомумән алганда, мәкаль һәм әйтемнәрне куллану, сөйләмне образлы, бизәкле, тәэсирле итә. Лексиканың бик кызыклы бу кисәге, моннан бик күп еллар элек барлыкка килеп, тагын да баеп, үзгәреп, безнең көннәргә дә килеп җиткән, әле тагын да гасырлар буе телне бизәячәк әле!

**Әдәбият**


1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 1 т. 2-нче басма. – Казан: Татар кит. нәшр., 2010. – 623 б.
2. Aksoy O.A. Atasozleri ve deyimler sozltigii. 1. Cilt. Atasozleri sozltigii. Istanbul, 2007. – 155 s.


## Ф.С. САФИУЛЛИНАНЫҢ «ТЕКСТ ТӨЗЕЛЕШЕ» ХЕЗМӘТЕНӘ КҮЗӘТҮ


*Сәлахова А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова Ә.Ш.*


Филология фәннәре докторы, профессор Флера Садрый кызы Сафиуллина 100гә якын фәнни монографияләр һәм фәнни-методик хезмәтләр авторы. Алар арасында татар теленең синтаксисы, лексикологиясе, стилистикасы, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр зур урын алып тора. Моннан кала, ул 500гә якын фәнни һәм укыту-методик мәкаләләре белән дә татар тел белеменең үсешенә зур өлеш кертте [3: 9].

Флера Садрый кызының эшләрендә татар теле синтаксисына караган бик күп актуаль мәсьәләләр тикшерелә. Шулар арасыннан “Развитие синтаксического строя татарского литературного языка”, “Синтаксис татарской разговорной речи”, “Порядок слов русского и татарского языков”, “Структура текста”, “Сопостовительный синтаксис русского и татарского языков” монографияләрендә XX нче гасыр татар теленең синтаксик төзелеш үсеше проблемасы карала. Бу хезмәтләрендә татар теленең гади һәм катлаулы җөмлә төзелеше һәм системасындагы үзгәрешләр мәсьәләсе анализлана, татар теле синтаксик системасының үсеш тенденцияләре билгеләнә. Галим тарафыннан беренче тапкыр күтәрелгән һәм чишелгән синтаксис теориясенең күп сораулары татар тел белеме өчен генә түгел, төрки тел белеме өчен дә зур әһәмияткә ия.

Югары уку йортлары өчен язылган “Текст төзелеше” дәреслек-кулланмасы 1993 нче елда Казан университеты нәшриятында чыга. Әлеге китапта сөйләмнең иң зур берәмлеге булган, коммуникатив дискурсның төп үзенчәлекләрен үзендә чагылдырган берәмлек – текст һәм аның төзелеше турында сүз бара. Ф.С. Сафиуллина сүзләренчә, “Бу китап университетта күп еллар буе текст төзелешенә, лингвистикасына, стилистикасына караган махсус курс һәм семинарлар алып бару вакытында язылды. Аның гомумлингвистик нигезләре гомуми һәм рус тел белеменнән алынып, яңа терминнар татар теленә тәрҗемә ителделәр яисә җайлаштырылдылар” [1: 3]. Хезмәтне эшләгәндә галимә күбесенчә И.Р. Гальперинның “Текст как объект лингвистического исследования” (М., 1981) дигән китабына мөрәҗәгать итә.

Ф.С. Сафиуллинаның “Текст төзелеше” китабын моннан элегрәк басылып чыккан фәнни эшләренең үстерелеш, баетылышы дип тә карап була. Чөнки аның моңа кадәр татар телендә сүз тәртибе, сөйләм теленең синтаксик үзенчәлекләре, әдәби әсәрдә хикәләү һәм аның синтаксик үзенчәлекләре, татар синтаксик төзелешенең соңгы гасырдагы үсешен өйрәнүгә багышланган монографияләре һәм күп сандагы мәкаләләрендә бу зур өлкәнең проблемаларын тикшергәне була.

Хезмәттә текстка билгеләмә бирү, аның төп үзенчәлекләре һәм категорияләре, татар матур әдәбиятында текст оешу закончалыклары һәм текст стилистикасына караган мәсьәләләр үзәктә тора. Югары уку йортлары өчен төзелгән әлеге монография студентлар, фәнни хезмәткәрләргә генә түгел, укучылар һәм журналистлар өчен дә зур бай мәгълүмат туплаган.

Хезмәткә күзәтү ясаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек.

1. Текстка тулы һәм төрле яклап ачыклый торган билгеләмә бирелә. Аның төп үзенчәлекләре, категорияләре билгеләнә. Татар матур әдәбиятында текст оешу закончалыклары һәм стилистикасына караган мәсьәләләр күтәрелеп чыга. Текстны барлыкка китерүче төп билгеләр

арасыннан Ф.С. Сафиуллина “төгәлләнгәнлек, мәгънәви бөтенлек, композицион-структур оешканлык, текст элементларының үзара тыгыз бәйләнеше, текстның атамасы булу, текстның язма хәлдә булуы”н [1: 10] һәм информативлык белән модальлекне аерып чыгара.

2. Хезмәттә текстның татар тел белемендә өйрәнелүенә караган мәгълүматлар да китерелә. Шул рәвешле, Ф.С. Сафиуллина текст проблемасына XX гасыр башында күзәтү ясала башлавын билгеләп үтә: “Һ. Максуди, Г. Ибраһимов, Дж. Вәлиди, Г. Алпаров һ. б., ким җөмләләрне аңлатканда, аның башка җөмләләргә бәйләнешенә дә игътибар итәләр. Соңрак бу мәсьәлә М.З. Зәкиев тарафыннан эшкәртелә” [1: 11]. Текст теориясенең тарихи үсеш тенденциясе каралу ягыннан да бу хезмәт әһәмиятле урын алып тора.

3. Ф.С. Сафиуллина синтаксик бөтен, җөмләләр арасында параллель бәйләнеш, текст эчендәге бәйләнешләр (когезия), континуум күренеше, тексттагы ретроспекция һәм проспекция, интеграция,

4. Мисаллар әдәбияттан да, көнкүреш сөйләмнәреннән дә тупланган. Галимә тезмә текстларны да, чәчмәләрен дә җентекле анализлый. Ул өлешләрдә без Ф.С. Сафиуллинаны телче буларак кына түгел, әдәбиятчы буларак та ачабыз. Шигъриятне кабул иткәндә галимә бер генә сүзнең дә артык түгеллеген аңлап эш итүне үрнәк итеп куя. Китапта авторның меңләгән санлы картотекасы белән беррәттән, студентлар тарафыннан табылган мисаллар файдалануы да искәртелә. Мисалларның күплеге текст төзелешен тирәнтен өйрәнергә мөмкинлек бирә.

5. Текст стилистикасы бүлегендә Ф.С. Сафиуллина Ф. Әмирханның һәм Ә. Еникинең поэтик синтаксисына, Г.Ибраһимов прозасындагы текст оешу закончалыкларына, Г. Исхакыйның хикәяләү осталыгына кагылышлы мәсьәләләргә тукталып, конкрет авторлар иҗатын өйрәнүгә дә игътибар бирә.

**Әдәбият**

1. Зайнуллин М.В. Филология фәннәре докторы, профессор М.В. Зәйнуллин Ф.С. Сафиуллинаның фәнни хезмәте хакында // Фәнгә багышланган гомер. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. – 216 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 264 б.

3. Юсупова Ә.Ш. Казан университетында – ярты гасыр... // Фәнгә багышланган гомер. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. – 216 б.

## ҚАЗАҚ ӘЛІПБИІН ЛАТЫН ГРАФИКАСЫНА КӨШІРУ МӘСЕЛЕСІ

*Серікжан Н., Семей медицина университеті, II курс студенті*

*Ғыл. жет. – пед. ғыл. канд., доц. Жорокпаева М.Д.*

Қазақ әліпбиі XX ғасырдың 20-30 жыл ішінде 3 рет әліпбиін (алфавитін) ауыстырды. Бірнеше ғасыр бойы қазақ халқы араб графикасына негізделген әліпби жүйесін пайдаланып келген. 1929–40 жылдары аралығында латын графикасына негізделген әліпби жазу

жүйесіне енгізіліп, 1940 жылдан бері кирил әліпбиі қолданысқа кіреді. Ахмет Байтұрсынұлы: «Біздің жасынан орысша я ноғайша оқыған бауырларымыз сөздің жүйесін, қисынын нағыз қазақша келтіріп жаза алмайды, я жазса да, қиындықпен жазады. Себебі – жасынан қазақша жазып дағыдыланбағандық. Орысша оқығандар орыс сөзінің жүйесіне дағыдыланып үйренген. Қазақ сөздерін алып орыс сөзінің жүйесімен тізсе, әрине, ол нағыз қазақша болып шықпайды» [1: 142]. Орыс графикасы негізінде қалыптасқан қазақ әліпбиі мен орфографиялық емлесіне әр кезде (1957 жыл, 1970 жыл) әртүрлі өзгерістер енгізілді. 2017 жылдың 9 қазанында қазақ әліпбиін латын әліпбиіне көшіру жобасы ұсынылды. 2017 жылы 26 қазанда қазақ тілінің жаңа латын әліпбиі Қазақстан Республикасының Президентінің жарлығымен бекітілді. 2018 жылғы 19 ақпанда осы қаулыға түзетулер енгізілді. Латын әліпбиіне негізделген қазақ жазуы әлемдік деңгейдегі білімге апарар жол. Біздерге олармен рухани, мәдени, ғылыми, экономикалық қарым-қатынасты, тығыз байланысты күшейтеміз. Мысалы, Б. Қалиұлының «Қазақ тілінің орфографиялық сөздігінің 6-шы басылымы жөнінде» атты мақаласында: 2007 жылғы жүз мың данамен таралған қазақ тілі орфографиялық сөздігінің ең соңғы (6-шы) басылымын қолға алып, ұқыптап қарасаңыз, одан біраз кемшіліктерді табуға болады, -деп атап көрсетеді. 1) Шындығын айтайын, орфографиялық сөздіктің жаңа басылымындағы *моңғол* сөзінің жазылуы менің көңіліме қонбайды. Құлақ түріп көріңіздерші, қай қазақ *моңғол* деп, «О»-мен айтады? Кімді тыңдасаңыз да бәрі *маңғол* деп, бірінші буынды «А»-мен дыбыстайды. Ең дұрысы: бұл сөзді айтылуы мен естілуі бойынша *маңғол* деп, «А»-мен жазған мақұл еді. Орфографиялық сөздік дегеніміз – сайып келгенде, ауызша сөйлеу тілінің жазба нұсқасы емес пе?! Сондай-ақ, біздің орфографиялық сөздігімізде жазылғандай ешбір қазақ «киіз үйдің шаңырағына жабатын төрт бұрышты киізді» *түндік* деп, «Н»-мен айтпайды. Оны *түңлік* деп, «Ң»-мен айтады. Дәл осы секілді сіз ауылдың қазағынан (қаланың қазағы ондай сөздерді бәрібір білмейді): – Омыртқаның жамбаспен жалғасқан ұш жағын не дейді? – деп сұрап көріңізші. «Оны *құймышақ* деп атайды» деген жауап аласыз. Ал осы сөз орфографиялық сөздікте *құйымшақ* деп беріліпті. 2) Біздің орфографиялық сөздігімізде бір сөз екі түрлі жазылып, әліпбилік реті бойынша олар екі жерде жүргенін кездестіруге болады. Мәселен, сөздіктің бір жерінде *мақшар* деп, Қ-мен берілсе, оның екінші бір жерінде *махшар* деп, Х-мен жазылған. Осылардың қайсысы дұрыс? т.б. [2: 139]. Қазіргі таңда латын графикасына негізделген қазақ әліпбиін орфографиялық сөздіктердің кемшіліктері мен жетістіктерін ескере, қазақ халқының артикуляциялық ерекшеліктеріне баса мән бере отырып, ғалымдардың талдауларынан, халықтың пікір көзқарастарын сарапталады.

Әліпби 32 әріптен тұрады. Осы ұсынылып отырылған әліпбиге қатысты пікір- көзқарастар ғалымдар арасында, сынамалық топтарда, қарапайым халық пікірлері арасында талқыланып жатыр. Сынамаға қатысушылар әліпбидің кемшіліктері мен қиындықтарын, оны жөндеудің жолдарын қызу талқылап, емле ережесін жасаушылар үшін аса қажетті ұсыныс-пікірлер жазып, өздерінің тәуелсіз көзқарастарын білдірді. Халық ы (у) мен у (ý), и мен і таңбаларына өзгерту енгізуді, ш (sh) және с (s), х (h), һ (h) әріптері қатар келетін сөздер оқылым мен жазылымда қиындық тудыратындықтан, ш дыбысына диграф емес, жеке таңба арнауды, у дыбысына u таңбасын беруді сұрап отыр. Сондай-ақ кейіннен қ-мен таңбаланып жүрген рақмет, рақат, дастарқан тәрізді сөздерді қайтадан х-мен жазуды, г-мен таңбаланып жүрген қыргүйек, шегара, көгөніс сөздерін к-мен жазуды қызу талқыға салды. Бұл орайда сынамаға қатысушылар ол сөздерді қ, г таңбасымен емес, бұрынғыдай х, к таңбасымен жазуды талап етіп отыр. Халық тарапынан айтылған бұл ұсыныс-пікірлер әліпбиге өзгеріс ендіру қажеттілігін және емле ережелерін қоғам пікірімен санаса отырып, аса ұқыптылықпен бекіту керектігін айқын аңғартты. Сонымен қатар, апробация нәтижесі жаңа емледе қазіргі жазу жүйесіндегідей босаң норманың (қыркүйек те дұрыс, қыргүйек те дұрыс, ғафу да дұрыс, ғапу да дұрыс т.б.) мүлде болмау керектігін, халықтың санасында берік орныққан базалық нормаларды қайта-қайта өзгерте бермеу қажеттілігін көрсетіп отыр. Емле мен орфографиялық сөздікке 4–5 жыл сайын өзгеріс енгізе бермей, үкімет тарапынан бір-ақ рет бекітілуі шарт екенін де апробация нақты айқындап беріп отыр[3]. Шеттілдік сөздерді тіліміздің айтылым нормасына бағындыру керек деп, орыс орфоэпиясына салып сындыруды ұсынғандар да кездесті (канститутсиа, кәмпүйтер т.б.). Бірақ шеттілі сөздерінің жазылымын орыс орфоэпиясымен қалыптастыру дұрыс емес. Керісінше, орыс орфоэпиясымен айтуды да доғару керек. Бірақ біздің қоғам конституция, компьютер т.б. сөздерді дәл осылай айтуды ұят деп есептейді. Ал жаңа емле бойынша компьютер сөзін латын әліпбиімен kompýter (айтылымы кампутер), продюсер сөзін prodýser (айтылымы прадусер) деп таңбалаймыз Бұл үдеріс – саяси реформа. «Кеңесіп пішкен тон келте болмас» деген сөз бар. Қазақ айтқандай, «елу жылда – ел жаңа, қырық жылда – қазан жаңа», – дегендей жаңа қазақ әліпбиі еліміздің мәдениетін, рухани құндылықтарын және ғылымымызды, әдебиетімізді, салт-дәстүрімізді әспеттеп әлемдік деңгейде көрсете алтын дәрежеде болатыны анық. Қазіргі кезеңде білім саласындағы жаңа реформаның жүзеге асырылуы да, яғни жаңартылған білім мазмұны осы латын әліпбиіне көшуде өз үлесін қосады деуге болады.

**Әдебиет**

1. Тіл тағлымы. – Алматы: Ана тілі, 1992. – 142 б.

2. Қалиұлы Б. Ахмет Байтұрсынұлы және қазақ терминдері // Ұлттық рухтың ұлы тіні. – Алматы: Ғылым, 1999. – Б. 409–416.
3. https://egemen.kz/article/174218-emle-erezhesi-zhurtshylyq-talqysynan-oetti

## ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ В ОПИСАНИИ ХАРАКТЕРИСТИКИ И ПСИХОЛОГИЧЕСКОГО СОСТОЯНИЯ ПЕРСОНАЖА
(на примере романа А. Нурпеисова «Қан мен тер»)

*Серикова А., БГПУ им. М. Акмуллы, магистрант I курса*
*Науч. рук. – док. филол. наук, проф. Насипов И.С.*

В казахском литературном языке фразеологизмы играют важную роль для выразительной и красочной передачи мыслей. Устойчивые сочетания слов дает тексту не только особую форму, но и открывает новый мир для читателя. Фразеологизмы – это готовое средство, которое оживляет язык художественного произведения; модель языкового мышления, впитавшая в себя народную мудрость. Это богатство языка используется писателем в произведении по мере необходимости, в зависимости от его мыслей, эстетического вкуса, общественно-политических, философских взглядов и др. Употребление фразеологизмов в языке художественного произведения – это определение красочного выражения языковых способов для создания собственного стиля автора.

Стилистическая окраска и экспрессивная возможность фразеологизмов более мощная и широкая по сравнению с отдельным словом. По этой причине фразеологизмы дают особый стилистический характер и в речи, и в художественном произведении. Основная функция фразеологизмов в художественном произведении – создание образа, речевая характеристика героя, заключение к определенной ситуации, ирония и сарказм и т.д. [2: 54–56].

Писатель А. Нурпеисов в произведении «Қан мен тер» («Кровь и пот») умело использовал фразеологизмы в художественных целях: 1) для характеристики героев; 2) для передачи психологического состояния участников произведения.

1. Помимо внешнего портрета писатель делает портрет мировоззрения, характера и внутреннего мира. Для этого А. Нурпеисов, обратившись к фразеологизмам, активно использовал экспрессивную характеристику. Например: а) *Құдайменде қонақасыға* ***мырза.*** *Оның ішінде, әсіресе, пейілі түскен кісіге* ***ағыл-тегіл***. В этом примере слово *мырза* используется в значении «щедрый». Автор использует фразеологизм, *ағыл-тегіл*, тем самым усиливает экспрессию текста и дает положительную характеристику героя; б) *Ол кеткесін балықшылар тағы да қауқылдасты:* - ***Қара білек***, *мықты жігіт!* Когда главный герой *Мөңке* ушел, жители аула стали обсуждать его, используя словосочетание *қара білек*, которое раскрывает трудолюбие, силу и твердость характера героя; в) *Еламан бұрын-соңды жас адамды, дәл мұндай* ***дініне берік*** *кісіні көрген емес.* В раздумьях *Еламана* о девушке

автор использует фразеологизм *диіне берік*. Нурпеисов хотел, чтобы читатели без лишних слов сами смогли создать образ горделивой натуры со своеобразным воспитанием и принципами. Самая главная функция данного фразеологизма в приведенном примере, донести до читателя, что *Еламан* был отвергнут *Акбалой*. Благодаря метко выбранному фразеологизму мы смогли сделать характеристику героини и понять причину ее действия.

В приведенных примерах фразеологизмы имеют сильную окраску, с преобладанием экспрессивного значения и точно отражают качества персонажа. Такие картины вызывают эмоциональное воздействие на читателя, дают живой тон художественному произведению.

2. Все образные слова, влияющие на чувства в художественном произведении, усиливают общую экспрессивную гармонию произведения, делают эмоциональную окраску более контрастным. В точном, разностороннем изображении понятия фразеологизмы имеют выигрышную позицию. В произведении писатель выбирает фразеологизмы с целью четкого отображения психологических состояний героев в тех или иных ситуациях. Например: *а) Ақбала ә дегенде* ***сұп-сұр боп кеткен-ді****. Бірақ тез есін жиып,* ***бет-өңін билеп ала қойды***. С помощью фразеологизмов описывается, как *Акбала* сначала растерялась, после сразу смогла овладеть своими эмоциями и старалась не показывать свое волнение; *б) Балықшылардың* ***арқа-етегі кеңіп*** *сала қойды.* В примере говорится, что только после ухода начальника рыбаки смогли дышать полной грудью. Использованный в данном примере фразеологизм точно описывает насколько рыбакам было ненавистна присутствие начальника; *в) Ызам* ***ішіме сыймай, қара тырнағыма дейін күйіп*** *тұрсам.* В данном примере автор использует две фразеологических единиц. Они означают последовательное действие, тем самым усиливает экспрессию текста и дает читателю почувствовать насколько зол автор этой реплики.

Таким образом, можно сделать вывод, что фразеологизмы в приведенных выше примерах раскрывают и дополняют образы, раскрывающие многообразные черты характера персонажей, с особой выразительностью, проявлением различных душевных чувств к разным событиям в жизни героев. Фразеологизмы в произведении писателя оживляют язык художественного произведения и дают ему национальный колорит, сочетаются с идеей произведения и акцентируют внимание на звучность и мелодичность казахского языка, но самое главное точно и тонко передают характер казаха-сына степей. Стиль использования фразеологизмов в творчестве А. Нурпеисова отличается именно такими качествами.

**Литература**

1. Бейсенбай А.Б. Тұрақты тіркестердің авторлық өңдеудегі қолданысы. – Алматы, 2006. – 120 с.

2. Қожахметова Х.К. Фразеологизмдердің көркем әдебиетте қолданылуы. – Алматы, 1972. – 112 с.
3. Манкеева Ж.А. Мәдени лексиканың ұлттық сипаты. – Алматы, 1997. – 272 с.

## БҮГЕНГЕ ШИГЪРИЯТТӘ ДИАЛЕКТАЛЬ СҮЗЛӘР

*Сибагатуллина А., Бөгелмә р-ны М. Өнҗәл ис. лицей-интернат, X сыйныф*
*Җит. – Юнусова С.Г.*

Поэзия, ягъни тезмә әсәр җанлы сөйләмнән аеруча нык аерылып торган, мәгълүм тел кагыйдәләре таләбенә туры китереп оештырылган булуы белән аерылып тора. Шулай булуына карамастан, поэзиядә күпләп диалекталь сүзләрнең кулланылышы күзәтелә.

Әлеге фикерне Хәсән Туфанның «Ике чор арасында» поэмасыннан алынган өзектәге диалекталь сүзләрнең кулланылыш ешлыгы раслап тора.

Әйдә, агай, чабатаңны сиплик,
Кичәгенәк
Без бик әйбәт юкә урладык
Пеше юкә
Штраудан куркып,
Яшереп куйдык әле без аны...

Өзектән күренгәнчә, шагыйрь милли тел байлыгын мөмкин кадәр тулы файдаланырга, бар җегәрен, моңын, матурлыгын эшкә җигәргә тырыша. Шуның белән бергә бу хәзинәдә әле әдәби тел нормаларыннан беркадәр аерылып торган, таррак сферада йөри торган диалекталь сүзләр катламы да бар: кичәгенәк – лексик-морфологик диалектизм: ул кичә һәм *-генәк* кушымчасыннан тора; Урта диалектның, Казан арты сөйләшләре төркеменә керә торган Лаеш сөйләшендә кулланылучы рәвеш; пеше – әдәби телдә урын алган диалекталь сүз, сыгылмалы һәм нык дигән мәгънә белдерә, шулай ук Урта диалектның, Казан арты сөйләшләре төркеменә керә торган Лаеш сөйләшендә пешкән, пешүле мәгънәсендә кулланыла, Златоус сөйләшендә чирак мәгънәсендә кулланыла; штраудан – алынма диалектизм, чыгышы белән рус теле аша немец теленнән кергән штраф сүзеннән үзгәртеп ясалган, нәрсә дә булса административ органнар тарафыннан акчалата түләтелә торган мәгънәсендә. Әдип чор, төбәк, даирәнең сулышын, колоритын төсмерләтү өчен аларны әсәрләренә кертеп җибәрә. Шуның белән бергә «ул үзен һәрдаим тыеп тора, арттырып җибәрүдән саклана.Ул аларны үтә чикле күләмдә, сиздереп куярлык, ишарә итәрлек дәрәҗәдә генә ала».

Поэзиядә шагыйрьләр диалекталь сүзләрне әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаганда кулланалар. Мәсәлән: тегермән стеналарына кунып кала торган он тузаны дигән төшенчәне белдерү өчен, әдәби телдә сүз булмаганга, 1956 елда ук инде С. Хәким болай дип язган булган:

Беркемнең дә кулы кагылмаган,

Соңгы ачлык узгач түшәлгән

Онта коела, күксеп беткән онта...

*Онта* исем сүз төркеме белән бирелгән диалекталь сүз, он тузаны мәгънәсендә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә онта сүзенең мәгънәсе теркәлгән, димәк бу сүзнең әдәби телебездә ур¬нашып калуын күрсәтүче факт. «Җирле сөйләмнән, халык авыз иҗатыннан табып алынган сүзләр сүзлек байлыгын тагын да арттыра ала», ягъни сүзлек хәзинәбезне баетучы чыганак булып тора.

«Телебезнең байлыгын барлый башласаң, халкыбызның бөек шагыйрь булуына да таң каласың». «Төрле җирле сөйләшләребездә таралып яткан этнографик диалектизмнарга гына бер күз салыйк: алардагы образ, алардагы чагыштыру, дөньяның матурлыгына соклану, яшәү матурлыгын раслау! Һәр атама – үзе бер «шигырь»:

Чапты атлар басу юлларыннан,

Ә юл, ә җир – каты....

Башын иде чуклы сөлгеләрдән

Җиргә нәзер аты.

Татар халкының инде күптәннән килә торган бик матур бәйрәме – Сабан туенда арттан килгән атка нәзер әйтү, адарыну бар; бу күптәнге йола. Сибгат Хәким шул гореф-гадәтебезнең асылын ачып бирә.

Шигъри әсәрләргә күз салсак, поэзиядә туганлык атамаларының кулланылышын күзәтергә була. Халык шагыйре Хәсән Туфан *бертума, канәт* сүзләрен куллана:

Без – күбәү, безенең тагын бар

Бертума – алтмыш туган.

Шуларның уртанчысы – син,

Ә зурысы вәт – мин булам!

Исле гөлләр исен хәтерләтеп

Искә төшкән Кармәт төбәге!

Кичер мине, канәт, сезнең хакта

Ярты сүз дә язган юк әле.

*Бертума* – Мәләкәс сөйләшендә бертуган мәгънәсендә; бер ата-анадан туган. *Канәт* – автор аңлатмасында, апа-абыйларның кече туганнарына «үскәнем», «акыллым» мәгънәсендә иркәләп эндәшүе.

Шагыйрьләр диалекталь сөйләм сүзләрендәге киң мәгънә үзенчәлекләреннән оста файдаланалар. Мәсәлән, Сибгат Хәким буылган сүзен бөялгән дип куллана. Бөялгән – Казан арты, Дөбъяз сөйләшендә буылган мәгънәсендә кулланыла:

Табамын эзләп җыелган,

Бөялгән күлләр суын.

Йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: диалекталь сүзләрнең поэзиядә законлы урыны, хокукы диалект һәм милли телнең үзара бәйләнеше, йогынтысы белән билгеләнә. Диалектлар – халыкның тел диңгезен тулылан-дырып торучы чишмәләр алар. Әдәби телдә сүз булмаганда, шагыйрь алардан сүз-сурәт ясый.

**Әдәбият**

1. Туфан. Х. Әсәрләр: 5 томда. Т. 1.: шигырьләр, поэмалар. Кереш сүз авторы М. Гайнетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 73.
2. Хәким С. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 414.
3. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Ф. Рамазанова, З.Р. Садыйкова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – Б. 163–529.

## ТВОРЧЕСТВО ФАТИХА КАРИМИ: РЕЛИГИОЗНО-ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ОСОБЕННОСТЬ ЭПОХИ

*Сибгатуллина М., Российский исламский институт, магистрант II курса*
*Рук. – Тухватуллин А.Х.*

Конец XIX–начало XX столетия в истории татарского народа принято считать эпохой общественно-духовного возрождения, охватывающего все области национальной жизни. Особое место в этом общенациональном процессе занимала художественная литература и публицистика, ярким представителем которой явился видный общественный деятель, педагог, литератор, издатель и публицист Фатих Карими. Его многогранная и плодотворная деятельность питалась идеями гуманизма, просвещения и развития духовной и материальной культуры татарского народа. Немаловажное значение при этом имеет окружение, с которым он общался, общие тенденции развития отношений в обществе между гражданами, властью и духовенством.

Эпоха активной деятельности Ф. Карими – конец XIX-начало XX вв. Данный период занимает особое место в становлении татарского народа, его культуры и ассоциируется с понятием «джадидизм». То, что основными проблемами в творчестве Ф. Карими были просвещение, духовные и нравственные ценности татарского общества служат тому подтверждением. Татарская интеллигенция, представителем которой был Фатих Карими, в результате объединения вокруг идей джадидизма, сумела сделать важный поворот в жизни татарских и других мусульманских народов.

Наряду с вопросами просвещения не только богословов, но и интеллигенцию волновали проблемы религиозной культуры татар в частности, и всех мусульман России в целом. Рассматриваемый нами автор ратует за получение человеком истинного религиозного и светского образования и воспитания, за гуманное решение женской проблемы, за знакомство с достижениями мировой культуры, науки, цивилизации.

Развитие религиозных отношений в становлении татарского народа на стыке XIX-XX вв. с точки зрения проблематики данной статьи имеет особое значение. Как известно, до активации средств массовой информации, художественная литература имела огромное значение в распространении информации, просвещении, воспитании. В силу сложившихся обстоятельств, в татарской литературе религиозная тематика развивалась с начала Средневековья. Религиозное воспитание занимает место среди таких систематичных и постоянных тематик литературы как любовь, просвещение, труд, семья, воспитание детей, взаимотношения людей и т. д. На почве богатой литературы, основываюшейся на традициях Ю. Баласагуни, А. Ясави, С. Бакыргани, Кул Гали, Махмуда бине Гали, Хисама Кятиба, Мухаммадьяра, Умми Камала, Кулшарифа, Т. Ялчыгола, Ш. Заки, Б. Ваисова, С. Аллаяра, М. Амин, Габди, Габдессалям, Г. Утыз Имяни и др. возникла новая волна таких выдающихся личностей татарского народа, как Ш. Марджани, К. Насыйри, Г. Кандалый, М. Акмулла, Г. Исхакый, Ф. Карими, Г. Тукая и др.

Помимо литературоведческой деятельности в становлении и сохранении татарского народа и татарского языка важную роль сыграла религия. Фатих Кармии сформировался как личность при поддержке выдающегося ученого татарского народа Р. Фахреддинова. Ризаэддин Фахреддин является крупным религиозным философом. Его творческое наследие внесло огромный вклад в развитие мусульманской культуры России, его труды востребованы сегодня религиозными деятелями, учеными, педагогами. Наследие Р. Фахреддина является ценнейшим источником по истории и культуре народов России и Востока. Изучение его является одним из условий дальнейшего развития исламского богословия и необходимо для поддержания конструктивного диалога мусульман с представителями других религий в РФ [2].

Еще одним современником Ф. Карими является Муса Бигиев. Он известен в мусульманском мире как ученый, ориенталист, богослов, общественный деятель. Имел светское и богословское образование. Как и Фатих Карими вел активную общественную деятельность.

С конца XIX века татары среди нерусских народов России вели активную деятельность в области книгопечатания, издания газет и журналов. Фатих Карими так же принимал активное участие в данном направлении. Однако в связи с известными событиями конца 1917 года, во всех направлениях жизни народов страны начинают происходить трансформации. Постепенно останавливается столь масштабная деятельность, проведенная татарской интеллигенцией по возрождению народа, его духовной и материальной культуры. Совсем скоро, в 1930-е года, практически

прекратилось издание книг по религиозной тематике. Начались массовые аресты религиозных деятелей и свободомыслящей интеллигенции.

Спустя несколько десятилетий, уже в наши дни чистота и сохранность понятий Ислама нуждаются еще более тщательном изучении и разъяснении. Это в первую очередь выражается в определенности общества в богословских ориентирах. Об этом свидетельствует принятая на IV Всероссийском Форуме татарских религиозных деятелей Концепция. В документе излагаются базовые положения Ислама и его учения по вопросам государственно-конфессиональных отношений и по ряду современных общественно значимых проблем. Документ также раскрывает позицию татарского мусульманского духовенства в сфере взаимоотношений с государством и светским обществом. Его основным предметом является фундаментальные богословские и социальные вопросы, а также те стороны жизни государства и общества, которые были и остаются актуальными для татаро-мусульманского сообщества в начале XXI века и в ближайшем будущем. Концепция призвана стать шагом к консолидации татарского народа на основе Исламских ценностей [1].

Таким образом, анализируя обстоятельста начала прошлого века и настоящего времени прослеживаются определенные параллели. Как известно, на рубеже XIX и XX веков произошли серьезные изменения и в жизни татарского народа. Соответственно новая эпоха ставила перед обществом целый комплекс вопросов экономического, политического и социального характера. Эти вопросы, в первую очередь, волновали национальную интеллигенцию, в которой одну из ведущих позиций занимал известный просветитель, писатель, публицист, переводчик и педагог Фатих Карими. Несмотря на то, что в век глобализации благодаря информационному потоку современное татарское общество претерпело некоторые изменения, ценности, проблематика эпохи Фатиха Карими остается классической.

**Литература**

1. Концепция «Ислам и татарский мир». Электронный ресурс. Режим доступа: https://islam-today.ru/islam_v_rossii/tatarstan/koncepcia-islam-i-tatarskij-mir-polnostu/ (Дата обращения: 12 января 2019 г.).

2. Фахретдинов, Ризаитдин Фахретдинович, https://ru.wikipedia.org

## ӘЛКИ РАЙОНЫНДА ҖЫЕЛГАН МӨНӘҖӘТЛӘР ТЕКСТЫНДА ДИНИ ЛЕКСИКА

*Сиразова С., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Җамалиева Л.Ф.*

Мөнәҗәтләр – татар фольклорының иң борынгы жанрларыннан берсе, ярымфольклор – ярымъязма әсәр. Мөнәҗәт – ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, ярлыкавын сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялвару [4: 29].

Көнчыгыш фольклорында һәм әдәбиятында мөнәҗәтләр VIII гасырда Гарәбстанда иҗат ителә башлаган, дип яза галимнәр. Иң беренче булып аларны изге Рабига иҗат иткән, диелә [2: 39]. Бу жанр гарәпләрдә, фарсыларда, төрекләрдә бик киң таралган.

Төрки шагыйрьләрдән мөнәҗәтләрне Әхмәт Ясәви (XII гасыр), Сөләйман Бакыргани (XIII гасыр) иҗат иткән. Ясәвинең «Кемләр өчен килде рәсүл» дигән мөнәҗәте халыкта хәзерге көндә дә башкарыла. Бөек төрки-татар шагыйрьләре – Кол Гали, Харәзми, Сәйф Сараи, Кятиб, Сәйади, Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр, Г. Утыз Имәни, Һ. Салихов, Ә. Каргалый, М. Акмулла, Г. Кандалый, Ш. Зәки, Дәрдемәнд һәм Тукайлар шулай ук мөнәҗәт жанрында аерым әсәрләр иҗат иткәннәр [1: 18]. Аларның әсәрләрен халык күп гасырлар дәвамында үзенеке итеп сөйләгән, яисә аерым строфа-мотивларын алып, яңа мөнәҗәт чыгарган. Бу уникаль күренеш тоташ грамоталы, язу белгән халыкта – татарда гына була алган [3: 25].

Казан дәүләт мәдәният институтында укыган вакытта без Әлки районы Югары Әлки авылында фольклор экспедициясендә булдык. Җирле авыл халкы белән очрашып төрле темаларга әңгәмәләр үткәреп, бай мәгълүмат тупладык.

Югары Әлки авылында йортан йортка кереп халык арасында бик күп җырлар, бишек җырлары тыңладык, төрле мифологик ышанулар, әкиятләр, риваятьләр, мөнәҗәтләр белән дә таныштык.

Югары Әлки авылында тыңлаган мөнәҗәтләрдә дә кайгы-хәсрәт, бәхетсезлек, фаҗига нәтиҗәсендә барлыкка килүе, татар халкының иҗтимагый, тарихи тормышы, язмышы никадәр вакыйгаларга бәйләнгәнлеге билгеле булды.

Информант – Сафиуллина Сәгадәт Әбрар кызы (1933 елның 25 гыйнварендә туган) 86 яшендә булуына карамастан аларның бик күпләрен белә. Яшь вакытта әбиләреннән ишетеп, өйрәнеп калган ул.

Иляһи син Гали Саттар
Хатага рәхмәтең гаффар
Гафу кыйл әйләдем зар-зар
Өмидем бар гафалардан.
Иляһым син үзең галим
Белерсең бәндәнең хәлен
Күзем яшьле,телем салим
Рәхим кыйл син узең Рахман.
Бу дөнья безләргә фаный
Фаный дөнья безне алдый
Бер А,ллаһым хозурына
Һичбер адәм бармый калмый.
Бу дөньяда безләр кунак

Барыр җирләребез ерак
Әгәр иман белән үтсәк
Йөзләребез булыр ап-ак.

“Дин – агу”, “дин – әфьюн” дигән шигырьләр яңгыраган шартларда барлык диннәргә, дин әһелләренә дә һөҗүмнәр булган. Әмма элекке гасырларда ук ныгып калган исламны татар халкы үзе саклаган. Дини фәлсәфә, үгет-нәсыйхәт тулы әсәрләр-мөнәҗәтләр иҗат ителгән, халыкны иҗаттан туктатып булмаган. Мәчетләр ябылып, манаралар киселсә дә, көнкүрештә Нижгар якларында дин яшәп килгән [2: 72]. Никахлар яшереп кенә укылып, туйлар тиешенчә үткән, мәетләр дин кушканча озатылган, алар рухына Коръән сүрәләре укылган. Дини бәйрәмнәр үткәрелгән, корбан чалу туктамаган. Бәйрәмнәрдә гает намазларын аерым өйләргә җыелып укыганнар.

Шулай итеп динне, иманны халкыбыз үзе саклады, югалтмады. Соңгы елларда, дин ирекгә тугач, һәр авылны азан аһәңе хисләндерә, һәр авылда бер генә түгел, берничә мәчет төзелде.

Халык иҗатында да дини жанрлар җанланып китте. Бигрәк тә мөнәҗәт жанры чәчәк атты, халыкның дингә, Аллаһыга, пәйгамбәрләргә булган хисләре шигъри яңгыраш алды.

Мөнәҗәтләр галимнәр тарафыннан берничә төркемгә бүлеп анализлана. Без язып алган мөнәҗәтләр арасында Аллаһыга, исламга, пәйгамбәрләргә, Коръәнгә мактау-мәдхияләр, ялварулар тулы дини әсәрләр, яшәү һәм үлем турында, ана белән бала мөнәсәбәтләре турында әсәрләр бар.

Динем ислам динедер
Нәбием Мостафадыр,
Нәс(е)лем адәм нәс(е)ледер
Белмәк кирәк кардәшләр.
Пәйгамбәрләр әүәле
Атабыз адәм торыр
Мөхәммәт ахры торыр
Белмәк кирәк кардәшләр.
Раббым йөз дә дүрт китап
Индермеш Рәсүлләре
Дүртеседер зур китап
Белмәк кирәк кардәшләр.
Коръән илә гамәл кыйлмак
Аллаһка тәгат кыйлмак
Фарызларның әүвәледер
Белмәк кирәк кардәшләр.

Шул рәвешле, мөнәҗәт текстларында Ислам диненә бәйле лексика бик еш очрый. Моның сәбәбе, мөнәҗәтләрнең эчтәлеге турыдан туры дин белән, Аллага ышану белән бәйле булуда.

**Әдәбият**

1. Гатина Х.Х., Ярми Х.Х. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче кит. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 201 б.

2. Җамалетдинов Л.Ш. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 3 нче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 305 б.

3. Исмәгыйлева С. Халык авыз иҗаты мәктәптә. – Алабуга: ЕГПИ нәшр., 2005. – 103 б.

4. Мәхмүдов Х. Борынгылар әйткән сүзләр. – Казан: Фикер, 2002. – 256 б.

5. Яхин А.Г., Бакиров М.Х. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1979. – 198 б.

## ТАТАР, РУС ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

*Слепова А., Тихонова В., Казан, 6 нчы гимназия, X сыйныф*

*Җит. – Закирова М.З., Хөснуллина Г.Н.*

Өч телдә дә сыйфатлар дәрәҗә белән төрләнәләр. Тикшерелә торган өч телдә дә гади дәрәҗә предметның гадәти билгесен белдерә: матур (красивый). Чагыштыру дәрәҗәсе татар телендә -рак, -рәк кушымчасы ярдәмендә формалаша: акыллы – акыллырак. Ә рус телендә: 1) -ее (-ей), -е суффикслары: умный – умнее; 2) сыйфатның гади формасына более, менее сүзләрен кушып ясала: более добрый, менее честный. Ә инглиз телендә чагыштыру дәрәҗәсе -er суффиксы ярдәмендә формалаша: big – bigger (больше, зуррак), thin – thinner (тоньше, юкарак).

Артыклык дәрәҗәсе (превосходная степень) бер әйбердәге билгенең башка шундый ук әйбердәге билгедән бик күпкә артык икәнлеген белдерә. Татар телендә артыклык дәрәҗәсе: сыйфатның кабатланып килгән беренче иҗегенә [п] яки [м] авазлары өстәлеп: кара – кап-кара (совершенно черный, пречерный); Рус телендә артыклык дәрәҗәсе -ейш-, -айш- суффикслары ярдәмендә, яисә сыйфатка “самый” сүзе кушылып ясала: самый сильный – (иң көчле). Аерым очракларда артыклык дәрәҗәсе -ш суффиксы ярдәмендә, яки сыйфатка “очень”, “весьма” мәгънәсен белдерүче пре- приставкасы кушылып ясалырга да мөмкин: высший, премилый – очень милый (бик сөйкемле). Инглиз телендә артыклык дәрәҗәсе -est суффиксы ярдәмендә, яисә сыйфатка more (более) һәм most (наиболее, самый) сүзләре кушып ясала: the darkest (самый темный). Сыйфатлар алдыннан артыклык дәрәҗәсендә the артикле куела. Мәсәлән: This is the shortest way to the station (Это самая короткая дорога к вокзалу).

Татар телендә кимлек дәрәҗәсе -ылҗем, -елҗем, -гылт, -гелт h.б. кушымчалары ярдәмендә формалаша: кызгылт, яшькелт. Рус телендә кимлек дәрәҗәсе аерып бирелмәсә дә, -оват, -еват суффикслары әйбердәге билгенең гадәттәгедән бераз ким булуын белдерә: беловатый – аксыл.

Туган тел һәм чит телнең үзара тәэсиренә нигезләнеп, чит тел өйрәнү тел гыйлемендә инде күптән кулланыла. Моңа үз заманында бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри да игътибар итеп, шул фикерне әйтеп уза.

Соңрак буын галимнәре дә аның фикерләре белән килешеп, телнең охшаш һәм аермалы якларын чагыштыруны телгә өйрәтүнең иң уңай алымнарыннан берсе икәнен ассызыклап үтәләр. Чыннан да, телләрне чагыштыру телне чит тел буларак өйрәнүчеләр өчен фәнни яктан яңа мөмкинлекләр ача. Телне башка тел белән чагыштыра белү укучының белем дәрәҗәсен киңәйтә, фикерләвен арттыра.

Димәк, татар телен өйрәнү өч телне чагыштырып үзләштерелсә, укучы өчен күпкә отышлырак һәм җиңелрәк була.

**Әдәбият**


1. Газизов Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Тат. кн. изд., 1987. – 235 с.
2. Гольцова Н.Г. Русский язык 10-11 классы. – Москва: Русское слово, 2012. – 120 с.
3. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан, 1994. – 312 б.
4. Верещагина И.Н., Притыкина Т.А. Английский язык. – М.: Просвещение, 2011. – 156 с.


## ВЛИЯНИЕ ЦИВИЛИЗАЦИИ НА ТРАДИЦИОННУЮ КУЛЬТУРУ ОХОТЫ У СИБИРСКИХ ТЮРКОВ


*Софронеев П., Северо-Восточный федеральный университет, студент IV курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Архипова Е.А.*


Одним из первых занятий человека была – охота. Это не просто добывание пищи способом убийства животного, но и своеобразный диалог природы с человеком, включающий в себя развитие в нем духовно-нравственных, физических и умственных качеств. Но с ростом цивилизации люди начали забывать о духовном, отдавая предпочтение материальному, новшествам модернизации.

Рассмотрим термин “модернизация” как макропроцесс перехода от традиционного общества к модерновому обществу, от аграрного – к индустриальному. Это развитие науки, техники, появление заводов, фабрик, рост городов и т.д. Все эти изменения существенно улучшают и упрощают жизнь современного, цивилизованного человека, но только в материальном плане. Порой мы не замечаем того, что происходит внутри нас, в духовной сфере. А всё духовное в нас, мне кажется, берется от природы, которую пожирает модернизация.

Вячеслав Даржа утверждал: “Сознание современных носителей культуры, подвергнутое разрушительному воздействию цивилизации, невероятным образом трансформируется. Самое страшное последствие этого воздействия – отчуждение от собственной культуры, забвение и обесценивание традиций, помогавших народу веками жить на этой земле. <…> Наиболее разрушительным последствием влияния западной цивилизации на тувинцев стало уничтожение в их сознании **Закона Меры,** сдерживающего потребительский эгоизм и примитивного хищника”[2: 8].

В древности человек был намного ближе к природе, считал себя частью природы, а не её властелином. В каждом народе имелись понятия о сохранении и обогащении своего ареала обитания. А сохранение природы требовало баланса всего составляющего. И баланс этот устанавливал человек, сам же являясь частью природы. В те времена охотник был не только человеком добывающим, но в то же время человеком создающим, дающим возможность прижиться, расплодиться другим живым организмам. Чтобы достичь такого уровня духовного развития, якуты с малых лет учили своих детей искусству охоты.

“<…> саха киһитэ, бастатан туран, булчут култууратын тутуһарга дьулуһуохтаах. Ол эбэтэр кини айылҕаҕа харыстабыл, сиргэ-дойдуга сиэрдээх сыһыан диэни өйдөөн, олох салҕанан барар сокуонун ытыктыахтаах уонна хаһан да умнуо суохтаах” [1: 27]. Якут, первым делом, должен придерживаться культуры охотника. То есть, бережно относиться к природе, уважать закон продолжения жизни.

Как мы уже поняли, основной удар цивилизации принимает на себя традиционная духовная культура. Так, как цивилизация – это, прежде всего, наука, а наука, в свою очередь, отрицает религию, а религия – это традиции, культура и обычаи, то их конфликт попросту неизбежен. Мы постепенно отдаляемся от природы, теряем человечность, слабеем нравственно и физически. Цивилизация отнимает у нас то, что сделало нас людьми, а именно – труд. По поводу данной проблемы Вячеслав Даржа высказался так: “К сожалению, цивилизация породившая огнестрельное оружие, хитроумные ловушки и прочие производные от ума средства, ударила в первую очередь по самому человеку. Сегодня уже не найти подростков 10–12 лет, способных на коне догнать и остановить волка, нет лихих наездников, способных догнать в одиночку и фактически “голыми руками” добыть волка. Мало осталось тех, невероятно выносливых охотников, способных зимой, в 40-градусный мороз, сутками преследовать волка, не смыкая глаз ни днем, во время преследования, ни ночью в засаде. Современная цивилизация стремительно поглощает в мужчине все самые достойные мужские качества: отвагу, стойкость к невзгодам и способность к самопожертвованию. Оставляя у слабого, не стойкого к невзгодам, лишенной физической силы и ловкости “особи мужского пола” зачастую только репродуктивные способности” [2: 436].

В заключении хочется отметить, что сохранение человечности и духовно-нравственных качеств является делом принципа. Должно быть каждый из нас слышал о жестокости нынешних охотников, об их безнравственности. Это говорит об исчезновении старой школы обучения молодого поколения, нынешние охотники руководствуются инстинктами, которые присуще всем, но древние люди умели укрощать азарт, жадность. С

развитием науки все проще удается обнаружить дичь, догнать ее и убить, открыв шквальный огонь. Это не честно по отношению к животным и самому себе. Нужно принципиально прививать своим детям с малых лет ответственность за жизнь других существ, любовь к природе и развить чувство меры. Мы должны научиться использовать цивилизацию, развитие технологий во благо всех живых существ, жить в гармонии с природой и поддерживать баланс.

**Литература**


1. Баай Байанай бэлэҕэ: булчут улахан кинигэтэ. – Дьокуускай, 2014.
2. Даржа В.К. Традиционные мужские занятия тувинцев. – Кызыл, 2008. – 150 с.


## «ЕГЕМЕН ҚАЗАҚСТАН» ГАЗЕТІ КӨТЕРГЕН СЫРТҚЫ САЯСИ МӘСЕЛЕЛЕР


*Султанова А., М. Қозыбаев атындағы Солтүстік Қазақстан мемлекеттік университеті, II курс магистранты*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., проф. Тайшыбай З.С.*


Қазақстан ЕЫҚҰ-на өзінің ғасырлар бойы қалыптасқан қиыншылықтар мен келіспеушіліктерді бірлік, келісім, толеранттық, сұхбаттасу арқылы бейбіт жолдармен шешу тәжірибесін ұсынды. Қазақстанның тәуелсіздік ала салысымен өз жеріндегі ядролық қарулардан бас тартуы осы бейбітшілікті жақтау саясатының заңды көрінісі еді. Егеменді Қазақстан 1991 жылдан бастап өзінің сыртқы саясатында ынтымақтасу, бейбітшілік, өзара пайдалы сауда-экономикалық қатынастар, өркениеттердің үн қатысуы принциптерін бұлжытпай басшылыққа алып отырды. Соның нәтижесінде ЕЫҚҰ Қазақстан төрағалығы «Trust – Traditions – Transparency – Tolerance» немесе сенім, дәстүр, ашықтық, төзімділік ұрандарымен жүрді. Қазақстан, біріншіден Батыс пен Шығысты жақындастыруға, олардың өзара үн қосуына үлес қосуды көздеді. Екіншіден, әлемдік қайшылықтар мен аймақтық соғыстарға себеп болып отырған күрделі мәселелер: Ауғанстан, Таулы Қарабақ, Днестр бойы, Кавказдағы соғыстар сияқты қайшылықтар көзін шешуді мақсат тұтты. Төрағалық қызметі барысында Қазақстанның сыртқы істер министрлігі өкілдері осындай қауіпті нүктелердің барлығында болып, Еуразия кеңістігінде бейбітшілікті нақты нығайту шараларын қарастырды. Қазақстан осымен қатар, үшіншіден, әлемдік қаржылық-экономикалық дағдарыстардан шығудың жолдары мен тәсілдерін Еуразия мемлекеттеріне ұсынды. Төртіншіден, гуманитарлық, діни, мәдени салалардағы толеранттылық пен мәдениетаралық сұхбат мәселелері көтерілді.

Қазақстан өзінің көпвекторлы сыртқы саясатын тұрақты жүргізуі арқасында әлем мемлекеттерінің арасында нақты беделге ие болды. Елдің геосаяси тұрғыдағы маңыздылығы, экономикалық және сауда қатынастары тұрғысындағы тартымдылығы, шикізат ресурстары тұрғысынан

пайдалылығы оның әлемдік сауда-экономикалық қауымдастығына жылдам енуіне негіз болды. Қазақстанның бейбіт сүйгіш сыртқы саясаты әлемдегі ынтымақ, теңдік, өзара сенім атмосферасын нығайтуға үлес қоса бастады.

Ерекше атап өтуді қажет ететін мәдени саладағы өзара қатынастың екі жақты үйлесімді мәселелері, ғылыми-техникалық және мәдени ынтымақтастық мәселелер бойынша жұмыс істейтін үкіметаралық қарым-қатынас тілге тиек етілген. Шын мәнісінде, Қазақстан-Моңғолия арасындағы қарым-қатынас, екі жақ үшінде ерекше тарихи үдеріспен екшеленетін болмысқа ие екендігі белгілі. Тіпті, отандық ғылымдар аясынан тыс тарихнамадан басқа да зерттеулерге арқау болып келе жатқан бір ғана Моңғол империясының тарихын сараптауда да, дүние жүзінің тарихын жазушы зерттеушілер әлі де болса нүкте қоймаған тақырыптар қашанда екі жақты байланысты төңіректемей өтпейді. Себебі, әлі де болса екі жақтың мемлекеттілігін айқындауда және тарихи кезеңдердегі мәселелерін анықтауда да деректер маңыздылығы күшін жойған жоқ.

Кеңес Одағының ыдырауы XX ғасырдың соңғы мезгіліндегі ең ірі уақиғалардың бірі болып, жалпы халықаралық саяси жағдайдың өзгеруіне әкеліп соқты. Бұрынғы Кеңес Одағының үлкен шаңырағынан бөлініп жаңа отау көтерген дербес елдер өздерінің сыртқы саяси бағытын анықтап, стратегиясын қалыптастыруға бел буды. Жас тәуелсіз елдермен дипломатиялық қатынастар орнату, Моңғолияның да сыртқы саясатында маңызды болған. 90-жылдардың басында Моңғолия саяси, экономикалық дағдарыста болғанына қарамастан, Қазақстан сияқты және басқада мемлекеттердің үкімет, мемлекет басшыларын Моңғолияға ресми сапармен шақырған. Қазақстан да сыртқы саяси ұстанымдарына сай, 1992 жылы 22 қаңтарда Моңғолиямен Достық қатынастар мен ынтымақтастық жөніндегі шартқа қол қойып, дипломатиялық қатынастар орнатты. Аталмыш Достық қатынастар мен ынтымақтастық жөніндегі жөніндегі шарт Моңғолия мен Қазақстанның жаңа кезеңдегі қатынастарының негізі мен бағытын анықтап берген тарихи құжат болып табылады. Бұл құжаттың, сонау заманнан бері көне тарихы бар көшпенділер өркениетінің дәстүрлі құндылықтарымен қазіргі жаһанданған әлемді байытып, моңғол мен қазақ жұртының отанын гүлдендіруге жұмыла күш салып, аймақтық қауіпсіздікті нығайту, ынтымақтастықты дамытуда ықпалы өте зор. Орталық Азия мен Солтүстік-Шығыс Азиядағы аталмыш екі ел үшін мұхитқа шағу мүмкіншілігінің жоқтығы қандай қиын болса да, артықшылықтарының да бар екендігі сөзсіз. Қазақстан және Моңғолия арасында ешбір қарама-қайшылықтар жоқ, қатынастары ашық және адал. Көшпенді өркениеттің мұрагерлері ретінде аталмыш елдердің дүниежүзілік диалогты реттеу мақсатында ортақ құрлықта тұрақтылық пен қауіпсіздікті нығайту үшін ұстанымдары бар.

Қорыта айтқанда, сыртқы саяси үдерістердегі қазақ-моңғол қатынастарына жаңа серпін беретін және екі жақты байланыстың қарқынына қарқын қосатын келелі мәселелер әлі де жарқын болашақтың үлесінде екенін айта кету қажет. Себебі, әлемдік саясаттың маңызды субъектілері саналатын екі мемлекетте, халықаралық геосаяси үдерістерге айырықша стратегиямен бет бұра, оған тарихи негізде сараптама жасау, екі жақты қарым-қатынастағы «үшінші көрші саясаты» және «көршінің көршісі саясаты» қадамдары ұстанымдарында қарау, сондай-ақ Орталық Азия мен Солтүстік-Шығыс Азиядағы екі мемлекеттің де аймақтық рөлін айқындау, көшпенді өркениеттің мұрагерлері ретіндегі үндестіктегі философиялық жақындығын екі елге сай бағамдау негіз болады деу орынды», – дейді автор сөз соңында. Елбасының жүргізіп отырған сындарлы саясатының астарында шетелдегі қандас бауырларымызды бір тудың астына жинауды күні бүгінге дейін мақсат тұтып келеді.

**Әдебиет**

1. Малиновский В. Глава государства суверенного Казахстана. – Алматы: Әділет, 1998. – С. 242.

2. Назарбаев Н.Ә. Тәуелсіз мемлекеттің негізін қалаушы. – Алматы: Қазақ энциклопедиясы, 2010. – Б. 50–100.

## «МАЙТРИ СИМИТ НОМ БІТІК» ҚОЛЖАЗБАСЫ: НҰСҚАЛАРЫ МЕН ОЛАРДЫҢ ҚҰРЫЛЫМЫ

*Сыламхан Е., Л.Н.Гумилев атындағы ЕҰУ «Отырар кітапханасы» ғылыми орталығының бас ғылыми қызметкері*

Түркі халықтарының қолданған руна (сына) жазуынан кейін аса ірі аумақта, ұзақ уақыт қолданған жазулардың бірі – көне ұйғыр жазуы. Бұл жазуда сақталған әдеби-мәдени жәдігерлер өте мол, мазмұны алуан түрлі. Осы жазуда сақталған мұралардың бірі – «Майтри симит ном бітік» жәдігері. «Майтри симит ном бітік» – буддалық мінажат, уағыз кітабы. Майтри – буддистердің аңсары бойынша келешекте келетін құтқарушы, шапағатшыл Будда (Бұрхан). Симит – санскрит тіліндегі самити (samiti) сөзінен шыққан, кездесу, жолығу, қауышу, ұшырасу деген мағынаны білдіреді. Ном бітік – ном кітабі, буддалық уағыз кітабы. Тарқата айтқанда «Будда (пұт) дінінің болашақ буддасы – Майтримен жолығуды баяндайтын уағыздық мінажат кітабы» [1: 95].

Қолжазба – кіріспеден және 27 тараудан (перделен) құралған. Тілі – ежелгі түркі тілі.

1959 жылдың сәуір айында Шығыс Түркістанның Құмыл аймағындағы Темірті деген мекендегі көне пұтхананың жұртынан қой бағып жүрген қойшы «Майтри симит ном бітіктің» тағы бір нұсқасын тауып алады. Бұл нұсқа «неміс нұсқасына» қарағанда, біршама толық болып шығады. Қолжазба қоңыр түсті қатты, қалың қағазға қара сиямен

көшірілген, жалпы көлемі – 293 парақ, 586 бет. Оның 114 парағының, яғни, 228 бетінің жазуы анық әрі бүлінбеген. Тарау мен бет сандары әр парақтың алдыңғы бетінің сол жағында көрсетілген. Қолжазба ежелгі пұт дінін уағыздайтын кітаптардың үлгісінде көшірілген, ұзындығы – 44 см, ені – 22 см, беттің асты мен үстінде қара жиек сызық сызылған әрі әр жол сайын аралығы – 1,5 см жол сызығы тартылған. Әр бетте 30 жол, ішінара 31 жол жазу жазылған. Жетінші мен тоғызыншы жолдардың аралығында диаметрі 4,6 см қара түсті шеңбер сызылып, шеңбер ортасында 0,5 см жіп өткізуге арналған тесік тесілген. Тарау (перде) сайын оқиғаның болатын жері қызыл сиямен жазылған. Сол жылы (1959) тамыз айында қолжазба Шынжаң мұражайына өткізіледі. 1974 жылы Шығыс Түркістанның Қарашаһар өңірінен аталған қолжазбаның 44 беттік тохар жазуындағы нұсқасы да табылды. Қазір ол да Үрімжі қаласындағы Шынжаң мұражайында сақтаулы тұр.

«Майтри симиттің» қолжазба мәтініндегі жалпы жазу үлгісіне қарағанда үш түрлі қолтаңба анық байқалады. Ал бүлінбей сақталған қолжазбада оны екі адамның көшіріп жазғаны баяндалған. Құмыл нұсқасының оныншы тарауының 8b бетінің 10–12 жолдарында: «mn waptsun šäli bitidim (.) užik äksük boltï ärsär kim qutluγ (tïnlγ) oqïsar münämäzün kšanti bolzun – Мен тақуа ер Шәли, (бұл номды) бітірдім. Кемшілік-кателігі болып жатса, (қолжазбаны) оқыған құтты адам жазғырмасын, кешірім етсін», – деп жазылған. Қолжазбаның келесі бетінде екінші бір адамның аты аталады. Мәтін біршама бүлінгендіктен де, оның қай тарау, қайсы бет екені анықталмады. Онда: «bars yïl ikinti ay yiti otuzqa mn tuγ tsupa äkä bitiyü tägintim – Барыс жылы екінші айдың жиырма жетісінде, мен Тұғ Тсұпа аға жазып тамамдадым», – деп көрсетілген».

Демек «Майтри симит ном бітік» уағыз кітабының құмыл нұсқасын көшіріп жазғандар: «Буддалық жолды берік ұстанған, білімдар тақуа ер Шәли мен сыйлы ел ағасы, оқымысты Тұғ Тсұпа аға», – деуге болады. Ендеше, көшіріп жазғандар белгілі болса, кім үшін, не үшін көшірілген? Бұл сұрақтың жауабы да дайын. Буддалық мінәжат ном кітабін жаздырған адам – Чұұ Тас игән тұтық. Қолжазбаның кіріспе бөлімінің алғашқы бетінде ол туралы:

1. ymä alqatmïš ayqa kösänčig künkä
2. ödrülmiš ädgü ödkä qutlu□ q(ï)wlï□ qoluqa
3. qutlu□ qoyn yïl ziin üčünč ay
4. iki otuzqa mn üč ärdinigä kirt-
5. günč köngüllüg upasi (čuu) taš ygän
6. tutuq kišim tüzün birlä kin kältä-
7. či maitri burxan-qa tušalïm tip
8. bir maitri süö bäzätdimiz bir

9. maitrisimit nomïn ymä

10. bititdimiz (Бұл арада тек Құмыл немесе неміс нұсқасы туралы ғана сөз болып отырған жоқ, жалпы қолжазбаның ең алғашқы аударылымының мерзімі туралы пікір қозғалып отыр).

Қазақша аудармасы: «Және алқаулы айда, армандағы күнде, ерекше кезде, құтты уақытта, құтты қой жылы үшінші айдың жиырма екісінде, мен – (Будданың) үш асылға сенетін, опалы көңілді тақуа ер Чұұ Тас игән тұтық, әйелім Түзүнмен бірге келешек Майтри бұрханға кездесейін деп, бір Майтри бейнесін жасаттық, Майтри симит номын жаздырдық» деген мәлімет берілген» [2].

Қолжазбаның көп жерінде аталып отыратын бұл адамның, біріншіден, буддалық жолды мықтап ұстанған діншіл тақуа, адал адам екенін, екіншіден, қолында құқығы бар ықпалды кісі болғанын, үшіншіден, Майтри бұрхан жолына арнап уағыз кітапті жаздырғанын аңғарамыз. Қытай ғалымы Гың Шымин бұл адамның тегі туралы: «Идіқұт хандығына (850-1250 жж) қарасты бір қаланың тұтығы (бегі) әрі осы хандықты билеген Чүй (qu) тектілердің ұрпағы болуы мүмкін», – деген жорамал айтады. Бұндағы «Чұұ» сөзі әулет тегі болуы мүмкін. «Тас игән» – оның лақап аты, ал Тас иген – тасты идірген, яғни, шапағатшыл, мейірімді, құтты немесе баяшатты, мамыржай, бейбіт тірлік иесі (Самарқанның көк тасы еритін күн)», – деген ұғымды білдіреді деп түсінуге болады [1].

«Тұтық» сөзінің төркіні қытай тіліндегі «дуду» (du du) деген сөзден шыққан. Бұл аймақтық әкімшіліктің бас билеушісі, бас биі мағынасын білдіреді. Демек, Тас игән тұтықты – шапағатшыл, мейірімді, құт иесі немесе бейбіт тірлікке жеткізуші бас би деп жорамалдауға болады [3].

Аудармашының кім екендігі, қайда туғандығы мәтінде анық көрсетілген. Түркі тіліне аударылған нұсқасында оның сахналық сипаты өзгеріске ұшыраған. Онда оқиға болған жер, кейіпкерлер және олардың диалогтары мен монологтары – оқиға желісіне кіріктіріле баяндалған, оған қоса аудармашы мен уағыз кітабін жаздырған адамның (Чұұ Тас игән тұтық) хал-жағдайынан хабар беретін үзінділер мен кіріспе тарау тыңнан қосылған.

Демек, буддалық үнді аңызын өзек еткен сахналық туындыны нәзиралық жолмен жаңғыртып, оқиғалы шығарма ретінде түркі тілінде қайта баяндаған. Бұл қолжазба түркітанулық лингвистика, археология, фольклор, әдебиет, дінтану салалары тұрғысынан толық талдауды қажет етін қолжазба.

**Әдебиет**

1. Қайыркен Т.З. Майтри симит және оның тілдік ерекшеліктері туралы. Шынжаң ғылыми мақалалар жинағы. – Үрімжі, 1991. – №1. – Б. 95–104.

2. Сыламхан Е. .Қазақ қолжазбалары. – Алматы: Ел-шежіре, 2012. – Т. 5. – 384 б.

3. Сыламхан Е. Қазақ қолжазбалары.– Алматы: Ел-шежіре, 2012. – Т. 6. – 416 б.

# МӘКАЛЬЛӘРДӘ «ГАИЛӘ» КОНЦЕПТЫ

*Тимерханова И., Казан, 121 нче лицей, XI сыйныф*
*Җит. – Валиуллина Р.Х, Миннегалиева А.И.*

Татарларда борын заманнан ук мәкаль һәм әйтемнәрнең кадере аеруча зур. Халык авыз иҗатының әлеге төре сөйләм телендә ныклы урын тота. Мәкаль һәм әйтемнәр кыска һәм җыйнак булулары, әмма шул ук вакытта мәгънәләренең тирәнлеге һәм киңлеге белән таң калдыралар. Алар халыкчанлыгы һәм хәтергә нык сеңеп калулары белән үзенчәлекле.

Мәкаль үзенең конкрет мәгънәсен һәм конкрет кулланылышын сөйләмдә таба. Күренекле фольклор белгече Н. Исәнбәт мәкальне: «Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәре», – дип билгели. Шуңа нигезләнеп, татар халык мәкальләрендә “гаилә” концептының чагылышын тикшерү өчен без әлеге тематикага караган күпсанлы мәкальләргә мөрәҗәгать иттек.

Иң беренче чиратта, шуны билгеләп үтәргә кирәк: гаилә темасына багышланган мәкальләр арасында нәкъ менә гаилә төшенчәсе, гаилә сүзе кергәннәре дә бар, әмма алар сирәк очрый: Гаилә – бәхет ачкычы; Кош оясыз булмый, кеше семьясыз булмый; Тату гаиләнең бишеге буш булмый; Тату гаиләдә җаның ял итә [5: 371–373].

Гаилә компоненты булган әлеге мисаллардан без татар халкының гаиләне ни дәрәҗәдә зурлап, хөрмәтләп күрсәтүен, кеше өчен иң югары кыйммәтләр рәтенә кертүен күрәбез. “Гаилә – бәхет ачкычы”, ягъни бәхетле тормышның башлангычы, аерылгысыз элементы буларак күзаллана. Шуңа күрә, мәкальләрдә “кеше семьясыз булмый”, “тиле генә семья кормас” дигән фикерләр дә урын ала. Димәк, әлеге мәкальләрдә җирдәге һәммә кеше дә бәхетле гомер кичерү, үз тормышына ямь кертү өчен гаилә корырга, гаиләле булырга тиеш дигән фикер салына.

Гаилә компонентын үзәккә алган бериш мәкальләрдә “гаиләне нигезе нәрсәдә?” дигән сорауга җавап эзләнә. “Мәхәббәтсез гаилә – тамырсыз агач” мәкалендә гаиләнең нигез ташы – сөю, мәхәббәт, бер-береңне ярату диелсә, “Тән сихәте – хәрәкәт, гаилә бәхете – бәрәкәт” мәкалендә гаилә бәхете, нигезе – бәрәкәт диелә, “Кош – канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле”, “Тату гаиләнең бишеге буш булмый”, “Тату гаиләдә җаның ял итә” кебек мәкальләрдә исә татулык, дуслык, аңлашып-килешеп яшәү иң беренче урынга чыга; бердәм, тату, тыныч-имин тормыш итү гаиләнең нигезе, тереклек көче итеп карала. Димәк, мисаллардан күренгәнчә, халкыбыз мәхәббәт, бәрәкәт һәм татулыкны гаиләнең нигезе итеп саный.

Күпчелек очракта, мәкальләрдә гаилә кору өйләнү, йортлы булу, оя кору, тормышлану синонимы белән, яки алу (хатын алу), бару (кияүгә бару) сүзтезмәсе белән алыштырып кулланыла: Өйләнү – сөйләнү генә түгел; Өйләнү – базарга чыгып, ат алып кайту гына түгел; Тормышланган-төпләнгән [5: 374].

Мисаллардан күренгәнчә, гаилә төзү бик тә четерекле, мәшәкатьле, зур игътибарлылык таләп итә торган гамәл, бик тә җаваплы, төпле адым буларак бирелә. Ләкин шул ук вакытта үз тиңең белән парлашып, гаилә корып яшәү кешенең үзе өчен саваплы, изге адым дигән фикер дә очрый (“Өйләнү – җаныңа җавап, башыңа – савап”), хәтта “Аллаһ юнь бирә” дигән гыйбарә белән беркетелеп тә куела дип әйтергә мөмкин. Бу очракта, әлбәттә, ислам динендә гаилә хакында карашлар, гаиләнең урыны, абруе, кадер-хөрмәте дә зур роль уйный.

Татар халык мәкальләрендә гаилә корырга тормыш иптәше, тиң, насыйп яр табу аеруча катлаулы эш буларак чагылыш таба: Алган ярың – җаның; Иргә бармый өйле булмассың һ. б. [5: 371–373].

Димәк, татарлар, ныклы гаилә кору өчен, булачак тормыш иптәшен сайлауны аеруча нәзбереклек белән, бик сайланып, гореф-гадәтләренә туры китереп, сынап карау аша гына башкарган дип әйтергә урын бар.

Гаилә турындагы мәкальләр арасында өйләнмәү, ялгыз тормыш итү турында мәкальләр дә байтак: Ир өйләнми тәүфыйкъ алмый; Өйләнмәгән кеше – ярты кеше; Өйләнмәгән өйсез булыр, тормышы көйсез булыр һ.б. [5: 371–374].

Әлеге мисаллардан без өйләнмәү, гаилә кормыйча, ялгыз яшәү, буйдак тормышы алып бару, киресенчә, бик нык тәнкыйтьләнүен, хәтта кимчелекле сыйфат (“Өйләнмәгән кеше – ярты кеше”, “Өйләнмәгән үчәр”, “Өйләнми картайганнан акыл сорама” һ.б.) дәрәҗәсенә дә кертелеп каралуына төшенәбез.

Мисаллардан түбәндәге фикер алга чыга: татар халкы, киленгә караганда, кияүне күбрәк якын күрә, үз итә. Кияүне кадерләп – хөрмәтләп, сыйлап тоту ягын карый.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

2. Синонимнар сүзлеге / Ш.С. Ханбикова, Ф.С. Сафиуллина – Казан: Хәтер, 1999. – 263 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / И.А. Абдуллин, С.Б. Вахитова, Ф.С. Садриева һ.б. 3 томда. Т. 3. – Казан:, 1981. – Б. 254.

4. Татар теленең фразеологик сүзлеге / Н.Исәнбәт. 2 томда. Т. 1. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1989. – 495 б.

5. Татар халык иҗаты. Мәкальләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 371–375.

# ФОАТ ГАЛИМУЛЛИННЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫ

*Тимофеева Т., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Габидуллина Ф.И.*

Матур әдәбиятны тәнкыйтьтән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Әдәби әсәргә һәм анда чагылган тормыш күренешләренә, язучылар иҗатына бәя бирү, әдәби әсәрнең чынбарлык белән бәйләнешен өйрәнү, аның идея-эстетик кыйммәтен ачыклау белән нәкъ менә әдәби тәнкыйтьчеләребез шөгыльләнә. Татар әдәбияты тәнкыйте үсешенә зур өлеш кертүче галимнәребезнең берсе – Фоат Галимуллин. Ул – күп кенә дәрәҗәле исемнәргә лаек булган җәмәгать эшлеклесе: Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди исемендәге бүләк иясе, Халыкара төрки академиясенең хакыйкый әгъзасы (академигы), филология фәннәре докторы, профессор. Әлеге исемлекне чиксез дәвам итәргә мөмкин, чөнки Ф. Галимуллин – күпкырлы талант иясе, кайсы гына өлкәне алма, бар яктан да югары нәтиҗәләргә ирешкән шәхес.

“Күңелендә әдәбиятка мәхәббәт булмаган, үзе иҗат каләме тотып карамаган кеше тәнкыйтькә дә килә алмыйдыр, мөгаен. Мин үземнең әдәбияттагы урынымны тәнкыйтьтә таптым. Казан дәүләт педагогия институтында укыганда һәм эшләгәндә, әдәбият фәнен нигезләгән Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, М. Мамин, Б. Яфаров, М. Гайнуллин, Х. Госман һәм башкаларның хезмәтләре белән танышу иҗатның шушы өлкәсенә хөрмәт уятты һәм кызыксыну тудырды” [3: 166], – дип яза Ф. Галимуллин үзе турында.

Аның тарафыннан язылган фәнни-тәнкыйди хезмәтләр шактый. Тәнкыйть мәкаләләренең күпчелеге “Инешләр Иделгә кушыла” (Казан, 1985), “Офыкларны алдан күреп” (Казан, 1995), “Эзләнү вакыты” (Казан, 2005) дигән китапларга тупланган. Әлеге мәкаләбездә без әдипнең “Эзләнү вакыты” китабында дөнья күргән, Гаяз Исхакый иҗатына багышлап язылган “Әдәби осталыкка килү юлында” мәкаләсенә тукталып үтәрбез.

Гаяз Исхакый (1878–1954) – гомерен милләткә хезмәт итүгә багышлаган, татар реалистик әдәбиятына нигез салган классик әдип, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы. Ул – “иҗатында бернинди дә методларга буйсынмаган, шуна күрә сурәтләү өчен тормыш материалларын сайлауда, өслүп куллануда ирекле эш иткән” [2: 161] язучы, “эчтәлекнең сурәтләү рәвешенә тәңгәл килүен булдыруда чын-чынлап новатор” [2: 161]. Ф. Галимуллин аның әдәбиятка алып килгән бер яңалыгын – “геройсыз” әсәр язу үрнәгендә, ә каләменең үзенчәлеге үзәк образларның гомумиләштерү үзенчәлегенә ия булуларында күрә. Мисал итеп тәнкыйтьче язучының берничә әсәрен анализлап уза. Мәсәлән, ул “Ике йөз елдан соң

инкыйраз” (1902) повестенда авторның игътибары аерым кешегә түгел, ә тулаем милләткә юнәлдерелә, ә Фәхри белән Шаһимөхәммәт байлар гомумиләштерелгән исемнәр булып кабул ителәләр дип саный. Ф. Галимуллин фикеренчә, акча түгүләр турында әйтелгән “курчак уены” да нәкъ менә “болгар халкының бөтен тормышы “курчак уены” дип аталырга тиешлегенә ишарә итә” [2: 162]. Әсәрдәге Җәгъфәр образы да гомумилеккә ия. Ул – юкка чыгу чигендә торган татар халкын җанландыручы, автор күтәргән мәсьәләнең әһәмиятен тагын да көчәйтүче образ.

Алга таба тәнкыйтьче Г. Исхакыйның “Тормышмы бу?” (1909) әсәренең төп герое – Шәкерт образына мөрәҗәгать итә. Шәкертнең исемсез булуы ук аның гомумилегенә ишарә булып тора дип саный тәнкыйтьче. Шәкерт – мулла малае, шуңа күрә аңа киләчәктә кем булачагы, ничек итеп тормыш алып барачагы турында баш ватасы юк. Мәхдүмгә яшьтәшләре белән уйнарга да, авыл кызлары белән аралашырга да ярамый, чөнки алар аңа тиң түгел дип санала. Шуңа бәйле рәвештә, аның күңелендә үзен чолгап алган тирәлеккә ризасызлык туа. Г. Исхакый исә үзенең әсәрендә шул күңел каршылыгын, эчке характердагы конфликтны сурәтли. Каршылыкның беренче катламы кызлар белән бәйләнгән. Шәкертнең дә башкалар кебек сөеләсе, яратасы, кызлар белән дуслашасы, шаярасы килә. Әмма ул кеше теленә керүдән, ата-анасының сүзеннән курка. Ә конфликтның икенче катламы исә белем алу белән бәйле. Шәкерт дөньяви фәннәр белән кызыксына, төрле тарихи, фәнни китаплар укырга ярата, иске тәртипләр буенча укыта торган мәдрәсәләргә каршы чыга. Ф. Галимуллин Шәкерт образының яңалыгын шушында күрә: “Тормышта да шундый кешеләр була, ул дөрес уйлый, күңеле белән әллә ниләр эшләргә әзер, хыялларының иге-чиге юк. Әмма шул ниятләрен чынбарлык итү өчен гамәленә керешә алмый” [2: 167]. Шәкертнең “Уян, күңел, уян! Уян, баш, уян!” дигән сүзләре дә бит татар халкына мөрәҗәгать итеп әйтелгән. Г. Исхакый шушы әсәре белән язмышына битараф булган кешеләрне тәнкыйтьли, чөнки андый кеше милләтне кайгырта алмый, ә бу үз чиратында аның юкка чыгуына китерә.

“Бай углы” (1903) романында исә Г. Исхакый бер үк катлам вәкилләре арасында әхлаклылар да, әхлаксызлар да барлыгын күрсәтә һәм моны тәрбия белән бәйләп аңлата. Фатыйх бай белән Сәгыйдә бикә улларына тиешенчә тәрбия бирә алмау нәтиҗәсендә, Кәрим дөнья белән бик яшьли хушлаша. Ә менә Кәримнең хатыны Бәдрия, әдәпле, динле, укырга-язарга өйрәнгән хатын, баласы Рифгатьне дә дөрес тәрбияли, укыта, дин танырга өйрәтә. Нәтиҗәдә ул байлык туплый, үзе кебек әдәпле, укымышлы, чибәр кызга өйләнә. Ф. Галимуллинның Г. Исхакый шәхесенә, иҗатына мөнәсәбәте шундый: үзенең тирән мәгънәле әсәрләре белән Г. Исхакый “халкыбызны белемле, инсафлы, эш рәтен белүче, таза нигезгә

корылган тормышлы итеп күрергә тели” [2: 175].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Фоат Галимуллин – әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен белүче, үзенең фикерен төгәл һәм нигезле итеп җиткерә алучы, дөрес һәм гадел бәя бирүче тәнкыйтьче. Югарыда искәрткәнебезчә, Фоат Галимуллинның әдәбиятыбыз һәм милли мәдәниятебез хакында язылган мәкалә-хезмәтләре шактый күп. Ул мәгарифне һәм мәдәниятне үстерү, туган телнең даирәсен киңәйтү өстендә бик күп еллар буе зур эшләр башкарды һәм хәзер дә әлеге эшчәнлеген дәвам итә. Ф. Галимуллинның татар әдәби тәнкыйди эшчәнлеге алга таба да этрәфле өйрәнелер дигән теләктә калабыз.

**Әдәбият**

1. Галимуллин Ф.Г. Бәләкәй Фоат // Казан утлары. – 2018. – №8. – Б. 174-184.
2. Галимуллин Ф.Г. Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.
3. Даутов Р. Балачак эдипләре: биографик белешмәлек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 253 б.
4. Миңнегулов Х.Й. Иҗади гамәлле шәхесләр: мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 286 б.

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЫҢ «БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ» ПОВЕСТЕНДӘ ҺӘМ АНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕНДӘ РЕАЛИЯЛӘРНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

*Тукаева Э., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нәбиуллина Г.Ә.*

Реалияләр – чыганак текстның милли колоритын, үзенчәлекләрен аңлата торган берәмлекләре. Реалияләрне тәрҗемә иткәндә, кайбер кыенлыклар белән очрашырга туры килә: тәрҗемә ителә торган телдә тәңгәл килгән сүз, эквивалент, аналог булмавы; реалиянең мәгънәсе (семантикасы) белән беррәттән, колоритын, милли һәм тарихи үзенчәлеген бирү зарурлыгы. Реалияләр – һәрвакыт табигый рәвештә халыкның милли карашы һәм көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән сүзләр. Реалияләрне өйрәнү өлкәсендә тикшеренү алып барган рус галимнәре реалияләрне эквивалентсыз лексика, варваризм, энографизм дип атаганнар, тиңдәшсез сүзләр рәтенә керткәннәр.

Этномәдәни берәмлекләрне тәрҗемә итү милли һәм тарихи үзенчәлекләрне бирү процессында туган авырлыкларның зур өлешен алып тора. Этник колоритны чагылдыра торган сүзләр буларак, реалияләр илленче елларда бик күп галимнәр тарафыннан өйрәнелә башлаган.

Тәрҗемә белгечләре реалияләрне төркемләүнең төрле юлларын тәкъдим итәләр. И.С. Алексеева үзенең “Введение в переводоведение” китабында реалияләр классификациясен өч төрлегә бүлә:

1. Географик реалияләр: а) физик география терминнары: прерия, саванна; б) эндемика (билгеле бер урынга гына хас хайван, кош-корт, үсемлек төрләре) терминнары: баобаб, кенгуру.

2. Этнографик реалияләр: а) кием-салым: кимоно; б) корылмалар һәм көнкүреш җиһазлары: сауна; в) милли эшчәнлек төрләре: икебана, скоморох; г) йолалар, ырымнар, уеннар: вендетта, тамада; д) мифология һәм культлар: тролль, синагога; е) үлчәү һәм акча берәмлекләре: аршин.

3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр: кантон, большевиклар. Билгеле бер халыкка һәм илгә генә хас иҗтимагый тормыш һәм материаль көнкүреш реалияләрен белдерә торган сүзләрне бер телдән икенче телгә дөрес итеп күчерүнең төп шарты – ул реалияләрнең үзләрен яхшы белү [1: 181].

Без Мөхәммәт Мәһдиевнең "Без – кырык беренче ел балалары" повестендә һәм аның Рәшит Ахунов тарафыннан рус теленә тәрҗемәсендәге реалияләрне И.С. Алексеева классификациясе буенча тикшердек, чагыштырдык.

1. Географик реалияләр: а) физик география терминнары: *"**Мөрәле** малае Әлтафи" – "Альтафи, который из **Муралей**".*

б) эндемика: *"Дөньны кояш баскан, дөньяны кояшта җылынган кычыткан, алабута, **мәче борчагы** исе баскан". – "Весь мир залит солнцем, напоен запахами млеющей на свету крапивы, лебеды, **мышиного горошка**" .*

2. Этнографик реалияләр: а) кием-салым: "*Сипкелле яңагын зәңгәр **бишмәтенең** сап-сары мех якасына яшерде" – "Он даже лицо свое веснушчатое в воротник запрятал – хороший воротник, меховой, тяжелый, а **бешмет** синий, тоже красивый".*

б) корылмалар һәм көнкүреш җиһазлары: *"Бәхәс инде шахмат тактасы яныннан **сандык** тирәсенә күчкән иде*" – *"Спор идет уже не за шахматной доской, а у давешнего **сундука**".*

в) мифология һәм культлар: *"Шуның өстенә укытучысы – нечкә аяклы,чандыр яңаклы, **шүрәле** бармагыдай нәзек озын бармаклы ир" – "...тонконожка, щечки впалые, губы красные, пальцы длинные, как у **Шурале**".*

г) үлчәү һәм акча берәмлекләре: *"Зарифуллинның әнисе хезмәт көненә **пот ярым** борчак алган" – "Мать Зарифуллина на трудодни получала пуд и ещё **полпуда** гороху". "... нибары бер бөтен ипи һәм бер **кадак** шикәр булган" – "...всего-навсего цельный каравай хлеба и **фунт** сахару, на большее у него, у бедняги, денег не хватало".*

3. Иҗтимагый-сәяси реалияләр: *"Элекке заманда бу йорт зур **алпавытның** дачасы будган" – "Раньше, в царские времена еще, дом этот был дачей одного крупного **помещика**".*

Реалияләрне чагыштыруның икенче аспекты – ул тәрҗемә итү юлларыннан чыгып, оригиналдагы һәм тәрҗемә текстындагы реалияләрне чагыштыру. Билгеле булганча, А.В. Фёдоров реалияләрне тәрҗемә итүнең өч юлын күрсәткән. Без шуларның һәркайсын аерым карадык, чагыштырдык, анализладык.

1. Тулы яки өлешчә транслитерация. Бу очракта реалия исеме турыдан-туры алына яки аның тамыры тәрҗемә теле аффикслары белән бергә кулланыла. *“Мөрәле **малайларының** чәч төпләренә хәтле кызарган башларыннан пар күтәрелә” – “У муралинских **малаев**, догадавшихся все же стянуть шапки, лица были распаренно-красные”*.

2. Реалияне белдерү өчен, тәрҗемә теле элементлары һәм морфологик үзенчәлекләр җирлегендә яңа сүз ясау ысулы сирәк кулланыла, әмма аларны да карап үттек: *“Ә җәйнең матур көнендә озын **арба** җигеп колхоз фермасына юкә миллеге ташу?!” – “Ну ладно, а как здорово на длинных **арбах** возить на колхозную ферму долгие связки лыка”*.

3. Функциясе буенча чит тел реалиясенә якын торган әйбер яисә төшенчәне белдергән сүздән файдалану ысулы да шулай ук сирәк очрый: ***“Шайтан** белсен!” – “А **черт** его знает”*.

Димәк, татар теленнән рус теленә реалияләрнең бирелешен, аларның үзенчәлекләрен Мөхәммәт Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары” повесте һәм аның Р. Ахунов тарафыннан тәрҗемәсе мисалында өйрәнгәндә, шул ачыкланды: этномәдәни берәмлекләрне тәрҗемәдә биргәндә күп очракта транслитерация яки транскрипция, тасвирлаулы тәрҗемә ысулы кулланыла яисә реалияләр бөтенләй төшереп калдырыла.

**Әдәбият**

1. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений. – СПб.: СПбГУ; М.: Академия, 2004. – С. 181.

2. Мәһдиев М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – 271 б.

3. Мы дети сорок первого года. Повесть / Пер. с татар. Р. Ахунов. – М.: Детская литература, 1981. – 143 с.

4. Нәбиуллина Г.Ә., Мөгътәсимова Г.Р. Тәрҗемә практикасы: әдәби һәм фольклор тәрҗемәләре. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы. - Казань: Ихлас, 2012. – Б. 91.

5. Юсупов Р.А. Тәрҗемәнең теоретик һәм практик мәсьәләләре. – Казан: ТДГПУ, 2001. – Б. 312.

## ШӘКӘРІМ ШЫҒАРМАШЫЛЫҒЫНДАҒЫ АУДАРМА МӘСЕЛЕСІ

*Турсынханова К., Қазақ инновациялық гуманитарлық-заң университеті, PhD докторант*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. док., проф. Еспенбетов А.С.*

Шәкәрім Құдайбердіұлы – қазақ әдебиетін жаңа белеске көтерген, қазақ халқының көркемдік ойының үздік үлгілерін туғызған қаламы жүйрік жазушы, заманы мен халқы жөнінде ой толғанған тарихшы, ойшыл философ, аудармашы, сазгер.

«Адам үшін еңбегім,
Өмірден барлық тергенім.
Қалағаның қарап ал,

Мұрам сол,жастар,бергенім», – деп тұжырымдай жырға қосқан Шәкәрім бүгін жарқын бейнесімен де жалынды жырымен де бізбен бірге жасасып келеді.

Шәкәрім тек қазақ әдебиеті тарихында емес, бүкіл қазақ халқының тарихындағы үлкен де ерен құбылыс.

Шәкәрім шығармашылығын алғашқы зерттеушілердің бірі, оның әдемі көркем мұрасын жоғары бағалаған ғалым Ш.Сәтбаева: «Шәкәрім Құдайбердиевтің мол мұрасының бір қыры – қазақ ұлт мәдениетінің, әдебиетінің басқа халықтар қазынасымен дәстүрді творчестволық байланысын дамытуы, байытуы. Бұл дамыту мен байыту қазақ ұлт әдебиетінде көркем аударманың және әлемдік маңыз алған туындылар үлгілерін, жекелеген образдардың бейнелі тіркестерін шығармаларында шебер қолдану, ойлау, жүйеге енгізу арқылы іске асты. Ол көптеген халықтардың ғасырлар бойы жинаған рухани қазыналарына еркін бойлап, терең игере білуі нәтижесінде бірсыпыра туындыларды қазақша аударып, халық игілігіне айналдырған. Шәкәрімнің көркем аударма ұстанымдары мен жүйесінің өзі – үлкен тәжірибе, тағылым, үлгі. Шығыс пен Батыс елдері әдебиетінің кейбір үлгілерін қазақ тіліне шебер аударды», – дейді [1: 12]. Бұл да Шәкәрім даралығының бір айғағы.

Шәкәрім өмірінің есею жылдарында қалыптасқан қасиеттерінің бірі – өз бетімен білімін өрісін кеңейтуі, бірнеше тілдерді араб, парсы, түрік, орыс тілдерін меңгеріп, қазына қорына еркін бойлап, осы тілдердегі шығармалардың кейбірін қазақ тіліне аударуы. Шәкәрімнің шығыс, батыс және орыс классиктерінің шығармаларын ана тілінде сөйлеткені бәрімізге белгілі. Лев Толстойдың шығармаларын аса жоғары бағалап, өз халқын дүние жүзілік озат мәдениетін игеруге шақырды. Американ жазушысы Гарриет Бичер-Стоунның «Том ағайдың балағаны» романын, Толстойдың «Үш сауал», т.б. әңгімелерін, А.С. Пушкиннің «Боран», «Дубровский» повестерін қазақ тіліне аударды. Шығыс әдебиетінен Хафиз, Фирдоуси, Науаи, Сағди шығармаларын аударды.

Араб, парсы, шағатай тілдерін жүйрік білген Шәкәрім үшін Шығыс шайырларына бойлап бару қиынға соқпаған сияқты. Қажы атамыз сол шығыс тілдерінде өлең де жазған. Шәкәрімнің өлеңдерін баспаға дайындаған жазушы М. Мағауин Хафиз бен Шәкәрімнің шығармашылық байланысына тоқталып, «Шәкәрімнің шығыс үлгісіндегі мұрасы сол тұстағы қазақ поэзиясының ізденіс өрісі, игерген аумағы туралы нақты түсінік берсе керек. Шәкәрімнің шығыстық жырлары көркемдік ойдың жаңа бір белесі болды. Мұндағы өрнек, иірімді жан толқынысы, үлгілі тіл мәдениеті-ұлттық поэзиямыздың Абай жеткізген ең биік тұғырымен деңгейлес» деп атақты ақынның шығыс ықпалында да өлеңдер жазғанын баса көрсетеді.

Шәкәрім Хафизден алған аудармаларына «Қожа Хафиз сөзінен» деп бір тақырып берген. Атап айтқанда «Кешегі басшы піріміз», «Ей жарымыз, ай нұры», «Көрініске шоқынған», « Қараңғы толқын қанды оқпын», «Кел, аяқшы, қымыз құй», «Тұр, аяқшы, бер қымыз», «Көңіл жібі қолымнан», «Анық ерге жолдас бол», «Егер сүйікті ол бала», «Мәжілісінде досыңның» деп аталады. Жиын саны он өлеңге барады. Хафизге неліктен бас бұрғанын Шәкәрім 1918 жылы «Абай» журналының үшінші санында басылған «Көрініске шоқынған» аудармасына кіріспесінде былай деген екен: «Баяғыда парсы жұртында әрі білгіш, әрі сопы, әрі ақын Қожа Хафиз деген кісі болған. Сол кісінің өзі мен сөзінен байқалған иманына қазақтың талантты жастарын таныс қылмақ үшін, төмендегі жырын қазақ тіліне аудардым», – дейді. Бұдан бұрын мына бір шумақта:

Науаи, Сағди, Шамси,Физули бар,
Сайқали, Қожа Хафиз, Фирдоусилар...
Бәйітше елден асқан шешен болып,
Әлемге сөздің нұрын жайған солар» – ақынның айтып кеткен ойы байқалады [2: 75].

Ақын Хафиз шығармаларын анағұрлым жатық тілмен аударған. Әрі өз отандастарының түсінігіне лайықтап, аздап әрлеп, өзгертіп, негізінен түпнұсқадан алшақтамау принципін ұстана отырып аударған. Яғни өз туындыларын қазақы өлеңнің қалыбына салып, таза ұлттық пішіндегі төл тума шығармаға айналдырған. Шәкәрім аудармалары ұлттық таным-түсінікке қабысатындай ұғымдылығымен ерекшеленеді. Ол қабылдаушының ұлттық ерекшелігін ескерген. Сонымен бірге эстетикалық қуаттың поэзиялық тұрғыдан төрт аяғын тең басқан көркем болуын назарда ұстаған.

Шығыс әдебиеті мен қазақ әдебиетінің сан қырлы байланысын ұзақ уақыттан бері табан аудармай зерттеп жүрген ғалым – Өтеген Күмісбаев. Өз зерттеулерінде Ө. Күмісбаев Фердоусидің әйгілі «Шаһнама» дастанының қазақ топырағында танылып, тәржімалану тарихы, Низами, Науаи, Сағди дастандарының ықпалындағы нәзирагөйлік дәстүрін сөз етеді. Зерттеуші «Хафиз, Абай және Шәкәрім» деген мақаласында Хафиз ғазалдарының ата жұртымызда насихатталуы, тәржімалануы туралы айтады. Автор Шәкәрім аудармасы жайында әңгімелей келіп: «Әлбетте Шәкәрім тұсында аударма теориясы қазақ үшін қалыптаспаған еді, тосын нәрсе еді, жолма-жол, тікелей аударманың тумаған кезі еді. Неміс классигі Гете Шығыстың бұлбұлы Хафизбен қалай жарысып еді, Шәкәрім сол үлгіні қалады. Ақын негізгі мазмұнын сақтап, Хафиз ғазалының рухын, тынысын бере білді», – деп түйеді [3: 4].

Ақынның аударма саласындағы туындылары жайында бірсыпыра пікірлер айтылды. Атап айтқанда, белгілі ғалым Ш. Сәтбаеваның «Шәкәрім Құдайбердиев» монографиясында ақынның аудармалары

туралы жалпы танымдық мағлұматтар берілсе, Ө. Күмісбаевтың «Терең тамырлар», «Казахские и персидско-арабские литературные связи XIX–XX вв.» монографияларында, А. Қыраубаеваның «Шығыстық қисса-дастандар» кітабы мен жекелеген мақалаларында, Б. Әбдіғазиұлының «Шәкәрім шығармашылығының дәстүрлік және көркемдік негіздері» монографиясында, И. Жеменейдің «Хафиз және қазақ әдебиеті» оқу құралдарында Шәкәрімнің шығыс-батыспен байланысының бірқатар мәселелері қарастырылған. Шәкәрімнің көркем аударма өнеріндегі атқарған ісі жөнінде бірталай еңбектер атқарылды десек те, алдағы уақытта толығырақ қаралатын мәселелер әлде де өз кезегін күтуде.

Әлем халықтарының көркемдік құндылықтарының үндесуі мен байланысуы ұлттық тілдерге үздік шығармаларының аударылуы арқылы үнемі жүріп жатады. Әдебиет классиктерінің туындыларын ұлттық тілге аудару ұлы ғұлама шығармашылығының елеулі бір саласы болды. Шәкәрім Орыс, Шығыс, Батыс әдебиетінің тамаша үлгілерін қазақ оқырмандарына таныстырды. Қазақ оқырмандарының кітапханасы Шәкәрім шығармашалығымен қатар аударма әдебиетпен де көп молықты.

**Әдебиет**

1. Әубәкір Ж. Шәкәрім Құдайбердіұлы (Библиографиялық көрсеткіш) –Семей, 2009. – Б. 75.
2. Жеменей И. Хафиз-Шәкәрім рухани үндестігі. –Алматы, 2008. – Б. 75.
3. Құдайбердиев Ш. Шығармалары. Өлеңдер, дастандар, қара сөздер.– Алматы: Жазушы, 1988. – 75 б.
4. Күмісбаев Ө. Егемен. – Қазақстан, 2008. – № 10. – Б. 4.
5. Сәтпаева Ш. Шәкәрім Құдайбердиев. – Алматы, 1991. – Б. 12-26.

## МАҚАЛ-МӘТЕЛДЕРДІҢ ЭТНОМӘДЕНИ СИПАТЫ

*Тұяқбаева Ж., М. Қозыбаев атындағы Солтүстік Қазақстан мемлекеттік университеті, II курс студенті*
*Ғыл. жет. – ғылым магистрі, аға оқытушы Синбаева Г.К.*

Қазақ халқы ерте заманнан бері қолөнер кәсібін жетік меңгеріп, тоқымашылық, зергерлік, етікшілік, ұсталық кәсіпті жақсы дамытқан. Қалың бұқара ішінде ежелден «он саусағынан өнер тамған» адамдар өте қадірлі болған. Халық арасында үлкен беделге, сый-құрметке ие жандар болған. Сондықтан болар, *өнерлі адам ешқашанда өлмейді* деген дана сөз қалыптасқан.

Жиде ағаштарынан, әдетте, сұйықтық алынады. Бұл ағаштың сұйықтығын алып, оны кептіріп, қатырып алған соң жыл бойы керек кезінде жібітіп, шашқа жағады. Мұны ел ішінде «желім» деп атайды. Қыз-келіншектерінің шашына жағатын бұл желімінің қасиеті – шашты табиғи азықтандырады, шаштың ағару, түсу және оған қайызғақ түсірмеу, сондай-ақ шаштың тозып кету құбылыстарының алдын алады. Бағзы замандарда бұл сұйықтық қазіргі дәуірдегі лак, гельдің қызметін атқарған. Күні бүгінге дейін шашы ұзын қыз-келіншектер бұл затты әлі қолданады. Осыған орай

ел аузында мысқыл, әжуа ретінде айтылған *«Тазға тарақ берсең, шашына желім тілейді»* деген нақыл пайда болған.

Қарап отырсаңыздар, аз ғана сөзге не болмаса бір, бірер сөйлемге қаншама дерек сыйыстырылған. Аз сөзбен көп жайды аңғартатын мақал-мәтелдер бүкіл этностың болмысын көз алдыңа елестете алады екен.

«*Бір құмалақ бір қарын майды шірітеді*» деген мақалын алсақ,

«*Бір құмалақ бір қарын майды шірітеді*»-нің беретін мәні *бір адамның істеген жаман қылығы көптің, ұжымның атына кір келтіреді.*. Қазақ халқы мақалға негізгі шаруашылық кәсібінде пайдаланылатын «құмалақ», «қарын» сөзін қолдана отырып, қалыптастырған. Демек, осы мақалдардың да өн бойынан халықтың тіршілігінің исі аңқып тұр. Сыртқы құрылымы мүлдем бөлек, алайда мазмұндас. Бір түсінікті, бір ұғымды береді.

Түсінік, таным, ұғым, ойлау, әдетте, тіл арқылы бейнеленіп, көрініс табады. Ұғым мен атаудың арасында табиғи байланыс міндетті түрде болады. Сондықтан атауларда олардың уәжділігі адам танымымен тығыз байланыста қарастырылады. Заттың белгілі бір бастапқы қасиетіне бағытталған сөз уақыт өте келе тілдік эволюция жолында алғашқы мағынасын жоғалтуы мүмкін. Кез келген сөздің атауы адам психологиясында қалай қабылданып, қай жағынан әсер ететіндігіне байланысты. Сондықтан кез келген сөз бен оны тудырған себеп арасындағы мағыналық байланыс үзіле береді. Жоғарыда келтірілген адам психикасының бітімі кейбір түсініксіз сөздерді қайта өңдеу арқылы оның басқа бір баламасын тауып, жаңа уәждеме жасай алады [1: 69]. Бұдан шығатын қорытынды балама құбылыстарға негізделген сөз бойындағы бейнелілік. Мақал-мәтелдер бойында кездесетін уәждеме, бұл – семантикалық уәждеме. Аталмыш терминді қазақ тіл білімінде кезінде ғалым Ж.Манкеева қолданған болатын және өз еңбегінде уәжділікті үшке бөліп қарастырады және де атаулардың дәрежесін былай жіктеп көрсетеді: «1) Бірінші дәрежелі немесе алғашқы атау (первичная номинация). Ол – атаудың аталушы заттың қасиеттерімен уәжделуі немесе «шындық фактілерінің тілдік жүйенің фактісіне айналуы». 2) Екінші дәрежелі немесе кейінгі атау (вторичная номинация). Онда сөздің семантикалық дамуы нәтижесінде өзін тудырған түбірімен мағыналық байланысы үзіледі, яғни «жаңа атаулар үшін тілде бұрыннан бар атауыштық құралдарды пайдалану». Ал уәждемені сөзжасамдық тұрғыда зерделеген Б. Қасым: «Уәждеме – шындық болмыстағы заттар мен құбылыстарға туынды атауға қажетті негіз болатын тілдік бірліктер», – дейді [2: 110]. Шынымен де адам заттар мен құбылыстарды танып білу нәтижесінде жаңа атаудың ұғымдық қасиетіне тән белгісін таңдауы оның дүниетанымына, тәжірибесіне байланысты айқындалады. Сол арқылы атауды белгілеудің танымдық қасиеті анықталады. Осы тіл қазыналарының бойында мотивтік

құбылыстың бейнеленіп, қалыптасуын Г.Л. Пермяков та: «Мақал-мәтелдердің ұзақ тарихи жасалу, қалыптасу жолы бар, өзіндік уәжділік негіздері бар, құрамдық-құрылымдық қалпы тұрақты, көркем де әуезді, поэтикалық заңдылық бойынша құрылып, негізгі мағынасы абстракцияланып, ауыс мағынасында қолданылатын, гомоцентристік принцип бойынша, негізінен, адамға ғана қатысты жұмсалатын этнолингвистикалық күрделі құбылыс», – дей отырып, мақал-мәтелдердің мотивтік негізде қалыптасқанын растайды.

Этнолингвистік топтастыру принципі бойынша жіктелетін «Адам», «Қоғам», «Табиғат» топтарына қарай сараланатын Мақал-мәтелдердің басым көпшілігі антропоцентристік принцип негізінде өзінің ауыс мағынасында болса да, адам болмысына қатысты болып келеді. Мақал-мәтелдер жоғарыда көрсетілгендей, әр тілдегі Мақал-мәтелдердің баршасы антропоцентристік принцип бойынша қалыптасып, қалай жасалып айтылса да, адам баласының өзіне, яғни әрбір халықтың өкіліне бағышталып, соның бойындағы не жақсы, не жаман қасиеттерін сипаттауға арналады.

Сондықтан «біз барлықтағы барша заттар мен құбылыстарды үлкен үш салаға топтастырып, ішкі жүйесі мен мағынасына қарай шоғырландырып қарағанда көре аламыз. Оларды біз шартты түрде «Адам», «Қоғам» және «Табиғат» деп атауды ұсынамыз», – деп академик Ә. Қайдар көрсеткендей [3: 134], жұмыста осы ғалым еңбегінің ізімен мақал-мәтелдер үш топқа бөлініп қарастырылды.

Мақал-мәтелдердің тақырыптық топтары әр халықтың өмір-тіршілігіне, дүниетанымдық қасиеттері мен рухани болмысына байланысты. Бұл топтардың мазмұны мен уәждік негіздері де әр түрлі.

Әр ұлт қауымында сан қилы тағамдардың барлығы, яғни өздері үнемі дайындап қолданатын астардың *ұлттық тағамдар* деп аталатыны белгілі. Осы ұлттық тағамдардың жасалу технологиясы мен сан алуан табиғатын білдіретін, оларға қатысты неше түрлі ұғымдарды сипаттайтын мыңдаған атаулар мен жүздеген тұрақты тіркестердің қатарында мақал-мәтелдердің баршасы тілдің ежелгі де байырғы және құнарлы қорына еніп, ұлттық менталитеттің тілдегі бейнелі бір көрінісі болып есептеледі.

*Ас иесімен тәтті, табағымен сәнді*

*Жақсы ас қалғанша, жаман қарын жарылсын*

Қазақ халқы – қонақ күтіп, тамақ әзірлеуге алдына жан салмайтын халық. Сондықтан болар кімге болсын тамақ бергенде жанында үй иесі қоса отыруы шарт. Онсыз астың дәмі де кірмейді. Яғни асты алдына қойып, үй иесі кетіп қалса, келген қонағы «мені жақтырмай отыр ма» деп ойлары әбден мүмкін. Сондықтан ас берген үй иелері де мақал-мәтелдерді қоса отырып, қонақты сыйлау, күту дәстүрі – ежелден келе жатқан дәстүр.

*Жақсы ас қалғанша, жаман қарын жарылсын*

мақалы тамақты, оған қаншалықты еңбек сіңірілетіндігін бағалау мақсатында қалыптасса керек. Шынымен де, ас даярлау оңай жұмыс емес. Егер тағам тәтті болса, босқа төгіліп, ысырап болмау үшін айтылған нақыл сөз. Бұның астарында халықтың жастарды асты қадірлеуге, босқа төгіп-шашпауға, ананың не болмаса ас дайындаушы адамның еңбегін бағалауға деген тәрбиесі жатыр.

Бұдан шығатын қорытынды: мақал-мәтелдер көбінесе, ықшамдалу құбылысына ұшырап, нақты ойды жеткізуге бейімделген. Тілдің динамикалық құбылыс екендігі белгілі. Соған сәйкес мақал-мәтелдерде өзінің тұлғалық, кейде мағыналық тұрақтылығын әрқашан сақтай бермейді. Сондықтан мақалдардың мағыналық тұрақтылық заңдылығы оның құрылымдық өзгерістерінің де заңдылығын қамтамасыз етеді.

**Әдебиет**

1. Қайдар Ә., Оразов М. Түркітануға кіріспе. – Алматы: Арыс баспасы, 2003 – 305 б.

2. Қасым Б. Қазақ тіліндегі заттың күрделі атауларының теориялық негіздері – Алматы: 2002 – 312 б.

3. Сағындықұлы Б. Қазақ тілі лексикасының дамуының этимологиялық негіздері. – Алматы: 1998. – 69 б.

## ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ УКУЧЫ ТАТАР БАЛАЛАРЫНА ХӘЗЕРГЕ ПРОЗАНЫ А. ЯХИН МЕТОДИКАСЫ БУЕНЧА ӨЙРӘТҮ

*Узбәкова Д., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гайнуллина Г.Р.*

Татар әдәбияты фәне – гаять катлаулы фәннәрнең берсе. Укучылар тарафыннан әдәбиятны, аның тарихын, мәдәниятен өйрәнү – мөһим аспектларның берсе дип әйтергә кирәк.

Матур әдәбият фәне балаларны рухи тәрбияләп кенә калмый, аларны һәрьяклап, универсаль ил гражданнары буларак тәрбияли дип әйтү дөрес булыр. Бүген татар әдәбияты дәресләрендә утыручы укучылар иртәгә ил гражданнары булучы кешеләр буларак әдәбият фәненең торышын, аның эчтәлеген белергә тиеш, әдәбият мөхитендә тәрбияләнергә, үзләрендә уңай сыйфатлар тәрбияләргә тиеш. Алда билгеләп үтелгән моментлар хәзерге татар прозасының мәктәп программаларында бирелешенең мөһимлеген тагы бер кат раслый [1: 35].

Әдәбият укыту барышында рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләү әһәмиятле урын алып тора. Татар әдәбияты буенча Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төзелгән гамәлдәге программалар татар балаларына туган әдәбиятыбызны өйрәтүнең максатын теоретик төшенчәләрне үзләштереп, әдәби әсәрне сүз сәнгате һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәсе буларак кабул итәргә әзерләү буларак билгелиләр.

Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүгә, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү һәм күнекмәләрне формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чараларын үзләштерү кебек юнәлешләрне тормышка ашыра [2: 37].

Хәзерге татар әдәбиятын татар балаларына яңача укыту ихтыяҗы елдан-ел үсә бара. Балаларга әдәбиятны уку кызык булсын өчен, яңа методлар һәм алымнар уйлап табу, программаны шул калыпларга салып, укучыларга кызыклы итеп җиткерә белү – укытучының укыту осталыгына бәйле булган төп шартларның берсе [3: 45].

Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова; Ә.М. Закирҗанов, Г.М. Фәхретдинова программалары нигезендә язылган дәреслекләрдә хәзерге татар прозасы гаять чикләнгән дип әйтергә кирәк. 5 нче сыйныфтан алып 11 нче сыйныфка кадәр аралыкта 1980-2000 нче еллар татар әдәбияты прозасы бары тик 7 нче һәм 9 нчы сыйныфта гына бирелгән. 7 нче сыйныфта хәзерге татар прозасына караган Марсель Галиевнең “Уйна әле”, Галимҗан Гыйльмановның “Язмышның туган көне” хикәяләрен кертеп карарга кирәк. 9 нчы сыйныфта алда әйтелгән программалар нигезендә төзелгән дәреслекләрдә хәзерге татар прозасына караган Фоат Садриевның “Таң җиле” романын әйтеп китәргә кирәк булыр. Гомумән алганда, 7 нче һәм 9 нчы сыйныфларда хәзерге татар прозасыннан барлыгы өч әсәр өйрәнелә.

Д.М. Абдуллина һәм Л.К. Хисмәтова тарафыннан төзелгән программа нигезендә язылган 7 нче сыйныф дәреслегендә бирелгән М. Галиевның “Уйна әле” хикәясенә ике сәгать вакыт бирелә [3: 35]. Әлеге әсәрне өйрәнгәндә татар мәктәбендә белем алучы татар баласы М. Галиевның кыскача тормыш юлын белергә, эпик жанрлар турында белемнәрен киңәйтергә, әдәби әсәрдәге образлылыкны, тема, проблема һәм идея кебек төшенчәләрне аера белергә, чәчмә әсәр үзенчәлекләрен үзләштерергә тиеш [4: 56].

Беренче дәрес яңа материалны өйрәнү дәресе кебек укытыла. Әлеге дәрестә Марсель Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү ясала, “Уйна әле” хикәясе турында гомуми мәгълүмат бирелә һәм хикәядән беренче өзекләр укыла. Дәреснең максаты өч юнәлештән гыйбарәт:

– коммуникатив (метапредмет): “Сез уйнарга яратасызмы” дигән темага әңгәмә үткәрү, укучыларның фикерләү сәләтләрен үстерү;

– фәнни (предмет): Марсель Галиевның “Уйна әле” әсәрен өйрәнү;

– тәрбияви (шәхескә кагылышлы): балачакның кадерен белергә, вакытны әрәмгә уздырмаска өйрәнү.

Әлеге өч максат, планлаштырылган нәтиҗәләр, дәреснең нигезен тәшкил итәләр. Бу өч максатны тормышка ашыру юлында репродуктив, өлешчә эзләнү, аңлату һәм күрсәтү методлары; укытучы сүзе, портрет белән эшләү, аңлашылмаган сүзләрне аңлату, әңгәмә кору алымнары уңышлы файдаланыла ала.

Дәреснең нигезен тәшкил итүче берәмлекләр (нәтиҗәләр): катлаулы текст белән эшләү, иң әһәмиятлесен таба белергә өйрәнү; "Уйна әле" әсәре ярдәмендә сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү; фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү; Марсель Галиевның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү; укучыларда шагыйрьнең иҗатына кызыксыну уяту; "Балачак – иң күңелле вакыт" темасына әңгәмә үткәреп, әлеге вакытның иң күңелле, онытылмас мизгелләр булуын аңлату [5: 23].

Икенче дәрес кабатлау, йомгаклау дәресе. Әлеге дәрес вакытында М. Галиев иҗатын өйрәнү, "Уйна әле" әсәрен уку белән бергә теоретик юнәлеш тә исәпкә алынып өйрәнелә. "Уйна әле" әсәрен сәнгатьле итеп укудан тыш, эпик жанр, образлылык, тема, проблема, идея, чәчмә сөйләм кебек төшенчәләрне дә өйрәнү һәм искә төшерү зарури күренеш дип әйтергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Д.М., Хисмәтова Л.К., Җәүһәрова Ф.Х. Әдәбият: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 7 нче сыйныф. 1 нче кисәк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 164 б.
2. Абдуллина Д.М., Хисмәтова Л.К., Җәүһәрова Ф.Х. Әдәбият: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 7 нче сыйныф. 2 нче кисәк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 37–40.
3. Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М. Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 35–40.
4. Ганиева Ф.М., Гарифуллина М.Д. Әдәбият: 6 нчы сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 174 б.
5. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

## ТАТАРСТАНДА ГАСТРОНОМИЯ ТУРИЗМЫ

*Фазылҗанова Г., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Бүгенге көндә туристлар арасында гастрономия туризмы көннән-көн зур популярлык казана. Сәяхәттән яңа тәэсирләр алырга теләгән кешеләр өчен, чит илгә аның аш-су мәдәнияты белән танышу максатыннан бару кызыклы юнәлешләрдән санала. Гастрономия туризмын "тәм белән сәяхәт кылу" дип тә атыйлар, чөнки аш-судан ләззәт алу теге яки бу халыкның мәдәниятен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Ризык – башка мәдәниятне танып белүнең иң мөһим чарасы һәм ул аны акыл дәрәҗәсендә генә түгел, ә хис дәрәҗәсендә дә тоярга мөмкинлек

бирә. Ризык элек электән туризм өлкәсенең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итеп, аның үсешенә уңай йогынты ясый [1]. Туклану – яңа кабул ителгән мәдәният һәм туризм концепциясенең төп элементы. Әлеге концепциянең нигезендә сәяхәт вакытында сыйфатлы тәҗрибә туплау теләгенә омтылу ята.

Тарих битләренә күз салсак, гастрономия туризмы мөстәкыйль юнәлеш буларак күптән түгел генә үсә башлаган. Ләкин, күпчелек белгечләр фикеренчә, дөньядагы беренче сәяхәтчеләр нәкъ менә гастротуристлар булган. Сәүдәгәрләр моңа кадәр күрелмәгән җиләк-җимешләрне, чикләвекләрне, шәрабләрне, тәмләткечләрне табу, аларны авыз итеп карау нияте белән ерак илләргә чыгып китә торган булалар. Алардан алынган тәэсирләр халыкның гореф-гадәтләрен тасвирлауның бер алымына әверелгән. Билгеле булганча, аерым фән һәм тармак буларак гастрономия күпкә соңрак рәсмиләштерелә һәм гастрономия төшенчәсе киң мәгънәдә азык-төлек һәм мәдәният арасындагы бәйләнешне өйрәнүче фән буларак кулланыла [3].

Аш-су туризмы термины 1998 елда Америкадагы Боулинг Грин дәүләт университетының халык мәдәнияте кафедрасы доценты Люси Лонг тарафыннан кертелә. 2003 елда Эрик Вульф Халыкара гастрономия туризмы берләшмәсенә нигез сала һәм бүгенге көнгә кадәр әлеге берләшмәнең президенты ролен башкара [2]. 2012 елда аш-су туризмы дигән терминны гастрономия туризмы дип алмаштырырга мәҗбүр булалар. Халыкара гастрономия туризмы берләшмәсе үткәргән тикшеренүләр күрсәткәнчә, америкалыларның күбесе аш-су туризмын бары тик байлар өчен уйлап чыгарылган юнәлеш дип саный икән. Шунлыктан әлеге терминны күпчелек өчен кулай һәм аңлаешлы булган терминга алмаштыралар. Шуннан башлап гастрономия туризмы азык-төлек кибетләре, шәраб заводлары, җирле халык өчен паблар, урам сәүдәгәрләре, үзенчәлекле рестораннар төшенчәләрен үз эченә берләштерә.

Б. Шмитт фикере буенча, кулинария туризмы чын гурман булган кешеләрне җәлеп итә, чөнки алар өчен яхшы ашамлык – гади ризыктан да мөһимрәк [1]. Бүгенге көндә гастрономия туризмы – үзенчәлекле тәм-томнардан авыз итү, җирле аш-су традицияләре белән танышу максаты белән чит континентка һәм илләргә сәяхәт итү. Әмма сәяхәтнең әлеге төре экзотик яки күптөрле тәм-томнар авыз итеп карауга гына кайтып калмый. Аның асылында гасырлар буе ашарга пешерү культурасын, халыкның гореф-гадәтләрен үз эченә алган рецептура белән ләззәтләнү тора. Аш-су йолалары илнең мәдәниятен тирәнтенрәк аңларга ярдәм итә.

Күпчелек туристлар фикеренчә, Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре үзенең аш-су гореф-гадәтләре белән кызыклы [3]. Биредә республика

халкының, барыннан да элек, татар халкының традицион мәдәниятенә бәйле гастрономик туризмның күп кенә юнәлешләре тәкъдим ителгән.

2018 ел Татарстан өчен нәкъ менә гастрономия туризмы өлкәсендә зур уңышлар китерде. Шуларның берсе – National Geographic Traveler Awards 2018 премиясендә катнашу. Алдынгы туристик юнәлешләр өчен тавыш бирү “National Geographic Россия” сайтында уздырылды. «Россия–гастрономия туризмы» номинациясендә тавыш бирүчеләрнең 40 проценты Татарстан Республикасын сайлады. Шул рәвешчә, Татарстан Республикасы Россия буенча гастрономия туризмы өчен иң яхшы төбәк буларак танылды [8].

Татарстан өчен тагын бер зур вакыйга — Россиянең рекордлар китабына теркәлү. Казанда узган ел футбол буенча дөнья чемпионаты FIFA ачылышына чәк-чәк пешерделәр. Китапка теркәлгән рекордсмен чәк-чәкнең авырлыгы 4026 килограммны тәшкил иткән, шул рәвешле дөньяда иң зур чәк-чәк статусын алган [6].

Татарстанның гастрономия туризмы өлкәсендәге уңышлары моның белән генә чикләнми. ТурСтат аналитик агентлыгы 2018 елның гастрономия туризмы өчен иң популяр гастрономия фестивальләре һәм бәйрәмнәре уздырылган Россия төбәкләре рейтингын төзегән. Әлеге статистика буенча, Россиянең Топ-5 гастрономия регионнары арасында Татарстан икенче урында тора [8].

Татарстан Республикасында гастрофестивальләрнең иң популярлары дип түбәндәгеләрне атарга була: Казанда «Тәмле Казан» ашамлыклар фестивале (6–8 июль), Зөядә «Зөя ухасы» фестивале (9 сентябрь), Питрәчтә «Скорлупино» йомырка фестивале (21 июль). Болардан тыш, 2018 елда уздырылган тагын берничә гастрономия фестивален ассызыклап үтергә кирәк: регионның ике йоласын, баллы чәк-чәк белән үләнле тәмле болгар чәен берләштергән “Чак-Чай” фестивале (30 апрель), яшелчәләр белән төрле мастер-класслар уздырып үткәрелгән “Көз тәмнәре” фестивале (15 сентябрь) һәм көзнең бер символы – кабакка багышланган “Кабак Көне” фестивале (29 сентябрь) һ.б. [5].

Шул рәвешчә, Казан үзенең кунакларын һәм шәһәр халкын гастрономия фестивальләре белән еш сөендерә. Фестивальләрнең кайберләре инде ел саен үткәрелә торган чаралар календарендә үз урынын алган һәм анда катнашучыларның саны югары булу белән мактана ала [7]. Болар барысы да гастрономия туризмы үсешенә үзенең өлешен кертә дип саныйбыз.

Димәк, Татарстанда, аерым алганда Казанда гастрономия туризмы көннән-көн үсә дияргә тулы нигез бар.

**Әдәбият**

1. Грег Ричардс. Еда и туристский опыт // UNWTO: Global Report on Food Tourism. 2012. – С. 20–21.

2. Джанджугазова Е.А. Литературный трактир или национальные особенности трапезы // Современные проблемы сервиса и туризма. – 2010. –№3. – С. 97–102.
3. Государственный комитет по туризму в Республике Татарстан. Официальный сайт. Деятельность. Планы и программы [Электронный ресурс]. Режим доступа: http:tourism.tatarstan.ru/
4. Инде. Интернет-журнал о жизни городах Республики Татарстан [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://inde.io/
5. История и Туризм в Республике Татарстан. Обзор Татарстана [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://tat-rating.ru/
6. Книга Рекордов России. Рекорды [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://knigarekordovrossii.ru/
7. Национальный туристический портал. Репортаж. Гастрономические удовольствия Татарстана [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://russia.travel/
8. ТурСтат. Исследования рынка туризма и путешествий по России и СНГ. Новости. [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://turstat.com/

## ҺАДИ ТАКТАШ ПОЭЗИЯСЕНДӘ АЧЛЫК КҮРЕНЕШЕ ЧАГЫЛЫШЫ

*Фатыйхова И., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Габидуллина Ф.И.*

Һади Такташның тормышы һәм иҗаты җир өстендә яңа заман җилләре искән бөек иҗтимагый тетрәнүләр чорына туры килә. Такташ үткән юл – гади татар авылыннан алып Яна Бохарадагы татар диаспорасына кадәр һәм татар мөселманнары үзәгенең берсе саналган Оренбург мәдәни мохитыннан башлап Төркестан башкаласы Ташкентка кадәр булган юлны үз эченә ала. Бөек шагыйрь мөселман халыклары сәяси һәм рухи үсешенең иң мөһим нокталарын уза, алар белән бергә 20 еллар афәтләрен кичерә.

1921 елның январь аенда яшь, максималист шагыйрь – Такташ Төркестан ягына, Ташкентка юл тота. Илдә дәһшәтле ачлык. “Пәйгамбәр – шагыйрь” үзе “Ташкент – икмәкле шәһәр”гә төпләнсә дә, иленең, халкының нинди дәһшәт тырнагы астында интеккәнен онытмый, шул фаҗигаләрдән әрнүен чагылдырып, Оренбургның “Юксыллар сүзе” гәзитенең 1921 ел 28 ноябрь санында, Ташкенттан җибәреп, “Ачлык патша” дигән шигырен бастыра.

Ач үлем, коточкыч күзләрен
Юнәлтеп сөякләр өстенә,
Тик тора; кан алган йөзләрен;
Чәчләре таралган; агарган
Сакалы җир белән тиң аның [1: 23].

Ач үлем коточкыч күзләрен корбаннары сөякләренә текәгән. Кулында дәһшәтле ялангач кылыч. Хөр илнең баһадир уллары аның аяк астына егылып: “Нан” – дип тилмереп кулларын күккә сузганнар. Ил караңгы бушлыкка әйләнгән. Җил генә тарихның дәһшәтле серен – бу җирнең кайгысын көйли. Шагыйрьнең шул чор иҗатына хас төрткеле

экспрессияле сурәтләр, космик күләмлелеккә омтылышлы образлар. Ниндидер аңлату таләп итми торган реаль дәһшәтле күренешне сурәтләү булганга, шигъри табыш, ачыш, биредә натурализм балластын җиңү чикләрендә кала. Шигъри матурлыклар ягына тема үткәрми. Әсәрдә бу берникадәр кырыс төсмерләр йөгерткәндәй сиземләнә [1: 242].

Һ. Такташ 1921 елның июнендә шигъриятебезнең олы казанышы саналырлык “Җир уллары трагедиясе” дигән драматик поэмасын яза. Беренче карашка, дөнья хәлләреннән, шул көн проблемаларыннан читләшү, хыял дөньясына качу кебек күренә бу әсәр [1: 242].

Библиядә, Коръәндә, “Кыйссасел әнбия”ләрдә сөйләнелгән хәлләрне, – беренче кешеләр, Адәм балаларының җиргә куылган көннәрен сурәтләүгә нигезләнә әсәр. Җирдә өйсез-нигезсезләр, оҗмахтан куылган Адәм балаларының дәһшәтле ачлыктан интегеп, законсыз, кыйбласыз, табигый һәм иҗтимагый тотрыксызлык шартларында яшәү күренеше. Аларның тиңсез гаҗизлектә яшәеше, зар-моңы хәтта фәрештәләрне тетрәндерә. Шул шартларда яшәүче кешенең, шәхеснең лаеклы тормыш, ирек, бәхет өчен көрәше яралу игътибар үзәгенә куела. Идея (Газазил) өйрәтүе буенча, Кабил үзенең генә түгел, туганнарының, Адәм балаларының кара бәхетсезлекләренә каршы баш күтәрә, шул кешелексез шартларга риза булып яшәүгә каршы протест белән чыга. Ул берәүләр рәхәттә, икенчеләр газаплы ут эчендә яшәү белән һич тә килешә алмый. Аныңча, кол булганчы, дөреслек, ирек өчен көрәшеп корбан булу артыграк. Аның беренче протесты туганнарының, колларның ач-ялангач яшәүләрен күреп әрнүдән башлана:

Анда ачлыктан, суыклыктан
Туганнарым минем
Бер-беренә сарлышып ярдәм көтәләр.
Соң мин нишлием [1: 30].

Кабилне ярсулы көрәшеннән бернәрсә дә туктата алмый. Ул: “Күктә канлы алла булса, җирдә башка алла бар!” – ди, кайдадыр “иркен хәятлы” бәхетле дөнья булырга тиешлегенә ышана һәм адәм балалары өчен бәхет эзләп шунда китмәкче була. Әкълимәне дә ул үзе белән барырга өнди:

Әйдә бу каргалган илдән
Без сәгадәткә таба
Юл салыйк, очыйк икәү
Иркен хәятле дөньяга!
Кайда юк Алла, канун
Һәм эч пошу, хәсрәт, көек;
Кайда без иркен яшәрбез,
Хөр, азат җилләр кебек [1: 47].

Ләкин ул үзенең теләгенә ирешә алмый, тигезсез көрәштә фаҗигале рәвештә һәлак була. Чөнки аның таянычы юк, ул ялгыз. Аның фаҗигасе әнә шул ялгызлыкта. Аны кызганучы адәм балалары да аллага табыналар.

Кабилгә-ярдәм итә алмыйлар. Ахырда, алланың “кануны” Кабилдән иң соңгы өмете – Әкълимәне дә тартып ала. Бу исә, – кеше өчен җайсыз нииндидер тотрыклылыкка китерелгән тиләлек кагыйдәләренә каршы чыгу, – бунт, гыйсъян санала. Андый нәрсә шул тотрыклылык тәртипләрен саклаучы, тотучы кодрәтле көчләрнең дәһшәтле каршылыгына, һәлакәтле һөҗүменә, эәрлекләвенә юлыга һәм кыюлык күрсәтмәкче булган затның хурлыкка җиңелүе һәм әрнүле һәлакәте белән тәмамлана. Мондый протестка җөрьәт итү шәхескә дә җиңел түгел. Ул кешегә, башына күктән таш яңгыры яудыру, куылу, һәлакәт, мәңгелек тәмугка хөкем ителү кебек тиңсез газаплар гына китерә. Шагыйрьнең тиктомалдан мондый фикерләрне җанландырып чыгуы заманга, бу чор яшәешенә протесты буларак бирелә [1: 242].

Бу – 1917 ел революцияләре, гражданнар сугышы, илне аяктан еккан ачлык дәһшәте тырнагындагы халык хис-кичерешләренә тәңгәл вазгыятьне күрсәтү. Кабатланмас чорның мәһабәт шигъри сурәте. Җәмгыять тормышының асты өскә китерелгән. Дөньялар яңару, – яңа тормыш, беренче яңа кешеләр яшәеше. Сугышлар, стихияләр (янар таулардай) тузынган шартлардагы көнкүрешнең беренче адымнары. Халыкның шул яңа тормышта үз урынын аныклаган, социаль мөмкинлекләрен, әхлак-гадәт кысаларын билгеләгән көннәре.

**Әдәбият**

1. Такташ Һ.Х. Әсәрләр: 3 томда. Т. 1.: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 407 б.

## XX–XXI ГАСЫР СҮЗЛЕКЛӘРЕНДӘ ЧӘЙ РИЗЫКЛАРЫ АТАМАЛАРЫ

*Фәсхиева З., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Татар милли аш-суы үзенең бик бай һәм төрле булуы белән танылган. Бу телнең ризык лексикасында да киң чагыла һәм тел белеменең лингвокультурология юнәлешендә тикшеренүләр алып бару өчен дә бай материал тупларга мөмкинлек бирә. Чөнки милли мәдәниятнең бер өлеше буларак ризык лексикасында халыкның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте, тарихы чагыла.

Татарларның туклану культурасына хас элементларның берсе – чәй эчү. «Тарихи мәгълүматлар буенча, чәй эчү традициясе татарларга Кытайдан кергән, – дип яза үзенең хезмәтендә Нурмөхәммәтова Р.С. – Чәйне татарлар кайнар килеш, каты итеп, сөт, сөт өсте салып, бал белән эчәргә ярата. Бу эчемлекне еш эчү кырыс табигать шартларына каршы тору өчен дә зарур булгандыр» [1: 182]. Татарларда чәй янына кайнатма, шикәр, бал кебек тәм-томнардан тыш, татар табынында төп урынны алып торган төрледән төрле милли камыр ризыклары да куела. Шул рәвешле, чәй эчү еш кына тамак ялгап алуны алыштыра.

Татар халкының чәй янына куела торган камыр ашларына бай булын XX–XXI гасыр башы сүзлекләрендә китерелгән лексик мәгълүмат дәлилли. Мәсәлән, безнең тарафтан тикшерелгән, 1913 һәм 2002 елгы татарча-русча сүзлекләрдә шактый ризык атамалары урын алган. Мисал өчен, түбәндә китерелгән камыр ашлары ике сүзлектә дә теркәлгән: **ایپی – ئه پی** / ***ипи*** – *хлебъ черный, (ржаной) хлебъ* [2: 40], хлеб (печеный) [3: 114]; **کومه چ/ *күмәч*** – *булка, белый хлебъ* [2: 175], *1) булка, булочка 2) белый хлеб, калач* [3: 207]; **قابارتمه/ *кабартма*** – *слойка, булочка (кабартма)* [2: 152], *кабартма (нац. кушанье типа пышки, пончика)* [3: 131]; **له وه ش/ *ләвәш*** – *плоскіе, круглые пирожки съ пастилой или вареньемъ* [2: 182], *1) лаваш (пирог); 2) лаваш (лепешка)* [3: 215]; **په ره مه چ/پره مه چ – په ر ه مه چ/ *пәрәмәч*** – *пирожокъ, пирожки* [2: 62–63], *перемеч* [3: 257]; **با ور ساق/ باغر ساق – باور ساق /*бавырсак*** – *лепешки* [2: 49–50], *баурсак (нац. кушанье)* [3: 47]; **قويماق/قيماق / *коймак*** – *блинъ, блины* [2: 168–169], *блинчик, оладья* [3: 165]; **چکچه کی/ *чәкчәк*** – *лепёшки, сладкія лепёшки* [2: 93], *чакчак (нац. кушанье)* [3: 395]; **صو مصا / *сумса*** – *пирогъ, пирожокъ* [2: 133], *сумса (нац. кушанье), пирожок* [3: 284] һ.б.

Әлеге мисаллардан күренгәнчә, бер гасыр вакыт үтүгә карамастан, татар аш-суында шактый камыр ашлары үз актуальлеген югалтмыйча сакланып килгән. Әлбәттә, еллар узган, заманалар үзгәргән саен татар кухнясы башка күп төрле камыр ризыклары исәбенә дә байый барган. Моны 2002 елгы сүзлектә теркәлгән ризык атамалары исбатлый*:* ***белен*** – *блин* [3: 54], ***гөбәдия*** – *губадия (нац. блюдо)* [3: 85], ***күзикмәк*** – *лепешка (из пресного теста)* [3: 204], ***катлама*** – *1) слойка 2) катлама, слоеный пирог* [3: 150], ***юка*** – *диал. лепешка* [3: 419], ***күптермә*** - *пышка* [3: 208], ***урама*** – *урама (нац. мучное изделие)* [3: 360], ***дучмак*** – *ватрушка* [3: 92], ***көлчә*** – *лепешка* [3: 200], ***бөккән*** – *бэккэн, пирожок* [3: 70], ***өчпочмак*** – *треугольник* [3: 448], ***кыстыбый*** – *кыстыбый (нац. кушанье)* [3: 193] һ.б. Әлеге атамалар 1913 елгы сүзлектә урын алмаган. Әмма без әлеге ризыкларның барысы да XX гасыр башында әле әзерләнмәгән дип әйтә алмыйбыз. Мисал өчен, *катлама, күптермә, урама* сүзләренең диалекталь вариант булулары турында «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә әйтелә. Бу исә әлеге сүзләрнең XX гасыр башы сүзлегендә теркәлмәвенең сәбәбе булырга мөмкин, ягъни сүзлекне төзүче С. Рахманколый аларны белмәгән булса кирәк. Мәсәлән, *катлама* төрле диалектларда төрле ризыкларны белдерә: «1. Түмән, кузнецк, чүпрәле, сергач, шарлык, хвалын, стәрлетамак сөйләшләрендә камырдан пешерелә торган кунак ашы: берничә кашык каймак яки сөт һәм йомыркага гына басылган ак он камырын юка гына итеп җәяләр дә, тар тасмалар итеп кисәләр; киселгән тасмаларны трубка сыман итеп төреп, кайнап торган майга салып пешерәләр; 2. Ләмбрә сөйләшендә йомыркага басып, юка итеп җәеп майда пешерелә торган төче камыр ашы, юка» [4: 279]. *Күптермә* – «Сергач,

хвалын, минзәлә, стәрлетамак, чүпрәле, тепекәй сөйләшләрендә – күпертмә. Тобол сөйләшендә – кабартма (булочка из дрожжевого теста)» [4: 355]. *Урама* – «кама тамагы, тобол сөйләшләрендә, бараба диалектында юка гына итеп җәелгән камырны буй-буй кисеп, аларны урап, кызган майда пешерелгән камыр ашы (кушанье в виде свернутых в трубки полос тонко раскатанного сдобного теста, жаренное в масле)» [4: 682]. Шулай ук бу очракта 1913 елгы сүзлекнең бер генә автор тарафыннан төзелүен һәм күләменең дә зур булмавын игътибарга алырга кирәк. Шуңа күрә, күзәтүләрдән чыгып, әлеге сүзлек үз чоры өчен кыйммәтле һәм бай материалга ия дип әйтә алабыз.

Шул рәвешчә, 1913 һәм 2002 елгы сүзлекләрнең һәр икесендә дә чәй янына куела торган бер үк төрле камыр ризыклары атамалары шактый теркәлгән. Бу хәл әлеге ризыкларның элек-электән әзерләнеп килеп, татар милли аш-суында әһәмиятле урын тотуларын билгели. Еллар үткән саен, яңа төр ризыклар белән бергә телгә аларның атамалары үтеп керүе, сүзлекләргә теркәлүе табигый күренеш. Әмма шул ук вакытта борынгыдан килгән милли ризыкларны, аларның атамаларын саклап, югалтмыйча, буыннан буынга күчерүдә сүзлекләрнең роле бәяләп бетергесез.

**Әдәбият**

1. Нурмөхәммәтова Р.С. «Чәй» лексемасының лингвомәдәни портреты // Теория и практика преподавания родных языков в системе среднего и высшего образования: современное состояние, проблемы и перспективы: матер. Межрег. науч.-прак. конф. (Казань – Кукмор, 28 февраля 2014 г.) – С. 182–185.

2. Рахманкулов С.Г. Татарча-русча лөгать. – Казань: Лито-типография Харитонова, 1913. – 210 б.

3. Татарско-русский словарь / И.А. Абдуллин, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мухамадиев, Р.А. Юналеева. Под ред. Ф.А. Ганиева. – Казань: Тат. кн. издат., 2002. – 488 с.

4. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

## XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ ИҖАТЫНДА ТЕАТР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

*Фәттахова А., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Гыйлаҗев Т.Ш.*

Милли театр, Беренче рус инкыйлабының шифалы җилләре тәэсирендә рәсми статус алганчы, катлаулы һәм кызыклы юл үтә. XIX гасыр ахырында татар театры үзенең беренче адымнарын ясый башлый. Татар сәхнәсе әүвәл өй шартларында куелган спектакльләр, мәктәп-мәдрәсәләр театрлары формасын ала. Шәкертләр һәм мөгаллимнәр катнашында Казан Татар укытучылар мәктәбендә тамашалар куела башлый. Г. Тукай «Халык иҗаты» дигән җыентыгында бу чорда шәкертләр тарафыннан үткәрелгән музыка кичәләре, әдәби укуларны искә ала.

Татар театр сәнгатенең башлангыч тарихы матбугат битләренә теркәлеп калган. Мәсәлән, тарихчы М. Рыбушкин XIX гасырның беренче яртысында басылып чыккан хезмәтендә болай дип яза: “Татарлар хәзер театрга гына түгел, төрле күңел ачу урыннарына да бик яратып йөриләр. Хәтта европача белемгә ия булган кешеләр дәрәҗәсеннән торып бу мәсьәлә турында фикер дә йөртәләр” [2: 125–126]. XX гасыр башында барлыкка килеп, зур тизлекләр белән үсеп киткән милли театрның актуаль проблемалары классик татар язучылары публицистик һәм тәнкыйди эшчәнлегендә дә киң яктыртыла.

Катлаулы организмны хәтерләткән театр сәнгатенең иң мөһим компоненты артистлар уены булу сәбәпле, сәхнә серләренең бөтен нечкәлекләрен үзләштергән профессиональ артистлар тәрбияләү татар театрының иң зур мәсьәләләреннән берсе була “Татарча спектакльләр” (1908) мәкаләсендә Ф. Әмирхан “Мәсхәрәләнмеш ханым”, “Көтелмәгән кадерле кунак”, “Кыз сорау” пьесаларында уйнаган артистлар турында, сүзләре ятланмаган булганлыктан, алар суфлёрны көтеп торырга мәҗбүр булулары һәм шуңа күрә пьесаның көлкеле җирләрен тәшкил иткән тиз-тиз фикер алышуларның кызыксыз чыгуын билгеләп үтә. Татар тормышын чагылдырмаганлыктан әлеге өч әсәр дә язма авторында канәгатьсезлек уята [1: 87]. Тәнкыйтьче Габдулла Кариевның карт ролен яхшы башкаруын, Вәлиулла Мортазин-Иманскийның любовник ролен “гүзәл чыгарырлык” дәрәҗәдә оста артист икәнен билгеи. Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, “пьесаларның гайре табигыйлекләренә үч иткән кебек, үз ролен камил диярлек башкара. Өммегөлсем Мостафина-Болгарская садә татар карчыгын бик яхшы уйнаса да, “көчләп татарка ясалган аристократка-княгиня” ролен бик зәгыйфь башкара, дип саный автор. Шул ук вакытта артистлар составы аз булу сәбәпле, сәләте булмаган кешеләрнең дә сәхнәгә чыгарылуын театр сәнгате өчен никадәр зарарлы икәнен күрсәтеп уза. Ул аерым рольләрне уйнаучы әфәнделәрнең “Фәзаилеш-шөһүр”дән “күңеле йомшап вәгазь сөйли торган абыстай шикелле сөйләп эффектны ваттуларын” мисалга китерә [1: 88].

Г. Исхакый да “Театр китаплары” (1907) мәкаләсендә «Денщик Гали», «Кыз сорау», «Көтелмәгән кадерле кунак» пьесаларына туктала. Язучы башлам өлешендә әсәрләрдә гәүдәләнгән вакыйгаларның татар тормышыннан ераклыгына үзенең тулаем тискәре мөнәсәбәтен белдерә: “Ләкин боларның берсеннән дә бертөрле дә мәгънә ала алмадым. Берсе хакында да бусы мондый, тегесе тегенди диярлек йирен (җирен. – *А.Ф.*) таба алмадым” [4]. Шулай ук тәнкыйтьче аерым пьесаларның саф татар телендә язылмыйча, аларда төрек, рус сүзләренең кулланылышын, катнаш телдә тәрҗемә ителүне дә якламый.

Алда спектакльләргә язылган рецензияләрне тикшергәннән соң, күренекле татар язучыларның сәхнә әдәбиятына программа булырлык таләп куюлары ассызыклана: милли театр өчен язылган пьесалар, чит әдәбиятлардан тәрҗемәләр, иң беренче нәүбәттә, татар тормышын чагылдырырга тиеш. Г. Исхакыйнын драматургия өлкәсендә калдырган бай мирасы әнә шул программа-таләпнең үтәлеше булып тора.

Хәл ителәсе икенче зур мәсьәлә — милли тамашачы булдыру. Моңа кадәр сәхнә сәнгате белән бөтенләй диярлек таныш булмаган халыкны тамаша залларына тарту җиңел эш булмый. Моның өчен татар халкының тормышын, актуаль иҗтимагый-милли бурычларны чагылдырган заманча әсәрләр иҗат итү көн тәртибенә куела. Ә аларны тамашачы яратырлык спектакльләр итеп сәхнәләштерү – милли театр хәл итәргә тиешле иң мөһим проблемаларның өченчесе булып тора. Шушы нисбәттән Г. Тукайның 1909 елда язылган “Безнең заман” исемле сатирик рецензиясенә мөрәҗәгать итик. Тәнкыйтьче вакыйгаларның эстетик югарылыкта чагылдырылмавын, пьеса төзелешенең комедия калыпларына җавап бирмәвен, характерларның эшләнеп бетмәвен, конфликтларның логик чишелешенең түбәнлеген күрсәтеп, әсәр авторы Ф. Сәйфи-Казанлыдан ачы көлә [3: 107].

1909 елда Панаевский бакчасының ябык театрында «Хуҗа һәм приказчик» куелу уңаеннан язылган “Татарча театр” мәкаләсендә Г. Тукай халыкның күплегенә игътибар бирә. “Театр сафыннан тәрәкъкый иттерүне (алга җибәрүне. – *А.Ф.*) үзләренә идеал итеп алган бу труппа артистлыктан башка эш илә шөгыльләнмәгәнгә, табигый инде, эч пошканнан гына театр уйнарга керешкән любительләргә кыяс итәрлек (чагыштырырлык. – *А.Ф.*) дәрәҗәдән күптән үткән вә үзенә тамашачы күңелен җәлеп иткәндер” [3: 108], – дип, бу труппаның актерлык осталыгын, аеруча Галимҗан ролен уйнаучы Кариев, Садыйк ролен уйнаучы Сакаев, Галим ролен уйнаучы Мортазин, С. Гыйззәтуллина-Волжскаяларның професиональлеген югары бәяли.

Күренә ки, XIX гасыр ахырында беренче адымнарын ясап, XX гасыр башында татар халкының мәдәни күтәрелешенә китергән сәхнә сәнгате һәм аның үсешенә турыдан-туры уңай йогынты ясаган театр тәнкыйте формалашуга классик язучылар үзләреннән зур өлеш кертәләр.

**Әдәбият**

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Т. 3. – Б. 86–88.

2. Рыбушкин М. Краткая история города Казани. – Казань, 1834. – Ч. I. – 180 с.

3. Тукай Г. М. Әсәрләр. 6 т.: проза, публицистика (1907-1913) / төз. З.Г. Мөхәммәтшин. – 2015. – Т. 4. – 431 б.

4. http://gabdullatukay.ru/tukay-environment/gayaz-ishakiy/gali-arslanov-gayaz-ishakyj-hem-tatar-teatry/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 18.01.2019).

# З. ХӘКИМНЕҢ «ТЕЛСЕЗ КҮКЕ» ПЬЕСАСЫНДА ШӘХЕС ҺӘМ СИСТЕМА КАРШЫЛЫГЫ

*Хадиева И., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Сәйфулина Ф.С*

З. Хәким XX гасырның 80 нче елларында әдәби иҗатка килә. Аның иҗат үченчәлеген күрсәтүче әсәрләре шактый күп, бу мәкаләдә бәяләү өчен без драматургның “Телсез күке” әсәрен алдык. Әсәрне шәхес һәм система каршылыгы яссылыгында өйрәнү, бер яктан, З.Хәким иҗатын тулырак аңларга ярдәм итсә, икенче яктан, хәзерге татар сәхнә әдәбиятында барган эзләнүләрне тоемларга мөмкинлек бирә.

Закирҗанов Ә.М. үзенең “Эзләнү юлында” дигән мәкаләсендә З. Хәким турында болай дип яза: “З. Хәким иҗат активлыгы, моңа кадәр читтә калып килгән тема-проблемаларга иркен мөрәҗәгать итүе, сәнгати фикерләү үзенчәлеге белән аерылып тора. Гаҗәеп бай иҗат фантазиясе, табигый сәләте, чынбарлыкның гаять гыйбрәтле, җитди вакыйга-күренешләрен оста тотып алуы – барысы да әсәрләрен киң яңгырашлы, эмоциональ тәэсирле итә” [1: 1].

“Телсез күке” кебек пьесалар халык характерын билгели. Без кая барабыз? Без, татарлар – “телсез күкеләр”, гел сабыр итәбез. Безнең Ватаныбызмы бу, әллә түгелме? Без үзебезгә үзебез хуҗа түгел, читләр кулындагы солдатлар гына. Кем өчен кан коярга безгә? Сталин өченме? Партия, империя, интернационализм һ. б. өченме? Әсәрнең максаты булып – әлеге сорауларга җавап эзләү тора.

Пьесада төп образ – Кызыл Армия солдаты, урманчы малае Зариф (Күке). Зариф образы З. Хәкимнең зур табышы дип карарга мөмкин. Ул тормышчанлыгы белән көчле. Автор аның гади-гадәти татар егете булып үсүенә кат-кат басым ясый. Урманда үсеп, табигать яратуы, аннан көч һәм тынычлык алучы егеттә горурлык һәм гаделлек, сабырлык һәм кыюлык кебек характер сыйфатлары аеруча калку чагыла. Егетнең җыр-моңга бай нечкә күңеле, ярдәмчел, миһербанлы олы йөрәкле булуы да ассызыклана. Иң мөһиме – яхшылыкны, изгелекне аңлый белү, шуны яшәү принцибы итү – Зарифның бөтен асылын билгели. Боларның җирлеге булып туган җире, туган халкы, аның иң матур традицияләре, гореф-гадәтләре тора.

Бу пьесада әһәмиятле урын тоткан шәхесләрнең берсе – Зыятдин. Ул – Финляндиядә туып үскән татар егете. СССР солдатлары Финляндияга үтеп кергәч, ул кулына мылтык алып, үзе теләп сугышка китә. Ул снайпер, ягъни, төз атучы, күке. Әмма бу күкене татар җыры телсез итә. Урманда татар халык җыры – “Кара урман”ны ишетү Зыятдинны әсир итә: Ничек инде ул татар башы белән, татар җырын җырлап торган кешегә атсын инде? Әле башта, егетләр белән землянка янында торганда ук, ул биш кешенең

берсен атып үтерергә тиеш була. Әмма кош очып киткәнгә игътибарын җәлеп итеп, ул ата алмыйча кала. Ә бу очракта татар җыры аны әсир итә.

Әсәрдә НКВДның Особый отделы офицеры Зимин Федор Семенович образы гаять үзенчәлекле. Разведкага бару өчен ул Лебедевтан үзенә биш солдат сорый. Лебедев аңа Шаталин, Яхно, Северюгин, Рассуханов һәм татар егете Зарифны бирә. Пьесаны кат-кат укысам да, әле Зиминның шәхес буларак төбенә төшеп җитеп булмый. Ә бит совет заманында аның кебек шәхесләр булган. З. Хәким бит аны күктән түгел, тормыштан алып язган. Беренче карашка, Зимин һәр солдат белән дә уртак тел таба. Һәрбер солдат белән үз итеп сөйләшә. Зариф белән хәтта татарча да сөйләшә. Лебедев биргән биш солдатны да үзенә аерым-аерым чакыртып сөйләшә. Монда аның астыртынлыгы ачыклана башлый. Һәрбер солдатның хәленә кергән булып, аларны һәрберсен энә күзеннән үткәрә.

Пьесада Зимин белән бәйле вакыйгалар үзгә бер катлам тәшкил итә. НКВД офицеры – системаның тугрылыклы сакчысы. Аның йөзендә без тоталитар җәмгыятьнең кешелексез асылы белән очрашабыз. Үз теләгенә Зимин я юмалап, я алдап, я куркытып ирешергә гадәтләнгән. Шуңа да Зариф белән Зыятдинның җитди каршылыгын һәм бер-берсен яклап, саклап эш итүләрен аңлый алмый. Ике татар егетенең туган җир, халык, аның җыр-моңына бәйле якынаюына, дуслашу-туганлашуына тоталитар система каршы тора алмый. Бер милләт вәкилләренең берләшүендә куркыныч күреп, Зимин төрле юллар белән моңа каршы көрәшә. Аның “эшен” улы дәвам итә. Гомере ахырына якынлашканда Зиминның Зариф янына килүе, билгеле бер дәрәҗәдә күңелен бушатуы, үзенең җиңелүен тануы да булып тора. Шул рәвешле, әлеге каршылыкның чишелеше рәвешендә автор яклаган фикер-карашлар калкып чыга. Алар исә Зариф омтылган Хакыйкать буларак бирелә: Халык тормышының чагылышы булган, Карелия урманнарын, салкын кышларын үтеп чыга алган халык җыры-моңы кешенең көче, рухы, өмете чыганагы булып тора. Зариф сүзләре белән әйткәндә, “Сугышта винтовканы телсез иткән тел әле яшәячәк ул! Винтовканы телсез калдырган җырны ничек үтереп булсын икән?!” Тормыш юлында күптөрле золым кичергән Зариф олы гуманист буларак сурәтләнә. Җаны-тәне белән явызлыкка каршы торучы карт күңелендә үзен кайгы-хәсрәткә дучар иткән кешеләргә карата нәфрәт-ачу хисе юк. Әсәр ахырында Зиминга ул болай ди: *“Мин сине гафу итә алам, тик аңлый алмыйм.”*

З. Хәким җан ачысы белән дөньяда татарларның тоткан урынын, татар бәхете, татар язмышы турында яза. Татарлар һаман сабыр итәләр. Җитәкчелеккә кайчан киң күңелле, дип әйбәт кеше килер икән көтәләр. Шуңа күрә әсәрнең ахыры ачык. Язмыш дулкынына яраклашыргамы, әллә

алга таба көрәшне дәвам итәргәме? Бу хәлләр тагын кабатланмасмы? Бу – автор тарафыннан күрсәтелгән проблеманың бер ягы гына.

**Әдәбият**

1. Закирҗанов Ә.М. Эзләнү юлында (З. Хәкимнең соңгы еллар иҗатына бер караш). – Казан, 2012. – Б. 10.
2. Хәким З. Телсез Күке: пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 480 б.

## ИСТОРИКО-ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ ДВУЯЗЫЧНЫХ СЛОВАРЕЙ XIX ВЕКА

*Хайруллина А., КФУ, аспирант I года*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. Юсупова А.Ш.*

Несколько столетий назад были созданы около тысяч двуязычных словарей. В них использованы различные системы построения и толкования материала.

Языковые словари выполняют важные социальные, политические и культурные функции. С одной стороны, они помогают представителям разных народов лучше узнать и понять друг друга, решать совместно жизненные проблемы. С другой стороны, такие словари концентрируют в себе основную массу знаний, накопленных ко времени их создания у того или иного народа и общества. Как писал выдающийся отечественный филолог XIX века, почетный член многих научных академий мира И.И. Срезневский, «хороший словарь должен удовлетворить каждого из тех, кто к нему прибегает. Чем образованнее народ, чем значительнее в нем масса людей просвещенных, тем у него лучше, богаче, полнее, удовлетворительнее словарь его языка».

Тюркские языки прошли очень длительный и сложный путь развития, о чем свидетельствует их богатый словарный состав, грамматический строй и система диалектов.

Несколько лет тому назад в одной из своих статей, посвященных вопросам тюркского языкознания, Н.А. Баксаков писал: «Пока ещё нет фундаментальных исследований по исторической и сравнительно-исторической лексикологии конкретных языков. Назрела необходимость разработки словарей на новых теоретических основах, обеспечивающих изучение процессов развития лексики и семантики. Не начаты лексико-семантические исследования, не изучена лексика в историко-типологическом и сравнительно-историческом плане» [1: 49].

Двуязычный словарь является важнейшим практическим пособием при изучении другого языка. Вместе с тем, это результат лингвистических исследований его составителя, поскольку в процессе лексикографического описания какого-либо конкретного языка часто сталкивается с проблемами, по мнению Беркова, успешное решение которых возможно лишь в

случае «обязательного обладания теоретическими знаниями в различных областях лингвистики» [2: 3].

За эти годы лексикологическая деятельность в области тюркских языков заметно расширилась. Завершена работа над двуязычными словарями, в которых дается наиболее употребительная лексика по конкретным тюркским языкам. Закончен первый этап исследования диалектов и говоров тюркских языков. Почти по всем тюркским языкам успешно ведется сбор и систематизация лексического богатства, включая диалектный материал и лексику языковых памятников. Появляются полные толковые, диалектологические, этимологические словари отдельных тюркских языков. Наряду с этим начали появляться труды, посвященные общим вопросам тюркской лексикологии. Продолжают выходить новые тома «Этимологического словаря тюркских языков», работа над которым была начата Э.В. Севортяном.

Основой системного изучения лексики как одного из важнейших уровней языка является комплексный подход к исследованию, т. е. анализ литературной лексики наряду с диалектальными и разговорными вариантами. На современном этапе своего развития татарская лексикография представляет достаточно систематизированное лексическое богатство языка в виде толковых, диалектологических и этимологических словарей.

В идеале в каждом словаре должен быть воплощен основной лексикографический принцип – «максимум информации на минимуме места без ущерба интересов читателя». Создание таких словарей, естественно, предполагает овладение специальными знаниями. Самое основное в двуязычном словаре – подбор точных переводных эквивалентов [3: 4]. При этом составители и издатели словарей должны осознавать, что они способствуют лучшему взаимопониманию и сотрудничеству разных народов.

Знаковым в истории тюркской лексикографии стал словарь Махмуда Кашгари «Дивану лугат-ат тюрк» («Словарь тюркских наречий» XI век), в котором зафиксирована бытовавшая в тот период лексика тюркоязычных племен Средней Азии и отчасти Поволжья [5: 48].

Важное место в истории тюркских языков занимает «Кодекс Куманикус» − памятник кыпчакского языка конца XIII − начала XIV века, составленный христианскими миссионерами и неоднократно переиздававшийся в разных странах. В словаре отражен разговорный язык западно-хуннский тюркских языков, глоссы даны латинскими буквами. Словарь имеет важное значение для изучения складывавшегося в то время письменного языка тюркоязычных народов [4: 87].

Генетические пласты тюркской лексики образовались путем слияния нескольких исторических слоёв. Результаты сравнительного анализа тематической лексики татарского языка показывают, что огузский пласт татарского

языка также имеет более ранние и более поздние слои. Более ранний огузский слой охватывает лексику не только современных огузских языков, в эту общность входят также некоторые тюркские языки Сибири и Саяно-Алтайского нагорья, такие как хакасский, тувинский, шорский и др.

**Литература**

1. Баскаков Н.А. О некоторых общих задачах тюркского языкознания // Советская тюркология. – 1986. – № 4. – С. 39–52.

2. Берков В.П. Вопросы двуязычной лексикографии: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. – Л., 1971. –30 с.

3. Берков В.П. Двуязычная лексикография. – М.: Астрель, 2004. – 236 с.

4. Наджип Э.Н. Исследование по истории тюркских языков XI–XIV вв. – М.: Наука, 1989. – 291 с.

5. Хаков В.Х. Национально-русское двуязычие в диахронном и синхронном аспекте // Актуальные проблемы развития межнациональных отношений, интернационального и патриотического воспитания. – Казань, 1989. – С. 154–157.

## ТЮРКСКИЕ ИСТОКИ И СТИЛИСТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ УКРАШЕНИЙ В КОМПЛЕКСЕ КОСТЮМА КРЯШЕН

*Хасанова А., КФУ, студент III курса*

*Науч. рук. – канд. пед. наук, доц. Салахова Р.И.*

Формирование этноконфессиональной общности кряшен происходило в результате сложных этнокультурных процессов, приходивших в Волго-Уральском регионе [3: 5]. Ученые имеют различные предположения по поводу происхождения кряшен и иследования не дают однозначного ответа.

Многие исследователи пишут о том, что с принятием христианства кряшены оказались изолированы от основной массы татар [1], что способствовало более длительному сохранению в их костюме первоначальных форм, и, несмотря на их заметную сближенность с соседствующими финнами, в наряде и быте кряшен сохраняются и тюркские истоки. Проследим это на примере сравнения комплекса украшений кряшен с комплексами других близких по территориальному и языковому признаку народов.

Украшения кряшен, как многих тюркских и финно-угорских народов украшены монетами. Это имеет не только практическое, но и сакрально-практическое значение, например, в книге «Очерки истории традиционной культуры и религиозности татар-кряшен» Исхаков Р.Р. описывает обряд гадания кряшен на праздник Нардуган: добровольцы-парни снимали нательный кресты, а девушки, помимо этого, украшения из серебряных монет, что говорит об их оберегательной функции [3: 87]. Кроме того, украшения являлись своеобразным "страховым фондом" девушки [3: 297].

Обильно украшенные монетами нагрудное украшение «тамакаса», известное различным группам кряшен, и матерчатый нагрудник замужних женщин «тушлек» имеет схожие черты как с тюркскими («ама» у чувашей, нагрудник типа сакал у башкир), так и с финно-угорскими народами

(нагрудные украшения марийцев бывшего Елабужского уезда Вятской губернии), проживающими на территории Поволжья.

Возможно, данный тип украшений восходит к найденному болгарскому нагрудному украшению из ткани, покрытому монетами и имеющим застежку сзади [2: 97]. Также Гаген-Торн Н.И. пишет о том, что «в коллекциях МАЭ имеются также болгарские матерчатые нагрудники из алого сукна обшитые позументом бисером и монетами» [2: 98].

Однако стоит провести еще одну параллель по форме и материалу основы – нагрудник «тушлек» имеет лопатообразную форму, что делает его схожим с нагрудником казанских татар изу, который, как пишет Гаген-Торн Н.И., представлял собой «лопатообразный кусок материи, коленкора или холста, на который нашивались ряды позумента, парчовых лент, блях и украшений, причем в середине его остается разрез или имитация разреза, который скреплен бляшками и обшит кругом лентами. В верхних углах изу пришивались завязки, укрепляемые на шее, а снизу он пришпиливался к кульмэку» [2: 90]. Стоит отметить также вероятное сходство с матерчатым якутским нагрудником, который исчез к XIX веку. Они были, как пишет А.П. Окладников «ближе всего не к тунгусскому переднику, а к аналогичной части женского костюма некоторых других тюркских племен, в том числе сибирских тюрок и башкир» [4: 252].

Текстильные нагрудники были также известны другим тюркоязычным народам: казахам, каракалпакам и киргизам. Казахские «алка» представлял собой прямоугольник с застежкой на шее, сверху пришивалась тесемка или узкий стоячий воротник. Иногда нагрудник имел закругленные нижние углы. В северном и центральном Казахстане алка расшивали серебряными монетами и кораллами. В своей работе «Нагрудник в девичьем / женском костюме тюркских народов средней Азии и Казахстана» Л.Ф. Попова, Е.Л. Кубель сообщают: «Этот вид нагрудников в собрании РЭМ представлен, во-первых, двумя экземплярами лопатообразной формы (один свадебный, возможно татарской работы), во-вторых, предметом в виде длинного языка с нашитым массивным металлическим украшением онір жіек, характерным для казахов Прикаспия и Приаралья» [5: 206].

Мы не можем утверждать, возник ли данный тип украшения обособленно у каждого народа или имел общее происхождение. Однако, вероятнее всего, нагрудник у всех описанных нами народов имел общую практическую функцию – прикрывать разрез рубахи.

Иногда общность происхождения украшений можно проследить не только исходя из сравнения внешних признаков и конструктивных особенностей. В комплексе украшений почти всех групп кряшен есть головной убор, представляющий собой круглую шапочку украшенную бисером или монетами «такья»[1]. Подобный головной убор встречается и у других

народов Поволжья, его название созвучно: у удмуртов и бесермян «такья», «тухья» или «тохья» – у чуваш, «такыя» у башкир[2: 152–156]. Подобный головной убор, называемый «тахья» был и у туркмен Средней Азии [2: 156]. Гаген-Торн Н.И. приводит выдержку из «Корневого чувашско-русского словаря» под авторством Н.И. Золотницкого: «Слово это арабское: такия – шапочка; по-татарски такия называется шапочка, вышитая серебром; тюркское такье значит шлем» [2: 155]. Мы можем сделать предположения о тюркском происхождении данного головного убора, которое впоследствии было перенято соседними народами.

На данных примерах понятно, что комплекс украшений кряшен формировался под влиянием сложных процессов, элементы перенимались у предков, преобразовывались со временем и под воздействием соседствующих культур.

**Литература**

1. Воробьев Н.И. Кряшены и татары: некоторые данные по сравнительной характеристике быта // Труд и хозяйство. – 1929. – № 5. – С. 12.

2. Гаген-Торн Н.И. Женская одежда народов Поволжья (материалы к этногенезу). – Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1960. – 228 с

3. Исхаков Р.Р. Очерки истории традиционной культуры и религиозности татар-кряшен (XIX–начало XX вв.). – Казань: Центр инновационных технологий, 2014. – 332 с.

4. Окладников А.П. История Якутской АССР // Якутия до присоединения к русскому государству – Т. 1. – М.; Л., 1955. – С. 252.

5. Попова Л.Ф., Кубель Е.Л.. Нагрудник в девичьем / женском костюме тюркских народов Средней Азии и Казахстана // Лавровский сборник Материалы XXXVIII и XXXIX Среднеазиатско-Кавказских чтений 2014–2015гг. – СПб.:МАЭ РАН, 2015. – 536 с.

## МӨСЛИМ ТӨБӘГЕ ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘМЕНЕҢ КАЙБЕР ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Хафизова Я., КФУ, II курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Галиуллина Г.Р.*

Җәмгыятьтә аралашу сөйләм аша бара. Күренекле галим Р.С Абдуллина күрсәтүенчә, сөйләм ул – бер-берсенә бәйле ситуацияләргә мөнәсәбәте булган бик катлаулы процесс [1: 7]. Сөйләм теле кешелек җәмгыятендә зур урын били. Ул кешеләрнең көндәлек аралашуын оештыру өчен кулланыла. «Сөйләм теле, әдәби нормаларның тиешенчә сакланмавы һәм территориаль диалектларны, гади сөйләм элементларын алу белән аерылып тора. Моннан кала, сөйләм теленең үзенә генә хас лексик-семантик, фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре булуын һәм сөйләм телендә кулланыла торган берәмлекләрнең үзара ярашу мөмкинлекләре үзгә икәнен дә искәртү зарур» [2: 29]. Әлеге мәкаләдә без татар сөйләм теленең фонетик үзенчәлекләрне өйрәнүне максат итеп куябыз. Моның өчен этник составы ягыннан татарлар күпләп яшәгән

Мөслим районы вәкилләренең аудиоязмаларга теркәлгән сөйләмен алырга булдык. Бу аудиоязмаларда Мөслимдә яшәүче унике татар кешесенең сөйләме теркәлгән. Катнашучыларның икесе ир-ат, унысы хатын-кыз җенесеннән, яшьләренә килсәк, бишесе 60 яшьтән югары, 40–60 яшь арасындагылар биш кеше, икесе –17–23 яшьтәгеләр.

Мөслим районы Татарстан Республикасының көнчыгыш өлешенә урнашкан. Ул төньяктан республикабызның Актаныш, төньяк-көнбатыштан Минзәлә, көньяк һәм көньяк-көнбатыштан Азнакай һәм Сарман районнары, көнчыгыштан Башкортостан Республикасының Бакалы районы белән чикләнә. Мәйданы 1466,2 кв. км., халкы 20,2 мең хисаплана. Халыкның 89,9% татарлар алып тора, моннан кала, руслар (6,3%), марилар (2,7%) яши. Мөслим районы татарлары сөйләме урта диалектның Минзәлә сөйләшенә керә [3].

Анализланган материаллар нигезендә билгеләнгән кайбер фонетик үзенчәлекләргә тукталабыз.

Урта диалект сөйләмнәренә хас булганча, минзәлә сөйләшенең киң таралган үзенчәлекләреннән берсе – «җ»ләштерү күренеше, мәсәлән, *яңа* – [*җаңа*], *ятып* – [*җатып*], елан – [*җылан*], *яңгыр* – [*җаңгыр*] [4: 219]. Аның асылы йә, йа, йы, йэ, йо, йө дифтонгларын «җ»ләштереп әйтүгә бәйле. Бу төр үзенчәлек күмәклек сүзләрендә генә түгел, ялгызлык исемнәрендә дә күзәтелә, мәсәлән, *Яхъя – Җахъя, Ярулла – Җарулла, Язилә – Җәзилә* һ.б. Безнең информантларның сөйләмендә дә бу төр үзенчәлек чагылыш таба, мәсәлән, [*зур* ***җылға*** *идэ мәллә* ***җылғасы*** */ бэз шунда су кэрә торған ийэк//*] (78 яшьлек информант); [*мин мәктәпнэ җитмэш а*$^{о}$*лтынчы* ***җылны*** *бэтэрдэм // қырық бэр* ***җыл*** *үтсә дә / қырық бэр көн гэнә сыман //* (62 яшьлек информант); [‹...› *әлэ* ***җа***$^{о}$***ңа*** *әзрәк кэнә рәтли әлэ әниләрэ ба*$^{о}$*лалар туздырған өйнө // мин мэнә а*$^{о}$*лҗап* ***җа***$^{о}$***тып*** *торадырием әлэ*] (65 яшьлек информант); [*можэт бездә* ***җуқтыр*** *ул*] (44 яшьлек информант); [*быйылғы* ***җыл*** *мэнә / йәшелчәләр үстэрэргә бик мөмкинлэкнэ бирми әле*] (65 яшьлек информант). Әмма шунысы күзгә ташланды: урта буын информантлар сөйләмендә «җ»ләштерү күренеше кими бара, ә яшьләр сөйләмендә исә гомумән күренми.

Төрле яшьтәге информантлар сөйләмендә таралыш тапкан күренеш – сүз ахырында [и] авазының дифтонглашуы, мәсәлән, *ни* [*нэй*], *ди* [*дэй*] сүзләрендә, – *мыни/-мени* [*мыный /мэнэй*] кисәкчәләрендә һ.б. Информантлар сөйләменнән берничә мисал китерик: [*а*$^{о}$*нда спэциал'ны йасалған маңгаллары/ өстәлләр бар а*$^{о}$*нда/ гэл искитмәлэ* ***нэй***] (51 яшьлек информант); [*әйткәннәрэн йазыб* ***ба***$^{о}$***рмадыңмынэй***] (62 яшьлек информант); [***Нэй*** */ иртәгә иртүк торасы бит // қа*$^{о}$*йтырға кирәк ийе*] (23 яшьлек информант); [*ашқа тоқмач са*$^{о}$*лдыңмы* ***әнэй***] (20 яшьлек информант); [*са*$^{о}$*бантуйға са*$^{о}$*тырға чығыш. //* ***нэй*** */ а*$^{о}$*лла бирсә // иртәгә ба*$^{о}$*рып* ***нэй*** *элэ / фритурнитса а*$^{о}$*лам да праизвотствыға / қа*$^{о}$*мырларын*

*йа°сап а°лып чығабыз*] (55 яшьлек информант) һ.б. Әлеге күренеш, безнең карашыбызча, югалмый, киресенчә, аның таралыш даирәсе тагын да киңәйтә.

Мөслим төбәге өчен үзенчәлекле сыйфат буларак теш арасы [d] авазы билгеләнә. Әлеге үзенчәлек күмәклек сүзләрендә генә очрап калмыйча, кеше исемнәрендә дә күзәтелә, хәтта кешенең рәсми исеме буларак та теркәлә, мәсәлән, *Зөлфия – Дөлфия, Зөфәр – Дөфәр, Заһит – Даһит, Рәзинә – Рәдинә, Илүзә – Илүдә, Илиза – Илида* һ.б.

Без караган информантлар сөйләмендә әлеге үзенчәлек пассив, бары тик өлкән буын вәкилләрендә генә очравын билгели алабыз, мәсәлән [***хәdәр*** */ панидэл'ник уқырға / сәғәт өчтән тороп җәйәw ба°рыш*] (78 яшьлек информант). Урта буын вәкилләре сөйләшендә әлеге аваз беркадәр тел алдында әйтелеп [$д^з$] га әйләнә: [*йа°л көннәрэндә балыққа төшөргә* ***йа°ратабыд***$^з$ *индә*]; [*мэнә шуны ха°ман да сағынып* ***көтәбеd*** *индә*] (51 яшьлек информант). Урта буын кешеләре сөйләмендә теш арасы [d] авазының беркадәр тел алдында әйтелеше сөйләм процессында вариантлашырга мөмкин. Без аны алда күрсәтелгән информантның сөйләмендә ачык ишетәбез. Яшьләр арасында теш арасы [d] авазын кулланып сөйләүчеләр бөтенләй юк диярлек.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Мөслим төбәгендә яшәүче татар кешеләренең сөйләмендә элек-электән таралыш тапкан фонетик диалекталь үзенчәлекләр беркадәр үзгәреш кичерәләр. Өлкән буын вәкилләре сөйләмендә аларны еш очратсак, урта буын татарларның сөйләмендә әдәби тел нормаларына яраклашкан әйтелеш тарала башлаганы, ә яшь буында исә әдәби телдәгечә әйтелешнең киң җәелгәнлеге күзгә ташланды.

**Әдәбият**


1. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. –527 б.
2. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. 2018. – № 1 (10). – Б. 22–35.
3. Электронная версия атласа татарских народных говоров // http://atlas.antat.ru/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.01.2019)
4. Татар халык сөйләшләре: 2 китапта. 1 нче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.


## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА ГӨЛ СҮЗЕ


*Хәйруллина Д., Казан, 124 нче мәктәп, XI сыйныф*

*Җит. – Җамалиева Л.Ф., Мөслимова К.У.*


Үсемлекләр дөньясына бәйле образлардан *гөл* сүз-сурәте татар җырларында бик киң кулланыла. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә аңа: «Бүлмәдә яки бакчада матурлык өчен үстерелә торган үлән-үсемлек»,— дигән аңлатма бирелә [1: 284]. Шушы мәгънәсеннән үк аңлашылганча, нәфис шигъри сурәтләү чарасы буларак, ул барлык төркем җырларда да актив кулланыла һәм аның образлы мәгънә төсмерләре дә киң кырлы.

К.Миңнуллинның «Җырларның лексик составына күзәтүләр» дигән хезмәте «Татар халык иҗаты» күптомлыгының җыр җыентыкларында урын алган әсәрләр нигезендә башкарылган. Анда күренгәнчә, гөл сүзе татар халкының йола җырларында – 16, уен җырларында – 106, тарихи җырларында – 10, борынгы җырларында – 99, совет җырларында – 64, кыска җырларында – 473 тапкыр очрый [2: 184] .

Кеше күңелендә матурлык уятучы *гөл* символы җыр текстына нәфислек, өсти. Җырларда ул күп төрле эпитетлар белән баетылып файдаланыла. Яфраклары һәм чәчәкләренең төсенә, формасына, исенә, төренә бәйле рәвештә татар халык җырларында аның аергычлары да арта бара: *ал гөл* [4: № 51; тат. 5: № 362], *куе зәңгәр гөл* [3: № 779], *кына гөле* [4: № 63], *үрмәле гөл* [4: 2062], *тамчылы гөл* [1: 2655] *исле гөл* [4: № 89], *зәйтүн гөл* [4: № 377], *роза гөле* [3: № 2529], *миләүшә гөлләр* [3: № 3124], *рәйхан гөле* [3: № 369] һ.б.

Татар җырларында *гөл* сүзе еш кына *ал* сүзе белән парлап кулланыла һәм күптөрле формаларда очрый: *Алдыр* синең яулыгың, *Гөлдер* синең яулыгың; [3: № 49]; *Алларым* диям сине, *Гөлләрем* диям сине [5: № 558]; *Ал* яулык бәйләүчеләр, *Гөл* яулык бәйләүчеләр [тат. 3: № 478]; Алтын пәке *ал* кисәр, Көмеш пәке *гөл* кисәр [3: № 4371], *Аллар* алышыек без икәү, *Гөлләр* алышыек без икәү [тат. 4: № 56]. Борынгы җырларда бу пар күпчелек очракта кушымтада файдаланыла:

Өстендә күлмәк, башында калфак,
Үзәген өзә Латифә аппак.
*Ал бадъяным* Латифә,
*Гөл бадъяным* Латифә [5: № 303].

Күргәнебезчә, *ал – гөл* парының күп төрле сүз төркемнәре белән бәйләнешкә керүе җыр текстларындагы ритм төзеклеген тәэмин итә, җырның яңгырашын матурайта.

*Гөл* сүз-сурәтенең иң киң таралган мәгънәсе – матурлык, бу очракта ул еш кына *чәчәк, бакча* сүзләре белән бергә килә: «Сандугач сайрый бакчада *Гөл бакчасы сәйран дип».* Бу юллардагы «гөл бакчасы» *бәйрәм* образына янәшәлектә килә: «Без урамнан җырлап узсак, Кызлар чыга бәйрәм дип» [3: № 43]; Сад *бакчада* берәү йөри, Ике кулларына *гөл* учлап [3: № 56].

Халык *гөл бакчасын* күгәрчен оясына тиңли (тат. 5: № 316), сандугачлар *гөлне* күреп оча [5: № 362], сөйгән ярны да *гөл чәчәге* үскән бакчадан сайлап алалар [4: № 60]. Кыз елату җырларында да кыз бала үзенең туган йортына – иленә *гөлләр* чәчеп калдырырыга тели: Бакча ишеккәем ачаем, Түбәсенә *гөлләр чәчәем* [4: № 25]. Яисә:

*Гөлбакчадай илләремә*
Кайтыр микән, кайтыр микән,

Дусларым, сөйгәнем [4: № 54].

*Гөл* – лирик герой өчен туган илнең бик матур бер бизәге: Агыйделкәй суы, ай, бер генә, Агыйделкәй буе *гөл генә* [5: № 101].

Кайбер җырларда туган ил дә *гөл бакчасына* тиңләштерелә: «туган илем гөл арасы» [2: № 152], «Казан иле – гөлбостан» [3: № 459] һ.б. *Гөл бакчасы* янәшәлек аша *туган илне* символлаштыра:

*Гөл бакчасына* керер идем,
*Гөл чәчәгенә* буялам;
Туган илем исемә төшсә,
Йокымнан каушап уянам [3: № 1304].

Җырларда якын дуслар, кадерле туганнар да гөлгә тиңләштерелә: Сезгә охшаган *гөлләр үсә Гөлбакчалар эчендә* [4: № 144]; Кара безнең дус-ишләргә, *Бакчада үскән гөл кебек* [ 3: № 1579].

Гөлләр матур булып чәчәк атсалар да, билгеле бер вакыт җиткәч, алар саргая, кибә, шау чәчәктә утырганнарының да көтмәгәндә сынулары мөмкин. Гөлнең яшәү рәвеше белән бәйле шушы процесслар җырларда лирик геройның рухи халәте белән чагыштырыла: *Гөл саргая* диеп *без саргаймыйк,* Бәлки рәхәт көннәр дә булыр [3: № 29, 2988]; *Сынган гөлләргә* охшатам Аерылган көннәремне [5: № 555, тат. 3: № 492] *Суласың ла,* йөзем, ай, суласың Өзелеп *җиргә төшкән гөл кебек* [3: № 1696].

Җырларда урын алган гөл-чәчәкләр, аларның матурлыгы, туган җир матурлыгын, мәхәббәт сафлыгын, гүзәл яшьлекне, шул ук вакытта гомер агышын, сагыш-моңны гәүдәләндерүгә дә хезмәт итә. Күп гөлләрнең чәчәк атуы да аларны бер-берсенә якынайта. Гомумән алганда, *гөл* образы татар җыр сәнгатендә киң таралган. Яраткан кеше, аларның матурлыгы, туган ил гөлгә тиңләнә. Гөлләрнең аерым билгеләре исә лирик геройның кәефен, психологик халәтен чагылдыруда файдаланыла.

**Әдәбият**

1. Миңнуллин К.М. Җырларның лексик составына күзәтүләр // Фольклор теле – шигърият теле. – Казан: Фикер, 2001. – Б. 123–221.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1977. – Т. 1. – 476 б.
3. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 319 б.
4. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар / И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 392 б.
5. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар / И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 488 б.

## МӘКТӘПТӘ УКУ-УКЫТУ СИСТЕМАСЫНДА ПРОЕКТЛАР МЕТОДЫН КУЛЛАНУНЫҢ МЕТОДИК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Хәмидуллина Л., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хөснетдинов Д.Х.*

Татар теле белемендә сүзләрнең морфологик төркемнәре галимнәр тарафыннан шактый тулы тикшерелеп, аларның сөйләм оештырудагы

рольләреннән чыгып, иң элек, мөстәкыйль һәм ярдәмлек дигән ике зур тармакка аерылганнар. Соңгылары үз эчендә сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган модаль дип аталган төркемгә, вазифалары сөйләмдә мөстәкыйль мәгънәле сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйли торган бәйләгеч сүзләргә бүленүе мәгълүм. Бәйлек һәм бәйлек сүзләр – бәйләгеч сүз төркеменә карый торган үзенчәлекле берәмлекләр.

Җәмгыятьнең хәзерге үсеше этабында татар телен укыту яңача якын килүне таләп итә, чөнки традицион укытуда төп урын алган әзер белемнәр бирү ярдәмендә генә заман ихтыяҗларын канәгатьләнедерә алырлык шәхес формалаштыру мөмкин түгел. Проектлар методы турында исә галимнәр: “үз эшчәнлегеңне проектлаштырырга өйрәнүнең формалашуы гына да заманча җәмгыятьтә кирәкле булган белем бирү нәтиҗәсен тәшкил итә” [2: 3], дип язалар. Мәктәптә белем бирүне заманча аңлап, аның төп максаты укучы шәхесен үстерү икәненә төшенү дә проектлар методына мөрәҗәгать итүне таләп итә, чөнки мондый эш укучыларның интеллектуаль, иҗади, ихтыяри потенциалын үстерә, рефлексиягә сәләтле шәхес буларак формалаштыра, фәнни күзаллау булдыра. Соңгы елларда уку-укыту процессында актив кулланыла торган методлардан проект эшләүгә зур игътибар бирелә башлады. Галимнәр аны уку-укыту процессын укучыларның кызыксыну даирәсеннән чыгып төзәргә мөмкинлек бирүе, эшне планлаштырганда, оештырганда һәм танып белү эшчәнлеген контрольдә тотканда укучыга мөстәкыйльлеген күрсәтергә мөмкинлек бирүе өчен югары бәялиләр. Галим Ф.Ф. Харисов аның уңай якларын түбәндәгедә күрә: “бу методика шәхескә юнәлтелгән, чөнки укыту гадәти аралашуга якыная төшә һәм татар телен өйрәтүнең яңа технологияләре таләпләренә җавап бирә, балаларның акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерә” [5: 223].

“Проект” сүзе тамырлары белән латин – “projectus”, ягъни “алга ыргытылган” сүзенә барып тоташа. Мәктәптә проект методын куллану үзенчәлекләрен төрлечә якын килеп өйрәнгән галимнәр терминга мондый аңлатма бирәләр: “укытучы тарафыннан махсус оештырылган, укучылар тарафыннан мөстәкыйль башкарылган, укучы өчен әһәмиятле мәсьәләләрне чишүне күзаллаган гамәлләр комплексы” [3: 12]. Инновацион метод кебек тәкъдим ителсә дә, XX гасырның егерменче елларында америкалы Джон Дьюи нигез салган дип саналучы проектлар методы” Россиядә гасыр башында ук билгеле була. Ләкин Совет власте елларында әлеге технология үсеш ала алмый, 1931 нче елда бөтенләй тыела. Методологик нигезләрен дөрес билгеләмәү нәтиҗәсендә, махсус әзерлек үткән педагогик кадрлар булмау сәбәпле аны куллану уңышлы булмый.

Хәзерге вакытта, эволюцион үзгәреш юлын үтеп, проектлар методы төрле илләрдә актив кулланыла. Аның киң таралышы үзенчәлекләре белән

бәйле: проект башкару вакытында укучыларның төрле өлкәләргә караган белемнәре арасында бәйләнеш булдырыла, алар алган белемнәрен гамәлдә, тормышта төрле ситуацияләрдә кулланырга өйрәнәләр, шул ук вакытта проект башкару вакытында яңа идеяләре дә туа.

Проектлар методын популярлаштыручылар арасында билгеле галимә Е.С. Полат һәр проектның гамәли юнәлеш алган булуына, конкрет максатка төбәлгән булуына игътибар итә

Укытучының укыту һәм тәрбия бирү процессында проектлар технологиясен куллану күнекмәләрнә ия булырга тиешлеге документларда да атала. Мәсәлән, укытучының Һөнәри стандарты (6 нчы декабрь, 2013 нче ел) болай ди: “укытучы уку-укыту белән шөгыльләнү кысаларыннан чыккан форма һәм методлар: проект эшчәнлеге, лаборатор экспериментлар, кыр практикасы – белән дә эшли белергә тиеш [1].

Проектлар методы киң кулланылса да, терминнар арасында беркадәр буталулар күзәтелә. Күп кенә мөгаллимнәр “проект”, “проектлар методы”, “проект эшчәнлеге технологиясе” терминнары арасындагы чикләрне күрмиләр. Проект эшчәнлеге дигәндә, “укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге нәтиҗәсендә теге яки бу проблеманы чишәргә һәм нәтиҗәләрне тәгъбир итәргә мөмкинлек биргән уку-укыту һәм танып белү алымнарының эзлекле бөтенлеге” аңлашыла [4: 30]. Педагогик технология буларак проектлар методы дибез икән, “бер яктан, эзләнү, тикшеренү, проблемалы методларны куллануны, икенче яктан, фән, техника, сәнгатьнең төрле өлкәләренә караган белем һәм күнекмәләрнең интеграциясен күзаллаган технологияне” күздә тотабыз [4: 30].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: проектлар методы үткән педагогик мираста кулланылган. Дөрес, әлеге тәҗрибә уңышлы барып чыкмаган, әмма үткәндәге хаталарны кабатламаган очракта заманча җәмгыять таләп иткән шәхес тәрбиясен һәм аңа белем бирүне проектлар методы аша башкару максатка ярашлы. Әйтергә кирәк, хаталарның берсе булып проектлар методын артык күп куллану була, шуңа күрә хәзерге мәктәптә әлеге методны куллануда чикләрне дә куя белергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Артемов М.Ю. Историко-критический анализ метода проектов в системе языкового образования. – URL: https://cyberleninka.ru/article/v/istoriko-kriticheskiy-analiz-metoda-proektov-v-sisteme-yazykovogo-obrazovaniya

2. Власенко В.А. Методика организации проектной деятельности учащихся основной школы при обучении информатике в условиях информационно-коммуникационной образовательной среды: автореф. дис. … канд. пед. наук. – М., 2013. – 24 с.

3. Голуб Г.Б. Метод проектов – технология компетентностно-ориентированного образования: методическое пособие для педагогов – руководителей проектов учащихся основной школы. – Самара: Учебная литература, Федоров, 2006. – 176 с.

4. Ивашедкина О.А. Технология организации проектной деятельности // Современные педагогические технологии. Основная школа. – СПб.: КАРО, 2015. – 176 с.

5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 302 б.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ – ЖУРНАЛИСТ

*Хәмитова Н., КФУ, IV курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Хәбетдинова М.М.*

А.М. Гыйләҗев тудырган сәнгать дөньясы авторның индивидуальлеге белән баетылган, шуңа күрә дә аның әсәрләрендә һәрвакыт сәнгать һәм тормыш, яшәеш дөреслеге ачык чагыла. Язучы үзенең беренче романында татар газетасы редакциясе тормышын һәм журналистлар эшчәнлеген җентекләп сурәтли. Без әлеге әсәрдә язучының журналистика өлкәсендә туплаган шәхси тәҗрибәсе зур роль уйный дип уйлыйбыз.

А.М. Гыяләҗевның журналистлык биографиясе этабын торгызу безнең тикшерену эшебезнең яңалыгы булып тора. Тикшерену материалы булып язучының һәм аның тормыш иптәше Н. Гыйләҗеваның хатирәләре хезмәт итә.

Лагерьдан кайткач, А.М. Гыйләҗев озак еллар үзенең тормышын оештыра алмый. Безгә язучының әлеге чор биографиясе белән танышырга тормыш иптәшенең хәтирәләре ярдәм итә: «Аязны 1955 елда тоткынлыктан кайткач беркем дә эшкә алырга батырчылык итмәде. Аяз үзе “Чаян”, «Яшь сталинчы» (“Татарстан яшьләре”) газеталарына мәкаләләр язып әз-мәз гонорарлар алып, шулар белән канәгатьләнеп яшәп йөрде. Аңа матбугат битләрендә урын бирү мәсьәләсе үзе үк проблема булып, аның әсәрләрен бастырырга шүрлиләр иде. Күпчелек очракта, соңыннан телевидениенең атаклы журналисты булып киткән, ул вакыттагы Аязның сабакташы булган Мөкатдәс Юсупов белән төрле завод-фабрикаларга барып репортажлар оештыргаладылар. Ә Аяз анда да исемен күрсәтмәскә тырыша иде. Чөнки ул кара тамгалы кеше”.

“Мөкатдәс завод-фабрикаларга барып мәгълүматлар алып кайта, ә Аяз аларны әдәби яктан эшкәртеп язып бирә. Мөкатдәс килешмәгән якларын килештереп редакцияли. Шулай итеп мәкалә языла да, аны Мөкатдәс “Яшь сталинчы”га илтеп бирә иде дип беләм. Аяздан шул вакытта сорашканым булды, ул аңлатуны кирәк тапмады. Гонорарны уртаклыйлар иде”.

“Шәүкәт абый ул елларда “Чаян” журналының әдәби бүлек мөдире булып эшләде... Шәүкәт абыйга аның иҗатка мөнәсәбәте, язучы булырга омтылучан табигате ошагандыр күрәсең, 1957 елның 2 мартында ул Аязга “Чаян”га эшкә килергә тәкъдим ясады. Бу тәкъдим чын мәгънәсендә Аязның тормышына якты балкыш китерде. Аяз шул көнне “очып” килеп, миңа тәкъдим ясады: ”Мин өйләнәм, эшкә урнаштым, мине кешегә саный башладылар кебек”, диде. Шәүкәт абый шундый адым ясарга батырчылык итмәгән булса, аның шулай “кешегә саналмыйча” йөрүе күпмегә барган булыр иде, билгесез!”, – дип үз хәтирәләре белән уртаклаша Нәкыя

Гыйләҗева. – “Ул вакыттагы “Чаян” редакторы борынгыдан килгән затлылыгын саклаган, нәселе зыялылардан булган Фатих абый Ибраһимов Аязны эшкә урнаштырды, Аязга канат иңдерде! .... Аяз аңа гомере буе рәхмәтле булып яшәде”. “90 сум эш хакы ала”. “Аяз сәгать 6–7 дән торып редакциягә чаба. Өйдә аңа язарга бөтенләй мөмкинлек юк”. Журналга килгән хатларга җаваплар яза, үзе дә командировкага чыгып кайткалый [5].

“1957 елның 3 мартында Ш. Галиев ярдәме белән А. Гыйләҗев «Чаян» сатирик журналында эшли башлый, үзенең фельетон, карикатура, памфлетыларын Котбетдин, Мирсәет улы тәхәллүсләре белән бастыра. Ялкау, үшән, куштаннарны, эчкечеләрне әдип аямый. Ул чорда аның белән бер фатирда яшәгән Ш. Рәкыйпов иптәшенең хезмәт сөючәлегенә шакката торган була: «Аның өлгерлегенә, вакытны файдалы итә белүенә, күргән беләкәй генә очрактан фәлсәфә чыгарып вакыйга ясый алуына шаклар катам. Бик тиз арада газета-журналларда егермеләп хикәя, фельетон бастырып чыгарды» [4: 520].

“Беренче сатирик әсәрләре, М.М. Хәбетдинова фикеренчә, жанрлык хасиятләре җәһәтеннән игътибарга лаек. Яшь прозаик очерк, фельетон, карикатура, интермедияләр язып, шәхси стилен чарлый. Тышкы комиклык артында җәмгыятьтәге җитди проблемалар калкытып куела. Язучы бюрократик системадан мыскыллап көлә. Төрмә-лагерьлар шулпасын эчкән әдип дәүләт системасының бюрократизмны көчәйтүгә ярдәм иткәненә инана. Ирония, юмор, сарказм, «үзе өчен үзе сөйли торган исемнәр», сатирик портрет алымнары, образның сөйләме, аерым сыйфатын калкытып кую ярдәмендә автор шул темаларны яктырта. Аерым очракларда әдип, әйтик, ситуациядәге драматизмны ассызыкларга туры килгәндә, психологик анализ алымын да куллана” [4: 520].

1958 елда ук А.Гыйләҗев үз иҗатын бөтенсоюз әдәби-мәдәни мәйданга тәкъдим итә. «Бүләк» хикәясе «Крокодил» журналында [1], “Чаян”ның юморы” җыентыгында басыла [2]. 1959 елда “Чаян”да басылган 9 хикәяне әдип “Рәтле кешеләр” исемле җыентыкка туплый: «Хатының иркә булса...» (1958), “Эшләп кем баеган” (1956), “Җинаять һәм җәза” (1958), “Күлмәк” (1958), “Күңелле мәҗлеснең күңелсез соңы” (1958), “Үбү” (1958), “Уйлап табучы” (1957), “Бүләк” (“Подарок”) (1957), “Наполеон” (“Наполеон”) (1958) [3]. Китапның тиражы 4000 экз.

1959 елның 5 мартында А.Гыйләҗев “Азат хатын” журналына эшкә күчә. Әниләренә язган хатында бу адымны шулай дип аңлата: ““Чаян”да бик ардырды. Айга ике мәртәбә, ике телдә чыга. Үземнең иҗат белән шөгыльләнергә бер дә вакыт калмый иде. Монда бераз иркенрәк булыр дип уйлыйм” [4: 299]. 1959 елда А.Гыйләҗев “Ялкын”, “Совет әдәбияты” журналларында; “Идел” альманахында үз әсәрләрен баса бышлый. 1961 елның сентябреннән А.М. Гыйләҗевкә Мәскәүдәге Югары курсларга

китергә тәкъдим иттеләр. Ул ике еллык Югары курсларда укуны язучы "Күктән төшкән бәхет" итеп кабул итте. 1963 елның язында Мәскәүдән укуын тәмамлап Казанга кайта. Июнь аеннан А.М. Гыйләҗев профессиональ язучы булып китә. Газета, журналлар белән иҗади элемтәдә тора. "Казан утлары" редакциясендә 1975 елда редколлэгия әгъзасы булып эшли.


**Әдәбият**

1. Гилязов А. Подарок / Пер. Г.Валеева // Крокодил. – 1958. – №20. (1526). – С. 6.
2. Гилязов А. Подарок / перевод Г. Валеева // Юмор "Чаяна". – М.: Правда, 1958. – С. 24–28.
3. Гыйләҗев А. Рәтле кешеләр, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 56 б.
4. Гыйләҗев А.М. Сайланма әсәрләр. 6 т.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Т. 2. – 719 б.
5. Гыйләҗева Н. Язмыш // М.М. Хәбетдинова архивы. Кульязма. – 264 б.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АТНА КӨННӘРЕ АТАМАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ


*Хисамеев Р., Түбән Кама, 20 нче урта мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – Ишмөхәммәтов И.Ш.*


Татарлар – бай тарихлы, үзгә мәдәниятле, борынгыдан сакланып калган ядкярләре булган халык. Татар халкының үзенең атна көннәре атамалары булганмы? Нишләп алар хәзер кулланылмый? Безнең максатыбыз булып шушы сорауларга җавап табу, телнең тарихи үткәненә ачыклык кертү тора.

Атна – борынгы фарсы *адинә* сүзеннән. Борынгы Һиндстан һәм Иран халыкларында, шулай ук Борынгы Болгар дәүләтендә дә атна биш көнлек булган. Р. Әхмәтьяновның этимологик сүзлегендә атна сүзенең мәгънәсе "атнаның бишенче көне, биш көнлек атна" дип аңлатыла [1: 22]. Көнчыгыш Азиядә тугыз көнлек атнаның гамәлдә йөргәнлеге дә билгеле. Атна фарсыча – һәфтә, җидекөнлек. Мондый атна айның (бигрәк тә күктә яңа ай туу периодының) якынча чирек өлешенә туры килә.

Г. Дәүләтшин фикеренчә, Ислам дине кабул ителү белән болгарларда фарсы-гарәп, ягъни мөселман атна көн исемнәре киң тарала [3: 31].

Халык җомганы *"атна көн"* дип йөртә. Фарсыларда да "Җомга ни дә, атна ни – икесе бер" дигән мәкаль бар. Шуңа күрә җомга алдыннан булган көн пәнҗешәмбе халыкта *"атна кич"* яки *"кич атна (кече атна)"* дип тә атала. А. Тимергалин фикеренчә, бу термин мөселман календаре урнашканнан соң туган, чөнки һиҗридә көннең кичәсе аның үзеннән алда килә [5: 110]. В.М. Беркутов Казан татарларының пәнҗешәмбене *"кече атна"*, *"кече җомга"* дип, ә җомганы *"атна"*, *"олы атна"*, *"олы җомга"* дип йөрткәнлеге турында яза [2: 19]. Башкортстанның Тепекәй сөйләшендә атна кичне *"кысима"* диләр икән. Халык телендә дүшәмбе – *башкөн*. "Баш көн" атнадан соң килгән беренче көн. Урал татарлары дүшәмбене *"туган көн"* диләр, кайбер сөйләшләрдә *базар арты көн*, сишәмбе – *бушкөн*

(мишәрләрдә), бу борынгы ышануларга бәйле. Мәҗүсиләр бу көнне яңа эшләр башларга, юлга чыгарга, ниндидер килешүләр төзергә җайсыз, уңайсыз дип ышанганнар. Сишәмбе көн татарларда тукучылык, эрләү-бәйләү көне булып исәпләнгән. Чәршәмбене *“канкөн”* дип атау исә ерак гасырлардан ук килә. “Кан көн”дә мәҗүсиләр корбан чалганнар (XIII-XIV гасыр болгар эпитафияләрендә дә очрый). Бу көн татарларда табиблык, багучылык, имчелек көне булган. Юкса татарда “Им көне – шимбә көн” дигән борынгы гыйбарә дә бар. Шимбә – *атна арты, атнарасы көн* (мордва-каратайларда – *аракөн*) я *корыкөн*, якшәмбе – *башкич, базар көн*. Кайбер сөйләшләрдә шимбә көнне *аракөн* яки *атнарас (көн)* дип атаган вакытта *“татар атнасы”* белән *“урыс атнасы”* арасындагы көн күздә тотыла. В. Беркутов татарларда бу көннең *“җомга иртәсе”* дип аталуын да искәртә, монда “иртә” – “иртәгәсе көн” мәгънәсендә [2: 21]. Шушы ук автор керәшен сөйләшендә шимбәнең дә, чәршәмбе кебек үк, *“атна кич”* дип аталганын хәбәр итә итүен. Ләкин бу очракта керәшеннәр әлеге көннәрне бер-берсеннән аеру өчен, шимбәне, ихтимал, *“урыс атна киче”* дип атаганнар булырга тиеш. Якшәмбене *“базар көн”* дип йөрткәннәр, ә кайбер сөйләшләрдә ул *“урыс атнасы”* һәм *“урысйома” (урыс җомгасы)* дип атала. Шунысы кызык: Чистай керәшеннәре җомга көнне *“татар атнасы”* дип атыйлар. Кайбер чыганакларда “җомга” мәгънәсендә *адинә* язылышы да очрый *(“атна”*). Керәшеннәрдә сишәмбене *“утлари көне”* дип йөртәләр (чувашларда – *ытлари көн*). Пермь татарларында сишәмбе – *атланган көн*. Карачай-балкарларда бу көннең (изге) *“Георгий көне”* дип аталуын искә алсак, әлеге исем атка атлану мәгънәсендә булырга тиеш сыман. Әлеге атамаларны борынгы болгарлар кулланган туран календарендагы белән чагыштырып карыйк. Дүшәмбе – *әрнә башы*, *туган көн*; сишәмбе – *ат көн* (күк җайдагы көне); чәршәмбе – *кан көн* (ыру-нәсеп көне); пәнҗешәмбе – *кече әрнә* яки *урта көн*; җомга – *әрнә көн* (атна көн); шимбә – *ара көн*; якшәмбе – *зур* яки *урыс атна көн* [5].

Керәшеннәрне өйрәнгән диалектологлогларның хезмәтләреннән күренгәнчә, һәр төбәктә нинди дә булса аерма күрергә мөмкин. Казан арты һәм Түбән Кама керәшеннәрендә бүген дә *“дүшәмбе”*, *“шишәмбе”*, *“шәршәмбе”*, *“атна кич”*, *“татар атнасы”*, *“атна арты”* һәм *“атна көн”* атамалары кулланылышта йөри. Балык Бистәсе районында дүшәмбе – *атна арты*, сишәмбе – *базар алды*, чәршәмбе – *базар көн*, пәнҗешәмбе – *кичатна*, җомга – *татар атнасы*, шимбә – *мунча киче*, якшәмбе – *атна көн* дип йөртелә икән. Чистай керәшеннәрендә элегрәк алар *баш көн*, *буш көн*, *кан көн*, *кичатна*, *татар атнасы*, *атна кич*, *атна көн* буларак билгеле. Мәлки керәшеннәрендә борынгы көн исемнәре бераз үзгәрәк яңгыраган: дүшәмбе *–тунди көн*, сишәмбе – *ултари көн*, чәршәмбе – *кан*

*көн*, пәнҗешәмбе – *кечатна*, җомга – *олы көн*, шимбә – *атна көн*, якшәмбе – *урыс атнасы*.

Атна көннәрен нинди базар үткәрелүенә карап атау да күзәтелә. Мәсәлән, Татарстандагы Биектау районы Мәмдәл авылында дүшәмбене *кала базары көне* дигәннәр, ә сишәмбе көн *Мәмдәл базары көне* булган.

Моннан без атна көннәренең тәртибе фарсычадагы кебек булмаганлыгын күрәбез, чөнки фарсыларда атна башы шимбә көннән башлана. Хәзерге татар телендә фарсы көн исемнәре үзгәрешсез диярлек кулланыла: *шимбә* (шәмбе) – җомгадан соң беренче көн, *якшәмбе* – шимбәдән соң беренче көн, *дүшәмбе* (дошәмбе) – шимбәдән соң икенче көн, *сишәмбе* (сәшәмбе) – шимбәдән соң өченче көн, *чәршәмбе* (чәһоршәмбе) – шимбәдән соң дүртенче көн, *пәнҗешәмбе* (пәнҗешәмбе) – шимбәдән соң бишенче көн мәгънәсендә, ахырда исә – *җомга* (җомъә) [4: 41].

Керәшеннәрдә хәзер атна көннәре рус телендәгечә аталып йөри, ләкин дини текстларда воскресенье (якшәмбе) *атна көн* дип алынган.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: атна көннәре атамалары халыкның мәдәни мирасы булып торалар. Татар әдәби телендә атна көннәре исемнәрен фарсыча атау кабул ителгән, ә халык хәтере аларны төрки-татарча да саклаган.

**Әдәбият**

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

2. Беркутов В.М. Бизмәннәрдә вакыт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 80 б.

3. Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура (Домонгольский период, X – нач. XIII вв.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 192 с.

4. Зәйнуллин Җ. Әссәләмүгаләйкүм (Язма мирасыбыз нигезе). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 175 б.

5. Тимергалин А.К. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Т. 1. – Б. 110–111.

## ЧУАШ ТЕЛЕНЕҢ ТАРТЫМ ФОРМАЛАРЫ

*Хисияма Ю., Токио чит телләр университеты, аспирант*

*Җит. – Кадзама С.*

Чуаш теле – төрки телләрнең огур төркеменә кергән бердәнбер тере тел. Татар теле һәм башка төрки телләр кебек үк, чуаш теле дә тартым кушымчаларына ия.

Krueger язганча, чуаш телендә тартымны (personal possession) белдерүче өч ысул бар [1: 113, 116]. Беренче ысул – инглиз теленең “my, our, your...” сүзләренә туры килгән, иялек килешле зат алмашлыклары белән белдерү ысулы: *манӑн лаша* (минем ат), *санӑн лаша* (синең ат), *унӑн лаши* (аның аты), *пирӗн лаша* (безнең ат), *сирӗн лаша* (сезнең ат), *вӗсен лаши* (аларның аты) [1: 113].

Krueger аңлатуынча, тартым төшенчәсен белдерүче әлеге ысул чуаш телендә киң кулланылса, башка төрки телләрдә дә очраган тагын бер ысул бар. Ул да булса, ия булучының кем икәнен күрсәтү өчен махсус кушымча куллану ысулы. Мәсәлән: *ывăл-ăм* (ул-ым)*, ывăл-у* (ул-ың)*, ывăл-ĕ* (ул-ы), *ывăл-ăмăр* (ул-ыбыз)*, ывăл-ăр* (ул-ыгыз)*, ывăл-ĕ* (ул-ы) [1: 113, 116].

Krueger, әгәр предметнең кемнеке икәнен ачыкча әйтергә кирәк икән, өстәге ике ысулны бергә кулланалар дип аңлата. Бу ысул башлыча, инглиз теленең “Our son did this, but their son did that.” җөмләсендәге кебек, аерым басым ясау өчен кулланыла: *манăн ывăл-ăм* (минем ул-ым), *санăн ывăл-у* (синең ул-ың), *унăн ывăл-ĕ* (аның ул-ы), *пирĕн ывăл-ăмăр* (безнең ул-ыбыз), *сирĕн ывăл-ăр* (сезнең ул-ыгыз), *вĕсен ывăл-ĕ* (аларның ул-ы) [1: 113, 116].

Kruegerның сүзләренчә, хәзерге чуаш телендә, I һәм II зат күплек тартым кушымчасы урынына, анатитик конфтрукция еш кулланыла. Мәсәлән, *ывăл-ăмăр* урынына *пирĕн ывăл, ывăл-ăр* урынына *сирĕн ывăл-у* кулланыла [1: 118].

Сергеев, Андреева һәм Котлеев, чуаш телендә предметның кемнеке икәнлеге түбәндәге ике ысул белән белдерелә дип аңлата [2: 266, 267].

1) Исем алдында, кемнеке икәнен белдерүче сүзне (*манăн, пирĕн, санăн, сирĕн, унăн, вĕсен*) кую (синтактик ысул). Мәсәлән: *манăн ручка* (минем ручка)*, пирĕн ручка* (безнең ручка)*, сирĕн кĕнеке* (сезнең китап), *унăн ручки* (аның ручка)*, вĕсен кĕнеки* (аларның китабы).

2) Предметның кемнеке икәнен морфологик ысул, ягъни махсус кушымчалар белән дә белдереп була. Мондый кушымчалар тартым кушымчалары (чув. камăнлăх аффиксĕсем) дип атала. Мәсәлән: *сĕтел-ĕм* (өстәл-ем), *сĕтел-ӳ* (өстәл-ең), *сĕтел-ĕ* (өстәл-е).

Сергеев, Андреева һәм Котлеев аңлатуынча, I һәм II зат тартым кушымчалары хәзерге чуваш телендә сирәк кулланыла. Аеруча, предметның I затныкы икәнен кушымчасыз, контекст белән белдерергә була. Мәсәлән: *куç курмасть* (күз күрми) үрнәгендә, күзнең I затныкы икәнлеге контексттан аңлашыла. Шуңа күрә, I зат тартым кушымчалары аралашуда сирәгрәк очрый [2: 270].

Сергеев, Андреева һәм Котлеев, предметның кемнеке икәнен әлеге ике ысулнв бергә кулланып белдерергә дә мөмкин дип яза. Мәсәлән: *санăн (хăвăн) кĕнек-ӳ* (синең (үзеңнең) китаб-ың), *пирĕн (хамăрăн) учител-ĕмĕр* (безнең (үзебезнең) укытучы-быз). Мондый конструкция, предметның кемнеке икәнен ачыграк белдерә, ләкин аралашу теленә характерлы түгел, матур әдәбиятта күбрәк очрый дип аңлата [2: 272].

Сергеев, Андреева һәм Котлеев, III зат башка затлардан аерымалы буларак, һәрвакыт тартым кушымчасын ала дип искәртә. Мәсәлән: *(унăн) тетрач-ĕ* ((аның) дәфтәр-е), *(вĕсен) пӳрч-ĕ* ((аларның) йорт-ы), *(хăйĕн) лаш-и* ((үзенең) ат-ы) [2: 272].

Күренгәнчә, ике хезмәтнең авторлары чуваш телендә предметның кемнеке икәнлеген белдерүче өч ысул турында яза. Әлеге хезмәтләрнең икесендә дә, I һәм II зат тартым кушымчаларының сирәк кулланылуы искәртелә, ләкин ни дәрәҗәдә сирәк икәнлеге җентекләп тикшерелмәгән. Шуңа күрә, без чуваш теленең онлайн корпусыннан файдаланып, чуаш телендә I һәм II зат тартым кушымчаларының кулланылу ешлыгын тикшерүне максат итеп куйдык.

Без чуаш теленең тартым формаларының кулланылу ешлыгын интернетта эшләп килүче “Чăваш чĕлхин икчĕлхеллĕ çӳпçи (Двуязычный корпус чувашского языка)” исемле корпустан файдаланып тикшердек. Әлеге корпуста, 1 миллионнан артык сүз теркәлгән, һәм башлыча газета-журнал мәкаләләрен һәм дини эчтәлекле язмаларны үз эченә ала.

Без, исемле тартым конструкциясендә синтактик форма (мәсәлән: *манăн ывăл*) һәм морфологик-синтактик форманың (мәсәлән: *манăн ывăлăм*) кулланылу ешлыгын тикшерү максатыннан, корпустан һәрбер I һәм II зат алмашлыгына 50, барлык 200 тартым конструкциясен җыйып алып, ике форманың санын санап чыктык һәм түбәндәге нәтиҗәләр алынды:

| | синтактик форма | морфологик-синтактик форма |
|---|---|---|
| *I зат берлек (манăн)* | *42 (84.0%)* | *8 (16.0%)* |
| *I зат күплек (пирĕн)* | ***49 (98.0%)*** | *1 (2.0%)* |
| *II зат берлек (санăн)* | *13 (26.0%)* | ***37 (74.0%)*** |
| *II зат берлек (сирĕн)* | *31 (62.0%)* | *19 (38.0%)* |

Бу нәтиҗәләрдән аңлашылганча, I зат күплек тартым кушымчасы иң сирәк, ә II зат берлек тартым кушымчасы иң еш очрый. II затныкына караганда, I затныкының сирәгрәк кулланылуы да күренеп тора. Бу тенденцияләр, татар теленең тартым конструкциясендә дә күзәтелә. “Татар теленең язма корпусы”ннан һәрбер I һәм II зат алмашлыгына 250, барлык 1000 тартым конструкциясен җыйып алып, ике форманың санын санап чыктык һәм түбәндәге нәтиҗәләр алынды. Чагыштырыгыз:

| | синтактик форма | морфологик-синтактик форма |
|---|---|---|
| *I зат берлек (минем)* | *91 (36.4%)* | *159 (63.6%)* |
| *I зат күплек (безнең)* | ***209 (83.6%)*** | *41 (16.4%)* |
| *II зат берлек (синең)* | *51 (20.4%)* | ***199 (79.6%)*** |
| *II зат берлек (сезнең)* | *134 (53.6%)* | *116 (46.4%)* |

Ике телдә уртак тенденцияләр күзәтелүе игътибарга лаек. I зат күплек тартым кушымчасының иң сирәк, ә II зат берлек тартым кушымчасының иң еш очравының сәбәбе нидә? Безнең карашка, чагыштырмача озын тартым кушымчалары, экономия принцибыннан чыгып, ешрак төшеп калырга мөмкин. Татар телендә күплек сан тартым кушымчалары (*-ыбыз, -ыгыз*) берлек сан тартым кушымчаларына (*-ым,* -

*ың*) караганда озынрак. Чуаш телендә, I зат күплек тартым кушымчасы (-*ăмăр*) калган тартым кушымчаларына (-*ăм, -у, -ăр*) караганда озынрак.

Моннан тыш нинди сәбәп булуын ачыклау һәм әлеге тенденциянең башка төрки телләрдә дә күзәтеләме-юкмы икәнлеген тикшерү – алдагы бурычыбыз.

**Әдәбият**

1. Krueger, J. Chuvash Manual. Introduction, Grammar, Reader, and Vocabulary. Indiana University Publications, Uralic and Altaic Series 7 – The Hague: Mouton, 1961. – 271 pp.

2. Сергеев, Л.П., Андреева, Е.А., Котлеев В.И. Чăваш чĕлхи: чăваш филологи факультечĕн студенчĕсем валли хатĕрленĕ вĕренӳ кĕнеки. – Шупашкар: Чăваш кĕнеке изд-ви, 2012. – 431 с.

## Р. МИҢНУЛЛИННЫҢ «КЫШКЫ КИЧ» ШИГЫРЕ
(русчага тәрҗемәсенә чагыштырма анализ)

*Хөҗҗәтова С., Актаныш,“Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат” ДАГУ, X сыйныф*
*Җит. – Әһлетдинова Л.Ф.*

Роберт Миңнуллин диюгә, иң элек күз алдыбызга балалар шагыйре килеп баса, ләкин ул зурлар турында да бик күп шигырьләр авторы. Аның шигъриятендә Ана-Әнкәй образына багышланган лирик шигырьләр аерым урын алып тора. Һәрбер кешенең күңелендә тулып йөргән хисләрне ул сүзләр белән әйтеп бирә алган. Шуңа да аның язган һәрбер сүзе, һәрбер юлы безгә якын, кадерле. Р. Миңнуллинның олы тормыш юлына басуына, поэзия дөньясына кереп китүенә әнисе Гөлҗәүһәр апаның роле чиксез зур. Иң мөһиме шул: ул улларын, кызын чын кеше булырга, тормышта үз урыннарын табарга, кыенлыклар алдында җебеп төшмәскә өйрәткән.

Шагыйрь үзе ни өчен бу образга еш мөрәҗәгать итүе турында болай ди: «Әнкәйләр турында нигә күп язасың?» − дип сорыйлар. Ничек җавап бирсәм дә тулы булмас кебек. Әнкәй белән генә үскәнгәдер, бәлки? Әллә инде Әнкәйнең безне – биш баланы – нинди авырлыклар, газаплар белән үстергәнен белгәнгәме икән? Аның олы җанлы, кече күңелле икәнен, акыллы, таләпчән һәм горур булуын аңлагангамы? Төгәл генә әйтә дә алмыйм» [2: 3].

Татар әдәбиятында ана образын чагылдыруның олы традициясе бар. Ә традиция бар икән, образның яңадан-яңа сыйфатларын табу, ана портретының яңа штрихларын сызу кыенлаша. Иҗатчының зур оста булуы шарт. Ирексездән сорау туа: шагыйрьнең яңа ана образын тудыруда яңалык нидән гыйбарәт?

Роберт Миңнуллинның ана образын тудыруда үз алымы бар, образны төрле яктан күрсәтергә тырыша: ул итәк тутырып бала үстерүче дә, күңелендә яшьлек ялкыны дөрләгән колхозчы да, киләчәк алдында үзенең җаваплылыгын дөрес аңлаган гади авыл хатыны да һ.б. Шулай

итеп, Ана, Туган җир һәм Ватан төшенчәләрен бер “ана” сүзенең асылына сыйдырырга омтылу – шагыйрьнең яңалыгы.

Аның һәр шигыре яңгырашлы һәм үзенчәлекле, шуңа күрәдер аның иҗатын бик яраталар. Шул шигырьләрнең берсе булып торган “Кышкы кичтә” шигырен тәрҗемәсе белән чагыштырыйк. ” В гостях у мамы” дип аталган бу шигырен Р.Кожевникова тәрҗемә иткән. Исеменнән күренгәнчә тәрҗемәче шигырьнең чын исемен язмыйча “В гостях у мамы” дип кенә куйган. Куелган максатыбызны тормышка ашыру өчен түбәндәге **бурычларны** билгеләдек: 1) тәрҗемә вариантта оригиналдагы эчтәлек бирелү дәрәҗәсен ачыклау; 2) телнең төрле катламларындагы үзенчәлекләрнең тәрҗемә вариантларда чагылышын тикшерү; 3) тропларның, тел-сурәтләү чаралырының тәрҗемәдәге чагылышын оригинал әсәр белән чагышытып карау; 4) ритм, рифма ярашуын тикшерү.

Куплетларның мәгънәсе тәрҗемәдә дә саклана. Автор Әнкәйнең әйткән сүзләрен бик дөрес итеп тәрҗемә итә. Бу ике куплетның тәрҗемәсен дә автор элеккегә кайту мәгънәсен ачып күрсәтә.

| | |
|---|---|
| Безгә таныш, безгә яшьтәш лампа,<br>Тик куыгы бераз чатнаган.<br>Ә шулай да яна. Ярый, Әнкәй ,<br>Кирәк булыр, диеп саклаган... | Нам это лампа сызмальство знакома<br>До трещинки на краешке стекла.<br>Круг света над столом, в родимом доме…<br>Как кстати мама лампу сберегла! |

Роберт Миңнуллин бу лампаны “безгә яшьтәш лампа” ди, Кожевникова да моны кулдан ычкындырмаска теләп, “это лампа сызмальство знакома” дип сурәтли.

| | |
|---|---|
| Ут сүнде дә, кинодагы кебек,<br>Малай чакка кайттык бу кичне.<br>Малай чакны яктыртты ул лампа,<br>Күңелләрдән күпме уй кичте... | Мы в этот вечер очутились в детстве,<br>Случайно, как бывает лишь в кино.<br>При тускловатом керосинном свете.<br>Мальчишество кнам юркнула в окно. |

Р. Миңнуллин шигырен: а, б, а, б буенча яза. Тәрҗемәдә исә шигырь: а, а, в, а. Димәк, иҗек саны буенча бу шигырьләр бер-берсеннән аерылалар.

| | |
|---|---|
| Өйдә – р \әхәт. Өйдә – ипи исе.<br>Ялкынланып ап-ак мич яна.<br>Мич – өйләрнең кайнар йөрәге ул,<br>Үзенә тарта безне мич яны. | Здесь вкусно пахнет<br>Хлебом деревенским,<br>И пляшут в печке языки огня …<br>Печь в доме, словно пламенное сердце,<br>Дом жив, покуда в нем жива она [2: 33]. |

Тәрҗемәчегә тәрҗемә итәсе әсәрнең телен генә түгел, авторның һәм образларның милләтен, мәдәниятен белергә кирәк. Р.Кожевникова нәкъ шулай эшли дә. Алпамыш белән Су анасы – татар әкиятләрендә еш очрый торган образ. Су иясе исә татар мифларында гына очрый.

Эшебезгә йомгак ясап, түбәндәге нәтиҗәләрне әйтергә кирәк:

1. Әлеге тәрҗемәдә тел-сурәтләү үзенчәлекләре, троплар үзгәрешсез чагыла. Безнеңчә, бу бик уңышлы. Әгәр тәрҗемә аларны катгый үзгәртүгә корса, әсәрнең милли калорины югалыр, автор стилен тою авыр булыр иде.

2. Рифмалашу үзенең үзенчәлекләрен сиздерә. Бу татар әдәбиятына хас

шигырь төзелешен рус әдәбиятына яраклаштыру авырлыгы белән аңлатыла.

3. Ритмга килгәндә, тәрҗемә үрнәгендә үзенең эчке гармониясен саклап кала алган. Шигырьләрдә бушлыкны тутыру яисә рифма өчен генә кулланган сүзләрне табу авыр, һәрбер сүзгә авторның тирән мәгънәсе яшерелгән.

4. "Су анасы" ялгызлык исеменә анализ ясаганда, берникадәр төрлелек сизелә. Бу авторның индивидуаль якын килүе белән аңлатыла.

5. Оригинал әсәрдәге троплар, тел-сурәтләү чаралары лаеклы эквивалентлар белән алмаштырылган, мәгънә ягы истә тотылып эш ителгән.

Күргәнебезчә, тәрҗемә үз заман таләпләренә буйсындырылып эшләнгән. Тәрҗемәченең стиле ул яшәгән, эш иткән заманга, иҗтимагый карашларына һәм шәхси мәнфәгатьләренә бәйле. Ләкин тәрҗемә әсәрләрен никадәр генә матур, төгәл дисәк тә, әсәрне автор язылган телдә аңлап укысаң гына чын асылына төшенә аласың. Димәк, моның өчен төрле телләрне камил белергә, төрле халыклар тарихын, гореф-гадәтләрен, авыз иҗатын өйрәнергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Миннуллин Р.М. Еще не вечер. – Казань: Тат. кн. изд., 2008. – 122 с.
2. Миннуллин Р.М. Когда душа тоскует… – Казань: Тат. кн. изд., 2004. – 155 с.

## ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ ШИГЪРИЯТЕ ҖЫРЛАРДА

*Шакирова Г., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Каюмова Г.Ф.*

Җыр – сәнгатьнең киң таралган, олылар да, яшьләр дә тарафыннан аеруча яратып башкарыла һәм тыңлана торган төре. Җыр – кешенең гомер юлдашы. Ул башкаручысының, тыңлаучысының күңел халәтенә тәэсир итә, кайгы-хәсрәтен җиңеләйтә, шатлык-куанычын уртаклаша, кәефен күтәрә.

Җырның сүзләрен профессиональ шагыйрь иҗат иткән булса, аларны әдәби җыр яки профессиональ җыр дип атыйлар. Димәк әлеге җыр төре булсын өчен, профессиональ язучы тарафыннан шигырь һәм композитор тарафыннан көй язылган булуы шарт. Халык күңеленә хуш килгән сурәттә, алар киң таралыш алып халыклашалар, ягъни әлегеге җырның кайчанда булса автор тарафыннан язылган булуы кешенең исеннән чыга. Бу исә халык җыры булып танылуга китерә һәм шагыйрьнең дә, копозиторның да эшенә иң югары бәя булып санала.

Шәүкәт Галиев халык тарафыннан, шундый югары дәрәҗәгә лаек булу бәхетенә ирешә. Югыйсә, ул иҗатын лирик шагыйрь буларак башлый. Аннары юмористик шигырьләр авторы, балалар язучысы буларак танылa. "Ә җырлары… Монысы үзе бер дөнья. Алар белән заман агышы да, вакыт җилләре дә хисаплашырлык. Чөнки халкыбыз берсен дә онытмый, түкми-чәчми җырлый бирә…" [2: 168].

Әдипнең шигырьләренә А. Ключарев, А. Сәйдәшев, Ә. Бакиров, Ә. Хәйретдинов, И. Хисамов, И. Якупов, К. Хөснуллин, Р. Зарипов,

Р. Курамшин, Р. Хәсәнов, С. Вәлиди, Ф. Әхмәдиев, Х. Вәлиуллин, Ш. Шәрифуллин һәм күп кенә башка күренекле композиторлар көйләр иҗат итәләр. Шул рәвешле шагыйрь иҗатын халык арасында танытуда зур өлеш кертәләр.

Халык күңеленә Ш. Галиев язган лирик җырларыннан мәхәббәт турында: “Тамчылар тамар чаклар” (Ф.Әхмәтов көе), “Күпме күзләр күреп онытылган” (Р. Гомәров һәм М. Яруллин көйләре), “Утыр әле яннарыма” (И. Хисамов), “Янып-көясем килә” (М. Яруллин көе), “Раушаниям бәгърем (В. Хәбисламов көе), “Шомырт чәчәкләре ак кына...” (Х. Вәлиуллин көе) дигәннәре кереп калган.

Әлеге җырларда сөюнең эчкерсез сафлыгы, гыйшык утының кайнарлыгы, югалту-сагышлары, кавышу шатлыклары, ягъни мәхәббәтнең бар асыл сыйфатлары урын ала. Әлеге җырларны башкарып, берәүләр сөйгән ярларына мәхәббәтен аңлата, икенчеләре исә йөрәк ярсуларын баса.

Аның җырлары гашыйклар тарафыннан гына түгел, ә даими рәвештә танылган җырчылар тарафыннан да сәхнәләрдән, радиолардан башкарыла. Мәсәлән, халык тарафыннан күптәннән татар халык җыры исемлегенә кертелгән “Утыр әле яннарыма” җырын – З. Басыйрова, Х. Бигичева, Г. Хәйруллина, А. Хабибуллина; “Тамчылар тамар чаклар” җырын – Ф. Сөләйманова, Фәридә-Алсу дуэты, “Саз” ансамбле; “Күпме күзләр күреп онытылган” җырын – Н. Нигъматуллин, “Саз” ансамбле; “Шомырт чәчәкләре ак кына...” җырын – З. Әхтәмова кебек танылган җырчылар башкара.

Һәркем Ш. Галиевның җырларында үзенең хис-кичерешләренә аваздаш таба. Аның “Гашыйк сүзе” дигән шигыре нәкъ шул турыда:

“Мәхәббәт җыры күп диләр,
Ышанмыйм күп дигәнгә,
Яхшы җырлар арту кая,
Җитми әле сөйгәндә! (...)
Уртача алганда бик күп
Җыр сыйдыра бер йөрәк,
Һәрбер гашыйк җан башына
Җыр җитештерү кирәк!” [1: 29].

Шулай ук, әдипнең туган якны сагыну хакында “Саумысыз арышларым!” (М. Шәмсетдинова көе), ирләрен сугышта югалткан тол хатыннарның моң-сагышлары турында “Ник яңара сагышлар” (Ф. Әхмәдиев көе), мәктәпне тәмамлап, зур тормыш юлына аяк басучы укучыларга багышланган “Кыңгыраулы мәктәп еллары” (Р. Хәсәнов һәм Х. Вәлиуллин көйләре) дип аталучы җырлары да бар.

Ш. Галиевның лирик шагыйрьләреннән тыш, композиторлар аның юмористик әсәрләрен дә үз итәләр. Шулардан: “Бар икән күрәселәр” (1958),

“Яр эзләдем, яр таптым” (1958), “Көлегез, көлегез!” (1958), “Гарантияле мәхәббәт” (1960), “Аннан-моннан” (1966), “Шалт мөхәммәтҗан!” (1968), “Озак яшәүнең сере” (1968) дигәннәрен әйтеп китәргә була.

Шулай ук, әдипнең балалар өчен язылган шаян җырларны әйтми китү мөмкин эш түгел. Әлеге җырлар арасында балалар күңеленә аеручa ятышлы: “Бикмулла” (1960), “Бииләр итек, читекләр” (1962), “Суда шуабыз” (1963), “Менә нинди чебиләр” (1963), “Кыңгыраулы бозау” (1980), “Колын бара каладан” (1980), “Үткенлек” (1980), “Кояшка карый” (1984) дигәннәре һәм башкалары да бар.

Шулай итеп, Шәүкәт Галиев үзенең иҗаты белән җыр сәнгатенә дә зур өлеш кертә. Халык күңелен үзенең мәхәббәт, туган ил турындагы җырлары белән моңландыра, уйландыра. Юмористик рухтагы җырлары белән моңайган кешенең күңелен күрә, кәефен күтәрә. Балалар өчен язган шаян җырлары белән сабыйлар күңеленә көйле шигырь ярдәмендә җырлап торып әхлакый тәрбия орлыкларын чәчүен дәвам итә.

**Әдәбият**


1. Галиев Ш.Г. Сайланма әсәрләр. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Т. 2. – 496 б.
2. Кәримов К. Шигъри хәтер // Казан утлары. – 2018. – № 11. – Б. 166–171.


## ОБРАЗЫ МАТЕРЕЙ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Ч. АЙТМАТОВА «МАТЕРИНСКОЕ ПОЛЕ» И М. КАРИМА «ДОЛГОЕ-ДОЛГОЕ ДЕТСТВО»


*Шамсутдинова Г., БГПУ им. М. Акмуллы, студент V курса*
*Науч. рук. – Галина Г.Г.*


В творчестве Чингиза Айтматова жанр повести занимает особое место. С начала 50-х годов в русской и киргизской литературе родились повести, способные осмыслять, анализировать послевоенную действительность. Герои произведения этого периода вырисовываются авторами более объемно, детально и реалистично. Главной темой повестей этого периода стало изображение военного детства, борьбы против фашизма в глубоком тылу. Среди таких произведений есть повесть Ч. Айтматова «Материнское поле» с ярко выраженной гуманистической и нравственной проблематикой. Это произведение сообщило о приходе в литературу писателя с глубоким пониманием мира, в произведениях которого киргизский и русскоязычный читатель мог найти ответы на «вечные вопросы» бытия, размышления о сущности человечности, актуальную гуманистическую проблематику.

Изучение образной системы повести Ч. Айтматова «Материнское поле» – актуальная задача современного литературоведения, так как в одном из первых произведений автора отражается национальный характер его творчества, начала философских и нравственных поисков великого писателя.

В нашем исследовании мы обратились к образу матери в произведении Ч. Айтматова в сопоставительном плане с героиней Оло Инэй в повести М. Карима «Долгое-долгое детство». Как известно, в литературоведении

творчество М. Карима и образная система их произведений изучена достаточно хорошо. Так, известными «айтматоведами» являются К. Асаналиев, А. Акматапиев, Г. Гачев, Е. Озмитель, А. Садыкова, Л. Укубаева, Ж. Бакашова, В. Воронова. Творчество М. Карима рассматривается в трудах Г. Хусаинова, Т. Кильмухаметова, М. Ломуновой, Д. Хренкова.

В повести «Материнское поле» Ч. Айтматов обратился к национальному характеру, средствами устного народного творчества он сумел рассказать историю вдовы – матери Толгонай.

«Материнское поле» – одна из самых трагических повестей Чингиза Айтматова. В ней писатель изобразил судьбу всего народа – того поколения, которое только что вошло во взрослую жизнь и тут же шагнуло в окопы, под пули (Касым, Маселбек, Джайнак), и тех, кто оставшись в тылу, трудился в поте лица для нужд фронта (Толгонай, Алиман). Повесть написана автором от первого лица, о своей жизни рассказывает сама главная героиня – мать Толгонай, вспоминая свои самые счастливые и самые страшные дни жизни. Но в ткань повествования Ч. Айтматов органично вплетает диалоги Толгонай и поля ее родины, с которым разговаривает мать. Такими диалогами начинается и завершается повесть. На фоне осенней грустной степи появляется образ старой женщины, повязанной белым платком, медленно идущей по опустевшему полю. По мнению В. Воронова, «эта живописная характеристика героини содержит трагические ноты, ибо уже в самом портрете Толгонай угадывается нечто драматическое. Чувствуется, что она знает высшую истину, о которой хочет поведать людям» [3: 87]. Эти пейзажные и портретные описания наполнены щемящей тоской, что-то трагическое скрывается в облике матери.

Ч. Айтматову для того, чтобы рассказать о судьбах миллионов людей, не нужна галерея образов, центральная фигура повести – образ матери доносит до нас правду о страшной войне. Толгонай рассказывает о своей любви, о тех радостях, которые она принесла собой, о рождении трех сыновей, о счастливой жизни с мужем Суванкулом. Но в ее монологе больше грустного, трагического ощущения бытия.

Война не изображена в повести Ч. Айтматова, мы не видим в «Материнском поле» ни военных действий, ни приготовлений к ним. Но война незримо присутствует в каждом шаге Толгонай, в ее рассказах. Она словно спрятана «за кадром», на заднем плане тех картин, которые рисует нам писатель.

Отдельные эпизоды повести дают представление не только о тяжелой жизни и труде в тылу, но и о жестокости самой войны. Одной из таких сцен является встреча Толгонай и Алиман с Маселбеком, встречи мимолетной, во время которой Маселбек только успел выглянуть с вагона и бросить матери свою солдатскую ушанку.

Важное место в произведении занимают сцены хождения Толгонай по домам односельчан с целью собрать последние килограммы семян и засеять маленький участок земли. С бричкой обходила она дворы многодетных семей и так уже голодающих, которые, тем не менее, отрывая от сердца, отдавали ей последние горстки семян. В описании этих картин автор снова проявил себя как мастер психологического описания.

Разговоры Толгонай с полем приобретают в повести символическое значение. Автор обратился к народным традициям, фольклорному творчеству киргизского народа. Как отмечает Ж.К. Бакашов, «диалоги матери с полем часто опережают события, о которых впоследствии рассказывает Толгонай, готовит читателя к ретроспективному изображению довоенных, военных и послевоенных лет. Символика материнского поля раскрывает внутреннюю печаль героини, горесть вдовы, но в то же время природа утешает ее, сочувствует ей, терпеливо слушает ее рассказы, что пережито и что навсегда запечатлелось в памяти матери» [2: 45].

«Материнское поле» – это атмосфера добра и справедливости, беззаветной материнской любви и постоянной заботы о детях и их судьбах. «Материнским полем» назвал Чингиз Айтматов свою повесть. Образ матери в произведениях Айтматова как драгоценный камень сверкает и переливается своими чудодейственными гранями. Солдатская мать Толгонай – героиня повести – приходит в поле и вспоминает свою жизнь, полную радости и печали, труда и забот, свидетелем которой было ее поле:

«Вот так я мечтала сама с собой, и звезды мечтали вместе со мной, и мне вдруг так захотелось, чтоб все это сбылось, и тогда я в первый раз обратилась к матери-земле с человеческой речью. Я сказала: «Земля, ты держишь всех нас на своей груди; если ты не дашь нам счастья, то зачем тебе быть землей, а нам зачем рождаться на свет. Мы – твои дети, земля, дай нам счастья, сделай нас счастливыми!» [1: 45].

Полю поведала мать о своих заботах и тревогах, ему она рассказала обо всей своей жизни. Материнское сердце помнило все. Перед ее глазами оживали счастливые дни ее молодости, когда сыновья впервые вышли работать с отцом в поле. Тяжело было вспоминать Толгонай о страшной войне, которая унесла жизнь трех ее сыновей и мужа. Горькая скорбь о погибших легла тяжкой ножей на сердце матери: «Сын мой, обидно мне, что из двенадцати цветов жизни ты не сорвал ни одного. Ты только начинал жить, и я даже не знаю, какую девушку ты любил… Последняя свеча горит в душе моей, скоро она погаснет. Но я все помню, помню и тот злосчастный день…» [1: 67].

В повести Ч. Айтматова образ матери Толгонай предстал перед читателем в облике сложившейся личности. Мы видим сформировавшийся женский характер, стойкость и силу женщины-вдовы, пережившей страшную войну.

Толгонай видит в земле вместилище народной мудрости, терпения, памяти. Она ощущает свою неразрывную связь с нею, испытывает потребность в частом контакте с природой, ибо земля наделена в повести Ч. Айтматова человеческими чертами, она не только любит, тоскует и помнит, как люди, но и страдает от войн. Они отнимают у матери-земли ее детей. Символика матери-земли дополняет образ Толгонай, в них проявляется народная мудрость и мировидение. Ч. Айтматов показал национальный характер не только в лице конкретной героини, но и всего народа. Во взаимодействии Толгонай с народом есть удивительная гармония, которая позволяет матери-вдове обрести внутреннее спокойствие. В то же время, Толгонай остается личностью глубоко трагичной.

Башкирская литература, наряду с киргизской литературой, создала величайшие образы матерей, которые несли в себе вековую мудрость, своеобразные этнические культурные черты народа. Образ Оло Инэй в произведении Мустая Карима «Долгое-долгое детство», как нравственный идеал, во многом похож на героиню Толгонай в повести Чингиза Айтматова «Материнское поле».

В отличие от Мустая Карима, Чингиз Айтматов главной героиней своей повести выбрал представителя простого народа – мать-крестьянку. В повести глубокие размышления героини сочетаются с психологическим анализом ситуации войны, что характеризует глубокий лирико-философский тон произведения. В этом «Материнское поле» во многом похоже на повесть М. Карима «Долгое-долгое детство», где основным героем становится сам автор и его размышления. Однако, героиня Толгонай в «Материнском поле» – первое лицо, ее душевные переживания и чаяния возвышают в ней общематеринские черты.

В отличие от Толгонай, образ Оло Инэй концептуализирует общие нравственные черты мудрой женщины в религиозной народной культуре. В повести М. Карима нравственные ценности отождествляются с образом Оло Инэй. Оло Инэй – «повитуха и величайший нравственный авторитет аула, женщина редкостного житейского такта. Не оскудевает и ее доброта, распространяющаяся далеко за пределы собственной, живущей еще по законам шариата семьи. Она всегда готова прийти на помощь соседям делом или своевременной, ненавязчивой подсказкой» [4: 54].

Роль Оло Инэй, в отличие от Толгонай, не ограничилась пределами семьи. Она – повитуха, участвует в воспитании всех детей, которых сама приняла. Оло Инэй воплощает в себе прекрасные черты башкирской женщины-мусульманки, выявляя душевное состояние своих окружающих, оберегала их от осуждений, от бед, оказывая им милосердие. Оло Инэй, в отличие от Толгонай, несет в себе религиозные нравственные ценности: «Будьте добры друг к другу – и сами с добром будете» [4: 250]. Если Толгонай – со-

бирательный образ советской женщины-крестьянки, то М. Карим в образе Оло Инэй изображает национальные ценности башкирского народа, выраженные в культе повитух, преданности обычаям и верованиям.

Таким образом, Толгонай и Оло Инэй входят в образную галерею повестей Чингиза Айтматова и Мустая Карима как носительницы материнского начала. Ч. Айтматов в этой повести через образ матери задумался о трагических последствиях войны, судьбами народа. Судьба киргизской крестьянки, потерявшей в войне мужа и сыновей, взявшей на себя управление колхозом, выстоявшей во всех бедах и вырастившей не родного ей по крови внука стала откровением для всей советской литературы. Жизнь Толгонай была подвигом, как жизнь тысячи других солдатских матерей-тружениц.

**Литература**

1. Айтматов Ч. Материнское поле. – М.: Просвещение, 1988. – 257 с.
2. Бакашова Ж.К. Художественное мастерство Ч. Айтматова. – Бишкек, 1998. – 147 с.
3. Воронов В. Чингиз Айтматов «Очерк творчества». – М., 1976. – 250 с.
4. Карим М. Долгое-долгое детство. – Уфа: Китап, 1995. – 371 с.
5. Хусаинов Г.Б. Мустай Карим. – Уфа: Китап, 1994.– 487 с.

## МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫНДА ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЛАРЫ БИРЕЛЕШЕ

*Шаһабиева Й., КФУ, II курс студенты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Сәйфуллина Ф.С.*

Мәгърифәтчелек чоры – кешелек дөньясы тарихында фәнни, фәлсәфи һәм иҗтимагый фикер үсешенә тәэсир ясаган иң әһәмиятле чорларның берсе. Әсәрләр аша кешеләр рухи кыйммәтләрнең мөһимлеген аңлый башлыйлар. Мәгърифәтчеләр әдәбиятны яңа буын тәрбияли алучы корал итеп күзаллыйлар. Бу чор әдәби әсәр үзәгенә куелган тема, проблема һәм идеяләр башка яссылыкта карала башлыйлар. Гасырлар буе сөйләнелгән тышкы матурлык арткы планга кала, аның урынына рухи дөнья, аң-белемле шәхес образлары килеп баса. Барыннан да бигрәк, хатын-кыз образы башка яссылыкта карала башлый. Мәгърифәтчелек чорында хатын-кыз үзенең чибәрлеге белән генә егет күңелен яулап алучы түгел, ә нәкъ менә белемле, зыялы, күңеле белән матур зат буларак сурәтләнә башлый.

Һәр халыкның әдәбиятына да мәгърифәтчелек реализмы чоры хас. Әмма аларның барысында да үзләренә генә туры килә торган үзенчәлекләр чагылыш таба. Мәсәлән, шул ук хатын-кыз образы гына да төрле халык әдәбиятында төрлечә гәүдәләнеш ала.

Татар халкының күренекле язучысы Фатих Кәриминең “Морза кызы Фатыйма” повесте мәгърифәтчелек реализмы кануннарына туры китереп, шул вакытның реаль вакыйгаларына нигезләнеп языла. Язучы әлеге повесть сюжетын Исмәгыйль Гаспралының эти-әнисе тормышыннан

ала. Әлеге әсәрдә татар морзалары тормышы яктыртыла. Бигрәк тә хатын-кыз образы уңай яктан гәүдәләнеш таба. Фатыйма – әсәрдә уңай герой буларак сурәтләнә. Ә романтик рухлы әсәрләрдә бу тип геройлар гадәттә рухи иреккә омтылалар. Фатыйма – татарча һәм русча укыган, яхшы тәрбия алган морза кызы. Ул – үз максатларына ирешер өчен кыю адымнар белән киләчәккә атлый. Туып үскән җирен, якыннарын ташлап, үз бәхете өчен көрәшергә, ягъни чит җирләргә китәргә дә әзер. Сөйгәне Мостафа белән ерак Истанбул җирләренә юл тотканда ул бик көчле рухлы итеп сурәтләнсә дә, романтик әсәрләргә хас рәвештә сентименталь итеп тә бирелә. Фатыйма, бик моңсуланып, әти-әнисе өчен борчылып, туган җире белән саубуллаша. Туташ – үзенең хисләрен башкаларга җиткерергә курыкмый. Тик, шул ук вакытта, тыйнаклык та саклый белә. Моны автор яшь кызны чапаннарга да төренеп йөрми, шул ук вакытта һәр “кешегә көлеп, күз кысып китә торган Казан вә Оренбург хатыннарының бәгъзеләре кебек, тәрбиясезлек вә әдәпсезлек тә күрсәтми” дип искәртеп китә. Гомумән алганда, төп герой идеаллаштырылып сурәтләнә.

Рус мәгърифәтчелек чорының классик үрнәге булган, шулай ук сентименталь рухта язылган “Мескен Лиза” (Бедная Лиза) әсәрен алсак та, анда төп герой буларак хатын-кыз – Лиза образы чагылдырыла. Иң беренче чиратта, Лиза – Фатыйманың капма-каршысы. Ул – гади авыл кызы, әнисе белән ярлы тормышта яши. Белеме турында бер сүз дә әйтелми, тик әлеге әсәр герое бик тырыш, бар эшкә дә ризалашып, гаиләсен туендыра. Үз якыннары өчен җан ата, шул ук вакытта Лиза мәхәббәтле һәм беркатлы итеп сурәтләнә. Аның эчке дөньясының матурлыгы идеаллаштырыла. Ул үз-үзенә кул салыр алдыннан да, иң беренче чиратта, гаиләсе турында уйлый һәм аларга акча калдыра. Рус кызы Лизаның мәхәббәте татар морзасы кызы Фатыйманыкы белән чагыштырганда капма-каршы булып чыга.

Ә татар халкына кардәш булган төрек әдәбияты мисалында хатын-кыз образы нинди гәүдәләнеш ала соң? Төрек мәгърифәтчелек әдәбиятында хатын-кыз образы иң көчле булып яктыртылган әсәр ул – Нәмыкъ Кемальнең “Гөлнихәл” (Gülnihal) пьесасы. Әлеге әсәрдә рус һәм татар әдәбиятларыннан аермалы буларак, мәхәббәт утларында янучы яшь кыз үзәккә алынмый. Киресенчә, инде тормышны күргән тәрбияче хатын образы бирелә. Рус әдәбияты герое Лиза кебек Гөлнихәл дә ярлы, әмма бик көчле рухлы. Татар һәм рус әсәрләре белән чагыштырып карасак, төрек әдәбияты мисалында хатын-кыз кеше бәхете, ягъни яшь кыз – Исмәтнең бәхете өчен көрәшә. Әлеге яшь кызның сөйгәне Мохтарны төрмәдән коткарыр өчен, Гөлнихәл ялганга бара, аңа мәҗбүри рәвештә явыз Каплан-паша белән никах укыта. Ә соңрак бар халыкка җәбер күрсәтүче Капланга каршы чыгып, фетнә күтәрә һәм ике парны кавыштыра. Әмма үзе Каплан-

пашаның кылычы астына эләгеп һәлак була. Бу очракта авторның фикере кеше гомеренең фаҗигасе аша яхшылык белән яманны эзләвеннән генә түгел, ә җәмгыятьтәге гаделсез шартларны фаш итүеннән дә гыйбарәт. Гөлнихәл образында – төрек хатын-кызының иң югары сыйфатлары тасвирланган: батырлык, чын мәгънәсендә ярату һәм нәфрәт. Гөлнихәл өчен гаделлекнең иң югары дәрәҗәсе хас. Алда китерелгән әсәрләр белән чагыштырганда, төрек әдәбиятында хатын-кыз образы, гомумән, башка аспектта яктыртыла.

Шул рәвешле, Мәгърифәтчелек әдәбиятында хатын-кыз образының күтәрелеше – халыкны мәгърифәтлеккә өндәүдә, аларның мәдәниятләрен арттыруда ярдәм итәчәк дип фаразлыйлар. Татар әдәбияты мисалында ул – белемле, үз бәхете өчен көрәшүче морза кызы булса, рус һәм төрек әдәбиятында белемгә аның кадәр игътибар бирелми, рус әдәбияты героена артык хискә бирелүчәнлек һәм эш сөючәнлек хас. Ул да үз бәхете өчен көрәшә, әмма әсәр аяныч хәл белән тәмамлана. Ә инде төрек әдәбияты үрнәгенең төп герое Гөлнихәл, киресенчә, кеше бәхете өчен бар көчен җигә, шул ук вакытта ул белеме булмаса да, татар кызы белән охшаш рәвештә бик тирән фикер йөртүче, зирәк була.

Әмма шулай да әлеге әсәрләрдәге хатын-кыз образларын берләштерүче сыйфат ул – көчле рухлы һәм киң күңелле булулары. Нәкъ менә көчле рух белән алар кискен адымнар ясыйлар. Ә киң күңеллелек белән башкаларның да йөрәкләренә үтеп керәләр.

**Әдәбият**

1. Карамзин Н.М. Бедная Лиза (сборник) – «Public Domian»., 1792. – 102 с.
2. Кәрими Ф.Г. Морза кызы Фатыйма. – Казан: Татар. кит нәшр., 1996. – 414 б.
3. Namık K. Gülnihal. – Milli eğtim basımevi., 1989. – 162с.

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА ӘХЛАК ТЕМАСЫ

*Шәйхетдинова З., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Каюмова Г.Ф.*

Милли педагогикабызда әхлак “кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр калыбы, кысасы һәм мәсләкләре тупланмасы” [3: 116] дип аңлатыла. Матур әдәбиятның тәрбияви потенциалы гаҗәеп зур. Нәкъ менә әдәбият баланың интеллектына, хисләренә, иҗади фантазиясенә берьюлы тәэсир ясап, дөньяга караш, мораль йөз, эстетик зәвык, изгелек һәм явызлыкка мөнәсәбәтләрен формалаштыра. Шигырьләре педагогик миниатюра буларак бәяләнергә хаклы булган Роберт Миңнуллин иҗаты – баланы зур тормышка намус белән аяк басарга өйрәтүдә алыштыргысыз табыш ул.

Балалар һәм хайваннар арасындагы дуслык, бер-берсен аңлау сәләтләре әдәбиятта еш сурәтләнә. Мондый әсәрләр шәфкатьлелек, ярдәмчеллек кебек сыйфатлар тәрбияли. Роберт Миңнуллинның “Әни, мин

көчек күрдем!” шигырендәге бала әнә шул сыйфатлары белән үзенә тарта. Ул, яңгыр астында дер-дер калтыранып утырган көчекне кызганып, әнисеннән аны өйгә алып керергә рөхсәт сорап ялына. “Дустымны эзлим” шигыренең герое да дустын югалкан, шуның өчен бик кайгыра, күрүче булса, сөяк биреп китүләрен, хәбәр итүләрен үтенә.

Мәктәп – балачак яшәешенең аерылгысыз өлеше. Белем йортлары элек-электән татарларда изге, мөкатдәс саналса да, хәзер мәктәпнең кыйммәтен кире кагу очраклары да юк түгел, шулай ук телеэкраннарда да мәктәп һәрдаим уңай яктан гына тасвирланмый. Бу яктан Роберт Миңнуллин шигырьләренең тәрбияви көченнән файдаланырга кирәк. Мәсәлән, “Дәрестә” шигыренең герое дәресләрдә бөтенесен белеп калырга омтыла, көчне кызганмаска өнди:

*Мәсьәләләр чишелми дип*
*Куркып торaламы соң?*
*Икелегә я өчлегә*
*Укып торaлармы соң?* [1: 163].

Әдип тырышлык, эш сөючәнлек сыйфатларын тәрбияләүне күздә тоткан әсәрләр дә иҗат итә. “Бәрәңге алышабыз” шигырендәге геройлар яңгыр яву, салкын җил исүгә карамастан, басуда олыларга бәрәңге алышалар. Алар моны ихластан, бар тырышлыкларын җыеп эшлиләр, хезмәтләре белән горурланалар.

Роберт Миңнуллин шигырьләрендә даими рәвештә үткәрелә торган фикерләрнең тагын берсе – гаиләдә бер генә бала булырга тиеш түгел (“Энекәш кирәк миңа!”). Мәгълүм, безнең әби-бабаларыбыз унар бала тапкан очраклар да сирәк булмаган. Мондый мохит баланы мөстәкыйльлеккә, ярдәмчеллеккә өйрәтә. Әлбәттә, шагыйрь хәзерге заман шартларын, җәмгыятьтәге үзгәрешләрне яхшы аңлап, бер-бер артлы бала алып кайтуны пропагандаламый, әмма сеңел-энеләр, абый-апалар арасында үскән баланың шәхес буларак иртәрәк җитлегүен, аның нормаль үсеше өчен туганлык җепләре белән бәйләнгән балаларның әһәмиятен ассызыклап үтә.

Роберт Миңнуллин шигырьләре мөһим париотик тәрбия бирү вазифасын да башкаралар. Туган илгә мәхәббәт әдипнең “Туган илнең улы мин”, “Кунакка килегез” кебек шигырьләрендә чагыла.

Роберт Миңнуллинның балалар өчен шигъриятенең үзенчәлеге – балаларның битараф булмавы, гамьлелекләренең даими ассызыклануы. Тормыштагы куркыныч картиналар, сугыш фаҗигаләре, гомумән, аяныч чынбарлык аларны кырыс та, гадел дә булырга өйрәткән. Менә кечкенә герой сугыша гына белә торган генералларны барысын да кеше аягы басмый торган утрауга илтеп ташларга хыяллана:

“*Куркып тормас идем әле*
*Мин аларның каршында –*

*Бушатыр идем утрауга*

*Мин аларның барсын да*” [2: 147], – дип яза батыр герой.

Моңа охшаш мотивлар шагыйрьнең күп кенә шигырьләрендә чагылыш таба: “Астронавт абыйга хат” шигырендәге “Мин” галәмгә очучы абыйларга бер тәкъдим белән килә: дөньядагы барлык бомбаларны Марска яисә Айга илтеп ташларга кирәк; “Ак кәгазь бите” шигырендә кечкенә герой буш кәгазь һәм бомба шартлаганнан соң калган бушлыкны янәшә куя; “Авыру йоксын иде” шигырендә автор нәни герое авызыннан бомбаларга “йогышлы бер авыру йоксын иде” дип теләк белдерә, чөнки бу очракта кешеләр бомбаларга кагылырга, аларны хәрәкәткә китерергә җөрьәт итмәячәкләр, дип уйлый; “Яшәү рәхәт түгелмени” әсәренең каһарманы өлкәннәрдән бомбаларны яшереп куюларын үтенә һәм сүзләрен гади дә, фәлсәфи дә сүзләр белән тәмамлый:

*Ясамагыз яңа бомба,*

*Кызыгып кара данга.*

*Яшәү рәхәт түгелмени*

*Үлүгә караганда*? [2: 147].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Роберт Миңнуллин иҗатында әхлак темасы шактый киң урын ала. Әдип шигырьләре балаларда кызыксынучанлык тәрбиялиләр, битараф, ваемсыз буын үсүгә каршы чыгалар. Әдип бигрәк тә белемгә омтылучы, тырыш, ватанпәрвәр шәхесләр тәрбияләүне әһәмиятле дип карый, әсәрләрендә шул әхлакый сыйфатларны пропагандалый.

**Әдәбият**

1. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. 7 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Т. 3. – 543 б.

2. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. 7 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Т. 4. – 528 б.

3. Шәймәрданов М.Х. Татар милли педагогикасы: югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ АВАЗЛАР ЧИРАТЛАШУЫНЫҢ ӨЙРӘНЕЛҮ ТАРИХЫ

*Шәнгәрәева А., КФУ, I курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Саттарова М.Р.*

Телдән сөйләм электән үк кешеләрне кызыксындырган. Шуңа бәйле, фонетика, тел белеменең авазларны, аларга хас булган закончалыклы күренешләрне өйрәнүче тармагы, грамматика, лексикологиягә чаклы барлыкка килгән борынгы фән булып тора. Хәзерге көндә фонетика әдәби телдә дөрес сөйләү, сөйләм культурасы, чит телләр укуда кирәк. Фонетика фәне үз алдына күптөрле бурычлар куя, шуларның берсе – телдәге аваз үзгәрешләрен һәм шул үзгәрешләрнең сәбәбен ачыклау. Телдәге аваз үзгәрешләре төрле сәбәпләр аркасында барлыкка килә, моңа тышкы һәм телнең үзендәге эчке факторлары йогынты ясый. Гомумән, барлык аваз үзгәрешләре комбинатор һәм позицион төрләргә

бүленәләр. Комбинатор үзгәрешләр – төрле комбинацияләрдә килгәндә, авазларның бер-берсенә тәэсир итешү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган аваз үзгәрешләре. Мондый төр үзгәрешләргә ассимиляция, аккомодация, диссимиляция керә. Ассимиляция процессы йогынтысында чиратлашу барлыкка килә – бер морфема составындагы төрле авазларның теге яки бу кагыйдә нигезендә тәңгәлләшүе.

Аваз чиратлашулары, гомумән, татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К. Насыйриның «Кыскача татар грамматикасы»нда күренәләр. Анда аваз чиратлашулары, авазларның үзара тәэсир итешүләре, сүз басымы кебек мәсьәләләр карала.

Г. Алпаровның 1926 елда басылган «Шәкли нигездә татар грамматикасы» исемле китабы татар авазларын чын фәнни нигездә тасвирлап бирүче хезмәт булып тора. Анда аваз үзгәрешләре, ассимиляция, орфоэпиянең кайбер мәсьәләләре аерым-аерым карала. Ү.Ш. Байчураның «Татар теленең аваз төзелеше» исемле монографиясе, тел белгечләре фикеренчә, фонетистлар таяна алырлык, чын мәгънәсендә фәнни чыганак булып тора. Хезмәтнең икенче кисәгендә аваз үзгәрешләре, тартыкларның акустик билгеләре, сүз басымының үзенчәлекләре кебек мәсьәләләр карала. 1969 елда рус телендә басылган «Хәзерге татар әдәби теле» исемле китапта да татар теленең фонетик системасы тулы гына яктыртылган. Татар фонетикасына багышланган иң соңгы хезмәтләрдән Х.Х. Сәлимовның тикшеренүләрен атарга була. Автор, беренче мәртәбә спектраль анализ методын кулланып, татар вокализмын тикшерә, алынган мәгълүматларга таянып, татар сузыкларын акустик яктан тасвирлый, аларны рус һәм кайбер төрки телләрнең авазлары белән чагыштыра, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләренең төрләрен ачыклый.

Тартык авазларның чиратлашуына карата галим Л. Яфаров: “Татар телендә, шул ук вакытта башка төрки телләрдә дә, саңгырауларның яңгыраулаша баруы эпохалар буена килгән үсеш, үзгәреш һәм камилләшү процессы буларак, телдәге күп кенә тарихи фактлар белән исбатлана”,- дип яза. Ләкин шуны әйтергә кирәк, телебездә саңгырау тартыкларның яңгыраулашулары белән беррәттән, яңгырау тартыкларның саңгыраулашулары да күзәтелә:

Ерак җирдә имәсмен мән,
Дәгел шам я мәддинле (Г. Кандалый).

Иске төрки телдә һәм иске әдәби телебездә “б” тартыгы “м” тартыгына караганда күбрәк кулланылган. Милли әдәби телебез нормалашкан чорда бик күп сүзләрдә “б” тартыгы “м” белән алмашынган. Мәсәлән, бәңа, бәнем, бән, бондан, бәне сүзләре хәзерге әдәби телебездә миңа, минем, мин, моннан, мине формасында кулланылып йөриләр. Бу мисаллардан күренгәнчә әдәби телебезнең камилләшү процессында “м” тартыгы “б” тартыгына карата активлык күрсәткән

күп очракларда аны алыштырган. Бу авазларның әйтелешләренә карата Л. Җәләй: “Бу авазларның артикуляцион базалары бер-берсенә бик якын. “М” иреннәрнең бикләнүе, “б” исә, киресенчә, бикләнгән иреннәрнең кинәт ачылуы белән ясала”, – дип язды. Шулай итеп, “б” авазын әйткәндә, йомык иреннәр кинәт кенә ачыла да, авыз куышлыгындагы һава чагыштырмача зур көч белән атылып тирәлеккә чыга, тыштагы һавага чагыштырмача зур басым ясый.

Башкорт тел белемендә аваз чиратлашу, ул да түгел фонетика буенча беренче җитди хезмәтләр галим Д.Г. Киекбаев исеме белән бәйле. Бу чорда төп резонанс ҙ һәм ç авазлары тирәсендә кайнаган. Башкорт телендә «һ», «ç» и «ҙ» специфик тартыкларының килеп чыгышы галим М. Рясянен (1962), Б.А. Серебренникова (1963, 1972) фәнни хезмәтләрендә, Ш.В. Нафиков (2003) монографиясендә күрсәтелә. Т.Г. Баишев башкорт телендәге [һ] авазының килеп чыгышын монгол телләренең йогынтысы белән бәйли [4: 22–23]. Башкорт теленең казах, татар, себер татарлары, удмурт, марый телләре белән лингвоэтник бәйләнешләре бар. Башкорт диалектларына күптөрле чиратлашу вариантлары хас: т –д – з (ҙ) – й, й ~ ж ~ з ~ д~ с, ҙ ~ д ~ з ~ с ~ й һ. б. Башкорт теле грамматикасына зур өлеш керткән галим Н.К. Дмитриев “Грамматика башкирского языка” монографиясендә авазлар чиратлашуы мәсьәләсенә аерым бүлекчә багышлый. Әлеге хезмәтендә ул п,т, к, къ саңгырауларының б, г, гъ яңгыраулары белән чиратлашу мәсьәләсен карый, түбәндәге мисаллар китерә: сап-сабы, аяк-аягъы, һ.б. Монда ул искәрмәләр дә китерә: әйтелешләре белән язылышлары туры килгән рус алынмаларында яңгыраулыкта-саңгыраулыкта чиратлашу күзәтелми (“клуб”, “доклад”). Шулай итеп, чиратлашу күренешен Дмитриев мәҗбүри характерга ия ди, әдәби норма буларак, орфографиядә чагылуын табигый күренеш, дип яза. Авазлар чиратлашу мәсьәләсе, без карап үткән ике тел белемендә дә әлегә ачык булып кала.

**Әдәбият**

1. Дитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М.: Изд-во АН СССР, 1948. – 275 с.
2. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казань: Тат. кн. издат,1954. – 68 б.
3. Щербак А. Сравнительная фонетика тюркских языков. – Л.: Наука, 1970. – 204 с.
4. Яфаров Л. Татар теле фонетикасының кайбер закончалыклы тенденцияләре. – Казан, 1955. – 264 б.

## «ЛӘҺҖӘИ ТАТАРИ» СҮЗЛЕГЕНДӘГЕ ҺӨНӘР АТАМАЛАРЫ

*Шәнәр С., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Юсупова А.Ш.*

«Ләһҗәи татари» – татар телендәге беренче аңлатмалы сүзлек. Сүзлек ике томнан тора. Беренче том – 1892 нче елда, икенче том 1895 нче елда басылып чыккан. Сүзлекнең ике томы да Казанда Университет типолитографиясендә басылганнар. Беренче том – 226 бит, икенчесе 157 биттән

тора. Беренче том ‘әлиф’ хәрефе белән башлап ‘сад’ хәрефе белән бетә. Ә икенче том ‘зад’ хәрефе белән башланып, ‘йай’ хәрефе белән бетә.

«Ләһҗәи татари» татар халык сөйләм теле лексикасын эченә алган сүзлек булып санала. Чөнки сүзлектә әдәби телдә булмаган диалекталь сүзләр, жаргоннар юк. К. Насыйри «Ләһҗәи татари» сүзлеген төзүнең максаты – татар әдәби теленең лексикасын җыю, системалаштыру һәм сүзләрнең барлык мәгънәләрен теркәү. Сүзлектә сүзләрнең лексик-семантик, стилистик яктан куллану үзенчәлекләре күрсәтелә. «Ләһҗәи татари»да фразеологизмнар, сүзләргә грамматик һәм этимологик тасвирламаларны күрә алабыз.

Сүзлектә 7043 чамасы сүз бар. Алардан 1601 сүз татар теленә башка телләдән кергән алынма сүзләр булып тора. Алынма сүзләр *гарәп, фарсы, рус* һәм *грек* телләреннән алынган. «Ләһҗәи татари»дә 1089 гарәп, 488 фарсы, 21 рус, 3 грек алынмасы бар.

К. Насыйри сүзлеге төзелгәндә борынгы төрки телдән килгән, саф татарча сүзләргә мөһим урын бирелгән. Сүзлектә 92 һөнәр исеме бар. Һөнәр атамалары нигездә борынгы төрки телдән килгән сүзләр. Мәсәлән, *алтунчы, арбачы, балчы, балтачы, буяучы, чүлмәкче, икмәкче, әлче, күмерче, көмешче, тәрбияче, юрганчы, бакырчы, укучы, укытучы* сүзләре татар теленең лексик-семантик, стилистик байлыгын күрсәтә. Шушы сүзләрдә исем ясау өчен кулланылган борынгы төрки телдән килгән *–чы/-че* кушымчалары белән һөнәр исемнәре ясалган. Мәсәлән "алтун" сүзенә *-чы* кушымчасы килеп аннары сүз һөнәр атамасы булган. Башка бер үрнәктә "әлче" сүзен караганда "ил" (дәүләт) сүзе "әл" булып чиратлашкан, *-че* кушымчасы белән кушылып һөнәр атамасы булып чыккан. Хәзерге татар телендә дә һөнәр исеме ясау өчен *-чы/-че* кушымчалары кулланыла. Сүзлектәге кушымчаларның барысы да турыдан туры төрекчә сүзгә кушылмаган. Мәсәлән "хезмәтче" сүзе гарәп теленнән кергән хезмәт сүзенә *-че* кушымчасы кушылып яңа исем булган. Гарәп телленнән *хадим, касаб, тәрҗүман, җасус* кебек сүзләр сүзлеккә кертелгән. *Хадим* сүзе хезмәтче мәгънәсендә кулланылган. Хәзерге татар телендә кулланылмый. *Касаб* сүзе ит сатучы кешене аңлата. Хәзерге татар телендә бу сүз урынына итче сүзе кулланыла. *Касаб* сүзен төрек телендә "б-п" үзгәреше белән "касап" буларак очратабыз. К. Насыйри сүзлектә "тәржүман" сүзен биреп *тәрҗемәче, телмач –тилмач, мөтәрҗим* язган. Бу сүзләрдән тәрҗемәче сүзе хәзерге татар телендә кулланыла. Телмач – тилмач сүзе борынгы төрки телдән килгән. Мөтәрҗим сүзе гарәпчә тәрҗемә сүзеннән ясалган сүз булып төрек телендә тәрҗемәче мәгънәсендә ешрак кулланыла. Җасус сүзен хәзерге татар телендә очратмыйбыз, аның урынына "шымчы" сүзе кулланыла.

Йомгак ясап әйткәндә, «Ләһҗәи татари» сүзлегендә К. Насыйри күбесенчә татарча әдәби һәм халык телендә кулланылган сүзләргә игътибар иткән. Сүзлекнең XIX гасыр ахырында төзелгән булуы анда гарәп теленнән кергән алынмаларның күп булуын күрсәтә. Ә һөнәр атамаларының саф татарча берелүе бу атамаларның телдә актив булуы турында сөйли. Аларда борынгы төрки телдәге лексик-семантик үзенчәлекләргә очрыйбыз. Моннан чыгып, К. Насыйриның, борынгы төрки телгә нигезләп, татар әдәби теле булдыру максаты белән эшләве аңлашыла.

**Әдәбият**

1. Батыршина Г.Г. Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. – Казан, 2007. – Б. 171.

2. Хангилдин В.Н. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри – 1825–1945. – Казан, 1948. – Б. 78–91.

3. Юсупова А.Ш. Вклад Каюма Насыри в создании татарско-русских и русско-татарских словарей // Востоковедение в России и странах СНГ на рубеже веков. – Казань, 2015. С. 152–159.

4) ناسدری ق.لهجه تاتاری.دلج۱ـ. نازق، ۱۸۹۵.ـ۲۲٦ ب.

5) ناسدری ق.لهجه تاتاری.دلج۱ـ. نازق، ۱۸۹٦.ـ۱۰٤ ب.

6) Öner M.,Kaya M. Y., Özşahin M. Lehçe-i Tatarî'nın Söz Varlığı Üzerıne Bır Deneme // Ученые записки Таврического национального университета им. В.И. Вернадского. Серия «Филология. Социальные коммуникации». – Т. 23 (62). – № 3. – 2010. – С. 9–19.

## САРМАН АВЫЛЫ ЭРГОНИМНАРЫ

*Шәрипова З., Сарман р-ны Сарман гимназиясе, X сыйныф*

*Җит. – Мәтҗанова Р.Г.*

Тел белеменең ономастика дип атала торган бер тармагы бар. Бу фәннең тикшеренү өлкәсе бик бай һәм кызыклы. Ул кеше исемнәрен, фамилияләрне һәм кушаматларны, күк җисемнәренең, географик урыннарның, мифологик затларның һәм башкаларның исем-атамаларын өйрәнә. Ономастика шундый күпсанлы һәм төрле-төрле исемнәрне җыйнау, туплау, тәртипкә салу, аларның килеп чыгышын, тарихи җирлеген аңлату кебек мөһим бурычларны гамәлгә ашыра.

Без эшебезне үзебез яши торган Сарман авылы эргонимнарын тикшерү максатыннан башкардык. Бурычлар: 1. Сәүдә нокталары һәм төрле хезмәт күрсәтү оешмаларының ялгызлык исемнәрен өйрәнү. 2. Аларны тематик төркемнәргә бүлү. 3. Һәр төркемнең үзенчәлеген ачу. 4. Исем сайлауның төп критерийларын өйрәнү.

Эргоним ике компоненттан тора. Объектның атамасы һәм объектның исеме. Мәсәлән: "Тәмле" кибете, "Дулкын" спорт-сәламәтләндерү үзәге. Әгәр рус теле белән чагыштырсак, анда киресенчә, башта объектның исеме, аннан объектның атамасы килә: магазин "Магнит", чәчтараш "Алтынчәч".

Без аларны төрлечә өйрәнеп төркемләдек. Иң башта төрле функциональ профильгә ия булган оешмаларны барладык һәм аларның ялгызлык исемнәрен өйрәндек. Безнең тикшеренүләрдән күренгәнчә, бүген Сарман җирлегендә 74 эшмәкәр оешма бар. Алар арасында 2 урта гомумбелем бирү мәктәбе, 5 балалар бакчасы, икмәк пешерү, “Сарман суы”, “Сарман мясо” комбинатлары бар. Иң күп санлысы – коммерция предприятиеләре. Бүген Сарман халкына 3 агентлык, 3 банк, 48 кибет, 5 кафе хезмәт күрсәтә. Мәдәният объектлары күп түгел: 1 кинотеатр, 1 мәдәният сарае, 2 китапханә, 2 парк, күңел ачу үзәге бөтенләй юк. Спорт үзәкләре: 1 спорт комплексы, 1 чаңгы базасы бар.

Аларның исемнәрен сүзьясалыш ягыннан тикшердек һәм аларда күбрәк тамыр, ясалма сүзләрне кулланганнарын күрдек. Исем итеп сүзтезмә алынган очраклар да бар.

Атамаларны ясалышы ягыннан, морфологик яктан, лексик-семантик яктан үзенчәлекләрне өйрәндек һәм мондый нәтиҗәләр ясадык: аларда безнең регионга хас үзенчәлекләр чагыла; республикабызда ике дәүләт теле булуын күрсәтә; авылны икътисади һәм мәдәни яктан характерларга мөмкинлек бирә; эргонимнар объектның эстетик ягын, уңай сыйфатларын күрсәтә; ниндидер билгеле бер товар тәкъдим ителүенә, яки аның үзенчәлеген күрсәтүгә нигезләнү бар.

Барлык эргонимнарның чагыштырмасы мондый: функциональ профильне чагылдыра (28 %), кеше исемнәренә нигезләнгәннәре (13 %), оттопонимик (4 %), абстракт исемдәгеләр (55 %).

Без халык арасында сораштыру үткәрдек, анда 100 кеше катнашты, 10 объект турында сүз барды. Һәр объектта 10 кеше белән сөйләшү алып барылды. Җаваплар буенча, сораштырылучылар сорауга җавап биргәндә эргонимның мәгънәви ягыннан, әйтелеш ягыннан, атаманың объектка туры килү-килмәвеннән чыгып фикер йөрткәннәр дигән нәтиҗәгә килдек.

Сораштыруда катнашкан тагын бер катлам объектка аерым тукталасы килә. Бу илкүләмендә киң таралган "Эссен", "Пятерочка", "Тәмле", "Магнит" кебек сәүдә үзәкләре. Алар сораштыручыларда уңай тәэсир уята. Сәбәбе: бу сәүдә йортлары авылыбызны икътисади яктан уңай сурәтли, аның зур шәһәрләр белән тиңдәш булуына ишарәли.Чит ил хәрефләре белән язылган эргонимнарга яшь буын уңай карый, ә өлкәннәр тискәре. Күп вакытта: "Үзебезнең сүзләр беткән микәнни? " дип җавап бирәләр. Кыскартулар да өлкән кешеләргә ошамый. Аеруча "СССР" салоны ("Салон сотовой связи Рашита") хакында тискәре фикерләр күп булды. Яшьрәкләр моны "кызык" дисә, өлкән буын тарихны пычрату итеп кабул итә. Шулай ук эчемлекләр сатыла торган "Сөембикә" кибете турында да шундый фикерләр яңгырады.

Җавапларны туплап, без гомуми нәтиҗәләр ясадык. Сарманда очрый торган эргонимнарга бәя түбәндәгечә бирелә: функциональ профильгә туры килә (30 %), әйтергә җиңел (30 %), матур яңгырый (10 %), милли (10 %), оригиналь (10 %), бистәне бизәп тора (10 %).

Бик күп элмә такталарда атамалар бары рус телендә язылган, татарча исеме бөтенләй күрсәтелмәгән. Бу тел турындагы Законны бозу күренеше. "СССР" кебек салоннарның, "Цезарь" кебек пицетерийларның тәрбияви яктан тәэсире бик начар ясый.

Атамаларга битараф булучылар да күп. Эргонимнар – авылыбызның йөзе. Йортларның матурлыгы, ишегалларының чисталыгы, яшеллеге, юлларның төзеклеге генә түгел, Сарманыбызның үз йөзен, күркәмлеген тудыручы, башкалардан аерып торучы бер үзенчәлек, район үзәгенә бәя бирүче фактор ул. Эргонимнар мәгънәлерәк булган саен, бу авылыбыз халкы турында фикер дә югарырак була дип уйлыйбыз. Шуңа да атамага битараф булырга да, аны сайлауга җиңел карарга да ярамый.

**Әдәбият**


1. Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1995. – 159 б.
2. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: Раннур, 2000. – 455.
3. Гарифуллин Д.Х. Шәҗәрәләр. – Яр Чаллы, 2002. – 159 б.
4. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 167 б.
5. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? // Татар исемнәре сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 189 б.


## ҰЛТТЫҚ ТӘРБИЕНІҢ ОТБАСЫНДАҒЫ МАҢЫЗЫ


*Шуренбаева Э., Батыс Қазақстан инновациялық-технологиялық университеті, философия магистрі*


Қазіргі таңда қоғамда ұлттық құндылықтарды бойына сіңірген саналы тұлғаны қалыптастыру, жас ұрпақты өнегелі, отансүйгіш, ұлтжанды, білімді етіп тәрбиелеу баршамыздың міндетіміз.

Жалпы, адам баласы қоғамда өзінің адамгершілік қасиеттері, қайырымдылығы, адалдығы, әділеттілігімен ардақталады. Қасиеттердің барлығы адамдардың іс-әрекеттері арқылы өлшенеді. Қасиеттерді адам бойына жастайынан қалыптастыру тәрбиеге байланысты, яғни отбасының басты міндеті. Ер баланың қос қолдап ауылдың үлкендеріне сәлем беруі, қыздарға ибалық жасау, үлкеннің алдын кеспеу, «сіз» деген сыпайылықтан аспауының өзі терең мәдениеттіліктің, көрегенді отбасында тәрбие алғандығының көрінісі деп білген. «Адамдықтың белгісі, иіліп сәлем бергені» немесе «кішіпейілділіктен кішіреймейсің» деп үлкен бабаларымыз жастарға үлгі етіп нақыл сөздерін айтып отырған. Отбасының, қоғамның дамуын, бала тәрбиесінің аналарға да тікелей қатысты байланысты екеніне ерекше мән берген. Қыз бала тәрбиесіне де

ерекше көңіл бөлген. «Қыз өссе-елдің көркі» деу арқылы арлы, инабатты қызды тәрбиелеуде барлық ауыл-аймақ болып ат салысуды меңзейді.

Жас ұрпақ тәрбиесі қай кезеңде де күрделі, өзекті мәселелердің бірі болып табылған. Бұл жөнінде өзіміздің тарихымыздағы кемеңгер ойшылдарымыздың тарихынан да байқаймыз. Жас ұрпақты тәрбиелеу ойшылдарымызды да ойландырмай, назар аудартпай қоймаған. Қазақ халқында жастарды, жас ұрпақты тәрбиелеуде өзіндік ерекшеліктері бар. Қазақты көшіп қонған сауаты аз халық деп сырттай баға бергенмен оның мәдениеті мен салт-дәстүріне үңілсек, рухани мәдениеттің тереңдігін байқаймыз. Мысалы, айтыс өнері, жұмбақ, жаңылтпаштар айту. Қазақ халқы арнайы бала мәселесімен айналыспаса да, қоғамдық орындар болмаса да өз ұрпағын бесікте жатқан кезінен бастап өлең-жыр, әңгіме, ертегі, тақпақ, санамақ арқылы тәрбиелеп отырған. Қазақ халқының тәлімдік мәні зор ой толғаныстары бесік жыры мен батырлық эпостарда, ертегілер мен аңыздарда, шешендік сөздер мен айтыс-термелерде, мақал-мәтелдерде көптеп кездеседі. Мұндағы ұрпақ тәрбиесінің негізгі түйіні-адамгершілік, имандылық, ақыл-ой, еңбек, отбасы тәрбиесіне байланысты мәселелерге кеп тіреледі. Халықтың ғасырлар бойы іріктеп алған озық тәжірибесі мен ізгі қасиеттері жас ұрпақ бойына тек тәрбие арқылы ғана дарыған. Қоғамдағы мемлекеттің, ұлттың, мәдениеттің, әдебиеттің, тілдің тағдыры мен болашағы да осы жас өскелең ұрпақтың біліміне, тәрбиесіне байланысты екендігі сөзсіз.

«Отбасы адамның өте маңызды, жауапты ісі. Отбасы өмірді кемеліне келтіреді, бақыт әкеледі, бірақ, әрбір отбасы, ең алдымен мемлекеттік маңызы бар зор іс болып табылады» деп А.С. Макаренко баға бергендей, отбасы қоғамның маңызды буыны. «Отбасы- бұл адамның некелік және туыстық, жалпы тұрмыстық байланысқа және өзара жауапкершілікке негізделген адамдардың бірлігі» [1: 180]. Отбасы адам өмірінде ерекше роль атқарады. Адамның өмірге деген көзқарасын, қарым-қатынасын, мінез-құлқын тәрбие қалыптастырады. Осындай тәрбиенің ең алғашқы бастауын әр адам өз отбасында сезінеді. Мұхтар Арын: – «Қалай десек те ең мықты, табиғи мектеп- отбасы. Осында қалыптасқан барлық жақсы қасиеттер өмір бойына серік болады. Отбасында кеткен қателіктерді ешбір мектеп түзей алмайды...» дегендей әрбір ата-ана өз баласы үшін – үлкен тұлға. Ата-аналар баланы тәрбиелегенде дәл өзіндей етіп тәрбиелеуге тырыспау керек, баланы өздерінен күшті әлдеқайда жақсы етіп тәрбиелеуге тырысу қажет. Өзі жетпеген арманға, өзі алмаған, бағындырмаған асуларды баласы алатындай етуге жағдай жасап еңбек ету керек. Өзі жасаған қателіктерді жасамауын қадағалап отырса снымен қатар өзі алған тәрбиенің жақсы жақтарын өз баласынан көре алуға күш

жұмсауы керек. Себебі, ата-ананың өзі өмір сүріп отырған дәуіріне қарағанда келер заманның талабы жоғары болатынын ескергеніміз жөн.

Пайғамбарымыз (с.ғ.с) хадисінде: «Бір адамның қайыр жолында жұмсаған ақшасының ең жақсысы-отбасына жұмсаған ақшасы», – делінген. Сондықтан да балаларды дұрыстап ішкізіп-жегізіп, өмірлерін баянды ету керек. Тәртіпті де тәрбиелі ұрпақ өсіру-отбасылық өмірдің негізгі мақсаттарының бірі. Отбасының үлгі бола алуы игі ұрпақты тәрбиелеп шығаруда басты роль ата-анаға жүктеледі. Өйткені, өмірінің алғашқы кезеңінде адам қоршаған ортадан бұрын ең жақын жанашырлары ретінде ата-анасын таниды. Солардан үйреніп, соларға еліктейді.

Мағжан Жұмабаев «Тәрбиедегі мақсат – баланы тәрбиешінің дәл өзіндей етіп шығару емес, келешек өз заманына лайық қылып шығару» деген болатын [2: 39]. Ақынның бұлай деуі бала тәрбиесінде отбасының, қоғамның алдында үлкен жауапкершіліктің тұрғандығын айқындайды. Белгілі педагог К.Д. Ушинскийдің «Баланы жан-жақты етіп тәрбиелеу үшін оның өзі алдымен жан-жақты болуы керек» деген ойы шын мәнінде тәрбие мәселесінде ата-ана, отбасының ролін тағы да ерекшелейді.

Белгілі жазушы Ғабиден Мұстафиннің «Ұлттың салт-дәстүрі бүкіл халықты тәрбиелейді» деген ұлағатты сөзі бар. Осыған қарағанда қоғамның ең күрделі де қажеттісі қазақтың бала тәрбиелеу дәстүрі екенін түсінеміз. Яғни әрбір адам ұрпағын ұлтының салт-дәстүр, әдет-ғұрып бай тәжірибе негізінде тәрбиелей отырып, жас буын өз ата-анасының рухани мұрасын игеруі тиіс.

Алдағы мақсатымыз ұлттық сана-сезімі қалыптасқан, ұлттық мүдденің өркендеуіне үлес қоса алатын, ұлттық құндылықтар мен жалпыадамзаттық құндылықтарды өзара ұштастыра алатын толық кемелді, ұлтжанды тұлғаны тәрбиелеу.

**Әдебиет**

1. Айтмамбетова Б., Бозжанова К. Балаларды семьяда адамгершілікке тәрбиелеудің кейбір мәселелері. – Астана, 1985. – Б. 180.

2. Жарықбаев Қ., Қалиев С. Қазақтың тәлім-тәрбиесі. – Алматы: Сана, 1995. – 81 б.

## ЭЧТӘЛЕК

**Вступительное слово**........................................................................................ 3
**Аббазова Р.** Межъязыковые омонимы………………………………………….. 5
**Абейдуллова А.Т.** Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында этнографизмнардан файдалану үзенчәлекләре.................................................... 6
**Абулсағит А.** Тарихи жырлардағы айшықтау мен құбылту үлгілері................ 8
**Аглетдинова Э.** Особенности передачи национально-культурного колорита в поэмах......................................................................................................... 11
**Азизова Р.** Татар телендә кешенең яшь үзенчәлекләрен чагылдыра торган фразеологик берәмлекләр.......................................................................... 13
**Айзатуллова И.** Татар әдәбиятында экологик тәрбия........................................ 15
**Айқын Г.** І. Жансүгіров шығармалдарының көркемдік ерекшелігі.................. 18
**Акабаева М.** Қазіргі қазақ медиа-мәтінінің прагматикалық ерекшелігі........... 20
**Алимбаев А.** Рухани жаңғыру – мәңгілік ел негізі............................................ 23
**Артемьева А.** Лексика материальной культуры в чувашском и татарском языках. 25
**Арын Р.** Культурная идентичность как основа тюркской цивилизации 27
**Arykkarakızıe L.** Şaire gülay sormageç'in çocuk şiirleri ve onun bazi özellikleri... 30
**Ахметзянова А.** Сопоставительный анализ роли окончаний в имени существительном на примерах русского, татарского и английского языков……….. 34
**Әбілқасымова М.** Қазақ әдеби тілі тарихындағы әлеуметтік ағым негіздері... 36
**Әбрарова А.** Казан шәһәренең антропологик атамаларга нигезләнгән урам исемнәре....................................................................................................... 38
**Әнуарбекова А.** «Семей таңы» газеті: тақырыптық және тілдік-стильдік ерекшеліктер.............................................................................................. 40
**Әсхәдуллина Г.** Татар телендә «ана» лексемасының чагылышы...................... 42
**Әхмәдиева Й.** Әдәбият һәм сәнгать бәйләнеше: Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасына ясалган иллюстрацияләр................................................ 45
**Әхмәтгәрәева Г.** Фэнтези әсәрләрен төрки телләргә һәвәскәри тәрҗемә итү мәсьәләсе.................................................................................................. 47
**Әхмәтова Л.** Милли характер − батырлык чыганагы........................................ 49
**Баһавиева Ч.** Татар халык сынамышларында парлы сүзләр............................ 51
**Begimtayev Ch**. Kurbangali halidi'nin hayatı ve toplumdaki yeri………………… 54
**Болгарова А.** Роль междометий в фразеологическом фонде татарского и английского языков..................................................................................... 56
**Валеева Э.** Тюркизмы в ранней лирике С. Есенина…………………………….. 58
**Вәлиева А.** Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында көнчыгыш романтизмы..... 60
**Вәлиева З.** Зооним компонентлы чагыштыруларның ясалу ягыннан төрләре... 63
**Вилданова Ә.** Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында һәм аның рус теленә тәрҗемәсендә синонимнар................................................................... 64
**Вилданова И.** Урта мәктәптә табышмакларның өйрәнелеше............................ 67
**Вотякова А.** Роль проекта «Возвращение к истокам» в формировании этнокультурной компетентности студентов……………………………………….. 69
**Габбасова А.** Көркем мазмұндағы әлеуметтік өмір көрінісі.............................. 71
**Габдрәшитова А.** Хәй Вахит драмаларында фольклор..................................... 74
**Габдуллин Р.** Г. Сабитов хикәяләрендә образ тудыру үзенчәлекләре................ 76
**Габидуллина Э.** И. Юзеевның башлангыч чор иҗатында поэма жанры........... 78

**Газиева А.** Шәриф Камалның «Буранда» хикәясендә әдәби урын һәм вакыт бирелеше 80
**Газизова И.** Чыңгыз Айтматовнын «Бер көн – бер гомер» романында һәм аның татарчага тәрҗемәсендә реалияләр бирелеше........................................ 82
**Гайнутдинова А.** Татар телендә фин-угор алынмалары.................................. 85
**Гайфуллина И.** Туган тел дәресләрендә җирле ономастик материал куллану 86
**Гайфуллина Л.** Мәктәп курсында Г. Тукай иҗатын өйрәнү технологияләре... 89
**Галиева А.** Әдәбият дәресләрендә Мәхмүт Хәсәновның иҗатын һәм «Язгы аҗаган» романын өйрәнү: тарихи яссылык һәм бүгенге алымнар...................... 91
**Галимова Г.** Речевые обращения в языковом этикете татарской этнокультуры….. 93
**Галимова Д.** Лилия Гыйбадуллина иҗатында образлар бирелеше.................... 95
**Галиуллина Г.** Луиза Янсуар шигъриятенең теле һәм стиле………………….. 98
**Галлямова А.** Фразеологические единицы с семантикой цветообозначения в русском и татарском языках……………………………………………………… 100
**Гарипова Р.** Татар телле телевидение: барлыкка килүе һәм үсеш этаплары..... 102
**Гарифуллина А.** Тарихны шәхесләр ясый....................................................... 104
**Гарифуллина Э.** Хәсән Туфанның башлангыч чор иҗатында поэма жанрының үзенчәлеге.......................................................................................... 107
**Гатина А.** Гомуми белем бирү оешмаларында эндәш сүзләрне кабатлаганда кулланыла торган эш төрләре.......................................................................... 109
**Гафурова И.** Туган төбәк микротопонимиясенә күзәтү.................................... 111
**Гәрәева Ә.** Муса Җәлил иҗатында юмор.......................................................... 113
**Гомәрова Д.** Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ендә төс компонентлы чагыштыруларның ясалыш ягыннан төрләре.................................................... 116
**Губайдуллина Л., Джоан Себастьян Гарридо Пинилья.** Сопоставительный анализ пословиц в разноструктурных языках…………………………………… 117
**Гыйздәтуллина Н.** Сәгыйть Сүнчәләй иҗатында дини мотивлар..................... 120
**Гыйззәтуллина А.** Лексикада төрки һәм фин-угор тәэсир итешүләре............... 123
**Гыйлметдинова А.** Хәзерге татар телендәге гарәп-фарсы һәм рус-европа алынмалары язылышында вариантлылык......................................................... 125
**Гыйлмуллина Д.** Татар һәм төрек телләрендә сыйфат фигыль формаларын куллану................................................................................... 127
**Гыймадиева Г.** Татар һәм төрек телләренең фонетик үзенчәлекләре............... 129
**Гыйрфанова Л.** Фәүзия Бәйрәмованың «Һиҗрәт» романында һиҗрәт сүзенең лексик составы.................................................................................... 131
**Давтян К.** Идиомы и фразеологизмы в английском, русском и татарском языках.. 133
**Дәүләтшина Э.** Урта мәктәпнең 5 нче сыйныфында Мөдәррис Әгъләмов иҗатын өйрәнү үзенчәлекләре......................................................................... 135
**Долгова Л.** Татар халкының традицион мәдәниятенә багышланган дәрестән тыш чаралар...................................................................................................... 137
**Ермағанова М.,** Жолдасбекова З. Оразгүл Нұрмағамбетованың мұрасындағы казақ-мажар әдеби байланыстары................................................ 140
**Ерошина Ю.** Ежедневное приветствие и этикет встречи в процессе межкуль-турной коммуникации в английском и русском языках………………………… 143
**Жанысбаева А.** Жаһандану жағдайындағы аймақтық басылымдардың құрылымы 145
**Җамалетдинова Д.** Татар телендә гарәп-фарсы чыганаклы хокук терминнары 148
**Җәләева Г.** 5 нче сыйныфларда татар теле дәресләрендә сәламәтлек саклау

технологиясен куллану үзенчәлекләре................................................................. 150
**Жиркова Ю.** Саха уонна казах омуктарын гендернэй суолталаах өс хоһоонноро 152
**Жорабек З.** Шаңырақтың символдық семантикасы............................................. 154
**Жұрнаш А.** Қазақ ертегілерінің зерттелу тарихы............................................... 160
**Закирова А.** Фәнис Яруллин шигырьләрендә антонимнар.................................. 163
**Закирова М.** Роберт Миңнуллин һәм Фаварис Галиев иҗатында охшаш яклар...... 165
**Зарипова Г.** Г. Гыйльмановның «Йорт иясе» хикәясендә мифологик мотивлар..... 167
**Зарипова Д.** Ф. Яхин хикәяләрендә кош образының тәрбияви әһәмияте...................... 170
**Зарипова Җ.** Татар һәм башкорт реклама слоганнарының кайбер лингвистик үзенчәлекләре.................................................................................. 171
**Зейнолова Г.** Шәкәрім және мәшһүр – Жүсіп Көпейұлы лирикасының еуропалық жанр үлгілері бойынша жіктелуі........................................................ 173
**Зиннатуллина Г.** Отрицательный образ женщины в фольклоре сибирских татар: лингвокультурологический анализ…………………………………………... 177
**Ибләминова З.** Хәзерге татар сөйләм теленә өйрәтү мәсьәләләренә карата...... 179
**Ильясова Ә.** Балаларның аңын, акылын, рухи-әхлакый сыйфатларын сөйләмдә чагылдыру һәм аны үстерү шартлары.................................................. 182
**Искакова А.** Қазақ әдебиетіндегі портрет жанрының дамуы............................ 184
**Исхакова Г.** Лексические переводческие соответствия в переводах поэзии А. Ахматовой на татарский язык......................................................................... 186
**Кабирова А.** Татарский образовательный портал «Әлбәттә» как инфокоммуникационная среда………………………………………………………………… 188
**Кабирова С.** Фразеологизмы заболотных татар с компонентом-соматизмом *күс* «глаз», образованные на базе формул зложеланий...................................... 190
**Кабышева Р.Б.** Специфика употребления русского языка в казахстанских СМИ 192
**Каваклы М.** Оқушылардың тілге құндылық бағдарын қалыптастырудың лингвомәдениеттанымдық маңызы..................................................................... 195
**Кадырова Г.** Гүзәл Яхинаның «Зулейха открывает глаза» әсәре һәм аның татарча тәрҗемәсендә реалияләрнең бирелеше................................................... 197
**Кайдарова Б.** Рухани мәдениеттің квазистереотиптік мәні............................... 199
**Калимуллина А.** XX гасыр башы татар театры тәнкыйтендә Гаяз Исхакый пьесалары 201
**Кәлимуллина Г.** Ә. Баяновның «Зәңгәр кыңгыраулар» пьесасы....................... 203
**Кәпұлы Д.** Ақыт шығармашылығындағы зар заман сарыны............................. 205
**Кәримова А.** Яхъя хәзрәт Сәфәргалинең «Васыятьнамә»сендә уку-укыту мәсьәләләре 207
**Кәримова И.** Татар телендә рәвешләрнең үзенчәлекләре.................................. 209
**Кәрімхан З**. Жазушы Қ. Жұмаділовтің өмірі мен шығармашылығындағы «Жылау және жылату» философиясы............................................................... 211
**Кожанова Н.** Тіл мен сөйлеу аясында көрініс табатын сөздің коннотациялық мағынасы............................................................................ 214
**Қожахметова Г.** «Оқу мен жазу арқылы сын тұрғысынан ойлауды дамыту» технологиясын қолдану арқылы оқушылардың сөз мәдениетін қалыптастыру 218
**Кольчанова Ю.** История школы – это история страны...................................... 221
**Куакалова Г.** Мин үземнең нәселем белән горурланам...................................... 223
**Латипова Ч.** Ф. Әмирханның «Хәят» повестен өйрәнү үзенчәлекләре............. 225
**Лотфуллина Г.** Г. Тукай әдәби музееның шагыйрь исемен мәңгеләштерүдәге роле 227
**Мананова М.** Мәктәптә дифференциаль якын килеп укыту алымын куллану 229

**Мәрданова З.** Татар теле дәресләрендә уен технологиясен куллану................. 231
**Мингалеева А.** Этикет татарского застолья в селе Токаево…………………… 233
**Минзина Н.** Төрки телләрне өйрәтүдә яңа технологияләр................................ 235
**Мисбахова С.** Матур әдәбият әсәрләрендә фразеологик берәмлекләрне тәрҗемәдә бирү.................................................................................................. 237
**Михайлишина А.** Татар һәм инглиз телләрендә мактау-хуплау сүзләренең кулланылышында охшаш һәм аермалы яклар.................................................... 239
**Мөбарәкшина Л.** Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында тәнкыйди фикер йөртү технологиясен куллану.................................................. 241
**Мөхәммәтвәлиева Ф.** Татар һәм башкорт телләрендә «йөрәк» концепты белән ясалган эмотив фразеологик берәмлекләр................................................. 243
**Мөхетдинова А.** Ырымнар – буш сүз генә түгел................................................ 245
**Муллахметова Л**. Миграцион сүзләр……………………………………….... 247
**Мунадиева М.** Әсәрдә этномәдәни лексиканың роле........................................ 249
**Мухаметова Г.** Фольклорные средства языка в повести М. Карима «Долгое-долгое детство» и их использование на уроках родного башкирского языка… 251
**Мүрсәлім Г.** Ақындар шығармашылығындағы мифтік сарын.......................... 254
**Наби А.** Газет тақырыптарын зерттеудің аспектілері........................................ 257
**Назимкина А.** Сравнительный анализ русских и турецких пословиц о любви 259
**Нигматуллина М.** Переключение кода, смешение кода: история вопроса…... 261
**Нургалиева Җ.** Равил Бохараев – милләтебез горурлыгы…………………... 263
**Нурмөхәммәтов Ф.** Сүзлекләр һәм аларның җәмгыять тормышындагы роле 265
**Нурмухаметова А.** О сущности этнокультурного образования........................ 267
**Нуэрсяти Н.** А. Пушкинының «Капитан кызы» әсәренең кытай һәм уйгур телләренә тәрҗемәләре турында......................................................................... 269
**Нуэрсяти Х.** Уйгур телендә яулык атамалары.................................................... 272
**Нұрғали Р.** Көркем прозадағы шыңғыс хан бейнесі.......................................... 274
**Пазюкова И.** Нәкый Исәнбәт иҗатында фольклор традицияләре..................... 277
**Покушева М.** Фразеологизмы с компонентом «ветер» в русском и татарском языках: лингвокультурологический комментарий……………………………… 279
**Раимова Э.** К проблеме исследования национальной культуры: характеристика, структура……………………………………………………………… 281
**Рамазанова Г.** Ф. Яруллин прозасында «балалар дөньясы»…………………… 283
**Рахымбай Ж.** Түркі тілдеріндегі сөздердің байланысу тәсілдері туралы көзқарастар 286
**Ризванова А.** Мәктәп дәреслекләренә кертелгән хикәяләр аша табигатькә сак караш тәрбияләү.................................................................................................. 292
**Сабирҗанова Д.** Татар телендә белем бирү оешмаларында әдәби-тәнкыйди материалны укыту технологияләре........................................................................ 295
**Сабирова Э.** Прагматонимар ярдәмендә фонетика кагыйдәләрен өйрәтү үзенчәлекләре 296
**Сабитова З.** Туган телгә өйрәтүдә ММЧ роле..................................................... 298
**Сабитова Л.** Халык җырларында үсемлек атамалары........................................ 300
**Саглам З.** Татар һәм төрек телендәге мәкальләрдә хатын-кыз образы.............. 303
**Садрова Л.** Татар телендә ир-ат матурлыгын сурәтли торган лексик берәмлекләр.............. 305
**Садыкова Р.** Алаш ұранды «Сарыарқа» және Халел Ғаббасұлы...................... 307
**Саламова И.** Межъязыковая и межкультурная коммуникация на уроках истории и обществознания.......................................................................... 309

**Салахова А.** Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында тирәлек һәм герой каршылыгы........................................................................................ 311
**Сарин К.** К вопросу об идентичности и этнических стереотипах кочевников Евразии 313
**Сатбай Ж.** «Уыз» лексемасының қолданылу ерекшеліктері.............................. 316
**Сәйфетдинова Д.** Гомәр Бәширов әсәрләрендә фольклоризмнар...................... 318
**Сәйфетдинова Л.** Татарча һәм төрекчә зоонимлы мәкальләр тәңгәллеге.......... 320
**Сәлахова А.** Ф.С. Сафиуллинаның «Текст төзелеше» хезмәтенә күзәтү........... 321
**Серікжан Н.** Қазақ әліпбиін латын графикасына көшіру мәселесі..................... 323
**Серикова А.** Фразеологизмы в описание характеристики и психологического состояния персонажа…………………………………………………………………… 326
**Сибагатуллина А.** Бүгенге шигъриятtә диалекталь сүзләр............................... 328
**Сибгатуллина М.** Творчество Фатиха Карими: религиозно-просветительская особенность эпохи...................................................................................................... 330
**Сиразова С.** Әлки районында җыелган мөнәҗәтләр текстында дини лексика 332
**Слепова А.** Татар, рус һәм инглиз телләрендә сыйфат дәрәҗәләренең үзенчәлекләре һәм аларны чагыштырып өйрәнү................................................... 335
**Софронеев П.** Влияние цивилизации на традиционную культуру охоты у сибирских тюрков (тувинцы, якуты)……………………………………………….. 336
**Султанова А.** «Егемен Қазақстан» газеті көтерген сыртқы саяси мәселелер.... 338
**Сыламхан Е.** «Майтри симит ном бітік» қолжазбасы: нұсқалары мен олардың құрылымы.................................................................................................... 340
**Тимерханова И.** Мәкальләрдә «гаилә» концепты................................................ 343
**Тимофеева Т.** Фоат Галимуллинның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә Гаяз Исхакый иҗаты.......................................................................................................... 345
**Тукаева Э.** Мөхәммәт Мәһдиевның «Без – кырык беренче ел балалары» повестендә һәм аның рус теленә тәрҗемәсендә реалияләрнең бирелеше.................. 347
**Турсынханова К.** Шәкәрім шығармашылығындағы аударма мәселесі............ 349
**Тұяқбаева Ж.** Мақал-мәтелдердің этномәдени сипаты...................................... 352
**Узбәкова Д.** Татар мәктәпләрендә укучы татар балаларына хәзерге прозаны А.Яхин методикасы буенча өйрәтү....................................................................... 355
**Фазылҗанова Г.** Татарстанда гастрономия туризмы.......................................... 357
**Фатыйхова И.** Һади Такташ поэзиясендә ачлык күренеше чагылышы............. 360
**Фәсхиева З.** XX–XXI гасыр сүзлекләрендә чәй ризыклары атамалары............. 362
**Фәттахова А.** XX гасыр башы татар әдипләре иҗатында театр мәсьәләләре.... 364
**Хадиева И.** З. Хәкимнең «Телсез күке» пьесасында шәхес һәм система каршылыгы 367
**Хайруллина А.** Историко-лингвистический анализ двуязычных словарей XIX века 369
**Хасанова А.** Тюркские истоки и стилистические особенности украшений в комплексе костюма кряшен………………………………………………………… 371
**Хафизова Я.** Мөслим төбәге татарлары сөйләменең кайбер фонетик үзенчәлекләре 373
**Хәйруллина Д.** Татар халык җырларында гөл сүзе............................................ 375
**Хәмидуллина Л.** Мәктәптә уку-укыту системасында проектлар методын куллануның методик традицияләре......................................................................... 377
**Хәмитова Н.** Аяз Гыйләҗев – журналист............................................................ 380
**Хисамеев Р.** Татар телендә атна көннәре атамаларының кулланылышы.......... 382
**Хисияма Ю.** Чуаш теленең тартым формалары.................................................. 384
**Хөҗҗәтова С.** Р. Миңнуллинның «Кышкы кич» шигыре.................................. 387

**Шакирова Г.** Шәүкәт Галиев шигърияте җырларда........................................... 389
**Шамсутдинова Г.** Образы матерей в произведениях Ч. Айтматова «Материнское поле» и М. Карима «Долгое-долгое детство»....................................... 391
**Шаһабиева Й.** Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятында хатын-кыз образлары бирелеше 395
**Шәйхетдинова З.** Роберт Миңнуллин иҗатында әхлак темасы......................... 397
**Шәнгәрәева А.** Татар һәм башкорт тел белемендә авазлар чиратлашуының өйрәнелү тарихы........................................................................................... 399
**Шәнәр С.** «Ләһҗәи татари» сүзлегендеге һөнәр атамалары.............................. 401
**Шәрипова З.** Сарман авылы эргонимнары.......................................................... 403
**Шуренбаева Э.** Ұлттық тәрбиенің отбасындағы маңызы.................................. 405

*Научное издание*

**ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ**
**Материалы X Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов**
**Казань, 20–21 февраля 2019 г.**

**ТӨРКИ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ:**
**ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАР**
**Гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында укучыларның X Халыкара фәнни-гамәли конференциясе материаллары**
**Казан, 20–21 февраль, 2019 ел**

**TURKIC LINGUISTIC CULTUROLOGY:**
**PROBLEMS AND PERSPECTIVES**
**The proceedings of the X International Scientific and Practical Conference for pupils, undergraduate and postgraduate students**
**Kazan, 20–21 February, 2019**

Подписано в печать 12.02.2019.
Бумага офсетная. Печать цифровая.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л. 24,06
Уч.-изд. л. 25,75. Тираж 100 экз. Заказ 72/2

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
Тел.: (843)233-73-59, 233-73-28